# КАЗАН УТЛАРЫ

11.1993



## Мөдәррис Әгъләмов

### Ә без — исән!

Без —
тапталган
һәм сытылган
һәм изелгән халык;
Шул хәлдә дә калып кара
милләт була алып!..

Шул хәлдә дә кара әле
Син аякка басып,
Нинди генә йодрыкларны
Татымады касык.

Уйладылар: инде күптән
беткәндер дип, бөер.
Ә без — исән,
Ә без — милләт,
күкрәгеңне киер!

— Әлхәм шөкер, җилкәм чокыр,
Күкрәгем киң,— диген,—
Бөтен тиңнәр арасында
Мин кемнән ким,— диген.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**(853)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

РАФАИЛ. Язмыш. *Шигырьләр* . . . 3
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Йөгез, бер дога! *Роман-хатирә* . 7
С. БАТТАЛ. Төрле еллардан. *Шигырьләр* . . . 94
Н. САФИНА. Эх, сүз кирәк... *Шигырьләр* . . . 100
С. ЗЫЯЛЫ. Гаеп. *Шигырьләр* . . . 105
Б. РАФИКОВ. Хәтер. *Шигырьләр* . . . 126
С. РӘХМӘТУЛЛА. Бездән соң да... *Шигырьләр* 128

ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

М. ӘГЪЛӘМ. Атадан бала яшь кала . . . 107
Р. КУТУЙ. Хикәяләр . . . 111

ТАРИХ ҺӘМ СӘЯСӘТ

Б. СОЛТАНБӘК. Сикәлтәле юлдан — бәйсезлеккә 133

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. НИЗАМИЕВ. Барлык илләрнең татарлары, берләшегез! . . . 139

АЛТЫН УРДАГА 750 ЕЛ

И. ТАҺИРОВ. Алтын Урда һәм «Идегәй» дастаны 145
М. ГАЛИЕВ. Әрем исе әрнүле . . . 148

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Т. ӘЙДИ. Хәзинәләр уртак *(Төрек-татар бәйләнешләре)* . . . 156

ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ

Б. КАДЫЙРОВА. Чын әдәбият ул искерми! . . . 171
Ә. НИЗАМЕТДИНОВ. Хатлар яздым утырып . . 173

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ГАЙНЕТДИНОВ. «Мөртәт социалист» шигыре . . . 177

СӘНГАТЬ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Чын безнеңчә матур, милли... 180

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Рөстәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

**Индус Таһиров**

**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*

**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман-воспоминание А. ГИЛЯЗОВА; стихи РАФАИЛА, С. БАТТАЛА, Н. САФИНОЙ, С. ЗЫЯТДИНОВОЙ, Б. РАФИКОВА, С. РАХМАТУЛЛЫ.
«К 90-летию А. КУТУЯ»: статья М. АГЛЯМОВА, рассказы Р. КУТУЯ. «История и политика»: статья Б. СУЛТАНБЕКОВА «Тернистый путь к суверенитету»
«Публицистика»: статья Р. НИЗАМИЕВА «Все татары мира, соединяйтесь!»
«К 750-летию Золотой Орды»: статьи И. ТАГИРОВА «Золотая Орда и дастан «Идегәй» и М. ГАЛИЕВА «Горький запах полыни».
«Истории культуры»: статья Т. АЙДИ посвящена турецко-татарским отношениям.
«Дискуссия»: статьи Б. КАДЫЙРОВОЙ и А. НИЗАМУТДИНОВА о проблемах современной литературы.
«Литературная критика»: Статья М. ГАЙНУТДИНОВА о судьбе одного стихотворения Ш. Бабича.
«Искусство»: статья Г. ЗАЙНАШЕВОЙ посвящена 55-летию Татарскому государственному ансамблю песни и танца.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сабантуй» — музыкально-хореографическое выступление Татарского государственного ансамбля песни и танца; известный писатель Р. Кутуй.

**• Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.**

**• Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**

**• Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.**

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 1.10.93 ел. Басарга кул куелды 28.10.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 000. Заказ Я-613. Бәясе 30 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.



## Рафаил

### Язмыш

Тагын безнең язмыш чәбәләнә
Мәкерләрнең канлы учагында,
Күмелмәде микән иманыбыз,
Помпей сыман, көлләр кочагында?
Җанда ничә гасырларның көле?!
Тарихларда көлләр мең катлам.
Үпкәләрдә дога эзе иде,
Һәм яшисе гомер — бер саплам.
Язмыш-кыршау кыскан йөрәкләрне,
Кара каннар сауган йөрәкне
Атлар койрыгына тагып чапты,
Лашманчылар итеп сөйрәтте.
Себерләрдә безнең гомерләр дә
Пычкы чүбе булып сибелгән,
Пычкының бер сабын без йолыктык,
Себер тартты иkenчесеннән.
Язмыш Болгар җирен телем-телем
Кисеп, телгәләде бәгырьне,
Бульдозерлар телем-телем телде
Ханнар зиратында каберне.
Безгә ялгыйсы шул телемнәрне,
Дәвалыйсы канлы бәгырьне,
Терелтәсе, аннан уятасы,
Җир шарының бөтен почмагында
Безгә рәнҗеп яткан каберне.
Офыкларда язмыш чәбәләнә
Теткәләнеп беткән әләмдәй.

---

Рафаил ГАЗИЗОВ (1947) — *шагыйрь, берничә китап авторы. Мамадыш районы Кече Кирмән авылында яши.*

Тарих кайтавазы якынлаша
Каны тамып очкан сәламдәй.

*
* *

*Рифкать Закировка*

Җемелдәүче якты тәрәзәләр
Очкын булып куна күзләргә,
Поезд, Зингер машинасы кебек,
Шпалларны тегә үрләргә.
Гүләп ала дөнья колакларда,
Гасырларның өне шикелле.
Дошман, хакыйкатьне вагоннарга
Төяп, себерләргә китерде.
Хәтер — юеш селекозлы шахта,
Хәтер басаауган агач күк,
Хәтер кыршау булып башны кыса,
Көне-төне кыса палач күк.
Себер картасына кулны куйсам
Бармак арасыннан кан тама,
Вагон-вагон җинаятьләр кайта,
Кире кайта Кызыл мәйданга.
Йөрәкләрдән аккан каннар микән
Һәр ташында тора беленеп?
Шуңа, ахры, кояш нуры төшми,
Гөмбәзләргә кала эленеп.
Сугым тагарагы булган мәйдан,
Әле дә сугымчылар азмы анда?
Сугым мәйданы шул, һәм әйләнгән
Исеме дә — Кызыл Мәйданга.

## Монда авыл булган

Монда авыл булган. Бу чокырлар —
Үзәк өзгеч йөрәк авазы.
Аумый калган капка баганасы
Нәфрәт булып тишкән һаваны.
Ул багана шырпы булып кергән
Чорыбызның тырнак астына.
Әй сызлана күңел, үрсәләнә,
Дәва таба алмый ярсуга.
Шайтан таяклары, тигәнәкләр
Баскан ил картлары каберен,
Бу авылдан качкан кешеләрнең
Тигәнәкләр баскан бәгырен.
Шушы җирнең кычытканын ашап
Исән калган уллар, кайда сез?!
Бу ташландык авыл — сезнең зират.
Сезгә дәшү, беләм, файдасыз.
Исән килеш сез күмелгән монда,
Тигәнәкләр — сезнең каберда.
Исемен җуя авыл! Бу фаҗига

Инә булып чәнчи бәгырьгә!
Дөньядагы иң кызганыч җирләр —
Кеше ташлап киткән авыллар:
Кеше киткән, песи, этләр киткән,
Хәтта керми уза давыллар.
Җырлар, якты уйлар, чишмә киткән,
Тик каеннар китә алмаган.
Каеннарны тамыр җибәрмәгән,
Тамыр — өзелмәскә ялганган.
Ә кешеләр үзә тамырларны,
Ялганмаслык итеп өзәләр.
Каеннардан гыйбрәт алсак икән,
Алар кала, алар түзәләр.
Алар кала. Каян белсен каен
Мондый хыянәтнең киләсен?
Бу каеннар белән авылның да
Беләм изге исеме үләсен.
Соңгы теләк тели бу каеннар,
Теләкләре — бәгырь сызлавы:
— Давылларга түздек, ялгызлыкка,
Хыянәткә түзеп булмады.
Хет бер килеп сүгенсеннәр иде,
Йә киссеннәр — без бит өч кенә.
Кешеләрнең хыянәтен каплап,
Авар идек авыл өстенә.

## Очып бара

Кол Шәриф[1]нең кылыч тоткан кулы
Күктә оча, очкан өзелеп,
Без кол булган гасырларны турый,
Зынҗырлары кала өелеп.
Кол Шәрифнең кулы очып бара,
Кылыч түгел, яшен уйнатып,
Мәрткә киткән иманнарга суга,
Каберләрне китә уятып.
Кол Шәрифнең кулы очып бара,
Китапларның җанын тойган кул,
Кылыч белән түгел, каурый белән
Гасырларның сынын койган кул.
Кол Шәрифнең кулы очып бара,
Зыялы кул, дога укыган,
Кеше кыйбласының изге ае —
Намус аңа кылыч тоттырган.
Кол Шәрифнең кулы очып бара,
Эзли күмеләчәк каберен,
Белмидер шул күптән җирләнгәнен
Үзәгенә минем бәгырьнең.
Дүрт-биш гасыр яулый бу изге кул
Азатлыкның якты таңнарын,
Канлы йодрыгында зөлфәкарьмы,
Соңгы азанымы Казанның?!

---

[1] Кол Шәриф — атаклы дин галиме, сәет, шагыйрь; 1552 елның 15 октябрендә урыслар Казанны алган көнне, кулына кылыч тотып сугышканда, китапханә бусагасында туракланa, кабере билгесез.

## Хатирәләр

Артта еллар кала, идәндәге
Купкан сайгак кебек шапылдап.
Хатирәләр борчый, тәрәзәгә
Бәргән ботак кебек шакылдап.
Хатирәләр койма аша төшкән
Исерек күк ишек кагалар,
Баш төзәтеп кенә чыгып китми,
Чиләк-чиләк канны савалар.
Хатирәләр, ялгышларым булып,
Яңагыма китереп сугалар,
Сугалар да, аннан намусымны
Танк кебек таптап узалар.
Хатирәләр, сөйгән ярлар булып,
Эреп ята кайчак куенда.
Һәм аларның күпме хыянәтен
Таш күк асып йөрим муенда.
Хатирәләр — мине сырхау иткән,
Газаплаган күңел саулыгым.
Бурыч диңгезендә коендырган
Һәм бөлдергән иң зур байлыгым.

## Мин

Мин дөньяны кочам. Һималае
Кулларыма коя ак карын,
Һималайның чыңлы кыясына
Бәйләп куйдым шигырь тулпарын.
Мариан иңкүлеге төпләреннән
Алып менеп энҗе бөртеген,
Зөһрә кызның калфагына тездем,
Әйтте: — Төсең итеп йөртермен.
Сөйләп тормыйм сезгә Зөһрә белән
Булган гыйшык-мыйшык турында.
Тиешсезне сөйләп йөргәннәрне
Җир күп йотты тигез урында.
Мин дөньяны кочам. Урманнары
Әти яңагыдай тырмыйдыр.
Мин бит әтиемне хәтерләмим,
Миңа болай әйтеп булмыйдыр.
Мин дөньяны кочам. Океаннары
Кысылып-кысылып куя йөрәк күк,
Җир шары да сулый, яралана,
Кеше кебек икән, кирәк бит.
Мин дөньяны алам кочагыма,
Кемнәр белер аның кадерен?
Иркәләүгә беркем чыдый алмый,
Сулык-сулык елый бәгырем.

## Китеп барырсың

Минем гомер яз көнендә эреп
Һаман кими барган кар сыман,
Метеор күк очкан мизгелләре
Арасында гасыр бар сыман.
Вакыйгалар язгы кар күк тыгыз,
Якыная бара заманнар,
Өреп кабартылган шар шикелле
Шартлый — хәтта илләр, ялганнар.
Язгы кар шикелле минем гомер,
Кимегән саен арта кыйммәте,
Язмыш һәр мизгелнең күкрәгеннән
Яшь бозау күк имчәк эзләтте.
Язгы кар шикелле кими гомер,
Гөрләвектәй чыңлый язмышым.
Мин каенда бөре булып калам,
Ә син, гомер, китеп барырсың.



Казан утлары
китапханәсе
Аяз Гыйләҗев
Йәгез, бер дога!



## Аяз Гыйләҗев

# ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА!

РОМАН-ХАТИРӘ

Без дүртебез дә яшьтәшләр идек. Лагерьда: «Нигә утырттылар?»— дип сорашу, кызыксыну юк, ярамый да, әмма яшьтәшләр арасында сер каламыни?.. Егетләр Карабаска тап булганчы икеөч елны үз тирәләрендәге «совет утарларында» үткәргәннәр. Себер бит, аңа мең вә миллионнар сыя... «Ерткыч иде безнең колхоз рәисе, котырган бүре, туймас аждаһа иде! Ялгышып кырын күзең белән карасаң да, чәйнәп-өзеп ташлый иде! Хатыннар ялгыз баштан йөрергә куркалар, тышка чыкканда да карчык-корчыкны ияртәләр иде. Ничек көче-гайрәте җиткәндер, авылдан берәүне дә кыз килеш ычкындырмады! Язу-мазар кирәк икән — астына ят. Паспорт бары кызлыгын җәлләмәгәннәргә генә эләкте! Әни минем чибәр, сылу!.. Мин бердәнбер бала. Хәер, апам булса, ни ярдәме тияр иде? Рәис аналы-кызлы янәшә салып, кыерларга үлеп ярата иде! Яман эчә үзе! Килә, хуҗа булып түргә уза. Әнине чишендереп туңкайта, акырып-бакырып өерли... Менә, тешләремне кара: вакланып-чәрдәкләнеп беткәнгә ул! Әни түзәргә куша, бәләкәй чак, түзәсең! Тешләр шунда чәрдәкләнде, ныгымаган тешләр... Көзге дөм караңгы төндә капкадан кергәнен сагалап торып, әтинең ау мылтыгы белән күкрәгенә терәп аттым!.. Исән чагында авылның бөтен хатын-кызы зар җылады. Ә үтергәч, менә гаҗәп, авыл хатыннары шул ата этне сагыналар икән... Миңа беркем хат язмый, әни дә... Үтергән өчен ул да каргады!»

Бу сүзләрне тимер тәнле, кырыс Пермяков күз яшьләренә манчып сөйләде. «Хат алмагач, авыл хәлләрен каян беләсең?»— дип сорамыйча түзә алмадым. «Күршебездә бер кыз бар иде, яшьтәш, гарип бичара, ике аягы да йөрми... Мәктәпкә бара алмады, үзлегеннән укыды. Үтә дә акыллы сылу бала инде! Шул гына миңа яза хатларны. Авыл хәлләрен сөйләп, белдереп тора. Хуродзе әйтә: «Кайтасыз!»— ди! Әгәр исән-сау

Дәвамы. Алдагы өлеше журналыбызның 10 санында чыкты.

авылга кайтсаммы... Ә мин барыбер кайтачакмын! Күзләренә кылчык булып кадалып яшәячәкмен! Әнә шул гарип Аннушкага өйләнәм дә кабергәчә шунда яшим. Теге кабахәтнең кабере өстенә барып баш очына чәптерәсем килә!»

Моны сөйләп бетергәндә Пермяковның чыраена туры карарга куркыныч иде. Егетнең киеменә сыймаган чиксез көче, калкан-калкан күкрәге, ачлык та йомшарта алмаган корыч беләкләре хәрәкәтләнәләр, күзенә күмер төшеп, зәһәр утлар кабынып елтырый, ирен читләре күбекләнә...

Сабырлыгы, сүзсезлеге, ныклыгы өчен мин Мишаны яратсам да, бригадирыбыз Хохун аны өнәмәде. Үзе дә чамасыз көчле, гайрәтле булганга яратмады бу Себер егетен, әллә урыс булганы өчен дошман күрдеме, көннәрдән бер көнне Мишаны бик нык кыйнады. Миша каршылык күрсәтмәде, кайтарып сукмады, ул дәү боксер капчыгы кебек бер урында тик басып торды. Иреннәре кысылган, бикләнгән. Ә Хохун төепме-төя аны! Булса да була икән шундый аяусыз тукмау! Куе кан иң элек ирен читләреннән сызылып чыкты, колак очларыннан тама башлады, ияге суелды, ертык изүдән тимгел-тимгел җәрәхәтләр күренде. Миша дәшмәде. Хохунның күзен кан басты, маңгае тирләп су булды, аркасы дымланды, ул ниндидер явыз тәм табып, дәү гер-йодрыклары белән Пермяковның корыч тәнен изде. Миша түзде, чыдады. Ни көтте ул? Ни уйлады? Хохунның таза-таза иптәшләре, бендеровчылар ишле иде, алар үзара ныклы төркем булып, төйнәлеп яшиләр иде. Шулардан шигәйдеме Миша, белмим. Ә без... яңгырдан качып куе ябалдашлы агач астына кергән кәҗә бәрәннәре шикелле, калтырап басып тордык. Бер Хуродзе генә: «Җитәр, Микола, булды инде!»— дип вагонка өстеннән җилфердәп эндәшкәләде...

Эшкә йөрмибез. Көндезләрен барак ишекләре ачык, лагерь эчендә эт куабыз, якташларны эзләп табабыз, аңгәмә сугабыз. Кичләрен, барак ишекләре тыштан бикләнгәч, аерата күңелле була торган иде. Бригадниклардан өч кеше искиткеч матур җырлыйлар иде. Закарпатьедан Мукачево шәһәреннән килгән Николай Лаврентьевич Новиков бас белән җырлый. Бераз тынкыш (борын эчендә полиплар бар икән!), өлкән яшьләрдәге, лыпшырдык гәүдәле бу урыс йөзләгән җырны яттан белә, сорасаң ялындырмый, шаян-шук такмакларны да сибеп җибәрә иде.

Власовчы Володя Кондаковның йөреш-торышы гаҗәп иде! Ике аягы да сул аяк, ул каршыга искән көчле җилне ерып баргандай ярты гәүдәсен кыегайтып, алга авып, иелеп йөри. Ике сүз әйтүгә кансыз теш уртларын, черек теш төпләрен күрсәтеп көлеп җибәрә. Һәр сүзен көлешкә төреп озата торган бу адәмне бөтен дөнья үз итә. Борын куышларыннан сап-сары төргәк-төргәк йон тырпайган, чәче дә соры Володяның яшен төгәл генә әйтүне кыенлаштыра иде. Көлгәндә яшәрә, көлеп туктауга бабайга әйләнә дә кала. Җырлый иде Володя, җыручы иде. Мәскәүле Павел Иванович Токмаков зыялы, бармаклары нәзек, озын, тавышы да неп-нечкә, җеп калынлыгы гына, аның ипи телемен кулына алуын карап тору кызык. Әйтик, без, ипи кыерчыгын «хап!» итеп йотабыз, калай тәлинкәләргә бүленгән баланданы кашык тыкмыйча гына чөмерәбез. Ә ул ашарга да керешмәгән була әле...

Токмаков, Новиков, Кондаков — «трио», алар борынгы урыс җырларын да, сугыш елларының катлаулы моңын ачкан заман җырларын да иң суык җаннарны кузгатырлык, йөрәккә үткәзерлек итеп җырлыйлар. Җыр яратмаган кеше юк, җыр канатлары тагып, һәркем үз үткәннәренә очып кайта. Безгә, яшьрәкләргә, яшәү җиңелрәк — без ялгызаклар, хатын, бала-чагаларыбыз юк, әти-әниләр дә безнең көнгә калмаган. Ярый, әле алда озын-озак гомер бар, дип тә юанасың. Үзем балалар үстереп, өйләндереп, нәбәрәләрем булгач кына, хәзердән торып, Карабас лагерендә яшьләрне чолгаган өлкәннәрнең ни кичергәннәрен аңлыйм шикелле. Аңлы гомерен урыс төрмәсендә уздырып, Казакъстанда җәфа чиккән

грузин Хуродзе урыс жырларын, романсларын үлеп ярата иде. Ул очлы, арык тезләрен сәләмә одеал белән төреп, житү сакаллы янавычтай иягенә жип-жинел йодрыкларын терәп онытылып тыңлый. Өлкәннәр белән безнең язмыш уртак булса да, мин аларның хәл-әхвәлләрен әле аңлап бетермәгәнмен. Хуродзе үз гаиләсен телгә алмады, мин сорашмадым. Булгандыр ич, хатыны калгандыр аның, балалары... Өлкәннәр өчләтә, бишләтә артык газап чиккәннәр икән ул заманнарда! Новиков инде карт, яше алтмышлар тирәсендә булгандыр, жырлый башласа гына яшәреп, юкарып кала. Жырлап хәлдән тайган, жырлы төннәрдә көчсезләнеп астына сия торган бу тынгысыз жанга сүз әйткән, сүгенгән кеше юк. Төрмәдә жырчы — юаныч ул, байлык, хәзинә ул.

Бер чакны Миша Пермяков белән Митя Шорохов мине аулак коридорга дәшеп чыгардылар да бүген кич Павел Токмаковны үтерергә жыенуларын белдерделәр, киңәш сорадылар. Аптырап киттем, аптыравымны сиздермәскә тырышып: «Ни өчен?» — дип кызыксындым. Егетләр күзәтеп йөргәннәрме, юктан гына шик төшкәнме, болай дип аңлаттылар: «Мәскәүле ул! Сатлык алар... Токмаковны икс тапкыр кум чакырып алды!» «Кум» дип зонада МГБ вәкилен атап йөртәләр иде. Уйга калдым. Шаяра торган егетләр түгел, чамалыйм... Кум мине дә чакыртып, кылымны тартып караган иде. Егетләргә шуны әйттем: «Чакыра инде ул, эше шул!» — дидем, ашыкмаска, мәсьәләне төрле яктан ачыкларга кирәклеген әйттем.

Нигә киңәшкә егетләр миңа килделәр? Минем сүземне тыңлап Токмаковны ничек исән калдырдылар? Хәзергәчә аңламыйм мин моны, аңлата да алмыйм. Әллә һаман шул — университет студенты булу ярадымы? Яшьтәш итеп ышаныч белдердеме егетләр? Ничек кенә булмасын, Ходай шаһит, мин Павел Ивановичның гомерен саклап калдым бугай.

Карабаста мин Николай Ильич Градобоев белән дуслаштым. Без бергә ашый башладык. Лагерьда кемнең кемлеген белергә һәм аңларга теләгәндә: «Кем белән ашыйсың?» яки «Кем белән ашадың?» — дип сорыйлар. Ифрат зур сорау бу! Совет анкетасының барлык зәһәр сорауларына торырлык сөаль! Зонада һәркем иртәдән кичкә кадәр жим эзли. Чынлап жыласаң, юк жирдән дә әз-мәз табыла ризык. Арада алыпсатучы — барыгалар килеп чыкты. Бу эшкә аерата молдаваннар маһир иде. Өс киемнәребезне әкрен-әкрен шулар кабып йотты. Кышкы бишмәтемне бер калай кружка солы ярмасына алмаштырдым. Әлинур күлмәгемә уникс бәрәңге бирделәр. Оеклар, кульяулыклар барыгалар кулына күчте. Алар, үз чиратларында, надзирательләр арасыннан ишләрен иснәшеп таптылар. Кием-салымнар зона читен үткәч, кайларга барып житкәндер, әмма сәүдә эшләре кызганнан-кыза барды.

Әнә шул, мең бәла белән тапкан ризыгыңны ялгыз гына ашау юк, чөнки син бүген тапсаң, кулалмашың иртәгә нидер юнәтә. Ризык табыштырган дуслык аерата кадерләнә анда!

Градобоев белән ничек-ничек табышканбыздыр, исемдә калмаган. Түбән Тагил шәһәре урысы, урыстан битрәк жәя яңаклы марига тартым, утыз биш-кырык яшьләрдәге бу адәм сугышкан, әсир төшкән, Германия белән төрмә-лагерьлар аша танышып йөргән. Мең жәфа чигеп, ун төрле чир ияртеп илгә кайтып аугач та әле аңа тынгылык эләкмәгән! Колагы әзрәк тынгач эшкә кергән, слесарь булган, өйләнеп тә жибәргән. Өйләнү-мәхәббәт тирәсендә зонада сер юк диярлек, өен сагынган чакларда Николай Ильич күп сүзле булмаса да әйтеп куйгалый: «Йөргән кызымның да яше бар, сазаган чагы, үзем дә олыгаеп барам, артыгын көтәргә чама калмады! Яшәр урын юк, өмет чикле, нидер булыр дип кан калтырап яшим, шулай да: «яшәү жиңеләймәсме?» — дип өйләнештек. Кәләшемне яшәп яткан алачыгыма алып кайттым. Зәфаф кичәсе, мәнге истә каласы кавышу төне... Йокларга яттык. Ә урыным... баш-башына ике артсыз урындык куелган такта топчан. Берзаман икебез дә идәнгә тәгәрәп китмәбезме?.. Ул жылый, аңа ияреп мин жылыйм. Көчсезлегемнән

гарьләнеп шул тиклем үксегәнем юк иде. Ә ул... мине юата. Топчанны почмакка ыргыттык та идәнгә яттык. Үпкәләмәде тагын. Тугры, ачык хатын булды... Берүзе ничек яшәр инде, яратыша идек!»

Хәзер без бергә, ни тапсак, ни юнәтсәк шул уртак. Оста кеше иде Түбән Тагил урысы, бервакыт без иске теш щеткалары җыя башладык, нәни пычкы юнәттек. Щеткаларны мин турыйм, ә Николай кисәкләрне тишә, шомарта, мөштек итеп тезә. Аллы-гөлле мөштекләрне конвой солдатлары теләп сатып ала икән. Бригадирлар, ашханә, ипи кисүдә эшләүчеләр дә хирыс аңа. Иске щеткалар гына житсен! Мин куркаграк, ул кыю. Ул оста, мин ярдәмче. Яшәп ятабыз шулай!

Карабас зонасын мин тар итеп, бары тик үз секция кешеләре аша гына истә калдырганмын. Хуродзе, себер егетләре, бандеровчылар. Жырлы-моңлы «трио», ниһаять, Градобоев. Аның ни өчен баланда чөмергәнен мин бер чакта да сорашмадым, белмәдем дә. Мәгәр Николай Ильич ярдәмчел, чын егет иде!..

Һәркем уртак учакка йомычка өсти, хәбәрләрдән кабынган учак дөрли, чартлап яна, сүздән сүз чыга, фикер туа. Барыбызда да бер үк шик: ник җыялар Казакъстан туфрагына сәясиләрне? Әллә кайларда боз араларына сеңгәннәрне дә кубарганнар, Европадан Мари, Коми тирәләреннән дә кирәклеләрне чокып чыгаралар, тайга базларыннан табып алалар. Карабаска Тернопольдән этап килеп төште, Львов төрмәләреннән западникларны китереп тутырдылар. Минск төрмәсеннән дә «сәях»ләр килеп төшә, алар өзми-куймый майор Столяровның юрамаларын китерәләр: «Сәяси тоткыннарның хәле яхшырырга тиеш!» Эзләвем житмәдеме, Карабаста мин татарларны очратмадым. Аннан без — татарлар, кабыгына кереп югалырга ашыккан әкәм-төкәм шикелле, белергә ашыкмыйбыз, белдерергә теләмибез!

«Тиздән Карабастан алып китәләр!» — дигән хәбәрләр йөри башлады, зур этапка әзерләнәбез. Минем шушы тәүге зонамнан китеп барышым шактый мажаралы һәм гыйбрәтле булды.

## 3

*Алмазлар табыладыр җир тирәнлегендә генә, ә хакыйкатьне исә кеше үз чоңгылларыннан гына эзләп алып була.*

Виктор ГЮГО

Яз килә, март якынлаша! Тоткынлыкның нәни генә юбилее, бер еллыгы! Олы нужалар татыганым, күтәрә алмаслык олы кайгылар кичергәнем юк әле минем. Мөхтәрәм укучым! «Бәрәкәт, төрмәдә түгел, оҗмахта яткан бу бәндә!» — дип бәя куя күрмәгез! Яңа дөнья, язмыш арбаларына гыйбрәт һәм акыл төягән адәмнәр белән тыгыз, эчкерсез аралашу нужа күргәннәремне әзме-күпме җиңеләйтте бугай. Магадан-Колыманы татыган, немец лагерьларын кичкәннәр чирчорлардан җәфа чигә, мин сәламәт, ул яктан да әлегә зар-моңым юк. Төрмә никадәрле котсыз, аяусыз булмасын, минем өчен гыйбрәтле мәктәп иде. Җанымны кысып, зиһенемне тарайтып, иркен суларга ирек бирмәгән яшьлегем сорауларына ап-ачык, үзем хак дип кабул иткән гадел җавапларны мин шунда таптым. Өлешчә мин бәхетле идем. Тиңдәшсез бөек әсәрләре белән халкын таң калдырырга җыенган тынгысыз җан, ниһаять, үз урынын, Аллаһе тәгалә вә бөек могҗизалар иясе — Табигать билгеләгән үсеш ноктасын төрмәдә тапты! Кем белгән, ул ноктаны бүтән мохиттә, үзгә тормыш шартларында тапкан булсам, нәтиҗәлерәк, бәрәкәтлерәк яшәр идемме икән? Хәзерге акылым белән шулай уйлыйм: Сталин чорында да бары тик төрмә диварлары артында

гына рух иреген саклап калырга мөмкинлек булган икән! Юк-бар цитаталар ятлап, гомереңне тикмәгә исраф итмисен. Белем алыйм дисәң, якын-тирәңдә ничаклы белгечләр, галимнәр, профессорлар, дөньяның дүрт ягыннан җыелган кызыклы шәхесләр. Берәү дә төрмә эшен ачып бетерми, бу тирәләргә юллар ябык, алай да һәркемнең күңелендә синең сусыныңны кандырырлык тормыш баскычлары бар. Һәркем — укылмаган мажаралы китап, авыр язмышы төйнәлгән йомгак. Кагылдың исә, тәгәри дә китә...

Карабаста эш хуҗалык утарында гына. Кемнәрдер шунда эшкә барып йөриләр иде. Ишетәм, подвалда бәрәңге аралыйлар, суган черекләрен чистарталар. Финляндиядән өчме, дүртме җыелма йорт кисәкчәләре килгән дә, безнең бригада йортларны җыярга тиеш булды. Һич көтмәгәндә без хуҗалык утарына эшкә йөрергә тотындык. Бригадамдагы адәмнәр яңа яктан ачылып китте: моңарчы таң җиле булып тавышсыз гына йөргән ач яңаклы, чуендай кара хохол Иванюк төзелеш остасы икән! Белмәгәне юк! Финляндиядә эшләнеп, аерым-аерым тартмаларда сәяхәт кылган йорт кисәкләрен ул бернинди сызымсыз, күңел күзе белән чамалап җыя башлады. Сүтә, җыя, теге җеккә ята, таслап кына куя. Без дә йөгереп кенә йөрибез! Барыбыз да эшне сагынган. Шунысы да бар, шундук безнең ипи паегын арттырдылар. Мине түбә ябарга, астан тар басма аша черепица ташырга куйдылар. Бу сүзнең чын татарчасы юк, Гражданнар сугышы чорында Украина күргән язучылар «чүлмәк түбә»,— дип атап йөртәләр. Телдә «чирәп» дигән атама да йөри. Бишалтыны беләгеңә аркылы саласың да авыш басмадан җил-җил менеп китәсең. Туктап тору юк, икенчеләр астан сине куалый... Өстә, агач рейкаларга черепицаларны бүтәннәр тезә. Йортлар салынып беткәч, аларны хуҗалык утарыннан аерачаклар, яшәргә безнең сакчылар — офицерлар керәчәк. Дүрт йорттан нибарысы икене җыя алдык. Бездән алда йортларга нигез әтмәлләгән бригада Казакъстанның чакматашыдай туң җирендә интегеп азапланмаган, алар ерак-ераклардан килеп алтын бәясенә төшкән өй кисәкләрен дер-дер яндырганнар да җебегән, йомшаган җирне казыганнар. Иванюк, чын хезмәт кешесе буларак, ихлас күңеленнән каргана, бүтәннәр шырык-шарык көләләр. Дүрт йорттан ике? Социализм кануннарын белгән кешегә бу әле әйбәт! Бригаданы шул сәбәпле алыштырганнар икән, тегеләрне каядыр җәһәннәмгә этапка куганнар. Әллә бу «яхшы эшләсеннәр!» өчен чекистлар уйлап чыгарган параша гына идеме? Белмәдем.

Безне дә озак тотмадылар. Бригадниклар тамак дигәндә эшне печеп башкара, шыпан-шыпан гына бәрәңге, суган тирәсен урап кайталар. Авыр аяклы, боксер, тамаксау Иштван Полачекны бәрәңге урлаганда тоттылар да өч көнгә карцерга яптылар, безне кичке ашсыз калдырдылар.

Февраль ае бетеп бара. Иртәләр сизелерлек яктырды. Көндезләрен котсыз барактан бүселеп чыгабыз да, ябагалы мал-туар сыман, кояш күзендә бөялеп, җылынып, нурларның мәрхәмәтен күбрәк умырырга тырышып тик басып торабыз. Кояш күрмәгәнгә ел була! Башта төрмәдә, аннары зонада... Кояш әлегә кинәндерми, нурларының җир җуләрләренә әсир төшүен теләми шикелле. Кояш ул аңлый!

Мин, кояшка гашыйк җан, барак ишегенең ачылуын түземсезлек белән көтеп торам. Секциядәге исләр — тир, иске кием исе, чергән аякчулар, оеклар исеннән тыгызланган агулы һавадан тизрәк котыласым килә. Кояш күзенә чыккач, зонаны кысып кочаклаган биек-биек коймалар. Сталин пәрәвезләре дип аталган чәнечкеле тимер чыбык җәтмәләр дә ягымлырак күренә, дөнья киңәеп китә.

Ул көнне дә шулай булды, йозак шылтырый башлауга мин әллә кайчан ишек катында идем. Ишек иренеп кенә ачылды, аннан ургылып кергән яктылыктан күзем күрмәскә әйләнде. Надзиратель йозагын болгап эчкә кергәнче, мин аның култык астыннан шома гына үтеп китеп,

рәхәтлектән күземне ачарга да өлгермәдем. «А ну-ка назад!»— дигән котсыз тавыш колакны ярды. Мин сискәнеп һәм сәерсенеп як-ягыма карандым. «Кемгә шулай жикеренә бу сакау?» Ак тунлы, чөгендер чырайлы, кызгылт чәчле урыс мина кычкыра икән! Берни анламыйча сакауга ияреп секциягә кердем. «Где бригадир?»— дип сорады ачу ташы кызган сакчы. Аны абайлап, почмак яктан Хохун күтәрелеп кенә килә иде. «Вот он!— Надзиратель миңа төртеп күрсәтте.— Нарушил порядок! Я его забираю в карцер!» Киләшчә куллар мине эләктереп тә алды. Иптәшләрем минем тәртип бозмавымны, әлерәк кенә чыгып баруымны күреп тордылар, әмма дәшмәделәр. Каушап үзем дә сүзсез калдым. Шулчак хыянәтче тынлыкны бозып Хуродзеның тынлыкны кисеп-тураган зәгыйфь тавышы яңгырады: «Как нарушил? Это же самый дисциплинированный парень. Отпустите его, гражданин сержант!» Карт грузин урыс сүзләрен ватып-жимерә торган иде, бу юлы «дисциплинированный» дигәнне әйтә алмыйча йөдәде.

Сакау беләгемнән кысып тотып-умырып, моңарчы миңа караңгы булган почмакка, карцерга алып китте. Ишек ачылды, ишек ябылды, келә бикләре шалтырады. Як-ягыма карарлык хәлгә килгәндә мин дүрт ягы да цементтан коелган, тимер ишегендә волчок күзе дә булмаган карцер бүлмәсендә идем. Ишек өстендәрәк, нәкъ түшәм астында тузанга манчылган зәгыйфь лампочка яна. Идәнгә тибеп карадым, ул сап-салкын, җансыз һәм шадра-кытыршы иде.

Валлаһи, таллаһи, бермәлгә мин ялгыз калуыма сөендем. Ел була, шуның ничә минутын ялгыз башым үткәреп җибәрдем икән? Әзрәкмәзрәк бер башым утырырмын да кемдер килеп ачып чыгарыр дип өметләндем микән? Әле стеналарның бозлы бәсләрен дә, почмакта параша дус юклыгын да, тоташ тимер ишектә кормушка булмавын да абайламадым. Киресенчә, жылынып-кайнарланып киттем, эре-эре атлап йөренгәндәй итәм, янәсе, бирешмим! Күңелемне киңәйтеп иҗади уйлар кайтты, нидер язасым, кешелекне шаккатырасым, үземнең гаҗәеп, бөек зат икәнлегемне раслыйсым килде. Иске бушлат төймәләрен ычкындырып, итәгеннән тартып билемә кысыбрак урадым да йөрим, тыным тигезләнде, карашым калын, таш диварларны, тимер ишекне кисеп үтеп еракларга төбәлде. Ышанасызмы, ялгызлыкның чиксез рәхәтлеген мин шунда татыдым... Гаҗәп хәл, илле дүртенче елны, яңадан Черек күлне «сагынып» кайткач, ике ай ялгыз камерада утырганда да мин бик бәхетле идем! Күңелемә һич көтмәгәндә «Чык бөртеге» дигән повесть иңде. Әсәрнең башы-ахыры, төгәл тукымасы, тере образлары бар иде. Әгәр шунда кулыма кәгазь-каләм тоттырсалар, мин ул әсәрне язып та ыргыта идем. Тагын да гаҗәбрәге шул: мин, котылып чыккач, ул әсәр хакында бер тапкыр да уйлап карамадым, тора-бара бер генә сызыгы да хәтердә калмавын аңлап көлемсерәдем...

Суык монда да үзенең хуҗа икәнен сиздерә! Чүгәләп аркамны диварга терәп карыйм — куыра! Юка табанлы ботинкаларыма иелеп карарга куркам. Иректә киеп кергән галушларымны йөк була дип Свердловски төрмәсендә калдырган идем. Хәзер ярап торыр иде ул тугры хезмәтче галушлар! Суыкка бирешмәс өчен уй йөгертергә тотындым: менә бригада ашханәгә китте... ашадылар... кайттылар... Ашказаным сулыгып-сулыгып алды. Димәк, вакытны дөрес билгеләдем. Хәзер төркемләшеп гәп сугалар. Барыга-молдаван, гадәтенчә, иснәнеп кеше арасында йөри. Булса да була икән ачкүз! Ярым-йорты бәягә бригаданы чишендерә. Бер шырпы кабы тәмәкегә күлмәк сатып ала. Хәзер аның күзе миңа төшми, иярә килгән соңгы күлмәгемне биш сумга сатып җибәргәч, ул авызын ерып, иңемнән какты: «Пока такие добрые люди есть, жить можно!» Шушы соңгы хөкемне ишеткәннән бирле җирәнәм мин аннан. Җәберсетте ул мине, алдана торган беркатлы булуымны раслады. Карцерда беренче булып исемә керде дә ярсытты мине Барыга! Аны буып ташлардай булдым!

Әче үч тойгысы нигә шулай соңарып килде дә күңелем үтә җайсыз урында шулай давылланды? Хәзер дә аңламыйм. Ярсыдым, маңгаемны тотып карадым, дымлы! Акылга сәер сорау инде: адәм гәүдәсенә күпме җылы сыя икән? Һәм минем тән әгъзаларымны җылытып торучы ягулык кайда саклана икән? Нәни генә һәр хәрәкәт өчен җылылык энергиясе кирәк. Суыктан кәңкәймәс өчен саклап тотарга аны? Әлбәттә, мине монда озак тотмаслар, кизү офицер керер... Бүген дежурлыкны кем алды икән? Алар арасында да төрлеләре бар. Бәлки, карцерга ябылганнарны лагерь начальнигы да күздән үткәрәдер әле? Керер, гаепсез булуымны аңлагач, чыгарыр да җибәрер. Градобоев минем икмәкне җыеп куя алса ярар иде. Ашны алып кайта алмас...

Җылым чыгып түгелеп бетмәсен өчен хәзер мин артык хәрәкәт ясарга да куркам, салмак басып кына әйләнәм, бияләйле кулларымны җиң эченә тыктым, бүрекне басып кидем, өтек якамны күтәрдем. Чыдарга тиеш мин, бирешмәскә! Елга якын камалуда утырып, меңнәрчә сөйләкләрдән сталинчыл җәзачыларның немец фашистларын явызлыкта йөз һәм мең тапкыр уздырып җибәрүләрен аңласам да, кайдадыр, күкрәкнең тар гына ярыгында совет кешесенең миһербанлы һәм ярдәмчел булуына өмет чаткысы саклана бит! И беркатлы сабый акылы чыгып бетмәгән тилемсә чаклар! Еллар буе дәвам иткән, көне-төне баш миенә тукылдаган өндәмәләр эзсез узмаган, укыган китаплар, кинолар, спектакльләр, Чапаевлар, Щорслар, Левинсоннар, коммунистик шәфкать изләре шул ук томанлы аңга сеңдерелгән. Шунда коммунистик мәгънәсез явызлыкның иң югары ноктасында туңып-калтырап йөргәндә лагерь башлыклары керер дә, хәлемне җиңеләйтер дип өметләнгәнмен бит! Икеле-микеле тәрбия, өзмәс коткы яңгырында яшәргән акыл Черек күлдә сорау алу вакытларында телдән ычкындырырга ярамаган сүзләрне берәм-берәм суырып алды. Хәйлә, ялган, янау, куркыту, башны бутау... Керәсең тикшерүче янына. Син куян, ул — буар җылан. Ул боргалана-боргалана сүзката: «Әһә... синең әтиең укытучымы әле? Әһә...» Шуннан ары бер сүз дә өстәми. Йөрәк куян коерыгы сыман дерелди... Тикшерүче кулында коралның тагын да хәтәррәге бар: «Тәк, тәк... Укытучы! Зәй районында укытамы әле? Тәк, тәк». Эчемә ут төшә, утны боз алыштыра. Инде шушы яманлык белән башланган эш әтигә дә барып җитсә?.. Тикшерүчем әллә ниләр белә! «Мулла малаемы әле ул? Сарман мулласының улымы?.. Алабуга төрмәсендә атылган Сахабетдин баласымы?.. Сезнең нәсел-нәсәбегез, бабаларыгыз XIX гасыр азагында Төркиягә күчеп киткәнме?.. Әһә! Абыең да укытучы икән бит синең?!»

Тикшерүче мине изә, сыта, күнитек табаннары астына салып таптый, тантана итә. «Шушы, булган кадәресе дә сине төрмәдән мәңге чыгармаска җитә. Ләкин, аңла, тумар баш! Совет власте иң гуманлы, иң гадел власть... Без коммунизм төзүчеләр. Коммунизм бит ул социаль гаделлеккә сусаган хезмәт ияләренең Компанелла, Томас Мор, Шарль Фурье кебек бөекләрнең әсәрләрендә чагылыш тапкан һәм соңрак Маркс һәм Энгельс тарафыннан фәнни нигезгә утыртылган күп меңьеллык хыялы... Син — шул бөек агымга каршы чыгарга маташкан бөҗәк. Коммунистлар партиясе һәр хезмәт иясенә җылысын мул бүлеп бирә...» Китә, мин сиңа әйтим, китә! Ярата минем тикшерүчем вәгазь сөйләргә!.. Аның әгъвәләве моңарчы, егерме ике ел дәвамында колакка гел кереп торган вәгазьләргә барып тоташа... Нәтиҗәдә, камерада утырганда үз-үзеңә: «Нык булырга, нык! Артык бер сүз дә ычкындырмаска!» — дип беркеткән аңың кинәт җеби, син камырга әйләнәсең, һәм синдәй сарыкларны бөгәргә, шыр ялганга да ышандырырга әзерләнгән җаһил, кансыз чекист сине үзе теләгән калыпка кертә...

Күр инде, бер гаепсезгә карцерга китереп тыктылар, ә мин алардан шәфкать көтеп утырам! Алай да, алай да... Адымнарымның ешаюын сизми дә калам, ачу уты кабына, көйри, давылланып ыргыла, борын тишекләреннән гейзер кебек җылы пар ата.

Күпме вакыт үтте икән? Суык иң әүвәл арканы биләде, астан өскә, өстән аска йөгереп йөрде дә күзәнәкләрдән җылыны куып чыгарды, үзе җылы урынына оялады. Китмәс, таралмас булды. Кул җиткән кадәр үрелеп бияләй белән аркамны төям. Ул арада салкын сул аякны камады. Берзаман борын, бит очларын тешләде. Күкрәккә кереп ятты суык, уралды, җилкәне яулаган илбасар белән тоташты. Тавыш-тын юк, тимер ишекне төеп карыйм, туңган иреннәрне чак кыймылдатып кычкырам. Тел дә, иреннәр дә, алардан атылып чыгасы сүзләр дә туңган-өшегән икән! Диварларга сарган күе бәс минем тыннан нәни генә тирләп елтырый башлаган кебек иде, хәзер бәс калынайды. Мин үземне боз табутта яткандай тоя башладым. «Бетүем шушы икән!»— дигән шом килеп җитте. Мин юк тавышым, юк көчем белән кычкырып җырларга тотындым! Чамалыйм: мине камый барган шомга ирек бирсәң, хәзер тышаулап упкынга ыргытачак! Җырлыйм гына! Тавышым булмаса да Югары Багражның сөйкемле, рәхәт тауларында сарык көткәндә, «ялгыз башым, юк юлдашым!»— дип җырлап юана торган идем. Җырлыйм карцерда, үз тавышыма үзем гашыйк булып җырлыйм. Бүгенге бөек шагыйребез Гамил Афзал әйтмешли: «Калмагандыр җырланмаган бер җыру да!»

Вакыт исәбе буталды, корсак сулкылдаудан туктады, шулчак тавышсыз гына ишек ачылды, юк, надзиратель түгел, сары бушлат, колакчынлы бүрек кигән өтек кенә бер егет әләмәсе килеп керде. «Ни улыйсың, ач бүре?»— диде ул. Кылт итеп исемә төште, Иштван карцердан кайткач: «Надзирательләр кереп тә карамый, керсәләр дә аларына түзәргә була! Менә анда карцер дневальные чегән бар! Аның кыланышларына түзәр чама юк!»— дип сөйләгәнен ишеткәнмен икән!

Әйе, бу — ул, дневальный иде. Мин чегәннең вазифаларын уйлапнитеп тормастан, мөмкин кадәр йомшак тавыш белән: «Мине моннан кайчан чыгаралар?»— дип сорадым. Әле өметләнеп тегенең кулларына карадым: ипи-мазар китермәгәнме! И сабыйлык!.. Безне кат-кат тунап, кайнарда пешекләп, салкында туңдырып акылга утыртасы бар әле!.. Чегән күмер күзләрендә ут давылы уйнатып, катлы-катлы сүгенде. Сизәм, бу егет әләмәсе сүгенүнең классигы! Матур сүгенүче классиклар була, хәтта сүгенү аларга килешә дә, алар аны концерт номеры башкаргандай үтиләр, чегән исә әшәке итеп, рәнҗетеп минем өшегән гәүдәмне шакшы сүзләр ташкыны белән күмде. «Утыр, утыр, фраер! Җылыт карцерны! Тәртип бозуның ни икәнен аңла!» Бу сүзләрнең һәммәсеннән соң ул ун, егерме катлы итеп дөньяның бар аналарын, аталарын, бабаларының гүр такталарын таптап үтте. Сүгенә икән — хуҗа, бездәйләрне боерга рөхсәте бар. Кер бәләге чаклы сары бушлат алдында телемне теш артына батырып тик торам.

Лагерьда надзирательләр тирәсендә ялманган, аларга тәлинкә тоткан бер төркем этләр була. Бөтен пычрак эшне алар эшли. Минем төз басып торуым чегәнгә ошамадымы, әллә бүтән сәбәпләр аркасында котырынып кергән идеме, сизми дә калдым: ул үкчәсе белән эчемә китереп типте! Мин бөгәрләнеп барып төштем. Чегән атылып минем өскә килде һәм ике аяклап алмаш-тилмәш типкәләргә тотынды. «Карцер рәхәтен татымыйча чыгаралар дисеңме, сука! Тәмен таты, гомер онытылмаслык булсын, падло!» Әллә ниләр әйтмәк булам, телем әйләнми, ятам бетон идәндә ыңгырашып. Типкәли торгач, чегәннең йөзе бурлаттай алланды, мин дә җылындым, валлаһи! Озак кыйнагандыр, ахрысы, һуштан язганмын... Белешмичә, ыштанны юешләгәнмен! Хәзер нишләргә? Чыланган әгъзаларымны суыкта ничек асрарга?.. Кергән мәлдә мин параша юклыгына әлләни игътибар да итмәгән идем. Җүләрбаш, керә дә чыга, имеш! Кыстала башлагач хәҗәт үтәргә җай юклыгын күрдем-күрүен, анда да бу уй тиз-тиз үтеп китте... Бер мәлгә: «Почмакка чаптырыргамы әллә?»— дип тә уйладым. Шуннан күз алдыма теге бичара, җилкәсе чиләнеп канга тузганчы вагон идәнен ышкыган бахыр килде. Әгәр бу шадра идәнгә салып ышкый башласалар...

Хәл үтә мөшкел иде. Үз-үземне тыярга, иплэргә тырышып уйларымны еракка, бәхетле балачакка, туган төягемә йөгереп карыйм. Тик бу җиңеләю, акылны алдарга тырышу озакка бармый. Чынлык тагын карцерга бөтереп тыга. Теге тәре баганасы чегән, тез күмәчләренә дә типкән икән, эч авыртуы тезгә кадәр төшә дә хәл китә, тын алу авырлаша, борын тишекләреннән тын көч-хәл белән чыга да өши, югала. Тып-тын. Шылт иткән өметле тавыш юк. Басып тора да алмыйм, ботларымны җырып, чалбар балаклары кушылган төштәге сыкы бөртекләрен коя-коя чүгәләдем. Тамагым яна иде, диварга сарган җансыз кар бөртекләрен учлап авызыма тутырдым. Ашказаным уянды, котырып-сызланып ризык таләп итеп фетнә күтәрде. Сыкрый! Чүгәләгән хәлдә авызыма учлап-учлап кар тутырдым. Аягыма баскач беренче эш итеп, эре-эре хәрефләр белән дивар кырына: «Ай-һай, дөнья, туйдым синнән!» дип яздым да, чатлы-ботлы итеп имзамны салдым. Шик төште, имзамны, сүземне күргәннәр ни кылмаслар? Хәер, миңа барыбер түгелмени?.. Муеннан шарфны салып бот арасына кыстырдым... Егылмасам гына ярар иде. Вакыт ага, ага! Дөньядан туйдым дип язсам да, һич тә туйганым юк минем аннан!..

Карцерда тәүлектән артык утырганмын. Елга якын төрмәдә булып беренче мәртәбә кара өметсезлеккә чумдым. Мине кем йолкып алыр дип, шүрәледәй бәргәләнәм. Иман, Коръән сүзләре хакында уйлана башладым. Кешеләр арасындагы өметсезлектә без һәр очракта да Аллага кайтабыз. Мондый чакта догалар укып, Тәңрегә баш орып, җаныңа хәл кертсәң ярый да... Юк белгән догаларым, юк! Үз сүзләрем белән гап-гади татарча тәңрегә кадерле сүзләремне әйтәм, ялварып карыйм. Һәм, сөбханалла, томаланган колакларым ачылып киткәндәй булды. Якында гына гөжләү тавышларын ишеткәндәй дәррәү сагайдым, тыңланам. Гөжләү шактый озакка сузылды, шактый ишле кешеләр сөйләшкән кебек. Этап килдеме әллә?.. Берзаман, якындарак кына, кемдер исемемне атап кычкырды: «Аяз! Я твои вещи взял!» Градобоев! Николай Ильич!.. Ни ди?.. Юк, аңлатмый... (Соңыннан мәгълүм булды, Градобоевны бер секундка гына карцер ихатасына кертkәннәр икән!)

Димәк, мине этапка куалар икән. Шулай дип юрадым. Бүтәнчә түгел. Көтәм, тыпырчынам, суык, ачлык онытылды. Этапка диләр икән, хәзер минем арттан керергә тиешләр. Юк кына, килмиләр, ишеккә ябышып ятканымны сизмәгәнмен дә...

Типкәләп аңга китерделәр, абына-сөртенә конвой артыннан йөгерәм! Вахтага килеп җиткәндә тоткыннарны сыйган кадәр әрҗәгә шыплап тутырган актыкка машина кузгалырга тора иде. Этапка куар алдыннан һәркемгә киез итек өләшкәннәр. Искереп таланган, табаннары гына түгел, куныччлары да кат-кат ямалган, көя шадралаган пималарга мин әрнү катыш кызыгып карадым. Итек өләшкәннәр икән, этап барасы юл шактый озын дигән сүз! Җитмәсә үз бригадникларым арасына да эләкмәдем, иптәшләр бер-бер чарасын табарлар иде, мөгаен. Калын, дәү якалы йомшак толыплар кигән ике солдат кабинага аркасын терәп минеп басты, без Карабас лагерь-төрмәсен артта калдырып, ыжлап торган төн җилен яра-яра коммунизмның яңа ярларына таба кузгалдык. Юлдашларым минем итексез баруымны әзрәк утыргач гына аңладылар, кемдер: «Бу фраерны уртага алыйк!»— дип пышылдады. Ә безгә кузгалмаска боерылган, мин селкенмәскә дә тырышып әз-мәз шуышмакчы булам, суык тимер төсле тавыш яңгырый: «Куда, куда, контрик! Сиди, падло!» «Иптәшләрнең сөйләшә белә торганнары да бар икән, берсе: «Аңа итек эләкмәгән, аягын өшетә ич!»— дип, кем эндәшкәнен дә сиздермәслек кыска арада кычкырып җибәрде. Конвой солдатлары нидер мөгердәшеп алды, берсе: «Куч монда, кабина ышыгына, фашист проклятый! Чтобы ты подох, паскуда!»— дип кычкырды. Сүгенү дә вакыт-вакыт сандугач булып ишетелә икән, мин калкынмаска тырышып, арт белән шуышып, иптәшләрнең кырыкка бөгәрләнгән аякларын изә-изә солдатның озын

толып итәгенә барып җиттем һәм җанга якын сарык исе аңкып торган тирегә ышыкландым. О бәхет! Сиңа рәхмәтлемен, кызыл погонлы солдат! Бу юлы син мине тибеп очырмадың. Шунда, утырган җирдә йоклап та киткәнмен. Берзаман күземне ертып ачсам, машина бортлары каерылган, иптәшләрем ак карга шыбыр-шыбыр коелалар. Мин киерелеп ачылган ач капкадан соңгы кеше булып, аксап-туксап барып кердем. Кемдер: «Актас бу, Актас лагере!» — дип пышылдады.

4

*Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы.*
*Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры —*
*Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә*
*Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы.*

Габдулла ТУКАЙ

Мөхтәрәм укучым! Бу бүлектә бәян ителгән уй-фикерләремне, ашыкмыйча, сеңдереп кенә укысаң иде! Нигездә, болар һәммәсе дә шәхси фикерләрем. Төрмә юлларындагы күп санлы күзәтүләремә, белгән-ишеткәннәргә, йөзләрчә акыллы кешеләр: репатриантлар, Власов офицерлары, илнең төрле якларыннан җыелган галимнәре белән тел-логать алмашып яшәгән кадерле юлдашларыма таянып ясадым ошбу йомгакларны. Хак, Ходам шаһит, төрмәдән котылгач та мин утыз биш елдан артык кайнап торган тормышның кап уртасында яшәдем. Кыскасы, ярты гасырлык аңлы гомер юлымның кайбер нәтиҗәләренә мин әкрен-әкрен бара-бара ирештем. КГБ архивларына үтеп кереп, җыелма документларны өйрәнергә кулым җитмәде, теләгем дә юк иде. Мәгәр, бу йомгаклау сүзләремдә, сезгә нindидер яңалык җиткерерлек яки сезгә мәгълүм хәбәрләрне яңартырлык гадел хаклык, аяусыз дөреслек бар дип ышанам.

Сталин һәм аның сүзсез баш ияргә гадәтләнгән канлы яраннары СССРны иңләп-буйлап тагын бер мәртәбә җәза дулкынын үткәрүне планлаштыралар. Чөнки алар шыпырт кына Өченче бөтендөнья сугышын ачарга әзерләнәләр. Урыс шовинистларының: «Эх, бер тотынгач, Германияне тезләндергәч, ник тукталып калырга иде? Америка-инглизчәннарны дөбердәтеп куып чыгарып, Франция, Испания, Португалияләрдә совет властен урнаштырып, коммунистик демократия юлына борып, ленинча яшәтә башларга иде?!— дигән үкенү-әрнү сүзләрен бер генә тапкыр ишетмәдем. Мең еллар буена басып алу, сугышу, буйсындыру күзәнәкләре канына сеңгән гади урыслар да, генерал-адмираллар да шул фикердә булмады дип кем әйтә ала? Бу фикер яшәгән, кемнәрдер аны әзерләгән, кемнәрдер аны белгән, хуплаган. Урыс империясенең мәңгелек хыялы — дөньяны басып алу булса, хыялларның иң якындагысы Әфганстан — Һиндстан аша үтеп, җылы диңгезләргә, океан киңлекләренә чыгу күздә тотылган. Аңа яшертен генә, әмма зур кимәлдә әзерләнгәннәр! Ватан сугышында җиңү белән зур сабак та алган дөньябасар Сталин һәм аның котырган өере дөньяны яулап алыр өчен иң әүвәл тылны әзерләргә тотынган. Шуңа күрә алар һичбер гаепләре булмаган, бары тик ил хуҗаларының, хәрби командирларның җебегәнлеге һәм булдыксызлыгы аркасында гына дошман кулына әсир төшерелгән солдатларны күпләп-күпләп төрмәләргә тутыралар. Шул планнарын алга куеп, утызынчы, кырыгынчы елларда Сталин төрмә баскычларын үтеп күзе ачылган, аңнарына Совет хакимиятенең игелексез асылы сеңеп калган сәяси тот-кыннарны өр-яңадан җыя башлыйлар. Онытмаган аларны коммунистлар партиясе, һич күздән җуймаган! Әнә шул мәкерле планнарның корбаны

булып совет вузларыннан аңлырак, сәяси яктан кыюрак булган егет-кызларны берәм-берәм чүплиләр. Черек күл төрмәсенең һәр камерасында студент яшьләрдән «тулы хокуклы бер илче бар иде» дип юкка гына кабатлыйммы мин? КГБ студентларны сөзештерүне оста һәм нәтиҗәле оештыра алган, аларны бер-берсенә өстергән! «Фәлән өчен утырган икән, төгән өчен аны япканнар!»— дип, бер сүз белән шушы дөньякүләм вакыйганы аңлатырга тырышулар балалык авыруы гына ул! Легионерлар, әсирләр, икенче, өченче тапкыр камалганнар — болар һәммәсе дә бер агач җимешләре ләбаса! Төрмә механизмы ул чакта да житез, шәп эшли! Трибуналлар, Мәскәүдәге «особое совещание»ләр хөкем карарларын пичәтләп кенә тора. Һәр өлкәдә өр-яңа концлагерьларга нигез салына. Иң кулай итеп чиксез далалар, аулак почмаклар иясе Казакъстан сайлана. Бигрәк тә аның Караганда тирәләре иң җайлы, шым урын итеп табыла. Караганда өлкәсендә зур-зур өч лагерь идарәсе төзелә. «Степлаг» — бу комсыз лагерь идарәсенә Кингир, Балхаш, Җизказган төбәкләре керә. Һәрберсендә каторга хезмәте, караңгыдан караңгыга кадәр чикләнмәгән эш көне, бакыр чокырлары, ташкүмер базлары. Бакыр рудниклары ачлы-туклы иза чиккән, чамасыз көч түгеп эшләргә мәҗбүр ителгән тоткын ике-өч елдан артыкка чыдамый, беркем дә анализ ясамаган җир асты сулары эчеп, чирләп, кыйналып, таушалып беткәннән соң сәясиләрне чираттагы җәһәннәм юлы станцасына — Спасск төрмә лазаретына китереп ташлыйлар. Кингир-Җизказган рудникларын үтеп, йөздән берәү исән калып, Караганда тирәләренә килеп җитә алган тоткыннар Спасскины котлары чыгып искә алалар иде. Иван Копач, Федор Попежук, Митя Полещуклар белән бер бригадада озак айлар эшләдек. «Һай! — диләр иде алар, агарынып.— Җәһәннәм кайда дип сорасалар, анда ул, анда!» Спасск төрмә-лазаретта утыз биш мең кеше койкада чирләп ятучы исәпләнә! Хәллерәкләрне анда да тик яткырмаганнар, таш базына куганнар. Берәүләр ташны аргы тирәдән бирегә ташый, икенчеләр, алар ташыган ташны кирегә илтә. Спасск төрмә-лазаретны алты метр биеклектәге таш койма белән әйләндереп алганнар. Үләселәр Спасскида ятып калган, җан саклаганнарны «икенче дәрәҗәдәге» йомшаграк режимлы «Луглаг»ка озатканнар. Чираттагы лагерь — йөз капкалы особый лагерьлар җыелмасы - сәяси тоткыннарны йотып кына алган. Шахта базлары казыган тоткыннар, кирпеч заводларында, ДОКларда эшләгәннәр, шәһәр-поселоклар салганнар. Инде шушы җәһәннәмнең ике катын узып, гомерлек чир-чинкеләр алган, гарипләнгән, кыйгайган, кырык-кырык биштә чал сакаллы бабайларга әйләнгән тоткыннарны, ахыр чиктә, «Карлаг»ка төяп китергәннәр. Ярым гарип, ярым аңсыз тоткыннар авыл хуҗалыгында хезмәт күрсәткәннәр, яшелчә үстергәннәр. Казакъстанның юмарт далаларына соңгы елларда эләккәннәр аерым бер каты режимда яшәгәннәр. Хат язарга ярамый, елына ике ачык хат, анда да урыс теленда. Гәүдәнең дүрт җирендә номерлар. Бикле ишектән чыгып таңда эшкә кузгаласың да, кайтып тамак ялгауга, сине тагын шатырдатып бикләләр. Сине йөзләрчә солдат-офицерлар саклый. Лагерь эчендә бүребүре надзирательләр. Конвой гаскәрләренә күпчелек дөнья күрмәгән, урысча белмәгән Урта Азия егетләрен җыялар. Казакъ, кыргыз, үзбәк, бигрәк тә таҗик балалары, йорт-тирәләрендә йомшак күңелле, юмарт егетләр, ярты елда бозылып ерткычларга әйләнәләр. Тоткыннарның канын суырган аждаһалар, дию пәриләре алар арасыннан чыкты. Ул елларда Рәсәй халыкларының малын имеп, талап, тырышып-тырмашып гүзәл дөнья — социализм төзеп яткан Европа илләрендәге сәяси тоткыннарны илләрендә тотмыйлар иде, аларны да алмаш-тилмәш йөгергән кызыл вагоннарга төяп Казакъстан далаларына ташыдылар. Актас лагерендә немецлар дисеңме, румын-болгарлар, мадьяр-поляклар дисеңме — һәммәсе ишле-ишле төркемнәр булып, без «бәхетлеләр» янәшәсендә газап чигәләр иде. 1952 нең җәендә Берлинда булган каты чуалышлардан соң кулга алынган көрәшчеләрне дә безгә китереп тутырдылар. Болай да

ишле немецлар саны тагын да артып китте. Квантун армиясенең әсир төшкән офицерлары да безнең арада иде. 1956 елның сентябрендә илләренә кайтарылган соңгы 360 офицерның күпчелеге шул тирәдәге лагерьларда яшәп, аларның байтагысы белән мин якыннан таныш идем. Безнең арада кытайлар, кореялылар да шактый иде. «Илдән төньякта Совет иле дигән гүзәл дөнья бар икән дә андагы халаеклар оҗмахта яшиләр икән!»— дигән коткыны Кытайда кем һәм ни рәвешле тараткандыр. Шуны ишеткән ярлы-ябага крестьяннар чикне үтеп, оҗмах нигъмәтләре эзләп, туп-турыдан туп-туры урыс аждаһаларының тимер тешле авызына килеп кергәннәр. Үз ана телләреннән башка бер тел белмәгән, күз күрергә үк фәкыйрьлекләре беленеп торган бу бичараларны эре күзәнәкле җәтмә белән сөзеп кенә алганнар! Кулга төшкән һәр кытай өчен чик сакчыларын орден-медальләр белән сөендергәннәр, алар кесә тулы акчаларына шап-шоп суга-суга туган җирләренә ялга кайтып батыр булып йөргәннәр...

Әфганстан-совет чиген саклаган ленинчыл комсомоллар да тик ятмаган! Алар шыпырт кына чикне үтеп Әфган җиренә кергәннәр дә, шунда сабан сөреп, тырма тарттырып йөргән бәхетсезләрне урлап Сталин кояшы астында яктырган Совет иленә алып чыкканнар һәм... «чикне бозган» өчен хөкем чыгарып, зинданнарга бикләгәннәр. Үзләре «кыюлык һәм батырлык өчен» бүләкләр алып пионер-комсомолларга үрнәк итеп куелганнар! Безнең арада Европаның бөтен илләреннән, Кытай-Япониядән кайткан репатриантлар да күп иде. Аларны илләрдән пачкалап ташыганнар! Кемнәрдер коткыга ышанып, кайберәүләр — илгәзәк күңелләләр, туган төякләрен җирсеп-сагынып кайтканнар да, очрашу күз яшьләре кипкәнче үк совет поездлары аларны ашыктырып-кабаландырып Сталин-Берия могҗизасы түрәләренә түндергәннәр. Ерак Колыма, Магадан лагерьлары моңарчы ярап торган, хәзерге шартларда аерата куркыныч саналган тоткыннарны да, күнеккән лагерьларыннан чүпләп-йолкып, мондагы көтүләргә китереп кушканнар.

Мин «сагынып-саргаеп» килеп житкәндә лагерьлар оешу чорын үткәрәләр, эзләнәләр, аларның структуралары әле камилләшмәгән иде. Җөмләдән бер мисал, килеп төшүгә мина «Ц-86» номерын тактылар, бераздан, ни сәбәптер, аны «П-225»кә алыштырдылар. Бу — номерлар системасының эзләнү чоры икән. Инде актыккы номерым — «1-Г-732» күп нәрсә сөйли ала иде. «Луглаг» лагерь системасындагы тоткыннарның фамилияләре «Г» хәрефеннән башланган «беренче меңенә» кергән 732 нче сәяси тоткын идем мин. Мең артыннан тагын мең китә, кемне очратсаң да, син аның сан ягыннан кайсы урын билгәләнен белеп, белешеп торасың. Тоткыннарның ныклы «списочный составы» теркәлде һәм моннан ары инде номерларда үзгәрешләр булмады. Меңнәрне җыйдылар, миллионнарны көтү-көтү куып китерү йомгакланды диярга ярый. Лагерьларның шушы төгәл структурасы озакка, мәңгелеккә үк булмаса да, большевикларның кан дошманнары дөмегеп беткәнче, кумелгәнче совет властена хезмәт итәчәк. Һәммәсе шушы төп максаттан чыгып эшләнгән, шул исәптән чыгып бөтен чаралар билгеләп куелган. Ил чиген үтеп чыккан бөтен әсирләрне бер урында туплау, бандеровчыларны, латыш-литва «яшелләрен» шунда ташу, репатриантларны куып китерү, хәтерегездә саклансa нәкъ менә кырык сигездә башлана. Илленче еллар туганда дәвам иткән, бермә-бер көчәйгән кулга алулар, гигант лагерь идарәләре барлыкка килүләрнең төп максаты бер була... Бу четерекле мәсьәләгә бәяне биргәнче тагын бер төенгә — Төньяк белән Көньяк алып барган Корея сугышына күз ташлыйк. Ике илгә бүленгән бер үк халык сугыша. Асылда Рәсәй белән Америка тарткалашуы иде бу. Тоткыннар арасында: «Шушы сугыш, һичшиксез, Өченче бөтендөнья сугышының башы булыр!»— дигән хәтәр ышаныч яши иде. Дөньяны тәмамысы кулга төшерергә, аның стратегик байлыкларына хуҗа булырга ясканган ике систе-

маның кайчан да булса бер канга-кан киләсенә без тирәнтен ышана идек. Һәм менә шул, ике системаның язмышы хәл ителәчәк соңгы бәрелешкә әзерләнгәндә, Сталин-Берия җитәкләгән җәза органнары ныгытып-ныгытып Рәсәйнең эчке халәтен яхшыртырга тырышканнар. Хәлиткеч сугыш башланганда тоткыннарны нишләтергә дигән карарны алар әллә кайчан әзерләп, лагерьларның кат-кат тимерле сандыкларына салып куйганнар. «Сугыш ачылган көннәрдә үк особый лагерьларда тотылганнарны рәттән юк итәргә, тылдагы куркыныч миналардан котылырга!»

Актаска килгәннең беренче көннәреннән үк, илнең вә дөньяның бар нокталарыннан көчләп китерелгән меннәр арасында яши башлауга, безнең алдагы көнне билгеләп куйган канлы карарны ишеттек без! Ни сөйләшсәк тә сүз әнә шул очлы кадакка барып төртелә.

Ара-тирә бик оста җорлана торган җитди профессорыбыз Ростислав Иванович Илечко беркөн ах-ух килеп секциягә кайтып керде. Күзлеге котсыз ялтырый тегенең! «Ребята, мужики,— диде ул серле тантана белән.— Сугыш булмаячак!» Колаклар үрә торды, Ростислав янына очып кундык. «Булыр, булачак!» дип калтырап тор да: «Войны не будет!» Көтәбез. Ростислав көлми, ул яр буендагы балыкчы сыман җитди, тын. Озак кына карап торгач, егетнең авыз ачылды: «Иркутские лесорубы дело мира взяли в свои руки!»— дип әйтеп салмасынмы! Әйтте дә эчен уып шаркылдады: «Правда» яза. КВЧыда үзем укыдым!»

Без төкеренеп, читкә таралдык. Илленче елларда «Мир... Мир...» дигән шайтан коткылары, шул сүзгә ябышып яшәүче әрәмтамаклар, кызыл авызлар байтак елләрдә кәеф-сафа чигәләр иде. Ромеш Чандра ишеләрнең кыланмышы косасыны китерә торган иде...

Карабастан шактый күп санлы этап килеп төшкәч, Актастагы халык саны дүрт меңнән артып китте. Актас лагерен әүвәл башлап япон әсирләре салган. Билгесез сәбәпләр нәтиҗәсендә аларны немец әсирләре алыштырган. Япон, немец әсирләре бер-бер арты Актас кирпеч заводларының беренче чиратын төзегәннәр. Японнар да, немецлар да хәзерге лагерь утарыннан ерак түгел землянкаларда яшәгән. Илдә вакыйгалар алмашып торган, япон-немецларны каядыр «яшергәннәр», нәлэт төшкере кырык сигезенче ел алмашка килгән, Актаска урыслар «күчерелә». Алар кирпеч заводының нәүбәттәге икенче номерлысын салганнар һәм хәзерге баракларны җиткергәннәр. Унбер идеме, унбиш идеме, игезәк бараклар Актаста ишле генә иде. Бер-ике ел элек баракларга хатын-кыз тоткыннарны китереп тутырганнар. Ирләрне уртадагы ялгыз бер баракка бикләгәннәр. Җитмеш биш проценты бандеровчылардан торган хатын-кыз командасы бүтән баракларны биләгән. Күпчелеге бик зур срокларга хөкем ителгән латыш, литва, эстон хатын-кызлары украинкалар төркемен бизәгәннәр, санын арттырганнар.

Без килер алдыннан гына Актас хатын-кызларын моңарчы буш яткан землянкаларга күчергәннәр, саннарын киметкәннәр, хәзер анда өч меңгә якын хатын-кыз, «иң иркен, иң бәхетле ил» вәкилләре яши иде...

Шул чор лагерьларының иң якты төсмерләре ни дигәндә, шуны әйтә алам: сугыш башланган тәкъдирдә һәлак ителергә тиешле тоткыннар үзләренең хөр фикерле булулары белән аерылып торалар иде. Әле урыслар белән украиннар да туганнар кебек яшиләр, Балтыйк буе вәкилләре дә урысларга якты күз белән карый, чит илләрдән китерелгәннәр дә шау-гаугасыз гына тереклек итә, язмышлар уртак, бүләсе маллар юк, әле лагерь буржуазиясе тамырда чак, һәммәбез дә бер булып уртак киләчәккә, язмышлар хәл ителәчәк куркыныч киләчәккә карап торабыз. Чыннан да, егерме бишәр ел утыртмаслар ич тоткыннарны! Дөнья бер, ул үзгәрә тора, ил башындагылар «корыч исемен» йөртсәләр дә, «корычтан» коелмаган...

Әнә шул урнашкан татулык, бердәмлек, көннән-көн ныгый барган дуслык җәза ияләрен шиккә төшерә. Сәяси тоткыннарны иң дәһшәтле

читлекләргә төяп-тутырып, гап-гади хокуклардан да мәхрүм итеп, ярымкеше, ярымхайван итеп калдырырга ниятләгәндә, тоткыннар бердәмлек, ныклык һәм аң мәктәбен үтәләр түгелме? Сукыр түгел төрмәчеләр, күрә! Әлбәттә, бу җәһәттән төп рольне озак-озак Сталин төрмәләрендә утырган тоткыннар уйный! Моңарчы бурлар, караклар, талаучылар, педерастлар, наркоманнар белән иза чиккән акыл ияләре — сәясиләр, советка каршы чыккан күп санлы яшь отрядлар килеп кушылгач, рухи ирек, рухи туганлык сизәләр! Алар үз күргәннәре белән уртаклашалар, совет властена булган балаларча сукыр өметләрне җимереп-ватып ташлыйлар. Һәм лагерь хуҗалары ни күрә: төрмәләр үзенә бертөрле университетка әйләнә бара түгелме... Нишләргә? Зур көч түгеп бергә җыйган, ерак-ераклардан ташылган тоткыннарны бер-берсеннән ничек ерагайтырга?.. Сугыш башланган хәлдә, мондый бер йодырык булып йомарланган мең вә миллионнарны «ә» дигәнче җир йөзеннән югалтып булырмы? Илленче еллар башында илдәге сәяси тоткыннар моңарчы күрелмәгән зур көчкә әйләнә...

Бергә туплаган тоткыннарны да бер урында озак тотмыйлар, аларны эш юктан эш булсын өчен күчереп йөртәләр, мингерәүләтеп бетерәләр. Һәр этап — кимсетүләрнең соңгысе ул! Әйе, коллыгыңны әзгә генә онытып бер урынга ияләнгәндә, якташларың, фикердәшләрең белән аралар ныгыганда сине дөбердәтеп алып китеп, җиде ят арасына илтеп ташлыйлар икән, бу — бәхетсезлек. Ияләнгән җир — ияләнгән җир инде ул! Лагерьда түгел, Черек күлдә камерадан камерага куып йөрткәндә дә мин җайсызлык тоя идем. Күчерәләр икән — синең теләк-ихтыярыңнан чыгып түгел! Күчерү — рухи изүнең, түбәнәйтүнең сыналган бер әмәле ул.

Тик тоткыннарның сүзсез берлеген вату өчен мондый койты әмәл генә өз булып чыга! Дөрес, тоткыннар әле берләшү, берләшмәләр аша бер-берсен яклау хакында авыз тутырып сөйләшмиләр, әмма күпчелек үзенең ялгыз түгеллеген тоя, һәркем үз рухына яраклы кешесен эзләп тапкан, аның бер мисалы: хәзер ялгыз ризык ашаучылар юк диярлек. Ашаганда, кадерле ризыкны бүлешкәндә тел генә түгел, тешләр генә дә түгел, уй да эшли. Кемнең кем белән ризык бүлешкәнен лагерь хуҗалары күзәттеме икән, белмим, мәгәр алар ризыкның адәмнәрне җилемләүче көч икәнен аңламадылар түгел! Тоткыннарның көннән-көн ачыла баруларын, аларның кыю рәвештә уй йөртә алуларын лагерь җәзачылары күрмәде түгел. Сәяси тоткыннарның берләшүе нәкъ менә Казакъстан далаларында башланды дип расларга җыенмыйм, бәлки бу янарыш мин күрмәгән төбәкләрдә иртәрәк тә кабынгандыр, мәгәр мин килеп кушылганда тоткыннар рухлары сынган, буйсынган коллар өере түгел иде инде! Түгел! Бәлки кемнәрдер уртак югары фикерчә уйламагандыр, уйлау гына түгел, безне берләштергән идеяләрне күңелләренә кертеп чыгарырга курыкканнардыр да, әмма уртак язмышлар, уртак кичереш-гамәлләр аларны битарафлык утравыннан шаулы сәясәт диңгезенә китереп салды. Кичәрәк кенә украин авыл-урманнарыннан тотып китерелгән, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда тотрыклы белем ала алмаган ярсу-тәвәккәл егетләр сәяси лагерьларда җитди әзерлек мәктәбе үттеләр. Башын әз-мәз исәрлеккә салып, беркайчан да зонадан эшкә чыгып йөрмәгән матрос Попов, түшенә гәзитләрдән кисеп алынган Ленин ордены сурәтләрен тезеп, «Смерть Сталину!» дип язылган ак чүпрәкне маңгаена урап, түш киереп йөрде. Саналырга җыелган мәлләрдә ул мәйдан уртасына чыгып маңгаендагы өндәүне кычкырып-кычкырып та йөри торган иде. Онытмагыз, бу бит 1951 нче ел! Сталинның якынаеп килгән картлыгы, әҗәле белән яшерен тартышкан дәһшәтле еллары!

Ниһаять, лагерь хуҗалары, Бериянең өйрәтелгән этләре бу юнәлештә дә астыртын көрәшү юлларын таптылар. Бу явыз планнарында берникадәр уңышка да ирештеләр...

## 5

*Тормыш — язылган кануннардан күпкә киңрәк. Әхлак — хыялдагы шәүлә булса, тормыш — чынбарлык ул.*

Меша СЕЛИМОВИЧ. «Дәрвиш вә үлем»

Милли хис! Адәмнең меңгә тармаклана алган җанында аннан да кайнар, аннан да сизгер, аннан да нәзек берәр хис бармы икән?!

Адәм баласы үз ындыры артыннан еракка чыгып йөрмәскә дә мөмкин, аның Достоевский, Куинджи, Веласкес, Рабләларны ишетмәве дә бик-бик ихтимал, ул Шаляпинның күкләр күкрәтер тавышыннан Собиновның былбыл моңнарын аера да алмый торгандыр, аның омаркысалалардан явыз иткәне дә юктыр, мәгәр һәркемнең җанын беркетеп торучы бөек бер мәгънә бар — ул аның МИЛЛИ ХИСЕ. Милли хис бөтен чорларда да бертөсле, тапкырлау җәдвәледәй үзгәрмәс була алмый, аны адәми җаннарда эзләп табарга, сакларга, үстерергә, тәрбияләргә кирәк. Моны исә тере милләт үзе, аның барлыгын һәм бердәмлеген тәэмин иткән милли аң, туган тел, җыр-моң, гореф-гадәтләр үтәп килә. Кеше туып, сөекле әнкәсенең туган телендә: «Улым! Кызым! дип җан җылысы белән эндәшүгә сабыйның чиста-саф аң дәфтәренә тәүге милли сызык сызыла, моннан ары күз, колак һәм бүтән бар әгъзалар, күзәнәкләр аша баланың тын чишмә булып аккан канына газиз милли хис иңә, сеңә бара. Шул чакта гына кеше ярала! Кеше җанын әкрен-әкрен яулый барган милли хис никадәр югары тәрбия алса, ул кешенең иманы нык, карашы киң, күңел офыклары якты була, андый адәм, һичшиксез, ватанпәрвәр булыр. О-о, җан бизәге булган милли хисләргә саксыз кыланып кагыла күрмә! Милли хис ике яклы пычак ул, ул бөек һәм нәзек булган кебек, аяусыз, куркыныч вә дәһшәтле дә була ала! Бер милләт вәкилләре икенче бер милләт вәкилләренең җан тибешен, кан йөрешен, күз карашларын кабул итәргә, аның асылын һәрдаим югары бәяләргә тиеш. Милли хисләрнең нечкәлеге белән еш кына шовинистлар, диктаторлар, илбасарлар оста, мәкерле рәвештә файдалана. Без моның кайбер кызганыч мисалларын алда күрербез әле.

СССР җәзачылары «совет халкы» дип атарга тырышкан күп милләтле коллар төркемен һәрдаим бер-берсенә каршы куеп, бер-берсенә каршы котыртып килде. Ил буенча сыналган, ленинчыл тәҗрибәләр белән ныгытылган «каршы кую, өстерү» ысулы лагерьларга да килеп керде. Канлы палачлар адәмнәрнең милли хисләрендә оста «шаярдылар»! Әйтик, Актас мисалына күз салыйк. Һәр лагерьда КГБның вәкаләтле вәкиле бар. Актаста ул «Сухостой». Фамилиясен белми идемме, оныттыммы, хәер — аның әһәмияте юк! Урысның томанасы, әммә урыс дигәндә чәчрәп китә торган шовинист, кайнаррак урыс егетләрен чакырып ала да, тегеләрнең милли хисләрен кытыклый: «Һи-хи, Александр Невский, Суворовлар токымында да батырлар калмаган икән. Безнең көннәргә җебегәннәр генә калган! Шул хохляндиягә баш иеп торасыз бит. Оят!»

Икенче, өченче көннәрдә ул үз янына әлерәк кенә урыска каршы корал тотып көрәшкән, борын төпләреннән кан исе китеп бетмәгән бандеровчы егетләрне дәшеп ала. Аны-моны сораша һәм сүз арасында гына: «Сез нәрсә, хлопчики, горние молодцы! Һаман шул москальләрнең табанын ялыйсызмы?»

Бер җырлый шушы канлы җырны, ике, өч! Армый! Телендә гел шул. Һәм бу фикер, мондый гамь-ваемнар кара төндәге кап-кара җылан булып кара язмышка дучар ителгән, күңелләре агарып-яктырып бетмәгән егетләрнең ике төркеменә дә шуышып үтеп керә. Без килгәндә моңарчы тату яшәп яткан, бер-берсенә тартылган сәяси тоткыннар арада шомлы упкын

калдырып, икесе ике якка тартыла башлаган иде инде. Мин тагын чиләнеп төйнәлгән сораулар эскәнҗәсендә торып калдым.

Яшьлеккә мавыгулар хас. Мавыгуларның яхшыга да, яманга да китерүе ихтимал. Свердловск, Петропавел төрмәләре аша үтеп, мин яшьлегем мавыгуларына — хак юл эзләп интегүләремә чик куйган идем шикелле. Рәсәйдә илленче еллар дәвамында хак юл бары тик төрмә-сөргеннәр юлы, дөрес сүзне, гаделлекне бары тик шул юлларны үтеп кенә кабул итеп була дип уйлады күңелем. Юл дәвамында икеләнүләр, шик-шөбһәләр килеп киткәләсә дә, бары тик яхшылыкка гына омтылган туймас җаным шикләрне юлда чәчә килде. Һәр сәяси тоткын минем туганым. Украина-Балтыйк буйларыннан сөрелгән һәр кеше минем фикердәшем иде. Беләм, аңлыйм, безнең әзерлек, аң дәрәҗәләребез төрле югарылыкта булып, бик күпләр үзләренең ни өчен газап чигәргә дучар итү-ителүләрен белми дә калганнардыр. Кабатлап әйтәм, төрмә, иректә чакта бик ерак булганнарны да тигезли. Карабас күчеш төрмә-лагеренда да без тигезләр идек дип әйтәсе килә... Шунда ук исемә чыган малае килеп төшә! Тигезсезлек, капма-каршылык булган, минем яшь күңелем генә аларны күрмәмешкә салышкан.

Актаска килеп, мин тоткын иптәшләрем белән якынаймадым, ерагайдым гына. Иң беренче нәүбәттә, Николай Градобоевны югалттым. Тегендә чакта уртак буйлар, күзәтүләр, йомгак ясаулар, киләчәккә өметләр безне берләштереп тора, шуның өстенә безне биеккә күтәрә, уйларның да югарыларын уйлата иде. Актаска килеп төштек, безне шул көнне үк бригадаларга тараттылар. О бәхет! Градобоев та безнең бригадага эләкте!.. Николай секциягә караңгы төшкәндә генә килеп керде. Анда да әзгә генә... Авызы ерык егетнең, күңеле шат, уйчан күзләреннән гамь киткән. Ул көне буе әрле-бирле чапкан, нарядчикны күргән, нормировщиклар белән сөйләшкән, нык саклап йөрткән, өйдән үк килгән бик шәп мехлы күн пирчәткәсе бар иде, аны кемгәдер төрткән... Градобоевны кирпеч заводына шофер итеп күчергәннәр. Кош тотканмыни! Егерме биш еллык срогын кыскартканнар диярсең... Ялт итеп керде, елт итеп чыгып югалды.

Хәзерге акылым белән иләп карыйм: нигә үпкәләдем икән мин Градобоевка?.. Бәлки рәнҗергә сәбәп тә булмагандыр?.. Нишлисең, мин үземнән күпне көткән кебек, иптәшләремнән дә бүтәнчәрәк булуын теләгәнмендер шул! Николайның гомердә булмаганча хихылдап көлүләре, канәгатьлек белән учларын бер-берсенә ышкып сөйләшүләре, тыпырдап куюлары җенемне котырткандыр. Бәлки башка иптәшләремнең күз алдында үзгәрүләре ошамагандыр миңа? Ходам шаһит, Карабас мәктәбен бергә үткән юлдашларымны Актаста җен алыштырды! Миша Пермяковны аңлыйм да, аңлап та бетермим. Карабаста ул җан дусты гарип кыздан хәбәр ала алмады. Ул көне-төне аннан хат көтә! Хат! Сүзсез хат букчасы килсә дә разый Миша... Хохун аны кыйнап җир күмерә ясагач, мин Миша Хохунны үтерер дип куркып йөргән идем... Кызык бу кеше дигәнең! Әнисенең үчен алган, ә үзе өчен — юк... Лагерьда кеше үтерү гадәти эш дияргә ярый. Әнә, ике карт шахмат уйнап утырганда талашып китәләр дә берсе икенчесенең «манарасына» кәкре таягы белән чәпи! Ми капкачы юка булган бичараның, тәгәри дә үлә. Шул сәгатьтә бөтен карт-корыйның таякларын җыеп алдылар... Гостев белән Шороховны сирәк-мирәк кенә күрәм, койрыкларын күрсәтәләр дә югалалар. Күпме күрешми торабыз, авыз тутырып әйтерлек сүзебез юк. Яшьтәшләр, гомер юлларында хәтәргә беркетерлек бердәнбер гамәлләре — рәисне үтерү генә булдымы?..

Черек күлдә минем тормышыма байтак кеше эз сызып китте. Татар легионерлары, икенче кат утыручылардан Анатолий агай Рязанов, инженер Кулешов... Репатриантлар... Карабас Хуродзе исеме белән күңелемдә сеңеп калды. Ә бүтәннәр... Актаста яши башлауга, корт төшкән алмалар сыман, җилсез көнне дә коелып беттеләр. Җил, давыл чыкса нишләрләр иде икән алар?

Утызынчы, кырыгынчы еллар лагерьларында социаль бүленеш бик гади хәл кылынган. Бу хакта меңнәрчә сагышлы хатирәләр басылган. Сәяси тоткыннарны газаплы хезмәт белән интектереп, янгырда-карда, төньяк суыкларында, сазлык-баткакларда көне-төне эшләтеп, кешелекнең бар хокукларыннан мәхрүм итеп яшәткәннәр. Шулар өстенә тагын бер — чиксез авыр җәза тәртипләре керткән гадел большевиклар: сәясиләр арасына каракларны, законлагы бурларны, явыз хулиганнарны, Рәсәйнең җыен эшлексезен китереп ташлаганнар. Сәяси тоткыннар үзләре өчен генә түгел, әнә шул бәдбәхетләр, большевикларның гыйшкы төшкән кара йөзләр өчен дә эшләргә, норма тутырырга мәҗбүр ителгәннәр. Сәясиләргә — эш, каракларга — аш. Лагерьның әзме-күпме «җылы урыннары» каракларга. Ашханә, икмәк кисү ноктасы, хуҗалык утары — һәммәсе караклар карамагында булган. Сәяси тоткыннарга килгән посылкага хуҗалары имзасын гына сала, аны шундук «хап!» итеп караклар йота. Җәза хуҗалары сәяси тоткыннарны бергә җыйгач, аларның берләшү, туплану мөмкинлеген дә күз алдына тотканнар. Особый лагерьлар оешуга, җәзачылар сыналган ысулны кулланып карыйлар: Караганданың махсус лагерьларына каракларны, сукырларны китереп тыгалар. Ике-өч тапкыр зонадан качучыларны хәрби трибуналларга тапшырып, аларга «экономик саботаж» дигән куркыныч статья чәпиләр, егерме бишәр ел срок бирәләр, карак-бурларны да номерлар белән бизиләр. Әмма көннән-көн ныграк төйнәлә барган бандеровчылар аларны тиз айныттылар. Этап зонага керүгә, бандеровчылар күрер-күзгә блатной тоткыннарны аерып алалар да «кылдан нәзек, кылычтан үткен» күпер аша үткәрәләр. Күпчелек зонага кереп тә тормый, мәче баласыдай чыелдап: «Начальник!» — дип безелдәп вахтага, чекистлар кулы астына чаба. Табыла, бандеровчыларның тәҗрибәле штабистлары каракларның карага манчылган гонаһларын җәлт казып чыгаралар, андый очракта бандеровчылар тегенең аяк-кулларын тотып өскә күтәрәләр дә арты белән асфальтка дыңкыйлар. Өч-дүрт мәртәбә күтәреп төшергәннән соң борыннан, колактан кан китә, исән калса да, карак моннан ары чын кеше була алмый, сырт сөяге сынып яки казаланып кала. Арт саны сынган бичара этләрнең сөйрәлеп йөргәнен күргәнегез бармы?.. Карак шул хәлгә төшә. Аларның мисалларын, очрашырга теләмәсәк тә, алда күрербез әле.

Без килеп төшкәндә зонада андый сурәбәтләр шактый иде шикелле. Бер көнне бараклан чыгып киләм: Седой кушаматлы урыс егете, Юра исемле шестеркасына кәстрүл тоттырып, ашханәдән кайтып килә икән. Юркага бәрелеп чак кына кәстрүлен җиргә төшермәдем. Седой: «Гужуйтесь фраера, пока урки спят!» — дип акырып өстемә килә. Мин: «Виноват!» — дип кырыйга тайпылдым. Седой: «Виноват, виноват! Накажем!» — дип йодрыгын баш өстемдә уйнатты. Ярый, минем арттан ук бригада егетләре — бандеровчылар килә икән, алар хәлне аңлап, безне чолгап алдылар. Седой да, аның тугры хезмәтчеләре дә йом булдылар. Юра житез, хәрәкәтчән, йоп-йомыры үзбәк үсмере, үзе дә карак, лагерьның мәшһүр талаучысы иде. Озакламый аны этапка кудылар, шунда, зоналарның берсендә, төзелеш басмасында кәефләнеп кенә ялкау симертер ятканда, тук һәм мәс Юраның башын кисеп ыргытканнар дигән хәбәр килеп ирешге.

Урыслар берләшә, украиннар берләшә, литвалылар уянып килә, Актас зонасында әтрәк-әләмнәргә рәхәт калмады шикелле. Бу аз санлы сорыкортларга урын бетте, көн калмады, аларны каядыр олактырдылар. Җәзачыларга алар белән хушлашу авыр булгандыр дип исәплим, сәясиләр өстеннән күзәтчелекне дә, гадәттә, шул төркемнең сатлык җаннары башкара иде дип беләм! Һава сафланып калды...

Шуны да өстәп әйтим, зона сасыткан бурларны бандеровчылар шактый кырды да! Алар, гомумән, үз тәртипләрен куярга, тәртипне үзләренә кулай итеп урнаштырырга ярагалар иде. Ике зур милләт вәкилләре күзгә күренеп оешып килгәндә бүтән, вак халык вәкилләре дә әз-мәз

төркемләнә башладылар. Литвалылар йодрыгы да йомарланды, яшьрәкләре чалбар балакларын киңәйтеп тектеләр, иртәнге барлау мәйданына алар төркем-төркем оешып чыгалар һәм башка төркемнәргә каш астыннан гына карап торалар. Нәкъ шул чорда «каралар» дип аталган махсус төркем хасил булды. Кавказлылар, усал һәм гайрәтле егетләр, Урта Азия халыклары, гөржи-әрмән, үзбәк-таҗик, төрекмән-кыргызлар шул тирәдә укмашкач, «каралар партиясе» дә шактый күп санлы булып чыкты.

Инде, сүз җебе тәмам онытылмасын өчен, Актас лагерендагы миңа кагылышлы хәл-әхвәлләргә кайтыйк.

Мин кирпеч заводында эшләүче яңарак оешып килгән Федор Лобков бригадасына эләктем. Төзелешкә, шахтага билгеләнгән белеш-танышларым миннән көнләштеләр. «Кирпеч заводы — җылы урын, анда инде җәһәннәм суыкларында да катып үлмисең!» — диде кемдер. Тоткынның беренче аяусыз дошманы — ачлык икән, ямандыкта аның рәтендә торганы — салкынлык. Шушы кыска гына вакыт эчендә Караганда далалары патшасы — җилнең көчен, аяусызлыгын, зәмһәрир суыкларның пырдымсызлыгын тулаем белеп бетерә алмасам да, казакъ кышыннан куркып өлгердем. Зона яшәеше табигать капризларына тыгыз бәйләнгән, салкын җәзачылардан бер дә ким түгел — ул сине әллә кай тишекләрдән дә эзләп таба. Колыма-Магаданны кат-кат иңләгән тоткыннар беравыздан: «Да, җылы җир — бәхет ул!» — дигәч, кирпеч заводына эләгүемә сөендем. Югыйсә, эшнең авырлыгын кисәтеп җанымны куркытып бетергәннәр иде.

Федор Лобков, йомшак төк белән капланган бит-яңаклары кыпкызыл, тездән түбән озын бушлат кигән, тәбәнәк кенә урыс иде. Яшькә миннән чак кына өлкәнрәк булгандыр, кайсы як кешесе, ни сәбәпле утырткаңнар, мин аларын белми калдым, әлегә мин салага, вак балык, бригадир янына барып, гәп сугып, аны-моны белергә теләп сүз куертырлык дәрәҗәдә түгел. Солженицын: «Бригадир — это кормилец!» — дип юкка гына әйтмәгәндер. Секциягә кердем, төйнәлгән әйбер-караларымны (Градобоевка рәхмәт!) баш астыма салып, вагонканың какшау гәүдәсен дер-дер селкетеп «икенче этаж»га мендем дә сузылып яттым. Советлар Союзының иң алдынгы «эшче сыйныфы»ның какшамас бер бөртеге булып китте абзагыз.

1951 елның язын мин төрледән төрле эшләргә куелып, Актас кирпеч заводында үткәрдем. Ташкүмер төягән вагоннар килә икән — без анда. Күмер бушатабыз. Тимер юлны тип-тигез җиргә сузганнар, хәзер ике яктан да дамба өелеп, рельслар аста калган. Вагон ишекләреннән кашыклап кына чыгып торган күмерне көрәкләр белән интегеп читкә чөяргә кирәк! «Әгәр эстакада булса соң, эш мең җиңеләер иде!» — дип сукранабыз, ләкин тоткын авызыннан чыккан сүзне хуҗалар берчакта да ишетми! Вагоннарны тоткарларга рөхсәт юк, безне каулыйлар, «вольняшкалар» — цех начальнигы, мастерлар безнең яннан китми, надзиратель дә шунда урала, ара-тирә безгә җикеренеп куялар. Градобоев куктә йөзә! Аның кәҗә хәтле генә иске «чытыр арбасына» күмерне без төйибез.

Вагоннарны бушатып бетереп, кара тирне сыпырып алырга да өлгермибез, безне кирпеч төяргә җибәрәләр. Ай-һай, авыр эш! Гофман мичләре алдына кирпечләрне шакмак-шакмак тау итеп өйгәннәр, шул өемнәрдән вагон-платформаларга тимер тасмалар сузасың, алтмыш-җитмеш кирпеч төялгән тачкаларны җан көчең белән этә-этә, вагон тирәсенә китереп туктатасың. Һәр платформага дүрт мең яки артыграк кирпеч сыя. Нормасын хәтерләмим, мәгәр үткер кырлы, чын чынаяк кебек, зыңгылдап торган ап-ак кирпечләрне ташый-ташый кәҗә маең чыга, бияләйләр теткәләнеп бетә, бияләй тишекләреннән чыккан бармаклар суелып чиләнә, каный. Җәрәхәтләргә кат-кат утырган тузаннан чыдар әмәл юк. Төйисең, авыр тачка артыннан йөгерәсең, вагонга бер менәсең, бер төшәсең. Лобков бригадир буларак явыз түгел, мәгәр тик торганны сөйми торган шактый быткыч адәм иде. Норма һәр көн үтәлергә тиеш!

һәр көн! Житмәсә, бер бригадир тирәсендә өч-дүрт кеше ялмана, алар эшкә төп-төгәл чыгалар, завод ихатасына кергәч күздән югалалар, кайтыр алдыннан тагын пәйда булалар. Федор Лобков тирәсенә шактый сәер кешеләр тупланган, бригадирның тән сакчылары дип тә атап булмый аларны, аның көнкүрешен кайгырта вә җиңеләйтә торган адәмнәр дә түгел... Полковник Каршаков Василий Федорович. Төрмәдә дә таудай корсагы шиңмәгән, кue кунык белән капланган эре тешле, калын тавышлы, юк өчен дә шаркылдап җибәрә торган бу гамьсез-ваемсыз кеше белән Лобковның ни уртаклыгы бар? Ясмык-ясмык шадралар бизәгән битле, тар чебеш күкрәкле, зәгыйфь кәкре аяклы Иван Домрачев. (Икенче фамилиясе Бочарников иде!) Карабас триосының күренекле җырчысы Володя Кондаков бу өергә каян килеп кергән тагын?.. Юньләп эшләмиләр, ашаганда кашыкның дәве алар кулында, эштән буш чакларда Лобков ятагы янына елышалар да, кияүгә китә алмаган кызлар сыман, чышын-пышын өзлексез сөйләшәләр. Ишеттермиләр, каһәрләр!.. Димәк, ниндидер серләре бар. Димәк, катлаулы һәм чуалчык зона тормышының мин белә алмаган үз серләре, үз мөнәсәбәтләре бар. Өчесе тиң шактый өркәк, моңа кадәр шактый чуар зоналар аша үтеп, карак-угрыларның гадәт-йолаларын ияркән Володя белән Иван бандеровчылардан бик нык шүрлиләр иде. Артларында пычрак эзләре бар идеме, белмим, андамонда, украиннар белән урыслар әрепләшкән мизгелләрдә койрыкларын кысалар иде. Ә бандеровчылар үз көчләрен еш-еш күрсәтеп, зонадагы өстенлекләрен расларга яраттылар.

Менә секция ишеге киерелеп ачыла, аннан ун-унбиш егет җил-давыл булып бәреп керә, алар тамак төпләреннән гайрәтле аваз чыгарып: «Утыр! Кузгалма! Утырырга!» — дип боерык бирәләр. Кулларда пычакхәнҗәрләр җем-җем итә, пычак чыгармаганнар кулларын итек кунычларында, билләрендә тоталар. Алары да кораллы! Секция шым булып сеңә, без тын тартырга да кыймыйча керүчеләрне күз чите белән күзәтәбез. Кемне эзәрлекли алар, максатлары ни, сорашырга куркыныч, ә төркем үзәгендә торган бандеровчылар арасында минем якыннарым юк иде.

Кемнәрдер бер-берсенә тартылалар, оешалар, шуннан тәм, юаныч табалар. Әллә бүтән серләр аларны берләштерәме?.. Диндарлар: «Субботниклар», «Иегово шаһитлары», моңарчы ишеткәнем дә булмаган тар мәзһәб вәкилләре туктаусыз эзләнәләр... Озын буйлы, тотлыгып сөйләшүче майор Тихомировны «Иегово шаһитлары» барлап, үзенә тартты. Әсир төшкән, немецта йөз мәртәбә кыйналган, үзебездә мең мәртәбә тукмалып теле тотлыккан, җаны теткәләнгән арык бу кешене асылынган җиреннән бавын өзеп тартып төшергәннәр... Хәзер асылынмас, кайгыхәсрәте дә кимрәк булыр: диндарлар арасында аның абруе зур!..

Зонада ниндидер хәрәкәтләр бара, ул тере, кыймылдый, кайгыра, бәргәләнә. Карабастан килгән Николай Лаврентьевич Новиков вафат. Тамагы ач булса да, кич буе җырлап утырган, җыры хырылдауга күчкән. Сүзен дә әйтә алмаган... Хәер, ни әйтәсе калды икән бичараның?.. Безгә күрше секциядә заводның тимер-томыр тирәсендә кайнашучылары яшәп ята. Бригадирлары Сидоров фамилияле аю, фил дисәң дә ярый, тап-таза гайрәтле урыс. Әмма чебенне дә рәнҗетми торган әүлия, үз бригадасына тап булган гарип-горабаны да чит итми, зарланмый, ничек тә җаен табып, тамагын туйдырырга тырыша. Асыл ир! Тимер-томыр тирәсендә белмәгәне юк дип сөйлиләр. Зонаның күркәм кешеләре дә, эте-кошы да күзгә бәрелеп, аерылып тора башлады. Барак ишеген кергәч тә сул кул якта, иң читтә старостаның нәни генә секциясе. Безнең староста — Хәсәен Зәлиханов исемле балкар. Алтын тешле, ак чырайлы, тезләрен бөгеп, аяк башларын аерып, иләп кенә йөрүче бу адәмгә якын барырлык түгел, һавалы, тәкәббер, текә кеше. Барактагы эчке тәртип өчен ул җавап бирә, диләр. Якташы балкар Магомед Толгуров — кыяфәте белән дә, торыштотышы белән дә кара крестьян. Җир кешесе. Зәлиханов түгәрәгендә

тагын ике сәер кеше бар, икесе дә кабардиннар. Хәмит исемлесе безне күптән инкубатор чебешләре итеп бертөрле киемнәргә урасалар да, һаман үз өс-башыннан йөри. Шулкадәр шома, елгыр егет Хәмит, заводка чыга, кыл да кыймылдатмый, гел механиклар тирәсендә урала. Хәмит — дөньяның мөгезеннән элэктергән егет, заводта хәнҗәр ясый, кыра, үткенли, әле бандеровчыларга, әле урысның кәттә егетләренә шуларны сата, дигән сүзләр йөри. Дөрес булгандыр ул!.. Мал таба, яхшы ризыктан өзелми, бандеровчылар арасыннан яшьрәкләрне, симез-түгәрәкләрне сайлап «куенына ала» дип тә сөйлиләр. Булыр, булыр... Староста чоланыннан соңгы кеше Алихан атлы кабардин иде. Калын, башмак иренле, карасу-тутлы йөзле бу кеше Магомед шикелле үк крестьян иде булса кирәк. Әлеге зона буржуазиясенең ишеген ачып караганым булмады, нигәдер бу төркем вәкилләренә катнашып китәргә курыктым, алай да Магомед Толгуров миңа бик якынайды. Балкарча эндәшә, мин татарчалыйм, бер-беребезне җиңел аңлыйбыз. Хәер, зонада ятлар белән аңлашканда телгә ничә сүз кыстырасың инде? Күпчелек тамак ягын кайгырта, сүз гел шул тирәдә әйләнә. Хөсәен Зәлихановның мине туктатып эндәшкәне, ары-бире хәл белешкәне юк иде шикелле. Барак старостасы зур кеше, надзирательләр дә аңа баш кагып, күрешеп китәләр, кичләрен секциядән җыр тавышлары яңгырый. Хәзер беләм, «придуроклар» кәеф-сафа коралар, чефир эчәләр һәм ач малайларны бозалар...

Зонада тормыш гел буталышлардан, чуалышлардан тора. Бер буталыш икенчесен тудыра. Җәзачылар да тынмый, арабыздан күренеклерәк шәхесләрне чүпләп-чүпләп алалар да этапка куалар. Кемдер китә, кемдер килә. Украинаның көнбатыш өлкәләрендә ир-ат калдымы икән? Львов, Тернополь, Ровно өлкәләреннән халык килә тора, сеңә тора. Александр Хуродзены Спасск төрмә-лазаретына алып киттеләр. Үләргә. Аның соңгы сәгате якынлашканын врачлар да, лагерь хуҗалары да белеп тора, һаман рәхим-шәфкать юк бичарага! Җан биргәндә авызына су салучы да булмаячак! «Империя таралачак!» — дип ымсындырган, дәртемне кузгаткан беренче кеше идең син, Хуродзе агай!..

Кемнәргә таянып, нинди уйларга чумып, шундый нәтиҗәгә килә алды икән ул?.. Әллә шул утлы фикердән чыгып, лагерьдагы беренче көннәремдә мин юлдашларымнан риза булмыйчарак мырлап яшәдемме?.. Кем хокук биргән мин — авыл гыйбатына бөтен кешеләрдән нидер таләп итәргә, таләпләрем үтәлмәгәндә нарасыйлык күрсәтеп сукранырга, эчтән янарга?..

Хәзерге акылым белән уйлыйм: мин үземне белә-белгәннән язучы булу турында хыялландым!.. Дүртенче класста шигырь-поэмалар язып, аннан хикәя-пьесаларга күчеп, язучы булып яшәдем! Төрмәдә дә мин язучы идем. Әзерлегем бәләкәй, офыкларым бикләнгән булса да, күнелем чикләрне үтеп чыга алырлык дәртле иде. Тормышны да мин әдәбият мәйданы, сәхнә итебрәк күрдем шикелле. Әнә шул югарылык, биеклек, язучы дигән җаваплы исем бик яшьли сеңгәнгә, мин еш кына буш хыялый, җилле-давыллырак җан булып калдым бугай. Бүтәннәргә караганда бер өстенлегем дә бар иде: дөньяга мин әдип күзе белән карый идем. Кешеләрдән дә шундый үзенчәлекле тормыш мисаллары көткәнгә, Градобоевларга да, Гостевларга да өстән торып, хөкемдар рәвешендә карадым. Мин һәр адымым белән әнә шул бөек максатыма — язучылыкка якынайганда күңелгә ниләр килеп ниләр китмәгәндер дисең?! Иптәшләр бер мәлгә таралды, мин моны шактый авыр кичердем, ләкин ул дәвердәге таныш-белешләремә мин гомергә рәхмәтлемен: без алар белән бергә Карабас дигән мәктәпне үттек. Карабас Актасны әзерләде. Әдип исә тормышны тоташ хәрәкәттә,ербөтен итеп күрергә тиеш. Юк икән, аның иҗатын сугарып торучы чишмәләр юк, коесы кипкән... Меңләгән җаннарны бер бик астында йомарлап тоткан Актас мине яңа кешеләр, җанымның кайнарлыгын, намусымның сафлыгын саклап калырга ярдәм иткән гаҗәеп бай кешеләр арасына выжгытып алып кереп китте.

*Безгә курку иңде, хәзер шул җитәкләп алып бара. Без сөйләсе урында ул әйтә, оялсак та хәзер ул хуҗа!*

Меша СЕЛИМОВИЧ. «Дәрвиш вә үлем»

Син — бик астында. Тормышың чикләнгән. Явыз кануннар сине бөтен яктан камаган. Әле хат алучылар бик сирәк. Безнең белән яки бездән соңрак килгәннәрдән илгә, өйгә хәбәрләр китсә дә, кем белгән — чыннан да, киткәннәрме алар, әллә цензура киштәләрендә аунап яталармы?.. Биек-биек коймалар, кышкы карда куян эзе сыман чигелгән чәнечкеле тимер чыбык киртә-аулары. Без беркая чыгып йөри алмыйбыз... Эшкә барып-кайтуны санамыйм, син анда да мең күз бикләгән сак астында... Ачлык тагын безне куып җитә, аны тоткарлый торган коймалар юк. Беркем беркаян посылка алмый. Сатыласы киемнәр шуып беткән, күбесен тәмәкегә алмашканнар. Тәмәке — төрмәнең валютасы ул. Бер төрерлек тәмәкегә бер пайка ипи бирүчеләр дә бар. Бар шундый сазаган тартучылар, алар бер суырыр өчен җаннарын бирергә әзерләр! Безнең бригада һаман төрле эштә изалана. Бер көнне безне машиналарга кирпеч төяргә куйдылар. Кирпеч күп җыйналган, машиналар чутсыз килгән, төяүчеләр үзләре генә өлгерми, имеш. Баксаң, аларның эш шактый хутлы икән лабаса!.. Шоферлар төпчек тә калдыралар, кайбер бәхетлеләргә пачкасы белән махорка да биреп киткәннәр. Аларга хат тапшырырга да була икән!..

Мөхтәрәм укучым! Әгәр минем язмаларым мажаралы бер сызыктан ялганып-ялганып бармыйлар икән, кичер!.. Язып уза торган хәлләргә ярты гасырга якын вакыт үтсә дә, хәтерем бик күп гыйбрәтләрне түкмичәчми саклап йөртте. Әле мин йөзләрчә кешеләрнең исемнәрен, төскыяфәтләрен, зонада чиккән газапларын бүгенгедәй хәтерлим, хәтердә чакта тын гына, ара-тирә мине борчып, аннан тагын тынычланып, ми күзәнәкләрен биләп яткан хатирәләр кәгазьгә күчә башлагач, тәмам җанландылар. «Мине яз! Безне онытма!» — дип йолыккалыйлар, унгасулга тарталар, һич көтмәгәндә артка да сөйрәп тинтерәтәләр. Әгәр вакыйгалар бер-берсен узышып, көннәр-айлар, хәтта ки, еллар буталып китә икән, моңа вакыт гаепле... «Ачлык» дип авызымны ачтым да, инде үзем дә ялыгып беткән шушы яман хәл хакында языйммы-юкмы, дип үз-үзем белән байтак сугыштым. Әле минем һәр милләт вәкилләренең ачлыкны ничек-ничек кичерүләре турында да язасым бар. Күп әле гыйбрәтләр, күп, бер-бер артлы ишелеп ага алар!.. Зона ачлыгын әз-мәз күз алдыгызга китереп бастырыр өчен кыска гына язып узам...

Ачлык безне тәмам ваклады. Режим дибез, паек дибез, зонага ипи килмәгән көннәр була! Көне-төне буран котыра, юллар өзелә, машиналар йөри алмый — ипи юк. «Ач кешенең ачуы яман», тик без ачуны читкә чыгармыйбыз хәзер. Зона хуҗаларына сүз әйтергә куркабыз. Ачлык кансыз хуҗаларның күңеленә шәфкать иңдерә дип уйлыйсызмы?! Кашки шулай булсачы! Ары-бире телдән карышкан, эшкә чыгудан баш тарткан кыюракларны дөбердәтеп карцерга ябалар да... зонасында ачлык патша йөреп торганда карцердагы хәлләрне күз алдына китерү кыен түгел!

Һәркемгә җаны кадерле, һәркем җан саклауның юлын эзли, чәбәләнә. Иртәнчәк, барак ишекләре ачылуга, бер иш тоткыннар атылып диярлек чыгалар да, сөйрәлеп, кыптырдап ашханәнең су түгү чокырына юнәләләр. Шәүләләр, күләгәләр бара! Һәркем узарга тели! Бер-берсен төрткәлиләр, аяк чалалар, егып калдыралар. Тизрәк, җәтрәк, бәрәңге кабыклары, ашлы сулар түгелгән урынга барып җитәргә кирәк. Янгышмонгыш бер-ике бәрәңге дә таба алсалар... Шунда ук чи килеш кимерергә тотыналар. Бәрәңге кабыгы, калдык-постык замат арасында юк була...

Иртәнге чәйдән соң атлы чанага төяп хуҗалык утарыннан көндәлек паек ашханәгә кайта. Капка белән ашханә арасы ике йөз метрдан артык. Ризык төягән атлы чана күренүен илле-алтмыш тоткын сагалап тора. Чанада бәрәнге, саргайган ак кәстрүлләрдә әче кәбестә килә. Ит, балык ише нәрсәләр дә була. Мәгәр аларның күпчелеге зонага кереп тә житми, лагерь башлыклары, офицерлар итне-майны кая җибәрергә кирәген беләләр!..

Эш дигәнең канны суыра! Кирпеч заводын аласыңмы... Пресста бертуктаусыз агып торган юеш балчык кирпечләрне кулдан-кулга йөртә-йөртә җаның гына тәндә исән кала! Ә шахта казучылар?.. Сменасыз эш, кулда отбой чүкече, алдыңда үзле тыгыз балчык, өстеңә шыбыр-шыбыр көне буе су ага! Мине күзлек кенә коткарды, югыйсә мине дә су астына төртеп төшерәләр иде...

Тоткыннар корык-корык ютәллиләр, төннәрен бараклардан ыңгырашу, җылау тавышлары туктаусыз ишетелеп тора. Күпләрнең эче китә, кан төкерәләр...

Бер кичне, отбой булыр алдыннан безнең секциягә алты-җиде әзмәвердәй егет килеп керде. Алар мәһабәт гәүдәле, гаять таза, кып-кызыл чырайлы, гәүдәсеннән көч-гайрәт бөркелеп торган берәвесен уртага алып, өчәр-өчәр кырыйларга бастылар. Колагыма ишетелмәгәндер дип гамьсез генә утырып торам, теге баһадир мине сорый, имеш. Зонаның өлкән пешекчесе кырым татары Мохтар мине эзләп кергән икән! Зонадагы гайрәтле хуҗаларының берсенә: «Казаннан бер татар студенты килеп төште»,— дигән хәбәр ирештергәннәр икән Мохтарга. Разведкасы шәп эшли өлкән пешекченең. Мохтарны белмәгән кеше юк, минем колагыма да чалынган иде, бригаданың йокысы качты, бөтен күзләр бездә! Лагерьларда җидеме, сигезме дошманын теге дөньяга җибәргән, катлы-катлы срокларга хөкем ителгән, ызгыш-талашларда берәүгә дә баш бирми торган, чиксез көчле Мохтар легендар бер шәхес иде. Урыннары дәрәҗәләрәк кешеләр катында каушап кала торган мин — сарык телемне йоттым, биргән сорауларына ык-мык җавап кайтарырга тырышып, иягем белән түшемне кашып, күз күтәрергә дә кыймыйча дөмегеп утырам. Мохтар миңа урысча дәште, авыл кабартмасы булуымны ике сүземнән аңлады, әле төрмә тәҗрибәм дә сай икән, көч-гайрәтне сынаганда да, буй дисәң буй юк, физик эштә чыныкмаган... Тагын ниләр уйлагандыр миңа карап Мохтар-пешекче, ул сүзне озакка сузмады, ашханәгә килеп йөрергә, йомыш-кара чыкканда туп-туры үзенә мөрәҗәгать итәргә боерды. «Кил, мин анда раздачага әйтермен, кисәтеп куярмын!» — диде. Калкынды, вагонкалар арасына кысылып, безнең тарафка колак-локаторын юнәлткән бригадашларым чәчелеп, аңа юл бирделәр.

Моннан берничә көн элек яңа танышларымның берсе, мәскәүле урыс егете, сөйкемле һәм зыялы студент Анатолий Кузовкин кырым татарларының берсе белән өстән-өстән генә таныштырган иде. Кыргызга тартым кыяфәтле, ләкин озын буйлы, арык кына кырыс адәм: «Менә синең землягың!» — дигәч, кылычтай озын танавын ямьсез җыерып: «Мондый күзайнаклы адәм нишләп минем землягым булсын!» — дип шиген белдергәч, кырым татары бер секунд эчендә сөйкемсезгә әйләнде. Абдулла Жумаев ППЧда нормировщик булып эшли икән, придурок, танауны өстәрәк һәм җилдә тотарга остарган тоткын. Абдулла белән без бер чакта да якыная алмадык. Кырым татарларыннан тагын ике тоткын бар иде. Кайсы урыннарда эшләгәннәрдер, якташларының берсе өлкән повар, икенчесе нормировщик булгач, бәрәнге кабыгы эзләп чыгып чапмаганнардыр, кыяфәтләре дә тук, шактый таза күренә иде. Казанча сөйләшә алмагач, мин аларга тартылмадым, татар дип кабул итмәдем. Берәвесе төп кебек юантык, киң битле, киң маңгайлы утыз-кырыклар тирәсендәге Кырым кешесе иде. Күрсә ерактан ук кулын сузып килә, йөзе яктыра, моның әллә нинди олы йомышлары, әйтәсе сүзләре бардыр, дип уйлыйсың... Килә, килә, кулларымны тотып ала: «Әхвәлләр кандай?»

дип сорый да жил-жил үтеп тә китә. Кырымчалап: «Яваш, яваш!»— дип җавап бирергә дә өлгерми калам. Дүртенче татар яшь, кап-кара, сылу егет иде. Анысы бөтенләй сөйләшми, очрашсак елмая, кулын җилкәмә сала, шулай сүзсез-өнсез аерылышабыз. Шунысы гаҗәп, татарларның икесенең дә үз тешләре юк, авызларын елтыр-елтыр килеп торган эре-эре алтын белән тутырганнар иде.

Көнләшүчеләр пәйда булды, табылды! Бригадада миңа мөнәсәбәт капылт үзгәрде. Кемдер кәтилүгең биреп тормакчы булды, кемдер ашханәгә мине ияртеп йөрергә җыенды. «Хәзер синең эш на мази! Көне-төне гужуйся! Мохтар әйтсәме... Тамак сыйлы хәзер синең! Барак старосталары, нарядчик, нормировщиклар белән бер казаннан ашый башлыйсың!» Әллә тамагым ачка, әллә ач иптәшләремнең коткы-хорыннан исереп, кемнәндер кәтилүк алып, аска карап, курка-курка ашханәгә атладым. Меңнәрчә май, су таплары-тамчылары белән чуарланган, җылы пар һәм әллә нинди исләр озатып торган аш бүлү тәрәзәчеге янына мин бик озак бардым бугай. Теге яктагы, башына кайчандыр ак булып хәзер сорыга әйләнгән башлык чәпәгән, дәү корсагы шуып идәнгә төшмәсен өчен киндер алъяпкыч белән кысып куйган, кысык күзле бер бәндә: «Мохтар...»— дигәнне ишеткәч, минем ямьшәйгән кәтилүкне калтыранган кулымнан тартып алды да күздән юк булды. Бераздан әйләнеп килде, кәтилүктә без һәркөн ашый торган сыек, төссез баланда чайкала иде. «Тамак сыйлы!»— дидем үз-үземә, гарьләнеп. Сер бирмәскә тырышып, көлемсерәп кайтып кердем, өскә үрмәләдем һәм чыраемны күрергә теләгәндәй баланда өстенә иелдем. Кашыгымны тыгып карыйм, йөрми, каядыр куега эләгә. Баланда астында тыгыз пешкән, майлы тары буткасы икән! Ялт иттердем тегене, ашап бетергәч кенә иптәшләргә карадым. Алар кайсы өстән, кайсы астан шыпырт кына мине күзәтәләр икән! Шулкадәр оялдым, җир тишеге булса, вагонкамнан сикереп төшеп, шунда кереп убылырдай булдым!

Тәңрем, шушы минутларда сиңа баш орам! Ходам, үзең шаһит! Илаһым, һәммәсен беләсең: кәтилүк күтәреп теге тәрәзә-авыз каршысына яңадан эз дә басмадым! Тәнем чирканды, каным котырынды, иптәшләрдән кайберәүләр: «Ник бармыйсың? Ник йөрмисең?»— дип сораштырганда дәшмәдем, иягемне генә як-якка кактым. Хак, юмарт күңелле, искиткеч мәрхәмәтле Магомед Толгуров барак старостасыннан калган ашларны мичкә яшереп куеп эштән кайтканымны көтә торган иде. Калган ашлардан баш тарта алмадым. Ачлык биткә ыштыр элә торган яман, үтә яман китмәс чир икән ул!

Зонаның үзенә генә хас сүзлек составы бар. Без дә яңа сүзләр, өр-яңа тәгъбирләр ятлап алдык. «Доходяга» диләр икән, беләсең, ачлыкның соңгы чигенә килеп җиткән адәмне күз алдына китерәсең. «Фитиль» дисәләр, бусы тагын да куркыныч, димәк, тоткын чикне үтеп киткән. Аннан бер генә юл кала бичарага: «агач бушлат» кия! Җаны күккә очып киткән тоткынга «агач бушлат» кигертеп маташмыйлар маташуын... Хәзер хуҗалык утарыннан атлы чанага төялгән бәрәңге-кәбестә кайта башласа, чананың ике ягына кулларына күсәк тоткан сигез-ун кеше тезелә. Тоткыннар җилкәләренә төшкән күсәккә игътибар да итмичә чанадагы капчык-савытларга карчыгадай ташланалар, кулларына ни эләксә, шуны гел-гел ачык авызларына тутыралар... Ат алдыннан барган әзмәвер юлда басып торганнарны тибеп-тибеп очыра, ә чана тирәсенә сырышканнарны бүтән каравылчылар рәхимсез рәвештә дөп тә дөп төяләр!

Имән дөмбәскәдәй ирләр әкрен генә эри... Ирләрнең нинди мөшкел хәлгә төшкәнен мунча кергәндә күреп имәнеп китәсең.

Мунча, мунча! Җанга рәхәт, тәнгә сихәт биреп, гомерне озайта торган урын. Этапта куганда мунчаны еш керәсең. Этапта куганда җәзачыларның иң курыкканы — бет. Бет — чир ташый, бет — сәяси тоткыннардан кала, бериячеләрнең иң көчле дошманы. Аның белән көрәшә-

ләр, бөтен фронт буйлап ударникларча көрәш җәелдерәләр. Кайсы төрмәдән этапка кусалар да, сине мунча хөрмәтеннән башка юлга чыгармыйлар. Бармы су, юкмы су, кайнармы ул, сап-салкынмы, аны тикшергән кеше юк, син тазыңны һәм авызыңны күтәреп, йомык борынлы краннан су тамганын көтеп торган арада синең кием-салымың эссе камерада пешә. Анда җәһәннәм. Анда тәмугның үзе. Анда социализм бетләренә каршы удар көрәш бара! Камера ишеге ачыла, синең сәләмәләреңне идәнгә чыгарып ыргыталар. «Киенергә!»— Команда кырыс, житди. Киемнәрдән көйгән ис тарала, элгән бөжраларга кул тидерерлек түгел... Юлга чыкканда шундый тиле мунча аша узасың, барып төшкәч, «кичке мунчада» шул ук сынауларны кабатлыйсың. Җәзачылар бетне ярата, алар бет эзли! Җәзачы-берияче ләр көрәшсез тора алмый, аларга һәркөн, һәрдаим көрәш кирәк! Көрәшергә Ленин бабабыз кушкан! Серкә-бетләрне тәки җиңеп чыгалар! Кыздыралар, куыралар, яндыралар. Бара-бара өс киемнәреңнең кылкасы гына кала. Мондый галәмәтләргә бет түгел эт тә чыдамас!..

Яңа тормыш, яңача гыйбрәтләр аша телгә яңа сүзләр кереп ныгый. Элек күңелне җылытып, бизәп торган кадерле сүзләр һаман чигенә, ерагая баралар. Бет — дошман, аны җиңдек. Әле кандалаларга көрәш ачасы бар! Икенче фронтны американнар сыман озакка сузарга ярамый. Кандала — көчле дошман, хәйләкәр. «Кандала — большевик ул,— диләр үзара,— үзе кызыл, үзе кан эчә, үзенең исе, ай-һай, зәһәр!» Кеше арыклаган саен аны кандалалар ярата төшә. Берзаман фитиль-тоткыннарның берсе вагонка тактасы буйлап кандала йөгергәнне күрә. Шап бармагы белән тегенең өстенә! Карый, кандала бармак астыннан чыккан да үз юлы белән элдерә. Нygытып, бар көченә тагын бер баса теге бичара. Юк кына бит, кандала шуа да чыга, шуа да чыга. Чыдары беткән фитиль җылап җибәрә: «Стальной што-ли!..» «Әйе, төрмә кандалаларын да корычтан коялар икән! Кирпеч заводында җылы, тышта-буранда, җил күзендә казынсаң да, туңсаң, кирпечтән бушаган мичкә кереп котыласың. Җылы бар икән — ачлыкны да җиңеп була. Кирпеч заводының абруе көннән-көн күтәрелә, чөнки ябыга, арыклана барган саен адәмнәр салкынга тизрәк бирешәләр. Ачлык белән суык бу сиңа бет белән кандала гына түгел инде!.. Лагерь авыз иҗатыннан бер гыйбарә күңелемнән китми. «Костер все ниже-ниже, а фитили все ближе, ближе!» Ходавәндәм, әгәр мин рәссам булсам, Сталин чорының истәлеге итеп шушы коточкыч рәсемне язар идем!.. Төзелеш... Кирпеч өемнәре. Җил. Салкын. Тыннарны куыра торган суык. Фитиль-тоткыннарны эшкә куып китергәннәр. Бичаралар каяндыр йомычка-чыра юнәтеп, ут тергезгәннәр. Учакны урап алганнар, кысылышып түгәрәкләнгәннәр. Ә утын әз, җылы саран... Учак уты бетәм, бетәм дип калтырый. Ә тоткыннар кысыла-кысыла учак өстенә иеләләр... Бер-берсен төртеп чыгарырга житешеп җылыга тартылалар.

Озак еллар ачлыкны татыгач, ул хатирәләрдән китеп тә, котылып та булмый. Ипекәйне мин утыз яшемдә генә туя ашадым, утызга житәрәк шоколадтан авыз иттем, утыз биштә шампан шәрәбен эчеп карадым. Һәр милләт ачлыкны үзенчә кичерә, ашау, ризык эзләү, юнәтү җәһәтеннән дә һәр милләтнең үз алымы, үз ысуллары бар. Актаста, әйткәнемчә, кытайлар шактый иде. Кытайларның күплеген яз житеп, кар эреп беткәч абайладык. Менә чәнечкеле тимер чыбык киртәләр ягасында яшькелт-аксыл үлән кыяклары калкынды. Күзләрне иркәләп тә өлгермәдек, шушы юрганнарга кытайлар ташланды. Кыш буе тинтерәгән, ел дәвамында тоташ ачыккан кытайларны туктатыр, тыяр көч юк иде. Кая барсыннар бичаралар, урысча бер сүз белмиләр, аларны кухняга якын җибәрмиләр, таңдагы «бәрәңге кабыгы өчен барган коммунистик бәрелешләрдә» арык, көчсез кытайларны тибеп кенә очыралар, сирәк-мирәк килеп житкән посылкалардан да аларга өлеш чыкмый. Алар үзләре дә сораныш-теләнеп йөрмиләр. Эштә дә намуслы алар, филонить итеп,

жылы мичләргә кереп йомылмыйлар. Бар икән — ашыйлар, юк икән — сүнгән күзләрен түбән тәгәрәтеп, тын гына утыралар, мыштым гына йөриләр. Минем кытайның аяк тавышын ишеткәнем булмады. Яшел кыяк аларның канын яңарттымы, котырттымы? Каян тапканнардыр, бер чиләк су керешле кәстрүлне ике таш өстенә утыртканнар да чүп-чар җыеп, ут кабызганнар. Кытайлар йөгерә-йөгерә үлән кыякларын йолкалар, шуны кәстрүлдә кайнаталар да көн озынына шул яшькелт суны чөмерәләр. Шешенеп беттеләр, бичаралар, корсаклары күпте, күбенде. Лагерь начальнигы явыз майор Калпочков иде, әй-һай, усал бәндә! Врач кытайлар өстеннән шикаять иткәч, зонадагы карт-корыны куып чыгарып, үлән кыякларын гына түгел, тамырларын йолкытып, корытып бетерде.

Немецлар да ачлыкны бик авыр кичерә... Майор Калпочков ашханәгә йөрүнең ныклы тәртибен, графигын булдырды. Һәр бригада билгеләнгән сәгатьтә, алдан тәгаенләнгән өстәлдә ашарга тиеш. Ныклы күзәтү куйды Калпочков: әгәр бригада өч минутка кичексә, бригада йә иртәнге аштан, йә кичкесеннән мәхрүм ителә. Ашар алдыннан бригадалар ашханә алдындагы мәйданга килеп тезеләләр. Чираты җитүгә тоткыннар ут капкандай атылып, ашханәгә бәреп керәләр дә озын аяклы өстәлләрне камап алалар. Савыт-сабаны юып тору юк, иртәдән кичкә кадәр касмакланып карага каткан әлүмин табаклар йөзләгән ач авызларга карап шаккатып торалар. Тыгызланып басуга, бригадир ярдәмчесе теге парлы тишек-тәрәзәгә барып кәстрүл белән баланда алып килә. «Второй» да бар, әйе, бар! Ул суда пешкән бер кашык әчегән тары боткасы яки сасып-исләнеп беткән шыр тоз балык кисәге була. Бик сирәк кенә ит исе килеп киткәләгән бәрәңге яркасы эләгә. Баланданы кашыклап ашау юк, тәлинкәңне күтәреп чөмерәсең генә. «Второй» дигәннәрен ачлар иленнән килгән яәҗүҗ-мәҗүҗ сыман бер кабуда йотасың. Бригада килә, китә, алдагылардан калган балык кылчыкларын җиңең белән сыпырып идәнгә төшерәсең. Чираттагы тоткыннар идәнгә ябышкан балык сөякләренә басып-басып йөриләр. Шул сөякләрне җыеп ашаучылар да бар иде. Күп иде алар, балык кылчыгы өчен ызгыш-талашлар да чыга иде. Хәтеремдә, озын, кайчандыр зифа, текә буйлы булган немец капитаны бар иде. Иреннәрен чак кыймылдатып сөйләшә, үз кирәгенә урыс сүзләрен дә шактый шома пупалый. Гәүдә зур, таза, электән сый-хөрмәттә калынайган корсак та шактый мул, кирпеч заводында эшли, эш авыр, ашказаны батыр, посылка алмый, хәйлә белми, һичкайчан урлашмый немец. Балык сөякләренең даими «аучысы» иде батыр капитан, бригадалар алмашкан арада кай арада кереп өлгерә диген, кылчыкларны балавыздай шомарган авызлы френч кесәсенә тутыра да чыгып шыла. Барак астына яшереп куйган ике ташны тартып чыгарып, балык сөякләрен вәсенләп, иренмичә төя. Күкрәк кесәсеннән чүпрәккә төргән ипи кыерчыгын алып, аңа кылчык буткасын яга, күзләрен чытырдатып йома, башын артка ташлый һәм «немецча» әзерләнгән бутербродны ашый. Капитанның шул бәхетле мизгелләрен күрсәгез сез!

Адәмнәрнең милли сыйфатлары ачыкканда һич көтелмәгән яктан ачылып китә икән! Әйтик, япон офицерын төелә-төелә балык сөягеннән әвәләгән бутерброд ашаганын күз алдыңа китереп кара! Һичкайчан була торган хәл түгел! Иң горур, иң буйсынмас, әллә нинди кыен хәлләргә калганда да кешелек сыйфатларын җуймаган, сынмаган, буйсынмаган адәм — япон булыр. О-о, алар берчакта да зарланмыйлар, сукранмыйлар, ачыксалар, юкны-барны эзләмиләр, язмышларын учларына йомарлап, җаннарын эт типкәсенә ычкындырмыйча яхшылык көтәләр, яхшылыкка һәм ходаларына ышаналар. Японнар сокландыргыч дәрәҗәдә бердәм, эшлекле халык икән, язмыш аларны бергә җыйса, шунда ук арадан өлкәне аерылып чыга, бүтәннәр һич карышусыз, һич икеләнмичә аңа ышаналар һәм буйсыналар. Кайтып, илдәге танышларыма ошбу хәлләрне сөйләгәч, күпләр: «Әй, алар хәрбиләр бит, чин-дәрәҗәләренә

карап өлкәнне билгеләгәннәр!» — дип әйткәннәремне юкка чыгардылар. Юк шул, алай түгел иде шул, еш кына бу өлкәнлек вә олпатлык хәрби дәрәҗәгә яки яшь чамасына карап билгеләнми, кемнең рухы нык, иманы какшаусыз — шул узаман булып китә. Чит ил тоткыннарыннан японнар урысчаны иң тиз эләктереп алдылар. Кытай ун елга нибарысы ун сүз үзләштерсә, японнар арасыннан телне белмәгән кешеләрне очратмадым. Горур, буйсынмас, көчле халык! Кытай, кореялы, япон — төскә-биткә бер чамадарак халык, диләр. Һич алай түгел, менә шушы бер төбәктә яшәп ятучы өч халык вәкилләрен аралаштырып тезеп күрсәтсәләр, мин, япон вәкилләрен һич ялгышусыз аерып алачакмын! Японның күз карашында олпатлык, гыйлем, үз-үзенә ышану, серлелек һәм яхшы мәгънәсендә хәйлә бөркелеп тора. Японнар берчакта да милли тарткалашларга, вак-тояк ызгышларга катнашмадылар, ипи-тоз өчен дошманлашып йөрмәделәр. Булса да була икән нык куллы, бөек халык! Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, эш-хезмәткә килгәндә, япон эшкә тотына икән, ышан, ул аны наять башкарып чыгачак. Лагерьда, гадәттә, «световой рабочий день», бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшләтәләр, мәҗбүр итәләр. Япон исә бу җүләр кагыйдәгә буйсынмый, ул дүрт сәгать эшләгәч туктый, ял итә, хәл җыя, бер сәгатьтән тагын җиңен сызгана, тагын дүрт сәгать дәвамында эшли, ут уйната. Ас син аны, кис, сигез сәгатьтән ары эшләтә алмыйсың. Урыс исә көннәр буе былагайланып, эшләгән булып йөри, башкарган эше эт яламаслык. Японнар — пөхтә халык, чиста халык. Актаста алар мунча тирәсенә урнаштылар. Мунча ягалар, кер юалар. Мин кай арада мактанып та куям... (Нишлим, бар инде шундыйрак гадәтләрем!) «Япон генерал-майоры минем керләрне юа иде!» — дип җиффәрәм. Бу сүз дөп-дөрес булса да мактанырга кирәкмидер, мөгаен? Аерылышыр алдыннан японнар миңа өр-яңа, йомшак бер одеял бүләк иткәннәр иде. Аны шундый ачык төскә манганнар җитмәсә, елкылдап тора. Бара-бара ул одеял калкып чыгар әле! Абдулла Али-казының якын дусты полковник Саттаро Тогучи урысча ватмый-сындырмый сөйләшә торган елгыр кеше иде. Мин аннан: «Саттаро-сан, берәр заман урыс белән япон тату яши башлармы?» — дип сорадым. Ул миңа кап-кара күзенең нурларын тирән уйланды да: «Никогда!» — дип җавап бирде. Каушадым хәтта, валлаһи! Хәзер Курил утраулары өчен үзара тарткалаш барганда аның шул сүзләре исемә төшә.

Милләт вәкилләре арасында төрле кеше бар, зонада син микроскоп астына эләккән бөҗәк хәлендә, берчакта да кеше күзеннән читтә кала алмыйсың. Синең һәр адымың айлар-еллар дәвамында гел кеше күзе алдында!

Балтыйк буе илләреннән ир-атларның җитмеш биш проценты зоналарга чәчелгән иде. Латышлар — сакчыл, ипле, итәгатьле халык. Алар милли төркемнәр чуалышыннан гел читтә кала алдылар. Литвалы яшьләр исә ярсу, тәвәккәл, алар тиз арада ныклы отрядларга берләштеләр. Урыс белән каралар — бер төркем, бандеровчылар икенче булса, литвалылар өченче төркемне хасил итте. Литвалылар төркеме аерылса да, алар берчакта да үзләрен бүтәннәрдән өстен итәргә тырышмадылар, каршылыкны пычакка-пычак китереп җиткермәделәр, ыгы-зыгыларны «парламент юлы белән сөйләшүләр аша хәл итеп» яшәделәр...

Милләтләргә хәлиткеч тамга сугарга җыенмыйм, болар — минем шәхси хәтерләүләрем икәнен аңлаган хәлдә язам, билгеле...

Зона яши, дуслаша, дошманлаша, безнең күзгә күренмәгән, барлыгы да беленмәгән әллә ниләр килеп чыга анда. Җөмләдән шуларның берсен, канлысын сөйләп үтәм. Төн урталары. Ниндидер куркулы пышылдаулар уяттымы мине, ялanaякларның чап-чап итеп идәнне вакытсыз таптавы сискәндердеме, елт итеп сикереп тордым. Кабаланып-эзләнеп, күзлегемне чак идәнгә төшереп җибәрмәдем. Ходам сакласын, күзлексез калсам — бетте баш! Карыйм, элегрәк уянганнар ишек катында бөялешеп торалар. Кайберәүләр ялт кына ишекне ачалар да агарынып, котлары очып,

вагонкаларына чабалар. Идәнгә мин дә бастым, ишек янынарак килдем, кызыксыну бер мәлгә куркуны җиңде. Ишекне ачып коридорга, унга-сулга карадым. Залихановның ишек төбенә житкәч... күзләрем атылып чыгардай булды! «Приблатненный фраер»,— Юра исемле урыс егете, болгаткыч таяк, каракларның төс-кыяфәтенә йөз токкан таза бәндәчек — аякларын аерып, чалкан яткан берәүнең корсак турына атланган да ике кулындагы ике хәнҗәр белән тегенең тәненә кадый. Бүтәннәр тиз-тиз шылганнар иде, мин тиз генә аерыла алмадым, дымланган табан асларым как идәнгә ябышып-беректе, тораташ каттым. Тере кеше тәненә чаж-чож үтеп кергән пычаклар тавышы бик озакка кадәр колакларыма эленеп, газаплап йөрде. Төшләремдә имәнеп, шабыр тиргә манчылып уяндым. Юраның корбаны пычак кергән саен авыр гына ыңгыраша, бичараның инде селкенерлек тә хәле калмаган...

Юра безнең күршедәге бригадир Сидоров янына кергән, йоклап яткан мәлдә тегенең корсагына ике тапкыр пычагын кадаган, аннары коридорга сөйрәп чыгарып, өстенә менеп атланган. Таза, егәрле урыс Сидоровның гәүдәсеннән кырык ике җәрәхәт санадылар. Юрага ни булды дисезме, ул чирек гасыр срогының өчесен утырган икән, салага әле, яңадан суд булып шул өчне өстәделәр үтерүчегә. Юра күздән югалды, зонада бүтән күренмәде. Бу фаҗиганең серен, сәбәбен беркем дә белә алмады. Имеш-мимешләр күп йөрде, беркатлырак тоткыннар: «Сидоровны картада оттырганнар икән, фәлән-төгән»,— диделәр. Акыллыраклар үтереш сәбәпләре серенең очлары тирәндәрәк икәнен, ахыр чиктә аның милләтара тарткалашларга барып терәлүен искәрттеләр. Юрадан соң күп тә үтмәде, искәрмәс этап оешты, урыслардан, бандеровчылардан ике-өч егетне, каралардан Мохтарны каядыр алып киттеләр... Байтак вакыт үткәч, илле дүртенче елның августында, Майкудук төрмә-лагерендә, йомык карцерда язмыш мине җан кыючы Юра белән тагын очраштырды...

Хатирәләр, хатирә дулкыннары! Сез муенчаклы бозау итеп, тартып кая алып барасыз мине? Кайларга илтәсез? Бер сүзне башлап кына җибәрәм, хатирәләр кар тавының чите кителә, тау ишелә башлый, уйларыма уралып, үзем дә кар ташкыны астында бүленеп калам! Сүз башым «Актас мунчасы» иде ләбаса!.. Мунчага барып керә алмыйча ары-бире тулганып зонада йөрим! Актас мунчасына алып кереп сезне дә «чабындырып» чыгыйм әле бер!..

Онытмагансыздыр, төрмәгә кадәр Достоевский белән җенләнгән чакларым бар иде минем! «Записки из мертвого дома» әсәрен соңрак, төрмә-лагерьларны урап кайткач укырга туры килде. Кулыма каләм тотып, җирсегән ярсу күңелемне тыя-тыя, Достоевскийның кешенең җанын ача алу бөеклегенә шаккатып, таң калып укыдым. Әйе, төрмә-каторгалар кемнедер изгән, гомерлек рухи гарип, төшенке күңел ясаган, ә Достоевский төрмәдән пәйгамбәр булып чыккан. Безнең чорның кайбер иптәшләре төрмәдән: «Мин бөек Ленин китапларыннан аерылмадым!» — дип, шыр тилегә әйләнеп кайттылар, кайберәүләр большевизм сандугачы булып океан арты әһелләренә көчсез, зәгыйфь йодрыкларын селкеделәр. Әйе, ялган абруй казанды андыйлар, телләрендә һаман Ленин исемен биеттеләр, аның тугры варислары Саддам Хөсәен, Фидель Кастро сыңарларына — канлы палачларга мәдхия укыдылар. И төрмәдә дә дөньяны аңламас җаннар! Урыста да булды андыйлар, Галина Серебряковалар, Дьяковлар. Татарда... шактый иде алар, шактый иде!

Достоевский заманында, авыр капитализм чорында адәмнәр дә бүтәнчә яшәгән, төрмәләрдә дә бүтәнчә тормыш иткәннәр алар. Җан кыючыларда, үтерүчеләрдә, каракларда, бандитларда — тоткыннарның һәммәсендә әз-мәз иман җылылыгы, кешелек калган әле. Достоевский мөселман тоткыннарда дин сеңдергән и м а н  н у р ы н күрә алган, мөселманнарның бүтән халыклардан әчке бер матурлык белән нык аерылып торуын сизгән. Без «иман нуры» дип шапырынырга яратсак та, шул нур

ияләрен бүтән милләтләр кабул итәрлек итеп әдәбиятта беркетә алганыбыз юк. Бусы — сүз арасындагы уйланулар...

Достоевский мунчасыннан Актас мунчасына кереп барабыз. Тәбәнәк кенә сап-салкын, идәне боз шугалак, почмакларын бәс сарган кар базы... Түшәмнән асылынып торган боз сөңгеләрдән чуп-чуп итеп болганчык су тама. Чишендек, киемнәрне бет куырырга тимер сандыкларга төеп тутырдылар. Кулга өч-дүрт литр су керешле, тоткалары төшкән тас һәм сагыз күмәче хәтле сабын кисәге тоттырдылар. Бер ишек янына килеп бөялдек. Ишекнең теге ягында тәрәшле тарагыдай тешләнгән плитваларын тотып, өчәү — чәчтарашлар утыра. Алар янына барып җитүгә, салкын суга учыңны манчып, кендектән түбән болында үсеп утырган йон әрәмәсен чылатасың. Чәчтараш арган, ул бүген йөзләгән кешене кырыккан, ул кырыс, усалланган. «Бильярд шарларыңны уңга тәгәрәт, сулга!» — дип команда бирә дә үтмәс плитвасы белән сине кычкыртып туный башлый. Урыста: «Тупым серпом по яйцам!» — дигән тәгъбир бар. Җәзаның иң хәтәре шул, диләр. Боларның кыланышы да шуннан һич ким түгел... Бу «игелекле хөрмәттән» соң мин аксадым. Күзлегемне салсам берни күрмим, салмасам да күрмим икән — парлана! Юеш, авыр ишекне көч-хәл белән каерып, ниһаять, чираттагы кысан бүлмәгә сыйдык. Монда сулдагы дәү бүксәле калай кубтан бер тас җылымса су бирәләр икән. Шуны эләктерәсең дә алгарак үтәсең, күз күтәреп карасаң... адәм балалары буткасында бер бөртек ярмага әйләнгәнсең! Һәркем үз тасында басып тора, синең бердәнбер урының шул. Шул су белән тәнеңне чылатасың, шул су белән сабынланасың, шуның белән үк коенырга да мәҗбүрсең. Ташып, озын-озак кар эретеп, чак-чак җылы кергән суны бүтән ала алмыйсың. Тас — норма.

Тирә-ягыңда йөзләрчә кабыргалар. Шыраеп торган очлы калак сөякләре. Оча сөякләре калыккан. Адәмнәрнең балтыр, бот сөякләре кәшәкә юанлыгы булып кына калган. Иң куркынычы — беркемнең артында да карга чукырлык ит калмаган, ул кибеп корыган. Ачлыкта тора-бара күт ите бетә икән. Күтсез, шыр сөяк ирләр янәшәңдә, тез астын юыйм әле дип иелсәң, берәүнең котсыз арык тәненә барып тиясең, ул чирканып тартыла, син читкә кагылгандай буласың һәм шул минутта ук икенче берәүнең шылтырап торган коры кабыргаларына орынасың. Дүрт ягыңда дүрт шүрәле, дүрт ягыңда дүрт кенә түгел, ун, егерме, утыз, йөз шүрәле! Усаллар сүгенә, тибешә, юашлар тын гына түзеп торалар. Команда бирелмәгән — чыгып котыла алмыйсың, тас — синең мунча биләмәң, ишектә бик, түшәмнән кайгылы башыңа сагышлы тамчылар коела: тып, тып, тып... Кар суыннан безгә аш пешерәләр, чәй кайнаталар. Моңарчы кар суыннан зарланган юк иде, мунча кереп чыккач, ачу кузгалды. Тау-тау өелеп яткан, көшел-көшел таралган карны күбрәк эретеп булмый микәнни?

## 7

*Бәхеткә күрә, аллаһе тәгалә тере җаннарны качн эзләргә кирәклеген белә.*

Виктор ГЮГО

Бәхет адәм улларын тәмам йотып ала, күп нәрсәләрне онытгыра. Бәхет белән исергән чакларда адәмнең туган төяге дә, ата-бабалары да, яшьлектә чамасыз кадерле булган нәрсәләре дә читкәрәк китә. Кайгы ишелеп килгәндә, җанны бер-бер артлы чагып торган кара еланнар тинтерәткәндә йә ата-анаң йортына кайтып егыласың, җиргә баш орып алардан рәхим-шәфкать сорыйсың. Инде кайтыр әмәлең юк икән, хат арты хат язасың, инде алай эшләргә дә җаең калмаган

дәверләрдә күңелеңне эшкә җигәсең. Илле беренче ел урталарында Актас зонасында чакта мин өйгә байтак хатлар язганмын икән. Алда әйткәнемчә, безгә хат язышу мөмкинлеге бик нык чикләнгән иде. Зонадан елына ике хат кына җибәрә аласың. Посылка-мазар алсаң, «открытка» белән рәхмәт әйтеп, исәнлегеңне белдерергә дә рөхсәт. Кирпеч заводы Караганда төбәгенең кайнап торган бер почмагы иде ул чакта. Елына миллионлаган кирпеч әзерләп өлгертә торган заводка әллә кайлардан машиналар килә иде. Машина килә, машина белән шофер зонага керә. Тоткыннар әнә шул шоферлар аша хат салырга тырышалар иде. Күпчелек шоферлар элегрәк лагерьларда булган, хәзер сөргенлек җәзаларын үтәп ятучы, комендатурага һәркөн барып «явить була» торган бәхетсезләр иде. Бар арада кыюлары, алар хатны алмастай булса, алып тормыйлар, алсалар — җаен табып почтага җиткерәләр. Бар үтә куркак-өркәкләр, болары хатны берсүзсез ала, заводтан чыгуга аны йә ерткалап ташлый, йә кайдадыр күмеп калдыра. Боларны да гаепләп булмый. Әгәр зонадан хат ташуын белә калсалар, көн-төне комендатура күзәтүе астында яшәргә мәҗбүр ителгән кичәге тоткынга — ике сөйләшеп тә тормыйлар — яңа, әшәкерәк срок чәпиләр. Актаста чакта хатларны бихисап күп яздым мин! Аларны «Ибраһим» яки «Искәндәр» дигән исемнәр куеп туганнарыма — күпчелеген әниемнең энесе Мирзаһид абыйларга җибәрә тордым.

Иң курыкканым: әтиләргә, Азат абыема, энекәшләргә авырлык китерү ихтималым иде! Мин төрмәдә, әти — укытучы, Азат — укытучы, энекәшләр дә белем алып яңа тормышка әзерләнә... Минем аркада алар да бер-бер зыян күрмәсләрме?.. Арабызда бары тик туганнары өчен генә газап чигүче, төрле вакытларда төрмәгә ябылган бәхетсезләр шактый күп иде! «ЧСИР» дип аталалар иде алар, «член семьи изменника родины». Сүзләрен генә кара син, сүзләрен!.. Шуңа күрә хатларны курка-курка гына язганмын: «Тормышыбыз әйбәт, Совет хөкүмәте безне монда нык кайгырта, тамагым тук, торган урыным җылы» — дип хат аралаш кабатлаганмын. Хатларның бик күбесе барып җитмәгән, барганнарын әни саклаган. Төрмәдән кайткач, мин аларны җыеп барладым һәм истәлеккә дип төреп куйдым...

Алдагы бүлекләрдә мин Актас хәлләре белән сезне таныштырган идем инде, мөхтәрәм укучым. Хәзер өйгә язган бер-ике хатым белән танышып китегез.

**«12 июнь, 1951 ел, Актас.**

**Исәнмесез, кадерле әти, әни һәм туганнарым Азат, Алмаз, Альберт! Шулай ук әби, Мирза абый, Нәҗия апа һәм кечкенә сеңлем Люзә! Барыгызга да сагынычлы сәламемне җибәрәм. Агай-энеләргә, күршекүләнгә миннән сәлам тапшырыгыз. Үзем исән-сау, әкрен генә яшәп ятам. Җибәргән хатларыгызны алып торам һәм бу минем өчен бик күңелле. Үзем еш кына открыткалар салам, аласызмы юкмы, белмим. Открыткага әллә ниләр язып булмый, нихәл итәсең, алар шул исәнлек белдерергә генә ярап торалар инде. Хатлар да язгалыйм. Бердән, җибәрү кыен булса, үз кулың белән почтага салмагач, китүен дә белә алмыйм. Тормышымда артык зур үзгәрешләр юк, бер төрле генә һаман кирпеч заводында эшлим. Эшем башланган чорда бик авыр һәм пычрак тоелса да, хәзер чистарак һәм җиңелрәк эшкә күчтем: дүрт килолы кирпечләр хәзер абзагызның кулында дүрт йотарлык бәрәңге кебек сикерешеп кенә торалар! Эшебез саф һавада, кояш астында. Эш урынында күл бар. Кояшта кызынабыз, су керәбез. Акрын гына үтә гомер, җибәргән 3 посылкагызны, Азаттан бер посылка алдым. Кипкән ит бик ошады. Күкәйләрнең беразы ватылган иде. Посылканы безнең үз кулыбызга бирмиләр, капчыкка селкеп бушатканда күкәйләр, алданрак тәгәрәп төшеп, тәбә ясалды. Азат капчыкка тутырган, анныкылар ватылмаган. Аңа хат язган идем, ала алдымы икән? Тормышыгызның ару булуына куандым. Посылка алу, бер яктан, күңелле булса да, икенче яктан бик оялам! «Гомер буе шулай игелексез бу бала!» —**

дип уйлыйсыздыр кебек тоела. Ләкин... тирә-якка карыйм да... кемнәр генә юк! Бер мин генәмени?! Гомер буе мин дә болай булмам. Тормыш ул шундый нәрсә, бер битен, бер артын күрсәтә, диләр. Саулыгым әлегә әйбәт. Тик уң як тешләрем генә начарланды. Төрмәдә тешләрне бик карап тотсам да, монда андый мөмкинлек юк. Посылка салганда исле сабын, теш пастасы салырга онытмагыз. Ә биредә теш каратуны уйларга да мөмкин түгел. Урт тешемдә куышлык барлыкка килде. Нык авыртсалар, йолкытырмын дип уйлап торам. Күзлегем әлегә исән. Краснов мине онытты. Мине гомергә киткәндер дип уйлый торгандыр. Әгәр бик теләсә, ул да минем янда була ала иде бит! Иптәш итеп бер хат кисәге язганы юк. Якташ!.. Хәерле булсын!

Биредә яз матурлыгы, җәй гүзәллеге дигән бер нәрсә дә юк. Җәйме, көзме, аера алмассың. Хәер, монда аның белән кызыксынучы да юк. Кеше төштәге кебек яши. Шау-шулы, ызгышлы, ыгы-зыгылы тормыш. Кайчан үтәр инде ул? Тормыш бара, гомер үтә дип тә кайгырмыйм. Бу мәктәпне исән-аман бетерә алсаң... бу — иң югары мәктәп! Алмазның эше уңышлы барса, минем өчен дә зур куаныч.

Әти, әни! «Балалар, балалар»,— дип, үзегезне онытмагыз. Әтинең 25 майда язган хатына җавап открытка салган идем.

Мирзаһид абый! Үпкәләмә инде, хатны сиңа юлларга туры килә. Әгәр вакытың булса, бер хат язып сал. Әби мине, чит җирләрдә каңгырып йөргән бәхетсезне онытмасын, минем өчен Ходайга гыйбадәт кылсын. Бәхетем булса, бер кайтырмын әле! Хат көтәм.

Сәлам белән Ибраһим».

Чит куллар аша үтеп, ирекле кешегә тапшырылып, өйгә барып элгәшкән беренче хатым шушы булса кирәк! «Ибраһим» дип имза беркетеп, хатны Сарман районында яшәүче Мирзаһид абыем Сөләймановка адреслаганмын.

«23 июнь, 1951 ел, Актас.

Төшләр күреп, төшләреңдә туган җиреңдә булып, Зәй буеның хәтфә болыннарында, хуш исләрдән сәрхүшләнеп йөргән чагыңда... даң-доң, даң-доң! Бигрәк ямьсез иртәнге чаң тавышы, үзе моңлы-сагышлы, үзе куркыныч. Уянасың... Иң авыр чак — уяну чагы. Таң сине көн караңгылыгына алып кереп китә. Уянып күзеңне ачсаң, тимер рәшәткәле тәрәзәдән авыр таң саркыла, таң рәшәткәле тәрәзәгә сыймый. Һаман шул ук шыксыз бүлмә, акшары саргаеп беткән диварлар, әле анда, әле монда мыгыр-мыгыр нидер сөйләшәләр. Төрле телләрдә сөйләшсәләр дә, кайгы-хәсрәтнең теле бер, аңлашыла. Күңелдә төнлә күргән төшләрнең махмыры бөтерелеп тора! Шул бөтерелеп торганда салам сырма өстеннән кузгалуы авыр да соң! Башкасы болай зарланырлык түгел. Сасы ис мәңгегә сеңгән бүлмәләрдән, тараканнар кебек кыймылдап, кешеләр чыгалар да ачы кәбестә белән кипкән балык исенә тынчыган ашханәгә өстерәләләр. Тиргә батып беткән аш бүлүче үзенең чүмече белән селтәнә бирә. Ашыйлар, сүгенәләр, төкерәләр, ызгышалар. Әйе, кызганыч бәндәләр, кызганыч бәндәләр! Тормыш үзенең тимер кысасы белән кешеләрнең иң яхшы, иң нәфис сыйфатларын үтерә, алардан каһкаһә белән көлә. Озак еллар утыручылар чып-чыннан тупа аңлы, ярымидиотка, иләс-миләскә әйләнгәннәр инде. Әйе, көннәр үтә, тарих тәгәрмәче безнең көннәрне дә үзенең серле йомгагына урый. Әйе, безнең көннәр дә дәшми-тынмый үтеп тора. Бару-кайту, эш ыгы-зыгысы белән кич җиткәнен сизми дә каласың. Тимер чыбыклы биек коймаларны алтынга манып, ваемсыз Кояш байый. Күк кыйммәтле хәтфә келәм кебек аллы-гөлле. Әйе, тормышның караңгы якларын шушы кадәр якыннан белү кешеләрне, аларның характерын, гадәтләрен үзгәртә. Соры күктәге купшы койрыклы күгәрченнәр һәм музыка гына үзләренең гадәттәгелекләрен югалтмыйлар. Кайдадыр аргы башта квартет уйный, кларнет һәм аккордеонның уйгын авазлары, куркын-

ган песнәк өере кебек шаулап, чыркылдап оча, кемдер язгы җилдәй йомшак тавышы белән җырлап җибәрә:

Помнишь ли ты,
Наши мечты?..
Это было лишь сон...
Это было лишь сон!

«Исеңдәме безнең хыяллар? Бу бит төш кенә иде, төш кенә!» Газиз җирнең соры туфрагын үбеп үкереп җылыйсым килә, бәргәләнә-бәргәләнә үксисе иде бер! Кояш саллы күз яше кебек тәгәри, күк читенең кызыл керфекләре астына күмелә, дан-доң, дан-доң!! Отбой! Тагын йокы. Тагын төшләр. Ристан төшкә кадәр төш сөйли, төштән соң төш юрый, дип көлешә үзара безнекеләр. Шулай. Акыл теше чыкмаса да, акыл җитәрлек булды. Ачы әйберне ашап, татып карамыйча, татлының чын тәмен, кадерен белмисең. Шуның төсле, ирексезлекнең газабын татымыйча, тормышның тәмен мин дә белмәгәнмен. Былтыр җәй буе кояш күрмичә тилмереп чыксам, быел кояшка рәхәтләндем. Эш арасында барып күлгә чумасың! Их, рәхәт тә соң! Көненә икешәр мәртәбә су коенам. Тәнем кояшта янып, кап-кара булдым. Сәламәтлегемә куанып бетә алмыйм. (Күз тимәсен, ярабби!) Иптәшләр дә: «Син коеп куйган кебек!» — дип сокланалар. Элек вак-төяк баш авыртып йөри идем, монда эзе дә калмады. Гомумән, баш монда бушанып ял итә алмаса да, укыгандагы чак кебек түгел. Минем бу хатларны берүк саклагыз. Чөнки биредә көндәлекләр алып барып булмый, бердәнбер истәлекләр — сезгә язган хатлар. Алар миңа кирәк булыр әле. Язучылык хыялын ташлаганым юк, валлаһи! Хөкүмәт яңа кодекс кабул итә дип сөйлиләр. Бәлки (бу хәбәр чынга чыкса!) якын араларда өйдә дә булырбыз. Язмыш ул! Әтинең 14 июньдә язган хатын алдым. Ул да бик сирәк һәм әз яза башлады. Курыкмагыз, мин алай ук зур җинаятьче түгел, ләкин зур җинаятьчеләр арасында. Ә Кояш тиресне дә, роза чәчәген дә тигез яктырта, зурлар өчен булган катылык мине дә чыбыркылый. Шуның өчен хатларны тегеләй-болай язарга туры килә. Бишенче посылкагызны һәм 200 сум акчагызны алдым. Посылкалар ешайды. Азыгым июнь аена тулысынча җитәрлек. Июньдә тагын берне салган булсагыз, июльдә җибәрмәгез. Салсагыз, август башында килерлек булсын. Азык-төлек тулысынча үз кулыбызга керә, әни соравыңа җавап: посылканы тикшереп күздән үткәреп, тулысы белән үз кулыбызга бирәләр. Сездән һаман-һаман ярдәм сорау бик тә кыен, әмма нишлисең?! Тормыш бит. Әнинең көннәре мин игелексезгә тегене-моны әзерләп үтәдер. «Балалар!» — дип үзегезне онытмагыз. Алмаз энекәшнең, Альбертның, Лиюзә сеңелнең (аның зур булып үсүен Алмаз язган иде!) уңышларына шатланам. Әбинең сихәт, сау-сәламәт йөрүенә бик куандым. Тәңредән аңа сәламәтлек бирүен сорыйм. Шулай. Тагын язармын. Сез дә языгыз, бу хатны алсагыз: «7 нче открытканы алдык»,— дип искәртерсез. Барыгызга да сагынычлы сәлам белән Ибраһим. Теш пастасы белән исле сабын салыгыз!»

Сагынуларымны арттырып исле сабын да килгәндер, бүтән кирәк-яраклар да, ничәмә еллар төрмәдә утырып, әти-әнидән бер әр сүзе ишетмәдем, алар бөтен авырлыкны бергә күтәрештеләр, ташламадылар. Әти, әни!.. Гәүдәләрегез Бигеш авылының тын зиратында ял итә, ә җаннарыгыз... мине кайгыртып, яратып, булышырга теләп, һаман тынгысыз баш очымда әйләнә. Рәхмәт сезгә!..

Соңгы яңалыкларның берсе шул булды, сүзе даими ирешеп торган майор Столяровны Актаска китерделәр. Күр инде син, туры килүен әйт! Уртача буйлы, калын-мул гәүдәле, дымы китмәгән калынча иренле, елгыр һәм сүзчән кеше икән майор! Инде өмет сүзләрен тоткыннар майорның үз авызыннан ишеттеләр: «Шулай... Быел — борылыш елы. Яңа кодекс кабул ителәчәк. Сроклар кыскара — режим үзгәрә. Тоткыннарга күп җиңеллек киләчәк!..» Майорны күтәреп йөртә башладылар.

иртәнге барлауга мәйданга чыгарып тезгәндә бөтен күзләр аны күрергә тырышты... «Әнә ул, әнә!.. Унгарак кара, шул инде, шул үзе!».

Лагерьда көннәрне түгел, сәгатьләрне саныйсың. Абына-сөртенә, сукрана-сукрана вахтага чабып барган тоткын, чыраен җимереп, гадәттән тыш җитдиләнеп бер мәлгә туктап кала икән, бел: ул арифметика белән изалана! Елларны саный, бармакларын бөкли-бөкли айларны исәпли, атналарны бер-берсенә куша, көннәрне арлы-бирле чигерә.

«Син кайда эшлисең?» — дип сорыйлар. «Кирпеч заводында!» — дисәм, Карабастан ук таныш, әз-мәз күз күргән, этапларда зар-моннарны алмашынган иптәшләрем тел шартлаталар. Казакъстанның тәнне өшетеп, җанны туңдыра торган салкыннары турында төрледән-төрле куркыныч риваятьләрне этапта ук ишеттергәннәр иде, мин дә ары-бире сүзләгәндә кыстырып үттем, ахрысы? Колыма суыкларын беләләр, Магаданның әче, ач җилләре хакында Рәсәй империясендә ишетмәгән, кан калтырап «ләхәүләсен» укымаган кеше бармы икән? Казакъстан дигәч, аны кайнар Урта Азиягә охшаш җылы төбәк дип ялгышалар. Әле безнең дә күткән суыкларны күргән юк диярлек, «Карабаста без иркәләнеп кенә яттык әле!» — диләр казакъның кунакчыл түренә элегрәк «прописка кергән» тоткыннар. Алда күпме кышлар, күпме кар-бураннар, җәфалар көтә әле безне! Тоткын, суыктан коткара торган икән, җәһәннәм базына төшеп югалырга да әзер. Хөкем карарларында, «Особое совещание» сәгать саен пичәтләп торган кәгазьләрдә әйтелмәсә дә, сәяси тоткынга өстәмә җәза тәгаенләнә: туңарга тиеш ул, ачыгырга! Алардан бер чакта да котылмак юк! Соңгы чаң янгыраганчы ул шундый ике Иблис белән көрәш алып бара.

Завод суыктан котылып тору урыны дип мактап, бераз ялгышканмын икән. Тәҗрибә арткан саен күз җитерәк күрә башлый. Иң авыр хезмәтләрне бергә туплаган газлы, сасы исле, сөремле, тузанлы, юешпычрак бу урынның бүтәнчә «ягымлы» яклары да бар икән! Сменалы эш! Бу — тоткынның хыялы. Сине караңгыдан-караңгыга куып йөртмиләр инде, иртәнчәк зонадан иң соңгы колонна булып чыгасың да әле бүтәннәр шахтада, төзелешләрдә җан-фәрман кара тир түккәндә кайтып кереп, юеш өс-башыңны чишенеп ташлап, вагонкага менеп сузылып ятасың. Сменалы эш кулайрак.

Язган идем шикелле, заводларның икесен дә япон-немец әсирләре төзи дә, сәяси тоткыннарга аерым режим урнашкач, бу якларга хатын-кызларны китереп тутыралар. Актаста ул чакта өч мең тирәсе хатын-кыз була. Хатын-кызлар кайнаган шаулы диңгез уртасында аерым утрау булып ирләр барагы утырып кала. Анда кирпеч заводына көндезге сменага йөрүче механикларны ябалар. Ике сменада эшли-эшли хатын-кызлар ваткан пресcларны төзәтә алар, электр, пар хуҗалыкларын карый, бүтән тимер-томырны хәстәрли.

Актас һич көтмәгәндә мәхәббәт утравына әйләнә. Бишенче номерлы баракта калган ир-атларның язмышы тоташтан үзгәрә. Барак бер катлы чәнечкеле тимер чыбык киртәсе белән генә уралган, «утлы зона» юк, кызлар янына керәсең икән, тимер чыбыкны күтәр дә... әйдә, алга!

Төньяк лагерьларыннан, Красноярск тирәләреннән куып китерелгән хатын-кызлар янына Украина авылларыннан, Литва урманнарыннан яшьләрне китереп кушалар. Күкрәп торган яп-яшь украинка бандеровчылар! Кем хак, кем нахак утыргандыр, йөгенә керү мөмкин түгел, срокларны да мул бүлгәннәр аларга: җәлләп тормаганнар. Күпчелеккә егерме бишәр елны сылаганнар!...

Зонадагы хатын-кызларның язмышы үтә катлаулы, явыз конвой да кымтырыклый аларны, лагерь эчендәге надзирательләр дә тынгы бирми, матурракларны өстән, югарыдан килгән күп санлы инспекторлар да кочакка ала. Анда инде карышып тора алмыйсың! Без килгәндә лагерьда булган өч меңгә якын хатын-кыз төркеменең нибарысы унберендә генә кызлык булган. Ни өчендер аларны аерым санап торганнар. Хәтта кыз булганнары өчен йөз грамм ипи өстәп бирәләр икән. Дөрес, шул унбер

арасында өч-дүрт бәлтерәйгән монашкалар, өске тешләре аскы ирене астына чыгып елтыраган бер убырлы карчык... һәм үтә чибәр, дөньяларны бизәрлек сылу кыз да була! Кыз үзен ничек саклагандыр, нинди әмәлләр табып, комсыз офицерлардан котыла килгәндер, аңлата алмыйм, мәгәр Актас сылуы, гыйффәтле туташ хакында Караганда лагерьларында адәм ышанмаслык легендалар йөри иде.

Без килер алдыннан гына хатын-кызларны японнардан һәм немец әсирләреннән калган землянкалар зонасына күчергәннәр иде инде. Убырлы карчыкны да, сылу кызыкайны да күрү миңа насыйп булмады. Кирпеч заводында эшләр өчен нигә шул кадәр хатын-кызны монда тотканнардыр, белмим, хәтерем алдамаса, аларны бүтән объектларга йөртмиләр иде шикелле. Инде Карагандага барып кайтып, Актасның шәһәргә бик якын икәнлеген белгәннән соң, мондыйрак уем бар. Карагандада урнашкан җәзачы идарәләрнең күп санлы офицер-башлыклары шунда, аяк очында гына меңләгән сылу украинкаларны, талчыбыгыдай литва кызларын үз кирәкләренә файдаланыр өчен еракка җибәрмәгәннәр булса кирәк. Мәскәүдән, Алма-Атадан кунак-башлыклар килеп төшә икән, эзлисе, еракка барып вакыт әрәм итәсе юк, бар да кочагыңа ал! Зур күкрәклесе кирәкме, кечерәкне яратасыңмы, ак сачлысы ошыймы, карасымы — һәммә төрдән бар. Чибәррәк офицерлар килеп кочакка алганда кызлар үзара көнләшеп, тарткалашып та бетәләр икән. Кемнеңдер чәчен кискәннәр, ачудан бит алмасына пычак очы белән сызганнар. Яшьләр бит, хатын-кыз табигате нинди шартларда да ир-ат назына мохтаҗ, ирләр кочагы һәм нык ирләр кулы аларның төшләренә кереп җәфалый!..

Карабастан ишле этап китергәндә бу, өч мең кыз арасыннан яр табып, иркәләнеп яткан ир-атлар Актаста калган иде. Алар хатын-кызлардан аерылуны бик авыр кичерделәр, һич яшермичә кызларны сагынуларын бергә-бергә чакта тормышның җиңел-матур булуын ашыгып-ашыгып сөйләргә, хәсрәтләрен уртаклашырга, мактанырга тотыналар иде. Без, зоналар аерылгач, тол калган ирләр яныннан кача башладык!..

Кирпеч заводының роле көннән-көн арта бара иде дисәм дә, хата булмас... Ул ике зонаның почта бүлекчәсе дә булып чыкты. Иң әүвәл Актаста кавышып аерылышканнар язышa башлады. Теге яктан хатын-кызлар, бу яктан ир-атлар бер-берләрен таныштырырга тотындылар. Заводның бөтен аулак почмаклары хатларны кабул итеп, цензурасызнисез генә зонадан зонага йөртә иде...

Минем юлдашларымны аралап, берәүләргә якынаеп, икенчеләрдән ерактарак йөри торган чагым иде. Беренче дуслашып киткән ике латышны бүгеннәрдә дә оныта алмыйм. Минем сыман икенче катка урнашкан бу ике дус көне-төне бергә яшәп, юктан гына да куанычлар табып, бер-беренә көч-куәт биреп, тигез генә тормыш итәләр, ризык бүлешәләр иде. Теодор Августович Цеплитис, яңаклары ябышкан, күзләре тирәнтирән чокыр казып, бу дөньядан качарга тырышкан латыш зыялысы укымышлы һәм әдәпле кеше иде. Такы-токы тамак туйдырып, зәңгелә белән кат-кат авырып байтак лагерьларны кичкән бу кешенең тешләре сынып-ваклапып, уртлары аксыл-зәңгәрләнеп беткән иде. Урысча оста сөйләшә, җөмләләре төзек, латыш әдәбиятын гына түгел, дөньяның атаклы әдипләрен вә китапларын белә, буш вакыты булса, шунда ук китапка чөрәеп ябыша иде. Иң кызыгы — Теодор Августовичның үз көтепханәсе бар, латышча байтак китапларны үзе белән күчереп йөртә, бүтән зыялылар белән алмашынып, алардан китап алып тора, үзе дә бирә. Аның янына зыялы латышлар еш килеп йөри, ул алар арасында аерым бер абруй тота дисәм дә, хата булмас. Бунинның «Арсеньевлар тормышы» романы өчен Нобель бүләге алуын да, мәшһүр норвегияле язучы Кнут Гамсун китаплары турында да тәүге хәбәрләрне аның авызыннан ишеттем. Башта мин аны укытучы яки фәнни хезмәткәрдер дип уйлап йөрсәм, бик сак телләр генә аның җандармерия офицеры булганлыгын җиткерделәр. Совет властеның чын, әзерлекле, акыллы дошманы

коммунизмны алда бары тик һәлакәт кенә көткәнен һич тайчынмыйча әйтеп бирә торган иде, игътибарлы кеше белән тиз дуслаштык. Дуслаштык дию мөгаен бик үк дөрес тә булмастыр, чөнки ул миңа караганда нык алга киткән, өстен фикерле, иманына ябышып яткан, сәяси карашларыннан бер чакта да тайчынмас, баш бирмәслек горур ир иде. Аның белән янәшә яшәүче Жанис Матисович Миезис гәүдәсе белән дә, кыяфәте белән дә бөтенләй аңа охшамаган латыш иде. Ул урысча бер сүз белми, белергә дә теләми, ничә еллар зонадан зонага күчеп әллә кемнәр белән аралашса да, тик латыш телендә генә сөйләшә иде. Бүтәннәр йомыш-кара төшкәндә ана Теодор Августович аша гына эндәшә алалар иде. Бу үтә көчле, баһадир күкрәкле, әле кырыс, әле елмаерга әзер чырайлы кеше илендә кем булгандыр, белмим. Мин Цеплитиска тартылгач, Миезис та мине үз итте, ул мине «чикерткә» дип, мин аны «аю» дип яратып атап йөри башладык. Шушы ике латыш мине үз араларына алды. Миезис Теодор Августовичка хәл кадәренчә булышырга тырыша, авыр әйберләр күтәрергә, күчерергә туры килгәндә җиңен сызганып, аның янына килә, эшнең авыр өлешен үзенә ала торган иде. Алар үзара туган телләрендә гөр-гөр килеп сокландыргыч матур сайрашалар иде, мин аларның шулкадәр дус, игътибарлы яшәүләренә сокланып һәм көнләшеп карый идем. Икесенең дә хатыннары төрмәдә утыралар, күчеп йөри-йөри хатыннарның эзе югалган, алар моның өчен бик нык кайгыралар, пошыналар һәм ярдәм итә алмаулары өчен борчылалар иде. Цеплитис «особый лагерь»ларның ни максат белән оештыруларын чамалый иде булса кирәк, ике-өч тапкыр: «Алар безне тәмам юк иткәнче, әз-мәз хокукларыбыз бар чагында адресларны булса ла табышасы иде!» — дип әйткәнен хәтерлим. Ул сорау биреп тинтерәткәнне, вак-төякне төпченгәнне, кайтарып кызыксынганны өнәми иде шикелле, сорашсаң җавапсыз калдыра, мәгәр үзе белеп, миңа ни кирәген чамалап-иплəп кенә акыл бүлешә торган иде. «Сез, татарлар, алдагы көндә ничек яшәргә уйлыйсыз?» — дип ул үзе сорау бирде, минем ык-мык торганны күргәч, үзе аңлатуны кирәк тапты. «Без әле урыс кулында алай озак та яшәмәдек, ләкин урыс шовинизмы безнең милләтне дә таркатты», — диде. Минем: «Революция солдатлары, Ленинның иң ышанычлылары латышлар булган шикелле», — дип курка-курка гына әйткән сүземә: «Ялланганнар! Сатылганнар!» — дип ачулы гына карап куйды. «Син нигә шул кадәр күңелсез йөрисең?» — дип сорады ул иртәләрнең берсендә. — Алай йомылып яшәсәң, срогың азагына барып җитә алмассың. Зонада һәркем үзенең урынын дөрес билгеләргә тырышсын. Әле алда ни күрәчәкне белгән юк. Безгә сак һәм үзара игътибарлы булырга кирәк». Ике дус янына мин дә сыйдым шикелле, алар белән аралашып яши башлагач, күңелем күтәрелгәндәй булды, Цеплитис дөнья хикмәтләрен әдәби китаплар аша миңа да сеңдерергә тырышты.

Латышлар эшчән, тырыш, һөнәрман халык, аларның ризыкка аерым бер хөрмәтләре барлыгын мин тиз абайладым, тиз арада «латыш саранлыгы»ның ни икәнен дә белдем. Бригадабыздагы тагын бер латыш — Гинтерс турында әйтеп китим инде, бу кешегә яңадан әйләнеп кайтып тормам. Бригадада эшләгәндә Гинтерс ни белән шөгыльләнгәндер, хәтерләмим. Бу адәм күзгә күренмичә йөри белгәндер, ахрысы. Озын торыклы, нәзек аяклы, озынча кабак башын урталайга ярып тар гына пеләш үткән бу латыш ниндидер дини мәзһәбнең рухание иде шикелле. Мәзһәби кардәшләре зонада булмагандыр шул, аның янына килеп йөргән, аралашкан кешеләр бөтенләй юк. Гинтерс ничә карасаң да, ялгыз иде. Берзаман Гинтерска посылкалар ява башлады. Өйләнмәгән, мәзһәбе таләп иткәнчә өйләнергә хокукы да булмаган бу сәер кеше үз тирәсендәге йөзләгән инсанны санламыйча, адәм улларына күз дә салмыйча үз уена үзе батып, байгыш сыман яши бирде. Посылка килгәнен беләбез, чөнки андый бәхетлеләрнең исемен тактага язып, КВЧ ишеге янына эләләр. Исеме күренә Гинтерсның, посылкасын алып кайтмый, күрсәтми, шунда каптеркада гына калдыра. Бәлки каптерка хуҗасы буш калмагандыр,

хуҗалар үзләре белеп бирмәсә, астан гына кимерә торган сычкан-күселәр оялый каптеркага... Гинтерсның барганын да, итәк астына качырып төрледән-төрле ризык алып кайтканын да күргән кеше юк, җир астыннан җылан йөртә Гинтерс! Кайта, юрганына төренеп качып ашый, авызын чапылдатмас өчен чәйнәми, ни ризык булса да шуны суыра. Ярты төнгә кадәр башын чыгармый, суыра! Ара-тирә агач чумаданнан флейтасын чыгара да уйнарга тотына. Бүтән берәү уйнаса, музыка яратучылар аның янына җыелыр иде, юк, флейта тоткан Гинтерс янына беркем дә килми. Флейтасын куя да тагын одеялына чорналып яшеренә. Иртән вахтага беренче булып барып җитә, аны бик ерактан танып алып була. Балагы кыска чалбарлы Гинтерска таман кием таба алмадылар. Тегү-ямау цехына барып балагын озайтуны сорагач, Гинтерс хакында хәбәрдар осталар бер түгәрәк колбаса сораганнар. Бирмәгән саран тәре... Үзара тату, игътибарлы латышлар арасында Гинтерс аерым бер адәмчек иде. Теодор Августович та, Миезис та аның белән аралашмыйлар, иртәнчәк беренче очрашканда баш кагып кына узалар иде.

Меңнәрчә кеше арасында тома ялгыз калу куркыныч, шомлы фал. Бер иптәшсез, фикердәшсез акылдан шашуың ихтимал. Гинтерска ул куркыныч янамый иде. Сараннар ялгызлыкны ярата, күрәсең, алар ялгызлык корбаннары.

Тынгысыз Теодор Августович хатын-кызлар зонасына бер-бер артлы хатлар җибәреп, якташларын эзләп тапты, алар арасыннан иректә чакта ук таныш хатын да тавыш бирде, алар тиз-тиз хат алыша башладылар. Хәзер элеккечә сөйләшеп утыра алган да юк, эштән кайта да кәгазь-каләмгә ябыша. Яза, яза... Ни язарга мөмкин ике зона арасында?! «Хатын-кыз,— диде ул бер көнне көлемсерәп,— җан азыгы! Иң өметсез чакларда да ир-атны бары тик хатын-кыз гына аяп, саклап алып кала ала. Ир-ат ялгыз тормыш алып бара алмый. Өйләнмәгән, тол ирләр дөнья бичаралары, алардан аерым бер ис килә хәтта. Хатын-кыз ир-атның юлбашчысы, юл күрсәтүчесе. Акыллы ир аларның һәр сүзен колак салып тыңлый. Әле ярый аллабыз дөньяга хатын-кызны яраткан! Тукта, нигә син кызлар белән язышмыйсың... Бәлки, теге зонада якташларың, татар кызлары бардыр?»

Бу сүзләрдән мин сискәнеп алдым: чынан да?! Кызык булыр иде якташлардан берәвесе очраса! Теодор Августович үзенең таныш хатынына махсус хат язып, аның белешүен, эзләвен үтенде. Латыш хатыны көттермәде, җавап язып җибәрде. Хатында ул татар кызларының юклыгын хәбәр иткән һәм: «Башка милләт кызлары ярамыймы синең дустыңа? Әйтик, безнең бригадада бик сылу латыш кызы бар, Дзидра исемле. Ул язышырга риза»,— дигән сүзләр теркәгән иде. Мин читенсенеп кенә ризалаштым да хат язып салдым, озакламый кызлар зонасыннан хат-хәбәр дә килде. Шакмаклы дәфтәр битенә пөхтә, тигез хәрефләр белән язылган, моңсу теләктәшлек белән тулган бу хатны мин нык дулкынланып укыдым. Кызлар хаты!

## 8

*Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбәрәттер йөрәк —*
*Парә-парә кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы.*

Габдулла ТУКАЙ

*Әллә ниләр бирер идем, аһ дигән сүзләренә!*

Татар халык җыры

Моңарчы Актас зонасы кызларын без меңәрләп кенә санап йөртә идек. «Өч мең анда, өч мең!» «Алай гына да түгелләр, аларга да этап арты этап килеп кенә тора!»

Элек шулай иде, менә бүген кулымда шул төркемнән аерылып, миңа таба атлаган кызның хаты. Укый-укый теткәләп бетердем мин хатны. Үз

тормышы, үз язмышы, нык төйнәлгән кайгы-хәсрәтләре, хат юллары арасына кысылып-посып килеп җиткән сагышлы моңы белән кыз мине бер эретте, бер суытты. Ис! Шомырт чәчәге исеме кәгазьдә, ясмин гөле исеме, ис — хатын-кыз хакында әллә ниләр сөйли алган хикмәтле көч ул! Сүз — әгәр ул хатын-кыз авызыннан син өзелеп көткәндә чыккан икән — әкият ул, хикмәт, аяк өсте күрә торган төш!

Саф-саф тезелеп, курка-өркә каушап, кабаланып, «егылмасам ярар иде!» — дип тәңрегә ялварып, эшкә барганда үзебезнең сафларга карап алам да... имәнеп китәм! Тәбәнәкләргә эләккән көтек, кыска ямаулы бушлатлар, учак очкыны куныр тишек иләккә әйләнгән авыр сырган чалбарлар, иске чана табанына әйләнгән олтанлы киез итекләр, майланып, шомарып беткән, як-ягыннан кара мамык кисәкләрен җилдә уйнаткан бүрекләр... Җимерек кашлар, юеш танаулар, аннан-моннан кырылган ияк-яңаклар... Бу әле ирләр!.. Ә хатын-кызлар ни хәлдә?! Мең еллар дәвамында җырларда җырланган, күңелләрне куандырган, иртәнге чык төсле саф хатын-кызлар нинди җан ияләренә әйләнмәгәндер?..

Дзидрадан хат килгәнче хатын-кызлар зонасы миңа төссез бер төркем булып тоела иде һәм, дөресен әйтергә кирәк, «үз кайгым үземә җиткән», диебрәкме, мин алар хакында аерым пошынып уйланмый да идем шикелле. Менә бу хат,хуш исле, ялгызлык сагышыннан җилфердәп торган дәфтәр бите, әллә ниләр уйлатты. Гаҗәпләндем: кайнап торган кешеләр казанында ничек инде ялгызлыктан җәфа чигәргә булсын ди?..

Исәңгерәп, сөенеп, кыз катына беренче кат барырга җыенган үсмер сыман дер калтырап, каләм очын кимерә-кимерә Дзидрага тагын хат яздым, моннан ары ике арада хатлар өзлексез йөреп тора башлады. Үзебезнең «почта бүлекчәсен» булдырдык. Зонада «бүгенгене иртәгә калдыру» гадәте юк, һәр тарафтан шушы канун канга сеңгән, без ашыга-ашыга язмыш-гамәлләребезне бер-беребезгә озата, бүлешә башладык. Дзидра шәһәр кызы, сугыш беткәч, күп тә тормаган — аны кулга алганнар. Сөяргә, сөелергә, яр булырга, ана булырга өлгермәгән, бөтен өметсөенечләр берьюлы киселгән. Пермь урманнарында агач екккан, кыенның моңарчы тарих белмәгән төрләрен татыган, кыйнаганнар аны, көчләгәннәр, мәсхәрәләгәннәр, чишендереп корсагы өстендә шап-шоп карта уйнаганнар. Нигә боларны миңа сөйләде Дзидра гүзәл, ник ачып салды?.. Авыр хатирәләреннән котылырга, хурлыкларыннан арынырга теләдеме?.. Әллә минем кызып-кайнарланып, ап-ачык теләктәшлек күрсәтеп язган хатларым, дустанә мөнәсәбәтем сәбәпче идеме, ул — кызлар зонасында чишелеп китә алмаган, большевиклар режимы йомарлаган кыз — миңа рухи хәзинә артыннан хәзинә җибәрә торды. Завод капкасы мәйданында, хатын-кызлар сафы бер ук җитәрлек ераклыкта туктаганда мин Дзидраны күрү бәхетенә дә ирештем. Күрдем дип, ходавәндәм, сукырбукыр күзләрем белән ни күргәнмендер. Дзидраның озын буен, иңенә таратып ташлаган аксыл, мул чәчләрен шәйләдем бугай. Пальмаларны күргәнем булмаса да, мин аны көнчыгыш шигъриятендә мең тапкыр җырланган, гашыйкларның уртак сөенече — пальмага тиңләдем. Бу чагыштыру дүрт җиренә кара тамга чәпәлгән, сөеп тә, сөелеп тә карамаган кызга ошады, ул мине: «Писатель мой!» — дип атап йөртә башлады... Әнә шул «язучылык»ны, күңелнең киң вә бөеклеген аңладымы сизгер латыш баласы?! Аның язуы шулкадәр матур, ул хәрефләр язмый, чигү чигә, каяндыр хуш исле ап-ак кәгазь таба, кәгазь битләрен һәрвакытта бертөсле итеп бөкли, һәр ишарәсеннән төгәллек, пөхтәлек аңкып тора. Ул мине, мин аны күрә алмасак та, мин дә чистарак, пөхтәрәк йөрергә тырышам, җәй башында, иңнән калын сырмалар, күттән калын, сырган чалбарлар төшкәч, үз-үзеңне күзәтергә, җыйнакланырга җай да бар иде. Бригаданы, төрле эштә буталып йөрүдән алып, ачык һавага күчерделәр һәм без завод чыгарган кирпечләрдән йорт төзелешләре өчен блоклар ясый башладык. «Күл буенда рәхәтләнеп ятам!» — дип әтиләргә мактануымның сәбәбе әнә шул иде. Агачтан нәни генә станоклар ясап

китерделәр, осталар шул станокларга кирпеч тезә, ә без Ростислав Иванович Илечко белән лачинкага салып, аларга измә таратабыз. Измәне дә үзебез болгатабыз. Эш җиңел, осталар байтак, без икәү генә, норма зур, бу инде түбәдән кар төшерү яки чүп-чар җыеп яндыру түгел, анда теләгәнчә күз буярга, «туфта» ясарга була. Монда һәммәсе күз алдында: блокка фәлән кадәр кирпеч керә, бригада көн дәвамында төгәнчә блок өлгерткән. Бик якын кешеләрем Теодор Августович белән Жанис Матисович та монда. Иң зур бәхет: Ростислав Иванович белән көне буе без бергә! Профессор Илечко хакында алда сүз булып әле. Теодор Августович мине ташчы һөнәренең серләренә өйрәтә башлады. «Дөрес, совет власте мәңгелек түгел, көннәрдән бер көнне ул бетәчәк! Гаделсезлек, хаксызлык, җәза көчләренә генә таянган бер власть та озак яшәмәгән, үзеннән үзе чери аның тамырлары. Алай да котылып чыгарсың, сине Красноярск тирәләренә сөрерләр. Анда барып эләккәнче бер-бер һөнәр белергә кирәк! Син шигъри күңелле егет, машина боргычларга яратмыйсың, шахтага төшәргә ярамый сиңа, күзлегең ватылыр. Урман кисү өчен җен көче булу шарт. Әйдә, ташчы бул! Әдәби юллар урынына кирпеч тез... Күңелле эш икән ул! Мин ташчы булуым белән бәхетлемен, өйрән!»

Дзидрадан шомырт чәчәгедәй ап-ак кәгазьгә язылган хатлар килә. Ә мин... кирпеч яндырыр алдыннан арага кыстырган кап-калын, сап-сары чергән йомычка исе килеп торган кәгазьләргә язам... Сизәм, бер мин генә түгел, яшьрәкләрнең һәммәсе теге зона белән арадашлык урнаштырды, эштән соң зонага кайтып кергәндәге тентүчеләр усалланды. Баксаң, бүтән объектларга йөрүче ир-атлар да, кайсы кемнән адреслар алып, танышып, белешеп хатлар язышалар икән! Бер авыз урысча белмәгән кытайлар да, житез-житез кореялы яшьләр дә, азиатлар да, кавказлылар да кызып-кызып хат алышырга тотындылар. Әйткәнемчә, смена алышканда хатын-кызлар колоннасы, кагыйдә буенча, бездән өч йөз метрда тукталырга тиешләр. Кайчагында конвой илтифат итеп тормый, безнең аралар якынаеп та куя! О-о, күзең җете икән, абайлап өлгер! Ирләр ягы да җанлана, ә хатын-кызлар, зона гүзәлләре тәмам шашыналар. Калын шәл-яулыклар шуып иңбашларына төшә, бушлатларның төймәләре чарт-чорт чишелә, чишелмәгән төймәләр өзелеп җиргә чәчрәп тәгәри, гәүдәләр турая, кинәт тузгып киткән чәчләр җилдә җилферди, җил юк икән, анда да җаен таба кызлар! Һәр җан үз мөмкинлегеннән чыгып үзенең әле хатын-кыз икәнен, тере җаны барлыгын искәртеп калырга ашыга. Ирләрнең тыны талгын җил белән аларга барып җитә, кемдер берәү: «Эх!» — дип аларның шашынган йөрәкләренә моң өсти, хатыннарның тез буыннары калтырый, егылып китүчеләрне култыклап алалар. Ә күзләр! Күзләр! Кара, зәңгәр, соры, коңгырт, яшькелт күзләр тоташ утка әйләнә, ике колонна арасында ут, ул кабына, дөрли, шаша, бии... Җылынып калырга кирәк, сөенеп калырга, иртәгә конвой бүтән булачак, ул кызлар колоннасын әнә тегендә, таучык башында, үрдә туктатачак, һәр ым, һәр ишарә өчен хатын-кызларны мәсхәрәләү сүзләрен гасырлар буена җыйган урысның авызын ник ачтырачак, хатын-кызлар өстенә бозлар, ташлар, чүп-чарлар, гүр такталары явачак... Ә бүген... адәмнең бөтен көче, дәрте-гайрәте, кайнарлыгы җаны, омтылуы ике күзгә төйнәлә. Күз әллә кайлардан еpактан күрә башлый. Ирләр сафында да хәрәкәт: яшьрәкләр, керәшеннәрнең ышкытып бию әмәлләрен кулланып, табаннарын ышкытып, конвой солдатларының күзен сукырайтып-гипнозларга теләгәндәй, алгарак чыгалар... Ике бәхетле дә, бәхетсез дә колонналар арасына кереп баскан суык-шәм солдатлар үзләренең нинди уклар, утлы ядрәләр, мәхәббәт кылычлары арасында калуларын сизмиләр. Ни ул Бородино кыры! Ни ул Ватерлоо бәрелеше! Ни ул Чыңгыз гаскәренең ашкынып-ыргылып Көнбатышка баруы!.. Туңнар шул КГБ солдатлары, пешкән шалканнар... Дөньяда шушы кадәр тере һава дулкынланган тагын бер-бер урын бармы икән? Әнә шушы кыска-кыска күрешүләр, күз сирпешләр, ерактан торып мәхәббәт аңлашулары өчен дә

яшьрәкләр кирпеч заводына эшкә күчәргә тырышалар, бригадирны җайлыйлар, нарядчикны көйлиләр, хәтта ППЧ начальнигы Фунтиковка ук барып җитәләр. Фунтиков та кеше, аның да тормышы бар, авызы зур, тоткыннар ни китерсәләр дә, «хап!» итеп йотып кына тора!

Ярым ач, алама, ничәмә-ничә еллар хатын-кыз назыннан мәхрүм ителгән тоткыннар Актас җирендә берникадәр җиңеллек тоеп, бәхет татып яшиләр. Ул хат алганда һәм язганда татыган сөенечләр! Һәр хат өмет уята, кемнәрдер язмышларын уртаклашырга, котылып чыккан мәлдә бергә яшәргә, кавышырга вәгъдәләшә. Кемдер, Дзидра кебекләр, сердәшләрен табып, күңелен бушата. Ике арада бүләкләр дә йөри. Кызлар кулъяулыгы чигеп сала, чәчләреннән... кайчы белән кисеп төрле төстәге «сихер» бүләкләре җибәрәләр. Ирләр зонасыннан хатын-кызларга украинкалар бик яратып кия торган, «чоботы» дип аталган җиңел итекләр китә. Карьер цехындагы компрессор шлангаларын сүтәләр дә эчтәге нык киндердән тегәләр ул атаклы «чоботыларны». Зонада итек төзәтү цехы эшли, хәзер ул кавыштыру, таныштыру өлкәсендә иң-иң абруйлы бер урын. Дагстанлы, түгәрәк ак йөзле, коңгырт күзле, килешле кара мыеклы авар Гасан шул шланг эчәгеләреннән кызларны шашындырырлык итекләр тегә.

Кызлар зонасына итек салмаган берәр кытай калдымы икән зонада? Әй яраталар иде алар украин кызларыннан хат алырга! «Ванечка, мой милый, кохоний мий!» — дип көйләп укып җибәрсәң, Ванечкалар һуштан яза иде. Зонада һәр кытай кызлар өчен «Ванечка», һәр кытайның арадашчысы, кызларга хат яза торган «сәркатибе» бар. Бригадабызда башмак иренле, чокыр күзле, бәләкәй иякле күсе Хан-Жубо бар иде. Ничәмә ничә хат яздым мин аның исеменнән, теге яктагы билгесез Галядан килгән җылы хатларны укып, Ваняның кайнар күз яшьләрен күпме агыздым. Иленнән, ватаныннан, теленнән аерылган, җәмгысы утыз биш елга хөкем ителгән, илендә тормыш корырга өлгермәгән бу эшчән, үтә тырыш, эчкерсез, хәйләсез кытай егете хатын-кыз өчен үләргә дә әзер иде. Булды, көнләшүчеләр туды, хатын-кыз өчен ызгыш-талашлар купты. Хәтеремдә, ике кореялы бер үк украинкага хат язалар икән... Мут алар украинкалар, күңелләрен берәү белән генә бастыра алмыйлар, шуклыналар, егетләрдән көләләр. Ике кореялының күчәрләре күчәргә бәрелгән бит берзаман. Заводта, кирпеч таулары арасында пыр тузып бәргәләшәләр. Берсе икенчесенә: «Әйдә, кеше күрмәгән җиргә барыйк та үлгәнче сугышыйк!» — ди. Араларына мин кердем, уртак фикерләрен белдереп, алар мине шаһитлыкка чакырдылар. Тагын мин! Таза-базык кореяннар бер-берсенә ыргылалар, ут уйнаталар. Нинди сүзләр табып ипкә китергәнмендер аларны, орыш үлемгә барып җитмәде... Хан-Жубо ничек юнәткәндер, тәмле телле тәчекәй Галяга чоботыларның менә дигәнен юлладык, кытай егете имән чикләвеге дәүмәлеге шешәләрдә хушбуй бүләкләр дә җибәрә торды. Кытай җиргә башын бәрә-бәрә миңа рәхмәтләр укый. Япон-кытай, мадьяр-немец, румын-поляк тоткыннары, иранлылар, әфганлылар, үз илләреннән хәбәр ала алмаган коллар, Актас зонасыннан терек суы — хатлар салып торган хатын-кызларга үлгәнче рәхмәтле булганнардыр дип уйлыйм. Дзидра белән язышканнан бирле үзем дә бер башка үсеп киттем! Мин кемгәдер кирәк идем. Туганнарга, әти-әнигә кирәклек ул бер нәрсә, монда чит милләт кызы сине күңел угы очында тота. Кемдер кызганмыйча миңа үз җылысын озатып тора.

Бер кичне, әле бараклар ябылып өлгермәгән, күрше секцияләрнең берсендә йогышсыз тавыш-гауга купты. Озакламый тузанлы коридорда якага-яка килгән ике яшьрәк ир-ат күренде. Пыр тузып талашалар тегеләр, тавышланмыйлар да, әмма теш араларыннан чыккан сүзләре эт яламаслык иде. Сүз ниндидер хат турында бара иде. Бүтәннәр шыпанмыштым гына секцияләренә чумды, мин, күрмәмешкә салышып читтән генә карап торам. Берсе безнең баракныкы, карьер цехы бригадиры Виктор Дождев дигән егет. Икенчесе, озыны, көчлесе бүтән барактан

килгән. Колагыма «Лена» «Иван Капустин», «этап-юл», «хатлар» дигән сүзләр ишетелеп китә. Тарткалаш чын сугышка әйләнә дигәндә Хөсәен Залиханов килеп чыкты, әтәчләр уртасына кереп, тегеләрне аерды. Виктор: «Мә, ал, күсе!» — дип дүрткә бөкләнгән кәгазьне идәнгә ыргытты, озын егет аягы белән кәгазьне таптап, төкеренеп чыгып китте. Кәгазь исә идәндә аунап ятып калды. Кеше-кара юк, кәгазьне шым гына алдым да секциямә сендем.

И язмыш! Синең каян, кай тарафлардан ниләр китереп чыгарасыңны бер Алла беләдер!.. Хатны, нигәдер, куркып-ашыгып ачтым. Анда нибары ике-өч җөмлә генә бар иде. Лена Иваненко дигән кыз хәленең авырлыгыннан зарланган һәм «Виктор! Нигә хат язмыйсың?!» — дип хатын тәмамлаган иде. Шушы юк кына хат кисәге өчен нигә тарткалашканнар егетләр? Аңламадым. Ленаның эре-эре хәрефләре чәчрәп, күзгә ук булып кадалып торган хатын ташламадым, матрас саламы арасына тыгып куйдым...

Илленче ел таш табутта үткән булса, илле бернең җәе чагыштырмача әйбәт узды дияргә була. Җәйлектә кирпеч заводы хәлләнә, ыжгырып эшләп утырган өч пресска балчыкны экскаватор казып, вагонеткаларга төяп озата тора. Барлыгы дүрт пресс, алмаш-тилмәш берсен төзәтеп, тешәп, балчык-комнан ашалган өлешләрен алыштырып торалар. Махсус бригада карьерны кышка әзерли, кышын кулдан казылачак мәйдан өстенә калын такталардан түшәм җәя. Кышын бригада шушы түшәм астына чума, балчыкны отбой чүкечләре ярдәмендә казый, вагонеткаларга кулдан төйи. Эш төгәл бүленгән: берәүләр җәйдә хәстәрләнгән түшәмне юан баганалар ялгый-ялгый ныгыталар, икенчеләр дыр-дыр балчык казый, өченчеләр тимер юлларны күчерә. Ак тыгыз балчык ике тапкыр тегермәнгә кереп чыга, ваклана һәм киң-киң тасмалар аша пресс цехына ага. Һәркемнең ныклы эш урыны, һәр бригаданың планы һәм бурычлары тәгаенләнгән. Эшкә тотынгач, кычыткан җиреңне кашырга да вакыт калмый! Завод, бригадалар, һәр аерым кеше — һәммәсе әнә шул туймас тамак резин тасмага бәйләнгән, ага да ага ул, бүтәннәрне үз ритмында эшләргә мәҗбүр итә. Көчли, тарта, йолыккалый, үзеннән калдырмый.

Җәй күңелле үтте диярлек, балчыгы алынган карьер чокырларына яздан су тулып калган, әтиләргә язган «күлләр» шулар инде, суы ап-ак һәм сыек боламыктай булса да, без шунда су коенабыз. «Черек күл» дә йотарлык су тапмыйча изалансам, монда «ак ташлар» җирендә су керәм бит, әй! Ярлары кай урында шактый текә, корып, ярмаланып торган балчык кыяларны керәшәләр каян белеп тапканнардыр, текәрәк ярларны тишеп-тишеп оя типкәннәр. Илле беренченең җәе эссе һәм үтә коры булды. Без әлеге дә баягы кирпеч блоклар ясадык. Җәй азагында бу җиңел эш тәмамланды, безнекеләр җайлырак, җиңелрәк эш эзләп, уңга-сулга карана башладылар. Бригаданың таралачагы көн кебек ачык иде, шушы вакытта йоклап калмасаң, эшнең үзеңә охшаганрагын сайларга да була иде. Кем тәкъдим иткәндер, мин карьер цехына елыштым. «Җылыда!» — диделәр. Миңа отбой чүкече тоттырдылар. Бригадир Виктор Дождев чүкеч тоттырды да мине яшь кенә «западник» янына куйды: «Өйрәт!» — диде. Янәшә эшли башладык, шулчак мин үземнең украин телен бөтенләй белми икәнемә төшендем. «Западниклар» — заманында СССР басып алгач, «ирекле кушылган» санала торган өлкә вәкилләре арасында тиз-тиз урысчага шомарган адәмнәр байтак иде. Әмма «западниклар»ның күпчелеге, аерата яшь-җилкенчәк урысча сөйләшми, урысларны яратмый, милли аерымлыкларны һәрдаим сиздереп, үзләренең өстенлеген раслап тора иде. Белсә дә, урыс сүзләрен бик астына куйган Микола мине эшкә өйрәтергә тотынды, ә мин... торам шәнкәйгән колагымны селкетеп. Аңламыйм тегене! Ә тегенең талкан шактый коры, Кырым татарларыннан гасырлар дәвамында җык күргән халыкның «татар» дигәндә мыегы чуала, гел кырын карый егетем! Карьерда тимер юл

төзелешендә Фельдман фамилияле өлкән генә яһүд эшли иде. Аның белән танышып киттек. Западниклар Фельдманны «пан профессор» дип нык хөрмәтләп йөртәләр, аны авыр эшләрдән коткарырга да тырышалар. «Професор тек профессор». Баксаң, Фельдман гап-гади авыл мәктәбе укытучысы икән. Ул миңа украин теленнән «дәресләр» бирә башлады. Миколаның чырае ачылды. Кайсы милләтче үз телен өйрәнергә тырышканны яратмасын ди?..

Хәтерләмим, ничек янәшә килеп басканбыздыр, мин бригадирлар күзеннән читтәрәк йөрергә тырыштым, вахта алды идеме икән. Виктор кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды. Хат! Укыды, бригадирның битараф чырае үзгәрде, житдиләнде, ул хатны ертkалап читкә ташларга теләгәндә күзе миңа төште. Йотылып карап, торуымны күреп, көлемсерәде һәм: «Укыйсың киләме?» — дип сорады. «Зонаданмы?» Бригадир беренче тапкыр минем йөземә бакты, хатны сүзсез генә миңа сонды. Нидер сизенгән йөрәгем талпынып куйды, эре-эре командир хәрефләр белән язылган, тигез, саллы юлларны йотылып укып та чыктым. Хат әлеге дә баягы Лена Иваненко исемле кыздан икән. Ире-хатыны бергә торган заманда Лена зонаның иң мәшһүр егете Иван Капустинның мәгъшукасы булган. Теге озын егет Капустин заманында Лена артыннан йөреп караган, хәзер дә хатлар язып кызны тинтерәтә икән! Һәр җөмләсе төзек Ленаның, һәр җөмләсеннән көчле хис бөркелеп тора, бер сүзе дә битараф калдырмый иде. Язу рәвеше дә, җөмләләрнең берсе өстенә берсе өстәлеп куерткан уйлары да, кыюлыгы да ошады миңа ошбу хат иясенең. Юк, юк, Лена Дзидра кебек ялгызлыктан зарланмый, киресенчә: «Чибәрләрне ялгыз тотмыйлар шул монда!» — дип, күз яшьләрен түкмичә генә зарланып ала. «Карурманга кереп адашасы иде дә, адәмнәр генә түгел, ай-кояш та күрмәсен иде! Үземне үзем күрмәс өчен Азия хатыннары сыман чадра кияр идем!» — дип яза-яза да иң актыктан: «Ванюша кайсы лагерьга эләкте икән, хәбәр-хәтер юкмы?» — дип сорап куя. Хат урысча төзек, шома язылса да, Лена украинка иде. Кыюланып киттемме, Виктордан Ленаның кайсы бригадада эшләвен белештем. Кикригем тиз шиңде, Лена хатын-кызлар зонасының коменданты икән! Лагерь башлыклары арасында минем иң курыкканым комендант иде. Кинофильмнарда немец комендантларын күреп курыккангамы, Ленаның югары чинын ишеткәч, алдагы җылы кызыксынуым бердән юкка чыкты. Ленаның күз карашымда тукыла башлаган серле шәүләсе эреде. Дөньяның мин бер чакта да ирешә алмаслык биеклегеннән миңа чөгендер чырайлы, табак битле, түшенә потлы-потлы герләр элгән албасты карап калды. Телем генә тыела алмады: «Чибәрме?» — дип сорады. Виктор чырт итеп җиргә төкерсә дә, төкерегенең кая барып тигәнен аңладым. Ул ахмак соравыма каршы акыллы сорау белән җавап кайтарды: «Капустинны күреп калган идеңме? Ул ямьсез хатын-кызны яр итә торган егетме? Лена... дөньяның бер гүзәле ул!»

Илле бернең көзендә, вакытын төгәл хәтерләмим, иләс-миләс, чәбәләнгән күңелем ишеген киереп ачып, дөнья гүзәлләренең гүзәле, кызлар зонасының дәһшәтле коменданты Лена Иваненко килеп керде. Исеме уйларыма ябышты, төкмач кунасын кытырдатып кимергән сычкан шикелле, гел бимазалап, тыкырдатып тора башлады. Дзидра белән кызыпкызып язышабыз, миңа да аннан бүләк насыйп булды, латыш кызы миңа хуш исле бер кап папирос җибәрде. Ул чакта мин сасы махорка исенә күмелеп, пуф-пуф тарта идем. Икмәк пайкасын бер чеметем тәмәкегә алыштырыр дәрәҗәгә җитмәсәм дә, иблис сеңдергән гадәт шактый нык иде әле. «Без янганчы — тәмәке янсын!» Дзидра да аллы-гөлле папирос кабына: «Не кури, писатель мой!» — дип сырлап куйган.

Дзидраның биш-алты яшькә олы булуын да, аның зифа гәүдәсе янәшәсендә кәтүк икәнлегемне дә чамалыйм, әмма күңел сизә: тиздән ике арада мәхәббәт хатлары да йөри башлаячак! Зона ялгызлыгы иң кабахәт ялгызлык ул, адәм балаларын тилертә торган шомлы ялгызлык! Дзидра

башлап сүз әйткәнне: «Яратам!» — дип ыңгырашканны көтә, шул шәүләхисләргә тотынып, тормышын җиңеләйтергә, корып барган өмет бакчасына шифалы мәхәббәт тамчысы тамдырырга тырыша! Мин моңарчы Дзидраның йөрәгенә ачкыч ятатырга, аның тормыш серләрен алырга ашкынмадым, тиешле-тиешсез сорау яудырып кызны борчымадым. Әнә шул сабыр тыйнаклыгымны ошаттымы, аның хатлары һаман-һаман жылырак, хәтта ки кайнарырак була бардылар. Аннары, нигә яшерергә: сине, көйгән йон исе сеңгән, тәбәнәк, арык гәүдәле берәүне: «Писатель мой!» — дип зурласыннар әле! Лагерь башлыклары бар, комендант-нарядчиклар бар, гайрәтле бригадирлар баракта ничәү, тик алар берсе дә язучы түгел. Бу балачактан көткән илаһи дәрәҗә түгелмени?! Иректә ни тырышып ала алмаган бөек дәрәҗәне юмарт күңелле латыш кызы Дзидра бирде миңа.

Виктор Дождев күренгән саен исемә кылт итеп Лена килеп төшә. Уйлыйм-уйлыйм да, безнең җаннар әле белешмичә дә бер-беренә омтылалар түгелме, дигән нәтиҗә ясыйм. Хат язарга омтылам да тыелам, асыл егет Капустинның мәгъшукасы исә күкрәгемне туктаусыз кимерә, бөркет булып чукый. Градобоев белән сөйләшкәлибез, ул, хатын-кызның тән хыянәтен бер очракта да аңламый торган тугры җан, миңа үгетнәсихәт бирә. «Язышма! Агулама күңелеңне! Син хатыннарның бу зонада чакта ниләр кыланганын ишетмисеңмени! Шашынганнар алар монда, күрсәткәннәр кәмитне! Сан артыннан куганнар алар, бер-берсен уздырып кочакларына әле урысны алганнар, әле немецны. Башмак иренле кытайлардан да чирканмаганнар!.. Өч мең хатын-кыз дүрт йөз ир-атны туктаусыз көчләгән. Пычрак аларның җаннары!» — дип, очрашкан саен котырта. Чит ил вәкилләре нәүмиз, боек, аларга хат алышырга, исәнлекләрен хәбәр итәргә дә рөхсәт юк, үз туган илләре өчен алар беткән, югалган кешеләр. Безнекеләр әкренләп хат-посылкалар ала башлады. Градобоевка хат юк та юк. Хатыныннан хәбәр алмыйча тилмергән ир кеше хатыннар хакында нинди юньле сүз әйтсен? Николай Ильичның теленә шайтан төкергән, әле бер хәбәр ияртеп килә, әле анекдот сөйләп чыгып китә. Җөмләдән берсе: бер фитиль эштән кайткач, арып-алҗып кызлар барагы яныннан үтеп бара икән. Фитиль — «доходяганың» югары баскычы, зонада «тонкий, звонкий, прозрачный, имеет макоронную походку, ул кем?» — дигән соравы да, җавабы да үзенә сыйган тапкыр табышмак йөри... Шулай бара фитиль, артыннан комы коела, күрә бу, шыр ялангач чишенеп ташлаган, тупырдап торган имиле, нечкә билле бер чибәркәй, ботын-чатын аерып, барак баскычында утыра икән. Дәшеп фитильне туктаткан бу: «Әй! — ди икән, — мужик, кочакла мине, кети-кети уйнап алыйк!» Фитильнең күзеннән кайнар яше ага икән. «Бик кочаклар идем дә, — ди икән, тибрәнеп атынып торган куш имиләргә карап, — кочагымның шөребе бушады шул!» Градобоевның тел төбе ачык: «Теге зонадагы кынҗырлар фитиль кочагына да ташланырга әзер!»

Сүз сөрешем хатыннар зонасына кереп-чыгып йөри башлагач, кайбер йомгаклау уйларымны да сезгә җиткеримче, мөхтәрәм укучым.

Озак вакытлар хатын-кызлардан аерылырга мәҗбүр ителгән ирләр, гадәттә, үзара нәрсә хакында күбрәк сөйләшәләр, дип кызыксынсагыз, әйтәм. Эш болайрак була. Ач ир-атлар бары ашау турында гына гәп куерталар. Тук чакта игътибар итмисең, ашыйсың-эчәсең, яшисең: иртән ни ашаганың кичкә онытыла. Юк, икән, чыкмый икән, тамагың гына ачыксын, ашказаныңны котыртып, кәефеңне бозып, һәммәсе тезелеп искә төшә! Күргән сый-хөрмәтләр, көч түгеп тапкан ризыклар, тәмнәре, төсләре, рәвешләре белән шундук хәтергә ишелеп авалар. Инде тамагы туйган, канәгатьләнгән ир-ат арасына барып керик. Андый чакта ир-атлар бары тик эчү турында гәп сугалар. Аракыны кайсы илдә, кайсы шәһәрдә шәбрәк ясыйлар, кайсы ил ирләре күпме күтәрә ала, күп эчсә дә исерми, телдә гел шул сүзләр, аракы сөременә ияреп килгән хатирәләр. Ач чагында тел-теш күрсәтә алмаган йомыкыйлар да чәчрәп уртага чыга,

ач каргалар да тук сандугач булып сайрый... Инде килеп тук тамакка харам ризык — аракы да кереп китсәме? Телләрнең капкалары киерелеп ачыла, ирләргә канат үсеп чыга, иелгән башлар күтәрелә, җимерек танаулар өскә чөелә, дөнья сытып изгән ир күкрәкләре бүлтәеп алга чыга, йодырыклар яшен булып ут уйната. Телләрнең йозагы төшә, моңарчы бер айга ун сүз дә әйтә алмаган, тынкышланып, сакауланып мыгырдаган мыштыбыйлар да Цицеронга әйләнә! (Тоткыннарның шушы мәлен күрер өчен генә дә исерткечне уйлап табарга кирәк булгандыр!) Ирләр теленә хатын-кыз килеп керә. Кем кемне кочкан да, кайда-ничек итеп үпкән. Өйләнгәндә, кыз урлаганда, көндәшләренең авызын ачык калдырганда нинди батырлыклар эшләгән, туйда күпме акча тоткан, кәләшенә нинди бүләкләр әзерләгән, аның туеннан мең кеше исереп, дөнья бетереп җырлап кайтып киткән... Мәхәббәт мажаралары кат-кат, телләргә сөял чыкканчы, сүзләрнең бәясе төшкәнче сөйләнәләр. Дөрессен әйтим, сәрхүш ирләр, аек чакта ни акыллы, тыйнак булсалар да, авызларына «шайтан сидеге» кергәч, корыкуык мактанчыкка, сүз саен тере саескан очыртучы ахмакка әйләнәләр. Алар гаярь, җиңүче, көчле, теләгәннәрен һәрчак тормышка ашыручы батырлар, имеш... Мин озак вакытлар моның серен аңламадым, хәзер дә тулысынча аңлатып бирә алмыйм. Мәс тоткын ярым дуңгыз, ярым маймыл сурәтендә була ул. Хатын-кыз хакында сөйләшмәгән, аларны янәшә куеп торып үзен күккә чөймәгән ир буламыни дөньяда? Фитильләр дә хатыннар хакында сөйләшәләр. Ансыз булмый, ансыз мөмкин түгел, сагынган хатын-кызларын сөйләмичә ир-ат түзә алмый. Шунысы бар, фитильләр, фәкыйрь-фокаралар хатын-кызны һәрвакыт мактап, һәрчак олылап кына телгә алалар. «И юмарт инде минем хатыным! — дип башлап җибәрәләр дә, — ул пешергән татлы-тәмле ризыклар... Ул юган керләрдән килеп торган хуш исләр...» — дип, тыела алмыйлар. Фитильләрне тыңлаучы юк, абруй бәләкәй, анда да тынмый тоткын, түшәмгә карап, кандалалар салган кәкере эзләргә йомык күзен текәп, барыбер сөйли бирә фитиль. Ач ир-ат ризык белән хатын-кыз арасына тигезлек билгесе куя, хатын-кызны бары тик ризык әзерләүче, оста пешекче, өй караучы, тәрбияче итеп кенә сагына. Ачлар авызыннан хатын-кызның сихри тәне, тылсымлы күкрәкләре, сыгылмалы билләре, бала бишегедәй тирбәлеп торган йомыры артлары турында ләм-мим ишетә алмассың. Ач ир туктаусыз ашауны сагына, ашказаны адым саен чурлап кычкыра, ризык таләп итә, ачның сүзе мәңге бер фикер белән түгәрәкләнә. «О, — ди берәү диварга ябышып, — минем карчык пешергән пилмәннәр! Кәбестә бөккәннәре, таба тутырып кетердәп кызган беленнәр, чумар-токмачлар, ысланган кабыргалар, какланган казлар... Күпме ризыкның төсе, исе, рәвеше саклана кеше күңелендә! Ашауны, бәйрәм табыннарын, ел фасылына килешле үзгәреп торган ашсуларны юксынган ирләр, шушы татлы хатирәләргә кушып, тугры хатыннарын да өзелеп сагыналар. Сагына белмәгәннәрнең дә күкрәк бозы әкренләп эри, ирләрнең күз төпләре дымланып, кичке шәфәкъ нурларында тамчылар җемелди икән, бел дә тор — ул сагына, сагына! Ирләрнең өзмәс керә торган зона төшләрендә хатыннары көмеш чук булып, мул, җитеш табын тирәсендә бөтерелеп йөрүче фәрештәдәй көлеп-елмаеп, ирләрен ак сөлгеләр тотып каршылап керәләр. Ач ирләр телендә хатын-кыз — фәрештә, әүлия, бер чакта да, сүз белән дә хыянәт итми торган изге җан.

Белмим, кайсы көннең, нинди рәхмәтле мизгелендә шәбәйгәнмендер, мин Лена Иваненкога тәвәккәлләп хат яздым. Ни язганмындыр, ни уйлап чыгарып мактанганмындыр, төгәле исемдә сакланмаган. Әнә шул, үземне әз-мәз сискәндергән «якты дөньяда ялгыз кала алмыйсың», дигән җөмләсенә тотындым шикелле. Үземнең дә ялгыз калуны зарыккан мәлләрем бар иде. Зонада бер чакта да ялгыз кала алмыйсың, эшкә көтү итеп куалар, көтү булып өерелеп ашыйсың, ашханә, мунчаларда адәм уллары умарта күче булып тузгый, эшкә чыбыркылаганда базар ясый,

бәдрәфтә дә, бөек Ремарк әйтмешли, трамвайдагы сыман тезелеп утырасың. Юк, юк, Ленага боларны язмаганмындыр, шәт, минем бик шәп буласым, шәп күренәсем, Актасның иң, иң, иң... кызын шаккатырасым килде бугай! Язучы булырга омтылу — ниндидер бер дәрәҗәдә замандашларыңны шаккатырырга теләү дә ул! Хатка акыл да, мактану да, Ленаны мактау да кушып болгатканмындыр шикелле, чөнки ул озакламый җавап хаты язып та салды. Хатны сөенеп укыдым дисәм, бу сүз ярым-йорты гына хисләремне аңлатыр. Мин очынып, шашынып, онытылып укыдым аның хатын. Ленаның беренче хаты акыллы күзәтүләр, кыю бәяләр, тормышны тирән, киң аңлавы белән мине сокландырды. Кыз мин көткәнгә караганда дә акыллырак, туры сүзлерәк иде.

Шулай итеп, Лена беренче хатларыннан ук мине йотып алды. Аның гаҗәеп маҗаралардан торган үткәне, үткәнендәге чаялыгы, усаллыгы, дәһшәтле дә, йомшак та була белгән камил табигате, хатларының һәр бирмеш сүзендә, һәр җөмләсендә бөркелеп торган акыл таланты минем өчен күктән төшкән бәхет иде...

## 9

*Китәсем килеп китмимен,*
*Туган илдән кем туйган?*

Татар халык җыры

Без эшкә йөргән урынның рәсми исеме: «Актас кирпеч заводлары». Заводлар бер-берсенә ялгансалар да, алар икәү. «Бу заводлар бер-берсенә тагылган баржалар кебек, тик аларның койрыгы кайда да, борыны кайда икәнен белеп булмый. Кая таба баруларын әйтү дә кыен!» — дип язды Лена. Хак бит әй, дөп-дөрес чагыштыру. Җете күзле кыз икән бу Лена! «Карьер цехы мастеры Ревякинга игътибар иткәнең бармы? Икмәктер, бер уникум инде ул, сирәк очрый торган җәнлек!»

Нинди үтергеч бәя! Мин гап-гади балчык казучы, мастер белән эш йөрткәнем юк, Лена әйткәннән соң Ревякинга бүтәнчәрәк, сынап карадым һәм бу юлы да Ленаның хак сүз әйтүенә сокландым. Ул мин күрә алмаганнарны күргән ләбаса!

Алдарак искәртеп киттемме икән, заводның һәрбер цехында иректә яшәүчеләрдән начальник та, мастерлар да бар иде. Алар бригадир белән тыгыз бәйләнештә торып, көндәлек эшне җитәклиләр. Күп вакытта бу иркле хуҗалар җаваплылыкны бригадирга тулаем тапшырып, эш барышына күзәтчелек кенә итәләр. Эшкә турыдан-туры катнашмыйлар, юкбар белән борчымыйлар, үзләре дә борчылмый, тоткыннар белән җылы диярлек мөнәсәбәттә булалар. Карьер цехы мастеры Ревякин бөтенләй башка үлчәүдәге, бүтән калыпта сугылган адәм иде. Карсак буйлы, яз-көз гәләфи чалбар киеп, дуңгыз тиресеннән тегелгән каты каеш белән тартып-кысып буган, йөзе-бите каралҗым-кара ермаклардан гына торган, шәңкәйгән дәү колаклы бу урыс... анасы телендә сөйләшә дисәк, әнкәсенә хурлык, мәгәр аның телен аңлар өчен кырык мәктәп үтәргә кирәк иде! Шушы җәһәннәм уты дөрләгән вакыт эчендә Ревякинның акыру-бакыруына чыдасаң, ныклыкка олы бер сынауны узасың! Ревякин урыс теленең барлык килешләрен, исемнәрен, фигыльләрен, ымлыкларын һәм алмашлыкларын бот арасына ябыштырып бетерә ала торган тылсымчы, мәшһүр, дөньяда сирәк очрый торган сүгенүче иде. Ул ирләрнең, бигрәк тә хатын-кызларның мәгълүм әгъзаларын грамматиканың иң нечкә кагыйдәләренә сыйдырып бетерә дә үзе уйлап тапкан кабахәт телдә кычкыра. Юк, ул сөйләшми, сөйләшә белми, сөйләшә алмый, авызыннан йомыры бер аваз ычкынуга аның очлы бугаз төере каз борыныдай төртеп

алга чыга, төкләр белән тыгызланган борын тишекләреннән җил сызгыра башлый, барабан карындыгы сыман тартылган яңаклары шытырдый, муен тамырлары карасу-зәңгәр жыланга әйләнеп кыймыл-кыймыл килә, куе куnык саргайткан китек-митек тешләрен аралап төкерек чәчри, биеклеге алтмыш-җитмеш метрлы, ине хәтсез караңгылыкка кереп югалган карьерның бөтен күләме төнге күкрәү кебек дөберди, унарлаган әрсез отбой чүкечләренең тавышын басып китә, парлап туктаусыз һава куган компрессорларның шавы йотыла — дөньяда, җирдә, күктә, җир астында бары Ревякин уйлап тапкан хәтәр сүзләр, шайтан таягыдай җөмләләр генә кала. Карьерга хатын-кызлар бригадасы кергән чакта алар моңа ничек түзә икән? Хыялы чиксез Мюнхаузен да аны күз алдына китерә алмастыр. Ревякин сүзлегенә, шакшыга манчылган, пычракка буялган теленә мин чак-чак түзә идем. Түзми кара, аңа берәүнең дә каршы сүз әйтә алганы юк, ул кеше сүзенә колак та салмый, шәңкәйгән әрекмән колаклары җилдә җилбердәр өчен генә элеп куелган шикелле, моның кадәр кире, сансыз, тома мәгънәсез бәндә Казакъстанда гына түгел, Рәсәйдә дә булмагандыр. Алмаш-тилмәш зәңгәр канатлы гәләфи чалбарларына күз салсаң, аның заманында йә МВДда, йә КГБда тырышып хезмәт иткәнен, зур-зур тәрбия мәктәпләре үткәнен чамалыйсың. Гади тоткыннар гына түгел, бригадирлар да аннан шүрлиләр, зонада чакта бодай кылчыгыдай һәркемгә кадалырга әзер фраерлар да аның зәһәр күзенә чалынмаска тырышалар. Компрессорларның берсе әзгә генә туктап калса... пресс цехларына балчык агымы барып җитмәсә... Әле кемсә генә! Дәҗҗал мәлгунь шатырдатып бикләгән тәмуг ишеге шартлап ачыла, бар дөньяны боз төягән болыт һәм кара су ташкыны баса. Инде компрессорларның икесе дә сафтан чыкса!.. Дөнья бит, андый хәлләр дә булгалый! Бетте, беттең! Ревякинның кай тарафтан убылып чыгасын белмисең! Астан-өстән, уңнан-сулдан, алдан-арттан, ярык-тишектән шайтан арбасы булып дөберләп килеп чыга да тирә-якны кырып сала, кан эчә! Ата-аналарны әллә кай ямьсез тишекләргә өерләп кертә, оятсыз җирләрне каншый, каргый, сүгә, төкеренә. Тоткыннар тынып калган отбой чүкечләрен чәчеп-ташлап ян-якка сибеләләр, аның шайтан сигән күзенә эләкмәскә тырышалар, ләкин бөркет карашлы, шоңкар күзле, ел саен «ворошиловчы стрелок» ярышларында беренче призлы урынnарны алган Ревякин тоткыннарны пыркытып куа, кулына ни эләксә, шуның белән компрессор хадимнәрен тукмый. Мине эшкә өйрәткән западник Миколадан: «Ник аның үзен тукмап ташламыйлар?» — дип сораган идем, килгән шәпкә инде, сарык чакта, Микола баш бармагын чигәсе тирәсендә йөртә-әйләндереп башын чайкады. Мастерларга кул ягу түгел, каты сүз әйткән өчен дә нинди җәзалар көткәнен белми идем әле...

Әйе, без чебешләр яшәгәндә, корыч томшыклы тилгән Ревякиннар яши. Ул тол, дус-ише юк, беркая барып йөрми, китап укымый, якшәмбеләрдә дә завод зонасында, анда ул хуҗа, ни теләсә, шуны кыла ала.

Мин Лена, Дзидралар белән кызып-кызып язышкан арада заводны ике сменалы эшкә күчерделәр. Большевиклар яңалыксыз яши алмый, бу яңалыклары безнең тез астына сукты. Сигез сәгатьлек эш көнен йомгаклап, тезелешеп кайтып китүләр бәйрәм булган икән. Хәзер таңнан чыгып китәбез, көндез ярты сәгатькә әбәдкә туктаталар, зонадан китерелгән, юлда суынып-чирап беткән баланданы аяк өсте генә чүмерәбез дә тагын эшкә ябышабыз. Көч кимүен, хәлдән калуымны шуннан беләм, карьерны заводка, пресс цехына тоташтыра торган, кышын җылы, җәен салкынча озын галерея аша үтәргә кирәк. Менәсең, чайкалып китәсең, такта стеналарга ябышкан аксыл-соры тузанга кагылып аласың, тузан төчкертә, йөткертә, косасыны китерә. Менәсең, аякларың хәрәкәтләнгәндәй була, борылып карасаң — нибары энә буе җир киткәнсең.

Актасның балчык карьеры! Илле беренче, илле икенче еллар! Иң авыр, иң газаплы интектергеч дәверем. Бер кешегә норма — сигез вагонетка. Авыр отбой чүкече дер-дер килә, син аңа ябышасыңмы, ул синә-

мы — барыбер, үзле, ябышкак, авыр балчыкны каерып-каерып алгандай итәсең. Күп вакытта ул авыл шишарасы дәүмәлеге булып кына куба. Забойны башлап җибәргәндә рәхәт, эш көйле бара, аска, карьер төбе тигезлегендә вагонетка сыярлык куентык ясап, тимер юлчыларның рельс сузуларын көтеп торасың да, өстән, шактый биектән улак ясап, чокыган балчыгыңны вагонеткага шыбырдатып агызып торасың. Авыр эшкә дә күнегәсең. Чүкеч эшкә җайланмаган кулларымны йолкып чыгарырдай калтырата, чүкечкә ияреп, вакытсыз кубарылган әрвахтай селкенәсең. Чүкеч сөңгеләре тиз ашала, тупыйлана. Кай ара компрессорларның көче җитми, чүкеч киреләнә, сине тыңламый, сиңа буйсынмый. Сигез вагонетка — сигез вагонетка ул! Берзаман өске катламнарны ашый-ашый түбәнгәрәк төшәсең: балчык шыбырдап агудан туктый. Хәзер башта балчыкны кузгатасың да кулыңа көрәк аласың! Көрәк — дошман, авыр ул, җайсыз ул, ике-өч сәгать селтәнүгә уч төбе кабарып чыга, сытыла, сызлый. Җәлпәк савковый көрәк белән сигез вагонетка тутырып кара әле син! Норма үтәлми, карьер цехы норма үтәмәсә эш харап: житез presслар әкренли, ыжгырып-янып дәү авызларын ачып, кирпеч көтеп утырган Гофман мичләре сүрелә. Эш башы — карьерда. Ревякин ише котырган этне карьер цехына мәңгегә беркетерләр идемени? Ревякинга карыйм да Черек күлдәге Пронин исемә төшә — тугры палачлары бар большевикларның!

Тыныч холыклы, ипле, артык вакчылланмаган Виктор Дождевны каядыр алдылар, безгә баш булып западник килде. Западниклар арасында да «службист»лар еш очрый иде! Кавырсыннары ныгымаган, бик яшьли кулга корал алып явызланган, хәтәрләнгән, бер чакта да ике уйлап тормаган бандеровчылар арасында өскәрәк калкырга тырышкан, дәрәҗәгә омтылган адәмнәр байтак иде, байтак! Кызлар зонасының янәшәдә генә булуы, арада элеккеге якташ танышларының да очраштыргалап куюы егетләрнең канын котырта, читлектә котырган кан исә бер чакта яхшылыкка илтми иде. Урыс белән украиннарның пычакка-пычак килерлек дәрәҗәдә дошманлашуын кызлар зонасында белмиләр идемени?! Хатын-кызлар арасында да яшертен генә, шомлы күләгәдә каршылык агачы тамыр җибәреп ятканын миңа Дзидра сиздергән иде инде. Лена да: «Син ике арага барып керә күрмә, кысылырсың!» — дип кисәткән иде. Яңа бригадир килде, бу инде Хохун да, Лобков Федя да түгел, бу йомшак җәеп катыга, теләсә очлы кадакка утырта торган астыртын адәм. Сине иң җайсыз забойга куя ул, өске җиңел катламнарны үз яраннарына бирә. Синең кулыңнан көрәк төшми. Җан газабы! Паегыңны кыса, аш бүлгәндә куерагын читкә сала, синең кашыгың һаман, һаман Идел кичә, суда йөзә. График буенча ял итәбез, анда да ул син теләмәгән көннәрдә ял бирә, үч алыйм дисә, бригадир — аждаһа икән! Аңа карышып тору юк, уннарча лагерьлар үтеп, бригадир-нарядчикларның, комендантларның һәр төрен күргән, азау тешләре яралган, акыл тешләре саргайган тоткыннар да аның алдында песием-песием булалар. Яңа себерке миңа тәмам үчекте дип тә әйтмим, мәгәр минем күзлекле булуым аңа бер дә ошамады, исемемне онытты, моннан ары исем «очкарик» булды, нишләмәк кирәк, артың белән киртә җимерә алмыйсың...

Балчык карьерында уникe сәгать эшлибез. Лена белән кызып-кызып языйкан чакка туры килде бу хәлләр. Лена зонада, ул — комендант. Ашханәгә дә барып йөрми ул, ваксынмый, аңа ашның куесын, тәмлесен «асраулары — шестеркалар» ташый. Шулар ук аның вак-төяк йомышларына да йөгерәләрдер дип уйлыйм.

Лена Иваненко Сумы шәһәреннән. Адресы да хәтеремдә: Холодногорская урамы, 19 йорт. Урта мәктәпне тәмамлап, Киевтә медицина институтына укырга керә һәм киностудиядә оператор булып эшләүче абыйсында фатирда тора. Беренче курста укыганда абыйсын кулга алалар, «халык дошманы!» дигән кара буяуга манып аталар да.

Өй эчендә кем бар, бөтенесен әзерләп алып китәләр дә төрле төрмәләргә тараталар. Лена да явыз Сталин җәтмәсенә килеп эләгә. Яшь,

сылу, якты күзле кызны турыдан-туры Колымага куалар. Колыма хәлләрен белмәгән укучы калмагандыр инде, һич югында Ибраһим Салахов, Варлам Шаламов әсәрләрен укыганнардыр? Лена андагы «тәртип»ләр хакында артык чәчелеп китмәсә дә, һәр сүзендә, һәр сагышында күргәннәренең җәһәннәм газабы икәнлеге сизелә иде. Ир-атлар вә хатын-кызлар аерым баракларда яшәсәләр дә, зона бер, япь-яшь студентка закондагы каракларның да, әле матурлыкка күз күтәреп карарлык хәлләре сакланган «мужик»ларның да сулышын ешайта. Лена — күргәнегезчә, зонага аяк басуга ук һәр нәрсәне җентекләп аера алган зирәк кыз — кая, кемнәр арасына тап булганын төшенүгә, тирә-якта, Колыманың бөтен караңгы почмакларында атаклы каракны яр итә. Каракның үзеннән генә түгел, исеменнән дер калтырап тора зоналар, исемен бер әйтү бурлар дөньясында кемнәргәдер юл ача, кемнәргәдер юлны йомарлап ябып куя, бикли. Зарури икән, чикли дә! Аның кырын күз карашы булат кылыч ялтыравы белән бер, пышылдап әйткән соңгы хөкем сүзе җир тетрәтә, ишарәсеннән соң давыл куба! Беркем Ленага сүз катарга җөрьәт итми. Элегрәк оятсыз елтыраган зиначы күзләр йомылалар, ул зонадан үтеп барганда олысы-кечесе юл саба! «Телисеңме, Лена! Син үткәндә алар җиргә ятачаклар!» — ди кияү-карак... Дөнья тар, дөньяны тимерчыбык киртәләр белән большевиклар урап алган, алар патшалыгы, караңгы вә шомлы биләмәләр! Ленаның матурлыгы турында риваятьләр йөри, әллә кайларга барып ишетелә алар. ГУЛАГ идарәләреннән шома яшь офицерлар килә-китә, Мәскәүдән Дзержинский шәкертләре уралып-чуала. Һәммәсенә сый кирәк, сый! Иң татлы сый — кызлар тәне! Иң әшәкесе шул: йөзләрне, меңнәрне өркетеп торган шәүлә — Ленаның сөяркәсе, лагерь башлыкларының боерыгына буйсына, бүтәннәр күрмәгән коерыгын болгый һәм затлы кунаклар кочагына «мәгъшукасын» үзе илтеп тапшыра. Моңа охшашлы хәлләр еш булып тора, коммунистлар дөньядагы иң азгын кавемнәр, ваклыкларына кереп тормыйм, Лена үзе дә бу хакта өстән-өстән язды, хатын-кызларны кимсетүләр һәрвакыт бертөсле тәмамлана. Егылганчы эчәләр дә кызны чиратка куялар. Лена искиткеч тырыш, әдәбият-сәнгать белән яшьли танышкан, абыйсы аркылы Киевнең зыялылары белән даими аралашкан, ул яхшылыкның югарылыгын да, намусның кыйммәтен дә белә. Ни кылсын: кыз бер чакта да, бер генә төнгә дә япа-ялгыз кала алмый. «Ялгыз калдырмыйлар, филләр, арысланнар юк чагында мәйданга төрле мәет җыючылар, марабулар, сасы көзәннәр чыга. Син һәрдаим дошман боҗрасы эчендә, камалышта. Таңда гиеналар, син төшеңдә дә ялгыз кала алмыйсың! Караңгылык та, яктылык та сиңа дошман. Сәнәк куллы гориллалар, туймас буар еланнар, албастылар, убырлар төшеңә кереп йөдәтә, алар синең күлмәк итәгеңне кисәләр, күкрәкчәләреңне йолкып ыргыталар, иске башмактай тузган, селәгәйле иреннәре белән күкрәк башларын чапылдатып суыралар. Эчеңә дәү корсакларын иплэп сине изәләр...» — Лена шулай дип язды. Дүрт елга якын шушы кимлекләрдә җәфа чиккән горур кыз түзә алмый. ГУЛАГтан килгән чираттагы офицерга тапшырырга алып барганда, үзен сөяркә итеп тоткан мәшһүр каракның йөрәк түренә үз хәнҗәре белән кадый. Колымадан хәбәр ил буйлап тарала, көчлеләр көнләшә, көчсезләр сөенә, күз күтәреп карарга да базмаган вак-төяк караклар, шушера, сукыр черкиләр Ленаны тагын камап алалар! Мәшһүр каракның җанын кыйган батыр туташның тәмен татып карау аларның иң зур хыялы! Ләкин Лена батыр булып чыга, ике кулына ике пычак тотып, зона хуҗасының бүлмәсенә бәреп керә, ишек катында сакта торган солдатны тибеп очыра. «Әгәр мине Колымадан озатмасагыз, һәркөн бер адәмнең башын кисәчәкмен!» — дип кычкыра... Суд була, судьялар чышын-пышын аның нечкә биленә, күкрәкчәсез дә текә күтәрелгән имиләренә карап чышын-пышын нидер мыгырдыйлар да, тагын дүрт ел срок өстәп, этапка чыгаралар. Этапта йөри кыз, бер урында да аны кабул итмиләр, тоткарламыйлар: кайда, ничек беркетергә аптырагач, кызны

«ябык төрмәгә» илтеп тыгалар. Дау күтәреп ачлык игълан иткәч, тагын лагерьга күчерәләр. Айлар-еллар эчендә тәмам куркусызга әйләнгән затлы студентка дәһшәтле хатынга әйләнә. Особый лагерьлар җыела башлагач, кырык сигездә үк аны Караганда тирәсенә китереп ташлыйлар.

Без бердәй шартларда утырсак та, язмышларыбыз бер-берсенә һич охшамаган юллардан куыла, хәзерге мәлдә без капма-каршы ике котыптан торып хатлар алышабыз. Миндә унике сәгатьлек авыр эш, бер, ике... сигезенче вагонеткалар, үзле, ак булса да авыр балчык. Сөйрәлеп кайтам да егылам, ни дисәң дә физик хезмәт өчен яратылган тән түгел, көчем балчык төяргә дип алдан исәпләнелмәгән. Ул һәркөн миңа хат язып сала! Һәркөн! Атна дәвамында аның хатларын чамасыз сөенеп укыйм, түземсезләнеп, яныи-көеп көтеп алам. Аның ачы язмышының «бизәкләрен» уйлап, Ленаны кызганам, җәллим. Атна буе мин аның хатларына җавап әзерлим. Отбой чүкеченә буйсынып, йөрәгем тибә, аның шашкын ритмына ияреп, гәүдәм калтырый, уйларым гына иректә, алар карьер түбәсен тишеп чыгып китәләр дә җылы теләктәшлек җибәреп торган шәфкатьле украин кызы тирәсенә барып җитеп бөтереләләр. Бригада ярым караңгы галереядан әбәдкә сөйрәлгәндә мин ялгыз калырга тырышам. Болар — минем бердәнбер тыныч, иң бәхетле минутларым. Мин Лена хатларыннан җаныма күчкән тәэсирләрне барлар өчен әзгә генә ялгыз калам. Уйлыйм, уйлыйм. График буенча ял көнем килеп җитә, мин бригаданың чыгып югалганын зарыгып, тилмереп көтеп алам. Кеше акылы керделе-чыктылы ул, элгәре «ник безне уникешәр сәгать эшләтәләр?» — дип тыпырчына идем, хәзер, ышанасызмы-юкмы: «Нигә тәүлек буе тоташ эшләтмиләр икән, ул арада ялгыз баштан мин Ленага нинди хатлар язмас идем!» — дип көяләнәм...

Менә аяк тавышлары сүнә, тына, мин бушлыктан кинәнеп, тынычлыктан очынып-очынып хат язарга утырам. Ленаның хатларын сакларга тырыша идем мин. Бу җинел эш түгел! Завод зонасында надзирательләр күзәтә, алар аулак тишек-тошыкларны болай да тентеп йөриләр. Эштән кайтканда биш солдат котырынган күзе белән сине тишкәли-тишкәли каршы ала. Хат тапсалар — карцер. Шулай саклап алып кайткан хатларны яшерер урын юк, ара-тирә секцияләрне дә инә күзеннән үткәрәләр. Ә мин, камыр батыр, курка-өркә булса да Лена язганнарны җыя барам, хат язар алдыннан кәгазьләрне бер кат күздән кичерәм, уйларымда аның белән гәпләшәм, бәхәсләшәм, килешәм, кире кагам. Язарга тотынам. Әбәдкә без биш-алты кешелек нәни төркем булып барабыз, усалланып ризыкны чиратсыз алабыз, талашабыз, ризыкны күз ачып йомганчы хап-хоп йотабыз да мин баракка чабам. Лена мине дәфтәр белән тәэмин итә, ул таба.

Көне буе язам, анда да сүзем бетми. Бригада эштән кайтканда дәфтәрне тыгыз, вак юллар белән шыплап тутырып куям. Хәзер уйлыйм: иң яхшы әсәрләрем, уктай атылган, яшендәй яшьнәгән, тау шарламасы кебек шаулаган фикерләрем әнә шул дәфтәрләрдә калды. Лена белән бергә югалды. Күңелемнең айкалган, аргамакларга менеп җилдәй җилдергән чаклары! Әңгәмәдәшем — уңган, кыю, чая кыз! Уйларының төрлесен уеп салып, баш ватарга мәҗбүр иткән дәвер! Ул минем хатларны көтеп ала, алдагы атнада һәркөн шуңа җаваплар яза, сөенә, бәхәскә керә, хуплый, дәртләндерә, ярсыта. Мин Лена хатларының кадерен шул чакта ук аңладым, язучы булам дигән хыялның күңелдән төшкәне юк иде, хатларны берәмтекләп өйгә сала бардым. Рөхсәт юк, рөхсәт юклык хат язышырга теләкне үзе үк ашкындыра, ул арада мин тәҗрибәле тоткын идем инде. Әлеге дә баягы шоферлар яшәсен! Хак, хатларның күбесе, бик күбесе сәфәргә чыга алмады, югала торды. Багражга кайтып җиткәннәре дә байтак, сак әни аларны төрле почмакларга тыгып куйган. Хәер, бу турыда искәртеп киткән идем шикелле. Мин Ленага язган хатларыма чын исемемне куймый идем, ул хатларда мин «Алексей Неон», яки

«Алексей Глазунов». Зонада болай да исем юк, сине номерың саклап йөртә, күпчелек юлдашларым мине «Алексей» дип белеп калдылар. Лена хатларда исемемне аралаштыра, «Аяз» дип яза, «Алексей» дип тә куя. Кызганыч, Ленаның җан тартышларын ачкан бик күп хатлары эзсез югалды. Минскеләр кайда икән?!..

Ленага өзлексез язам, берүк вакытта Дзидраны да мәхрүм итмим. Бервакыт Теодор Августовичның белеш хатынынан мондыйрак хат килеп төште. «Синең дустыңның Дзидрага язган хатларын кулдан-кулга йөртеп кычкырып укыйлар. Укыйлар да утырып җылыйлар. Кем ул? Хатын-кыз җанын шул тиклем кайда өйрәнгән? Син аны яшь, студент дип таныштырдың лабаса! Шуны да әйтим... ул кеше безнең зонада атаклы булып китте, төрле сүзләр йөри, кыскасы, хатын-кызлар аның өчен канга-кан килергә әзерләр. Синең бәләкәй дустың һәммәсен уйласын!» Дзидраның Лена белән тарткалашырлык көче юк иде, әлбәттә. Ике хатын-кызның дошманлашуын һич теләмәдем. Дзидрага хатларымны әзләп-әзләп сирәгәйттем, ул үзе хәлне аңладымы, ел азагында безнең аралар суынды.

Ленаның илле беренче елның унберенче ноябрендә язган хатыннан бер өзек. «Сез, Алексей, хатын-кызның хисләре акылыннан өстенрәк»,— дип язасыз. Хатын-кыз хисләрен сез ничек аңлыйсыз? Бәлки, моны без — хатыннар аңлап бетермибездер? Мин аңларлык итеп язгыз әле җавабыгызны. Көтәм. Дөрес аңладыгыз, лагерь юлларында мин күргәнтатыганны тагын берәр җан татыдымы икән? Сез хаклы. Тоташ кошмар иде тормышым! Хәтергә алырга да куркам. Алай да, әгәр мин хискә бирелеп кенә яшәсәм, акылны алга чыгармасам — исән калыр идемме икән? Хатын-кызлар лагерь сукмагына төрлечә кереп китәләр, берәүләр язмышларын сакларга омтылып, очраклы ир-атларга авышалар һәм шул юлдан котыла да алмыйлар. Мин бу чуалчык системаны тиз аңладым, аңлагач көрәшү дә җиңеләйде. Мин бары тик берәүнең корбаны булдым, аны яшермәдем дә. Исем чыгудан куркып, күләгәдә шыпырт яшәргә теләгәннәр кулдан-кулга күчә китте! Алар срокларының азагына хәтле сатылдылар һәм намусларын тәмам пычраттылар. Мондый тормышның ни белән тәмамланганын аңлыйсыздыр? Стрептоцид һәм туктаусыз чирчинкеләр... Оятсызлык та гадәткә керә, андый хатыннар һәммәсенә кул селтәп, теләсә кемнең шакшы кочагына ташландылар. Теге вакытларда тормыш өчен көрәш әнә шундый гарип бер әмәлдә бара иде. Мин бүтәнчә яшәдем. Мин бик күп корбаннарны буйсындырган берәүнең генә корбаны идем. Яшермим, тәсем-битем, акылым-фигылем ирләргә ифрат ошый иде минем. Үземне һәм сүземне мин югары куйдым һәм бер дә иелмәдем. Мине буйсындырганнар мецнәрне кулларында тота торган затлар иде! Бүтәннәр миңа якын килергә курыктылар! Күнегәсең, аерылышканда хәтта моңсу була... Ялгыз калырмын дип моңсуланмыйсың, кая ул, ялгыз калдырмаслар дип борчыласың. Ә лагерьда... лагерьдагыча инде! Бүген монда, иртәгә анда! Лагерь тормышым минем шулай акты. Ни сөйләсәләр дә, җанымны арзанга бирмәдем мин, бөгелмәдем. Егыларга икән, югарыдан егылырга! Ә болай барасың да абынасың, атлыйсың да сөрлегәсең. Аяк киемең генә туза! Мине кочакка алганнарның һәммәсе дә гүзәл затлар иде, дип масаерга җыенмыйм. Ләкин минем белән якынайганнар бәямне беләләр иде!.. Сезнең зонада гайбәтләр йөридер, ышанам. Йөрсен! Хатыннарның эт талаган телләреннән төрле сүзләр хатлар аша йөреп торадыр. Белегез: Иван Капустин минем ерак лагерьлардагы дустым иде. Аның янында мин тыныч, сабыр диярлек яши алдым. Ә тоткын хатын-кыз өчен мондый язмыш бер дә җиңел түгел. Ярларны, дусларны, тән бүлешүчеләрне без сайламыйбыз, аны инде, Алексей, чекистлар билгеләп куйган. Нигә минем хакта шулкадәр күп сөйлиләр?.. Тезелешеп барабыз, конвой берәүгә дә бәйләнми, ә мине чокчып кына тора! Мәскәүдән берәвесе килә, мине чакырталар. Лагерьда хатын-кызның иң зур бәласе — чибәрлеге. Чибәрлегем аркасында күпме

кыен ашаганымны белсәгез!.. Сез үткәннәрем өчен мине кызганасыз, гөнаһларымны кичерәсез... Кызгану хисе миндә калмадымыни?.. Мин дә яныгызда басып торам, кайгы-хәсрәтләрегезне уртаклашам. Минемчә, бу инде әз түгел».

Илле икенче елның беренче гыйнварында язган хатта сүзләр инде бүтәнчә, хат та бүтәнчә башлана: «Здравствуйте, любимый мой!»

## 10

*С кем протекали его боренья?*
*С самим собой, с самим собой.*
Борис ПАСТЕРНАК

«Здравствуй, любимый мой!»

Илле икенче елга мин шулай, дөресрәге, без шулай, мәхәббәт көймәләренә аерым-аерым утырып, гыйшык диңгезенең шаулы-гөрле чагында бер-беребезгә төшләребездә йөзә-йөзә килеп кердек. Нигә кирәк булды икән бу язышу?! Яшь ягыннан миннән күпкә олы, тәҗрибә ягыннан мең тапкырлар өстен, озакламый ирекка чыгасы хатын хат язышыр өчен нигә мине сайлады икән? Юаныч идеме бу аның өчен, әллә бер-бер уен гына идеме? Хәзерге акылым белән уйлыйм, бәлки минем аша, яңарак кына университет аудиторияләрен ташлап чыккан егет белән сер алмашып, дөньяның яңалыкларын турыдан-туры белергә теләгәндер? Үзенең студент еллары, сагынылган бәхетле-ваемсыз көннәре хәтерен уяткандыр? Белмим. Әллә зона бозарга өлгермәгән, ирек җилләре җанымнан очып таралмаган кеше аркылы, тиздән үзе чыгасы дөньяның һава торышын ачарга теләдеме? Вакытын, көч-дәрманын җәлләмичә төннәр ката язган хатларындагы җаваплардан бигрәк, сораулар күп булуы шуны расламыйммыни? Ул чакта мин боларны, Ленаның тирәнлеген, фаҗигасенең кискенлеген аңлап бетермәдем, ул тәкъдим иткән мәхәббәт уенына кереп киттем шикелле. Аның кайбер фикерләре хәзер дә исемә төшә. Җөмләдән берсе, миңа калса — иң мөһиме: дусларны сайлап алу бәхете. Беренче карашка, бик гади мәсьәлә кебек: дусларыңны, әлбәттә, сайлап аласың! Син ирекле, һәрьяктан сайлау хокукына син хуҗа. Төптән уйлаганда исә, без дусларны чынлап торып сайлап алабызмы, әллә язмыш безне учында йомарлап тотып, дус дип аталган төркемне көчләп тагамы?.. Бу әле иректә, үз көнеңне әзме-күпме үзеңчә күреп ятканда шулай. Ә зонада? Төрмә-лагерьларда?! Моңарчы Лена Иваненко, меңләгән кеше сыйган казанда гөр-гөр кайнаса да, сайлап алу хокукы булмаган диярлек. Беркайчан да. Гәрчә ул бераз мактанып, бераз үз яшәү формасын аклап, Акланырга бик нык теләп, «лагерьның иң зәһәр карагын сайлап алдым да аның ышыгында хәвеф-хәтәрсез диярлек яшәп яттым», — дип, Колыма чоры тормышына йомгак ясалса да... ай-һай, үтерүче, карак, закондагы бур үзе Ленаны тозсыз-борычсыз кабып йотмадымы икән? Мөгаен, шулай булгандыр. Ә хәзер ул мин малай-шалайны, хатын-кызларны һич аңлап бетереп булмый торган илаһи затлар итеп санаган, бар яхшылыкны алардан гына күреп була дип инанган беркатлы сала кабартмасын өерләп кенә йотты. Яшермим, аның беренче хатларында беркатлылыгымнан көлү, ирония, чак кына мыскыллау да бар иде!.. Соңра, мәхәббәт алмашып, арада сөю хатлары йөри башлагач ул да йомшады, биеклектән минем янга төште.

Зонада дус-ишләрне сайлап алу мөмкинлеге юк. Яши-яши, бик күп рухи сынамышлар кичергәч кенә, кемнәрнедер сайлап алгандай буласың. Ә болай... зона якыннарын сиңа әче язмыш билгели, сайлаганда синең ихтыярны искә алучы юк, этап юллары бер-берсен аңламый торган бик күпләрне бер чокырга җыеп тутыра. Свердловск, Петропавел, Карабас

төрмәләрендә мин шаккатып караган сәяси тоткыннар сафы, тормышның усал бертөрлелегенә килеп эләккәч, вак-вак кисәкчәләргә таркала, җыелмаслык булып тарала икән.

Агач, саргаеп беткән такта вагонканың дүрт канатына язмыш җилләре дүрт яктан дүрт бәхетсезне китереп ыргыта. Һәр кеше — бикле йозак. Син, Лена әйткәндәй, бүген — монда, иртәгә — анда. Зонада беркем дә синең тормышыңа үтеп керә алмый, син дә азаккача аны берничек тә беләчәк түгелсең. Гәрчә, син срогыңның соңгы көненәчә чәнечкеле тимер чыбыктан матур үрелгән киртәләрдән генә түгел, үзенне ураган бик күп адәми җаннардан да котыла алмыйсың. Син һәр урында яңа вагонкага, яңа тимер капкаларга, яңа вышкаларга күнегергә мәҗбүрсең. Һәр зонаның үзенә хас эчке кануннары, әйтергә ярасa — эчке пружинасы бар. Ничәмә-ничә еллар шушы йомык капкалардан үтеп-сүтеп йөргән тоткыннар да аның серләрен ачып бетерә алмыйлар. Менә төрле тарафларга таралган төрле колонналар кайтып керә. Коллык язмышына тагын бер сызык өстәлә. Төрле милләт вәкилләре, төрле телләрдә тәңрегә табынучылар, телләр үзгә, һәркем үз ходасы аңларлык итеп эндәшергә тырыша, явызлар керткән сукмактан менә авам, менә түнәм дип бара да бара.

Дүрт-биш йөз кешелек колоннага укмашып, эшкә барган-кайтканда иптәшләрең хакында уйламыйсың, бөтен игътибарыңны конвой солдатлары ялмап йота. Син монда хайван өере, сиңа акыралар, бакыралар, карлы-бозлы суга сеңдереп түшең белән юлга яткыралар, артыңа китереп тибәләр, мылтык түтәсе белән сырт сөягеңне, кабыргаларны эзләп табалар. Конвой солдатлары һәрвакыт хаклы. Хәтәр минутларда тоткыннар кинәт берләшәләр, нык йодырык булып йомарланалар. Юлда шулай була. Инде кайтып кереп, көннән котылып төн ишеген ачасың, вагонкаңа үрмәләп менеп арган тәнеңне әлеге төркемнән ертып-йолкып аласың да өн белән төш арасындагы хыялый бушлыкта йөзәсең. Терәлеп яткан күршең шундук синең дошманыңа әйләнә: яту белән гырлый ул, вагонканы ике ЧТЗ тракторы сөйрәп җәһәннәм чокырларына чумдыра-чумдыра сине сөйри. Аның аягы исле, аякчуы чергән, тез башлары, терсәкләре чиләнеп, кутырланып тора. Уянасың, җылылык өметләнеп як-ягыңа багасың, ул йокымсырап ауный, шатыр-шытыр кашынып әйләнә-тулгана, салам сырмасыннан тузан бөркелә. Теш уртлары чергән аның, тешләре кителеп вакланган!.. Колыма, зәңгелә нәтиҗәләре! Һәммәсен беләсең, күңел белән кызганасың да аны, әмма син кәефсез, кичәге арганлык тәннән китмәгән, бригадир сине орышты, конвой эт итеп сүкте, кичке ашка биргән балыклары исләнгән иде, син ач корсактан яттың... Бер гаебе булмаса да, күршеңнең һәр сүзе сине шаштыра, хәтта иң гади, көндәлек гамәлләре — вагонканы какшатып-селкетеп менү-төшүе, чап-чап басып ялан тәпи идәндә йөрүе, кәкерәеп каткан калын, сары тырнаклары, төкерек чәчеп йөткереп куюы җан ачуыңны чыгара!.. Син аннан беркая китә алмыйсың!.. Нишләмәк кирәк, ул да синнән тәмам туйгандыр, синең һәр кыймылдап куюың аны котыртадыр, ялгыш күз карашың да аны акылыннан яздырадыр. Ләкин сез, сиам игезәкләре кебек, бер-берегезгә тоташкан, бер читлеккә ябылган, һәммәгезгә бер ишек, бер тишек, бер язмыш...

Асылда, дөнья йөзендәге һәр җан үзенчә яшәргә тырыша, төрмәдә исә аны яшәрү мөмкин түгел, төрергә кабыгың юк. Бер читлеккә ябылып яшәргә мәҗбүр ителгәндә кешеләрнең яхшылык сыйфатлары тоныклана, тора-бара бөтенләй югала, күз алдында бары тик тискәре яклары, ямьсез гадәтләре, җанны мыскыллый торган шыксыз гадәтләре генә кала. Һәркем сине үз барлыгы белән җәфалый, туйдырып бетерә. Тик кача гына алмыйсың! Бу әле бездә, ирләр зонасында шулай. Ә хатын-кызлар?.. Аларның табигатьләре нечкәрәк, алар юыныргa, пакьләнергә, бизәнергә, өс-башларын юарга телиләрдер... Ә тормыш землянка-читлекләрдә үтә. Хатын-кызлар бер-берсеннән көнләшерлек сәбәпләрне шушы соры, ямьсез, бертөрле аккан тормыш мәлләрендә дә табалар. Әнә ич, Дзидра белән Лена минем аркада чәкәләшә... Минем шик-шөбһәләремнең, бор-

чуларымның соңы буларак, кызлар зонасыннан яман хәбәр килде. Яшь кенә бер украин кызын үтергәннәр! Күкрәгенә өч тапкыр пычак белән кадаганнар, барагына кадәр сөйрәлеп кергән һәм сүз дә әйтә алмыйча җан тәслим кылган, бичара! Лагерьда үтерешләр булгалап тора. Актаста юк икән, бүтән зоналардан хәбәрләр килә. Әмма хатын-кызларның үтерешє безне сискәндереп җибәрде. Мин Дзидраның гомере өчен хафалана башладым. Колымада дөнья тоткан дәһшәтле каракны чала алган Лена... Тукта, тукта!... Лена, шәфкатьле Лена, дөньядан ярсып-көеп шәфкать көткән Лена. Мине җылы сүзләре, якты фикерләре белән баеткан Лена... Тиздән иреккә чыгарга әзерләнгән Лена... Минем якты хыялларыма теләктәш булган Лена, ахыр чиктә: «Мин сине өзелеп яратам!» — дип тәкрарлап торган Лена... Алай да, алай да... «Сагай!» — дип Дзидрага язарга да куркам. Хатның юлы сер, ялгыш-моңгыш читләр кулына төшеп, Ленага барып җитмәсме? Теодор Августовичның белеш хатыны: «Синең тәбәнәк дустың өчен хатын-кызлар чәчләрен йолкырга әзер!» — дип тиккә генә кисәттемени?!

Дзидрага кыска гына хат яздым да тындым. Озакламый аны этапка озаттылар. Лена гаепле дип уйламыйм, андый ук этлеккә бармас. Минем Ленаны күрәсем, күзләр ярдәмендә аның чынлыгын чамалыйсым килде. Мин аңа: «Төнге сменага бригада белән чык, очрашыйк!» — дип яздым, ул ризалыгын бирде.

Әйткәнемчә, хатын-кызлар колоннасы белән без көнгә ике тапкыр очрашабыз. Алмашка киләбез, алар күгәрек командалар астында сменадан чыгалар. Без әллә кайда, үрдә сураеп торабыз. Аларны озак тотмыйлар, һау-һаулап кычкырып, каулап, алып та китәләр. Йөзләре сулгандыр аларның, беләкләре, куллары котырып сызлыйдыр. Ярты тәүлек кирпеч сугып, чи-үзле балчыкка ябышып ятып, тирләгән, кешелектән чыккан хатын-кызлар, ир-атлар күрмәсен тагын, дигәндәй башларын салындырып, йөзләрен яшереп, авыр аякларын көчкә сөйрәп атлыйлар... Эшкә килгәндә, без заводтан чыкканда алар бүтән! Каян көч, дәрт киләдер аларга, алар конвой белән талашып, без чыгасы капкага якынаерга, елышырга тырышалар, җаен табып кына конвойга ялагайланалар да, украинча җырлы тавышлар белән таҗик-үзбәк солдатларына: «Миленький ты мой! Хлопчик ты золотой!» — дип сайрарга тотынсалар, бел дә тор: ирләр сафында аның тавышы, хатлар язышкан кешесе булырга тиеш. Чөнки бүтән зонага эшкә йөрүче яшь-җилкенчәкләр дә шашыпшашып хат алыша, тилереп, төн йокыларын калдырып гашыйк була, ул нарядчикны җайлап, бригадирны майлап бүген кирпеч заводына чыга алган, ул бу көнне йокыларын калдырып көткән...

Андый очрашу көннәрендә ирләр ашыкмыйлар, «очрашуны» оештырырга ярдәм иткән тоткын әле заводта, ул кайдадыр посып тора, кизү надзирательләр чабып-сүгенеп аны эзлиләр. Юк ул, юк! Ул арада ике колонна арасында яшен уйнап ала, ике яктагы сафлар да парадка чыккандай төп-төз басып, бер-берләрен күз белән капшыйлар, күз белән аңлашалар, күз белән иркәлиләр, күз белән үбәләр... Аралар шактый ерак булса да, күз карашын бер учмага җыйсаң, теләгән кешеңне күрә аласың икән. Мин моны үзем дә сынадым.

Бүген кичен заводка Лена чыгарга тиеш! Үзе язганча: «Гасабиланып, тамактан калып, йокысызлык чире белән авырып», шушы кичне көтә. Алай ук булмагандыр, беләм, аңа инде уналты яшь түгел, егерме алты да түгелдер, алай да мондый хатларны уку рәхәт иде. Кемнең мәхәббәттә алданасы килмәгән ди?!..

Таңнан торып, теге яктан куе караңгылык ишекне басып, ачтырмыйча торуына зарланып, коридор буйлап арлы-бирле чабып йөрим. Ишекне төртеп-төртеп карыйм, юк, авыр йозак авызын ачарга ашыкмый. Дөнья бер чакта да гашыйк йөрәкләр белән бер ритмда типми! Каһәр суккан дөнья! Каһәр орган тормыш!.. Тик... Күрәселәр алда икән! Бәхетсезгә вакытсыз, ишек ачылып та китте, төнлә бәйдә торган Казакъстанның тиле

җиле коридорга ургылып керде дә ябылмыйча калган ишекләрне шап-шап бәреп, җәядә киерелгән яңагымны тәпәли башлады. Тышка атылдым, күккә, авыр Казакъстан күгенә күтәрелеп карарлык түгел, офыкларга бөтен яктан кара-кучкыл болыт сәләмәләрен шыплап тутырганнар. Күрешүне өметләнеп, төн ката талпынган яшь күңелем болытларны ияртеп иңемә ишелде. Кая ул, мондый һавада кызлар зонасының коменданты Лена заводка барып йөриме соң! Ходавәндәм!.. Ленаның зона патшасы булуын инде оныта, аның дәрәҗәсенә күңегә башлаган идем, хәзер шул һич кенә дә исемнән китми бит! «Комендант, комендант!» — дип үртәлә күңелем, «комендант, комендант!» — дип үрти күңелем. Чыкмас кичке эшкә, бармас, йөрмәс... Комендант ул, зонаның иркә баласы! Бармас Лена, ә без барабыз, аяусыз тәртмә җил бәреп-бәреп екмасын өчен бер-беребезгә терәлеп диярлек атлыйбыз. Мондый чакта серне иптәшләрдән яшереп булмый, алар, хәлемә кергән сыман, минем якка карап-карап куялар. Ничек заводка барып җиткәнне дә, көн озынына ни хәлләрдә эшләвемне дә сизми калдым, көн азагында да мин уңган чабагачлар белән тукмалган, юкарган арыш көлтәсе хәлендә идем. Тукмаганнар мине җитез чабагачлар, күккә атылып менеп йолдызларны коеп төшергәннәр дә, күк тә, мин дә буп-буш калганбыз. Була бит, үзеңне сыгылган лимон кабыгы рәвешендә күрәсең. И язмыш, язмыш! Нигә гел-гел рәхимсез кыланасың инде?

Минем кыяфәт... Ходайдан фәрман ирешеп, конвой безнең сафларны бер-берсеннән ерагайта күрсен, ярабби!

Сәгать сукты, капкадан иләс-миләс чыктык та конвойның күзе кисешкән мәйданчыкта бишәр-бишәр тезелдек. Урысның авыр командасы сирәк-мирәк яңгырый. Этләр алга тартылып өреп ала. Баксам, көн аязган, болытларны җил тузгытып бетергән. Ходаның хикмәте диген, хатын-кызлар рәте таучык-үрне төшеп, шактый якында туктаган. Хатыннар тасыраешып безнең сафларны тараталардыр, үзләренә кирәк шәүләләрне әрсезләнеп эзлиләрдер кебек тоелды. Аларның бер чакта да болай якын тукталганнары юк иде! Соңгы көнне бимазалаган уй миемне ярым үтеп китте. «Комендант эше бу, аның тырышлыгы!» Багана-багана литвалылар, гәүдәле латышлар, сүзсез-кырыс эстоннар, мине алгарак чыгарып, беренче рәткә бастырдылар. Биек-биек, киң җилкәле бандеровчылар, мине алабута кумәче, черек бәрәңге кәлҗемәсе ашап орчык буе гына үсә алган кәтәнә татар баласын күз төшәрлек итәргә тырышалар. Уң ягыма ун көнгә ун сүз дә әйтми торган саргайган йөзле латыш Урбанис килеп баса, очлы борынлы, гәүдәсе гел хәрәкәттән генә тукылган бандеровчы Богдан Горобец сулымда, тәбәнәк-тәбәшәкләр мине урап кала, ниһаять, минем сынарга әзер буем да әз-мәз калкына, сафлар аяк очы белән генә кемнәргәдер ишарәләп пышылдаша башлауга чәрелдәгән команда яңгырый: «Молчать!» Урысча ипилек-тозлык та белмәгән Урта Азия солдатлары авызыннан урысның бас тавышларга көйләнгән командалары мәзәк булып яңгырый. Торабыз, тукталырга боерык юк әлегә, беләм, безнең бригададан молдаван егете Тикишан карьердан да чыкмагандыр, мөгаен. Ул мине коткарырга тиеш. Конвой начальнигы кемнедер эзә, сүгә, бригадирлардан өч-дүрт кеше кире зонага кереп томылалар. Янымдагы иптәшләрем: «Алгарак чык, алгарак!» — дип, мине иңләп кенә арттан этәлиләр. Артыгы ярамаса да, мин аяк озынлыгы чамасы алгарак күчәм. Кинәт мин үзебезне, үземне, конвой күзе белән түгел, бездән йөз метрлар чамасы читтә торган хатын-кызлар күзе белән капшыйм. Ни әйтсәң дә, иң әүвәл адәмнең өс-башына игътибар ителә. Менә без, ирләр сафы. Секундның йөздән бер өлешендә сафларыбызны чабып-тикшереп узам. Юа-юа агарган, төсен җуйган френчлар. Тез башлары кат-кат төрле төсләргә ямалган, балак очлары чачакланган котсыз чалбарлар. Яшь бандеровчыларның, кавказ егетләренең өс-баш арурак, юнәтә белә алар, җайларга да маһир. Матрос сүрүеннән телеп алынган «чөйләр»не балак җөйләренә кыстырып балакларын киңәйткәннәр. Балагың никадәр киң булса, зонадагы дәрәҗәң шулчаклы «бөек» диген сүз.

Димәк — эшләмисең. Кайберәүләрнең шулчаклы киң ки, атлаганда, йә алдан, йә арттан җилбер-җилбер җир себереп баралар.

Минем балаклар... аракы шешәсеннән әзгә генә юанрак...

Ниһаять, күңел күзем дә, күрер күзем дә кызлар колоннасының беренче бишлеге янына барып кадала. Укмашып, тын ташкын булып торган хатын-кызлар да урман өсте сыман тигезле-тигезсез, бу мине әз-мәз тынычландыра, кыюланып тере ташкынны ваклыйм, аерым кызларга игътибар итәрлек көч табам. Каһәр суккан күзлек, дәрәҗәсе — минус сигез, дым күз төпләреннән Камчатканың нәни гейзеры булып чәчрәп пыялага куна, керфекләр сагызланып бер-берсенә ябышалар. Кызларга байтактан карамаган егет керфекләре шул! Берни аера алмыйм, сантый баш, иптәшләрем аякларен кага-кага, муеннарын бер юнәлешкә сузып миңа Ленаны күрсәтәләр. «Әнә ул, әнә! Алда, уңда! Кулын күтәрмичә генә ак яулык болгый!» Кызлар кулындагы ак яулык миңа һөҗүм башларга яңгыраган соңгы чакыру төсле! Ак яулыклының иптәшләре як-якка тартылалар да Лена җыйнак кына нәни дүрткелдә берүзе кала! Күз алдымда текә күкрәкле, уртача буйлы, япь-яшь, сылу ак маңгайлы, бер караганда шом, икенче караганда мәрхәмәт-шәфкать чәчеп торган төпсез күзләр кала. Боларның һәммәсен дә аерып, шулай төгәл итеп күрә алмыйм, әлбәттә. Танышырга дип миңа һәйбәт фотосын салган иде Лена, шуның хәтердә сеңгән шәүләсен хәзер күз алдымда йөртә-йөртә тере Ленага томырылам. Ул минем хакта ни уйлагандыр, минем соңгы уй-тойгыларым әнә шундый булды.

Хәер, соңра бер-беребезне макташырга сүзләрен таптык бугай. И, мәхәббәт! Син адәмнәрнең авызын йома да, зур итеп ача да аласың. Рәхмәт сиңа!

* * *

Сумы шәһәре кызы Лена Иваненко турындагы «мәхәббәт кыйссасын» шушы урында тәмамлыйм. 1953 елның маенда безне Волынка таш карьерына, яңа зонага күчерделәр. Мин анда 1954 елның 6 мартына кадәр булдым. Аннан Ленага хат салдыммы, онытылган, хәтерләмим. Волынкадан яңадан Актаска кайттым. Кайтуыма Лена срогын тутырып иреккә чыккан, аны гомерлек сөргенгә Осокаровка дигән шәһәрчеккә җибәргәннәр иде. Актаста мине кош теле хәтле генә хатчык һәм адрес көтә иде. Биш көн эчендә мин Ленага унҗиде хат язып салдым. Ул, акыллы, гомер юлын алдан күрә алып, аңа адашырга ирек бирмәүчән хатын бер-ике җавап язды да тынды. Озын колактан Ленаның Красноярск төрмәләрендә ун ел утырып чыккан, гомерлек сөргенгә Казакъстанга тәгаенләнгән бик һәйбәт, укымышлы, затлы вә чибәр егеткә кияүгә чыгуы турында ишеттем.

Бүген исән булса, мин Ленага чиксез рәхмәтлемен! Бәхет телим мин аңа! Сталин лагерьларында утырып чыкканнар бәхет сүзенә никадәр мәгънә сыйганын яхшы беләләр! Әгәр тормыш Ревякиндай урыслардан гына торса, маңгаең белән таш ярыр идеңмени?! Шөкер, дөнья йөзендә Дзидра, Лена исемле шәфкать ияләре дә бар әле!

## 11

*Мы-то, мы-то ведь никогда не умрем!*

Александр СОЛЖЕНИЦЫН. «Крохотные рассказы»

Кызлар белән урысча язышырга туры килде. Мин, татар дөньясын яктыртырга әзерләнгән әдип, урыс телен әнә шул лагерь юлларында өйрәндем, ахрысы. Шулай да моңлы, сыгылмалы үтә бай татар теленең аерым тәгъбирләрен, аерым сүзләрен урысчага

«аудара» алмыйча интеккәннәрем хәтердә. «Яхшы сүз — җан азыгы». «Җан азыгы» — нинди бөек сүз!.. «Күңел җимешләре»н урысча әйтеп карагыз инде... Минем урысчам такы-токырак булгандыр шул, бу сүз тезмәләренең асыл мәгънәсен кызларга җиткерә алмадым. Аңлату — бик кирәк иде, югыйсә!

Хәзер мин, мөхтәрәм укучым, үзем озак еллар эшләгән бригадам, аның кайбер үзенчәлекле адәмнәре, кадерле юлдашларым турында язып китмәкче булам. Соңгы елларда гел-гел пошынып йөрим, гомерем кисеп үлеп китәрмен дә, хатирәләрем, әйтер сүзләрем дә күмелер шикелле. Ә зона иптәшләрем алдында мин зур бурычлы: табигать мине язучы-әдип ясады. Хәтерем төзек, зиһенем камил чакта мин аларның кадерле исемнәрен татар телендә булса да беркетеп калдырырга бурычлымын. Язмыш мине юкка-бушка гына алар арасына китереп керттеме? Безнең Актастагы чуар язмышлылар арасыннан моңарчы әдипләр килеп чыкмады шикелле. Бәлки чит ил кешеләре үз илләренә кайткач ни дә булса язып бастырганнардыр. Минем андый мәгълүматларым да, андый мәгълүматларны җыеп тупларлык мөмкинлегем дә юк. Мин нибарысы Хәтеремә генә таянам. Язарга тотынгач, бер нәрсәне ачыкладым: өзек-өзек сеңгән истәлекләр бер-берсенә ялганып, бер-берсен ачыклап-тулыландырып, мәгънәле бөтен бер рухи көчкә, үзеннән дә көчлерәк сүзгә әйләнәләр икән.

Үткән юлларыма, Актас тирәләренә, зонадагы хәлләргә кайтып уйлана гына башлыйм, күз алдыма без эшкә йөргән сукмаклар, шул сукмакларга чәчелеп калган вакыйгалар әле усалланып, әле йомшарып хисләрне кузгаталар. Башлап шуны әйтим, тоткынның яшәеше, тулаем тормышы кайда гына узмасын, конвой белән, сакчы солдатлар белән бәйләнгән. Тоткын һәм сакчы — капма-каршы көйләнгән ике көч ул, син алардан, алар синнән аерылып китә алмый. Сакчы белән тоткын билгесезлеккә чаба торган тимер юлның игезәк рельслары алар. Сакка күнегү кыен! Сиңа аерым гына бәйләнмәгән мизгелләрдә дә сак астында булуыңны һич оныта алмыйсың! Конвой — синең күләгән ул, кояшсыз көннәрдә дә, караңгы төннәрдә дә синнән калмый торган күләгә-дәҗҗалың. Моннан кырык еллар элек булып узган, минем баштан үткән вакыйгаларны һәм шәхси кичерешләрне бер-берсе аша ачыкларга тырышсам да, конвой хакындагы хатирәләрем өзек-өзек булыр. Хатирәләремнең ошбу сәхифәләре өчен бер нәрсә уртак: аларның һәр каюсында явызлык, соң дәрәҗәдә вәхшилек ярылып ята.

Без конвой башларының, сакчы солдатларның йөз-кыяфәтләрен мең кат ятлап бетерсәк тә, аларның кем икәнлеген бер чакта да белеп җиткерә алмыйбыз. Кызыксыну да юк, тырышсаң да, ни белмәк кирәк? «Сез илнең иң явыз дошманнары — фашистларны саклыйсыз... Сез, комсомоллар, ил таянычы!» — дип көн-төн кабатлап, Урта Азия кышлакларыннан җыелган, урысча сүгенүдән бүтәнне белмәгән (ни хикмәттер, Рәсәй милли кадрлары әүвәл башлап өлкән туганыбыз телендә бик шәпләп сүгенергә өйрәнәләр!), дөнья күрмәгән, тар карашлы таш маңгайларга, автомат, пулемет тоттырганнар да өерләп куып, Казакъстан далаларына китереп тутырганнар. Кеше сагына басуга адәм балалары җәһәт үзгәрә, җан-кан теләү тойгысы, мәгарәләрдә ятканда адәм улларына сеңгән иң түбән тойгылар уяна. Кулга утлы корал кереп, аңнарына өстенлек тойгысы да кушылып киткәч, кышлак малайлары еркыч җанварларга әйләнгәннәр. Лагерьда өч-дүрт мең тоткын исәпләнә икән, аларны мең кешелек явызлар төркеме — офицерлар, солдатлар саклый. Конвой солдатлары — өрергә, тешләргә, чәйнәкләп өзәргә өйрәтелгән этләргә тиң. Алар берәм-берәм чакта тоткынnарга якынаерга, сүз катарга базмыйлар, куркалармы, белмим. Бездән түгел, үз ишләреннән, якташларыннан сагаялар алар. Шулай хезмәт итә-итә аларның төс-кыяфәтләре үзгәрә, алмашына. Һәркаюсының чыраена усаллык, явызлык бәреп чыга.

Бит-маңгайны гына түгел, муенын, кыска буынлы юантык беләкләрен кус, тыгыз сипкел баскан көяз, калкан-калкан күкрәкле, багана

аяклы сержантны без «җиз бүкән» дип атап йөртә идек. Кычкырып әйткән, ишеттергән юк, болай үзара гына шулай атыйбыз. «Җир астында җиз бүкән», дигән табышмак бар татарда. Бу сержант кишер генә түгел, ачы торма, зәһәр суган, күздән яшь куа торган сарымсак та. Пушкин язган «Анчар» агачы сыман дөньяның бар зәһәрен үзенә туплаган агулы бәндә иде. Аның тук кыяфәтеннән, аяк табаннары белән лап-лап пичәт сугып, җирне изеп-таптап атлавыннан, корычтан коелган иңбашларын уйнатып, туп-туры баруыннан гайрәт, явыз көч бөркелеп тора иде. Ул төкеренергә ярата иде, ләкин бер чакта да җиргә төкерми, кысылган нечкә иреннәре артына яшереп төкерек-ядрәсен әвәләп әзерли дә безнең якка очыртып җибәрә. Оста ата кабәхәт, тидерми калганы юк. Куныч-лары җем-җем ялтырап торган хром итегенең табанына ябышкан үзле балчыкны кырып интекми, туп-туры сафлар өстенә, тоткыннарга карап селки. Аның сүз кушуын гына түгел, бәләкәй генә хәрәкәтен дә өйрәнгән явыз этләр шундук алагаемга безнең өскә ташланалар. Ул ярык, калын тавыш белән уставта каралмаган зәһәр сүзләр белән безне коендыра. «Әй, сез! Бетле фашистлар! Аңгыра сарыклар! Бандера көчекләре!» Сүз-лек составы — төпсез кое аның, инде беткәндер дисең, юк, иртәгә ул тагын да зәһәррәк каргана-сүгенә.

Ул өч көнгә бер конвой башы була. «Җиз бүкән» безне эш зонасына озатканда ике ара өч тапкырга озынрак тоела. Без зонадан чыгып, аның карамагына күчүгә, бер йодрыктай йомарланабыз. Сак бул, бер якка янтая, бер сөям дә иптәшләреңнән артта кала күрмә! Конвой башының кем икәнен белгән солдатлар күз алдында үзгәрә, чүл бүреләренә әйләнә. Аннан да, моннан да кышлак маңкалары — аның шәкертләренең ул барында гына ертылган авызларыннан: «Фашистлар!.. сарыклар!.. бетле дуңгызлар!» — дигән каһәрләүләр өзлексез яңгырый. Сипкелле юл буе тынмый, армый, тамагы карлыкмый, ул дүрт-биш йөз кешене берьюлы күрә ала, «җиз бүкән»нең күру сәләте дала ерткычларыныкыннан ким түгел. Ул тоткыннарның төп-төз, чак кына да янтаймыйча атлавын таләп итә. Язгы пычракларда, көзге куе яңгырларда юл балчыгы тоташ лайга, сазламыкка әверелгән бер вакытта ничек төз бара аласың?! Тик син күлләвекләрне, пычтырдап торган чокыр-чакырларны урап үтә алмый-сың инде. Туп-туры атла! Колонна алдында баручы бишлек — иң хәтәр урын! Алар җирдән күзләрен алмыйча туп-туры, төп-төз атларга тиеш-ләр! Әз генә тайпылдыңмы — беттең! Сипкелленең усал командасы биш йөз кешенең тынын бүлеп яңгырый: «Ложись! Ике яктан сагаеп атлаган үзбәк-таҗиклар шундук җанланалар, күзгә күренмәгән чыбыктан электр тогы суккан сыман сикерешәләр һәм дәррәү җиргә егылган тоткыннар боламыгы өстеннән зәһәр шөпшәләр булып пулялар очарга тотына. Карлы, шакшы су куеннарга тула, бот араларына үрмәли, ботинкалар-ның тишек-тошыгын эзләп таба. Ятарга урын сайлап мыштырдасаң аяк очыңа сержант үзе килеп җитә! Ялагай солдатлар аның артыннан таш-ланалар һәм кунитек үкчәләре белән сине изәләр. Гәүдәң болганчык салкын суда күренмәслек хәлгә килгәнче таптыйлар сине. Сипкелле ымы-на буйсынып, дүрт-биш солдат карабиннарын берәүгә сакка тапшыралар да безнең тирәгә ыргылып килеп җитәләр, конвой башының ачуын чыгарган затны колоннадан сөйрәп чыгарырга маташалар. Бер метр, юк, ярты метрга гына колоннадан аерылсаң — дөнья белән бәхилләш, син бәхетсезне шартлатып атып үтерәчәкләр. Тоткыннар боткасы өстеннән дулкын чабып үтә, җиргә ятканда төрле рәвешкә кергән тоткыннар җәһәт бер-берсенә тартылалар. Куркыныч яный! Беләкләр беләккә йозак-лана, беләккә буе җитмәгәннәр, аяклары белән ялгана, җайлаша, без тын гына усалланабыз. Тын усаллыкның буйсынмас көч икәнен без инде үзләштердек. Кымызны бүксә кап булганчы чөмергән, җылкы итен һәр әбәдтә күсәмәсе белән лыкынган казакъ-кыргыз егетләре, чуендай кара төрекмәннәр үз телләрендә бер-берсен куәтләп, үкчәләрен җиргә терәп безнең арадан кемне булса да суырып чыгарырга тырышалар. Аларга

кыргый көч өстәп, нәгърә орып, бит очындагы сипкелләре караләҗым-күк төскә кергән конвой башы басып тора. Солдатларга да җинеллек юк, таеп егылсалар, конвой башы аларны якаларыннан сөйрәп, муеннарын буып тартып торгыза. Ул берөзлексез тәмәкесен пыскыта, тибә, төкеренә, кайчагында тоткынның өстенә пес итүдән дә чирканмый...

Хәтердә! Эссе җәй иде. Кояш таңнан ук ярсып чыкты, әллә без арыкларны каклап киптерергә теләде инде?.. Бүген безне сипкелле «Җиз бүкән» кабул итеп алды. Аның аракы пары китеп бетмәгән бугазыннан Шаляпин тавышы белән: «Шаг направо, шаг налево — конвой стреляет без предупреждения!» — дигән догасын укуы булды, сафлар уртасыннан берәү: «Ага, отец дыякон!» — дип әйтеп салмасынмы?.. Сипкелләне җен алыштырды, болай да убыр иде, хәзер җиде башлы аждаһага әйләнде. Читтәрәк торган пулеметчылар якынрак тартылды, алар конвой башының сүз көчен расларга гәяр булып, сержантның ике ягына бастылар. Сержант, тамагын ярып: «Кем кычкырды?» — дип сорады. Без тоташтан җиргә сеңдек. Конвой башы тагын: «Кайсыгыз авыз ачты?» — дип акырды. Без сипкелленең холкын нык өйрәнгәнгә күрә, аның сөяленә басмаска тырыша идек. Арадан берәү, әйтик бүгенге кебек, янарак килгән тоткын коерыгын кыймшатырга маташса, ысылдап тиз үк аны тыябыз. Конвой башын җинә торган түгел, уен сүзе дә, ялгыш карап та, каты тавыш та аның җенен читлектән чыгара. Аның белән сүзгә килү безгә һәрчак көтелмәгән кыенлыклар китерә. Әле ярый завод сменалы эшли, сипкелле безне кан баскан күзләренең комсыз шартлары белән утка тотып, зәһәр кояш астында көне буе тотар иде!

Ниһаять, кузгалырга команды булды, киттек. Куа конвой, йөгертә, чаптыра! Бер җир буе китәбез микән, туктатып җиргә яткыра, типкәли, төкеренә, этләрне котыртып ырлата. Арабызда алтмыш-җитмешне яшәгән олкәннәр, чаллар бар. Мәскәүле Ной Борисович Окунь тыжылдап җирдән калкына алмый җәфаланганда эстонлы Ансонс белән латыш Скуя картны култыклап алдылар. Безнең сүзсез бердәмлек конвой башының акылына сыймый, ул ярсып, иреннәрен чәйнәп, кемнең дә булса берәүне — кычкырган кешене күрсәтүен көтә. Һич югында конвой башын сүз белән мәсхәрәләгән бәндә үзе калкынырга тиеш ләбаса! Ул да дәшми.

Безнең ята-тора, ава-түнә кыштыр-кыштыр чабышып килгәнне тамаша иткән, кызлар колоннасын алып китеп барган солдатлар, кычкыра, акыра биреп, хатын-кызларны җәһәт-җәһәт кудылар. Без әле үрдән төшеп кенә килә идек. Инде капка ачылды, каравыл йортыннан завод утарын саклаучы отрядның начальнигы чыкты. Шул чакны, очлы иякле берәү, казакъ булдымы, таҗикмы, карабинын күкрәгенә терәде дә безгә төбәп атып та җибәрде. Уң кул ягымда басып торган шанхайлы урыс егете Юра Кириллов сәер генә янтайды, бераз чайкалып та торды. Миннән өченчеме-дүртенчеме торган немец егылды. Ярый әле Юра аю табанлы түгел икән, пуля аның табан асты уемы астыннан үтеп чыккан, ботинкасын ике урыннан тишкән... Пуля җиргә бәрелеп рикошет ясаган да өскә очкан, немецның ияк астыннан кереп баш түбәсенең капкачын ачып ташлаган иде. Ых та итә алмады бичара. Кан, чәчрәгән ми күреп сафлар икегә аерылды, мәет уртада ятып калды. Сафларның аерылуын күреп, солдатлар шатыр-шотыр атарга тотындылар. Ул арада каравыл йортыннан офицерлар килеп чыкты. Баягы солдат кулыннан карабинны йолкып алып, аны тиз-тиз күздән югалттылар. Уртада мәет, безнең иптәшебез, без икегә бүленеп, һушсыз диярлек басып торабыз. Таралу, каушау, сүзсезлек күпме дәвам иткәндер, без аңга килеп тиз-тиз бергә кушылдык. Мәетне тыгыз сафлар чолгады. Ераккарак басканнар хәлне аңлагач, авыздан колакларга шомлы хәбәр барып кергәч, барыбыз берьюлы телгә килдек. Тавыш купты, көчәйде, янгырады, инде бу тавышларны бер түгел, ун җиз бүкән дә баса торган түгел иде. Офицерларның өлкәнрәге, майор идеме икән, кыюсыз гына атлап, безгә якынрак килде

һәм түбәнчелекле йомшак тавыш белән тынычланырга өндәде. Аптыраштa калдык: вафат булган иптәшне калдырып китәргәме?.. «Качарга җыенганда атылды»,— дип ялган хөкем чыгарып, хәлне йомарламасланмы? Калып нишли алабыз?

Көн аяусыз кызды, тамак яна, көч безнең якта түгел. Безне санап та тормыйча капкадан үткәрделәр. Үз урыннарыбызга таралдык, берәү дә эшкә керешмәде. Бер кавым шулай, җаннарыбызны йомарлап, аптырашып арлы-бирле сугылдык та вахта капкасы тирәсенә тартылдык.

Үрдәге мәет моннан ап-ачык күренеп тора, аның өстенә иске одеал япканнар, кан исенә тирә-юньнән эре-эре яшькелт чебеннәр җыелган иде. Мастерлар, цех башлыклары безне эшкә тотынырга өндәп карадылар, үгетләделәр, «үлгән артыннан үлеп булмый!» дигән кебегрәк сүзләр әйттеләр. Акырып-бакырып, дөньяга сыймас хәрәкәтләр ясап, Ревякин килеп җитте, иске паровоздай пуф-пуф мышлады, безнең бүгенге бердәмлекне, ныклыкны күреп, аның кызарган кикриге тиз шәңкәйде. Ул арада машиналарга төялеп өстәмә көчләр, взвод-взвод солдатлар килеп төште, алар бик күпне кырган эшем ияләре төсле кыланып, капка алдына, анда-санда кагаеп басып торган вышка асларына таралдылар. Вышкаларга пулеметлар менде.

Тик безне берәү дә җиңә алмады. Отбой чүкечләре, транспортерлар, пресслар ял итте. Кирпеч алырга килгән йөзләрчә машиналар буш шалтырап кире борылдылар, алар бездәге хәлне, түкми-чәчми бүтән зоналарга җиткерделәр. Бераздан шахта базында да, йортлар салу кварталында да эш тукталганын, Актас лагере тоткыннарының бердәм забастовка игълан итүләрен белдек.

Смена тәмамланганчы зонадан чыкмадык. Капка төбенә эленгән рельс кисәгенә куллары сөялләнгәнче каксалар да, беркем дә ул чакыруга буйсынмады.

Нәкъ вакыты җиткәч кенә без ишегалдында ук сафларга бастык, нык-нык басып капканы чыктык, иптәшебез һәлак булган урынны үткәндә баш киемнәребезне салып, аңа соңгы сәламебезне тапшырдык. Без үргә менеп җиткәнче хатын-кызларны еракта ук бөяп тоттылар.

Ике катлы тыгыз боҗра эчендә кайтсак та күңелләребез шактый күтәренке иде. Янасалар, куркытсалар да, без эшкә тотынмадык. Бу минем үз гомеремдә беренче забастовкам иде.

Конвой белән мөнәсәбәтләрнең төрле чаклары булды! Аларның да ялынган мизгелләре очрый! Хәтта аларны кызганганны күрергә дә туры килде. О, Казакъстанның җәйге вә кышкы бураннары! Истә, алар да истә!.. Караганда тирәләрендә урман түгел, ялгыз үскән агачларны да күрмәссең. Безнең зона урнашкан төбәктә тәбәнәк сыртлардан, түгәрәк түбәтәйләрдән, сузынкы үрләрдән гайре, телгә алырлык таулар да юк. Әчәнечкеле тимерчыбык киртәләрне, күләгәләре энә юанлыгы гына төшә торган вышкаларны җил бар дип тә белми. Дала күкрәгенә сырышкан тәбәнәк караганник куакларын җил җиргә тидереп бөгә, йолыккалый, талый. Юлыма аркылы төшеп тормагыз әле, янәсе...

Иртәнчәк алдавыч һава тын тора, караганник яфракларында чык җемелди. Без барасы юл аркылы кошлар очып үтә. Кичен каядыр кереп поскан дала исләре күңелне рәхәт кытыклый. Мондый иртәләрдә заводның буш яткан кишәрлекләрендә шампиньон үсеп чыга. Керәшен ягында яшәп балачактан гөмбә җыярга йөргән, гөмбәнең тозлаганын да, куырганын да бик яратып ашап үскән егет булсам да, кеше кулы үстергән ят гөмбәне моңарчы белми идем. Шампиньон ашарга мине Берлиннан килгән немец Һейнц Бем өйрәтте.

Табигать монда явыз! Әллә мондагы иярләнмәгән җилләрне большевиклар тотып-тукмап дәү-дәү читлекләргә куып кертканнәр инде? Әллә шул ябылудан котылып чыгып, алар яшь тайлардай дала өстендә котырыналармы?.. Көндезге икеләрдә анда-монда ком учаклары кабына. Бер урында ятырга яратмаган ком кисәкләре төтәп, бөтерелеп, нәни,

сөйкемле өермә ясап торалар да учаклар ишәя. Әче җил ком буранына кузгалырга кушып яман сызгыра, ары-бире бәргәләнеп бер урында бөтерелеп күккә аша да китә зилзилә! Бер юнәлешкә калган җил-давыл тыелгысыз үкерә, чиный, баш миен бораулап җәһәннәм авазлары чыгара. Башлана пәри туе! Котырына шайтан биюләре. Кара күк белән соры җир тоташа. Җил батыр, юлында ни очраса, шуны иярттеп чаба, оча, дала иңләп, йомарланып коры бүре уты — дүңгәләкләр тәгәри. Чаба-чаба алар бер-берсен эзләп табалар, кочаклашалар, йомарланалар, чүмәлә дәүмәлеге булалар. Ярый әле, ходага шөкер, кибән хәтле үк җыела алмыйлар, юлларында сакчы тимер чыбык киртәләр очрый. Дүңгәләк чүмәләләре шул киртәгә барып сыланалар да уфылдап ябышып калалар. Ни хикмәт, җил-давыл көндезге сәгать дүртләрдә сүрелә, кичке кими, тора-бара бөтенләй тына. Ачык җирләрдән ком таучыкларын кубарып алган җил чокыр-чакырларны тигезләп, юлдагы эзләрне күмеп бетергәч, тынычлана. Без эштән кайтышлый бу тамашага сирәк эләгәбез, алай да, хода күрсәтмәсен! Ком кермәгән тишек-тошыгың, ком кереп тулмаган кием-салымың юк.

Кышкы бураннар аерата аяусыз иде. Болай да сытык көн кинәт караңгылана. Тоташ стена булып кар ява, яумый — ишә, ишми — күк белән җил ялганып, каралҗым кара болытлар бөтен гәүдәләре белән җиргә төшеп яталар, тигез урыннарда тау өяләр. Бер кичтә, буран шулкадәр шашкан иде, безне бараклардан чыгармадылар, кичке ашка җибәрмәделәр, ишекләргә йозак элделәр. Җил-буран котырынып электр чыбыкларын өзде, без ач, арган хәлдә тома караңгыда борлыгып калдык. Сөйләшмәдек тә диярлек, җил баракларны бер урыннан куа да без шушы гарасат эчендә каядыр күчеп барган кораб хәлендә идек. Вакыт исәбе буталды, әллә көн, әллә төн!

Соңыннан ишетелде: солдатларны казармадан өерләп чыгарганнар, сакларны бермә-бер арттырганнар. Ышанасызмы, юкмы, бу төндә без конвой солдатларын чын күңелдән кызгандык. Аларның җил туенда, нидер күрергә тырышып төн ката керфек какмый, уяулык үрнәкләре күрсәтеп, постта торуын бәхетсезлек дими ни диясең?!

Якшәмбе иде. Бригадам эшкә китте. График буенча минем ялым, баракта калдым. Кичтән ашатмаганнар иде, иртән дә ач. Хуҗалык дворыннан ризык килмәгән, су юк, кар эретергә, ризык пешерергә электр тогы булмаган. Бригадам киткәнгә әллә ни вакыт үткәч кенә безне мәйданга — санарга алып чыктылар. Барак кизүләре, гарип-горабә-инвалидлар, зонада вак-төяк эш үтәүче филоннар кар көрәгәндәй итеп мәйданны әз-мәз әрчегәннәр. Җил тынган диярлек... Як-ягыма карасам, һай-һай, исем китте! Дүрт метрлы такта коймаларның очы да күренми, тимер чыбык киртәләр дә, кемнәндер качып көрткә чумганнар. Моңарчы биек-биек тоелган вышкалар тәбәнәк кенә булып калганнар, өстә корык-корык ютәлләп, солдатлар басып тора. Якында гына тракторлы, бульдозермы гөрли, поселок тирәсендә нидидер хәрәкәт барлыгы сизелә. Иртәнге барлауга лагерь начальнигы үзе — майор Калпочков килгән. Ияген күн пирчәткәсе белән уа-уа янындагы офицерларга җикеренә, нидер мыркылдый, сүгә. Дүрт мең кешене сыйдырырлык тигез мәйдан юк, надзирательләр бригадаларны анда-монда куалар, шау-шу.

Санау элек тиз үтә торган иде, һәр биргада үз урынын белә, бараклан йөгереп чыга да, кушылган сызыкка баса. Хәзер сызыклар югалган, юньләп йокы күрмәгән, иртә-кич ашамыйча аңгырайган токынннар, йокы чире эләктергән африкалылар сыман, чак-чак кыймылдыйлар. Калпочковның тавышы колакларны бораулый, эт-баш, сыер-аяк!

Бер санадылар. Башта уйга калдылар. Калпочковның чырае тагын да бозылды, ул кеше булудан туктап, явыз маймылга охшап калды. Инде баракларга керәбез дигәндә, надзирательләр ары-бире чабып баракларга кереп киттеләр, тиз-тиз әйләнеп чыктылар да ишекләргә йозаклар элепде. Ике санадылар. Эш бетте, керәбез дип һәркем үз барагына таба юл алды.

Тагын команда яңгырады, безне кары чистартылмаган почмакка көрт өстенә тупладылар. Калпочков күм-күк иреннәрен чак кыймылдатып, үзе санарга тотынды. Математикасы юк майорның, саташа, бутый, бригада үтеп китте дигәндә аны кире кайтаралар. Калпочков санаганнан соң тоткыннарны тагын ике кеше, дүрт күз аша уздыралар әле. Өченче санау үткәч ачыкланды: зонада ике тоткын җитми икән!..

Әле болары муен гына булган икән, тиздән уен башланды!.. Хәзер печән кибәне эченә яшерелгән инәне табарга калды!.. Дүрт мең арасыннан кемнәр качкан!.. Хәзер һәр бригада кешеләрен, номерларына карап, формулярын укып, кемнең кемлегенә ышанырга, инә күзеннән үткәрергә кирәк иде. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, җил көчәеп китте. Ә без тубыктан, тездән яңа яуган кар ястыкларына батып-чумып, суык туплауда бөялгән килеш басып торабыз. Хәвеф-хәтәрнең ни дәрәҗәгә барып җиткәнен хәзер сукырлар да күрде, саңгыраулар да аңлады. Зарлану, ың-шың, сукрану тавышлары яңгырады, көрт-койма өсләреннән үтеп, зона дип аталган кар диңгезенә өстәмә солдатлар керде. Була бит гайрәтле кешеләр, Калпочковның төсе качкан табак битенә карап: «Башта ашатыгыз, аннары санарсыз!» — дип кычкырдылар. Кем кычкыра диген әле... Абдулла Али казы, аның якын дусты Сергей Курский. (Бу кош борынлы, торна сыйраклы, һәрвакыт кара күзлек киеп күзен качырып йөрүче, юка, елгыр урысның чын исеме Дима иде, фамилиясен ишеткәнем булмады. Лагерь кушаматы исемдә! Әле без аның белән 1954 елның сентябрендә Чиләбе төрмәсендә очрашырбыз!) Калпочков ашатамы соң! Хәзер аның бер нәрсәне беләсе килә: кемнәр качкан? Чыннан да, качканмы?.. Абдулла белән Диманың таләбен ишеткәннәр ишетте, ишетмәгәннәр — юк. Дау күтәрелде. Яланөс, җиңелчә чыккан тоткыннарны тыяр хәл юк иде. Беткән баш беткән, болай да бетәбез!.. Ниһаять, хлеборезкадан икмәк яркаларын китерделәр, бригадирлар күзәтеп торды, ярсыган ач халыкка тиз-тиз ипи өләштеләр. Салкын арыш ипиеннән каз ите тәме килгәнен мин шунда аңладым. Ипи туңган, коры, тамактан үтми, тешләп аласың да кар йотасың...

Кем качканын аңлатып тормадылар, безне көнозын куып, куалап йөрттеләр, баракларга кайтып кергәндә берәү дә аяк өстендә тора алмады. Тагын кара төн җитте. Шакраеп каткан аякларыбызны җылыта алмыйча вагонкаларны селкетеп, бар тавышка зарланып, кара буранны, кара язмышны төрле телләрдә сүгеп ятабыз...

Качып китүчеләрен әйт син, юньләп урысча белмәгән ике немец, бер әзерлексез, ризыксыз, акчасыз, номер тегелгән киемнәрен дә алышмыйча зонадан чыгып киткәннәр икән. Качыр өчен түгел, әҗәлләрен табарга ашкынып чыгып тайганнармы? Кая барсыннар, бичаралар, анда да, монда да зоналар, сакчылар, кара буран, юллар юк, әз генә китеп бер зонага барып төртелгәннәр тегеләр. Җил уңаена барганнар, бары шул... Бездән конвой барып качакларны алып кайткан, икесенең дә кулына Сталин беләзекләре кигерткәннәр, бияләйләрен тартып алганнар. Суык тимер богаулар кыскан беләкләр кыймылдый алмаган, юл авыр, карлы, солдатлар йокысыз төн үткәреп чамасыз явызланган, немецларның аналарын өшкергәннәр. Кайткач та аларны сап-салкын карцерга япканнар. Исән калганнар калуын, икесенең дә кул чуклары өшегән, зәңгәрләнеп шешеп беткән. Ике немецның дүрт кулын да кисеп, шунда, зона артындагы исемсез зиратка илтеп күмгәннәр...

Буран Казакъстан чикләренә бер керсә, тиз генә ташлап китә алмый. Аңа монда рәхәт, киңлек, дула туйганчы, котырын!.. Ә безгә бәла! Буран, көн саен котырынмаса да, атнага бер дулап ала иде. Җир астыннан, карьердан, балчык патшалыгыннан ак бураннар арасына барып кергәч, күз күрми тора. Күзлекне тотып кына атлыйм. Бар курыкканым күзлек, ул ватылса яки югалса, ничек яшәрмен?! Читлектән булса да көн яктысын, төн карасын күрәсе килә әле! Ходам сакласын!

Буранда без завод капкасыннан бер-беребезгә тотынып чыгабыз, бер-беребезне ышыкларга, сакларга тырышып, бата-чума атлыйбыз. Ба-

рабыз, атлыйбыз,— без — күбәү. Ни булса да юлны табарга тырышабыз. Йөз кат үткән юл. Күзне йомып та үтәрлек юл. Тик буран алга карап барырга рөхсәт бирми, ул читкә кага, адаштыра, буташтыра. Конвой солдатларының хәле мөшкел. Алар берәм-берәм, куелган араны саклап кына атларга тиеш. Ялгыз-ялгыз солдатларны җил ияртеп алып китә, алар туктап тора алмыйлар, егыла-торалар, алар инде безне күрми, арада ак дивар. Зона утлары әле шәйләнми, завод утларын да каранrылык бик тиз йота.

Шул дилбегәсез, йөгәнсез җилкән гәүдәле үзбәкләрне, карсак кыргызларны бөтереп ала да безнең сафларга китереп бәрә! Ярты юлга җиткәнче солдатлар тоткыннар белән аралашалар, алар, тартып алмасыннар, дип, карабиннарына ике куллап ябышалар. Ни хикмәт, явыз этләр дә тына, кар аларның йон араларына тулып ак төскә мана, алар да авыр коерыкларын селкергә тырышып, ышыкка, тоткыннар арасына сыеналар һәм әкрен генә шыңшыйлар. Кыргыз-таҗик малайлары шулчак телгә киләләр дә инде! Алар туңган авызларын чак кыймылдатып, күз яшьләрен түгеп кешечә сөйләшергә маташалар: «Дяденки... зинһар, качмагыз! Берегез качса да безне үтерәчәкләр, әти-әниләрне атачаклар! Кача күрмәгез, яме?» Хәзер конвой безне түгел, без конвой солдатларын саклыйбыз, егылсалар күтәреп торгызабыз, көпшәләренә кар тулган мылтыкларын алып бирәбез. Малайлыклары чыгып бетмәгән, коммунистлар партиясе нәфрәт агуы гына сеңдергән, бу бозык, кешелекләрен җуйган кара солдатларга кемлегебезне аңлатып бирә алмасак та, без бүген — хәтәр юлда ярдәмебез, аларга булышырга әзер торуыбыз белән өстенлегебезне, күңелебез киңлеген раслыйбыз. Бүтәннәргә ярдәм итә алу мөмкинлеге явызларны да тәрбияли, ярдәмчелек хисеннән дә олырак хис бу дөньяда юк.

Буран басылып, көннәр ачылгач, юлда берәү дә качмагач, конвой өч-дүрт көн безне тын гына озата, акырмый-бакырмый, этләр дә шымаеп кала, алар үткер кайчы колакларын гына уйнаталар, әллә рәхмәт укыйлар, әллә яныйлар. Совет власте, Маркс-Ленин бозган адәм балаларын һәм явыз этләрне аңлап бетереп буламыни, анда тотрыклы, ышанычлы һава була алмый, бүген болай, иртәгә тегеләй.

## 12

*И бәрәңге! Син, бәрәңге! Кил, бәрәңге, җан ашым.*

Габдулла ТУКАЙ

Лагерьга бер вагон бәрәңге килгән дә, шуны бушатырга кеше җыялар икән. Куштан Кемсә артыннан ук надзиратель бастырып килеп җитте, ашыктыра башлады. «Тизрәк! Тизрәк!» Карышып тора алмыйсың, аннан тартып, моннан йолкып ун кеше җыйдылар да өч кешелек конвой карамагына тапшырып, безне чыгарып җибәрделәр. Ятим вагон япан кырда, жиде җил уртасында тора икән. Тимер юлның күгәреп беткән рельслары монда кадәр шуышып килгән дә өзелгән. Тупик. Машина әрҗәсен вагон ишегенә якынрак китергәндә ару буласы иде дә, булмады — рельсларга терәп диярлек шактый биек итеп ташлы балчык өелгән иде. Яңгырда җебеп, җилләрдә нығып балчык бетонга әйләнгән, кәйлә-көрәк алмаганбыз, көчсез үкчәләр белән тибептибеп карадык, балчык-дошман селкенми дә! Мин вольняшка шоферга: «Көрәк алып кил! Казып юл ачарбыз. Җиңелрәк бушатылыр!» — дигән идем, конвой башы итеп билгеләнгән ысланган чырайлы, кыска аяклы сержант: «Җиңелрәк ярамый! Рөхсәт ителми!» — дип, урысчаны ватыпҗимереп тәкъдимемне кире какты. Үзем дә җүләр, «тизрәк булыр!» диясем калган. Хәер, тоткын сүзен конвойның хуплаганы бармыни?!

Эшне болай көйләдек: берәүләр вагонга кереп чиләкләрне тотырып тора, икенчеләр йөгерә-йөгерә ташый, ике кеше өстә әрҗәдә бәрәңгене кабул итә. Тутырабыз, йөгерәбез, аударабыз. Тын алырга да вакыт юк. Шуның өстенә, өч ноктага баскан солдатлар: «Тизрәк! Җәтрәк! Ух, сезне, фашистлар!» — дип өзлексез каулап торалар.

Башлаган эш — беткән эш! Тигезле-тигезсез кыр юлыннан машинабыз әче төтен бөрки-бөрки китеп барды, без, кара тиргә батып, мышнап вагон эченә кереп тулдык. Аллакай гынам, әле мондагы бәрәңге!.. Ничә машина булырын да шәйләрлек түгел! Вагон эче ышык, җылымса, бәрәңге исе белән тыгызланган дымлы һаваны сулап, көшел өстенә таралып утырдык. Кай якларда, кайсы басуларда үскән бәрәңге икән? Тышта җил ныгыды, вагон тәгәрмәчләрен кузгатырга теләпме, сызгыра-сызгыра астан үтеп йөри. Эх, шушы бәрәңгеле вагонда утырып сәфәр чыгып китәсе иде. Барасың, туктыйсың. Учак ягып кайнар көлдә бәрәңге пешерәсең!..

Тир катарга да өлгермәде, үзара киңәшкән солдатлар безне вагоннан өреп төшерделәр. Ишек ачыгыннан күренеп торырлык итеп, чыбык очы белән «зона» билгеләделәр... Ә догасы бер!.. Хәзер алар эчтә, ышыкта, алар тук. Без ач, без җилдә бөкшәеп «зона»дан бер арыш та читкә китмәскә тырышып, яргыч алашалары сыман бер урында әйләнәбез. Дымлы җилкәләрне җил ялый, калтырата, үзәккә төшә. Зарыгып борылабыз, юк кына бит машинабыз, дөмекте! Конвой солдатларын карабиннарын тезләренә куеп, ышыкта тәмләп-тәмләп махра көйрәтәләр. Безнең тәмәке дә юк. Солдатларның берсе җиргә сикереп төште дә, мине, Леонтий Гаврилович Цурканны ияртеп, тимер юл буйлап каядыр алып китте. Цуркан белән без Свердловск төрмәсеннән бирле бергә. Песи борынын җыерып, «прх-х!» итеп көлеп җибәрә торган бу молдаван карышусыз, урысча кыенсынып кына сөйләшүче, ипле юлдаш иде. Алдан мин барам, Цуркан артымнан килә, карабинын безгә төбәгән солдат җикеренә-җикеренә безнең эзгә басып чаба. Ят яклар, таба төбе төсле теп-тигез, төссез тонык дала. Үләннәр кибеп-корыган, ком-таш арасына түшәлгән. Тып-тын. Ник бер аваз ишетелсен, ник бер-бер кош-корт күренсен. Мәрхәмәтсез, җансыз офыклар! Атлый торгач, без тимер юл тирәсендә нидер эшләп маташкан ике карамчыкны шәйләдек. Шпал алыштыралар икән тегеләр, тик яткан шпаллар да муртаеп, баш-башлары череп карала икән. Бер читтәрәк сумала исе таратып өр-яңа дүрт шпал ята. Солдат карабинын селтәп, яман кычкырып, тегеләргә читкә китеп торырга боерды. Безгә тавышын әкеренәйтеп, яңа шпалларның берсен алырга кушты. Тегеләр, ирекле адәмнәрне әйтәм, әлерәк кенә зонадан чыгып җаннары урынына утырмаган байгышлар булдымы, әүвәл солдатны күреп шүрләделәр, без шпалның баш-башына барып ябышкач, эшне аңлап, кыюландылар. «Кая аласыз аны? Дәүләт милке! Без җаваплы! Бирмибез!» — дип алмаш-тилмәш кычкырырга тотындылар. Бер мәлгә югалып калган солдат, кулында карабин барын искәреп, тегеләргә яман үкерергә тотынды. «Назад! Юкса атам!» Солдат мондый этлекне беренче мәртәбә генә күрмәгән, ахрысы, ияге белән шпалны күрсәтеп, безгә җикеренде: «Алыгыз, чучкалар!» Тимерьюлчылар ялынырга тотынды: «Хет искесен алырсыз, хәзер суырып чыгарабыз без аны!» — дип, җәһәт-җәһәт дәү, дүрт кырлы күгәргән кадакны суырырга керештеләр. «Юк! — дип акырды солдат. — Күтәргә вакыт юк! Солдат көтми!» Күтәргән яңа шпалны җиргә төшереп, бер эшчеләргә, бер солдатка текәләбез. Солдат, тимерьюлчыларның берсенең авызына сугып канатты, икенчесенә карабин түтәсе белән кизәнде. «Мин сезне!.. Таныйм мин! Комендатурага чакырып бер айга утырттырам!.. Баланда сагындыгызмы, хөрәсәннәр?!» Канлы ирен, борынын сеңгерә-сеңгерә, җылапҗыламсырап нидер әйтергә маташа, икенчесе тегенең калтыранган ике иңен кочып читкәрәк тарта. «Әхмәт, Әхмәт, китеп торыйк... Чәнчелсен шпалы!» Үз колакларыма ышанмыйча канлы иренгә бер-бер сүз кушарга

ниятләгәндә генә солдат Цурканны да, мине дә төрткәли башлады. «Ятрәк, фашист калдыклары!» Кулга ябышкан сумаланы тешләп җиргә тәкерә-тәкерә тыр-тыр йөгердек, әй.

Без кайтканда каһәр суккан машина һаман килмәгән, иптәшләрне тик тотмаганнар, алар тирә-яктан коры курай, караганник сыныклары җыештырып көчле генә учак тергезгәннәр. Шпалны дөрләп яткан ут өстенә китереп салдык. Ул бераз чатырдап, сасы ис таратуына куанып ятты, ятты да күңелле генә кабынып китте. Түгәрәкләнеп учак җылысы тошүгә, солдатлар безне вагонга өерләп керттеләр дә учак тирәли чүгәләделәр. Күмер-көл төшә башлауга учак төбен казып, бер чиләк бәрәңге күмдек. Бәрәңгеләрнең чубыргалы кабыклыларын, күзәнәкләре сай шомаларын, дәүрәкләрен сайлап алдык. И куанабыз, и сөенешәбез, көлдә пешкән бәрәңгене ашамаган кеше юк, урыс та ярата аны, украиннар да ашый, хәтта эләксә японнар да ялт иттереп куя! Ул арада кайдадыр «сулда» үз йомышы белән йөргән шофер килеп җитте.

Төяп озаткач, солдатлар безне вагон-куначага кертеп утырттылар. Ары-бире көткән арада учактан татлы ис — пар күтәрелә башлады, солдатлар карабиннарын бер читкә куеп, чүгәләп, кабыклары ярылып-ярылып киткән, кызарган бәрәңгеләрне күмер-көл астыннан тәгәрәтеп чыгардылар. Бәрәңге нәни таучык булды! Әй ашыйлар солдатлар, әй умыралар, әй кинәнәләр! Кырда пешкән бәрәңгедән дә тәмле нәрсә бар микән дөньяда?! Төсе дисеңме, исен әйтәсеңме, шоннык! Ашыйлар солдатлар, уралар, ачлар дөньясыннан килгәннәр диярсең. Без җил кискән яшьле күзләребезне мөлдерәтеп, иреннәрне ялап, селәгәйләрне йота-йота солдатлар авызына туктаусыз йөгереп кереп торган оҗмах нигъмәтенә карап торабыз. «Карамагыз,— дип җикеренә безне бурлыкка иярттеп барган җәллад.— Карап тормагыз!» Үзләре түгел, авызлары ояла бугай.

Әле кызышып, әле чамасыз туңып караңгы төшкәнче бәрәңге төядек. Кузгалды җил, дала җиле бәйдән ычкынды, тәмам суытты, кар бөртекләре өерелеп килә дә күзгә сылана, томалый. Күзлегемне әле генә арулыйм, җил явыз тагын сукырайта. Иптәшләрнең усалланып пышылдавын ишетеп, учак тирәсенә карасам... конвой ишәкләре калган түгәрәк бәрәңгеләрне туп итеп тибеп уйныйлар. Әй, кешниләр тук солдатлар, әй, хихылдыйлар!

Наум Песин берчакны шулай эчем катканчы көлдергән иде. Иртүк күзен ертып янымга килгән дә: «Син иртән гимнастика ясыйсыңмы?» — дип чеәеп тора. «Ә син?» — дип кире кайтардым. «Ясамыйм шул... һич тотынып булмый шуңа!» — дип китеп тә барды теге. Монда әле... гимнастикасыз да сөякләр камыр булган, янбашлары сызлый, аяк балтырлары шешенгән... Кемдер исемемне атап эндәшкәнгә уянып киттем. Текәлеберәк карасам, янымда Цуркан, молдован басып тора. «Пленда булдым. Франциягә барып җитә яздым. Европада мин сыярлык ярык, мин качарлык тишек калмаган иде. Җир шары, диләр. Шунда мин сыярлык бер почмак калмасын инде! Ходайның каргышы төште безнең буын кешеләренә. Хәзер монда... Әле срокның өч елы да үтеп бетмәгән. Алда башланмаган чирек гасыр! Шуңа тагын ике бишлек өстәлгән. Туганнан бирле икмәкне туя ашаганым юк... Инде, Столяров юраганнар юш килеп, иреккә чыксаң да, барыбер җаныңа хуҗа була алмыйсың икән. Кичәгене әйтәм, тимерьюлчылар, мәлҗерәп төште бичаралар. Шоферны ничек тукмадылар!.. Бөтереп кенә алалар ысланганнар! (Цуркан: «копченыйлар» диде)...

Һәм шунда ул җылап җибәрде. Мин торып утырдым, Цурканны үз янәшәмә утырттым. Тәне яна иде бичараның. «Чирлисеңме? Суык тиледме?» — дип сорадым. «Юк ла»,— диде ул башын чайкап.— Мин бит күпне күргән, тирем кат-кат иләнгән, каешланып каткан. Җәрәхәтсез, ярасыз бер квадрат сантиметр тирем юк минем. Инде әз-мәз исән калган җанылма да тукыналар... «Төрмә, зона» дибез. Зарланабыз. Безнең агай-энегә иректә дә сан юк, калмаган аңа сан!.. Нигә иреккә ашкынырга? Мин

батыр кеше түгел. Һәр туры килгән эт тешләп узачак. Һәр очраган явыз сугып авызны канатачак. Әле монда зонада түзәсең. Ә анда?! Егерме биш ел көтеп алган иректә дә һәрдаим мыскыл итсәләр!..»

Кичә, шпал күтәреп, көч-хәл белән тын алып кайтканда: «Сиңа авыр түгелме? Син бит эшләп үсмәгәнсең, укыгансың. Синең гәүдәң эшкә яралмаган. Түз инде, түз. Авыррак башын тотар идем, шпалның ике башы да тигез шул!» — дип ярым пышылдап, үзеннән бигрәк мине жәлләп кайткан Цурканмы бу?..

Иртәнге аш вакытында зона гөр килде. Тигез, сабыр холыклы, бер мәртәбә дә сүгенмәгән, берәүгә дә авыр сүз әйтмәгән, беркемгә кыенлык китермәгән әүлия Цуркан, молдован иле кешесе, беренчеләрдән булып баракттан чыккан да, нәкъ барак каршысындагы вышка турысында, чәнечкеле чыбык өстенә ташланган. Бер генә атмаганнар аңа, бер ядрә генә ала алмаган егетне, кыска җиңле френчын тишкәләп бетергәннәр. Кулы исә ике челтәр арасында буар җылан булып бөгәрләнеп яткан Бруно спиралена үк барып җиткән, гәүдәсен үлем кочагыннан кубарып ала алмыйча интектеләр...

Кичә булып үткәннәрне яшьле күз алдымнан үткәрә-үткәрә көне буе кара сөрем-болыт эчендә яшәдем... Цуркан һәлакәтеннән соң озак та үтмәде, шахтада тагын бер хәл булып алды, ямансу, сыек томанлы көннәрнең берсендә, эш зонасыннан бер тоткын, Харьков кешесе качарга тырышып карады. Шахтаның бөтен почмакларын актаралар — юк, килеп-киткән машина эзләреннән баралар, сораштыралар, чокчыналар, Караганда тирәләренә ут төртәләр — юк теге, суга төшкәндәй гаип булган. Ни әйтсәң, дә адәм баласы энә түгел — югала икән, эзе калырга, эзе беленергә тиеш! Уйлашалар, Мәскәү кадәр Мәскәүдән тикшерүчеләр өере килеп төшә, тирә-яктан белгечләрне чакырталар, көн эзлиләр, төн эзлиләр, төн киңәшәләр һәм ныклы фикергә киләләр: тоткын зонадан чыгып китмәгән булырга тиеш!

Шахта мәйданын квадратларга бүләләр һәм солдатларны унар-унарлап бүлеп, шул дүрткелләргә беркетәләр. Борының белән җир казы, тырнакларың купсын, чокы, иснә, тырма, иллә мәгәр тап!.. Очлы тимерләр тоткан солдатлар бер карыш җирне дә, җир асты чокырларын, фундамент базларын калдырмыйлар, мәшһүр этләрне китертеп йөртеп чыгаралар. Юк качкын. Тоткан бәхетлегә зур-зур бүләкләр вәгъдә итәләр! Тапкан солдатка — айлык ял! Акча! Көн үтә, икенче көн... Ике көн казынган, шашып-шашып эзләнгән солдатларга ышаныч бетә, аларны чыгаралар да, икенче, бүтән зонадан солдатлар китерәләр. Инде алар яңа күз, яңа көч белән үзләренә ышанып тапшырылган кишәрлекләрне жентекләп тикшерәләр. Партия утырышлары җыйнала, комсомолларны үгетлиләр, әмма большевиклар партиясенең олы бурычы, кичектергесез «заданиесе» һаман үтәлми. Солдатларны солдатлар алыштыра, офицерларны офицерлар, этләрне этләр, очлы тимерләр генә шулар ук, алар кулда кала. Юк качкын, юк. Атна эчендә шахта зонасы аша мең ярым солдат уза, таба алмаган өчен башлыклары аларны эт итә, унардан бер кешене гауптвахтага ябалар, отпускаларыннан мәхрүм итәләр. Аяусызланган явыз солдатлар анда җимерәләр, монда ваталар, тегендә каералар. Шахта төзелешләре ярым хәрабәгә әйләнә!..

Атна үткәч, вышкалардагы сак солдатларын җиргә төшерәләр, һичкемгә күренмәскә, шым торырга катгый кисәтәләр. Вышкаларның бушаганын ничек шәйләгәндер, җаны бераз тынычланган качкын, посып яткан җиреннән чыгып, иңенә тәрәзә рамы күтәреп (янәсе, урлап чыгып бара!) вахта ишегенә килә. Һәм шунда, йөзләгән кешенең йокысын качырган, меңнәрнең тынычлыгын алган тоткынны коры кул белән тотып алалар.

Табышмак бик гади чишелә: ике катлы склад бинасы салганда, арадан берәүнең качарга нияте барлыгын белгәч, түбә кыегы фронтонында иркен генә куыш ясап калдыралар. Озак кына буш тора куыш, сәгате суккач теге адәм әзерләнә, ризык, су ташый. Әз-мәз иске-москы кием

юнәтә, тегесен-монысын. Ашыкмыйча, җиренә җиткереп әзерләнә! Качар сәгатен бирәүгә дә сиздерми, хода-тәгаләгә ялварып, куышка керә дә чума бер көнне!..

Кичен тотып алганнар тегене, без эшкә барырга чыкканда... качакны богаулап, сугымны лапас өрлегенә күтәргән кебек, өскә тарттырып бәйләгәннәр, аяк очлары җиргә тияр-тимәс тора! Нык кыйнаганнар, күз-каш җимерелгән, яңаклар кутырлап каткан, күзләр йомык... Элек күргәнем булдымы икән, белгәннәр танымадылар. Нык, таза егет икән, ыңгырашмый, аһылдамый, керфекләре генә уйнап-уйнап, адәм улының ниләр кичергәнен сөйли иде...

Эштән кайтканда ул шул хәлдә асылынып тора иде, керфекләре селкенми, гәүдәсендә җаны барлыгын белү дә үтә кыен иде. Бер тәүлек асып тотканнан соң аны күздән югалттылар, кыйнап үтергәннәр икән дигән шомлы хәбәр йөрде.

Харьков егете үлде дә котылды, безнең көнкүреш тагын да әшәкеләнде. Шундый күрсәтмә булдымы, конвой башлыклары башы-күзе тонган котырган эткә әйләнделәр, авызлары иске чабата хәтле ачыла, тавышлары иләмсез көрәйде, һәр әйткән сүзләренә «анаңны да атаңны!» өстәлде. Барган-кайтканда хәзер һәркемнең коты чыгып, каны калтырый, куалар, чаптыралар яткыралар. Эштән кайткач, озак-озак капканы ачмыйча торалар, җил күзендә сәгатьләр дәвамында тинтерәтәләр. Бөтен кешегә тоташ ютәл төште, муен тамырларына, касыкларга йодрык-йодрык зәңгәрсу шешләр — чуаннар бәреп чыкты. Ай буена мунча якмыйча тора, бетләдек, корчаңгы таралды. Юлда бик күпләр арык күкрәкләрен ач бармаклары белән кыса-кыса буылып ютәлләләр, төнката бараклар корык-корык... Андагы хәлләрне адәм аңларлык итеп сөйләп бирер өчен сүз дә җитмәс, валлаһи. Ул көннәрдә вафат булганнарның санын берәр кәгазьдә беркетеп калдырдыларммы икән? Белмим...

Көндәлек вак-төякләр, бары тик безнең өчен генә әһәмиятле булган ыгы-зыгылар. Дөнья хәлләре, ил язмышы хакында зонадан-зонага күчеп йөргән имеш-мимешләр, шушы вак-төякләрне оныттырып, төн йокыларыбызны качыралар иде. Кореяда һаман сугыш бара, кореяларның үзара түгел, алар җирендә Рәсәй белән Америка сугышып ятканын бөтен кеше аңлый, сугышның азагын күз алдына китереп уфылдап куя. Өченче бөтендөнья сугышы нәкъ шуннан башланыр, дип һәммәбез бер тында ышанып һәм куркып яшибез. Себердә, көнчыгышта, Иркутск-Тайшет тирәләрендә безнеке сыман особый лагерьлар булдымы икән, ул җәһәттән хәбәрем юк, иллә-мәгәр илле икенче ел дәвамында сәяси тоткыннарны Караганда тирәләренә, Җизказган, Кингир, Балхаш лагерьларына, Тимертау, Чурубай нура, Карабас, Сарань зоналарына ил төбәкләреннән җыйнау дәвам итте. Актастан алып китәләр, каратөндә китереп тутыралар, җәзачылар кабалана, нидер сайлыйлар, нидер астыртын әзерлиләр. Җәзачылардан яхшылык көтмәгән безнең халык нык пошаманда, тәмам аптырашта. Майор Столяров һаман сүзен бирми: «Хәл аруланачак, безнең язмыш яхшыга борылачак!» — дип тәкрарлый, ләкин аның юраулары Минск төрмәсеннән килеп ирешкәндә югары дәрәҗәдә йөрсә дә, хәзер безнекеләр аңа бик үк ышанып та бетмиләр. Хак инде, күзгә күренеп йөри башласа, пәйгамбәр сүзләренең дә кадере кими.

Газиз укучым! Ниһаять, шактый озын, урау юллар үтеп, дөреслек эзли-эзли байтак юл-сукмаклар таптап, адашып та, айнып та яшәешемә, аң үсешемә, иманыма шактый зур йогынты ясаган тагын бер олы зат алдында тезләнеп рәхмәтемне укыйм. Болай озак, урап-урап килүемнең сәбәпләре бар. Әгәр мин төрмәләрдә алган сабакларымның ничек башлануын, кая таба дәвам итүен якын иптәшләрем язмышыннан башка гына чишәргә керешсәм, мөгаен, теләгемә ирешә алмас идем. Фикри кардәшләрем, затлы чордашларым, кадерле юлдашларым булмаса, мөгаен гына, сүнеп-сүрелеп, кайгыларга баш биреп ватылып калыр идем. Әз булдымыни андыйлар?

Кешелекнең мең-миллион еллар дәвамында сайлап алынган, тупланган, какшамас асыл сыйфатларын бозык елларда да, канлы юлларда да җуймаган, яшәү чаткысы сүнмәгән олы затлар — фикер узаманнары белән очраштырды мине Тәңрем! Рәхмәтлемен! Унар, унбишәр ел дәвамында кеше итеп саналмаган, эт типкесендә яшәгән, большевизмның агулы һавасында тын юлларын әрчер көч тапкан адәмнәрнең матурлыгы алдында әле да баш иям. Йа, Тәңрем! Бар бөек җаннар, бар! Берәүләре күңел күзәнәкләремдә, юмарт бал кортлары кебек, татлы сагыш-моң калдырса, икенчеләре сөенә-сөенә акыл, тәҗрибә, гыйбрәтләр аша дәрт бирде. Миңа, ындыр артыннан, Олы су дип аталган талгын инештән, тыкрыклардан, тәбәнәк-юаш таулардан ары әллә ни күрмәгән, алган белеме чамалырак булган (онытмыйк: сугыш елларында укыдым мин!), егеткә акылны, тормыш нигезләре фәнен — фәлсәфәне уч тутырып алар миңа бирде. Алар, һичшиксез, һич шикләнүсез минем остазларым, мөхтәрәм укытучыларым иде. Үкенечкә манчыйм каләмемне: мин һәрчак, һәр гамәлемдә, һәр сулышымда алар сеңдергән бөек тәгълиматка — хөр, саф яшәү кануннарына тугры калып, батыр йөрәкле булып яши алмадым. Советның астыртын өндәмәләре, явыз чынбарлыгы сеңдергән курку-өркүләрдән тәмамысы арынып, тәнне каплаган күгәрекләрдән чистарып бетә алмадым. Алай да мин зоналарда дуслашкан өлкән иптәшләремнең якты сүзләрен, җылы карашларын онытмадым. Әллә кайчан алар әйткән тормыш тәҗрибәсе үрнәкләре, алар авызыннан чыккан хак, кыю сүзләр елдан-ел ачыклана, ныгый барды. Никадәр зирәк, алдан күрүче булган алар! Мин — аларның тугры шәкерте. Бу әсәрем шуның бер мисалы түгелмени?!

Җанга якын татар әдәбиятында, үземне Фатих Әмирхан, Әмирхан Еникиләрнең дә шәкерте санап, бу әсәрем белән үземнең мәсләгемне, максатымны, кемлегемне әйтеп бирүем белән бергә, бу язмаларым фикердәшләремә бер һәйкәл булсын дип тә эшкә тотындым.

Илаһым! Теләгемнең якты, уйларымның изгелеген син күреп торасың! Адашам икән — юлымны турыла, нидер оныткканмын икән — хәтеремне яңарт! Минем алтмыш биш яшьлек чал икәнлегемне онытма, арган-талган, өметсезләнгән сырхау мизгелләремдә көч-дәрман өстә, ярабби!

Исемнәре телгә алынган байтак кешеләр догага лаек, әгәр шул бөек бурычны үти алсам, мөхтәрәм укучым, шул изге догамны түкми-чәчми сиңа да ирештерсәм, тәңрем каршысындагы иң олуг бурычымны үтәдем дип санармын.

Акыл иялəреннән булган дусларымның берничәсен санап үттем инде мин. Зинһар, кыска вакыт эчендә, мине, алла колын, зәһәр, шаулы тормыш диңгезендә йөзәргә өйрәткән грузин Александр Хуродзены онытмасагыз иде. Әнә ул, язу өстәлем башында, өемнең түрендә елмаеп басып тора. Күзәтә. Хак булырга өнди!

Миңа егерме өч яшь. Бу яшьтә күңел акыл дымы күтеп, зиһеннең баюын зарыгып, һәр ишеткән яңалыкны чумырып кына ала. Күңелнең төпсез бушлыгына челтерәп аккан нәни чишмәләр коя, җәһәт агымлы, сөзәк ярлы инешләр кушыла, килеп-килеп тоташа, диңгез-океан дулкыннары китереп бәрә! Хуродзе, Дзидра, Леналар күңелемнең тирән буразналар белән чуарланган уңдырышлы кырларына ләйсән яңгыр булып явып, керендереп китсәләр, Актас зонасында акылымның бөтен катламнарына төшеп җитә алган, уй тамырларымны киң дөньяга, дөньяви фикерләр байлыгына ялгаган шәхесләр дә бар. Шуларның берсе, иң олпаты, мөгаен, Ростислав Иванович Илечко булгандыр. Кем иде ул? Кай тарафлардан, кайсы юлларның хикмәтен үзенә урый-урый бу сагышлы дала якларына тап булган? Белми калдым, белмәдем. Кирәкме сиңа горур төс-кыяфәт, кирәкме сиңа пыялалар артыннан төбәп карап торган, һәр караган саен сабырлык, тынычлык, олылык нурлары чәчкән сөрмәле матур күзләр. Сабан туендагы көрәш мәйданыдай киң, килешле маңгай.

Аяк атлаулары нәкъ мәгърур арысланныкы. Кирәкмәскә беркем ашыктыра алмый аны, адым саннарын боза алмый. Тып-тын бара, ә күңел әллә ниләр ишетә: бу кеше барыр юлын тапкан, ул беркайчан, бөтен дөнья давыллары-җилләре куып житсә дә, ташлар явып жир ярыклар белән капланса да, сайлаган сукмагыннан тайпылмаячак. Чак кына алгарак бәреп торган нык ияге, бер-береннән ычкынырга теләмәгән кысынкы иреннәре аның шактый кырыслыгын да кисәтеп торалар! Барыннан да бигрәк аның маңгае килешле иде. Сократ маңгае димим, рух бөркелеп торган маңгайны ходай бер Сократка гына бирмәгән, чак кына бүлтәеп торган биек бу маңгайга табигать үз хәзинәсендә ни бар, шуны жәлләмичә тутырган иде. Гажәп, славян икәнен беләм, мәгәр милләтен дә, кайсы ил кешесе икәнен дә әзеп кенә әйтә алмыйм. Төрмә камерасына нинди хәтәр җилләр китереп ташлаганы аңлашыла: Илечко коммунистлар идеяләренең әзерлекле, төрле тәгълиматлар, мең дәлилләр, күзәтүләр, чыгармалар белән коралланган көчле дошманы иде. Хуродзе — үзенчә дошман, аны үз төбәгенең, үз милләтенең язмыш хәлләре аңга китергән, мисаллары да күбесенчә җирле шартлардан туган. Козлов-Куманскийның офык киңрәк — ул Мәскәү, Ленинград, Рәсәйнең мәркәзгә якын өлкәләре белән эш итә!.. Бандеровчылар, литвиннар, латышлар да күбесенчә идән асты дәлилләренә таяналар. Репатриантларның да офык бераз чикләнгән, алар теге илләрдә дә сеңеп, берегеп бетмәгәннәр, Совет иленең «серләрен» дә аңламаганнар, югыйсә кайтырлар идеме алар шушы җәһәннәмгә?! Әллә ишеттермәгәннәрме аларга сансыз-исәпсез дөнья хәлләрен?!

Илечко исә бүтән, аны махсус әзерлекле, үзенә генә багышланган калыпта койганнар. Ул Будапешт университетын мадьяр телендә укып бетергән, Прагада чех телендә докторлык диссертациясе яклаган. Ул Европа илләрен аркылыга-буйга гизгән, белем эстәгән, һәр тарафтан яңалык тапкан, өзлексез укыган. Берлин, Лондон фәнни китапханә хадимнәре ул кергәндә баш иеп, бил бөгеп каршылаганнар. Чөнки ул кызыксынган фәннәр, ул укыган китаплар Илечконы һич икеләнүсез хөрмәт итәргә кушканнар. Ул егермедән артык телдә иркен сөйләшә, укый, яза. Зонада бер авыз урысча белмәгән мадьярлар аңа тартыла, үзара низаг чыкканда немец офицерлары шым гына аның катына киләләр, румыннар аны эзли, поляклар да аның ярдәм сүзенә мохтаж... Әле зонада большевизм тузаны коелып бетмәгән, бүтән тәгълиматларны белмәгәнгә һаман шуңа таянып ятучы, Ленин ярдәмендә акыллы булып күренергә тырышучы кабак башлар да бар. Бәхәс чыгып эләгешеп китсәләр, алар да Илечко катына килә. Кул астында китап-мазар булмаса да, ул нәкъ кирәкле фикерләрне күңел диңгезеннән эзләп табып, моназарачыларны ипкә китерә.

Иректән хатлар килә. Хатлар йөк-йөк моң-зар, бәхетсезлек, кимлек мисалларын китерә. Берәүне фатирыннан куганнар. Киңәш кирәк, киңәш! «Кемгә сугылсам да, сөйләшеп тә тормыйлар, куркалар!» — дип язалар Иван Лапаевка. Илечко, бөтен тукталыш нокталарын билгели-билгели, Лапаевка эшне ачыклап бирә. Ул — юрист. Үзбәк баласының олы кызы чирләп егылган. «Больницаларга алмыйлар, дарулармыйлар», — дип үкси аның хатыны. Илечко — врач, ул йорт тирәсендәге даруларны ничек-ничек кулланырга икәнен вәзенләп язып бирә. Ике туган, агайне яшәп яталар. Өченче туганнары монда, зонада. Йорт низагы чыккан, ага энене төрмәгә тыккан. Нишләргә? Илечко — адвокат, кодексның бөтен маддәләренә таянып, гариза язарга булыша. Металл коючылар да ярата аны, поварлар да үз итә, ул — ветеринар, гинеколог, очучы, диңгезче. Аның җәгърафиядән белгәннәре, тарихның әллә кайда аста калган катламнарында иркен сулыш алып йөрүе безне таңга калдыра.

Әйткәнемчә, зонада барыбыз да югары мәктәп бетергән, университетлар чарлаган адәмнәр түгел. Безнең буын күп-күп җәһәттән томаназирәк калды. Бездән алдагы буыннар да совет чынбарлыгы чүкеп әзер-

ләгән камыр тешле, туң башлы томаналар. Әйткәнемчә, адәм баласы үзе күнеккән мохиттән аерылып, гадәттән тыш шартларда яшәргә мәҗбүр ителгәндә үз-үзен аңларга тырышып карый. Бу җәһәттән ошбу табышмакка ачкыч — дин. Моңарчы Хода ярдәменә әллә ни мохтаҗлык сизмәгән дәһриләр дә кинәт үзгәрәләр, уйларын кай якка төбәргә аптырап, төрле якларга ташланалар. Кеше — чынлап торып үз-үзен аңларга теләсә, аңа бары тик дин генә ярдәмгә килә ала!.. Чөнки без барыбыз да Гайсә, Мөхәммәт пәйгамбәрләрдән соң берөзлексез дини чакырулар дулкынында яшәгәнбез. Менә мин, динсез диярлек гаиләдә үсеп, керәшен авылында Коръән яңгырашларын бик сирәк ишетеп яшәсәм дә, хәзерендә, кайдадыр моңлы мәкам белән Коръән укый башласалар, тәнемә каз тиресе чыга. Сүзләренең тирән мәгънәләре килеп җитмәсә дә, Коръәннең тынычлыкка, сабырлыкка, татулыкка өндәп яңгыраган сихри аятьләре шунда ук, беренче аһәңнәрдән үк аңымны кузгата, мин тынам, җанымны бер ноктага җыеп, Аллага табынам. Илечко моның табигый серен дә миңа аңлатырга тырышты. «Гарәп телендә риторика үтә көчле, ул кеше психикасына турыдан-туры тәэсир итә, бу телдә иң югары дәрәҗәдә яңгырашлар мул, һәм алар адәм улларының бөтен хисләренә тәэсир итми калмыйлар». Мин моның дөреслеген соңрак укыган байтак китапларда күрдем. Мәшһүр гарәп тарихчысы Ф. Хитти: «Гарәп теле дәрәҗәсендә, шул телдә сөйләшүчеләргә тәэсир итәрлек, аларның җаннарын хәрәкәткә китерерлек бүтән бер тел бар микән? Әгәр бүген Каһирә, Багдад, Димәшкъ мәчетләрендә Коръән сүрәләре яңгыраса, шигъри юлларны интуитивно гына аңлаган адәмнәрдә бөек дәрәҗәдә хискә бирелә-ләр, телнең ритм, рифмалары, телнең музыкасы җанга хуҗа булып ала»,— дип язды. Хак сүзләр!

Тел музыкасын, Коръән сүзләренең яңгырашын гипнозга тиңлиләр. Коръән аятьләре адәм улларын йә кузгаталар, йә тынычландыралар. Берәү дә битараф кала алмый.

«Коръәнне әзерлексез, белер-белмәс кабул итү җиңел түгел. Мөхәммәт пәйгамбәр Коръәнне халыкка җиткергәндә гарәпләр динсез булган, потка табынганнар. Пәйгамбәрнең тәүге инануларын дошманлык белән тыңлаганнар. Мөхәммәт гомере буе шулар белән бәхәсләшкән, Алланың барлыгына вә берлегенә ышандырырга тырышкан. Без хәзерге заманда Мөхәммәт сүзләренең бөеклеген аңлатып та бетерә алмабыз. Чөнки без аңа каршы чыккан, аны дошманнарча кабул иткән адәмнәрнең дәлилләрен, фикерләрен белеп бетермибез. Коръән, Тәүратларда кешелекнең киләчәге яшерелгән. Кешелек әнә шул китапларга яшерелгән серләрне гомере буе ачарга тырышып яшәячәк. Кайбер дини кануннарның гадилеге сокландыра! Ламаизмны гына алыйк. Ул диндарлардан дини тәгълимат беркетелгән китапларны ятлауны таләп тә итми. Кангуирның йөз дә сигез томын ятлап алу монахлар шөгыле! Диндар, аллага табынучы кемсә бер җөмләне белсә, шул җитеп ашкан. Лхаса шәһәрендәге күп санлы җиз барабаннарның берсен әйләндереп, «Ом манипадме хум!» ягъни: «Лотос чәчәгеннән яралганга баш иям!» — дип кабатласаң, син — оҗмахлы».

Минем дә үземнең төшеп калганнардан түгел икәнлегемне кыстырасым килә, тотлыгып-ашыгып: «Ислам динендә дә» лә иләһә илла-Лаһ, Мөхәммәдән рәсүллүһү» дигән кыска гына дога да мәсләгеңне ача, кемлегеңне раслый!» — дип әйтеп куям.

Илечко көлемсерәп, башын чайкый: «Әгәр үз халкыңның тарихи юлын ачарга теләсәң, иң беренче нәүбәттә гарәп телен өйрәнергә, халкыңның аерылгысыз өлеше булган Коръәнне гизеп чыгарга кирәк»,— дип кабатлый.

Хәзер, шушы юлларны язып утырганда мин имгәтелгән гарип балачагыма кайтам. Бишенче сыйныфта укыганда календарьда гарәп алфавиты күреп, ятлап, кара тактага сөенә-сөенә исемемне язып куйган идем. Класс җитәкчесе күреп алды да, йә хода, агарынып, куркып,

колагымнан сөйрәп укытучылар бүлмәсенә алып кереп китте. «Нигә сиңа комган хәрефләре? Урыс теле җитмиме син наданга!» — дип сүкте. Илечко безнең телләр белмәвебезгә нык гаҗәпләнә иде. «Ярый, Рәсәй гражданнарын чит илләргә чыгармасыннар да ди. Нигә сез чыгу тыелганда чит телләрне өйрәнмисез? Тел — шул ук ил ләбаса, тел өйрәнеп сез аерым бер илгә, аның тарихына, аның мәдәни хәзинәләренә үтеп керәсез ич!»

Шул кыен шартларда, ачлы-туклы яшәгәндә, иртәгәге көнең шомлы кәфен белән капланганда Ростислав Иванович бер чакта да күңел нык-лыгын югалтмады. Зыялы бер литвин белән аралашып, аңа инглиз телен өйрәтте, үзе литва телен үзләштерде. Яратып һәм бирелеп, япон телен өйрәнергә тотынды. Ходаның һәр бирмеш көнендә, карлымы ул, яңгырлымы, барыбер, японча биш иероглиф ятлап алып, хисләрен тимер сандыкка бикләгән Саттаров Тогучины да шаккатырды. «О!» — диде Квантун офицеры урта бармагын күккә терәп.

Телләр җәһәтеннән Илечко тиңдәшсез талант иде. «Өч-дүрт телне өйрәнү әкрен бара, аннан ары телләр үзләре сиңа киләләр», — дия иде ул. Соңра, Сталин үлеп, безнең яшәү шартлары тиз-тиз үзгәрә башлагач, энем Алмаз Казаннан татарча газитләр бәйләме җибәрде. Һәм һич уйламаганда Илечко татар телен өйрәнергә тотынды. Мин — аның укытучысы. Укыту алымым да үтә гади: бер-ике җөмләне татарча укыйм да сүзен-сүзгә урысчага тәрҗемә итәм. Ул тыңлый, тавышсыз гына татар сүзләрен кабатлый, алга таба тагын укыта. Укыйм, аңлатам, тәрҗемә кылам, тагын укыйм, өченче, дүртенче көннәрдә профессор Илечко: «Әһә, сезнең телдә шундый-шундый кануннар бар икән!» — дип миңа татар теле кагыйдәләрен өйрәтә башлый! Могҗиза! Тел өйрәтәм дип, телсез калдым. Дөрес, мин элегрәк тә инглиз теленә тартыла идем, ләкин миндә Илечкога хас ныклык та, үҗәтлек тә, киләчәккә ышанып карау да юк иде!

Илечко — бүтән шартларда тәрбия, белем алган башка бакча гөле. «Дөнья катлаулы, яшәү авыр!» — дип кабатларга яратабыз без. Асылда, тарихта җиңел еллар, җиңел дәверләр булганмы? Юк, булмаган. Булмас та. Бер нәрсәне аерып әйтеп үтәргә кирәк: тарихның авыр елларында ил башында явыз диктаторлар утырган. Алар эш йөрткәндә ил тынмаган, дәвамлы сугышлар башланган, диктатор ил байлыгын талаган, исраф иткән. Һәм бу башбаштаклыкны ефәк пәрдәләргә төрү зарур булган. Илленче елларда «Тынычлык өчен көрәш!» — дигән ялган әләм күтәреп нихәр кыландырмадылар! Конгресслар уза, съездлар җыела, әй мактанышка кызыл авызлар! Ә Кореяда сугыш кызганнан-кыза. «Урысның шовинист элитасы бер чакта да сугышсыз яшәми, сугыш аның төп яшәү формасы, милли иманы, — дия иде Илечко. — Аның канлы генералларының әле Европаны басып аласы бар. Аларның якындагы хыяллары — җылы океаннарга үтеп чыгу! Корея җирендә ике дөнья, ике төп идеология, ике төрле яшәү формасы көрәшә. Кореялылар чүп, алар монда җанлы курчаклар гына. Асылда сугыш АКШ белән СССР арасында бара. Урыс түрәләре чамалый, сугышырга, яулап алырга, кырырга дигәндә Сталин гомере буе тәҗрибә туплаган фюрер. Ул сугыш кызып китәрдән элек үзенең артын, тылын чистартып, әзерләп куйды. Гитлер белән алыш башлангач, миллионлаган урыс солдатларының Власов канаты астына сыенуын, милли легионнар төзелүен Сталин гафу итте яки онытты дип беләсеңме? Юк, бу юлы ул үткәндәге ялгышларны кабатламаска тырышачак. Шуның өчен ул акыл сабаннары тирән буразналар ясап сөрә торган акыллы студентларны, шул җөмләдән синс дә йомып алды. Чит ил тормышын тамаша кылган, аның уңай вә кире якларын үзләштергән, үлчәү тәлинкәләренең кайсысы аска тартканны күреп белгән репатриантларны төрмәгә тыкты. Утыз жиденче елларда җәзаланып та исән калган могҗиза вәкилләрен яңадан дөбердәтеп җыйды. Иң куркыныч саналган сәяси тоткыннарны кырык сигезенче елда аерым төбәккә тупларга кереш-

те. Караганда — тирән тыл... Корея сугышы кайчан башланды? Илленче елда. Әгәр хәл соң дәрәҗәдә чуалып китеп, Сталин сугыш ачып җибәрә икән, безне әһ дигәнче турап чыгачаклар. Алга барамы урыс гаскәре, чигенәме, бу юлы — барыбер. Бу хакта яшертен күрсәтмәләр һәр зонаның спецчастендә ята. Бел, срогыңның азагына барып җитә алмыйсың син. Илләрдә мондый киеренкелек озакка чыдамый, йә аннан, йә моннан тишелеп чыга. Табигатьнең законы шул. «Хороша власть советская, но долга!» — дия иде акыллы бер дустым. Шуңа күрә син хәзерендә, Циплитис киңәшен тотып, ташчы һөнәрен үзләштерү турында түгел, көне килеп җиткәндә ничек котылып калырга да, иптәшләреңне ничекләр аяп саклау хакында уйла».

Табигате сабыр, холкы тигез, башкаларга илтифатлы Ростислав Иванович коммунистлар режимының тамырын актарганда гына усаллана торган иде. О-о, андый чакта аның гәүдәсе — үткер ук, усал сөңге булып турая, күзлек пыялаларын эретеп, күз чокырларында дөрли-дөрли ике нәфрәт учагы яна, саллы борын очына кызыл тап кунаклый. Нәфрәткә манчылган, нәфрәт белән сугарылган бик күп фикерләре инде онытылган. Ләкин истә калганнары да әле җитәрлек. Хәзерендә, коммунистларның канлы сәясәте, дөньядагы ленинчыл көрәшләрне алып барган юмакай, аумакай илләрнең Совет иленнән кучкән акчаларга гына яшәп ятканлыгы бүген тәмам ачыкланганда, мин Илечконың никадәр зирәктапкыр булуына сокланам.

«Будапешт урамнарында еш күрә идем, кирпеч сыман кызарган юан-юан симез апалар: «Икмәк! Икмәк таләп итәбез!» — дип акырып-бакырып йөриләр иде. Совет акчасына симергән оятсыз коммунистлар! Беркайда эшләмичә, кәеф-сафа чигеп яшәделәр бит, валлаһи! Хәер, миллионнарны кулыннан үткәргән, илләрдән-илләргә йөреп, муллыкта яши алган Ленинның бер көрәк балчык алып салганы яки сабан тоткасына ябышканы бармы икән? Юктыр!.. Ул, әүвәл башлап, эшләмичә генә ашауның, тир түкмичә генә яшәүнең классик мисалын бүләк итеп калдырган шәхес... Ленин төзегән режимны күп еллар элек ачып салган бөек акыл ияләре булган. Салтыков-Щедринның «Бер шәһәрнең тарихы» әсәрен генә мисалга ал! Совет власте халыкларга китерәсе бөтен бәла-казаларны никадәр алдан ук күргән әдип! Әсәрдәге шәһәр хуҗаларының кыланмышларына гына кара, совет власте чорында ил белән идарә иткән, илне талаган, таркаткан җүләрлекләрнең һәммәсен «мәшһүр градоначальниклар»да табарга була! Гореф-гадәтләр, алар керткән кануннар, зуррак, тирәнрәк күләмдә совет илендә чагылыш тапмадымыни?... Күр инде, кем үз иле гражданнарын «рабсила» дип атап йөртә дә, үз иле кешеләренә «госстрах» тәкъдим итә!... Салтыков-Щедрин большевиклар дәүләтенең бәйрәмнәренә кадәр алдан күргән! Игътибар итегез әле: «Праздников два: один весною, немедленно после таяния снегов, называется «Праздником неуклонности» и служит приготовлением к предстоящим бедствиям: другой — осенью, называется «Праздником предержащих властей» и посвящается вспоминаниям о бедствиях, уже испытанных. От будней эти праздники отличаются только усиленным упражнением в маршировке». Ягез, туганнар! Уйлап багыгыз: Беренче Май һәм Октябрь бәйрәмнәре түгелме соң болар! Килешләре, китешләре белән нәкъ үзләре ләбаса! «Тынычлыкны яклыйбыз!» — дип Кызыл мәйданның чуер ташларын чыкырдатып, һавага дәһшәт вә сөрем исе таратып, мең төрле сугыш кораллары — ракеталар, танклар белән дөньяның котын алган бәйрәмнәрне хәтерлисезме!.. Алдан күрә алган Салтыков-Щедрин, әмма китаптагы чынлыкны миңа җиткерә алган Ростислав Иванович та зирәк адәм булган! Ихтимал, Илечко бу өзекне миңа төгәл үк тә әйтә алмагандыр, шулай да мин аны әсәремне язарга әзерлек чорында эзләп таптым.

Илечко алдынгы бай илләрдәге коммунистик партия әгъзаларын сүзе саен «сатлык җаннар, канлы режим ялчылары, тишек барабан-

нар»,— дип атады. «Чыгалар. Париж, Рим урамнарын сасытып, төрледән-төрле коткы таратып, советларча яшәү рәвешен күккә чөяләр. Күне килә, чит илләрдәге партия житәкчеләре хатыннарын, маңка малайларын алып СССРга баралар. ил хезмәт ияләре бер чакта да күрә алмаган вә күрмәс ял йортларында типтерәләр, азыналар, котыралар. Чит ил компартияләре совет акчасына яши, гәзит-журналлар совет акчасына тарала».

Белеп яшәгән Илечко, коммунистлар сәясәтенең кара эшләрен әллә кайчан аңлаган. Шуның өчен аны таш капчыкка тыгып, халыктан яшереп, капчык бавын чекистлар кулына тапшырганнармы?

Шаярта да белә иде Ростислав Иванович! Берзаман лагерьдагы тоткыннар арасында «социалистик ярыш» хәрәкәте җәелеп китте. Валлаһи, нәҗес ашамыйча дуңгыз яши алмый!.

Бригадалар җиң сызганып «ярышка чыкты», тоткыннар үзара тырышып-тырышып ярыша башладылар. Ярышта җиңүчеләрнең слетлары җыелды. «Ялкынлы речьләрне» күлә-күлә сөйләдек тә, күлә-күлә тыңладык. Берзаман Актас зонасына би-ик югарыдан, мәшһүр Мәскәү калаларыннан «социалистик ярышның ничек-ничек җәелүен» тикшерергә вә күзәтергә ишле комиссия килеп төшә. (Мөгаен, кызлар зонасы тартып китергәндер ул чүл бүреләрен!) Свитасын ияртеп, яшь кенә бер генерал безнең зонага да килеп керә. Тоткынның борыны сизгер, югары начальство күрендеме, ул читкә таярга, күздән югалырга тырыша. Илечко андый кеше түгел, аның начальствоны якыннан күрәсе килә. Генерал бара, күз-күз атлып, артыннан вак ташлар булып бүтәннәр шыбырдыйлар, коелалар. Генерал каршысына тып итеп Илечко килеп чыга. Генерал үзенең җил куып йөрмәвен бүтәннәр алдында күрсәтергә ашыкканмы, үгезне мөгезеннән эләктереп алган: «Менә син, фәлән номерлы тоткын, кем белән ярышка чыктың?» — дип сораган. Мин булсам, валлаһи, көтелмәгән сораудан егылып китәр идем. Ростислав Иванович күзен дә йоммаган: «Мин старший повар белән ярышам»,— дип җавап биргән. Инде генералга чират җиткән, аптырап калган җәллад! Аптыраса да: «Ә сез ничек оештырдыгыз ул ярышны?» — дип кызыксынган. Ростиславның теле-телгә йокмый: «Ярышабыз! Хәзер ярышмыйча мөмкин түгел! Ул симерә, мин ябыгам!» — дигән. Генералның чырае бозылган. Ростиславны биш тәүлеккә БУРга яптылар. «Барак усиленного режима» була аны́сы! Тапкыр җавабыннан куанган Илечко БУРга күлә-күлә кереп китте, күлә-күлә ялт итеп килеп тә чыкты. Зарланмады, сөенеч зур иде: «Генерал кадәр генералны төп башына утырттым»,— дип, байтак вакытларга кадәр сөйләштереп йөрде.

Чит илләрдәге тормыш шартларын, андагы яхшылыкларны кимчелекләре белән бергә бәйләп сөйләгәндә Илечко, мин — беркатлы кемсәне хак юлга төшерергә тырышу белән бергә, үзе кайчандыр яшәгән җәмгыятьне, аның бай күңелле хуҗаларын, илләрне, илләр бизәге булган эшчән, тырыш кешеләрне сагына торган иде. Ул бу җәһәттән өзеп ачылып бетмәсә дә, сүз сөрешеннән, тавышының кинәт моңсуланып китүеннән мин инде күпне аңлый ала идем. Мәһабәт гәүдәле, яшьлегендә штанга күтәргән, футбол кырларында йөгереп йөргән Илечкога төрмә баландасы ашап җан саклау ифрат кыен булса да, ул бер чакта да ризык эзләп түбәнгә төшмәде, горур булып калды. Сагыну соңгы чиккә җиткән мәлләрдә ул кинәт юашланып, моңаеп кала һәм үзенә генә хас тыныч, моңлы тавыш белән җырлап җибәрә, йә булмаса Европа шәһәрләрендәге театрлар, мәшһүр концерт заллары, оркестрлар хакында мавыгып, белеп, оныткылып сөйләп китә иде. Чит илләрдәге урыс әдипләрен белә, күбесе белән якыннан таныш, арада ул бик яраткан җырчылар да булган. Аның белән очрашканчы Александр Вертинский хакында ишеткәнем дә юк иде минем. Ул исә Вертинскийның бик күп җырларын белә, еш кына аның моңнарын көйләп китә иде.

Чайный домик точно бомбаньерка,
С полисадиком цветущих роз.

С палубы английской канонерки
Заглянул туда один матрос...

Бу җырны ул искиткеч ярата, мин дә тулысы белән ятлап алып, юк тавышым белән аңа кушылып китәм дә без дуэт булып, инглиз матросы харап иткән чибәр кызны җәлләп, чиксез моңая идек. Аның икенче бер, тирән сагыш, куе саф моң белән тулган җыруын өзек-өзек кенә хәтерлим, монда, ирекќә чыккач бер дә ишеткәнем, китап-журналларда очратканым булмады. Болай башлана ул җыр...

Ах, вчера! Умерла...
Моя невеста бедная!..
Моя кукла валетная,
В рваном трико.
Девятнадцать шутов
С куплетистами
Отпевали невесту мою...
Я не плачу, нет, не плачу —
Я тоже пою...

Ростислав Иванович белән шактый айлар янәшә яшәдек, мин аның бердәнбер дусты иде дип әйтә алмыйм, юк, алай булмады. Илечко Абдулла Али-казы белән дә, Сергей Курский белән дә дустанә мөнәсәбәтләрдә булып, авызлары авызда иде.

1990 елның җәендә Караганда шәһәренә бардым. Җирле КГБга кагылдым. Максатым өч кешенең: Ростислав Иванович Илечконың, Абдулла Али-казы һәм Александр Васильевич Мерзленковның «Төрмә дело»ларын димим, алары хөкем ителгән идарәләрендә кала, гади генә — «формуляр»ларын карау иде. Бирмәделәр түгел, сөйләшеп тә тормадылар. Инде кайтыр юлга чыккач кына Германиягә көлә-көлә китеп баручы купедашларым, бәхетле немецлар: «Долинка лагерена барып карарга иде! «Формуляр»ларны шунда җыймадылармы икән?» — дип күңелемне җирсеттеләр.

Илечко миңа еш кына: «Өйрән ныклап инглиз телен, чит тел кайчан исә бер ярап куя ул!» — дип ничәмә-ничә үгетләде... «Дөнья үзгәрәчәк!» — дип тә ышандырды.

Беләм, зирәк бабайлар: «Дөнья куласа, бер әйләнә бер баса!» — дигәннәр.

Кызганычка вә оятыма каршы, күңелемнең ныклыгы җитмәде, ялкау идемме, аңкау булдыммы, инглизчә дәреслекләр дә соратып алдым, күз чите белән генә укыштыргандай иттем, мәгәр, басылып, ныкышып, үҗәтләнеп, дәртне котыртып, күңел салып, «эшлим!» дип рухымны нығытып өйрәнә алмадым инглиз телен!.. Бездә, татарларда, бу җәһәттән дә йомшаклык бар, бар. Йә, күпмебез ничә тел белә?.. Шул-шул...

Берзаман Сталин үлде, безгә, сәяси тоткыннарга әз-мәз хезмәт хакы бирә башладылар. Зонада ларек ачтылар. Анда икмәк, манный ярмасы, сирәк кенә май-шикәр саталар. Ростислав Иванович дүрт көн эчендә уналты бөтен ипине бөкләп куйды... Нишлисең, чәй-шикәргә акчасы җитмәгәндер... «Балаларыңны чит телләргә өйрәт!» — диде ул. Мин аның бу васыятен үтәдем: улларымның өчесе дә инглиз, немец телләрен беләләр. Олы улым Искәндәр Италия, Германияләргә барып, немец телендә докладлар сөйләп, чит илнең галимнәрен Татарстан, татар белән таныштырып йөри. Ах, Илечко белән соңгы елларда аралашкан булсак!.. Аңа булган олы, онытылмас хөрмәтемне, мөгаен, күрә алыр иде!

## 13

*Ведь где-то есть простая жизнь и свет,—*
*Прозрачный, теплый и веселый...*

Анна АХМАТОВА

1989 елның 21 февралендә поездда Мәскәүдән Минск каласына китеп барам. Истлочь дигән урынга, иҗат йортына. Күңелдәшем, мәшһүр Василь Быков яклары. Бу якларга беренче чыгуым. Иртә яз ике иненә дә яңгырлар тояп килде. Казанда яуды, Мәскәүдә койды, күңел боек; әле өс-баш лычма чылана, әле аякка су үтә.

Кислоталы, дару-агулы яңгырларга аяк киемне теткәзер хәл юк! Поездны ашыктырасы, үшән тепловозга мичәүләп пар атлар тагасы иде! Чапсыннар иде мин әле аяк басмаган серле Көнбатышка!..

Юлда йөргәнем борчалы, әз генә онытылып киткән кебек булам да дерт итеп уянам. Купедагы юлдашларымнан чынлап торып көнләшәм: изрәп, рәхәт итеп, онытылып, ирен чәпелдәтеп, борын тишекләреннән җилләр уйнатып һәм бәгъзе бер тавышлар чыгарып, хуҗа булып мес-лиләр. Мендәрне кысып изә-изә, җәймәмне кырыкка бөгәрли-бөгәрли гәүдәмә җайлы, җан сыярлык урын эзләп тинтерәп яттым да сикереп торып утырдым. Йокы бикле купега сыймады, качты, билгесез бер көч мине коридорга чыгарды. Поезд туктап тора. Чыктым. Яп-якты буп-буш коридордан тышка карадым. Перронда да җан ияләре шәйләнми, күзем күтәрсәм, нәкъ каршымда, махсус мин күрсен өченме дәү-дәү, аршынлы хәрефләр белән «Смоленск» дигән язу элгәннәр. Мин, шыр надан, Минскига барышлый Смоленск аша үтәсемне уйламаганмын да! Уйларым, хатирәләрем авырайткан поезд мыштырдап кына кузгалды, китә алмый-ча озак кына калтырап торды, инде кузгалгач та минем хәсрәт тавына менә алмыйча шактый вакыт интекте шикелле. «Смоленск» дигән эре-эре хәрефләр ава-түнә, бер зураеп, бер бәләкәйләнеп күземә ияреп бардылар. Мин авыр хәрәкәт белән яшәгән төнге яңгырлы вокзалга, аның сүнәр-сүнмәс җемелдәгән утларына багып, әсәренеп торганда яңгыр ялкау гына пыскый иде, хәзер өр-яңа көч белән ява башлады. Коридор тәрәзәсенең тоныкны, күпне күргән тәрәзәсенә сызылып-сызылып иртә килгән язның күз яшьләре сыланды. Җыламадым да шикелле, күңел генә, үз тирәнлеген-нән, әллә кайлардан, соңгы елларда өсле-өсле өелгән хәлләрдән арынып китеп, төптән тере хатирәләрне казып чыгарып әкрен генә, моң гына, туктаусыз сыкрады. Әгәр поездда ялгыз калып, сине хәсрәтле уйлар күче сара икән, тиз генә котылырмын, арынырмын димә. Хәсрәтле уй үзе үк чалыш-молыш хәрәкәт ул, поезд барган шәпкә ике хәрәкәт бергә ук-машып, синең ихтыярыңны җимереп, сине тугылый, кабып йота. Андый мәлләрдә татарның фәлсәфәсе сеңгән гади җырларының берәвесе искә төшә:

Ургый-ургый сулар менә,
Пароход идәненә.
Ышанмагыз егетләрнең
Яратам дигәненә.

Юл җыры бу, кыз җыры. Нәни генә иске ситса төенчеген тотып, әле суынып өлгермәгән түше белән пароход култыксасына ятып, усал күбек-ләнеп, яман кайнап аккан болганчык Иделгә карап җырланган бәхетсез җыр булыр бу. Кыз авылдан, Зәйдән яки Сарманнан Казанга, авылда чакта сөешкән егете янына барган. Юк, бармаган, канатланып очкан кыз, әкияти тулпарны иярләп җилдергән, житез карлыгачка әверелеп, иң хәтәр очкычларны узып киткән!.. Сөю канатлары таккан кызларның очу тизлеген кем үлчәгән?.. Барган. Очрашканнар. Шуннан кайтып килеше.

Моннан ярты ел элек кенә, йөк-йөк вәгъдәләр калдырып киткән авылдашы, татарларның мәркәзенә барып урнашкан да кышлау умарта дәүмәлеге тәбәнәк бер марҗага йортка кергән!.. Марҗаның житеп килүче кызы да бар, имеш! «Мәркәздә калырмын»,— диебрәк барган саф, сылу, эшчән, уңган, чиста-пөхтә татар кызы Казаннан, хыялларыннан, мәхәббәтеннән Мәккә мөшриге сыман качып бара. Һәммәсе уалган, чәлпәрәмә килгән, ватылган. Кайгының дәвамы — жыр, сөенечнең дәвамы да — жыр. Дүрт юллык татар жырлары кайчагында том-том китаплар әйтеп бетерә алмаган хисләрне ярып сала.

Тукта, кая каерылып кереп киттең син? Сүз башың бит, әвәлгечә, Шүрәле!..

Смоленск, Смоленск!.. «Өч аршын жир» Мәскәүдә басылып чыккач, ул миңа кыска гына, әмма тулы фикерле, жылы хисләр белән баетылган дустанә хат язып салган иде. Вакытында ник жавап язмадым икән?! Әйе, «Өч аршын жир»дән соң мине әз-мәз чеметкәли торган чор башланды. Татар әдәбияты төссез вә төшсез масса булып аккан чорда бу әсәр кай ягы беләндер кайберәүләрнең кучәр башына кагылып китте, шуңа чыдамаганнар минем тарафка шактый тәнкыйть сүзләрен юнәлттеләр. Юк, кире кайтып аларга рәнжеп, үч угын атарга жыенмыйм, аллам сакласын, ялгыш кына кагылып киткән өчен дә тарихи романнар мәтәштергән берәүнең кырык чөе кырылды! Бер нәрсә үкенеч, вакытсыз яуган бәрәкәтсез яңгырдай өстемә ишелгән тәнкыйть сүзләреннән соң, мин икеләнеп тә калдым бугай! Каерылдым да тәнкыйть күрсәткән сукмакка чак кына кереп китмәдем. Югыйсә, «Зәй энжеләре» сыман тешсез, төче һәм уй-фикерсез әсәр язар идеммени?! Ә алар... алар!... тегеләр инде тегеләр! «Энжеләрнең керәч ватыклары икәнен белсәләр дә... мактадылар! «Аяз хак юлга төште, аны без төшердек!» — дип күкрәкләрен төйделәр. Һәм мин бәхетле булгандай кыланып, шул акыл ияләре, мүкләк кәжәләргә ияреп, юк сакалны селкетеп: «Әйе, әйе!» — дип баш кагып тордым бит, имансыз! Хәзер беләм, тәнкыйтьнең әдәбият эшенә бер чакта да бәрәкәтле йогынтысы була алмый, булмый. Әдәбиятка килүче яшьләр моны бик нык һәм бик озакка үзләштерергә тиеш. Языла икән, языла. Рөстәм Сүлти яза, Ркаил яза, аларның һәр язганы Ходай биргән талант югарылыгында калачак.

Смоленск, Смоленск!..

Бу шәһәрдә Актас лагеренда кавышкан, бергә булган, якын дустым, урыс егете Сергей Сергеевич Козлов-Куманский яшәргә тиеш. Лавочкин урамында... Әле мин аның вафаты хакында ишетеп өлгермәгән идем. Нигәдер төрмә дусларымның һәммәсе дә исәндер кебек тоела иде миңа. Менә, алтмыш яшьлегемне озаткач, жай табып, кемнәрнедер кунакка чакырасы бар дип шыпырт кына адарынып та йөри идем. Туксан беренче ел көзендә жанга якын Переделкино ижат йортында Смоленскидан килгән шапшак кына, ярпач кына, бүрәнә ярыгы күргәч тә хихылдый торган бер язучы әләмәсен очраттым. Сорадым. Ул кинәт житдиләнде: «Козлов-Куминский?.. Әллә кайчан вафат ич инде ул! Жиде-сигез еллар бардыр. Ничектер эше көйләнмәде бичараның. Язучылар союзына керергә йөргән иде, нидер житмәде, нәрсәнедер үзе эшләп бетермәде... Шаушусыз гына үлеп китте».

Димәк, вафат. Хәбәрне ашханәдә, тәмләп кенә ашап утырганда, шырпы очы белән ваемсыз гына теш арасын казыганда ишеттем. Дөньяны оныттым, жылап жибәрдем...

Германиядән килгән немецлар аша Һейнс Бемне эзләттем, хәбәрхәтерләре килеп ирешмәде, тапмаганнардыр дип беләм. Немецлар вәгъдәчел халык. Мадьяр әдибе Даби Иштваннан лагерьдаш юлдашым, рәссам Арпад Голгоцины эзләшүен үтендем. Жавап бирмәде. Сергей Сергеевичның тәне жылы чакта ник кулымны бирмәдем икән? Адресы күз алдымда иде ләбаса?!.

Аптыраш дими хәлем юк. Әйе, үзең кылган кайбер гамәлләрнең асылына шактый вакытлар узгач кына әйләнеп кайтасың да үз ахмак-

лыгына, ваемсыз-гамьсезлегенә, ваклыгына шаккатып карап торасың. Исеме телгә килгәч, Арпад Голгоци хакында бер-ике хөрмәт сүземне теркәп калдырыйм әле. Күркәм егет иде кызларча нәзек билле, егетләрчә зифа буйлы, рәссамнарча нәзакәтле, зур күзле, үтә чибәр мадьяр егете. Зонаның рәссамы иде. Күпме кешенең сурәтләрен ясап ерак-ерак туганнарын, бала-чагаларын, хатыннарын сөендереп жылатмагандыр ул!.. «Фотогеничный» йөз барлыгын мин шунда аңладым. Арпад берәүләрне «коеп куя», икенчеләрнең йөз-битләре аның каләменә буйсынмыйлар.

Арпад та югалды. Әллә илле алтыда, советларның комсыз гаскәрләре мадьяр башкаласы Будапештка килеп кергәч, совет режимының, большевиклар хакимиятенең **нинди** икәнен үз җилкәсендә үк татыган шигъри күңелле егет советларның ыжгырып килгән канлы танкларына яланкул хәлдә каршы ташландымы?.. Горур егет иде мадьяр Голгоци...

Балчык карьерында уникешәр сәгать эшләп алҗыган чагым иде. Күзгә ак-кара күренми, яңа танышлар эзләү түгел, бар булганнарыннан ничек котылырга белмичә газап чиккән көннәр. Арып-ярсып, дөньяга вагон-вагон нәләт яудырып, каһәрләп балчык катламнарын ишәм. Кулбашлары котырып сызлый, кабыргалар бер-берсенә ышкылып кыштырдыйлар. Йөрәк хәлсезләнеп сулкылдапмы-сулкылдый. Кар баскан карьер, түбәсе ишелеп төшәрдәй булып, гәүдәне кыса. Һава җитми. Отбой чүкечләренең ач авазларыннан колак тонган. Янымa кемдер килеп сәлам бирде, ике-өч тапкыр дәшкәч кенә күз кырыем белән дәшүчегә бактым. Күзлекле, яньчек борынлы, кашлары бер-береннән качып китәргә җыенгандай читкә тартылганнар... Өстендә зонада сирәк очрый торган куе яшькелт бушлат. Юл сорый дияр идең, зонада адашуың мөмкин түгел. Ни җитми бу кешегә?.. Колагым ачылгандай итте, ниһаять, сораганын аңыштым. «Сезне, хәрби журналист, диләр. Хакмы бу?» — дип сорый икән. «Хәрби журналист», дип шыттырган чагым да бардыр, зонада кем нәрсә дип кенә шапырынмый? Ай саен, ел саен дәрәҗәңне күтәрәсең, иңнәреңә күренмәс йолдызларны өсти торасың. Күзлек астыннан яратып, үз итеп караган күзләрдән оялдым. Кызардым да бугай, «юк ла!» — дип эштән тукталып тордым. Әле генә мин ишкән балчык таучыгына утырып, берне көйрәттек.

Ревякин карьерга керел-чыгып йөргән чит тоткыннарны һич өнәми, очрата калса, ач козгын булып тегенә куна: чукый-чукый куып, типкәләп чыгара иде. Кышкы салкыннарда, җил-бураннарда урамда вак-төяк йомышлар башкарып йөрүче аксак-туксак, сукыр-букыр тоткыннардан җыйналган бригада әһелләре җил-суыкка түзә алмыйча йә җылыга, кирпече әлерәк бушатылган Гофман мичләренең куентыкларына посалар, ара-тирә карьерга кереп тә җылыналар. Сергей Сергеевич шуларның берсе икән. Сүзгә мавыгып, без кем патшалыгында утыруыбызны онытып җибәргәнбез бит, гөнаһ шомлыгы, берзаман карасак, янибызга курьер поезды сыман ыжгырып, җил кузгатып Ревякин килеп баскан, зәңгәр канатлы чалбарының гәләфиләре як-якка чайкала, авызыннан утлар чәчә. Икебез дә тордык, мин каушадым, чүкечемә барып тотындым. Сергей Сергеевич, Колыманы, эт җиккән яклардагы байтак зоналарны үткән сәяси тоткын каушамады, җебеп төшмәде, тамагын бер кырып алды да: «Фәлән-фәләнеч!.. Мин фәлән бригададан. Сезне искиткеч шәп мастер, яхшы кеше дип ишеттем дә карьер бригадасына күчәргә йөрим. Әле бу егеттән шуны сорашып тора идем. Егет тә сезне мактый, әгәр илдә сездәй шәп җитәкчеләр булса, без әллә кайчан коммунизмга чыга идек, дип сөйләп торды. Әгәр нарядчикны ризалатсам, бригадир каршы килмәсә, иртәгәдән карьерга эшкә чыгам!» Бу озын сүзне тыңлап торырга көче җиттеме Ревякинның, әллә Сергей Сергеевич кыскарак тоттымы, гаҗәп хәл, күтәрелеп бәрелмәде, йодрыкларын йомарламады, әтлеген итеп кенә: «Күчсәң күч, тик монда сөрхәнтәйләнеп, эш калдырып йөрмә! Хәзер үк югал!» — диде һәм... күзләремә ышанмадым, кәкере аякларын киң-киң атлап, китеп тә барды.

Без зонага кайткач, тынычта күрештек һәм Сергей Сергеевич срогын тутырып иреккә чыкканчы бер дә аерылмадык. Аннан соң да әле безнең дуслык җепләре өзелмәде.

Мәскәүдә Әдәбият институтында укыганда кулга алынган шагыйрь Козлов-Куманский мине өр-яңа дөньяга алып керде дисәң дә ярый. Урыс, дөнья әдәбиятларыннан йөзләрчә мәшһүр шигырьләрне яттан белүче, тирән хис белән җиренә җиткереп, йөрәккә үткәзеп укучы бу сабый күңелле дәү абыйның табынган шагыйрьләре икәү иде: Пастернак белән Мандельштам. Пастернак исемен моңарчы ишеткәләгән булсам да, Осип Мандельштам минем өчен өр-яңа кеше иде. Инде, «үз иҗатларыбыз» белән бер-беребезне таныштыргач, безнең аралар ныгыды. «Үз иҗатларыбыз» дип көлемсерәп әйтәм, гәрчә, минем дә басылган бер хикәям янында, язылып ташланган уннарча әсәрләрем, уннарча хикәяләрем бар ич! Кыен булса да танырга туры килә, бу юлы табылган фикердәшем дә күп яктан миннән өстен, ул, ялгышмасам, Ленинградта үскән, шунда укыган, зыялы кеше баласы. Ленинградтан, Ирина Борисовна Рак исемле ханымнан аңа посылкалар килеп тора. Посылкалары... ыслаган колбаса, куертылган сөт, телгә салгач эреп китә торган конфетлар.

Мин түгел, ул миңа дөнья яңалыкларын җиткерә, аның һәр яңалыкка үз мөнәсәбәте булу мине сокландыра иде. Зонада аралашкан кешеләре дә үзе кебек зыялылар иде. Мәскәүле профессор Галинкер белән аерата дус иде. Галинкер дигәннән, берзаман Мәскәүдә, телефон-автоматтан шалтыратып маташам. Янымда югары курслар буенча шәригем, искиткеч ягымлы егет Асанбай да бар. Кырыбыздан гына Галинкер узып китте. Мин Асанбайга төртәм: «Күрче, профессор Галинкер. Лагерь буенча танышым!» Асанбай атылып та чыкты Пушкин урамын яңгыратып: «Галинкер, Галинкер!» — дип кычкыра да башлады. Профессор тукталды, һич гаҗәпләнмәде, без аны куып җиттек, бик җылы күрештек. Ул таныр-танымас карап торды да: «Кайсы лагерьдан?» — дип сорады. Аңлаштык. Сергей Сергеевичны, уртак дустыбызны, яхшы сүз белән яд иттек. Зонада мин олысымак холыклы Галинкергә якыная алмадым, ике кешенең берсе белән йә француз, йә немец телләрендә сөйләшеп йөргән профессор Галинкер миңа буй җитмәслек биек тау булып тоела иде. Алай да, хәзер телефонын бирде, чәйгә чакырды. Сергей Сергеевичның төп ахирәтләре репатриантлар, Чехославакиядән кайткан казачий генерал улы Сидорин белән Врангель офицеры, архитектор Уклейннар иде. Икесе дә мәһабәт биек буйлы, сабыр акыллы, салмак урыс дворяннары мине дә бик якын иттеләр. Илле өченең гыйнварында миңа егерме биш яшь тулды. Үзенә күрә нәни генә юбилей! Зонадан тыш танышларымның берсе аша юнәткән бер ярты шәрабны бишкә бүлеп, үткәннәрне кадерләп искә ала-ала, алдагы өметләребезне җылытып, күңелле генә утырган да идек. Шул «бишлек» арасында югарыда әйткән дворяннардан тыш Сергей Сергеевич һәм немец дустым, берлинлы Һейнц Бем да бар иде. Уклейн Европада мәшһүр мөгәмәр булган, Лиссабонда тимер юл вокзалын һәм Прагада бер министрлык бинасын аның проектлары буенча салганнар икән. Шулары истә калган. Урыс булса да, Сергей Сергеевич яһүдиләр, зыялылар белән нык аралаша, аерата грузин яһүде Шалва белән серләре килешә иде.

Әдәбият институтында ул Елизар Мальцев белән бергә укыган. «Югославская трагедия» романын язып, Сталинга тәлинкә тотканы өчен дәүләт премиясе алган бу төссез бәндә аның төрмә язмышына мөнәсәбәтле идеме, алары истә калмаган. Аның иң рәнҗегәне яшьлек дусты, шәриге Савичевның бер генә хат та язмавы булды шикелле. Шәриге Савичевны ул үзеннән өстен куя ала, аның яшьлек иҗатына табына, еш кына аның шигырьләреннән дә мисаллар китерә торган иде. Сергей Сергеевич җаны-тәне, тотышы, гамәле белән ихлас күңелле шагыйрь иде. Хәтеремдә, ул еш кына шушы дүртьюллыкны кабатлый иде:

Жизнь — это сон!
Но каждому снится разное:
Кому сверкание алмазное,
Кому кандальный звон.

Шәриге Савичевка да «Алмаз җемелдәүләре» насыйп булмады, ахрысы, урыс әдәбиятында, урыс матбугатында аның исеме күренмәде.

Сергей Сергеевич зонада иҗат иткән шигырьләренең байтагысын миңа бүләк итте. Кызганыч, саклый алмадым мин аларны! Илле дүртенче елның көзендә мине Черек күл төрмәсенә кайтардылар. Шунда, Актастан зур юлга этапка үтешли мине ике көн Майкудук зонасында ябып тоттылар. Төрмә диварлары артында да дөнья тар, шунда камерада мин ике кеше белән утырдым. Аларның берсе, исегездәме, Сидоров фамилияле бригадир өстенә атланып, кулындагы ике пычак белән аның җанын кыйган Юрканы?! Берсе шул. Икенчесен очратуым кыска гына арада булды. Волынка таш базлары лагеренда булды бу хәл.

Әгәр зонага берәүне ялгыз гына китереп җертәләр икән — бу һәрчак шик уята. Бу базык, тәненең күзгә күренерлек һәр өлеше оятсыз сурәтләр белән чуарланган кешенең вахта аша үтеп капкадан керүе булды, зонадагы бандеровчылар-активистлар аны урап алдылар һәм буш баракка алып керер тә киттеләр. Ун-унбиш минуттан теге базык бәндәне ияртеп чыктылар, биш-алты кеше кул очлары белән өскә күтәрделәр һәм лык иттереп арты белән асфальтка бәрделәр. Чинап җибәрде урыс, «начальник!» — дип чәрелдәде. Бер бәрделәр, ике, өч... Үз эшләрен башкаргач, бандеровчылар таралдылар, теге бичара ыңгырашып, өстерәлеп, җирдә шуыша-шуыша вахтага таба китте. Ни гаепләре булгандыр, законлы бур идеме, сука булдымы — белми калдым. Һәм ни әйтәсең бу язмышка! Майкудукка килеп БУРның камерасына керсәм, Юрка янында ул да бар! Арт саны гарипләнгән икән бәхетсезнең, сөйрәлеп кенә йөри. Йөри дип, шул еллар эчендә аны бер тапкыр да зонага чыгармаганнар. Нихәл итмәк кирәк, лагерьларда да кара сакалың артыннан калмый. Урыс әйткәндәй, кара этне ничә юсаң да агармый икән инде!..

Әле болар гынамы! Майкудук БУРыннан этапка чыккан чагында мине... Карабастан китәсе көнгә каршы карцерга китереп тыккан җирән надзиратель тентеп озатты. Таныдымы мине, юкмы, белмим, мәгәр Сталин үлеп, безнең язмыш хәлләре аруга борылырга торса да, эт этлеген итми калмады. Сергей Сергеевичның шигырьләре, хатлары, Леналың соңгы язганнары шул ачәрвах эткә азык булды. Әгәр аяк терәп карышсам, ахыр чиктә, лагерь башлыкларын китерүне таләп итсәм, һич югында БУРны кузгатып акырсам, ярдәм сорасам, ул кадерле язмалар исән дә калыр иде, бәлки. Зонада чакта: «Илле дүртенче ел ич, безнең көннәр килде!» — дип гөрләшә торган идек. Ә эшкә килгәндә сырт сөяге һаман йомшак шул, ныклык җитми, ныклык!.. Турысын әйткәндә, янымда кул сәгате белән әз-мәз акчам бар иде. Әгәр карышып маташсам, теш порошогы тартмасының төбенә яшерелгән «хәзинәмне», һичшиксез, табачак иде теге эт! Акча, сәгатемне җәлләп, саранланып, дустымның хатирәләрен биреп җибәрдем. Сәгать күргәнме мин, акча күргәнме?.. 220 сумга сатып алган «Победа» сәгатен бик ярата идем, кадерли идем! Ходам гафу итсен, Сергей Сергеевичның рухы рәнҗемәсен.

Зирәк кеше иде, якты күңелле кеше иде! «Зоналарда мине шигърият аяды, Пастернак, Мандельштамнар мине саклап калды. Төрмәдә еш тукмадылар мине, ике тапкыр кабыргаларымны сындырдылар. Алар тоя, ә мин канлы иреннәрем белән пышылдап Пастернакны укыйм. Тегеләр тагын да котырып китәләр!.. Азакта барыбер мин җиңүче булып кала идем. Гомереңдә әз генә булса да җиңүче булып карарга кирәк шул, Аяз! Җиңүче! Татлы хис ул, бөек хис — Җиңү!»

Сергей Сергеевичның зирәклегенә бер мисал китерәм. Инде Сталин үлеп безне бер бәхетле итсә, Бериянең соңы зоналарны айкый-айкый

куандырды! 1953 елның июнь аенда Мәскәүнең зур театрында композитор Шапоринның «Декабристлар» операсы куелды. Спектакльне карарга Политбюро һәм хөкүмәт әгъзалары җыелды. Арада... Л. П. Бериянең исеме юк иде. Хәбәр басылган гәзитне күтәреп, Сергей Сергеевич яныма йөгереп килде. «Берия юк! Җәлладны юк иткәннәр! Йомдырганнар аны... Яки без Бериянең кем икәнен белмәгәнбез!» — диде чиксез сөенеп. Алдан күрүчәнлеге бар иде өлкән дустымның. Кай ара ул мине гаҗәпләндереп тә куя иде. Сталин вафатыннан соң ил башына Г. М. Маленков менеп утыргач, Сергей Сергеевич чиксез куанды. «Ниһаять,— диде ул,— Рәсәй башына чын урыс лидеры менеп утырды!» Мин белгәндә адәм улларын милли яктан бүләргә яратмаган, яһүд, гөрҗиләр белән йөрәген биреп аралашкан кешенең Маленковның урыслыгының иң алга чыгаруын күрү миңа бик сәер тоелды. «Маленков урыс, бу кеше инде Сталин юлыннан бармаячак, аның үлеме дә бүтәнчә булыр»,— дигән иде, бу юлы ник ялгышты Сергей Сергеевич. Маленков большевиклар сызган юлга тугры калды, шул юлда абынды, танавын канатты. Сөрделәр аны, кудылар. Һәм тарихның мәгълүм елларында илне дерелдәтеп торткан Маленков бәләкәй генә чиркәүнең нәни старостасы дәрәҗәсендә дөньяны куйды. Кемнең, кайда, кайсы капкадан чыгып китәсен бер хода белә!

Илле дүртенче ел азагында Сергей Сергеевич мәктәптә укыта башлавын хәбәр иткән: «Сиңа булган иң җылы мөнәсәбәтләремнең үзгәргәне, һич үзгәрәсе юк»,— дип, хат саен искәртеп торган. Лида исемле немец кызына өйләнде минем дустым, анда да мине онытмады, посылкалар салды, акча җибәрде... Хат дигәндә... менә алар! Күңел ныклыгын җилләрдә-давылларда да саклап кала алган җан дустымның соңгы хатларын да күз карасы кебек саклыйм...

Ул Смоленскида чакта ник язышмадык икән?! Монда, Мәскәүнең аяк очында гына икән лә ул шәһәр!.. Нигә очрашмадык? Төрмәләрдә чакта ватылмаган күңелләр, ирекка чыккач бүтән төрле сөремнәргә уралдымы әллә?.. Нигә без, кичәге тоткыннар, тыгыз аралашмадык?.. Бер шигем бар-барын, нигезле, куркынычлы шик... Утызынчы елларда кулга алынып, исән калып, утырып чыкканнарны кырык сигездә яңадан җыеп алмадылармыни?.. Ә безне, илленче еллар давылы корбаннарын тагын бер кат төрмәләргә тутырмаслар дип кем әйтә? Бармы андый пәйгамбәр?.. Урыс иленә, урыс иле шовинистларына ышаныч бик бәләкәй. Әллә ниләр күрәселәр бардыр әле!

## 14

*...Я счастлив.*
*В сонме бурь*
*Неповторимые я вынес впечатления.*

Сергей ЕСЕНИН

Илле икенче ел үтеп бара... Кем хәтерли хәзер ул елларны? Хәтерләүләр нигә кирәк?.. Ә безгә, Караганда-Тайшет-Балхаш тирәләренә бөялгән сәяси тоткыннар өчен истәлекле, авыр һәм куркыныч ел иде ул илле ике! Кореяда сугыш кызганнан-кыза бара. Урысларны илдән чүпләп-чүпләп шушы канлы мәйданга илтеп тыгалар. Татарларны да тик яткырмыйлар! Әйтик, Нур Гайсин да шунда, «урыс офицеры» булып кореялыларга, һәй, әйттем исә кайттым, американнарга каршы сугышып ята. Ике як көч сынаша, тарткалаша, өстенлеген дөньяга танытырга тырыша.

Зонаның илдә, дөньяда бара торган кискен хәлләргә үз мөнәсәбәте бар. Владивостокта сызгырсалар, Львовка ул күк күкрәве булып барып җитә. Львовта төчкерсәләр, Владивостокта кыя ташлар җимерелә. Тот-

кын теленнән тоткын теленә күчә торган хәбәрләр — секунд саен ишәя, минут саен көче арта торган хәбәрләр алар. Тоткыннар һәр яңа хәбәргә үз казаннарынның нидер өстиләр, өстәлгәне һәрчак тоткын файдасына була. Күргән төшләрне юрап, юрауларны укмаштырып, сыгып, өйрәнеп түгеп, төшкән маен — йомарламнарны ялгап, ямап, кисеп-үлчәп карагач, шул ук бер мәгънә табыла: тоткын һаман җиңеллек көтә. Ул нәни генә ялганга да, тау кадәрле алдауларга да ышанырга әзер, тик сүз азагы Азатлык булсын.

Тоткын көн саен җиңеллек көтә. Җиңеллек көтәргә нигез юк югын, ил башында һаман канлы тиран утыра. Особый лагерьлар Америкага өметләнәләр. Өченче бөтендөнья сугышы кабынып китсә, Советлар Америкага каршы тора алмаячак! Большевизмнан Җир шарын коткарырга вакыт! Черчилль шул хакта Фултонда кисәтте инде!

Юрау дигәндә майор Столяровка ышанмасак та, Уинстон Черчилльгә тәмам ышанабыз!

Этаплар китә тора, этаплар килә тора. Көндезләрен бик сирәк килеп төшә торган этап кабул итү вакыйгасын тамаша итәргә байтак тоткын җыйнала. Наум Песин, тәбәнәк, борча кебек житез, ачлыктан кибеп корыса да «яңа этап — яңа хәбәрләр» дигәндә аяк табаннарын җәлләмәгән Ленинград профессоры — лагерьның иң зур белгече. Хәбәрләрне ул җыя. Чәче кавыкланган, муены касмакланып каткан, тырнаклары киселмәгән, колак тишекләре шалкан чәчәрлек булган икенче бер профессор — бакулы Рафаэль Шапиро исә Песиннең күләгәсе. Песин кыбырсый, адымына көч өстәргә тырышып сикереп-сикереп куя, кабалана, алай да авыр аяклы Шапироны узып китә алмый. Песин чаба, борылып карасa, ике аршын җир киткән, ач бичара, хәле юк. Бу ике дус хәбәрләрне җыялар, рәткә салалар һәм анализлыйлар. «Килен килә, килен килә, кисап хәтле теле килә», — дигәннәр җор татарлар. «Этап килә, этап йөри, Песин белән Шапиро дус кайларга барып өлгерми!» Иртәгесен зонада: «Песин болай әйткән икән!» — дигән җылы хәбәрләр ягымлы дулкын булып тарала. «Ә Шапироның уе болайрак...» — дип аңа каршы төшүчеләр дә табыла. Песин белән Шапиро — безнең зонаның радиосы да, газит-журналлары да! Ялгыш кына кулга төшкән газит почкакларын да алар эшкәртә, ике сүздән өчне, өчтән бишне ясый. Аларга ышаналар, тоткын ышанып яшәргә тиеш, ярсу бандеровчылар да, сабыр акыллы литвиннар да, дөрләп кабынырга әзер кавказлылар да аларга ышана. Мондый мөнәсәбәт зонада сирәк ярала.

Столяровның абруе сынган чак. Майор телдә йөгерек булса да эшкә үшән, ялкау, чарасыз бер кемсә икән. Безнең арада филонить итүчеләр, аркылыны буйга алып салырга да иренгәннәр дә майорның мондый зурлыкка әле хакы юк. Яшь, күрер-күзгә таза... Эшләп күрсәт, «упирайся рогами!», аннан дөнья күрсәтер! Яһүдне бригададан бригадага куып йөртәләр. Майор горур кеше, сүксәләр — дәшми, кусалар — чыгып китә, берәүгә дә ялварып бармый, аннан куып, монда кабул иткәләгәнче ай уза. Актас зонасында илле-алтмыш бригада, майор һәммәсен йөреп чыкканчы, һи-и, срогының азагы җитәчәк. Ара-тирә майорны жәлләп, аның туктаусыз тәтелдәп торган телен хөрмәтләп санчастька да салгалыйлар. Ләкин Столяров ни хәйләкәр булса да, Песин һәм Шапиро кебек ышаныч казана алмады. Бандеровчылар да, бүтәннәр дә майорга караганда профессорларны өстенрәк күрәләр шул!

«Этап килде!» — дигән тавышка мин дә торып йөгердем. Якташлар, татарлардан берәвесе килеп чыкмасмы дип көтәм... Капка авызын ачты, конвой кабалана, тоткыннарны ашыктыра. Актас зонасы килгәннәрне йота бара. Йа ходам! Этапларның олысын күргән бар, кечесен, тоташ аламалардан оешкан төркемнәрне тамаша кылган бар, иллә мәгәр мондый боламыкны очраткан юк иде. Колоннадагы һәр кемсәне төн уртасында, ай яктысында очратсаң, кабердән кубарылган әрвах дип белеп, котың очар иде. Машиналарда килеп аяксыз калган тоткыннар бер-

беренә ябышып кына атлыйлар, арттагылар алдагыларны этә, йөзләр соры-сүрән, сакал-мыеклар җиткән, өс-баш таланган, ямау өстендә ямау...

Этап ерак зоналардан килә калса, тоткыннар тутырылган ябык әрҗәгә машинадан чыккан газны үткәрәләр. Бу — тоткыннар аңгырайсын, качу турында уйламасын, тавыш-гауга чыгармасын өчен эшләнә. Килә-килә газ белән агуланган тоткыннар баш әйләнеп, коса-коса җәфа чигәләр, гадәттә. Болар шулай ерак сәфәрдән килделәр микәнни дип уйласам, әзрәк күз ияләнгәч карыйм — картлар этабы! Ике йөз илле шәүләне, үләргә яткан урыннарыннан кубарып, эш зонасына китереп ыргыттылар. Илдә хәлләр үзгәргән. Инде Спасск тәмугын йолкый башлаганнар! КГБның суы бөялгән икән: тоткыннарның иректән килүе кимегән! Уңга-сулга каерылып «рабсила» эзләргә тотынганнар! Иске капчыкны ямарга тотынган чекистлар!

ППЧны кара кайгы басты. Бу өрәкләрне кай урыннарга җибәрергә? Завод карьерына төшерергәме? Пресс янына бастырыргамы? Шахта базына вертикаль стволны тишәргә куаргамы? Әллә әче җилләр кочагына биреп, төзелешләргә тапшырыргамы?..

Күпчелекне җылыга — кирпеч заводына тараттылар. Карт-коры этабы килеп төшеп, зонада әйле-шәйлерәк чуалган мондагы өлкәннәрнең хәлен бермә-бер авырайтты. Моңарчы җиңелрәк эш башкарып, зонада җыештырынып йөргән Ной Борисович Окуньны да... пресс цехына күчергәннәр! Карагандадан тикшерү килгән дә Окуньның формулярына «күз салганнар». «Использовать на особо тяжелых работах» дигән күрсәтмәне укыгач, йә хода, бәлтерәгән җитмеш яшьлек картның себерке тотып кына йөргәнен белеп, әй тузынганнар тикшерүчеләр, әй кабарганнар! Кемгәдер шелтә дә эләккәндер әле, мөгаен! Совет хакимияте шелтә чәпәргә ярата, социализмның алыштырмас коралы ич ул шелтә!

Чиксез авыр хезмәтле, болай да планын чак-чак үтәп баручы цехка биш-алты картны җибәргәч, бригадир эшеннән баш тарта. Бер куркыта тегене ППЧ башлыгы Фунтиков, өркетә, яный, азакта биш тәүлеккә БУРга озаттыра. Кыскасы, бригадир кабат зонада күренмәде, аны гаепле санап, ияреп йөрүче формуляр кәгазенә. «Бунтовщик» — дигән кара тамга салып, Актастан озаттылар.

Ничек булгандыр, кем сүз кузгаткандыр, көнен-сәгатен, ваклыкларын һич хәтерләмим, мине ППЧга чакырдылар да пресс цехына бригадир итеп билгеләделәр. Бригадир ярдәмчесе бандеровчы Николай Дарий тәкъдим итмәдеме, дип хәзер уйлап куйгалыйм. Нигә ризалык биргәнмендер, Ревякиннан куркып, карьер тирәсеннән ерагаясым килдеме, үтерегез, берсен дә хәтерләмим.

Мин бригаданы эшкә алып чыктым. Бригадир! Хәтәр, украиннар: «Пан бригадир!» — дип кенә эндәшә!

Цех башлыгы, төнтек кенә, арык кына, авыру кыяфәтле, алама тунын җәйге эсседә дә иңеннән төшермәүче Сергеев, гел аек килеш тә исереккә охшап, як-ягына авышып йөрүче олы аяк Григорьев, тоткыннарның туфтасын сагалап торучы ярым урыс, ярым казакъ, сары көрәк тешле, сары чырайлы, авызыннан сасы тәмәкесен төшермәгән Ундасынов мине җылы гына каршыладылар шикелле. Яңа өстәмә көчләрне — картларны цехның кара тузанлы, зәңгәр газлы томаны эченә яшереп, нәни чоланга, башлыклар бүлмәсенә кердем. Нишләтергә, кайларга урнаштырырга бичара ак сакалларны? Ә алар... арада берәвесе полк командиры, икенчесе инженер-конструктор, өченчесе сынаучы-очучы... Төрмә картайткан аларны, каннарын суырган! Мөлдерәшеп миңа карап торалар: «Без кая эләккәнебезне чамалыйбыз, алай да ярдәм итегез, зинһар, безне Спасскига кире кайтармасыннар! Анда үләргә генә кала безгә!»

Дарий Николай искеләрнең кайсын-кая эшкә таратты, пресс ыжгырып, балчык болгатып кирпеч кисәргә тотынды. Мин яңаларны ияртеп анда-монда сугылдым һәм үз хәлемне яшереп тормадым: «Мөгаен,

ялгышканмын! Бу эшкә тотынырга кирәк булмаган!» — дип уемны ачып салдым. Шунда картлардан берсе, инженер, өшәнгән агай: «Сезгә, бригадир Хуродзе сәлам әйтеп калды! — димәсенме?» «Исәнме ул?» — дип сөенеп сорадым. «Исән. Аны да чак кына этапка кумадылар»,— диде инженер. «Тырышыгыз инде, бригадир!» — дип кабатлады.

Григорьевка, Сергеевка рәхмәт — уен уйнатып тормадылар, чатнатып: «Без, вольняшкалар, эшчеләрнең кайсын-кая урнаштыру белән шөгыльләнмибез, анысы тулаем синең бурыч!» — диделәр. Димәк, аларга аркаланып, җиңеллек көтеп ятарга өмет калмады!

Ятам шулай топчанда, бригадир әләмәсе, керфекләремә уйлар эленеп авырайган. Көчсезлегемнән гарьләнәм. Ходам шаһит, бәлки ул кадәрә үк борчылмаганмындыр да, бәлки хәзерге көн ноктасыннан торып фикер йөртәмдер, мәгәр шунысы хак: нык гарьләндем!.. Адашкан торна баласыдай ике-өч көн каңгырап йөрдем дә... киңәшкә киттем!

Зонада тоткыннардан ике нормировщик барын белә идем. Икесе дә бүгенгедәй күз алдымда. Саша исемле яшьрәге көпшәк тәнле, өреп кабартылган яңаклы, шактый мул корсаклы урыс иде. Без ак ярлы күл буенда блоклар тезеп ятканда аның су кереpгә килеп киткәне бар иде. Нормировщикларның икенчесе Федор Федорович Маландин зонаның мәшһүр музыкантларыннан берсе булып, ул зур осталык белән балалайкада уйный, концертларда чыгыш ясый иде. Маландинның уенын офицер хатыннары үлеп ярата дип сөйлиләр иде. Лагерь башлыкларының хатыны концертларны яраттымы, бетте, концертлар була да була, тамаша тоткыннарга да эләгә иде. Федор Федоровичны төнлә-төнлә зона тышына да алып киткәлиләр икән дигән сүзләр йөрде. Шанхайданмы, Харбинданмы, Федор Федорович Кытай репатрианты иде, Илечко, Абдулла Али-казылар белән тыгыз аралашканга, Абдулланың нуры миңа да төшеп, Федор Федорович та мине ят итми, анда-монда очрашканда кул биреп күрешеп йөрибез, уртак әңгәмәләрдә фикерләр кисештергәнебез дә бар. Нормировщиклар тоткыннар эшләгән һәр объектка барып-кайтып йөриләр, зона халкы арасында аларның абруе шактый югары иде.

Күз яшемне түкмәсәм дә, кыяфәтем шактый мескен булгандыр шикелле, алар мине бүлдермичә, җитди генә тыңлап тордылар...

Алар да мине юатмады. «Камытын кигәнсең икән, тарт әйдә!» — дигән кебегрәк сүз дә ычкындырдылар бугай. Кая ул юату! Федор Федорович йомшак, тәмле теле белән миңа тагын бер авыр хәбәрне җиткерде. «Берәү дә лагерь бригадиры булып тумаган. Өйрән! Алда күз күрер, син цех начальнигына бик ышанма, ялганчы ул. Ә Григорьевның күңеле әйбәт. Син аның аша «вольняшка» нормировщик Җаксыбаев белән таныш. Сез, мөселманнар, үзара тиз табыша торган халык. Тагын шул... Заводка Виктор Захарченко дигән егет чыгып йөри... Аның срогы әз калды. Шушы вакыт эчендә ул слесарь һөнәрен үзләштерергә тели. Фунтиков яратмады Викторны. Элек ул бик атаклы карак булган. Ике кулына бер һөнәре дә юк. Ул механика цехында эшләштереп йөри. Аңа ярдәм кирәк. Заводтагы һәр бригадир аның өлешенә әз-мәз акча күчерә. Суммасын ай азагында үзем әйтермен. Карышмассың дип беләм?»

Чүп өстенә чүмәлә. Авырткан башка имән тукмак! Викторга ярдәм кирәк, ә картларны кая куярга?! Алар да яшьләр белән рәттән эшләргә, план үтәргә тиеш! План каты тешли: бригада ходаның һәр бирмеш көнендә егерме ике мең кирпеч чыгарсын! Лагерь баландасы чүмереп, әчегән тары ярмасыннан суда пешкән бер кашык бутка ашап сигез сәгать су, балчык арасында, билеңне турайтмыйча эшләп кара! Бригада элек тә эшләгән, бөтен нормалар ачыкланган, тикшерелгән... Күз буяп та, «туфта ясап»та план үтәгән булып кылану мөмкин түгел. Элек бер кайгым иде: ничек итеп үз тамагымны туйдырырга?.. Хәзер өстемдә — бригада!

Бер нәрсәне ачыкладым, бригадир ялгыз була алмый икән! Бригадир янында, өйне төрле яктан терәткән баганалар шикелле, аңа көч биреп, кирәк чакта аны өскә күтәрүче булышчылар зарур икән. Бүтән бригадир-

лар сыман үз халкыңнан ышанычлы кешеләрне җыеп-туплап алыр идең... Әйтик, татарларны. Зонада өч-дүрт татар бар, алары да... Бандеровчылар ягына авышыргамы? Литвиннарга? Әз санлы, әмма корыч бугазлы урысларны тупларгамы? Алар заводның эчке-тышкы серләрен белә. Ярдәмчем Николай Дарий әйтә: «Һәрбер эшнең сере, серле җае була!» — ди. Ләкин минем иң курыкканым: зонадагы бер-берсенә каршы торган төркемнәргә кушылып китү иде! Бер буялсаң, агарачагың юк! Моңарчы мин бөтен гаугалардан читтә кала белгән зыялылар төркемендә идем.

Уем шушы ноктага җиткәч, мин көлеп җибәрдем һәм берәүгә дә сыенмаска булдым. Бу айда план үтәлмәсә дә суга салмаслар, алда күз күрер! Рәхмәтлемен, миңа кадәр дә бригадир ярдәмчесе булган Дарий Николай ярдәмгә килде. Илечко, Козлов-Куманскийлар, котылу әмәлен әйтә алмасалар да, бирешмәскә, нык торырга өндәделәр. Иң элек, мин үземә берәүне дә якынайтмадым, һәркемгә, көчлеме ул, көчсезме, тигез карарга тырыштым. Маландинның киңәше ярады, Григорьев аша Җаксыбаев белән күрешергә теләгем барын җиткердем. Нинди әмәл табып булса да завод хуҗаларын, зона башлыкларын алдарга кирәк!.. Хаксызлыкка бары тик аннан да яманрак хаксызлык белән генә җавап бирергә мөмкин булуын мин үзләштергән идем инде. Бригада картларын аяп алырлык, аларны исән-аман яшәтерлек ризык табуның хак юлы юк, булу ихтималы да күренми!..

Җаксыбаев озак көттермәде — зонага керде. Күрештек. Йоны йолкынган арык чебеш, күкрәге тар, битенә вак-вак зәңгәрле-карасу төрткеләр сибелгән, кашы көйгән бәндәнең кулы йомшак һәм үтә дымлы иде. Кул кысышуга мин аны яратмадым. Вольняшкалар бер чакта да тоткыннарга кул бирмиләр, кул сузалар икән, сине йомарлап алырга, буйсындырырга телиләр дигән сүз! Татар икәнемне белеп килгән Җаксыбаевның авызы урысча ачылса да, татарчага күчкәч ябылмады. Нормировщик татарларны яратуыннан гәпне башлады. Аның фәлән агасының хатыны татар икән дә, төгән каладагы тутасы татарга кияүдә икән. Татарлар юмарт, кунакчыл, кече күңелле, рыясыз ярдәмләшә торган дөньяда бер мактаулы халык икән. Җаксыбаев әллә кайчаннан татарларны ярата икән, таныш-белешләре арасында да татар кавеменнән байтак могътәбәр затлар бар икән. Башка бер милләт вәкилләренең очрашуга татарларны мактый башлавын өнәп бетермим мин. Татарны беләм, нигә миңа аларның кемлеген аңлатырга? Җаксыбаев, казакъ баласы! Син мине татар булганым өчен яратма, зинһар! Мөселман булуым өчен дә төчеләнмә! Син миңа әнә шул бичара картлар үлеп китмәслек кенә ярдәм ит, шулар хакына булыш! Менә булырсың егет! Тап бер чарасын! Сүз башында Григорьев безнең тирәдә уралса да, кемдер чакырдымы, ул чыгып китте, без Җаксыбаев белән икәүдән-икәү генә калдык. Беренче тәэсир күп чагында алдаучан була, кем хакында булса да тәүге фикереңне әйтергә ашыкма! Дөрес, Җаксыбаев әрсез вә комсыз, әмма ләкин шактый кыю эшкуар булып чыкты. Йөрәкле дә икән, ике-өч күрешкәннән соң ул миңа шундый юл күрсәтте. «Бригадаңда кеше арткан. Өстәмәгәндә дә пресска эшче куллар җитә иде. Мин монда бүтән бригада башлары белән сөйләшермен. Ташкүмер килгән вагоннарны бушатырга туры килер. Аратирә кирпеч төяргә дә баргаларсыз. Вак-төяк ремонт эшләрен дә сиңа йөкләрбез. Картларның берсен чисталык комиссары итеп куярсың. Отстойник чистартырга берәвесен беркет. Ләкин мин, турысын әйтәм, каз биреп үрдәк ала торган кыек авыз түгел! Үрдәк биреп ике каз алырга яратам мин. Өчәү булса да артмас!.. Миңа яшь, үткер күзле, җитез куллы мөселман бригадир кирәк иде. Моңарчы заводта андыйлар булмады... Бригадаңда юныш остасы бармы? Эзлә!»

Күңелемнән тиз-тиз үз кешеләремне тезеп үткәрдем, латыш Романасның балта остасы икәнлеге колагыма чалынган иде. «Бар!» — дидем. «Ышанычлымы?» — дип төпченде Җаксыбаев. Романасның басынкы, тынлаучан һәм сүздә сак икәнлеген белгәнгә: «Ышанырга була!» — дидем.

Җаксыбаевның чырае яктырды, күкрәге киңәеп, буе үсеп киткәндәй булды. Романасны цехтан алып, юныш эшләренә куйдым. Вася Иванов эшләгән завод котельнясының эчкәрегә бер бүлмәсе бар иде! Аңа котельня аша гына үтеп йөреп була, читтән-чоттан карaганда барлыгы да беленми. Тәрәзәсез, ишексез бүлмәгә ярым караңгы коридор аша кысылып керәсең дә югаласың. Заводка өр-яңа рейкалар, опалубка такталары өзлексез килеп тора, Романас шул такталарны чәлдереп-йомдырып ташый да... Җаксыбаев кушкан җиһазларны ясый. Башта аш-су өстәле ясады, коеп кына куйды латыш, артсыз урындыклар да күз явын алып тезелеп үттеләр, тумбочкалар, кием элгечләре, тагын әллә ниләр, әллә ниләр ясап бетерде Романас. Калдык-постык йомычкалар көнгә чыкмый, Вася Ивановның мичләре аны убып бара. Ә әзер әйберләрне төнлә-төнлә ничек алып чыкканнардыр, сорашмадым. Кемнәрне җайларга, кемнәрне майларга, кемнәрне алдарга туры килгәндер дала улы Җаксыбаевка, әмма бригада картларының җанын саклап калырга чат ачылды. Креслоларга, диваннарга хәтле ясады Романас. Тора-бара мин аңа бер ярдәмче дә беркеттем.

Лагерь башларының кайсысына кадәр менеп җиткәндер Җаксыбаев, әмма без хәвеф-хәтәрсез генә байтак эш майтардык. Вася Ивановны вакыт-вакыт кум чакырып алганын белә идек, егет саф күңелле булып чыкты, безне сатмады. Наряд ябулар хакында Малandин белән дә, Саша белән дә сөйләшми идек. Эшләгәннәрне биш тапкырга арттырып язсак та кәгазьләр шома гына үтә торды. Виктор Захарченкога да акча күчерә идек. Виктор белән без дуслаштык дияргә ярый. Серле адәмнәрнең дә иң серлесе иде Виктор, азаккача шулай булып калды. Бүләк итеп биргән фотосы әле дә саклана. Баһадир гәүдәле, көчле иңбашлары калкынган, кабарынкырак киң битле, калын иренле көләч бу егет, чыннан да, заманында карак булганмы?.. Авызын чамалап ача, сүзен үлчәп кенә сөйләшә, лагерь урыслары арасында ул чамасыз көче белән дан алса да, милли чуалышларга бер чакта да катнашмады, җәнҗаллардан читтә йөрде, кыдрачлар якага-яка килгән мәлләрдә һәрчак әтәчләрне аралады...

Көз үзенә алмашка кышны чакырды. Октябрь азагында ук чамасыз җилле, өметсез салкыннар башланды. Вокзал төзелешенә йөрүче тоткыннарның берничәсе кул бармакларын өшетеп кайтты, колак, бит өшетүчеләрнең саны-исәбе юк иде. Газлы-сөремле заводның абруе күзгә күренеп артты. Безнең бригадага күчәргә теләүчеләр ишәйде. Беренче булып яныма майор Столяров килде.

Йөзәр, меңәр кеше укмашып яшәгәндә сирәк кешеләрнең, якын иптәшләрнең чыраена гына еш-еш текәлеп карыйсың, алардагы үзгәрешләрне чамалап күңелеңдә ниләр ятканын, нинди көчләр хәрәкәт иткәнен аңларга тырышасың. Ә бүтәннәр... үтә күренмәле шәүлә хәлендәрәк кала. Үткән-сүткәндә зонабызның мәшһүр затларыннан берсе — майор белән дә очрашкан, бер-ике сүз алышкан бар иде. Мәгәр яшәү шартлары таләп иткәнчә мин аңа шактый битараф булганмындыр ахрысы, төбәп караганым да, тирән кызыксынуым да булмаган икән. Туп шикелле тулышып торган бит очлары шиңгән майорның, шәбәйгән мизгелләрендә ядрә булып атылып чыгарга әзер күз алмалары сүрелгән, ертык тышлы сырмасы, куе йон котырып үскән иякләре, җыерчыклар йөгерешкән муенына ураган иске тастымал-шарфының майланып каткан булуы күзне кисте. Сөйли башласа ике сүзенең берендә «мин!» алмашлыгын куллана торган Столяров бүген бөтенләй бүтән кеше иде инде. Элек аны аңлау кыен булса, бүген йөз кыяфәте, аркылы тешләнгән теле аның ни хәлгә төшеп баруын раслыйлар иде. Нишлисең, майор әкрен генә сыза, сүнә бара икән, аны доходягалар, фитильләр сафы көтә икән. Йон баскан бармакларын бөреп, авызына якын китерә дә катлы-катлы ютәлли, гүя бөреп чыккан йөткерүләрен учына җыярга тели иде. «Суык тиде,— диде ул гыжлап.— Кыш җитте!»

Үзенең бер яңалык та әйтә алмавына уфтангандай, ул озак кына тынып, күрсенгәләп карап торды да, һич кирәкмәстә, мне мактарга керешге. «Работягалар сине ярата! Зыялы егетләр, кулларыннан эш килсә дә бригадирлыкка алынмыйлар! Юкка! Бригадир күп яхшылыклар эшли ала!» Майор тагын ниләр әйткәндер, әйткән кадәресеннән шул аңлашылды: ул кышкы салкыннардан качып пресс цехына эшкә килергә ниятли икән. «Чирләп ардым! Чирдән аруның ни икәнен аңлыйсыңдыр»,— диде ул өстәп. Ни әйтергә? Ничекләр юатырга бу дала дуңгәләгеп? Күренеп тора, әгәр кышкы салкыннарда калдырсаң, нәзберек тормыш иркәсе майор шыкранлап катачак. Бүтән халыкны белмим, үзеп әйтә алмыйм, мәгәр яһүдләр салкынга бер дә чыдамыйлар. Столяровны моңарчы армия ашаткан, армия киендергән, ул кем каршысындадыр абруй казанган, өскә үрләгән. Элеккеге язмыш төене белән хәзер тоткан урыны артык ераклашкан иде. «Синең янга бармыйча кем янына барыйм?»— диде ул.

Иртәгәсен ул безнең белән эшкә чыкты. Резин итек киеп, резин алъяпкычын кысып бәйләп, кирпеч кисәргә тотынды. Бер секундта, ике, өч... Ә пресс калаклары туктаусыз әйләнә, тыгыз, дымлы балчык бүткасын дүрткел авыз аша өзлексез этеп тора. Соңга калырга, кичегергә һич ярамый! Һәр секундта саен ике кирпеч киселеп чыга. Биш минутта майор тиргә батты, ун минуттан өлгерә алмый башлады, унбиш минуттан кулын селтәп, читкә китте һәм ярты сәгать аңына килә алмады. Мондый авыр эшне бригадада ике кеше генә үти ала иде: эстон Ансонс белән латыш Скуя гына!.. Бөтен бригаданы, картын-яшен шулар яшәтә. И карышусыз, армас-талмас эшли белгән латыш-эстоннар! Сез әле төрмә кысасында шулай эшли идегез, үзегезнең иректә илләр яралгач, үз хезмәтегезгә үзегез хуҗа булгач, нинди могҗизалар күрсәтмәссез икән сез?!

Күп еллар үткәч, Ялта шәһәрендә драматургларның бөтенсоюз семинарында белорус әдибе Владимир Львович Мехов белән очраштык һәм нык дуслаштык. Сугыш елларында Казан каласында эвакуациядә булган бу яшьтәш егет мәркәзебезне вә татарларны бик нык хөрмәт итә иде. Сүз иярә сүз чыгып, мин майор Столяровны телгә алдым. Озак та үтмәде Мехов: «Таптым мин синең майорыңны, исән-сау!» — дип хат язды. Нык талпынсам да, ул чакта Минскига барып чыгып булмады. 1989 елда Минскига килгәндә элеккеге хәрби журналист, майор, күп еллык партия стажыннан баш тартып, коммунистик кызыл билетын тапшырып, олыгаеп, күп санлы бала-чагаларын төяп яһүдләрнең тарихи ватаны Израильгә киткән иде инде.

Рәнҗемә миңа, Михаил! Сине җылы, ышык, тамагың тук эшкә урнаштыра алмадым, кичер. Син яшь идең ул чакта, интегеп булса да җаныңны саклый ала идең! Ә җитмеш яшьлек Ной Борисовичны, җаны усак яфрагы кебек калтырап торган, сугыш башланган көннән туя ашамаган, дөньяга бары тик рәшәткәләр һәм чәнечкеле тимер чыбыклар аша гына караган, адым саен бөсере төшеп интегә торган сөйкемле урыс Иван Лапаевны көймәдән төртеп төшерергәме? Ишкәк тотарлык хәлләре юклыгын белеп, аларны безнең бригада көймәсенә көчләп утырттылар лабаса!.. Максат: аларны юк итү, үтерү иде бит!..

Үпкәләмә, Михаил! Сине түгел, кан кардәшем үк булмаса да, җан кардәшем булган Эскандер Даирскийны да бригадама кабул итәлмадым мин ул чуалчык чакта!..

Аны милләттәшләре арасында бер чакта да күргәнем булмады минем. Юк, Эскандер, кырым татары булса да, бер чакта да якташларына тартылмады. Мин аның ялманып Мохтарның «тук тәрәзәсен» шакыганын хәтерләмим, йөрмәгәндер Эскандер... Тәне горур, олы җаны чак эләгеп торырлык кына калса да ул япа-ялгызы яшәде шикелле, ялгызлыгы белән дә бөек иде бу адәм.

Эскандер очучы, хәрби самолетларда күп тапкырлар очкан, сугышка кадәр үк Ленин ордены белән бүләкләнгән, һава сугышларының берсендә

немецлар аны бәреп төшергәннәр. Анда да югалып калмаган Эскандер, дөрләп янып, ыжгырып җиргә төшеп барган самолеттан чыккан, парашютын ачарга көче җиткән. Ләкин хәерсез җил аны немецлар басып алган авыл читенә китереп бәргән... Аягын сындырган батыр очучы, сул аягын тез тиңентен кисеп ташлаганнар. Операцияне әсирлектәге доктор гап-гади кул пычкысы белән башкарган. Даирскийирешә торганнардан түгел, ыңгырашмаган, бер тавыш чыгармаган, чыдаган, түзгән.

Белмәсәң, хәзер дә аның аяксыз икәнен абайлау мөмкин түгел, бу курач, ут күзле кырым кешесе Казакъстан җил-давылларында ничек очып китмәгәндер, бүгенгәчә аңламыйм. Бер учка сыярлык гәүдәгә калса да, аяксыз Эскандер Даирскийны эштән бер чакта да азат итмиләр иде. Чөнки аның да формулярында: «Использовать на особо тяжелых работах!» — дигән күрсәтмә бар. Бу, хөкем чыккан кызулыкта чыгарып атмасалар да, әкрен-әкрен, газаплы үлемгә дучар итү дигән сүз. Моны хөкем чыгаручы явызлар да, хөкем ителгән бичара да белә! Югыйсә Спасск төрмә-лазаретта әҗәлнең аяк тавышларын тыңлап, якты көн белән хушлашып ятучыларны кирпеч эшенә яки шахтага бөдәрләр идемени?!

Килде Эскандер, мин Теккерейның мәшһүр «Ярмарка тщеславия» китабын укып ята идем. Топчанга салам матрасны каерып утырды, шыр сөяк кулларын тезләре өстенә куеп, төн карасыннан уеп алынган күзләре белән миңа текәлде. Дәшмәде, базмадымы, теләмәдеме, мәгәр аның атылган бөркет кыяфәте миңа килүенең максатын да, сәбәбен дә ачып бирде. Шулай, дәшмичә, шактый утырдык бугай. Ниһаять, Эскандер кузгалды, протезы шыгырдап үзенең барлыгын, Эскандергә мәңгегә ияргәнен белдерде. «Картаям, ахрысы,— диде ул,— олыгаям! Элек салкыннардан бер дә курыкмый идем! Кар белән ышкына идем!.. Мунчадан соң көрткә чумып хәл алган чакларым була иде... Хәзер — юк! Аякнын киселгән төше туңа. Суыкта йөреп керсәң дә чамасыз сызлый. Төн йоклатмый». Кире кагарга да, ризалашырга да ашыкмадым. «Иртәгә безнең бригада белән чык! Мин нарядчикка әйтеп куярмын»,— дидем.

Эскандер көне буе диярлек пресс цехында уралды. Бервү белән дә сөйләшмәде, рейкаларга тезелгән кирпечләргә кагылып-кагылып алды. Цехтан кибү камераларына кирпеч илтә торган житез келлерны йөртеп бакты, кайтыр алдыннан минс читкәрәк дәшеп алды. «Аңладым,— диде.— Монда мин сыяр тишек юк икән! Җәһәннәм бу!»

Хәтеремдә, мин Эскандергә шахта төзелешенең кочегаркасына урнашырга ярдәм иттем...

Эскандер Даирский хатыны яшәгән Елец шәһәренә исән-сау әйләнеп кайтты. Без байтак вакыт хат язышып, хәбәрләр алмашып яшәдек.

**«Исәнме, дускаем Аяз! Кичә синең иске хатларың килеп чыкты да, төгәл адресыңны белмәсәм дә, хат язарга утырдым. Былтыр «Крокодил» журналларын актарып утырам... синең исемеңә юлыктым! Нигә яңадан журналда күренмисең? Хикәяң миңа ошады, шулай дәвам ит! Синнән Черемныхларны уздырырлык сатирик чыксын! 1960 елда Киевта командировкада булдым һәм кемне очраттым дисең? Петр Кравченконы. Актаста ул да бригадир иде. Хәтерлисеңме? Ачык чырай белән өенә чакырды. Бардым. Торган җире ташка үлчим. Алай да чәркә арты чәркә күтәреп, үткәннәрне, Актасны искә төшердек. Сине дә яхшы сүзләр белән яд иттек. Солохудиновны, «премьер-министр» Велягурскийны хәтергә алдык. Җөмләдән, Кравченко Иван Велягурскийны очраткан, тик теге тиз арадан күздән гаип булган.**

**Профессорлардан Виктор Августович Гринупны онытмадыңмы? Узган ел бер ахирәтем Сочига ялга барган иде, Гринупка кагылып чыккан. Мин аңа бер-ике шешә «күчтәнәч» җибәргән идем... шундук «Столичный»га ташланды, ди. Сала икән бичара! Өйләнмәгән, карт энисе белән генә тора икән, тормышы көйләнмәгән. Адресы: Сочи, Мак. Горький урамы, 2 нче йорт».**

**«Кичә эштән кайтып кердем, ә хатыным синең хатны тотып тора. Җаным чамасыз җылынып, кайнарланып китте. Хатны ачардан элек, җәмагатем үтенечен тыңлап, синең хакта сөйли башладым. Синең хактагы хатирәләрем шундый әйбәт ки, шуңамы, хатынымның сөйләгән саен сөйләтәсе килә! Бер-беребезне табышуыбызга чиксез куанам. Чын күңелемнән ышанам, биш-алты елдан синең исемең ил әдәбиятында яңгырый башлар. Шулай булырга тиеш, чөнки язучыларның күпчелеге син узган юлларны үтмәгән, нинди авыр язмыш кичердек бит без! Мин синең «Удодов алпавыт утарында» нинди газаплар кичергәнеңне онытмыйм!..**

**Лагерьда чакта ук телеңдә тибрәткән кызга өйләнүеңә куанам. Тиздән-тиздән нәни «сөләйманнар» туасына ышанам һәм шуны көтәм. Профессор Гринупның адресын салган идем, алгансыңдыр. Февраль аенда Мәскәүгә командировкага бардым, Федоровка «утарыннан» байтак таныышларны эзләп таптым. В. Пруссны, Арбатта яшәгән Гольштейнны очраттым. Израиль улларының икесен дә аклаганнар. Гольштейн Клинда эшли, ә Прусс Минскида. Хатыны Мәскәүдә яшәгәч, еш кына кайтып йөри икән. Премьер Велягурский хакында шуны да хәбәр итәм, азат ителгәч тә ул Херсонга кайтып киткән. Анда урнаша алмаганмы, Караганданың унтугызынчы кварталына кире кайтып, таныш прорабы янына эшкә урнашкан. Шунда язып кара, мөгаен, эзенә төшәрсең. Федоровкага, бездән бушаган баракларга «киңбалакларны» китереп тутырганнар. Әйдә, рәхәт күрсәтсеннәр бер!»**

**«Күптән түгел Карагандадан кунак килеп төште. Безнең йортта аның туганы яши икән. Без салып яткан 121 нче шахта шартлап күккә очкан. Бик күп корбаннар булган. Адәмнәргә ничаклы бәла-каза килгән диген! 21 май, 64 ел».**

**«Безнең шәһәрдә Казан татарлары байтак. Бергә-бергә аралашып яшибез. Арада затлы кешеләр бар, зур-зур заводларның директорлары. Әгәр килә калсаң, җыелышып олы бер бәйрәм ясар идек. Кил».**

Хатларының берсендә Эскандер Казанның Бишбалта бистәсендә әтисе ягыннан туганнары булуын язган иде. Ялгышмасам, аларның адресларын, исемнәрен дә хәбәр иткән иде. Нигәдер эзләшмәдек, очраша алмадык.

Пресс цехына асрамага алуны таләп итеп бандеровчылардан «делегация» кереп чыкты. Болары инде сорап, үтенеп тормадылар, «Аласың и бетте-китте!» — дип куйдылар. Өзеп сүз әйтмәдем, аптырашта калдым һәм бик нык курыктым...

Хәлләр бөтенләй бүтән якка кереп китте дә, бу вак-төяк мазалар онытылып торды.

Кешеләрнең кадерен җуя, канын суыта торган ак сакал кыш та килеп басты. Җиргә калын туң йөгерде, карьердан ленталы транспортер аша зур-зур кантарлар, ат башы дәүмәлеге балчык кисәкләре килә. Кантарлар ике тегермән аша узып вакланалар, шулай төелеп чикләвек зурлыгы кисәкләргә әйләнеп, прессларга бара торган тасмаларга сузылып яталар. Кайвакытта карьердан шундый эре, авыр кантарлар килә ки, алар тегермәннең тимер түгәрәкләре арасына шапылдап төшәләр дә хәрәкәтне туктаталар. Тегермән түгәрәкләрен әйләндерүче лента очып төшә, эш туктала, завод тына.

Тегермәндә ул көнне Василий Васильевич Терлецкий эшли иде. Этаптан ук таныш, Терлецкий тырыш вә хәйләкәр белорус крестьяны иде. Свердловск төрмәсендә аның өстендә ала-кола кайры тун, үкчәләре ашалып беткән күнитек һәм бер колагы сәлперәйгән малахай булды. Өсте-башы үзгәрсә дә, Терлецкий һаман үзе булып калды, ара-тирә шук сүз кыстырып куя да рәхәтләнеп, үз зирәклегенә куангандай, шаркылдап көлә. Кайгы алмады егетне, ачлык сындырмады. Чын крестьянда беркемдә дә булмый торган тазалык, дөнья мазаларына көлемсерәп, хәтта

ки тәкереп карау да бар. Ник кырык чөен кырылып бетми, дөньяның асты өскә килми, Терлецкийга барыбер. Колак төбендә Корея туплары атып торсын, ул тәкереп тә бирми, гырлапмы-гырлый! Үз телендә сөйләшкән бердәнбер белорус булганы өчен дә мин аны хөрмәт итә идем. Берзаман карьердан балчык килү туктады, кем кая ял итәргә утырды, бүген рейкалар ташучы тәбәнәк Урбанис бушаган арбасына чалкан ятып йоклый ук башлады. Без цех начальнигы Сергеев белән өзеклек булган урынга — тегермәнгә чаптык. Без килеп җиткәндә Терлецкий бункерның бер як яңагындагы тимер тәрәзәчекне ачып, шактый мул бөялгән кантарларны каерып-каерып алып, түбәнгә чөя тора иде. Тиргә баткан, мышмыш килә, астан, карьердан бәйдән ычкынган котырган эт Ревякин килгәнче эшне рәтләп куярга кирәк. Югыйсә — хана! Бетте баш, калды муен серәеп! Сергеев белән без астан тамаша кылып торабыз. Сергеев та ашыктыра тегене: «Күпме әле?» — дип секунд саен сорый. Терлецкийның башы бункерда, ни әйткәне дә аңлашылмый. Шулчак нидер булды, мин һушымны җуеп җиргә ауганмын. Күпме ятканмындыр, белмим, ачылган күзем иң әүвәл баш тирәсендәге кулыма төште. Кулым өзелгән кәлтә җылан коерыгы шикелле кыймыл-кыймыл килеп бер читтәрәк ята иде. «Кулым өзелгән икән!» — дип шомланырга уйлап өлгердем. Моннан бер-ике ай элек кенә Сергеевның кулы транспортер лентасына ияреп кысылды да аның сытылган бармакларын кыеклап кисkәннәр иде. Шул хәтеремә төштеме? Бер мәлгә тагын упкынга очтым, онытылдым һәм Терлецкийның ялварулы-гафу үтенгән тавышы белән «Бригадир, бригадир»! — дип кабатлауларыннан аңыма килдем. Торып утырдым. Муен дар бавыннан әлерәк ычкынганмыни, котырып авырта, баш түбәсе мең чикерткә булып чыңлый. Башны муеннан алып каядыр читкә куясы килә — авыр! Терлецкий эшне тизләтергә тотынганмы, без аны ашыктырып алгарак тартылганбызмы, аңлата алмыйм, бункердан чыгып ычкынган сарык башы хәтле балчык кантары нәкъ минем баш түбәсенә килеп төшкән дә... яньчегән үк булыр иде, ходага шөкер, бүтән бригадирлар шикелле мин башыма купшы куян бүрек чәпәп йөрмим, лагерь биргән калын, чүпрәктән сырган мамыклы бүрек киям. Рәхмәт ГУЛАГ тегүчеләренә, бүрекне калын, нык итеп сырганнар, мамыкны җәлләмәгәннәр, тимер каска диярсен, шул мине коткарып калган. Югыйсә, Актас читендәге «туганнар каберлегендә» исемсез-нисез И-Г-732 булып ятып калыр идем. Эш азагына тиклем такталар өстендә ятып тордым, зонага мине ике яктан култыклап алып кайттылар, санчастькә илттеләр. Врач: «Ул-бу юк сыман... Алай да ике-өч көн эшкә чыкма!» — дип ял бирде. Тынычлап ятып торырга да җай булмады, кизү надзиратель килеп, мине Кум янына алып китте. Ул вакытта Сухостойны күчергәннәр, безгә Коробейников дигән капитанны җибәргәннәр иде. Сугыш елларында тиз-тиз погоннар ябыштырып, югары күтәрелгән чиле-пешле бик күп «әфисәрләрне» сугыштан соң лагерьларга таратканнар иде. Коробейников шуларның берсе, үшән, ялкау, гөбе-гөбе ботлары казна ыштан балакларына чак сыйган симез бәндә, әле үзенең бүгенге дәрәҗәсенә күнегеп тә җитмәгән крестьян баласы иде. Кергәч тә утырып торырга кушты, заводта булган хәлне вәземләп сорашты. «Кем булса да оештырмаганмы!» — дип кызыксынды. Кат-кат кайтарып сорашса да җавабым бер булды: «Терлецкий гаепсез, кеше сүзенә карап адәм җаны кыя торганнардан түгел. Берәүдән дә шикләнмим», — дидем. Ярым янап чыгып киткән бандеровчылар исемә төшсә дә, бу күңелсез уйларны куып җибәрдем...

Бу юлга исән калдым, ходай бәла-казаларның бүтәннәреннән сакласын!

*Ахыры киләсе санда*



## Салих Баттал

### ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Гөнаһ шәрхы

*Кем яраткан? Кем чыгарган и, гөнаһ ләфзы, сине;*
*Мәгънәсезсең, сеңдералмый саф гакыл һәзъмы сине!*

Г. ТУКАЙ

Теплоходта барам. Яңгырдан соң
балкып чыккан кояш нурында
матур эзләр иясен мин күзлим
теге якта — Идел комында.

Чишенгән дә ул кыз су читендә
басып тора нәрсә уйлаптыр...
Белми бит ул,— биноклем аны
якынайта миңа ун тапкыр!

Ә теплоход үтә, ерагая...
Гомер шулай үтә,— димен,— аһ!
Пароходның тавышы, кайтаваздай:
— Кая карыйсың,— ди,— бу — гөна-а-а-аһ!

Тәүбә иткән тәүфикъ ияседәй
борылып арка бирәм «гөнаһ»ка.
Чөнки «гөнаһ», борылышка күмелеп,
күздән язды инде болай да.

«Ташладым» дип, шулай масаябыз
«Гөнаһ» үзе безне ташлагач:

---

Салих БАТТАЛ (1905)—*күренекле шагыйрь, прозаик әдип, драматург: күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

вегетариан булып әвереләбез,
иткә тешләр үтми башлагач.

«Гөнаһ» диеп, читкә борыл, имеш,
матурлыкка ачма күзеңне!
Үлем күзлегеннән караганда
яшәү үзе гөнаһ түгелме?!

Гөнаһ ни ул? Шуңа җавап кебек
теплоходыбызның яныннан
артка калды кеп-кечкенә буксир,
шуңар таудай баржа тагылган.

Ә баржада язу: «ут хәвефле».
Димәк, тулы анда ягулык.
«Гөнаһ» баржалары тагылалар
безнең койрыкка да тау булып,

Сөйрәү читен. Үзе «ут хәвефле».
Ләкин саклап яга белгәндә
бу гомернең салкын минутларын
Җылытып була «гөнаһ» белән дә...

Соң ни өчен ясала буксирлар
Һәм ни өчен буыла иделләр? —
Чөнки безнең «гөнаһ» баржалары
ансыз комга утырыр иделәр...

...Юк! Тарихның ачы сабагы бар:
Явыз Иван биләп Казанны,
уңдырышлы Идел буйларыннан
еракларга куды татарны.

Шуннан бирле, әлегәчә, безнең
ничә буын ата-бабалар
Иделеннән — гүя хәләл ана
Сөтләреннән мәхрүм балалар...

Күрдек, дошман гөнаһ шомлыгына
каршы, бүген Идел буылды:
авылларын су баскан урыслар
Идел буйларыннан юылды.

*1970*

## Англиядә сарык бәете бармы?

*«Сарыклар кеше башын ашадылар.»*

Англиядә тарихи әйтем

Күп бәетләр арасында
«Кәҗә бәете» дә бар...
Сарыкның кылган эше дә
бер бәетлек кенә бар,

монпан ике йөз ел элек,
бүре еккыры, Сарык
«Кеше ашаучы» титулын
йөри башлады тагып.

Кәбестә-фәлән урлаучы
кәҗә аңар тиңмени!
Инглиз! Кеше башы соң
кәбестәдән киммени?!

Язчы бер бәет, хезмәткә[1]
хокукың искә алып!
Шекспирың, Байронның бар —
син дә бит шагыйрь халык!

*1955*

## Дуслык файдасы

Таныш сатучыдан алган
сукноны илттем кире.
Мәйтәм, дуслык шул буламы,—
күр, менә черген җире!

Әйтте ул: шуның өчен мин
саттым да сиңа,— диде,—
чит кешегә саткан булсам,
ул тетеп сүгәр иде...

*1979*

## «Арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит...»

— Врач иптәш! Терелтегез мине,
сездә генә калды ышаныч.
Ышаныч юк икән, «Бар!» — диегез,—
сезнең алдау — миңа юаныч.

«Нинди ауру?» — дисез. Аш бик үтә.
Атча эшлим. Җитез барышым да
ял иттерми куа, үз-үземнән
ризасызлык хисе артымда.

Менә шул нәләттән котылыр өчен
дару әзерләргә ни кирәк?
— Утын кирәк — иҗат арбаңны ват;
йөрәк үгезен суй — ит кирәк...

*1970*

---

[1] Англиядәге «Кеше хокукын яклаучы интернейшнл» оешмага файдалы бер иҗат эше тәкъдим итү теләге белән язылды. *Автор.*

* * *

— Нинди яшьлек очкынлана! — дисең,
шигырем турында син сүз башлап.
«Нинди картлык!» — дип уйлыйсың эчтән,
җыерчыкларыма күз ташлап.

Каршылык юк монда: тормыш яза
җыерчыклар белән тиремә,
тик шуларны күчерәм кәгазьгә мин, —
шулар әверелә шигъремә.

*1956*

## Кунак булдым

Мин кунакта якын бер дустымда.
Якын тоелды ул тагын да,
Чөнки исерткечнең тамчысын да
Ул куймаган иде табынга.

Чәй эчелде. Без урамга чыктык.
Күрәм: тротуарда — таза ир
Утыра. Һәм хәмер исе белән
Аңкып тора шуннан тирә-җир...

— Инвалид, — ди дустым, — алкоголик...
Ничек әрәм булган, күр, менә!
Кызганыч бит, диеп, биш сумлыкны
Салып китте тегенең бүрегенә.

Читкә карап, чыраемны сыттым.
Шундый бер хис үтте күңелдән:
Әйтерсең лә чебен килеп чыкты
Ул эчергән чәйнең төбеннән.

*1978*

## Тукайга

Мәрхүмнәрне җиңел мактавы, —
һәйкәл тирәләрен таптавы.

Гаеплибез шулай без бүген
сине изгән патша режимын.

Тик фәрештә түгел, кеше без:
үз чорыбыз һәм үз эшебез.

Син, әлбәттә, Тукай, беләсең
Казанны һәм Пләтән төрмәсен.

Тик бар бездә шундый бер исем,—
без беләбез, ә син белмисең.

Чөнки сине изгән ул чакта
яшәгән ул башка сыйфатта...

Сорадың син, ярлы татар, дип,—
кемнәр сиңа иман таккан? — дип.

Синең сатираңнан котылып,
иман әверелде культ булып.

Син утырып йөргән пар атың
үтсә иде чорлар арасын,—

Син кичерсәң иде культ чорын,
кая илтәр иде кучерың?..

«Нурлы Казан!..» Тик шул чагында
күрер идең нурсыз ягын да:

Сазың тынар иде кулыңда
көпә-көндез,— совет чорында.

Әйе, заманалар үзгәрә,
җиңел булмады шул безгә дә.

Үтә баштан авыр сәгатьләр:
бетәр безне кыскан сәбәпләр.

Җаваплылык кич тә, иртә дә
хәзер үзебезнең җилкәдә.

Без җиңәрбез соңгы алышта
үзебез хәким булып язмышка...

*1993*

*
* *

Ни кадәрле салкын булса
биекләрдә очкан чак,
шул кадәр якын шәһәрем,
андагы җылы кочак.

Яңра, моторым тавышы,
шәһәргә төш, анда йөр
һәм йоклаган гүзәлемнең
колагына бар да кер!

*
* *

Һаман басым ясыйм, файдалырак
итәр өчен тырышам гомерне;

галим кешеләр басым ясаган күк
алмаз итәр өчен күмерне.

*
* *

Тырышып җырлавыннан артистканың
кызды бите, гүя ут яна!
Тик пудралы борыны гына ап-ак
туңган кебек калды уртада.

## Лев Толстой фәлсәфәсе

Кыйнаучыны кызган! Сабыр кирәк.
Күгәрсә дә гәрчә күз төбең,
кара аңар: ничек газаплана —
өзелеп-өзелеп суга, мескенем!

*
* *

Шундый сөям мин синдәге
балалар табигатен,—
кулыңда уенчык булып
әверелү — ниятем.

*1977*

*
* *

Илһам! Ташламадың, картлыгымда
тагын кайттың миңа, канатым,
сугышларда улы югалып та,
кайткан кебек сагынып анасын.

Алып кайттың шигъри хуҗалыкка
кирәк булган барлык сүзләрне.
Тик күбесен нидер каплый әле
яшь каплаган кебек күзләрне...



# Нәҗибә Сафина

## Эх, сүз кирәк...

Корылыктан кипкән җир шикелле
Яргаланган бүген халык җаны.
Ярылганны тагы меңгә ярып
Көчәйтә ул безнең ярсуларны.

Коллык богауларын кылыч итеп,
Юкартканчы ышкыган ул бүген.
Кул-аякны кисә, әмма ләкин
Дошман телен түгел, хет син сүген.

Поп сакалын селкә-селкә сөйли.
Җанга кермәк була тагы баскын...
Богаулардан ачкыч ясар иде —
Күңелләрне ачмый тимер ачкыч.

Эх, сүз кирәк! Күпләр ышануы,
Инануы җитми торалар бит!
Башка вакыт сүздән күп нәрсә юк,
Кая киткән? Шагыйрь сорала бит!

Җыела да, тарала да мәйдан.
Эх, сүз кирәк!
Шагыйрь табыйк кайдан?
Вакытында сүз катучы юкка
Халык бүген ярдәм сорый Айдан...

Эх, сүз кирәк!!!
Ышандырырлык сүз!
Инандырырлык сүз!

Кайдан табыйк шагыйрь...
Шундый чакта исереп яткан шагыйрь
Аталырга тиеш түгел Шаһ-ир!

Эх... мәйданда халык аптыраган:
Инандырыр сүзе кирәк чакта
Хәмер эчеп аунап яткан
Шагыйрьләрең җирдә үзе хата.

---

Нәжибә САФИНА — *журналист, шагыйрә. Шигырьләре матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

## Утлы уй

*«Утны яндырмас өчен дә,*
*сүндермәс өчен дә сакларга кирәк»*

Әткәй нәсихәтеннән

Кайчакларда утны сүндермәскә
Мамыкларга төреп саклаганнар.
Утны, суны, телне һәм намусны
Һичкайчан да ләкин сатмаганнар.

Кайчакларда утны сүндермәскә
Утын булган кура-киртәләре.
Сәкесез һәм җир идәндә генә
Каршылаган Кеше иртәләрне.

Утны сүндермәскә шашып аккан
Елгаларны буып туктатканнар.
Кешеләрнең учагына түгел,
Бәгыренә шулай ут якканнар.

Наз белән бер, яз белән бер бит ул.
Тауларда бер, далада бер холык.
Учакта — бер, җанда — икенче ул,
Кызу янган утта һич тотен юк.

Саклый белсәң генә сүнә дә ут,
Саклый белсәң генә кабына ла!
Утны кеше түгел, ә кешедән
Саклар заман җитте, йә хода ла!

Суны бума — суның үз юлы бар.
Утка-суга мәңге табыналар.
...Саклый белмәгәнгә илсез, җирсез,
Җансыз калганнар да табылалар.

## Котлыйм

Чын бәхетле булу бармы?
Әллә уйнау гынамы?
Фәкать, шушы — бәхет, диеп
Әллә уйлау гынамы?

Җаның туктаусыз ялварып,
Күгәреп торса күңел,
Кояш та тутык икән,
Ай йөзе чытык икән.

Ертკаланган, ергаланган
Болыт кебек таралдым.
Тапталган, каралган җирдәй
Ахры инде каралдым.

Яраларны кат-кат бәйлим,
Тышка чыгармыйм канны.

Бәйне тотмый, битлек япмый —
Кая куярга җанны?

Бәхет даулый, бәхет юк.
Тәхет даулый, тәхет юк.
Әй бу тынгысыз җанны,
Тәки сатты бит данны.

Инде миннән көләләр.
Теләгемне беләләр.
Үрелмә, диләр, өскә —
Тотып торалар көчкә.

Күпме кирәк бәхет — ал,
Ләкин бәйдә, диләр, кал!
Чыгып бара җан — тотмыйм...
Бәйсезлек белән котлыйм.

## Беренче һәм соңгы

Әкиятләрнең ахыры әйбәт була.
Мәхәббәтнең — була фаҗига.
Язмышыңны кара, дигән сыман
Әкрен генә шуып ай чыга.

Минем мәхәббәтем авыр, зур ул.
Сыйдыралмый әллә йөрәгең?
Тик югалткач кына аңларсың син
Минем мәхәббәтнең кимәлен.

Тик соң булыр, кояш, ай шикелле
Урап-урап йөрмәм, белеп тор.
Минем сөю сиңа беренче һәм
Соңгы тапкыр яңгыраган җыр.

## Туктап тормый дөнья

Син сүгәсең мине ахмак, диеп.
Акыллым, дип, кайчак сүгәсең.
Мин кылмаган гөнаһларны ягып,
Күпме йөз суымны түгәсең.

Хыялыңны бәлки эшкә җигеп,
Фәрештә дә миннән ясыйсың.
Син дигәнчә түгел дөнья диеп,
Күпме колак итем ашыйсың.

Мин дигәнчә түгел дөнья, беләм.
Син дигәнчә әллә барамы???
Әнә бүген шуның өчен дә бит
Синең, минем дөньям яралы.

...Димәгәнчә, тоймаганча бара.
Сөймәгәнчә бара, бара бит...
Син дигәнчә, мин дигәнчә түгел,
Җанда синең кадәр яра бит.

Туктап тормый дөнья, бара бит...
...дөнья яра бит...

## Шагыйрьгә җавап

*Илне сутеп җыясы бар...*
М. Әгъләм

Халык исән булса, ил сүтелми.
Хаклык исән булса, ул кителми.
Халык җаны кыелмаган булса,
Ватан дигән исем хур ителми.

Илне сүттек дисең, җыясы бар.
Тарих таплы икән — җуясы бар.
Илне баскан җансыз гәүдәләргә
Зөррә-зөррә җаннар куясы бар.

Халык белән хаклык арасына
Тоз сипмәгез бөтәү ярасына.
Шул икене аерырга теләп,
Һаман шартлау, һаман Хиросима!

...Минем җанда бүген Хиросима —
Чират басып торам керосинга...

## Ничек ышаныйм?

Ышандым язларны синең
Йөрәк ялкының диеп.
Каршыларга чыктым аны
Бәйрәм күлмәгем киеп.

Ышандым назлы җилләрне
Синең сулышың диеп.
Башларымны юләр иттем
Җилләргә кушылып биеп.

Кояш чыкмас дип уйладым,
Таңда син уянмасаң,
Онытырсың дип уйладым,
Әгәр мин уйламасам.

Һәм... син киттең.
Шашып-ташып,
Килә дә китә язлар.
Җилләр исә, җанны кисә.
Җилләр кемнәрне...
...назлар.

Көн дә таңда басып җанга
Калка да чыга кояш.
Нидән шулкадәрле ачы,
Күзләрне өтә бу яшь?

Яз, кояш, җил — юк, син түгел.
Аларына ышандым.
Үзем үзем түгеләнә
Әйт соң,
Ничек ышаныйм?

*
* *

Җир кадәрле авыр икән сөю,
Ләкин тора үзе күчәрендә.
Әйләндерү өчен дүрт кыйблага
Җитми икән ялгыз көчләрең дә.

Дүрт кул кирәк икән тоту өчен,
Ике йөрәк кирәк кузгатырга.
Тыпырчынам — селкенми дә күчәр,
Һаман дан җырлыйлар кыз-батырга.

Җир кадәрле авыр икән сөю,
Җыр кадәрле моңлы, михнәтле.
Кеше гомере генә җитмидер шул
Аңлар өчен шундый хикмәтне.

Әй тырыштым булсын, диеп сөю.
Сөю булсын диеп — күпме көю...
Күчәр инде әйләнеп тә китте —
Дөньясыннан китәр вакыт җитте.

## Яфрак булыр көннәр бар

Ачыл, бөре, ачыл гына,
Ялкын йә салкын булса,
Яфрак диеп аталырга,
Яшәргә хакың булса.

Агачка тел булырсың да,
Җилгә салырсың сүзең.
Яңа бөрегә җан биреп,
Җиргә төшәрсең көзен.

Ачыл, бөре, бөтерелеп
Кала күрмә көзләргә!
Ак җилләргә җаның ачып,
Туры килер түзәргә.

Беләм ак җилләр холкын.
Мин дә буранлы ташкын.
Ак җилләр кочагына
Абайламыйча таштым.

Бөре! Мин — туң йөрәкне
Аңлый алырсыңмы соң?
...Җаным бит җил иркендә.
Буйсындыралмый кем дә...

Ачыл, бөре, ачыл, син
Мин дә бер ачылырмын.
Яфрак булыр көнемне
Уйлап бер басылырмын.



# Сәйдә Зыялы

## Гаеп

Мин гаепле!
Телне тешләткәндә
Эчкә йоттым тозлы канымны.
Йоттым канны...
Канга тончыкканда,
Әллә инде телсез калдыммы?

Мин гаепле!
Әче фәрманнарның
Аңласам да татлы ялганын,
Куллар чаптым... Алга чаптым... Чаптым...
Шул ялганны алдый алмадым.

Чаптырды да, чактырды да фәрман...
Үзәкләрне өзде телсезлек!
Телсез телем! Телдең телем-телем...
Җанда — иман, җанда — денсезлек.

Мең гаепле!
Денсезлектән качып,
Денсезлеккә һаман абынам...
Канлы телем! Калдың телем-телем,
Киләчәккә инде табынам.

## Миләшләр

Табигатьнең күзе,
Су өсләре — күзге.
Күңел генә гел яшь, гел яшьнәр...
Күзләреңне алма:
Таң чыгыдай яна
Тәлгәш-тәлгәш кызыл миләшләр.

Табигатьнең күзе
Үзәкләрне өзде...

---

Сәйдә ЗЫЯЛЫ (Зыятдинова) — *шагыйрә, проза әсәрләре дә яза. Берничә китап авторы. Казанда яши.*

Мәхәббәткә нигә киңәшләр?
Йөрәккәем яна,
Утлы тамчы тама —
Тәлгәш-тәлгәш кызыл миләштән.

Гомеркәйнең көзе...
Йөрәккәем сиздә.
Мәхәббәтем сүнмәс, гел яшәр.
Таң чыклары янсын,
Кулларыңа ал син!
Тәлгәш-тәлгәш кызыл миләшләр.

Табигатьнең көзе.
Һәр сагышлы сүзе
Сөюемә, ахры, тиңдәшләр.
Йөрәк ничек түзәр?
Әйтелмәгән сүзләр —
Тәлгәш-тәлгәш утлы миләшләр...

## Онытмадым

Бер гөнаһсыз яшьлек вәгъдәләрем!
Мин бит сезне онытмадым.
Сезгә булган тугрылыкны саклап...
Гөнаһларга юлыкканмын.

Юлларыма чыккан игелекләр!
Мин бит сезне онытмадым.
Егылганга кул сузуның җаен
Бары сездән отып калдым.

Сөенечләр тулы бәхетләрем!
Мин бит сезне онытмадым.
Уйда сез яңаргач, ап-ак төстә,
Хәтта кайгы болытларым.

# АТАДАН БАЛА ЯШЬ КАЛА



*Рәсемдә:* **Һ. Такташ, Г. Минский, Г. Кутуй.**

Әдәбиятта шундый сихерле шәхесләр була ки: чоры белән бергә калыккан, бергә үскән — үз чорының баласы. Шул чорга килеп кагылдыңмы, аны читләтеп үтеп булмый.

Әнә шундый искитмәле фигураларның берсе — Кутуй. Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев. Тумышы белән элеккеге Саратов губернасыннан (хәзерге Пенза өлкәсе). Хәсән ага Туфан әйтмешли, «безнең мишәр — Пенза мишәре». Хәсән ага Такташ турында да «безнең мишәр — Тамбов мишәре» дия иде. Нәҗми хакында да шундый сүзләре хәтердә. Чыннан да, яңа әдәбият — совет әдәбиятының башында торган бу мишәр егетләренә сокланмый мөмкин түгел. Алардагы елгырлык, өлгерлек, дөнья вә урыс шигъри хәрәкәтен яхшы белүләре безгә дә үрнәк булырлык.

Шул хәрәкәт эчендә — Кутуй. Бүгенге күзлектән караганда язганнары артык зур игътибарга лаек та түгел сыман... Алай дисәң, «Тапшырылмаган хатлар» (1935) бөтен дөньяны урап чыкты. Туган телендә унлап, урыс телендә егермеләп басма күрде. Инглиз, француз, гарәп, корея, албан, монгол, вьетнам, чех, казакъ, үзбәк, кыргыз, чуваш, мари һ. б. дистәләгән халыкларның әдәбият сөючеләренә эстетик ләззәт, рухи тәрбия бирде.

Без еш кына, әйткән сүзебезнең асылын уйлап бетермичә, мәгънәсез тәгъбирләр ычкындырабыз:

Имеш, Җәлил, «Алтынчәч»не генә язган булса да...

Имеш, Кутуй «Тапшырылмаган хатлар»ны гына язган булса да...

Алай булмый ул, каләмдәшләр! Шәхес бөтен вакыйклары, көндәлек мәшәкатьләре, иҗади торгынлыгы һәм күтәрелеш мизгелләре белән бер бөтен. Бигрәк тә, Кутуй кебек, әдәбият тарихында тирән эз калдырган, аласы биеклекләре әле алда булган кабатланмас шәхеснең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнгәндә ихтирам һәм игътибар белән карарга кирәк:

Көн — кадак.
Тормыш — чүкеч.
Без —
        Кеше!
Бәр чүкечне.
    Сал кадакка,
    Нык — төшер!

*«Көн — кадак». 1925.*

Бу — шигырьдә яңа эра ачарга килгән футурист Кутуй.

Шул чорда бергә кайнаган Минский, Туфан, Ишморатлар белән янәшә яшәү бәхете эләкте миңа. Сүз Кутуй турында башланып китте исә, йөзләре нурланып, күзләре балкып китә иде. Ул — алар өчен бомба булган. Алар шул шартлау дулкыны белән күтәрелгәннәр, яшәгәннәр. Риза ага Ишморат — Кутуйның яшьтәше. Яшьтәше генә түгел, икесе дә бер айда туганнар — ноябрьдә. Аралары да тулыр-тулмас бер ай гына — егерме җиде көн.

Берсенең туган көне 1903 елның 1 ноябре...

Кутуйның — 28 ноябрь.

Һәм бу ике яшьти — берсе футурист мишәр, икенчесе дөньяви тип-тәр — беренче очрашканда ук «мөгез чыгарырга» әзер булганнар.

Бу очрашуга сәбәпче шул ук Уфа, аның барлык тамашачыларын таң калдырып, зур осталык белән декламацияләр сөйләп йөргән Габдулла Вилданов. Затлы кызларга, сәхнәгә, бөтен дөньяга гашыйк зат. Бу хакта Риза агай болай хәбәр бирә:

«Ул миңа үзенең юлдаш дустын тәкъдим итеп:

— Таныш бул, бу иптәш бүгенге әдәбиятыбызны әйдәп баручыларның берсе — шагыйрь Кутуй була. Укыганың бардыр?

— Юк, кызганычка каршы, укыганым юк,— дим, Кутуйга кул биреп.

— Зарар юк, укыр әле, укыр,— ди Кутуй, ялкынлы күзләрен текәп һәм кулымны каты гына кысып.

— Шагыйрь һәм артист Риза Ишморат! — дип тәкъдим итәләр.

— Шаяртмагыз! — дим уңайсызланып.

— Бүгенгә әле шагыйрь дә, артист та булып өлгереп җитмәгәнсез икән, бер дә борчылма, Казан ул, җаным, өлгертәчәк сине. Шагыйрь итеп тә, артист итеп тә, бик тырышсаң әгәр, нинди булса да берәр өлкәдә «мөгезле шайтан» итеп тә.

— Мөгезле шайтан?!

— Курыкма, дус кеше,— ди Кутуй,— Казан кадәр Казанга килгәнсең икән инде, берәр өлкәдә мөгез чыгармыйча булмый. Бигрәк тә бүген. Чөнки көннәре шундый. Шигырьнең дә, театрның да мөгезләрәге кирәк, үткенрәге...»

Бу — нәкъ Кутуй үзе. Егерменче еллар Кутуе. Биредә шуны да искә алырга кирәк, Гаделша 9 яшеннән урыс мәктәбендә укып, урыс тәрбиясе ала. 1912 елда әтисе Нурмөхәммәт абзый, гаиләсе белән Самара губернасындагы Алексеевск авылына күчеп, Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Ул биредә урыс мәктәбендә укый. 1917 елда Самара шәһәренә күчеп килгәч тә танылган рус язучысы Александр Неверовның әдәби түгәрәгенә йөри, беренче шигырьләрен урысча яза, ныклап торып шул еллардагы яңа поэзия, бигрәк тә Маяковскийның иҗаты белән якыннан таныша.

Әмма аны мишәрлеге, үз халкына хезмәт итәргә чакыруы, 1920 елда — 17 яшендә Казанга алып килә.

1924 елда ул «Көннәр йөгергәндә» исемле футуристик шигырьләр китабын чыгара. Сүзләре татарча булса да, бу китаптагы тезмәләр буталчык бер чүп өемен хәтерләтә.

1925 елда алар Ишморат, Әсгать Мәҗит белән берлектә, ачык һавада «Бомба» театры оештыралар.

Кутуй ул елларда һәркөн хәрәкәттә, аның белмәгәне, күрмәгәне юк. Ул һәммәсен белә.

Ул һәммәсен белә, дигәннән, Татар театрының чын, тулы, намуслы тарихы язылганда егерменче, утызынчы елларны Кутуйдан башка күз алдына да китереп булмый. Беренче мәртәбә куелган бөтен тамашаларга ул бәяләмә язып барган. Ул бәяләмәләр ташка басылган хәлдә Татарстанның көндәлек матбугатында калган. Мин әле «20—30 нчы еллар. Татар театры һәм Кутуй» дигән темага фәнни хезмәт тә язылыр дип уйлыйм.

Большевистик җиңүләргә чакырып,
Син калыктың дөнья өстенә.
Бәхет өчен, якты тормыш өчен
Җырлар ява Синең өстеңә.
*«Сталинга сәлам»*. *1939*.

Бу юлларның авторы да — Кутуй. Әмма, бүгенге көн күзлегеннән карап, биредә ирен чите белән генә мәсхәрәле елмаймаска кирәк. Борын-борын заманнарда ук мәшһүр шагыйрьләр бөек әсәрләрен фәлән-фәлән ханга багышлаганнар. Шагыйрь иҗатының әдәби кыйммәтен багышлау билгеләми. Шәхеснең әдәби хәрәкәттә калдырганын берничә зур әсәре билгели. Хәтта эш күләмдә дә тормый.

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күнелдә син һәрчакта.
*«Туган ил».*

*(Хәрәкәттәге армия. Берлин юлы. 1944).*

Бу юлларны, шагыйрь белән бергә, хәрәкәттәге армиядә барган кайсы татар солдаты гына кабатламады икән?! Ә чәчмә шигырь — нәсер белән язылган «Сагыну» әсәре?

«Сагындым, бик сагындым сине, туган ил! Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җинүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен Берлинга ашыгам. Берлинга мин илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм.

Иле ямьсез, суы тәмсез,
Өйгә кайтасым килә! —

дип җырлыйм мин.

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төер тыгыла. Мин төерне йота-йота җавап язам:

Телеграм баганасы — олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз — сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил.

...Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

*«Сагыну» 1944.*

Хәтеремдә, балачакта шушы нәсерне күңелдән укыганда, ут-суларны кичеп кайткан, балалар алдында күз-яшь күрсәтмәгән әткәй йөзен каплап үкси иде. Әйтә куя иде:

— Әнә шул ышаныч харап иткән инде аны. Сугышта үз-үзеңә артык ышану — иң куркынычы. Мин әле авылга — өйгә кайтып кергәч тә берничә ай ышанмадым. Шулай да көчле язган, соңгы сулышы белән, бәгырьдән өзеп алып...

Әйе, 1944 елны Кутуй язган шушы нәсер генә булмаса да, без никадәр ярлы булыр идек.

Әдип 1944 елны Казанга вакытлыча иҗади ялга кайта. Шул кыска гына вакыт эчендә дә ул «Рәстәм маҗаралары» исемле фантастик әсәр язарга өлгерә. Бу әсәрне инде әллә ничә буын укып үсте. Аның әдәби дәрәҗәсе, кыйммәте хакында сөйләшү артык. Гадел Кутуйга кадәр моңа охшашлы фантастик әсәрләр дөнья әдәбиятында байтак. Кутуй аның кайсын өлге итеп алгандыр, монысы билгечләр эше. Әмма биредә маҗараларның төп герое — Рәстәм.

Рәстәм Кутуй...

Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев — урыс мәктәбендә укып, беренче шигырьләрен шул телдә язып, соңыннан Казанга килеп татар дөньясын шаулаткан шәхес.

Ә инде улы тәрбияне, нигездә, урыс дөньясы аша ала. Әтисенең ачы әдәби язмышын белгән кебек, бер генә сәяси төркемнәргә дә кушыл-

мыйча, бер генә төрле «изм»нарга да йөз тотмыйча, үз юлы белән бара. Кайчагында уйлап куям — әтисе эшләргә тиешле йөкне күтәрә бара, лабаса!

1965 елны бер төркем студентлар Ленинградка бардык. Эрмитажда йөргәндә, безнең Казаннан икәнне белгәч, бездән сорашалар:

— Как там наш Кутуй?

...Бу сүзләр мине бик тә уйландырды. Шуңа кадәр кулыма да алмаган Рөстәм Кутуйны укый башладым. Урыс телендә язучы татар язучысы икән лә бит ул. Ул чакта ук инде мин Хәсән ага Туфан аша аксакалларыбыз белән аралашып яши идем. Алар, ни хикмәттер, Рөстәм Кутуйны таныырга теләмәделәр.

Ә бит казакъ халкы Оджас Сөләйманын урысча яза дип тормады.

Ә Фазыл Искәндәр...

Ә Чыңгыз Айтматов...

Без әнә шулай Кутуйларны югалтып, котсыз калдык. Кутуйның тамыры — кот, котлы...

Мин ике чор әдибе — ике Кутуйны бербөтен итеп кабул итәм. Берсе заман колы, икенчесе коллыктан азат булырга, бәйсезлек алырга теләгән өлеш.

Рөстәмнең әтисенә 90 яшь булыр иде. Аның яшьтәше Риза ага Ишморат әле яши, иҗат итә.

Аккош күлендәге урманда без Рөстәм Кутуй белән янәшә яшибез. Бу хакта еш кына әңгәмә дә куертып алабыз.

Уйлап та куям: элек нәсел, тамыр дәвам иткән. Хәзер инде балта белән чабылган. Котлылар Рөстәмнән соң бетәр сыман. Котсызлар гына калыр микәнни? Кикимора телендә язсалар да, нәселнең асылын югалтмаска иде бит.

Гадел Кутуй...

Рөстәм Кутуй...

Аталы-уллы ике зур шәхесне уйлаганда, бабалары Нурмөхәммәт агай җырлый торган җыр хәтергә килә. (Сибгат ага Хәким шулай сөйли иде):

Атадан бала яшь кала,
Бик күп эшләр башкара.

Рөстәм Кутуй әнә шул татар җырыннан яралган урысча язучы әдип тә инде.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ**

**Рөстәм Кутуй**

# ИМӘНЛЕК

хикәя

Йөз ел торуына карамастан, ул йортның кыйшаймаганына, нигезенә иңмәвенә, искереп яшелләнмәгәненә, йомычкага әйләнеп коелып тешмәвенә ышанасы килми иде. Агач корты тишкәләп, нәкышләп бетерсә дә, урынында ипле генә утыра да утыра. Аның теге ягында карлыган белән кура җиләге басып киткән бакча бар. Куаклыклары шул тиклем куедыр ки, җил дә үтәли исә алмый, кирегә чигенә.

— Әүвәле монда шифаханә булган,— ди иде әни.— Бөтенесе шул чактагыча.

— Сиңа гына шулай тоеладыр,— дидем мин.

— Беләм инде. Әнә, имәнлегеннә генә кара син аның.

Имәннәр исә еракларга таба җәелеп киткән кырлар иркенлегенә сөялеп торалар кебек иде. Җиде чакырым ары барсаң, аэродромга килеп төртеләсең. Андагы очкычлар уенчык сыман гына күренеп торалар. Ара-тирә нидер ялтырап куйгалый. Ә мин шуннан шифаханә «арбасына» утырып килгән идем.

— Берәр атна торып кит, хәл ал,— диде әни.— Бөтен җәй буена, көзгә хәтле калсаң да ярый. Кызын инде, шундый җайдан ничек качмакчы буласың син? Андый мөмкинлек һаман саен чыгып тормас. Ыгы-зыгы чәйнәп йотачак сине. Ел тәүлеге көтеп тормый — үтә дә китә. Аннары инде, ашык-пошык яшәлде, дип үкенүдән ни мәгънә.

— Шулайдыр инде, шулайдыр.

— Кая ашыгасың? Әнкәң исән-сау чагында иркенләп йөреп, кинәнеп һава сулап кал ичмасам. Ә син каядыр атлыгасың, кая икәнен үзең дә белмисең. Бөтенесен җыярсың да бит, ә яшьлегең үтеп киткән булыр.

— Шулаен шулай да бит...

— Ярар, мин китим инде. Әнә, икенче ачкычны калдырам — ал. Чиркәүне карап чык. Теләсәң, теге очта агач мәчет тә бар.

Ул, шулай итеп, мине яшел иркенлектә яшәп торырга кыстады да кыстады.

Ул чыгып киткәч, аның аяк тавышлары тынганчы тыңлап калдым. Төш кургәндә ыңгырашкан кебек итеп, баскыч басмалары шыгырдап алды, аста шапылдап ишек ябылды.

... Әни көтмәгәндә, кинәт картаеп китте шул, иңбашы салынып төште, адымнары авырайды. Ыгы-зыгыны әйләнеп уза торган булып китте, юлында, әллә нәрсәгә бүленеп, хәл ала торган булды. Андый чакларда ул, нишләгәнен яшерергә теләп, әйтик, ниндидер бер күбәләккә сокланган булып кылана.

Картлыкка таба аны пенсиягә чыгуы ашыктырып җибәрде бугай. Югыйсә йөгереп йөргән булыр иде әле. Иртәләрен көзге тирәсендә чуалыр, бизәнер-ясаныр, үзенә кызыксынып караудан туймас иде. Шуңа күрәдер инде, бер ара эшләп алырга булды ул. «Ичмаса авыл сөте эчкәләрмен,— диде.— Ни дисәң дә, тансык нәрсә.»

Без шәһәрдә аерым-аерым тора идек. Минем гаиләмдә эшләр пешмәде — әллә ничек килеп чыкмады шунда. Әрләш-талаш озаккарак китте. Әни минем бер канатымны сынганга саный. Ярар, ул кадәр дә коточарлык бөла түгел, дип фикер йөртте ул. Узар да китәр, җир дә ярык-ерыксыз булмый. Һәммәсен вакыт дәвалар әле, янәсе.

Әни озын-озак итеп, бер үк нәрсәләрне инәсеннән-җебенә тиклем санап, кайта-кайта сөйли торган булып китте. Әйтерсең лә берәмтекләп ашлык бөртекләрен аралый. Без сирәк — атнасына бер-ике генә мәртәбә очрашып сөйләшәбез, әрепләшмибез. Кайвакыт мин аның янында инде бездән читләшкән хатынымны — хәзер көлке бер чит хатын-кыз гына булып тоелган Динараны очраштыргалыйм. Өчәүләшеп чәй эчкәлибез. Читтән караганда нәкъ әүвәлгечә, һәммәсе ал да гөл кебек. Тик мин, әнинең күзенә әкертен генә җыела башлаган күз яшьләрен чамалап, тизрәк саубуллашу ягын карыйм. Ә хатын, шул мәлне йөзен сарган җыерчыкларын яшереп, тәрәзәгә борыла, муенындагы гәрәбәләрен тәгәрәткәләргә керешә.

Сәер, алар һаман дусларча мөнәсәбәттә, каза кичергән сыман, берберсен кызганышалар. Шуңа күрәдер инде, әни миңа кайвакытны «бәхетсезкәем» дип әйткәли. «Әнә, минем бәхетсезкәем килеп чыкты әле! Аркасына капчык астырып, үз бәхетен эзләргә чыгарып җибәрәсе дә бит... Бәлки, тапканыннан миңа пай чыгарыр әле. Бөтенебезгә җитүе ихтимал бит — хатынына да, әнкәсенә дә. Карасана, ә! Тормышына газап җитми, имеш. Бәхетсезгә берни җитми инде — койма корса, бәдрәфен ясарга онытыр, ә кышын суык куырып алгач, тактасын тапмас...»

Мин хәлне артык катлауландырмаска өйрәндем инде. Менә хәзер дә тупырдап өлгергән слива алып килдем. Тәлинкәдә көлеп, тәгәрәшеп ята табигать хәзинәсе. Тәмләп ашасыннар, шифасы тисен. Һичкемгә үчфәлән тотмыйм. Дөрес, мондый хәлнең күптәннән булганы юк иде инде. Бәлки, шуны истә тотыптыр, хатыным кинәнеп ашады.

— Эшеңдә ничек соң? — дип сорады ул.

— Бер көе, — дип җавап бирдем мин.

— Һаман шул — һәйкәлләр, истәлек-мазардыр белән мәш килеп йөрисеңме? Шулар өчен җан аткандай, шуларны саклагандай кыланып?

— Сакласам соң. Шуннан нәрсә? Мәдәният һәйкәлләре — алар мәңгелек нәрсәләр. Кеше гомеренең күләгәләре сыман.

— Беләм инде мин сине. Синең тырышлыгыңнан башка кая китәрләр димсең? Урлап китмәсләр иде әле. Шуңа күрә дә һәйкәлләр ич инде алар.

— Син менә кешеләрне дәвалыйсың инде, әйеме? Бер җирләреннән майласаң, икенче төшләреннән тишелеп чыга. Бар белгәнең — аларга микроблар турында сөйләү.

— Үз микробларыңны бел, яме? Аларны синнән конфет белән алдалап та чыгарып булмастыр... Ә һәйкәлләрең өчен күпме аласың соң?

— Йөз дә кырык тәңкә, — дидем мин.

— Бер дә кинәнерлек түгел шул. Мин үзем дә шул чама дип уйлаган идем.

Безнең Ирек атлы улыбыз бар. Аңа җиде яшь инде. Ярар, миннән башка да югалып калмас әле. Менә мин үзем, хатын уйлаганча, эшемә ябышып ятсам да, атасыз юкка чыкмадым ич. Эш — бәйсезлек дигән сүз ул. Ә инде әнинең «бәхетсезкәй» дигәненә һич үпкәм юк. Пәхтә, ыспай киенеп йөрсәм дә, кызгана икән — кызгансын инде. Әнә, ләгән сатып алдым, үземнекен үзем юып үтүклим. Теге һәйкәлләр, истәлекле йортмазарлар мине үз туганнары урынына күреп яратадыр кебек тоям. Миңа аларның һәркайсы билгеле, саны санга исәпләп куелган. Әледән-әле караштырып йөргәлим. Кайсылары авып төшәргә, җимерелергә тора, ә кайсыларына ниндидер оешмалар күз салып куйган: ничек тә йә алып ташлый, йә сүтеп, алар урынына үзләренә кирәкне корып куймакчылар. Ә мин, җүләр, шуларның берәрсенә куркынычмы, афәтме янаганын сизүем белән дөрләп кабынам да газеталарга хәбәр салган булам тагын. Шуңа күрә менә шушындый хәлгә тарыганмындыр да инде. Әле ярый торып торыр җирем бар, бер дустым Африкага китәргә җыена, әлегә менә шуның фатирында караватт шыгырдатып ятам.

— Минем эшемә акча күзеннән генә карама син,— дим хатынга, башланган сүзне дәвам итеп.— Мин, кем әйтмешли, киләсе буыннарны кайгыртып йөрим ләбаса.

— Ә үз «буын»ыңның туфли үкчәсе кыйшайганын беләсеңме соң син? Бу хәтле дә төзәлмәс киребеткән булырсың икән, ә? Сиңа тагын бер тапкыр гыйшык тотарлык, билләһи!

— Менә монысы булмас инде, кирәкмәс! Тагын бер истәлек һәйкәленнән башка да җитеп торыр.

— Шаяртуың — елан чагу белән бер!

— Ул чагында сине дәваларга кирәк булачак ич. Тузган, туздырылган һәйкәлне тергезгән шикелле. Ә монын өчен күпме цемент, алебастр, битум кирәген беләсеңме?

— И-и, шушы теленне!.. Улың да чат үзен ише: дәшми-тынмый йөри-йөри, дә, күзен чекерәйтеп, мең яшәгән карт шикелле бер әйтә дә сала.

Шунда әни килеп чыга да, мин баскыч төбенә чыгып баскан атлы кыланып, әкрен-әкрен генә таям инде.

Бер-беребезне тәрбияли-тәрбияли шулайрак яшәп ятмышбыз. Ә тәртеп торган ботакларга беренче булып кайсыбыз балта чабар икән соң?

Әгәр дә яшьлектә саграк кылансаң, саклансаң, жиде үлчәп, бер киссәң, як-ягыңа карансаң, гаилә корып маташмас идең дә бит. Ә без, унтугыз яшьтән бер-беребезне этә-төртә дигәндәй, шуңа әзерләндек. Менә, бара торгач, килеп төртелдек тә инде.

— Хәзергә, сөеклем! — дигән булам мин чыгып киткәндә.

— Исән-сау яшә, кадерлем! — дип котырта хатын да.— Микробларыңнан ничек тә үзең котыла күр инде.

Сөйләшүебезгә хәтле төртмәле бит, каһәр!

Бер заманны мин төшемлерәк бер урында эшләп алган идем. Һаман да шул бәйсезлек дигән нәрсәне эстәп. Ә Динара, карасам, кесәне тап-такыр калдырып сиберен чыккан. Янәсе, миңа шулай җиңелрәк, иркенләбрәк суларга кулай, барыбер башым бурычтан чыкканы юк.

— Кулыңнан килсә, әйбәт кенә хезмәт хакы эшлә, шабашник! — дип куйды бу миңа.

Нишләсәң дә ярап бетәрлек түгел: тапканым — әз, кирәк-ярак житешми. Тозлы балык кабып, чәй эчкән шикелле.

Динара әнигә дә:

— Нишләргә дә белгән юк инде,— дип зарлангалады.

— Ә мин сугыштан соң өч бала карап үстердем,— диде әни.— Җелекләрем суырылды, аяк астында жир тоймадым.

— Сугышта бит ул,— диде аңа Динара.— Барына да бер авырлык төшә.

— Сугыштан соң дим ич әле... Ә аерылышуны уеңа да кертмә син, килен.

Ә мине гаепләүләреннән туймадылар: имеш, тырышмыйм, имеш, тапмыйм. Йөгәнсез үскәнгә, янәсе...

Әни еш кына уйчанланып калучан. Аның күңеле ел фасылларына бәйле.

Язын болай дигән иде:

— Кызыл ярга үз яшьлегемне карарга барам әле. Анда авыл борынча ат арбасында дисеңме, чанада дисеңме күпме йөрдем, юынганым тузан да кар иде. Исең китмәле: амбулаториядә яшәп яттым бит, әй! Ун кешегә житәрлекне мичәүләп тартырга туры килде. Кендек әбисе дә булдым, адәм балаларының күзләрен мәңгелеккә дә йомдыргаладым... Барып кайтыйм әле, туйганчы бер күреп калыйм. Бер сезон эшләп алудан укам коелмастыр, шәт. Аннары күз күрер тагын, улым. Динарага да әйтим дә...

— Аңа нигә хаҗәт ул? Шуның фатихасына калдыммыни?

— Мондый сүзләр ничек теленә килә торгандыр? Фатиха алыр яшьтән чыккан инде мин. Ни дисәң дә, Динара якын җан, медик. Оныгым Ирекне дә алам әле. Яңа сауган сөт эчәр ичмасам.

Шулай итеп, ул Ирекне ияртте дә китте дә барды. Ике атна чамасы үтте микән, малайны больницага кертеп салганнар. Кыздырылган көнбагышны чамасызрак чиртеп ташлаган. Динара аны шуннан йолып кайткан. Күз алдыма килә: әнә Динара, әнине эчтән генә әрли-әрли, улыбыз Ирекне самолетка утырта, ә үзенең итәгеннән куәтле май җиле ачып-ачып җибәрә.

Әни малайны яңа сауган сөт белән сыйлаган-сыйлавын, сүзендә торган. Шуңа күрә, әзрәк савыккач, Ирек аның янына җибәрүебезне сорады. Ничек каршы киләсең ди?

И, бу хатын-кызны әйтер идем: ир-аттагы бөтен иҗат рухын таптап үтәләр дә, кар дими, яңгыр дими, гел үзләренекен генә беләләр. Гаҗәбе шунда: әнинең хатлары һәр искән җил саен диярлек килә торды. Түзмәдем, җилдәй очып, килдем дә төштем.

— Бөтенесе тәртиптә! — дип каршы алды әнкәй.

— Мин сезгә капка чөе мәллә? — дип әйтеп ташладым мин.

Әни сүзсез калды. Хатларымны, каршы җавапларымны җыеп яккан да, шуның җылысында җылынып утырамыни, ә?

— Мин синең килгәнеңне өй түбәсеннән күреп тордым инде, — ди бу.

— Анда ничек менәсе иттең? — дип сорадым.

— Ә чарлакка менгерүче баскычны кая куясың? Теге заманнарда монда земский врач менгәләгән дә, еракны якын итеп күрсәтүче торбадан бөтен тирә-якны карап торган, дип сөйлиләр.

Шул ук көнне мин әйләнә-тирәне энәсеннән-җебенә тиклем карап чыктым. Шуның өстенә тегендә-монда йөргәләп тә килдем әле. Бер мәлне машина моторын төзәтеп маташкан кара-кучкыл шоферга юлыктым.

— Мине монда бөтен эт белә инде, — диде ул. — Менә, төзәтеп ятыш әле. Яздан бирле төзәтәм инде.

— Арымадыңмы соң?

— Арымаган кая ул? Аптыраган инде. Эшләми генә бит, каһәр! Сыер мае сөртсәң дә юк. Чамасын белсә Якуп кына белә.

— Анысы кем?

— Авырып ята. Аны минем яннан әнкәң куып җибәрә. Имеш, үзем генә өшәним. Мин өшәнәмме? Ә Якуп түзмәде, качып кайтып китте. Берәр җирдә җитешмәгән нәрсә күрдеме — чәчри дә чыга. Ә минем кай җирем җитмәгән? Казына-казына өч кат тирем кубып төште инде. Менә ич, яшим, маташтырам, тик ятканым юк. Ә син кичке якта кил, шәраб капкалап утырырбыз.

— Мин бит техниканың рәтен белмим шул, — дидем.

— Ул чагында бар, юлыңда бул. Кичен килеп кит, миңа ярдәмче кирәк.

Шуннан мин ары таба — алда агарып торган чиркәү тарафына кузгалдым. Минем эшкә кагыла бит — тарихи истәлек. Аның инде ташы сөмсәгән, төссезләнгән, анда-монда тишекләр каралып тора. Кувалда белән җимерергә дә тырышып караганнар, тик алдыра гына алмаганнар. Хәзер аны ашлык саклау урыны иткәннәр. Бөтен җирен симез күгәрченнәр сарып алган. Шул тиклем туклар ки, җирдә туп шикелле тәгәрәшеп кенә йөриләр. Әллә ничек — йокымсыраган кебек. Шундук бер ата мәче йоклап ята, боларга исе дә китми. Күрәсең, тегеләр тук булгач, бу да ач түгел инде.

Мондагы хәерчелеккә, хуҗасызлыкка төкердем дә авылның теге очындагы мәчет ягына юл тоттым. Беләм: анда тыныч, тәртип. Мәчет эшли иде, ишекләрендә йозак-фәлән юк. Гомер-гомердән шулай килгән, шулай барыр да. Түфлиемне салып, эчкә уздым, әллә күрделәр, әллә юк. Ишек төбендә чүәктер, галуштыр. Өскбаштан гына йомшак келәмнәргә

басып эчкәре уздым. Кысык тәрәзәләр көндезге нур белән тулы. Мәчетнең диварлары нык. Кипкән бүрәнәләр тавыш-мазар килгән саен зыңлап тора, һавасы күңелне иркәли.

Туберкулез хастаханәсе урнашкан биеклек төбендәге үзәнлектә инеш тирәли йөрендем. Хастаханәне сәрби куаклары уратып алган, тәрәзәләре яшеллек арасыннан ялтырашып торалар. Шул инеш буенча әлеге калкулыкны урап чыктым да хастаханәгә барып кердем. Әнинең анда күренергә ярамый дигән сүзләрен дә искә алмадым. Ә ул гел әйтә килде: «Шаярма. Монда кая барып төртелсәң дә, Кох микробларына килеп юлыгасың. Бу тирәне әйләнеп үтә торган бул, яме?»

Каршыма озын буйлы, төз гәүдәле бер карт килеп чыкты. Әледәнәле чәчен бармаклары белән тараштыргалый. Кулы кош канатыдай житез жилпенә. Мин аны күрүгә: «Нервылы ахрысы бу»,— дип уйлап куйган идем инде.

Миңа ике адым житәр-житмәстән бу:

— Сез — чит кеше,— дип эндәште.— Ахыры хәерле булсын, мин көч кулланганчы, таегыз моннан.

— Нигә алай дип әйтәсез әле? — дидем.

— Монда бит кая карама — авырулар. Алар беркем комачауламаганда гына тыныч яши алалар.

— Мин аларга комачаулыйммыни, ә? Бу хакта уйлаганым да юк иде.

— Сезне сәламәтлегегез тота. Ә авыруларны — врачлар гына.

Аның кашлары уйнаклап алды. Ул миңа әллә нинди бер биеклектән караш ташлады. Житмәсә, мускулларын да уйнаткалап алгандай итте.

— Мин берәүне эзли идем әле,— дидем, башка сүз тапмыйча.

Кистереп салгандай итеп кенә ул:

— Берәүне дә эзләү хажәт түгел,— диде...— Авырдың икән — беттең инде. Чит кешеләрнең нинди ярдәме тисен? Йөрмәгез монда. Акыллы булсагыз, әлбәттә. Койманың теге ягына чыгыгыз. Мин сезнең койма тактасын аралап кергәнегезне карап торган идем. Бу тиклем дә киребеткән булырсың икән. Оятың бармы синең, юкмы, ә?

— Якуп! — дигән тавыш иңде. Таныдым инде, әлбәттә: әни бу.

Якуп аның тарафына башын борып куйды, нык итеп йодрыклаган кулларын кесәсенә яшерде.

— Якуп! Бар, палатаңа кереп ят! Тыңламасаң, мин сине көн режимын тотмаганың өчен чыгарам да жибәрәм. Туйдырып бетердең инде!

Карт аңа әйләнеп карамады, ә бәлки шып туктады да күзен метмелдәтеп алды.

Аның янына ашыгып әни килеп басты.

— Сез иртән кайда идегез? — дип сорады ул.

— Минме? Почтага бардым. Әнә, апкайткан гәжитләрне тумбочкага куйдым.

— Сезгә ни калган анда? Кем кушты? Ә теге хатларны нигә ертып ташлыйсыз?

— Миңа килгән хатлар. Теләсә нишләтә алам.

— Шулай ярыймы инде? Тагын бер ертканыгызны күрсәм, дүрт ягыгыз кыйбла, яме? Үпкәләштән булмасын... Ә аннары кая югалдыгыз? Сезне күпме эзләп йөрергә була?

— Күл буенда идем мин. Әзрәк миңа да рөхсәтсез йөрергә ярыйдыр ич?

— Карагыз аны, ахыры хәерле булмас. Алырлар да китәрләр.

— Миңа барыбер, доктор. Кая алып китсеннәр ди мине? Кемгә хажәтем бар ди минем?

— Шулай дигән булыгыз инде, Якуп. Ә шофер Володя янында ни калган сезгә? Күрмисезмени, нәрсә эчкәнен дә белми ләбаса ул! Машинасын да шуңа күрә юри тартып-сузып төзәтә.

— Сез нәрсә, доктор! Мин авызыма да алмыйм ич! Алла сакласын!

— Барыгыз алайса, кереп китегез.

Якуп иңбашын сикертеп алды да кереп китте.

Ак халат, башлык кигәнгә күрә аны яшәреп киткәндәй күренә иде. Йөзе көндәлек мәшәкатьләрдән арынып, ачылып киткән. Үзем дә сизмәстән, кулымны аның иңбашына куйдым. Йөрәгемә тыныч ягымлылык сарылган шикелле булды.

— Якуп кем соң ул? — дип сорадым мин. — Нигә аның өчен шулкадәр борчыласың әле?

— Ни диим соң? Ярар, аннары сөйләрмен әле. Кичен, яме. Карының ачкандыр инде. Минем әзер анда. Менә хәзер бушыйм да... Син бар, керә тор.

Шунда мин тәрәзә пәрдәсе артыннан текәлгән сәер бер карашны сизеп алдым. Эсселе-суыклы булып киттем. Бу шул — Якуп иде. Карасана, ничек кызыксына, ә? Мине аның гәүдә торышы һәм башының горур куелышы сокландырды. Кашы йөзен әллә нинди көчле, куәтле итеп күрсәтә. Бая ук игътибар иткән идем инде: әңгәмәдәшенә ничектер тәкәббер төстә карап сөйләшә. Кыскасы, андыйлар хакында: «Үзен куя белә дә соң!» — диләр. Кулы һич тик тормас, әле чәчен сыйпар, әле маңгаен ышкыр, әле күкрәген кашыр. Нindидер түземсезлеге җанынnan ташып тора. Йөрешләрен кара син аның: җәлт тә җәлт, хәрәкәтсез калырга мәҗбүр булганда нишләрен белмичә аптырый.

Аның холкы һәм менә шушы күзәтүләрем хакында мин аннары — хастаханә капкасы төбендәге эскәмиядә утырган чакта уйландым. Әнине көтеп утыруым иде.

Көтмәгәндә яныма бер хатын-кыз килеп туктады. Искәрми дә калдым. Кап-кара чәчле, кырыс йөзле, ул күзләре!.. Зурдан зур инде!

— Сигарет бирмәссез микән? — диде ул.

Биргәнне дә көтмәстән, яныма килеп утырды. Бер-беребезне сынашып карап, бер мәлгә нинди сүз әйтергә аптырашып тордык. Гап-гади бер шатлыкка ирешәсемне сизендем. Әллә нинди бер яңарыш буласын тоеп алдым.

Кабызган шырпыга иелгәндә ул миңа тагын бер карап алды. Кабызган утым әйтерсең лә учыма алган бер кашык су иде: сүндерсәм, шул су әрәмгә түгелер сыман тоелды. Әни генә килеп өлгермәсен иде, дип теләдем.

— Мария атлы булам мин, — диде ул. — Сез Тимерша бит, докторның улы. Мине пырдымсыз дип уйламассыздыр ич?

— Яхшы, яхшы, — дидем мин. — Һич тә көтмәгән идем.

— Мин үзем дә шушында эшлим бит. Бүген ял көнем, — диде хатын.

Ул миннән өлкәнрәк яшьтә иде. Тәгаен, моның кулы бик җылыдыр, дип уйлап куйдым. Тавышы да күкрәгенең әллә кайсы тирәнлегеннән иркенәеп килә.

— Күпкә килдегезме соң? — дип сорады ул.

— Иң кимендә бер атна торачакмын.

Куркып киттем бит, әй! Ә бу минем кайда эшләгәнемне сорашрырга керешсә? Үземнең һәйкәлләр, истәлекле йортлар буенча белгеч икәнемне сөйләп торыйм микәнни? Күңелсез булачак бит, билләһи!

— Бүген әнә теге имәннәр төбенә килеп чыга алмыйсызмы соң? — дип сорады ул. — Әйтик, сәгать кичке алтылар чамасында.

Сизеп торам: яхшыдыр анда, яхшыдыр.

— Ярар, килермен, — дидем мин ашык-пошык кына.

«Яхшыдыр» дип уйладым да бит... Ә ул, шуны гына көткән сыман, торып басты да хастаханә коймасына таба атлап китте. Шулвакыт койма ишеге төбендә әни пәйда булды.

Имәнлек турында ул күзенә чалынганны гына әйткән булгандыр инде. Миңа шулай тоелды.

— Син ашадыңмы әле? — дип сорады әни. Ә минем өчен шушы хатын җавап бирде:

— Рәхмәт яусын инде сиңа,— диде Мария һәм әнинең башлыгын төзәтеп куйды. Әни кыскарак буйлы иде, шуңа күрә гомер йөге төялгән гәүдәсе саллырак булып күренде. Мин аның шушы Мария яшендәге чакларын күңелемдә яхшы хәтерлим әле. Әнинең иелә-бөгелә кое чыгырын әйләндергәне күз алдыма килә...

— Вареньелар әзерләргә вакыт, Мария,— диде ул.— Табакларыңны әзерли тор, яме? Монда кыш буена торасы бар бит әле, кызым, хәстәрен күреп кал.

— Шулай, шулай,— диде Мария.— Йокы да килә анысы. Тик җәен ничек йоклап ятмак кирәк?

— Бәлкем, миңа да кышка калырга туры килмәгәе әле,— диде әни. Бергә-бергә көн күрер идек әле шунда.

— И-и апа! Нинди яхшы булыр иде ул!— дип шатланды Мария.— Аягың туңа калса, минем тагын бер пар киез итегем бар.

— Ярар, алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди, юрамый торыйк әле.

Шул рәвешчә сөйләшеп алгач, алар аерылыштылар.

Салмак җил исә башлады. Өлгереп килгән кара карлыган исе таралды. Сулыш алулары рәхәт булып китте... Ә миңа Мария белән кышын да күңелсез булмас иде дер, дип уйладым мин кинәт. Утыны янып торган кайнар мич күз алдыма килеп басты. Әйтерсең лә яңа тормыш корырга ниятләгәнмен. Бер көнгә никадәр кичереш: әле Якуп, әле Мария...

Йөрәгем үземә ишетелерлек булып тибәргә кереште.

Әни мине шатландырырга, сокландырырга теләде, ахрысы: җир җиләге вареньесы, маринадланган гөмбәле банкалар бирде...

— Йөреп, күреп туйдыңмы инде?— дип сорады ул.

— Имәнлеккә барып килсәм, тәмам күңелем буласы.

— Анда кичләрен Мария белән Якуп йөрүчән. Аерым-аерым. Берсе бу башта, тегесе — каршы якта. Имәнлек ап-ачык бит, бөтенесе үтә күренеп тора. Володя гына машинасын төзәтә дә төзәтә, матурлыкка күзе төшәрлек түгел. Күзен хәмер белән тутыра да шундук ятып йоклый. Күңел күрмәсә, маңгай күзең генә күрми шул. Авырып та китми ичмаса.

— Нигә алай дисең әле? Син врач лабаса.

— Авыруның, чирнең төрлесе була аның. Хәтер, ялгызлык авырулары... Миңа калса, бөтенесен әнә шул имәнлек дәвалый алырдыр кебек. Бөтенесе син уйлаганча гади генә түгел шул, улым. Мин синең хакта да еш уйлангалыйм: кешене ниемә дип тинтерәтәсең, үзенә буйсындырырга телисеңдер инде, белмим. Динара хакында әйтүем. Кара аны, ялгыша күрмә.

— Тормыш шулай кушадыр инде, күрәсең.

— Кушмый шул, бер дә кушмый...

Әнинең ничектер үзгәреп калганын тоеп алдым. Сөйләнгән көйгә, кояш каралткан кулы белән өстәл эскәтерен тигезли. Күзе әллә ничек төссезләнеп киткән шикелле. Аны эчтән нидер бимазалый. Көйдерә дию түгел-түгелен.

— Җүн бирмәгәнгә җан бирмәс, дип тикмәгә генә әйтмиләр, күрәмсең...— дип, ни уйлаганын әйтеп бетерми калды. Крахмалланган ак башлыгын салгач, ул гап-гади булып, арыган-талчыккан, картайган булып күренде.

— Кем ул Якуп? Сөйлә әле.

— Үзгә бер кеше ул,— диде әни рәхәтләнеп киткәндәй.— Аны кыерсытырга ярамый. Монда күптәннән инде ул. Хатыны вафат булган. Үзендә әллә нинди бер гөнаһ йөрткән кеше шикеллерәк. Нәрсә икәне миңа билгесез. Кызы белән бергә торудан баш тарткан. Оныклары да шунда инде. Араларында нидер бар. Кызы килеп тә чыккан иде, тик ул аның белән артык сөйләшеп тормады. Кызына таянырлык түгел, күрәсең... Ул әзер инде.

— Нәрсәгә?

— Нәрсәгә булсын ди инде тагын — үлемгә,— дип җавап бирде әни исе китмичә.— Ул җитмешнең теге ягында инде. Җыенса да таман гына.

Балкон пәрдәсе әледән-әле кузгалып ала иде. Безне кемдер күзәтеп тора. Тәгаен шулай.

— Канәфер чәчәк атып утырганда монда үлүе дә күнелледер.

— Шуннан, шуннан? — дидем мин, түземсезләнеп.

— Монда кем китереп тыкканын беркем белми инде. Бүлмәсенә бикләнә дә беркемне кертми. Әллә кайларга кәгазьләр язып җибәргәли. Өчәр көн буена чыкмыйча ята. Андый чакларында аны ашарга да көчкә чакырып чыгаралар. Алдырсаң, ягымлылык белән генә алдыра аласың аны. Елның ел буена шулай яши...

— Алайса нигә азаплыйсыз соң аны? Комиссия төзеп, тагын бер тапкыр тикшерегез дә...

— Болай да ярый, улым, торсын, комачауламый ич. Үзең дә күргәнсеңдер: үз-үзен әллә ниткән башлык шикелле тота. Туберкулез анда, каверналары да начар күренә инде, томан шикелле. Кызы Нижгауда тора.

— Карт дисәң дә карт! — дип куйдым мин.

— Миңа берни кирәк түгел, ди. Бөтенесе үзе белән, имеш. Ә шактый белемле ул үзе. Архитектор булган. Ә тормышы — ташкүлчим... Күрерсең әле. Анда, аста, ташландык бер көймә бар, кайчан карама — шунда утыра. Әллә көймә коргаксып беткәнгә инде. Үпкәләре чирле һәр кеше кебек үк, ул юештән, дымнан курка.

— Нindидер сере бардыр әле,— дидем мин.— Шуны сиздерәсе килмидер. Безгә үз кайгыбыз гына кайгы бит.

— Үзеңә карап әйтүеңме?

— Үземә дә. Ярамый мәллә?

— Ә Динара? Ирек? Аларны уйлыйсыңмы? Белми бу димә: ул миңа язып тора.

— Ышанмыйм,— дидем мин өстәл яныннан кузгалып.— Якуптан башладык та мине тикшерергә тотындык. Мин дә кеше ләбаса. Ә Динара... аңа бүтән кеше хаҗәт шикелле. Хатыннарның бөтенесе үзләренә боерып торучыларны ярата. Көч белән хакимлек итүчеләрне.

— Хаталанасың син. Мин дә атаң белән җәфаланган идем. Аннан нинди солдат чыксын да, ничек итеп кешегә атсын ди инде ул? Аның хәтле дә оялчан кеше дөньясында бер-ике генә булгандыр. Тиешенчә һәлак булмаудан да оялгандыр әле, «мин менә шундый заттан инде» дип уйлагандыр. Ядрә сайлап торамыни ул?..

— Ул күптәннән юк инде,— дидем мин.— Суга төшеп югалган шикелле генә булды.

— Телеңне тыяр идең ичмасам... Син Мария белән ни хакта сүз куертып утырдың? — дип сорады ул кинәттән, уйламаган-нитмәгәндә.— Юк-бардыр инде.

— Әйе, җыен юк-бар,— дидем мин, килешеп. Шулай әйтүемне көтеп тора бит әнә.

— Аннан берәр бәла чыгасын көтә тә тор,— диде ул уйчан кыяфәттә.— Андыйлардан теләсә ни көтәргә була. Боерса, агачны бөгәрдәй тәвәккәл нәрсә ул.

Мине алда ни буласы түземсезләндерә иде инде. Кайчакны билгесез нәрсә дә тансык. Тәрәзәдән имәнлеккә күз ташладым. Агач арасындагы үләннәр талгын гына тирбәлә иде. Аларның сусыллыгы, куелыгы моннан ук күренеп тора. Кәүсәләр арасында Мария белән икебезнең йөрүебез күз алдыма килде. Битебезне саф һава иркәли сыман иде.

— Башыңны югалта күрмә, кара аны,— диде әни уемны үтәли күргәндәй.— Адашма диюем, адашма. Якуп та адаштыргалый. Монда бөтенесе ихтимал. Якыннан гына бөтен җир уч төбендәгедәй күренә ул. Ары китә башласаң, табылырмын димә. Китап укып утыруың хәерлерәк. Әнә, җиләк аша. Юкка-барга аяк итеңне әрәм итеп йөрмә.

Ул имәнлеккә мин кояш баеганда гына барып чыктым. Агач ябалдашларыннан ычкынырга теләмәгәндәй, кояш офыкка авырлык белән генә якыная шикелле. Анда-санда кошлар сайраштыргалый иде. Имәнлек шундый иркен, үзеңне җирдән күтәрелгәндәй сизәсең. Чыннан да, монда беркая да посарлык түгел.

Мин үр ягына борылып карадым да хәйран калдым: борынгы хастаханә, бөтен тәрәзәләре белән балкып, алсу төскә манчылып утыра. Һәм шул балкыштан сукмак буенча Мариянең төшеп килгәнен шәйләп алдым. Куаклар арасыннан килеп чыкты да имәнлек иркенлегенә чумды.

Ул якынайган саен, мин аның җитез хәрәкәтләре дулкынына ияргән кебек булдым. Әйтерсең лә аның тирәсенә барча җилләр җыелган да, ул текәлектән төшкән арада барча яктан егылмаска булышып торалар. Ак кофта һәм кара юбка кигән, яшеллектә кайнар ялкындай янып, карашны биләп тота, үзенә таба әйди. Чыннан да, әллә ниткән бәйрәмчә бер ыспайлыгы белән ул күтелмәгән бер күренешне хәтерләтә иде. Мине күреп, тукталып калды.

Тәгаен, иртәгә безнең бу очрашуыбыз хакында сүз китә дә китә инде.

Аның күләгәсе, үлән өсләтеп, миңа таба якынайганнан-якыная барды. «Булса да булыр, ә? Көтмәгән-нитмәгәндә...»

— Төгәл кеше икәнсез сез,— диде Мария. Тиз-тиз генә шуны алдан ук теләп куйган төсле, өстәп тә куйды: — Без югартыннан шәрран ачык күренеп торабыз инде! Тел чәйнәү китә-әр... Миңа нәрсә: ялгыз башым, күнегелгән. Ә менә әниегез әрнидер. Ул миңа сезнең хакта, беләсезме, күпме сөйләде инде? Контор кенәгәсен ачып куй да хет роман язарга тотын.

— Әрләпме?

— Юк, борчыла ул. Мин тыңлыйм инде. Хатыныгыз хакында да. Сезне күрсәм, шушы имәнлеккә очрашуга чакырмый калмам дип, әллә ничә тапкыр уйладым.

— Ачу итепме?

— Шулайрак шул,— диде ул.— Бигрәкләр дә бәхетсез тоелдыгыз. Шуңа күрә ачыктан-ачык очрашырга исәп тоттым да. Имәнлек тигез ачык урында. Бу очрашуыбыз төшегезгә дә кермәгәндер, әйеме? Канәфер чәчәк атуга, әниегез, тыела алмыйча, миңа барысын да чәчми-түкми сөйләде дә бирде.

Имәнлек ябалдашлары өстеннән талгын җил исеп китте. Шул җил сыман, бу очрашуыбыз да исте-китте шикелле. Оялып китәрмен дә әйтәсе сүзләремне югалтырмын кебек тоелды. Тик, имәнлекне әйләнеп чыксак та, сүзебез өзелмәде, ташлар арасыннан аккан чишмәдәй, ары дәвам итте.

Шунда Мария аркасы белән бер имәнгә терәлде дә телдән язды.

— Килегез әле,— диде ул аннары.— Кочаклагыз мине... Нинди татлы! Мин сезне йөз ел беләм шикелле инде. Аналарның үз балалары хакында сөйләүләре кызык бит ул.

Минем уйларым чикерткәләр сыман сикерешә башлады. Үз-үземне тота алмас хәлгә җиттем. Кеше-кара күзеннән күпмедер яшереп, безне агачлар уратып алган иде.

Мариянең йөзенә тыйнак шатлык, куаныч төсмерләре таралган иде. Ул, миңа тәмам елышып, чәчемне араларга тотынды.

— Шулай акылдан язалардыр да инде, әйеме,— диде ул.— Мондый якынлыктан шашарсың да.— Шуннан соң ул, кашын җыерып:

— Бер төрлелекне, алдашу, ялганны күралмыйм мин! — дип өстәде.

Үр кашында берәү пәйда булып, кулын җәйгән көйгә басып калды. Безнең баш өстеннән болытлар туктаусыз агыла.

— Имәнлекнең теге ягына чыгыйк мәллә? — диде Мария.— Сез әллә нәрсәдән өркеп калдыгыз ахрысы, шулаймы? Мин «кочаклагыз әле» дигәч... Теләк дигән нәрсә миңа артыграк җыелган бугай. Тагын шунысы да бар: комсыз мин. Үземә насыйпны һичкемгә бирә торганнардан

түгелмен. Шушы имәнлек тә минеке генә. Ә дөресен әйткәндә, миңа дөньяда үземнеке генә булырга тиешле нәрсәләр бик аз, тиде. Кулга эләктерәм дигәндә генә шуып чыга тордылар. Сезгә минем хакта артыгын белү кирәк түгел. Нәрсәгә хаҗәт ул? Адәм баласы, күп белә торгач, аздан коры калучан. Алай гына да түгел әле. Бер-берсеннән ваз кичәргә әзер торалар. Менә сез дә эндәшмисез, ә минем сорыйсым килми. Ярар инде, шушысы да ярап торыр. Көнләшү дә, үпкә-сапка да юк. Агачлар бер-берсеннән көнләшмиләр ич әле. Имән чикләвекләре бер-берсенә су тамчылары шикелле охшаса да, тамырлары җирдә төрлечә яши аларның, тышка бәреп чыгарга теләмиләр.

Аның ирен кайнарлыгы минем иренемдә сүрелеп җитмәгән иде әле. Көйдергеч бер түземсезлек җанымны яндыра иде. Буа ерылган кебек, бүленә-бүленә сөйләнергә тотындым.

— Бәлки мин дә хыялланганмындыр ул. Ә монда — төштәге кебек. Тиешенчә әзерләнергә дә өлгерми калдым. Бөтен кеше сагышланадыр, хыялланадыр. Ә минем мондый имәнлеккә беркайчан да барып чыкканым булмады. Чиста монда, саф. Ихтимал, мин монда әллә кайчаннан бирле омтылып торганмындыр инде. Тормышның, яшәүнең гадилегенә, тыйнаклыгына, табигыйлегенә.

— Шулайдыр, шулайдыр,— диде Мария шатланып.— Монда яшәүне тын алгандагы шикелле тоймыйсың да ул. Беркемгә алдауның, кылануның хаҗәте юк.

Кулын салындырып һәм күзен йомып, ул яңадан имән кәүсәсенә сарылды. Аннары, йомшак кына итеп, миңа таба елышты. Ул баштан-аяк күләгәгә чумган иде.

Ябалдашлар турысыннан тавышсыз-тынсыз гына болытлар агылды да агылды. Күләгәләрнең куерганнан-куера баруларын һәм имән төпләренә елышканын сизми дә калдык. Ә бездән артта, урталай ярылган карбызны хәтерләтеп, текә үр күтәрелеп тора иде.

— Ай! — дип куйды шунда Мария учын-учка бәреп.

Алан аша шул үргә таба, буй-буй пижамасын җилфердәтеп, әлеге дә баягы Якуп йөгерә иде. Болан шикелле озын аяклы, гәүдәсе төз, бөкерәймәгән-нитмәгән.

Мариянең кычкырып көлеп җибәрүеннән сөрлеккән кебек, Якуп бер генә мәлгә туктап калды. Әмма борылып карамады.

— Менә шайтан, ә?! — диде Мария шат төстә.— Юри-мүри генә килеп чыккан ул монда. Безнең биредә икәнебезне белмичә. Бәла инде бер.

— Ихтимал,— дидем мин аны җөпләп.— Теләмәгән, әлбәттә. Каян белсен ди ул?

— Ул һаман минем кемгәдер охшаганымны кабатлап йөри. «Егыл да үл, шундый охшаш инде»,— ди ул. Үз гөнаһым, үз гөнаһым, дип кабатлый гына бит. Уйлавы да куркыныч: шул тиклем дә ялгызак булыр икән. Рентгенолог бит мин, үтәли күрәм. Бүлмәгә чакырганда килмичә йөдәтә дә соң! Башта үзен тәртипкә китерә. Чисталык ярата. Каршыга кереп баса да: «Үз-үземнең иң ерак, күренмәс төшләрен мин сезгә генә ышанып тапшырам»,— дип тотына. Кызык кеше ул үзе. Аның янында күңелләр күтәрелеп китә. Дөньяда ни тотадыр үзен. Аның авыруы беләп җитмештән соң кем дә яшәмәс, билләһи. Кызганам мин аны. Чишенеп ташлагач, каравы авыр. Яклаучысыз адәм баласы инде бер, Ходаем.

— Ул мине дә шаккатырды. Чак кына сугышырга тотынмады.

— Шулай артистланырга маһир инде ул. Ни әйтсәң дә — интеллигент! Сәхнәгә менеп басамыни: бөтен кешене гаҗәпләндерәсе килә. Посып кына якыная да, һөҗүм итә дә ала. Каян көч-куәт таба тseparate тиз...

Тәмам эңгер-меңгер иңде. Ерактагы тавышлар да аерым-ачык ишетелә иде инде.

Әни, тәрәзәдән тәрәзәгә күчә-күчә, тышка каранадыр инде. Үзе әйтмешли, бинокль гына җитми торгандыр. Аны җәлләп куйдым. Үз-

үзем хакында да уйландым. Авырттырмыйча, шатлык бирердәй тормыш белән яшәр өчен язмышыма шушы саф, инде салкыная башлаган һава белән Мариядәй бер хатын гына кирәк булгандыр, ахрысы. Яраламасын, гел төрпәләп тормасын, таләп итмәсен, ә бәлки сусауны гына бассын.

Безне яңгыр коендыра башлады. Каян килеп чыккандыр, хәерсез. Ә Якупка эләкмәде. Яңгыр явасын да алдан белеп тора, ахрысы. Палатасына кереп, иңенә җәймә япкандыр да, тын гына яңгыр шавын тыңлап торадыр әле, хәйләкәр.

Җылы яңгыр астыннан имәнлекне артта калдырып чыктык. Башын күкрәгемә куйган килеш, Мария минем кочагымда карышусыз гына атлады. Тирән бер уйга баткан шикелле.

— Әгәр дә без ярамагандай бер гамәл кылсак...

Мариягә уен әйтеп бетерергә ирек бирмәдем. Ул кая барасыбызны яхшы белә иде. Үрне әйләнеп үтеп, югары күтәрелдек. Ә анда, үрнең нәкъ каршында безне бәләкәй генә бер мунча кисәге үзенә сыендырды. Коры иде, сулган каен себеркеләре исе бөтен җирне тутырган...

Әни һични сораштырмады. Тәрәзәсе төбенә шәм яндырып куйган. Караңгыда адашырмын дип, чыннан да, борчылып көткән икән. Ә төн уртасына таба утны бөтенләй сүндереп куйдылар. Мин ялгызак шәм яктысына елыштым.

Уянып киткән чагымда әни өйдә юк иде инде. Тиз-тиз генә сөт эчеп алгач, почтага бер сүзле телеграмма сугарга ашыктым: тоткарланам. Үз-үземне яхшы хис иттем, әйтерсең лә бар буыннарым ниндидер эчке бер яшь гайрәт белән тулган иде. Төне буена тынмаса да, яңгыр иртән туктап калды, һәм бар дөнья ягымлы кояш иркенә бирелде.

Телеграмманы алган кыз миңа:

— Әниегез дә телеграмма суктырып китте әле,— диде.

— Булмас ла! — дидем мин ирексездән.

— Ул кемнеңдер тиз килеп җитүен сорады,— диде ул кызыксынудан татлы кысылган күзе белән елмаеп.— Шулай кирәктер, димәк. Ә сезнең белән нигә киңәшләшмәде икән соң ул?

— Миңа барыбер,— дидем мин нигәдер.

Почтага таба сузылган юл күлдән ерак түгел генә уза иде. Шунда таба бер сукмак барып тоташа. Күлнең тирә-ягын мең яшәр агачлар уратып алган. Яр биек иде.

Шунда тетрәнеп киттем: бер юкәнең кара кәүсәсе төбенә гәҗит җәеп, Якуп утырган да — елый! Ә күл суында — кәгазь кисәкләре. Мин аларның ертылган хат калдыклары икәнлеген танып алдым. Ә картлач, карашын бер ноктага төбәгән дә, катып калган. Кулы, хәлсез каз канаты шикелле, тездән түбән асылынып тора.

Шуннан соң без Мария белән имәнлектә үткәргән, мәңлегек кебек сизелмичә генә узып киткән тагын өч көн башланды. Безнең бәхет мөмкин кадәр тулырак булсын дигән сыман, кус кычыткан белән уратып алынган теге мунча бөтенесенә дә шаһит булган иде инде. Шуңа өстәп, Мария алып килгән шәмнең төнге караңгылыкны чигендерә алган күбәләктәй йомшак, ягымлы ялкыны...

Әни гел аны-моны әйтмәде, тик аның сүзсез күз яшьләрен күреп торуы җанны кургаштай бастырып тота иде.

Шайтан өермәседәй бөтерелеп, Динара белән Ирек килеп төште. Хастаханәнең болдыр баскычына утырдым да, башымны учлап, телсез калдым.

Аннары, һичкемне күрмәгән һәм күрергә дә теләмәгән хәлдә, бөтен хастаханә җирен әйләнеп чыктым.

Мария беркайда да юк иде.

Ашык-пошык бер язу яздым да, кем аша тапшырырга гаҗиз калдым. Шунда Якуп картлачны исемә төшердем. Аны тар гына палатасыннан табып алдым.

— Шушы язуны Мариягә тапшырыгыз әле, зинһар,— дидем мин.— Тик берүк беркем белә күрмәсен. Моны сез генә эшли аласыз.

Хатны тыныч кына кабул итеп, ул ризалык белән башын кагып куйды:

— Шикләнмәгез.

«Мин китәргә мәҗбүрмен. Тик ничек тә әйләнеп килү җаен табармын. Тиз көндә, яме?» — Мариягә мин шуны гына белдерә алдым.

Самолетның түгәрәк тәрәзәсеннән чагылып калган әлеге имәнлекне һәм хастаханәнең үрдән очып күтәрелергә torgандай тоелган түбәсен күреп калганда минем җаным кысылып килгәндәй булды.

Теге имәнлеккә барып чыга алмадым. Һичкайчан һәм мәңгегә.

Ә кайвакытны, бигрәк тә җәй уртасының йомшак җилләре исеп куйганда мине әйтеп бирә алмаслык үкенү, иркә бер хис биләп ала. Хәзер мин анык беләм инде: шул җәй уртасындагы өч көндә кичергән хисләрдән дә яхшырак һәм сафрак һични булмас инде.

# КАР АСТЫНДА ЗӘҢГӘР АТ

ХИКӘЯ

Сүнгән фонарьдан тонык кына күләгә төшеп тора, ә аның турысында, күчкә төпләнергә җыенган бал кортларын хәтерләтеп, кар бөртекләре тузгый — әле кушыла, әле аерыла, әйтерсең лә тере бер җан иясе инде. Зур-зур нугырт ташлары түшәлеп, бозланган юлның аргы ягында җигүле кара-зәңгәр бер ат басып тора. Эңгер-менгерле ишегалды каршында йөкчесе дә таптана.

Җиңелчә суыктан зәңгәр тоелган урам аркасын җыерып тора иде шикелле. Гүяки ак канатын җәеп, очарга әзерләнгән. Һәрхәлдә шулай тоелды.

Ә ул исә фонарь янынннан китми дә китми. Бер сәгать чамасы вакыт үтте инде. Мин ул арада почмактан ике мәртәбә үтәргә өлгердем, таягым белән бөтен рәшәткәләрне барлап чыктым, өстемә пыр тузынган күпме кар ятты — ә ул һаман тора да тора. Өстенә күпме кар сарган инде, кагынмый да ичмасам.

— Абый, монда ни дип торасыз сез? — дидем мин кыюланып.

— Бар, бар, юлыңда бул,— диде ул калтырана төшеп.— Йөр шулай.

— Берәр кешене көтәсез мәллә?

— Беркемне дә көтүем түгел. Кар тыңлап торам әле.

— Ничек инде ул? Карны тыңлап була димени?

— Тыңлыйм дим ләбаса. Комачаулама әле син. Сиңа йокларга вакыт җиткән инде.

— Өйдә кунаклар бар иде шул,— дидем мин.

— Сугыш барганда нинди кунаклар ул тагын?

— Сахаринлап чәй эчеп утыралар. Мине йөрергә чыгарып җибәрделәр. Миңа димәгәе!..

— Урамда эт тә юк ич. Ат белән мин дә, менә тагын — син. Өстәп — кар. Бушлык, суык. Ишетәсеңме соң?

— Нәрсәне?

— Карны дим ич. Аны сыйпасаң сыйпап була. Күп ич ул. Ат бөтенләй бөкерәйгән. Аргандыр инде. Кыр буйлата авылдан тоташлый чабулап килде. Ә өйдә һичкем юк икән. Болай булса, төн буена аягүрә чыгасы инде. Ул да уйлый белә торгандыр. Томан. Кунаклар...

Миңа эндәшкән атлы булып, ул, шулай, үз-үзе белән сөйләшә иде бугай. Тик миңа ара-тирә карангалап алырга онытмады. Эшләпәсенең кар кунып авырайганын да тоймады.

— Ә син нигә сугышта түгел?

— Сөякләрем картайганга.

— Карт сөяк тә туңамыни? — дип сорадым мин.

— Кар яуганны тыңлыйм дим ич. Ә кар бик биектән, ерактан очып килә ул. Әллә ничә кешегә кагыла-кагыла.

— Ә син үзең кем соң, абзый?

— Син моны аңларлык түгел әле, малай. Мин — музыкачы. Ә миңа музыкасыз һич тә ярамый. Шунсыз үлүең артыграк. Менә ич: сезнең өегезгә кунаклар җыелган, ә минем сөякләрем картаеп беткән. Шундыйшундый хәллә-әр... Ә тегендә — сугыш бара торган җирдә дөбер дә шатыр, җирләр убыла торгандыр инде.

Без басып торган һәм сүз куерткан урынны халык «ыштан» диеп йөртә иде. Чөнки бу урында бер урам икегә аерылып китә дә аска таба илтә. Ә урта бер җирендә, кирмән сыман, болытларга ашардай булып бер йорт күтәрелеп тора. Якында гына — стадион, ә анда флаглар җилфердәшә. Ә без, кадакланган кебек, театр почмагында сөйләшәбез. Монда нигә дип торабыздыр инде — Алла белсен.

— Киттек мәллә, олан?

— Кая? — дип сорадым мин.

— Кая булсын — миңа инде. Мин шушы тирәдә яшәп яткан булам. Анау тимер капканы күрәсеңме? Менә шунда.

— Театрда мәллә? — дип сорадым мин, ул капканың кайсы йортныкы икәнен белгәнгә күрә. — Менә кар яуганын тыңлап торгансыңторгансың да хәзер кереп ятасыңмы инде?

— Юк инде. Атым сымак ук, миңа көтәсе дә көтәсе әле. Менә, әскә күпме кар яткан инде, — диде ул, мин аңлап җиткермәгән бер нәрсәне уйлап. Шуннан соң тагын да бөкерәя төште шикелле.

— Ә син көткән нәрсә кайда соң ул? — дидем мин аның ниятен аңлап җиткермичә.

Ул җавап бирмәде. Барып җиткәч, келәне этеп, мине эчкәре уздырды. Арка ягыбызда тимер шакылдап калды.

— Сине ничек ялгызыңны чыгарып җибәргәннәр соң әле? Фонарьлар да янмаган көенчә. Мин әллә кайчаннардан калган фонарь төбендә күнегелгәнчә генә басып торган булдым ичмаса.

— Урамга мин үзем сорап чыгып киткән идем. Миңа кем тисен икән?

— Шулай инде, олан.

Аңардан салкын бәреп торган шикелле. Мин үзем дә шактый өшегән идем инде. Тегендә-монда йөренә торгач, миңа кар артык йокмаган да. Ә ул тик кенә басып торды бит, суык сөягенәчә үткәндер. Авызыннан пар килерлеге дә калмаган. Бактың исә куенында үзенә җитәрлек җылылыкны саклап калгандыр әле. Башын игән килеш күпме гомер басып торды ич, күкрәген тыны белән җылыта аладыр, күрәсең. Тик икебез дә шактый арыган — талчыккан идек инде.

— Монда караңгы, карап атла. Баскыч. Санап бар — бөтенесе төптөгәл унбиш. Саный беләсеңдер ич? Каяле, тавышыңны бирә бар, яме?

Мин кычкырып санап мендем. Тавышым әллә ниткән төсләр чыгара иде шикелле. Аны капшап була иде кебек. Авызымнан дөм-караңгылык үзеннән-үзе каядыр таралып барды сыман.

— Ни атлы соң син, олан?

— Казбек. Әни мине, таудан тәгәрәпләр генә килеп төштең, диеп бара.

— Ә мин Салих атлы булам. Мин бу җиргә кар белән бергә ишелеп килгән. Ә кар әле югарыга, әле түбән оча бит ул. Шуны беләсеңме?

— Белми ди инде!

— Егет тә икәнсең соң, ә?.. Мин дә менә шулай бер югарыда, бер түбәнтен очып йөрим инде. Кышны яратам мин, курыкмыйм. Миңа тигән кар эри дә төшә.

Аның сөйләгәннәре миңа әллә ниткән табышмаклар сыман булып тоела иде. Ә безнең өйдәге кунаклар карта уйнап та туйганнардыр әле.

— Менә, менеп җиттек,— диде ул һәм ишекне шакып алды.

Караңгыга күземияләшеп бетсә дә, мин аның кытыршы җиңенә ябыштым. Аның башы турысында сүнәм-сүнәм дигән шикелле генә тонык ут яна иде.

Баскыч төбендә ризык исе сизелә: чөгендер белән бәрәңге пешергәннәр болар, хәтта кабыкларының көек исен дә тоеп алдым.

Киез белән тышланган ишек сөйрәлеп кенә ачылып китте. Зәңгәрсу бер күбәләкне хәтерләтеп, сукыр ут яктысы күренде.

— Йөрисең дә йөрисең, ә? Аракы бирмәсәләр, бер заманны катып калырсың әле бер,— дигән тавыш ишетелде. Өлкән кеше тавышы икәнен шундук абайлап алдым.

— Менә, бер иптәш табып апкайттым әле,— диде Салих абзый.

— Берәр исерек баштыр әле шунда.

— Шикләнмә,— диде абзый минем җиңемә кагылып.— Караңгыда гына шулай усалрак сөйләнгән була ул. Черем итеп алгандыр. Уятканга ачуы чыккандыр. Күзе дә күрми инде... Чишенеп торма. Бездә суык. Әйдә, эчкәрәк узыйк әле.

— Тикмәгә шәм кабызасы түгел, бел аны,— дип калды безнең арттан әлеге карлыккан тавыш.

Бер ишектән кысылып үттек. Монда инде бүтән исләр борынга кагылып узды — агач та кәгазь.

— Адашмадыңмы? Хәзер шәм кабызып җибәрәм. Танышып китүебез хакына берьюлы икене дә кабызып куя алам. Ичмаса җылысы чыгар. Шәмнәрем бар иде, бер дустым танышлык хакына китереп китте. Утсыз калса, кешене җон каплый.

Ул шундук ут кабызып җибәрде дә бүлмәдәге бушлык әллә кая чигенгән сыман булды. Шунда ни күрим: учакта пианино агачы янып ятмасынмы? Әйтерсең лә үзем йөргән балалар бакчасының идәне янып яткан шикелле булып китте. «Три-тари-дам»,— дип көйләп куйдым мин үзем дә сизмәстән.

— Ни көйләп маташасың син, олан? Утыр әле, ә мин сиңа уйнап күрсәтим. Кул тунган, язарга кирәк.

Шуннан соң ул эшләпәсен салды да ике шәм арасына әйләндереп куйды. Аңа сарган кар бөртекләре күз алдында эри барды, ә суга әйләнгән тамчыларында ут шәүләсе уйный иде. Ә мин шул ике шәм арасыннан Салих абзыйның шулай ук эрегәндәй йөзен чамалап тордым. Хәтта күзе дә эрергә керешеп, аңа җан керә башлаганын карап торгандай булдым. Кулы күренмәде, иңеннән төшермәгән пәлтәсе каплый иде.

Ул уйнаган көй дә кар хакында иде булса кирәк. Миңа ничектер шулай тоелды. Бая гына әле югарыга күтәрелеп, әллә түбән төшеп уйнаган кар бураны яңадан күз алдыма килде.

Ә ул кар бөртекләре миңа әти яткан окоплар ягыннан килеп җиткән кебек иде. Менә хәзер очынырлар-очынырлар да, минем сулышымны ишеткәч, яңадан әти янына очып китәрләрдер инде. Тик сәламемне аңа илтеп җиткерерләр микән соң? Анысын белмим, тик әти үз улы Казбекның исән-имин икәнлеген, тәгаен, сизенердер шикелле булып китте.

— Йоклыйсың мәллә, олан? — дигән тавышка айнып киттем.— Сыйлар идем дә бит,— юк ич инде, нишләтим соң? Әйдәле, ичмасам озатып куйыйм. Сәгать күпмегә суккан икән инде? Сине көтеп, әнкәң ишекле-түрлеме, капка төбендәме йөренәдер инде.

Без яңадан баскыч буенча кармаланып төшеп киттек. Әле генә утырган бүлмәдәге сүрән ут чаткылары күз яшьләремә ияреп тәгәрәште шикелле. Шунда бу абзыйны кызганып куярга да онытмаганмын бит әле.

Бая гына уйнаган көе аның үзенә караганда да кызганычрак булып китте. Үз-үземне дә җәлләдем, әлбәттә. Шуңа өстәп, әнине, бу мизгелдә окоп төбендә яткан әтине. Караңгылык мине басып тота кебек иде. Әйтерсең лә әйләнә-тирәне югарыдан күзәтәм, әйтерсең лә мине сак кына каядыр өскә меңгереп куйганнар, ә аста — сыкы сарган Җигүле ат белән эшләпәле агай, яннарында үзем дә бар — телогрейка, киез итек кигән бер малай. Мондый хәлне беренче мәртәбә кичерүем. Карасана: үз-үзеңне кызганырлык дәрәҗәдә кечерәйтелгән итеп күзәт инде, ә?

Ә иртән әни:

— Сине ярым йокылы килешеңдә бер кеше озатып куйды, — диде. Чибәр генә бер ир. Кайда идең син? Ә ул берни әйтмәде. Ахрысы минем аны күргәнем дә бар бугай. Эндәшмәсен аңлатып, бармагын иренено тидерде дә чыгып китте. Туктатырга уйлаган идем дә, ул «Таунын кар астында йоклавы хәерле», — дип сөйләнде. Ни дигән сүз соң бу? И-и, аңладым: синең исемең Казбек ләбаса. Кем булды ул кеше?

— Музыкант, — дидем мин. Без аның белән бергә туңып тордык.

— Сине кайда очратты соң ул?

— Җигүле ат янында. Анда шугалак белән театр бар. Бер ишегалдына барып кердек... Әй, минем йокым килә әле!

— Нинедер әйтеп бетермисең бит.

— Аннары ул шәмнәр кабызып куйды, музыка уйнады. Шунда йоклап киткәнмен. Кар күп яуды да соң!

— Кар явуның ни катнашы бар монда?

— Ә кар бер аска, бер өскә ява ич.

...Аны карлы, күз камаштыргыч якты, суык бер көнне җирләделәр.

Мин студент идем инде. Бу хакта кинәт кенә, соңарып белеп алдым. Аның исемен һичкем атамады, тик әйләнә-тирәдә нидер үзгәрде, бусы тәгаен.

Куерып, мул булып, йомшак кына явып торган кар астына чыгып бастым. Ул мине күк гөмбәзенең бар төпсезлеге астында ялгызымны калдырды.

Бер таудан бакчага таба төштем дә аның бушлыгы аша узып киттем.

Яуган кар мине нәкъ теге чакны без икәүләп басып торган фонарь янына әйдәп китерде. Йөрәгем эре балыктай дулкынланып алды.

Кар өстендәге халык күпкә күрә, көн караңгыланып киткән шикелле тоелды. Аны театрның шарран ачып куелган ишегеннән күтәреп алып чыктылар.

Фонарь янынынан артык ераклашмаска теләп, мин шулай да якынрак атладым. Шунда калтыранып куйдым: каршы якта Җигүле шул ук ат басып тора, һәм ул нәкъ теге чактагы кебек үк җиңелчә буга төренгән иде. Шул еллар эчендә бирдән беркая да китмәде микәнни?

Аны музыка астында янәшәмнән күтәреп уздылар. Башына кар ява иде. Йөзе үзгәреп китеп, ул миңа борылырга, нидер әйтеп калырга теләгәндәй тоелды. «Менә нинди кар, ә? Шундый-шундый хәлләр, туган...» — дипме?

Йөзләрен кайгы-хәсрәт баскан кешеләрне аның артыннан музыка югарырак күтәреп әйди кебек иде.

Безнең арадагы серне аларның берсе-бер белми иде ул.

Әлеге музыка теге төнгеке иде, ахрысы, кар белән саубуллашкандагы ише, сагышлы. Бәлки, ул чакны без, җылы ипи кыерчыгын икебезгә урталай бүлгән шикелле, ялгызлык төнен бүлешкәнбездер? Ә андый төннәр кешеләрнең матур төшләре яктылыгына чумган шикелле була.

*Әхәт ГАФФАР тәрҗемәләре*

## Басыйр Рәфыйков

### Хәтер

Кайдан килгән җан әрнүе? —
Кеше белми, — ходай белсен!
...Хәтер саклый рәнҗетелгән
Балачакның исен, төсен.
Хәтер саклый тентүләрне,
Сугышларны, ачлыкларны.
Соцоҗмахлар вәгъдә иткән
Икейөзле башлыкларны.

*
* *

Алла кушып,
Милләт иркен сулыш алса,
Кайтса тәхете,—
Халык хәтерендә
Бер юл шигърем калса,—
Мин дә бәхетле.

### Бу көннәр...

Хәл ителәсе бәхәсләр
Кубәйгәннән кубәя.
Бу көннәрдә — низаг өстен,
Дуслыкка кими бәя.

Илләр өстенә җәелгән
Айның сары сагышы...
Ачы җилләр булып исә
Кыйтгаларның язмышы.

---

Басыйр РӘФЫЙКОВ (1921) — *Троицкида яшәүче татар шагыйре. Бернича китап авторы.*

## Әлифба язмышы

Әлифне таяк дип уйлап,
Сындырдылар, кундырдылар...
Инде
Ике мәртәбә сындыргач,
Өченчегә тотындылар.

## Төшемдә

Туган ягым — бабам бишегендә,
Татар телен онытканнар, имеш.
Төшенмим һич — ничек аңлашалар,
Әллә кытай теле, әллә идиш?

Миңамы ул үлеп юкка чыгу?
Мин ачудан көям, утта янам:
Мин — югалган әтрәк-әләм түгел,
Имеш, шигырь укыйм, аваз салам.

## Моң яшәсен

Идел кебек озын халкым юлы,
Чулман дулкынындай гаугалы.
Җырларында — йөрәгеннән чыккан
Нократ елгасының шаулавы.

Үзәннәрдә, чыклы үләннәрдә
Ат саклаган халкым учагы.
Тормыш фатихасын шунда биргән
Туган илнең җылы кочагы.

Үз сыйфатын югалтмыйча, халкым
Үткән борылмалы юлларны.
Яшәр өчен тормыш киңлегендә,
Канат куйган аңа моңнары!

*
* *

Чукракланган Җир — шартлау, атудан,
Дөреслек үлгән — алдау, сатудан.
Күңелләр каткан, җаннар алҗыган.
Әрнү бөркелә күзъяшьле җырдан...

— Ура! — кычкырып йөрдек бергәләп.
— Караул! — дибез инде берәмләп.

*
* *

Дөнья нишләр,
Кая барыр?
... Сорау җиңел —
Җавап авыр!..



# Салават Рәхмәтулла

## Бездән соң да...

...Тыныч кына яшәп ятканнар да...
Ә бер көнне — кызган кешеләр,
Миллион еллар буе яшәп килгән
Кануннарны бозган кешеләр.

Гайбәт сүзе түгел, тарих сүзе
(Тарих белми алдап торуны!):
«Җир — түгәрәк!...» — дигән Коперник карт,
«Һәм — әйләнә!...» — дигән Бруно...

Түм-түгәрәк җир әйләнеп торган;
Кичләр килгән, таңнар беленгән.
Коперниклар белән Брунолар
Яндырылган... дарга эленгән...

...Тәү тормыштан башлап — җан кыешлар,
Кан коешлар — тарих юлында...
«Без башка юл белән барабыз!» — дип
«Яңа юллар» сызган Ленин да...

...Гайбәт сүзе түгел, шагыйрь сүзе
(Беркөн кызган шулай Гафури!):
«Юктырсың ла, алла...» — диеп, диннең
Кануннарын бозган Гафури...

... Меңәр еллар «бүленми!» дип килгән
Атомнарны бүлгән кешеләр.
Һәм... бүленгән атом нурларыннан
Кара көеп үлгән кешеләр...

Табигатьнең кануннарын бозып,
Күк гөмбәзен тишкән кешеләр.
Бар галәмне иңләп-буйлап гизеп,
Җиргә янып төшкән кешеләр...

...Тыныч кына яшәп яткан җирдән
Без дә яңа юллар ярабыз.

---

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) — *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре, башкорт телендә басылган китаплар авторы.*

Яшәп килгән тәртипләрне бозып,
Үзгәртүләр алып барабыз!

Иң дөрес сүз бүген — без әйткән сүз!
Иң дөрес юл — безнең юлыбыз!
Кызып китеп, үлгән патшаларның
Якасыннан ала кулыбыз!..

Эз...
«Дөрес юлдан бармаганнар!» — диеп,
Бездән соң да кызар кешеләр:
Дистә-дистә еллар без төзегән
Кануннарны бозар кешеләр...

Сүзләремнән хата эзләп, кемнәр,
Миңа гаеп ташлап хисләнә?! —
Бу дөньяда бөтен изге эшләр
Кануннарны бозып эшләнә...

## Русия

...Кыйбласын да табалмаган урыс,
Ил баскан да мәңге ил баскан:
Күзләрен кан баскан...
Узган юлын
Хәрабәләр баскан, көл баскан.

Илләр арты — илләр, чәчәк-гөлләр... —
Байлыкларын талап, «үз» иткән:
Халыкларын, коллар итеп изеп,
«Рәсәй» дигән дәүләт төзеткән.

Һәр җиңелгән ил... урыска «кергән»,
Урыс тамга салган: «Бүленмәс!»
Илләр язмышлары — кара хәсрәт
(Карталарда — кызыл: беленмәс...).

...Кол биләсәң, мәңге тирләр түкми,
Йөзеп була мәңге муллыкта!..
Кол биләүчеләргә коллар кайда —
Билләр бөккән мәңге коллыкта?!.

Коллар юлы — көрәшчеләр юлы,
Көрәш аша — җиңү! — кем белмәс:
Чыңлап оча богау бәжралары,
Кисәк-кисәк куба «Бүленмәс!»

...Кыйбласы юк һаман (буласы юк!):
Халыкларның төшкән каргышы...
..Русиянең, әллә кайдан килеп,
Әллә кайда китеп барышы...

# Авылым зиратында

*Әллә кемнәр ята монда*
*Газиз башлары белән.*
*Чыгалмаслар: бастырганнар*
*Кабер ташлары белән...*

...Эченә керсәң — каберлек,
Ылыслы урман — читтән.
Кайтсам, шунда керәм:
Монда
Бабамнар йоклый күптән.

Дәрәҗәләр тигез монда:
Юк «бай», «ярлы», «урта»лар.
Мәңге яшәр сыманнар да
Бу «Мәңгелек йорт»талар.

Дөньяга сыймаганнар да
Сыйганнар: монда иркен!..
Төрмәдән — качалар...
Үлем,
Качалмый синнән беркем!

«Кызыл авыз»лар да хәтта
Ята... тик хәтер булып.
Гомер — бер: үтә,
Җитә бер
Соңгы сүз әйтер минут.

«Үлемне җиңеп була!» — дип
Лыгырдау — ялган, ялган:
Көрәшче картәтине дә
Газраил бөгеп салган.

Кабере монда абыем —
Җаным Барисымның да...
Туфраклары җиңел булсын,
Булсын барысының да!..

Чират җиткәч, Әҗәл үзе
Килә — кочагын ачып!..
Лагерьлардан качып була,
Үлемнән булмый качып...

Көттермәс, миңа да килер,
Килер ул — соңгы «бер көн»...
Каберлектә... «урын» эзлим,
Уемны белми беркем.

Әйтеп калдыралсам иде
(Яшәлгән кадәр тормам):
— Эченә... керсәң... каберлек...
Читтән ылыслы урман...

## Үтеп барышлый

*(Такташка ияреп түгел.)*

Син яшәгән кала аша — юлым:
Яннарына кердем: «Дус!» — диеп.
Кочакларың җәеп, каршы алдың:
«Шагыйрь дустым, түргә уз!» — диеп.

Кулларыңны кыстым, түргә уздым.
Табын кордың, «ак баш» куйдың син.
«Хәзер... эчмим!» — дидем...
«Мин дә...» — диден,
Касәләргә чәйләр койдың син.

Мәйләр түгел, бу болгавыр чорда
Анальгиннар эчү — яхшырак.
Имансызлар арта... Иманнарны
Саклау өчен аек баш кирәк!

Изгеләрдән изге динебез дә
Изге булган өчен... тыелган.
Тукаебыз барга бер сөенсәк,
Телне уйлап... җаннар кыелган...

Күрмәгәнен күргән татар халкы
Күрәсен дә үзе күрәчәк:
Үз киләчәгенә үз байрагы,
Үз дәүләте белән керәчәк!..

...Өреп-өреп чәйләр эчә-эчә,
Шигырь арты шигырь сөйләдем.
«Халкыбыз сау булса, югалмабыз,
Сау бул!» — диеп, саулык теләдем.

«Ак җәймәләр — йөргән юлларыңа,
Көрәш аша юлың, дус,— диден.—
Зур көрәшләр — алда: мәйданнарның
Уртасына — түргә! — уз!» — диден.

## Һәр татарда уян, татарлык!

...Язмышыбыз шаклар катарлык чор...
Әйтергә дә курыктык: «Без — татар...»
Меңәр-меңәр татар арасыннан
Табып булдымы чын... йөз татар?!

...Хыялларга байрак кадарлык чор!
Һәр татарда уян, татарлык:
Амбразуралары үлем чәчсә,
Газинурлар булып ятарлык!

*
* *

Чирәмнәргә ятып тәгәрәдем...
Хәзер
Яшьләр аша килә көләсем!
Тик син — көлмә: ул чак килгән минем
Җирнең тарту көчен беләсем...

«Җирнең тарту көче — юк!» — дияргә
Малай чагым тапкан чарасын...
Җирнең тарту көчен белер өчен,
Аерылып туган якларыңнан,
Еракларда яшәп кара син!..

## Сагышлы җыр

Җир астыннан юл саласы түгел,
Түгел таулар-ташлар тишәсе:
Яннарыңа барып җитәр өчен
Өч үр менеп, өч үр төшәсе...

Сиңа да юк дәрья кичәселәр,
Ташкыннарга каршы ишәсе:
Яннарыма килеп җитәр өчен
Баскычлардан йөгереп төшәсе.

Күзләреңдә ике кояш балкыр —
Йөзләреңдә таңнар беленгән.
Тик бер адым ара әллә күпме
«Ярамый»лар белән бүленгән...

Соңгы адым...
Кайнар сулышыңнан
Кайнарлана ике бит алмам.
...Гомерең буе килеп җиталмассың,
Гомерем буе барып җиталмам...

**Булат Солтанбәк,**

тарих фәннәре кандидаты

# СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛДАН — БӘЙСЕЗЛЕККӘ

Төгәл генә хәтерләмим, 1988 яки 1989 ел иде бугай. Үзгәртеп кору жилләре бик көчәеп искән бер мәлдә, Швеция яисә Австрия моделенә охшаш, «кешегә йөз белән борылган» социализм коруда «тәмам һәм ахыргача хәл ителгән» милли мәсьәләнең төп киртә булачагы авырлык белән булса да ачыкланып килгән бер вакытта, миңа Мәскәү телевидениесе тапшыруларының берсендә катнашырга туры килгән иде. Ул чакта «түгәрәк» һәм башка төрле өстәл янында сөйләшүләр еш оештырыла иде. Гәрчә алар турыдан-туры эфирга чыкмаса да, тапшыруларны кисүләр сирәгәйгән иде. Төрле республикалардан җыелган вәкилләрнең чыгыш ясау тәртибе төгәл сакланган нәкъ менә шундый тапшыруларның берсендә очраклы рәвештә микрофон «икенче сортлы», ягъни автономияле республика вәкиле кулына тапшырылды. Хәер, түгәрәк өстәл хуҗасы, КПСС Үзәк Комитетының ул чактагы милли бүлеге мөдире урынбасары Рамазан Абдуллатыйпов: «Менә микрофонга Солтанбеков ыргыла, аңа ничек сүз бирмисең инде?» — дип хәлне җайларга ашыкты. Сөйләшүдә катнашучылар бу шаяртуны аңлады, әлбәттә. «Иптәш, автономияле республикадан булса да, төшеп калганнардан түгел, янәсе». Хәзер мин бу вакыйганы кемне дә булса гаепләр өчен искә төшермәдем. Моннан кыенрак хәлгә юлыккан чакларым да аз түгел. Хикмәт бөтенләй башкада. Соңыннан, тапшыру тәмамлангач, аның хакында фикер алышканда, ул чактагы «үзәк» вәкиле Аркадий Вольский чыгышыннан соң берәү, Карабах вакыйгаларын искә төшереп һәм, барыннан да бигрәк, мине сискәндереп: «Менә татарларда хәл тагын да кискенрәк булачак. Ишетүемчә, алар үзләренә ханлык заманын кайтаруны таләп итә. Бер хатын-кыз ханбикә булырга да омтыла икән», — дип әйтеп куймасынмы!

Шунысын да әйтик, ул вакытларда ук инде Вольский: үзәк, ягъни Мәскәү, милли сәясәтнең бөтен нечкәлекләрен белми һәм белергә дә теләми, ә инде ни дә булса хәл итәргә кирәк булса, соңга кала, дип ачыктан-ачык әйтеп чыккан иде. Интеллигенция вәкилләрен, төгәлрәге — тарихчыларны тәнкыйтьләве белән дә Вольский йөз мәртәбә хаклы. Барыбыз да яхшы беләбез. Соңгылары исә бер көнлек файда хакына тарихны ничек кенә «бозып» күрсәтмәделәр һәм, шул рәвешчә, бу очракта әрмәннәр белән азәрбайҗаннарны бер-берләренә каршы котырттылар. Бу җәһәттән бер генә мисал китерәсе килә. Таулы Карабахта борынгы храм хәрабәләре бүгенге көнгәчә сакланып калган. Ә аның барлыкка килүе, кайсы милләт тарафыннан төзелүе турында ике диссертация язылган. Әрмән тарихчысы аны әрмән халкы төзегән дип исбатлый. Азәрбайҗан тарихчысы исә моның нәкъ киресен аңлатып бирә. Бу ике гыйльми хезмәт тә бер үк вакытта диярлек Мәскәү тарафыннан хупланган... Кызганыч ки, моңа охшашлы мисаллар совет тормышында адым саен очрап тора.

Тик хакыйкатьне, татарларның үткәнен ничек итеп аңлатып бирергә? Әлеге «түгәрәк» өстәлдән соңгы фикер алышуларда мин тагын бер мәртәбә шуңа төшендем: күпләргә, бик күпләргә татар тарихы әле аз билгеле. Алай гына да түгел, кыек көзгедәге сыман, ул ничә гасырлар дәвамында дөрес чагылдырылмый... Югыйсә, җәмәгатьчелектә халык аңының «кайнар нокталары»ннан берсе булган милли мәсьәлә белән кызыксыну соңгы вакытта көчәя бара. Хәтта урыслар да битарафлыктан арына. Моңа күп яктан, әлбәттә, иҗтимагый мәйдан-

да бәйсез Татарстанның күтәрелеп чыгуы сәбәпче булды. Бу җәһәттән аның бүгенге Президенты Минтимер Шәймиев тә үзенең һәр эшендә республиканың күп милләтле халкы акылына һәм тәҗрибәсенә таяна дип әйтәсем килә. Шуңа да аның эчке ышаныч белән сугарылган һәр сәяси чыгышы, һәр гамәле элеккеге СССР республикаларына һәм бөтен дөньяга үзендә суверенлык һәм яңача берләшү принципларын оста һәм нәтиҗәле эшкә ашыра барган дәүләт төзелешенә ия. Татарстан җөмһүрияте — конфликтларга юл куймаучы күп милләтле җәмгыять үрнәге булып тора. Ул без моңарчы күзаллаган дуслык «җепләре» белән бәйләнмәгән, чөнки алар әлеге җәмгыятьнең табигатендә, ул бәйләнеш җепләре ерак чорлардан килә. Аның төп шарты — бу җәмгыятьтә берәү дә кол булырга тиеш түгел.

Татар халкының узганы, бөтен тарихы шушы хакта кисәтә. Каһарманнарча аяусыз сугышуга да карамастан, явыз илбасарларның өстен көчләренә каршы тора алмыйча, 1552 елның октябрендә Мәскәү дәүләтенең көнчыгышындагы шанлы мәмләкәт башкаласы Казан җиңелә. Һәркем шәһәр сагына баса. Мәсәлән, хәзрәти Кол-Шәриф фатыйхасы белән Ядегәр ханны әсирлектән саклап калу өчен, кулларына корал алган мәдрәсә шәкертләре барысы да әлеге рәхимсез канкоешта һәлак була. Әнә шул рәвешчә, дистәләрчә елларга сузылган сәяси фаҗиганең канлы ахыры языла. Шәһәрдә ир-атларның һәммәсе диярлек үтерелә, хатын-кызлар һәм балалар төрлечә мәсхәрә кылынып, коллыкка озатыла. Шанлы мәркәз таланып, хәрабәгә әйләнә. Казанны «яулап алу» турында кемнәр генә язмый. Явыз Иванның турыдан-туры дошманы, бу сугышта үзе дә катнашкан кенәз Курбский язмаларын тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Ул, мәсәлән, урыс патшасы җимерелгән шәһәргә үтеп керсен өчен юлны тау-тау өелгән мәетләрдән арчырга туры килде, дип ачыктан-ачык язып калдырган.

Әйе, көннән-көн көч һәм кодрәт туплый барган урыс дәүләтенең рәхимсез һөҗүме нәтиҗәсендә юк ителгән Казан мәмләкәте тарихы хакында күп язылган. Алар арасында тарихи хезмәтләр дә, әдәби һәм халык иҗаты әсәрләре дә бар. Карамзин, Соловьев, Ключевский, Татищев, Рычков, Фукс кебек исемнәрне санап китү генә дә үзе күп нәрсә сөйли. Әмма шунысын да ассызыклап узыйк: ул әсәрләр җиңүче тарафыннан иҗат ителгән. Шуңа күрә дә бу авторлар ислам диненә, ул чактагыча әйтсәк, «басурманнарга» түбәнсетеп-кимсетеп караудан уза алмаган. Хәер, ил-дәүләтләрнең генә түгел, диннәрнең бугазга-бугаз килеп дошманлашкан чагында шунсыз мөмкин дә булмагандыр.

Әйдәгез, 1552 елгы октябрь фаҗигасенә китергән хәлләргә күз төшерик. Һәр халыкның диярлек иҗтимагый аңында үткәнгә бәйле кайбер хәлләр — ул аны телиме-юкмы — бәхәсләр китереп тудыра, төрлечә уйларга урын калдыра. Әйтик, татарларда ул — этнос мәсьәләсе, дөресрәге — кемнәр булган соң безнең ерак бабаларыбыз? Бу сорауның бер генә чорда да бирелми калганы юк. Без кемнәр: «игелекле» болгарлармы, әллә «кыргый» күчмә халык — татарларның варисларымы? Соңгылары исә урыслар аңында фәкать тискәре-яман фикер генә уята. Бу инде аларның канына сеңгән. Мисалга, «чакырылмаган кунак татардан да яманрак» дигән мәкальне генә китерик.

Мондый кимсетүле караш хәтта безнең милләт өчен бик күп игелекле эшләр башкарган кешеләр тарафыннан да күрсәтелә. Мәсәлән, «Идегәй» дастанын тәрҗемә иткәне өчен Г. Тукай бүләгенә лаек булган талантлы рус шагыйре Семен Липкинны татар халкы аерым бер хөрмәт хисе белән телгә ала. Әмма шушы авторның Алабуга каласында үзенә кул салган шагыйрә Марина Цветаева фаҗигасендә татарны гаепләве сәер, бик сәер.

Көтә сине алда Алабуга,
Көтә сине татар элмәге.

Югыйсә, урысның горурлыгына әйләнгән бу шагыйрьгә ул заманда язучылар ашханәсендә савыт-саба юучы булып урнашырга да рөхсәт итмәгәннәр. Моның өчен татарлар гаеплемени?! Бу фаҗига аның белән эвакуациядә булган каләмдәшләре намусында да.

Үткәнне кайтарып та, яңадан язып та булмый. Тарих безгә татар исемен биргән. Шуңа күрә аннан котылырга тырышуның, «болгар» исемен алырга маташуның һич хаҗәте юк, минемчә.

Сәяси вакыйгалар учагында кайнап, без кайчагында һәр халыкның килеп чыгышы катлаулы процесс булуын һәм аның мәгълүм кысаларга гына сыймавын онытып җибәрәбез. Хәлбуки, бу хакта кемнәр генә баш ватмаган. Урта гасырларның акыл ияләре дә уйланган, бүгенге бәйсез Татарстанның табадан гына төшкән академиклары да «тарихтагы ак тапларны» эзли. Менә шуларның бөтенесен

белгән тәкъдирдә, мәсьәләгә үзебезчә күз төшерик. Төгәл җавап алуга да дәгъва кылмыйк, чөнки хакыйкать яңадан-яңа буыннар дәвамында ачыкланыр.

Көнчыгыш тарафыннан куәтле халыклар һөҗүме (гадәттә, без аны Чыңгыз хан исеме белән бәйләргә күнеккәнбез) ул чордагы дөньяның сәяси агышын бөтенләй башка якка үзгәртеп җибәрә. Элгәрге барлык сугышлар белән чагыштырганда, күп җирләрне басып алу ягыннан аңа тиңнәр юк. Монгол һөҗүме астында җимерелгән дәүләтләр арасында ике күрше — Идел буе Болгар мәмләкәте белән болай да инде вак кенәзлекләргә таркалып барган Киев дәүләте була. Киев Русенда тәхетне кулга төшерү өчен үтерү, агулау, сукыр калдыру, әләкләү кебек пычрак алымнарның берсеннән дә чирканмыйлар. Көндәшләре тарафыннан явызларча үтерелгән туганнар Борис белән Глебның ачы тарихын гына искә төшерик...

Көнчыгыштан килгән илбасарларның ихтыяры белән боларның һәммәсенә чик куела. Безнеңчә әйтсәк, бәйсез кенәзлекләрнең хакимият даирәләре рәхим-шәфкать сорап монголларга барырга мәҗбүр була. Әле X йөздә үк төньяк-көнчыгышта бердәнбер ислам дәүләтенә әверелгән Болгар да мондый адымнан котыла алмый.

Әйе, Болгар халкының этник составы хакында күп санлы бәхәсләр алып барыла. Гәрчә, кайчагында төпле дәлилләр китерелмәсә дә, дәүләтчелекне дип әйтмик, ә менә мәдәният варислыгын дәгъва кылучыларны бер татар халкы дип кенә әйтеп булмый. Хәлбуки, бу илдә яшәүчеләрнең күпчелеге төркиләр булуы бәхәссез.

Чыңгыз хан империясе, хәтта бүгенге күзлектән караганда да, байтак зур дәүләтләргә таркалганнан соң, Русь һәм Казан язмышы Алтын Урда ханлыгы белән бәйләнә. Аның язмышы гаять кызыклы һәм гыйбрәтле. Анда теләсә нинди дин тоту иреге сакланган. Мәсәлән, бу мәмләкәтнең башкаласы Сарайда христианнарның епископ җитәкчелегендә епархиясе ирекле рәвештә эшләп килгән.

Идел һәм Чулман буе болгарларының Алтын Урда чигендәге җирләре Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында үзенчәлекле күпер хасил иткән, дәүләт үзәгенә әверелгән. Күп санлы чыганаклардан күренүенчә, ул мәдәнияте, авыл хуҗалыгы һәм һөнәрчелеге чәчәк аткан ил булган, аның шәһәрләренә шул заманның күпчелек галимнәре, акыл ияләре агылган. XIII—XIV йөзләрдә аның Алтын Урдага буйсынуы төрле үзгәрешләр кичерүгә сәбәп була. Ә бу исә аның мөстәкыйль рәвештә үсүенә йогынты ясый. Идел-Чулман төбәгендә сәяси вакыйгаларга тәэсир итү көче гаять зур булган Казан дәүләте күтәрелеп чыга. Ерак бабаларыбыз бу дәүләтнең башкаласын да дөрес сайлаган, ул хәрби яктан да, икътисади яктан да бик уңайлы урынга урнашкан. Әмма бүген дә Казан каласының кайчан төзелүе турында бәхәснең тукталганы юк. 1977 елда шәһәрнең 800 еллыгын үткәрергә омтылып карадык. Әмма эш омтылыштан ары узмады.

Бәхәссез ки, әледән-әле монгол яулары, урыс гаскәрләре һөҗүменнән, аларның талавыннан алҗыган, иза чиккән халыкның Чулман якларыннан төньякка агылуы Казан дәүләтенең икътисади куәте һәм сәяси йогынтысы тагын да үсүгә ярдәм итә. Аксак Тимернең дә бөлдергеч һөҗүмнәре шул заманга туры килә. Ул юлында очраган дәүләтләрне таптап-җимереп уза. Болгар да читтә калмый аның һөҗүменнән, ә кайчандыр кодрәтле булган Алтын Урда үзара йомшак бәйләнгән һәм бер-берләре белән даими дошманлашып торган кабилә берләшмәләренә бүлгәләнеп бетә. Менә шундый шартларда комсыз карашын һаман ешрак Көнчыгышка юнәлткән Мәскәү өчен Казан дәүләте бердәнбер киртә булып кала. Аксак Тимердән соң мөселман дөньясы урыс җирләренә бөтенләй диярлек һөҗүм ясамый. Хәл киресенчә үзгәрә, акрынлап ныгый барган Мәскәү дилбегәне үз кулына алып, үзе һөҗүмгә күчә, XIX йөз ахырында инде Һиндстан һәм Иран чикләренә кадәр килеп җитә. Чынлыкта Чыңгыз хан империясенең бик күп өлешен үзенә буйсындыра. XV йөз уртасыннан XVI йөз уртасына кадәр Мәскәү дәүләте тышкы сәясәт өлкәсендә Казан белән мөнәсәбәткә өстенлекле урын бирә. Бу хакта бик күп санлы тарихи чыганаклар сөйли.

Казанга кызыгырлык та шул. Бу дәүләт соңгы йөз ел дәвамында шактый алга киткән, төгәл идарә итү челтәре, мәгариф эше юлга салынган, куәтле гаскәри көчкә ия ханлык дәрәҗәсенә күтәрелә. Дәүләт эшләрендә халык вәкилләре дә катнаша, ил башлыклары дин әһелләренең дә сүзенә колак сала. Болар бөтенесе хакимиятнең бер кеше кулына гына туплануына юл бирми. Казан дәүләтенә кергән халыклардан (чуаш, удмурт һәм марилардан) оештырылган идарә ханлыкта тотрыклы тормыш юлга салынуга ярдәм итә. Бу исә Мәскәү белән бәрелешләр вакытында өстәмә бер калкан булып тора.

Еллар узу белән Мәскәү—Казан мөнәсәбәтләре тагын да кискенрәк төс ала. Әгәр XV гасыр урталарында дәүләт башлыклары бер-берсен туган дип атаса, ә

хәрби бәрелешләрдә өстенлек гел алмашынып торса, XVI йөз башында инде көчләр нисбәте кискен үзгәрә. Казан дәүләтен ахыргача тар-мар кылу һәм Русия империясендә «татар мәсьәләсе»н хәл итүгә бәйле вакыйгаларны аңлатуга көч-кәнче, шул чордагы Европаның сәяси хәленә дә тукталып узу кирәктер. Чөнки Европадагы вакыйгалар Идел буендагы мөнәсәбәтләргә дә турыдан-туры йогынты ясаган.

Византиянең җимерелүе һәм госманлы төрекләрнең куәтле империясе төзелү аркасында Европадагы бик күп дәүләтләрнең мөстәкыйльлегенә җитди хәвеф туа. Балканны яулап алу, бу һөҗүмнең Кара диңгез буена һәм Кавказга юнәлү ихтималы Австро-Венгрия, Венеция, Генуя кебек илләрне хафага сала. Европаның башка дәүләтләре дә пошаманга төшә. Акрынлап урыс җирләрен берләштерүгә ирешеп, көчәеп килүче Мәскәү дәүләте дә төрекләр тарафыннан үз мәнфәгатенә куркыныч янавын һәм Шәрекътә үзенә каршы торырлык яңа көндәше пәйда булуын тоя. Бу каршылыкның нигезе, әлбәттә, христиан диненең исламга дошманлыгы белән билгеләнә. Шунысын да онытмыйк, Византия җимерелгәннән соң, Мәскәү тышкы сәясәт өлкәсендә үзен «өченче Рим» итеп күрсәтергә омтыла. Аңа шушы максатын тормышка ашыруда Мәскәүнең Көнчыгыш чигендә бердәнбер куәтле-шанлы мөселман мәмләкәте — Казан ханлыгы гына төп киртә булып тора. Ә Чыңгыз хан империясенең бүтән калдыкларына — үзара дошманлашкан күпсанлы урдаларга, кабилә берләшмәләренә, кенәзлекләргә килгәндә исә, аларның берсе дә Мәскәү өчен җитди куркыныч чыганагы саналмый. Кырым ханлыгы әледән-әле Мәскәүгә һөҗүм оештырып торса да, Мәскәү үзен чагыштырмача иркен тоя.

Бу дәвердә Казан ханлыгында да тыныч булмый — тәхетне кулга төшерү өчен төрле сәяси төркемнәр көрәше көчәя. Мәскәү моны үз максатында бик оста файдалана. XV гасыр ахырында Казан берара Мәскәүгә тәмам бәйле хәлгә төшә — ул ни кушса, шуны үти. Моңа, бәлкем, урда һәм Казан биләмәләреннән чыгучыларны Мәскәүнең үз канаты астына алуы, аларга җир, бояр һәм дворян исемнәре бирүе дә сәбәпче булгандыр. Касыйм ханлыгы, мәсәлән, моның ачык мисалы. Бу дәүләт хакимияте һәм кешеләре Казанга һөҗүм белән килүдә гел Мәскәү ягыннан торып катнаша. Мәскәү кенәзлеге эчендә шундый биләмә яшәү, анда дини йолаларны иркен үти алу Төркия һәм башка мөселман дәүләтләре янәшәсендә урысларның дустанәлеген күрсәтүгә хезмәт итә...

Мәскәү белән Казанның йөз елдан артык сузылган тартышуы, барыбыз да белгәнчә, 1552 елда ханлыкның вәхшиләрчә тар-мар ителүе, рәхимсез талануы белән тәмамлана. Бик күп еллар дәвамында Русия, ә аннары совет тарих фәне моны игелекле эш дип танытып килде. Әлеге фикерне дәлилләү өчен Маркс белән Энгельс хезмәтләреннән өзекләр китерергә дә онытмадылар. Ә инде урыслар яки славяннар адресына нинди дә булса тискәре фикер әйтелсә, аны күрмәмешкә, белмәмешкә салыштылар. Югыйсә, бу адым яңа түгел. Икейөзле бәндәләр бүген дә шулай итә.

Идел буенда татар халкының шуннан соңгы тормышы Мәскәү дәүләте һәм Русия империясе шартларында узды һәм анда яшәгән башка барлык халыкларның аяныч язмышыннан аерылгысыз булды.

Татар халкы үткәненең шушы чорына күзәтү ясаганда иң әүвәле түбәндәгеләрне истә тотарга кирәк:

1552 елда заманына күрә шактый алга киткән, дөньяның башка илләре белән тулы канлы сәяси һәм икътисади хезмәттәшлектә яшәгән бәйсез дәүләт басып алына.

Анда дәүләтчелекнең эзе дә калмый. Байтак халык яшәгән урыныннан күчеп китәргә мәҗбүр була, ә югары үсешкә ирешкән уңдырышлы төбәкләрдән (Казан тирәсеннән, Идел ярларыннан) аларны көчләп куалар һәм әйләнеп кайтырга рөхсәт итмиләр.

Бу дәүләт төрки халыклар даими яшәп килгән җирләрдә төзелгән була.

Мәктәпләр, мәчетләр, китапханәләр юк ителә, җәмгыятьнең рухи мәдәниятен яклап килгән башка оешмалар шулай ук җимерелә.

Бу дәүләтнең куәтле күршесе тарафыннан йотылуы халыкның эреп юкка чыгуын аңлатмый. Ул беркайчан да үзенең вакытлыча басып алынган дәүләттә яшәгәнлеген онытмый.

Хәер, Русия хакимияте дә «Польша патшасы»н, «бөек фин кенәзе»н санап киткәндә иң беренче булып Казан патшасын телгә ала. Югарыда әйтелгән, Русия империясенә кергән ике дәүләт күптән инде тулы канлы мөстәкыйльлеккә ирештеләр.

XX гасыр башына кадәр диярлек Казан губернасы әллә ни үзгәреш кичерми һәм Казан ханлыгы мәйданының иң зур өлешен биләп тора. Губерниягә урыс

халкының күпләп күчеп килүенә дә карамастан, татар халкы милли үзенчәлеген югалтмый. Көчләп чукындыру да уңыш китерми, мәчетләрне күпләп кыру да татар халкын тезләндерә алмый. Әйтергә кирәк, мондый шартларда халыкны туплаучы һәм берләштерүче, аның милли үзаңын саклап калучы көч булып алга дин чыга. Халкыбыз үзенә аң-гыйлем биргән муллаларына рәхмәтле. Татар халкының чагыштырмача югары дәрәҗәдә укымышлы булуын замандашлары да танырга мәҗбүр булган.

Казан губернасының төп үсеш дәверләре һәм андагы халыкның тормыш дәрәҗәсе Русиянең башка төбәкләреннән әлләни аерылып тормый. Шулай да бу елларны татар милләтенең акрынлап күтәрелү еллары да дип әйтергә була. Аның аерым вәкилләре төрле һөнәрләрдә шактый зур уңышка ирешә. Мәсәлән, татар офицерлары, түрәләре һәм сәүдәгәрләре үсеп чыга. Татар иҗтимагый фикере дә акрынлап ныгый бара, канатын җәя. Халык иҗаты чишмәсе дә корымый. Дастаннар, бәетләр, җырлар, мөнәҗәтләр иҗат ителә.

XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында Русиядә иҗтимагый-сәяси хәрәкәт күтәрелеше татар аңында да чагылыш таба. Монда шулай ук күп нәрсәгә ачыклык кертәсе бар әле. Күп вакыт социал-демократларга гына ярарга тырышып, татарларны да шулар эшчәнлеге кысасына кертергә маташтылар. Ул чакта татар җәмәгатьчелеге өчен кадимчеләр һәм җәдитчеләр бәхәсе күпкә мөһимрәк иде. Шуңа күрә монда сыйнфый большевистик күзлектән карап фикер йөртү урынсыз. XX гасыр башында татар халкының рухи тормышы тарихында тирән эз калдырган күп кенә сәяси эшлеклеләребез көрәш мәйданына чыкты. Бүген без Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Һади Атласов, Гариф Бадамшин, Габделбари Баттал, Гаяз Исхакый, Габдерәшит Ибраһимов, Риза Фәхретдинев, Муса Бигиев, Сәетгәрәй Алкин кебек затларны хөрмәт белән искә алабыз. Шушы дәвердә әдәбиятыбыз да моңарчы күрелмәгән биеклеккә күтәрелә. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Галиәсгар Камал исемнәре халыкның горурлыгына әверелә. Алардан аз гына алдарак Казанда татар иҗтимагый фикере дөньясында тиңе булмаган тарихчы, акыл иясе Шиһаб Мәрҗани яши һәм иҗат итә. Ул үзенең иҗатында гаять зур тарихи чорны — урта гасырлардан алып XX гасырга чаклы заман вакыйгаларын колачлап ала.

**Хәзер инде курыкмыйча әйтергә дә була: Ленинның халыкларның иҗтимагый тормышында «ике мәдәният» яшәп килә дигән бәяләмәсе, гомуми канун буларак, заман сынавын уза алмады. Әлеге ялганга ышандырмакчы булып, «тугры ленинчылар» җиде дистә ел буе безгә шуны тукып килде. Татар халкының иҗтимагый тормышында социал-демократик агым булганмы дигән сорауга килгәндә, шуны әйтергә мөмкин: кемнәрдер соңыннан күпертеп күрсәтергә теләгәнлектән, ул, әлбәттә, «киң колач җәйгән». Нәрсә-нәрсә, әмма күпертергә, дәүләт күләмендә әкият уйлап чыгарырга осталар күп иде бездә. Казан университетындагы студентлар җыйналышын гына искә төшерик. Ул илкүләм вакыйгаларга ни дәрәҗәдә йогынты ясый алган соң? Тарих китапларында исә студентлар «шау-шуы» Бастилиягә утыртылу белән тиңләнде! Ләкин, әйтергә кирәк, В. И. Ленин мондый күпертүләргә ирониялe караштa була.**

Патшаны тәхетеннән төшерү һәм Октябрь фетнәсе арасындагы чор татар җәмгыяте өчен сәяси эшчәнлекнең моңарчы күрелмәгән үсеше, яңа юлбашчылар үсеп чыгу, тормыш куйган катлаулы сорауларга җавап табарга омтылу белән билгеләнә. Гомумдемократик һәм милли хәрәкәтләр белән бергә, радикаль агымнар да барлыкка килә, соңгыларына башлыча большевиклар һәм эсерлар җитәкчелек итә. Төрле-төрле милли оешмалар һәм алар төзегән органнар арасында без Мәскәүдә һәм Казанда узган мөселман җыеннарына, хәрби «Шура» оешмасына, милли мәҗлескә, мөселман социалистлар комитетына килеп юлыгабыз. Русиянең, нигездә Европа өлешендә эш йөрткән әлеге хәрәкәтләрдә һәм оешмаларда юлбашчыларның күпчелеген татарлар тәшкил итә. Бөтен иҗтимагый-сәяси атмосфера, ил үзгәрешенә якынлык, беренче нәүбәттә, нәкъ менә татар эшлеклеләрен сәяси көрәш учагына тартып керткән, күрәсең.

Октябрь фетнәсе һәм шуннан соңгы Гражданнар сугышы милли сәясәт өлкәсендә Большевиклар моделенең җиңеп чыгуына китерә. Алга килеп баскан мәсьәләләрне дөрес хәл итүдә һәрчак соңга калган, «бердәм һәм бүленмәс» чире белән авырган Вакытлы хөкүмәткә һәм башка көчләргә караганда, большевиклар елдамрак һәм өлгеррәк булып чыга. Мөселман халыкларының шушы кармакка ничегрәк килеп эләгүләре аңлашыла торгандыр. Алар нәкъ менә большевик юлбашчылар кул куйган декрет һәм өндәмәләрдә үзләре өчен азатлык авазын ишетә. Еллар узгач, халыклар язмышы хәл ителгән бер вакытта, бу өндәмә башкачарак формада яңгырады: **«мөстәкыйльлекне үзегез «йота алганча»**

**алыгыз».** Кем әйтмешли, еласаң — ела, көлсәң — көл. Тарихта нинди генә хәлләр булмый. Русиядә барлыкка килгән милли дәүләт корылышына карата большевиклар сәясәтендә төгәл генә ачыклык булмавын басым ясап әйтергә кирәк. Бу бигрәк тә автономияләр бирүдә ачык чагыла. Сталин сүзе белән әйткәндә, аны «буржуаз кабәхәтлек»тән арындырырга туры килә. Әнә шундый «гөнаһсыз» автономия бүләк итеп тә, һәммәсен искечә, Русия империясендәгечә саклап калу принцибы Татарстан белән Башкортстан мисалында да үтәдән-үтәли күренә. Гражданнар сугышы елларында телдән төшмәгән мөстәкыйльлек кануны («үз гореф-гадәтләрегез буенча яшәгез һәм эш итегез»), сугыш тәмамлануга, капма-каршы юнәлеш ала. Бөтен дөнья революциясе ясалмаганлыктан, социализмны хәзер бер генә илдә төзергә туры килә. Мондый шартта халыкларның милли мәнфәгатьләре кемгә кирәк соң? Политбюроның яшертен карарларына караганда, Татарстан һәм Башкортстан белән мөнәсәбәтләр Украинаныкы кебек төзелергә тиеш була. Әмма казарма социализмы шартларында әлеге автономияләргә бирелгән хокуклар тиз арада юкка чыгарыла.

**Шуннан соңгы елларда Татарстан, автономияле генә булганлыктан, гади генә мәсьәләне хәл итәр өчен дә Мәскәүгә баш иеп барырга мәҗбүр була. Әйтик, республикада нинди дә булса авыл яки поселок исемен үзгәртү мәсьәләсе күтәрелсә, РСФСР Югары Советы махсус указ чыгарырга тиеш иде. Республикаларның әнә шундый гади генә хокуклары да булмау СССРның таркалуына китерде дә инде. Эш моның белән генә чикләнеп калмый, Русия үзе дә таркалуга таба тәгәри. Чөнки ул да, күнегелгән юлдан барып, халыкларга, милли автономияләргә ирекле үсеш хокукын бирмәскә тырмаша.**

**Элеккеге автономияле республикалар алдында кыен хәлдән горур рәвештә чыгу бурычы тора. Моның бер юлын Татарстан күрсәтте. Тормыш аның дөрес юлдан атлап баруын раслый.**

**Рашат Низамиев**

# БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ТАТАРЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

*Мин Татарстан бөтен татар диаспорасын берләштерүче булырга һәм Россиянең милли сәясәтенә җитәрлек дәрәҗәдә йогынты ясарга тиеш дип исәплим.*

Татарстан Президенты М. ШӘЙМИЕВнең Бөтендөнья татар конгрессында сөйләгән чыгышыннан

Сүзнең башында ук иң элек Болгариядә эшләнгән «Аспарух хан» фильмындагы бер эпизодны хәтергә төшерик әле... Көче-гайрәте, матурлыгы ташып торган улларына Кубрат хан бик тә гыйбрәтле, фәлсәфи сабак күрсәтә: укны берәм-берәм бик ансат сындырып була икән, әмма себерке сыман төйнәп-җыйнап куйсаң, аларны сындырып ташлау һич кенә дә ансат эш түгел. Бу хакыйкатьне, ягъни бердәмлекнең нинди зур көч икәнен, шәт, аңлатып тору кирәкмидер.

Хәтерлим: без — Казан дәүләт университетының икенче курс студентлары — татар халык авыз иҗатын өйрәнү өчен 1969 елның җәендә Чиләбе өлкәсенә чыгып киткән идек. Уку программасында каралган бик тә җитди хезмәт бу. Шуңа күрә фәнни җитәкчебез дә, юл йөрерлек акчабыз да бар. Татарлар күмәкләп яши торган байтак районнарны гиздек. Кушнаренко районында исә менә нинди хәлләр белән очрашырга туры килде. Ике татар авылы — икесендә ике төрле язмыш! Авыл исемнәрен әйтеп тору кирәкмидер, дөресрәге, мин инде аларны хәзер төгәл генә хәтерләмим дә. Берничә иптәшем белән егерме-утыз йортлы кечкенә авылга килеп кердек. Көн эссе булганлыктан, урамда җан иясе әллә ни күренми. Йортларның балкып торганнары да, инде кыйшая башлаган мескенрәкләре дә күзгә чалына. Әйткәннәр иде: катнаш авыл бу, биредә татар белән урыс бергә яши, дип. (Кызганыч, ни сәбәпле катнаш икәнлеген сорарга ул чакта башка килмәгән...) Менә шушы авылда татарларның баштарак русча сөйләшергә тырышулары гаҗәпләндерде безне. Казаннан икәнлегебезне белгәч кенә телләре чишелде тагын. Хәтта бер агай, юмартланып китеп, бер чәйнек ачы бал чыгарды һәм болайрак җырлап та күрсәтте әле:

Без эчмәйбез пшеничный,
Без эчәйбез першувка.
Без эчмәйбез берәр сутка —
Без эчәйбез биш сутка!

Шулайдыр шул: кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дигәннәр ич. Русча сүзләр мул катнашкан бу иҗат җимешенең эчтәлеге-мәгънәсе дә «урысча»рак бөселеп чыккан... Фольклор үрнәгенең мондый «ачысын» җитәкчебезгә бирдекме-юкмы, хәтерләмим, әмма ул минем куен дәфтәремдә теркәлеп

калды. Соңрак икенче бер авылга кердек. Монысы инде гаять зур иде, меңгә якын хуҗалык, диделәр. Саф татар авылы. Бөтенләй башка тәртип бирелә: авыз тутырып татарча сөйләшәләр, татарча җырлыйлар. Казан хәлләрен сорашалар. Өстәлдә — чәй, юкә балы, чәк-чәк, бер өйдә хәтта кайнар өчпочмак белән дә сыйладылар әле.

Менә хәзер, еллар үткәч, кайта-кайта уйланам: кечкенә авылларда безнең милләт, тагын да дөресрәге — татар рухы азрак саклана икән! Зур, бердәм, оешкан авылларда исә милли рух, традиция һәм гореф-гадәтләр тотрыклы яши, буыннан-буынга күчә килә.

Хакыйкать кайда да кабатлана, күрәсең. Нәкъ менә шушыңа охшашрак хәлләрне миңа, Чувашстандагы татар әдәбияты көннәрен искә ала-ала, күренекле бер шагыйребез сөйләгән иде. Анда да нәкъ шундыйрак күренешкә юлыкканнар: кече авылда безнең милләттәшләр бикләнеп-йомылып яши, күмәкләшеп яшәгән зур авылларда исә татарның рухы вә әхлагы бөтенләй башка югарылыкта...

«Бер, ике, өч... бердәмлектә көч!» — дип җырлый идек без бала чакта.

«Бердәмнеке берәгәйле»,— дип өйрәтә иде әткәй мәрхүм.

«Ватансыз кеше — бакчасыз сандугач» — дигән канатлы сүзләр дә хәтердә уелып калган тагын.

Бердәмлек турындагы әлеге хакыйкатьләр минем газиз халкыма, аның тарихына да кагыла. Булган бит көчле чакларыбыз! Төрле илләр һәм кыйтгаларга тузганактай сибелеп, таралып бетүебез дә хак анысы. Тарих мәйданы элек-электән ду килеп кайнап торган, илләр сугышкан, кан коелган, халыклар яшәү өчен көрәш алып барган... Уйлап карасаң, табигатьнең үзендә билгеле бер тәртип, гармония, камиллек бар. Нигә соң кеше тикле кешелек яшәп яткан җәмгыятьнең үзендә дә шуңа охшашлырак тәртип-низам, гармония, үзара аңлашу ныклап тамырланып китә алмый? Әлбәттә, ут белән суны кушып булмаган шикелле, табигать белән җәмгыятьтәге тәртипләрне дә тоташтан тәңгәл куярга ярамыйдыр. Әйтик, табигать күренешләрен Дарвин «кем көчле, шул җиңә» дигән хакыйкать белән аңлатып бирде. Бу сүзләрдә хаклык зур иде. Аннары, аның шушы тәгълиматын байрак итеп, җәмгыятьтәге күренешләрне дә шушы эздән аңлатырга тырышучылар табылды, нәтиҗәдә «социаль дарвинизм» дигән төшенчә туды. Ә нигә, бер уйласаң, шулай түгелмени? Сугыш тарихларына, ил белән ил арасындагы низагларга күз салсак, көчле якның һәрвакыт җиңеп чыгуын, өстенлеген күрербез. Әмма...

Табигатьнең җанлы һәм җансызга бүленгән күптөрле күренешләреннән аермалы буларак, адәм балаларына акыл, хәйлә, зирәклек дигән нәрсәләр дә бирелгән. Җәмгыять тормышын, аның яшәү кануннарын иҗат итүдә кешенең әлеге сыйфатлары хәлиткеч роль уйный. Батырлык һәм Куркаклык, Намус һәм Мәкер, Мәхәббәт һәм Нәфрәт тарихта һәрвакыт янәшә атлаганнар. Кешелек язмышындагы байтак кына сәхифәләр менә шушы хакыйкать каләме белән дә язылган...

Тарихны хәтерлик. Ил-халыкларның глобаль язмышларын искә төшерик. Тарих сәхнәсе элек-электән зур — анда нинди генә халыклар уйнап китмәгән дә, кайсы гына халыклар тәкъдир чоңгылына кереп батмаган! Заманында дөньяны дер селкетеп торган греклар, римлылар, испан, монгол халыклары бүген әнә гап-гади тормыш белән яшәп ята: тыныч кына җир сөрәләр, мал асрыйлар, матди байлык җитештерәләр, сәүдә белән шөгыльләнәләр... Уналтынчы гасыр урталарында, каяндыр чәчрәп чыгып, ут һәм кылыч болгап, сәхнәгә урыс кавеме күтәрелгән. 1552 елда Казан ханлыгын яулап алганнан соң, алар акрынлап Җир шарының алтыдан берен хуҗа булалар, җиде диңгезгәчә барып чыгалар. Ләкин бу фани дөньяда бер генә нәрсә дә мәңгелек түгел. Октябрь түнтәреше иске Россияне пыран-заран туздырып ташлады, шуның җирлегендә тора-бара СССР дигән уникаль империя оешты. Әмма Советлар Союзы — көчләп, ясалма юл белән тудырылган ил иде, әгәр шулай әйтергә ярасa, гигант бер аквариум шикеллерәк. Андагы милләтләр, нинди җим сипсәләр — шуның белән тукланырга, бертөслерәк яшәү рәвешенә дучар ителгәннәр иде. Ләкин бу «аквариум» нибары 70 елга гына чыдады. Аны чистартырга, анда яшәүчеләргә кислород бирергә кирәк иде. Ниһаять, чистартырга керештеләр, кислород кранын ачтылар. Империя колониясендә яшәгән байтак кына милләтләр азатлыкка юл тотты, мөстәкыйльлек урамына аяк басты. Чын мәхәббәт, хөрмәт, «интернациональ» дуслык, гәрчә партия һәм хөкүмәтнең ул чактагы документларында еш-еш әйтелә килсә дә, тормышның үзендә чынлап торып булмаган, күрәсең. Үз хокукларын яклап, Балтыйк буе һәм башка республикаларда хәзер урыс халкын ачыктан-ачык кысарга, икенче сортлы халык хәленә калдырырга тырышалар... Язмыш бит көчлеләр белән дә ничекләр генә уйнамый әнә!

Онытып җибәрмик: бу дөньяда татар дигән безнең гайрәтле кавем дә бар бит әле. Заманында «татар» белән «хәтәр» сүзләре рифмалашкан икән, бу бер дә юкка түгел, әлбәттә. Тарих сәхнәсендә безнең татар да уйнап караган сон! Француз философы Шарль Монтескье сүзләрен искә төшерик: **«Без белгән күпме мәмләкәтләргә татарлар тарафыннан нигез салынган. Бу гаярь халык беркайчан да җинелмәсенә ышанган хәлдә, вакытлы дан белән мавыгып, үзенең үткәндәге җиңүләрен мәңгеләштерү турында уйлап та карамаган».** Әйе, татарның да дөньяны кулында тоткан чаклары булган. Мин бу хакта тәфсилләп язарга, галимнәрне кабатларга җыенмыйм, максатым да ул түгел. Ниятем — бүген һәм иртәгә татар нишләр, тарих вә алгарыш сәхнәсенә ул көчле милләт буларак яңадан әйләнеп кайтырмы, әллә башка халыклар кочагында эреп юкка чыгармы, дигән сорауга үземчә азмы-күпме җавап табарга тырышу.

Бүгенге хәлебезнең торышы һәркемгә мәгълүмдер. СССР җимерелер алдыннан да, инде аның «шинелен» киярга азапланган Россия янәшәсендә дә яңа Татарстан (кемдер теләгәнчә Татария түгел!) үзенең мөстәкыйльлек мәсләген алгы сызыкка куеп сөйләште һәм сөйләшә. Ни генә димик, күп нәрсә барыбер халык һәм хаклык сүзенә колак сала белгән җитәкчеләрдән, милли лидерлардан тора. Бу очракта беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең тарихи хезмәтен, сәяси зирәклеген аерым әйтеп китми мөмкин түгел. Шөкер, иң катлаулы сәяси шартларда да Татарстанның суверенитеты хакында Декларация игълан ителде. Инде, ниһаять, үз Конституциябез юлга салынды. Мәскәүнең информацион чаралары, гомер булмаганны, соңгы елларда Татарстан турында аклы-каралы төсләрдә шаулатып сөйли башладылар. Элекке СССРның байтак төбәкләрендә сугыш, ызгыш-талаш кабынып китсә дә, Татарстан иске илнең уртасында тынычкүркәм бер дәүләт буларак яши бирә. Аның төп ике сыйфаты, ике канаты күзгә бәрелеп тора: ул да булса — сәяси һәм икътисади яктан тотрыклылык! Чит илләрнең дәрәҗәле, сизгер эшкуарлары менә шуны бик тиз күреп алдылар һәм республикабызга хезмәттәшлек кулы суздылар.

Соңгы елларда тагын ниләр эшләнде соң, дисәк, әле тагын байтак уңышларны санап китәргә булыр иде. Әйтик, Татарстан Фәннәр Академиясе оешты. «Татар энциклопедиясе» китабына әзерлек эшләре бара. «Татарфильм» киностудиясе аякка басып килә. БТИҮ, «Иттифак», «Азатлык», «Мәрҗани» кебек милли фирка һәм оешмалар көрәш мәйданына чыкты. Милли мәктәпләребез, матбугат җанланды һ. б., һ. б. Бәй, күрегезче, татар — гайрәтле дә, каһәрләнгән дә татар — тәмам уянып килә түгелме соң? Милләтпәрвәр кешеләрнең йөрәгенә менә шундый горурлык ташкыны тулды. Кабынды, канат какты якты өметләребез!

Әйдәгез, бар нәрсәгә куана белик, тик бу — коры куаныч булмасын. Ә бит татар проблемасының тамырлары бик тирәнгә китә, аның чишелешен бүген-иртәгә генә табу мөмкин түгелдер. Гомумән, минем бу очракта мәсьәләне кабыргасы белән куясым килә: бармы соң ул бүгенге көндә татар? Бармы милләтебезне бизәрдәй олуг, талантлы шәхесләребез? Сорауны болай куюның хикмәте шунда ки, чөнки теләсә кайсы милләтнең йөзен, кагыйдә буларак, аның күренекле шәхесләре — «манаралары» билгели. Әйтик, Францияне — Эйфель башнясы, АКШны — Азатлык һәйкәле, Татарстанны Сөембикә манарасы гәүдәләндергән шикелле рәк. Сорау куелганнан соң аз гына чигенеш ясап алыйк. Соңгы җитмеш елда гына да татарның генофондына өч тапкыр удар ясалды: гражданнар сугышы, шәхес культы, аннары Бөек Ватан сугышы корбаннары... Башка милләтләр белән берргәттән, шушы һәлакәт кырларында татарның да иң эшчән һәм иң зыялы вәкилләре юк ителде...

Менә шуннан соң да — буыннар дисбесе шартлап өзелгәннән соң да — татарның күзәнәге, шөкер, яшәүчәнлек сәләтен югалтмаган икән әле! Мисаллар җитәрлек. Бу җәһәттән иң элек дөнья күләмендә танылган академиклардан Роальд Сәгъдиев һәм Камил Вәлиевне, вулканнар белгече Һарун Тажиевне, бию сәнгате осталарыннан Рудольф Нуриев һәм Ирек Мөхәммәтевне санап китик. Әйе, болар — саф татар баласы, аларда татар каны ага. Тик шунысы кызганыч: аларда космополитизм көчле, татар икәнлекләрен арткарак күчерергә тырышалар, милләткә хезмәт итү вә файда китерү турында артык борчылмыйлар кебек... Хуш, инде шахмат дөньясыннан берничә күренекле исемне атап китик: Артур Йосыпов, Евгений Бариев, Алисә Галләмова, Гата Камский. Һәммәсе дә дөнья күләмендәге атаклы уенчылар. Юлларына ак җәймә — уйнасыннар, көндәшләрен ота бирсеннәр генә. Әмма, мина калса, аларда да милли горурлык хисе әллә ни чәчрәп тормый бугай. Дөрес, бу җәһәттән Гата Камский шактый нык аерылып тора. Казанда әтисе Рөстәм әфәнде белән берничә мәртәбә булды, киләчәктә Татарстан флагы астында уйнарга теләге барлыгын ачыктан-ачык белдерде. Рәхмәт аңа!

Ни өчен читтәге күренекле татарларыбыз милли горурлык хисенә, гадәттә, салкын карыйлар яисә бу хисне күңел төпкелендә тыйнак кына «яшереп» тоталар соң? Ах, дусларым, моның артында әллә ничаклы тарихи, сәяси, социаль-иҗтимагый сәбәпләр бөялеп ята шул! Инде дә төптән уйлап карасак, шуларның һәммәсе дә бер генә нәрсәгә — дәүләтчелегебезне югалту факторына кайтып кала. Менә шуның кайбер сөземтәләре:

**— 400 елдан артык Рәсәй басымы астында яшәдек һәм әле дә булса яшәп ятабыз. Урыс дәүләте мәнфәгатьләренә хезмәт итеп, аның өлгесенә авышып гомер кичерүләр безнең бик күп милли сыйфатларыбызга, шул исәптән милли горурлык тамырларына сукты;**

**— татарның күп кенә акыл ияләре, 1552 елда дәүләтчелеген югалткач, ирексездән Россия самодержавиясенә хезмәткә мәҗбүр ителде. Андыйларның нәселе, акрынлап, хәтта исем-фамилияләренә кадәр «урыслашып» бетте. Тарихта моның мисаллары күп;**

**— җиңүче, дөресрәге, яулаучы буларак, тарихны Мәскәү һәрвакыт үз файдасына, үзе «теләгәнчә» итеп язды. Үзе өчен иң көчле көндәш саналган татарны начар, явыз затлар итеп күрсәтүгә ирешә. Хәтта совет дәреслекләрендә дә, әдәбиятта һәм кино сәнгатендә дә татар күпвакыт ерткыч һәм дошман сыйфатыннан дарак бирелде. Бу чеп-чи ялган фикерне тора-бара хәтта Европа аңына да дыңгычлап тутырдылар. Менә шуннан соң, кешечә яшисең һәм ашыйсың килсә, кем инде «мин — татар!» дип күкрәк каксын икән!?.**

**— чечен, балкар һәм тагын башка милләтләрне заманында Сталин туган җирләреннән көчләп кудырды. Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы варислары булган татар белән исә мондый телдә сөйләшү җиңел булмаячак иде. Шуңа да аны, «эш аты» буларак, идеологик кампанияләр шаукымы астында империянең төрле төбәкләренә тараттылар. Нәтиҗәдә, татарның бердәмлеге, теле, рухы, гореф-гадәтләре нык югалту кичерде, совет халкы диңгезендә ассимиляциягә дучар ителде;**

**— Татарстан — татарның татар икәнлеген юридик яктан беркетүче бердәнбер җөмһүрият. Ләкин ул бүгенге көндә геополитик җәһәттән бик тә җайсыз урында утыра. Менә дүрт-биш гасыр инде татарның ирекка омтылышы Россия чолганышында: географик яктан да, тарихи-иҗтимагый яктан да. Совет дәверендә исә ул рухи-мәдәни өлкәдә әлеге чолганыш элмәкләре белән тагын да ныграк уратылды — шәт, моны аңлатып тору кирәкмидер.**

Кыскасы, талантларыбыз әнә шул фаҗигале сәбәпләр аркасында элек-электән читкә сибелде, алар татар халкы һәм дәүләтчелегебез файдасына түгел, Русия мәнфәгатьләренә хезмәт иттеләр. Бер генә мисал. Быелның февралендә мин Мәскәүдә татарның генераллары-адмираллары очрашуында катнашкан идем. Милләтебезнең дистәләгән зур хәрбиләре җыйналып, анда миңа аларның күбесе белән якыннан аралашырга, әңгәмә корырга туры килде. Менә шунда шаккаттым: хәрби һава көчләре, флотилия һәм атом су асты гаскәрләренең иң җаваплы урыннарында безнең татар егетләре утырган яисә утыра икән ләбаса! Җиз иләктән, милли һәм тагын әллә нинди киртәләрдән сөзелеп ничек шундый да мәртәбәле дәрәҗәгә ирешә алган соң алар? Уйласаң, һаман да бер нәрсә калкып чыга: халкыбызга хас тырышлык, булганлык, сәләт, яхшы мәгънәсендәге үҗәтлек һ. б.

Ә бит милли байлык үз йортында газизрәк, үз халкың өчен кадерлерәк. Бу — хакыйкать. Кемнәрдер Тукаебызны Балтыйк буе халыкларына бөек шагыйребез дип күрсәтергә тырышкан иде, ни гаҗәп — тегеләр аңлый алмадылар. Бәлки, әйтик, америка халкы да Тукай иҗатын тулысынча кабул итә алмастыр, ул бит детективлар яисә шигъри шарадалар язган әдип түгел. Әмма Тукай — безнең өчен иң әүвәл халкыбызның бәгыре, азатлык җырчысы, үз илендә пәйгамбәр шәхес. Гаяз Исхакый да, әнә, күпме генә тыюларга карамастан, барыбер үз иленә, үз халкына әйләнеп кайтты. Ул элек тә үз милләтенә хезмәт итте, хәзер дә халкыбызның милли азатлык хәрәкәтенә тугры төстә хезмәт итә килә.

Татарның күренекле хәрбиләре белән очрашуны хәтердән уздырам да, янадан бер сорауга барып төртеләм: ни өчен соң теге чакта татар егетләреннән бер генә космонавт та чыкмады икән? Безгә бары анекдотлар гына килеп ирешә: Гагарин дигән сүзне «татарин» дип ишетеп, Хрушев бик нык гаҗәпләнгән, имеш. Бу очракта да һаман бер үк нәрсә аяк чалгандыр: татарны галәм кочагына җибәреп, аның данын күтәрергә ярыймы соң, аллам сакласын!

Әйе, шовинист җитәкчеләр урыс халкын элек-электән «бөек милләт», башка халыкларның өлкән туганы дип игълан итә килделәр. Шул ук вакытта татарны сәяси карачкы, «дошман» образы сыйфатында сурәтләргә дә онытмадылар.

Чөнки сәләте, тырышлыгы, яшәүчәнлеге шулкадәр көчле ки, башына сугып тормасаң, менә-менә үзенең элекке гайрәтле чагына әйләнеп кайтуы мөмкин аның. Югыйсә, гаделлек каланчасыннан карасаң, бу милләткә рәхмәт кенә укыйсы бит: күренекле тарихчы Лев Гумилев раславынча, нәкъ менә татарлар калканы Россияне Көнбатыш явыннан саклап кала, буфер ролен үти. Никадәр сәер тоелмасын, шул ук вакытта Европаны Россия коллыгына төшерүдән дә аралап торган бу халык. Тарих рәхмәт әйтә белми, рәхмәтне киләчәктән көтәргә кирәктер. Без, берләшеп, татарның дәүләтчелеген торгыза алабыз, цивилизацияле илләр дөньясына аяк басабыз икән, моның өчен киләчәк буын безгә, һичшиксез, рәхмәтен әйтер.

Тагын бер мәсьәләгә тукталу зарур. Сан ягыннан татарлар Россиядә икенче урында тора. Бәйләнер урын юк, бу — төгәл мәгълүмат. Рәсәйнең шовинист житәкчеләре бу санны бар җәһәттән кыскартырга, кечерәйтергә тырыштылар, билгеле. Инде дә татарны «кечерәйтәсең» килә икән, аны ничек кимету хәйләсен уйлап табарга кирәк. Халыкларны тигезләү, совет кешесе ясау сәясәте нәкъ менә шуңа хезмәт итте дә инде — илдә урыс халкы янсә иң кимендә урыс телендә сөйләшүчеләр саны гына арта бирсен! Статистика фәнен һәм аның мәгълүматларын хөкүмәт үз кулында нык тота белде ул чакта. Милли мәктәпләр ябылуга дучар ителгәнгә, урыслашкан саен тормышта һәм хезмәттә яшәү мөмкинлекләрең арта барганга күрә, нишлисең бит, бик күпләр, рәсми анкеталарга үзләрен «рус» дип язуны мәслихәт санады. Татарның итәк-җиңнәрен менә шул рәвешләрәк тә бик тиз кыскарттылар. Без һаман да, жиде миллион татар бар, дип сөйләшәбез. Бик тә шикле, бәхәсле саннар икәнлеге хакында уйлаучылар аз. Бу мәгълүмат, әлегә дә баягы, фәкать статистика җимеше. Табигатьтәге татар тумышын, татар канлы кешеләрне чынлап-торып исәпли башласаң, бөтенләй башка саннар пәйда булачак. Наполеонның: «Урысны тырнасаң, татар килеп чыга»,— дигән мәгълүм сүзләре әле бүген дә кыйммәтен югалтмаган. Шагыйрь Ренат Харисның «Татарлар» дигән монолог-поэмасыннан түбәндәге юллар да шуңа ишарә:

> Русны «бераз тырнаштырсаң,
> Татар чыгар!..» — дигән кемдер!
> Халкың газиз түгел икән,
> Шул татарны, яле, күмдер —
>
> Так аңа башка бер исем,
> Йә бүлгәлә кисәкләргә...
> Без күнегеп беткән инде
> Зурны ватып исәпләргә.

«Төрек дөньясы әл-китабы» (Анкара, 1976 ел) мәгълүматларына караганда, дөньядагы төркиләр арасында татарлар 12 миллион тәшкил итә. Мәсьәләгә мораль-әхлакый критерийлардан якын килсәк, бу саннар — арту хисабына тагын әллә ничаклы үзгәрешләр кичерәчәк әле! Тик менә җисеме, нәселе, каны татар булып та, әгәр ул үз милләте өчен янып-рухланып яшәмәсә, аның мәнфәгатьләренә үз өлешен кертмәсә, милли тамырларын өзеп ташлаган саналса — мондый кардәшебезне статистиканың кайсы ягына кертергә икән соң?

Кайчагында, дөресрәге, үзенә кирәк чакта, Россия дә үзенең белдемәсендә 5 миллион татар яшәгәнлеген искә алырга ярата. (Яулап алынган янсә урыслашкан татарлар икәнен онытa, әлбәттә). Европа аршины белән үлчәгәндә, 5 миллион халык — үзе бер дәүләт дигән сүз! Шушы миллионлы халык кырларда, завод-фабрикаларда, дәүләт оешмаларында турыдан-туры Рәсәйгә хезмәт күрсәтә, аның матди байлыкларын арттыра, хөкүмәтнең коедай төпсез кесәсенә әллә ничаклы салымнар түли. Әмма ни кызганыч: бу халыкның үзләре яшәп яткан Рәсәй җирендә туган телендә ни газета чыгарырга, ни телевизион тапшырулар оештырырга хакы юк иде. Чөнки беркайчан да рөхсәт булмады, элеккечә әйтсәк, «нез-зя!» Эшләргә, кол булырга хокукың бар, ләкин нәрсәдер таләп итәргә хакың юк. Рәсәйнең сукыр, милли мәсьәләдә баш бирмәс сәясәте әле һаман да әнә шулайрак фикер йөртә. Фикерне бик үзгәртерләр иде, «бүленмәс һәм таркалмас Россия»нең сүтелеп төшүеннән курка лар.

Әгәр мөстәкыйль Татарстан сәяси, икътисадый һәм тагын башка бик күп яклардан гөрләп чәчәк атачак икән, Россия моны бик авырдан кичерәчәк, билгеле. Чөнки белдемәсе ифрат зур, халык саны шулкадәр күп — тик анда җиң сызганып, хуҗаларча эшләргә теләүчеләр генә әллә ни күренми. Талау һәм яхшы

урыннарга күчену психологиясе геннарына сеңгән. «Нечерноземье» дигән киңлекләренә никадәр акча ташлап карадылар әнә, әмма алга китеш күренмәде ич.

Таныырга һәм ачык аңларга кирәк: Татарстан географик яктан да, сәяси яктан да Шәрык белән Көнбатышның уртасында басып тора. Дуслык капкасы ролен үти. Заманында шушы зирәк юлны сайлап, Төркия бик дөрес эшләде һәм цивилизацияле илләр дөньясына аяк басты. Безгә мондый тәҗрибәне өйрәнү зыян итмәс иде. Татарстанның суверенитетын Россия танымасын да инде, моның сәбәпләре яхшы аңлашыла. Әмма нигә соң безне чит илләр, барыннан да бигрәк, БДБнең яшь илләре таныырга һәм котларга ашыкмыйлар? Алар, әлбәттә, Россия кебек көчле, йогынтылы держава белән мөнәсәбәтләрен бозарга теләмиләр. Татарстан Республикасының бәйсезлеген тану аларга хәзергә сәяси очко китерми. Әмма вакытлар узар, ил башындагы күп кенә җитәкчеләрнең дә уйлары үзгәреш кичерер һәм алар Татарстанның көчен, мөмкинлекләрен, сәләтен, гуманлы сәясәтен таныырга мәҗбүр булырлар. Кызганыч ки, БМОда хәзергә иске догмалар һәм нафталинлы документларга ябышып яталар. Ә бит тормыш дигәнең катып калган нәрсә түгел. БМО да үяныр, яңача уйланыр әле. Без моңа ышаныйк, өметләник.

Татар бик нык сибелгән, таркалган, дидек. Моны инде бер мин генә түгел, меңнәр әйтә килә. Менә шуңа күрә, бүгенге яңача шартларда, безгә хәзер берләшүдән дә кыйммәт һәм мөһимрәк нәрсә юк. 1992 елның җәендә Казанда үткәрелгән Бөтендөнья татарлары конгрессы да асылда менә шушы олуг максатка хезмәт итте. Иншалла, берләшербез. Ачыктан-ачык әйтергә кирәк: ләкин бу берләшү башка халыкларга каршы юнәлтелмәгән. Киресенчә, дуслыкка, гаделлеккә, ихлас мөнәсәбәтләргә йөз тоткан гуманлы берләшү ул. Тарих мәйданында татарга үз сүзен әйтергә яңадан чират җитеп килә. Безнен бу яңа күтәрелеш фәкать халыклар арасындагы дуслыкка, хезмәттәшлеккә, тәрәккыяткә хезмәт итәчәк. Русиянең кайбер җитәкчеләренә менә шуны аңларга вакыт. Чөнки җиңүче урыс дәүләтчелеге заманында татарга, аның ил-көн тәҗрибәсенә таяну нәтиҗәсендә генә алга китә алган. Ул бүгенге яңа сәяси шартларда татарга хөрмәт белән карый белми, шовинизм һәм «мин-минлек» чиреннән арынмый икән, бу — Рәсәйдәге ике иң зур халык арасындагы дуслыкка, алгарышка каршы эш булачактыр. Татарны кысам дип, Русия үзе бик күп югалтулар кичерергә мөмкин...

* * *

Урманда үскән төрледән-төрле үләннәр һәм агачларның бер-берсенә комачау итмичә, этешми-төртешми генә, үзара тату бердәм яшәүләренә игътибар иткәнегез бардыр. Безгә, һәр милләткә, табигатьтәге шушы гармониядән үрнәк алырга вакыт. Җәмгыять урманында һәр халыкның үз урыны, сулышы, үзенә тигән язмышы бар. Россия — карурманга тиң ул. Шушы иксез-чиксез биләмәдә халыкларның сан ягыннан олысы да, кечесе дә, төрле язмышлысы гомер сөрә. Күзгә карап әйтик: аның патша заманнарыннан ук калган төпкелендә әллә ничаклы утлы кузлар, очкыннар посып-көйрәп ята. Шушы зур илдә ут вә янгыннар чыгармаска иде. Этешми-төртешми генә, бер-беребезнең азатлыгын таныган хәлдә, үзара тату, бердәм, аңлашып яшәү зарурлыгы көн кебек ачык. Тормыштагы бүгенге хакыйкатьнең иң зурысы әнә шулдыр.

Оптимист булыйк: сибелгәнне җыйнау да мөмкиндер. Менә шуңа да: «Барлык илләрнең татарлары, берләшегез!» — дигән чакыру хәзерге көнебез өчен дөрес һәм актуаль шикелле. Бу — һич кенә дә Җир шарының төрле төбәкләрендә яшәп яткан милләттәшләребезне Татарстанга күчеп кайтырга кыстау, ашыктыру, төрле тарихи сәбәпләр аркасында читтә тамырланып киткән тормышларын үзгәртеп ташлау, аерымлану мәсьәләге түгел. Асылда бу — рухи яктан тупланууга, туган телебез һәм мәдәниятебезне үстерүдәге хезмәттәшлеккә, җыйнап әйткәндә, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгыту һәм халыкара танытудагы эшчәнлеккә чакыру. Шуңа күрә тарихи яктан өлгереп җиткән шигаребез (лозунгабыз) бер дә гаҗәп түгелдер: чынлап та, барлык илләрнең татарлары, әйдәгез, берләшик! Бу — туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклау, мәдәниятебезне үстерү, милли рухны яңарту, ахыр чиктә татар халкын, аның генофондын саклап калу өчен кирәк. Әгәр Татарстандагы, Рәсәй һәм БДБ илләрендәге, АКШ, Германия, Финляндия, Төркия, Япония, Австралия һәм башка илләрдәге татарлар шушы мәсьләктә берләшә белмибез икән, Татарстанның дәүләтчелеген торгызу, аны халыкара таныту дигән иң зур максатыбызның чынга ашуы шактый икеле булачактыр.

■

Индус Таһиров

# АЛТЫН УРДА ҺӘМ «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫ*

Тарих фәне сәясәттән читтә кала алмый, чөнки аның төп тикшерү объекты — үткәндәге сәясәт. Моның шулай икәнлеген, ягъни тарихның үткән заманга юнәлтелгән сәясәт икәнлеген XIX гасырның алтмышынчы елларында ук инглиз галиме Джон Сиди исбатлаган. Моны исегезгә төшерүемнең хикмәте шунда ки, утызынчы елларда Покровский һәм аның мәктәбен тар-мар иткән дәвердә аларга шушы теорияне инкяр итү йөкләнгән була. Ләкин шунысы да мәгълүм булсын: большевистик хакимият, бер яктан, шушыны фаш итеп маташкан булса, икенче яктан, үзе иҗтимагый фәннәрне, шул исәптән, тарих гыйлемен дә актив рәвештә үз сәясәтенең хезмәтчесе итте.

Алтын Урда тарихы да, шул дәвернең мәдәнияте, беренче нәүбәттә, «Идегәй» дастаны да менә шушы сәясәтнең корбаны булды. Бүгенге сәясәткә шул тарих кирәк икән, аны тикшерүгә азмы-күпме мөмкинлек бирелә башлавы да табигый. Кыска гына вакыт эчендә күренекле тарихчыларыбыз Һади Атласый һәм Газиз Гобәйдуллинга да юл ачылган. Дөрес, солтангалиевчелеккә каршы көрәш җәелдерелгәч һәм утызынчы еллар репрессияләре башлангач, аларга да урын калмый. Татар тарихы, тарихи мирас белән ныклап кызыксынган бер төркем язучы, шулар исәбендә Нәкый Исәнбәт тә, имештер, «Җидегән» исемле сәяси оешма төзегән дип гаепләнә һәм шактый еллар буе җәберләнә килә.

Ләкин Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, СССР халыкларында ватандарлык рухы тәрбияләү мәнфәгатеннән чыгып, үткән тарихка шактый игътибар бирергә керешәләр. Шунлыктан, бу эшкә элегрәк әзәрлекләнә килгән язучылар да тартыла. 1941 елның 4 февралендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Муса Җәлил партия өлкә комитетына «актив иҗат һәм җәмәгать эшенә зур стажы булган, ләкин монарчы аннан читләштерелә килгән язучылар тартылды», — дип яза. Җәя эчендә Н. Исәнбәт, Г. Кутуй, М. Гали исемнәре күрсәтелгән. Моңа исә 1942 елда татар мәдәниятенең җәүһәре «Идегәй» дастанының 500 еллыгына әзерләнү сәбәп була. Мондый җаваплы, күп белем һәм мәгълүмат таләп иткән эшкә Нәкый Исәнбәт һәм Нигъмәт Хәкимнәр кирәк була. Эшне башкару Алтын Урда тарихын, аның мәдәниятен дә яхшы белүне таләп итә.

Язучылар берлегенең шушы юбилейны уздыру теләгеН ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты хуплый һәм аңа җитәкчелек итүне үз кулына ала. Тиз арада юбилей комитеты төзелә, аның рәисе итеп партия өлкә комитетының идеология секретаре Мөхәммәтев билгеләнә. Аңа партия һәм дәүләт эшлеклеләре белән

---

Индус ТАҺИРОВ (1936) — *галим, тарих фәннәре докторы, профессор; Татарстан ФА әгъза-хәбәрчесе, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, күп кенә гыйльми хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

* 1993 елның 9 августында Казанда «Алтын Урда: тарихы һәм мәдәнияте» халыкара конференциясендә сөйләнгән нотык.

бергә, Нәкый Исәнбәт һәм Кәрим Тинчурин да кертелә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк ки, юбилей уздыру ВК(б) Үзәк Комитеты тарафыннанда хуплана, чөнки бу эш партиянең гомум сәясәтенә дә туры килә. Өлкә комитетының беренче секретаре Алемасов кул куеп, Үзәк Комитетка җибәрелгән мөрәҗәгатьтә 1942 елда «Идегәй» дастанына 500 ел тулуы, шунлыктан Татарстан Язучылар берлеге шушы юбилейны уздыру мәсьәләсен күтәрүе аңлатылган. Документның белешмә өлеше игътибарга лаек. Анда дастанның чын халык иҗаты әсәре икәнлеге расланган.

Беренчедән, шушы бөек дастанның Алтын Урда дәүләте сүнеп барган вакытка, хан тәхете өчен көрәшнең кискенләшкән чорына туры килүе билгеләнгән. Кыска гына вакыт эчендә егермедән артык хан алышынган. Тәхет тирәсендәге даирәләр хакимлек өчен үзара сугышкан вакытта Идегәйдәй батырлар шул хакимнәргә каршы чыгудан да курыкмаган. Алар өчен Туктамыш яки бүтән хан түгел, ә Ил, Идел-йорт, халык мәнфәгатьләре беренче урында торган. Менә шуңа күрә дә дастанның төп каһарманы Идегәй булган.

Икенчедән, шушы дастанның утызлап варианты табылуы күрсәтелгән. Җәмгысе җиде мең шигъри юл. Шул вариантларның өчесе — кырым татарларыныкы, өчесе — башкортныкы, икесе — казакъныкы, берсе — нугайныкы, берсе — үзбәкнеке, калганнары — татарныкы. Бу Идегәйнең халык батыры буларак татар тарафыннан гына түгел, башка халыклар тарафыннан да танылуы һәм кабул ителүе хакында сөйли. Димәк, бу дастан — төрки халыкларның уртак мирасы.

Идегәй батыр турында җырлар һәм риваятьләр ул үзе исән чагында ук барлыкка килә башлаган. Идегәй турындагы әсәр күп еллар үткәннән соң кемдер тарафыннан төзелгән фальшивка түгел. Тарих андый бозуларны шактый күргән. «Идегәй» исә чын тарихи нигезе булган әсәр. Мәсәлән, заманында Алтын Урдага килгән сәяхәтче Ибн Гарәпша Идегәй турында легендалар, сәер истәлекләр барлыгын язып калдырган. Идегәй үлгәннән соң 50 ел үткәч Алтын Урдага килгән А. Ассабад: «Миңа очраган һәр кеше аның турыда кызык истәлекләр сөйләде, аның батырлыгын, кешеләргә игътибарлылыгын, хәрби юлбашчылык сыйфатларын тасвирлады», дип язып калдырган.

«Идегәй» дастаны — Алтын Урда тарихының соңгы сәхифәләре чагылышы. Аның нигезендә халык язмышы ята. Менә ни өчен партия җитәкчеләре шушы дастанның татар халкында ватандарлык хисләрен уятачагына шикләнми һәм юбилейне зурлап уздыруны яклый.

Тарих, тел һәм әдәбият институтына дастанны басмага әзерләү эше йөкләнә. Нәкый Исәнбәт биш пәрдәле «Идегәй» драмасын яза. Гомумән, бәйрәмгә әзерләнү уңышлы алып барыла. Тик менә аны үткәрүгә сугыш башланып китү тоткарлык ясый. Шулай да башланган эш тукталмый. 1943 елның декабрендә партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумында «Бөек ватан сугышы елларында татар әдәбияты» дигән доклад тыңланырга тиеш була. Анда татар әдәбиятының мең еллык традицияләренә таянырга, халкыбызның «чыдамлык, үз-үзен аямаучан батырлык сыйфатларын тарихтан эзләргә кирәклеге» басым ясап әйтелә.

Сугыш елларында дастанга игътибар кимеми. 1944 елның 18 апрелендә төзелгән бер документта — партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Никитиннең Кызыл Гаскәр баш сәяси идарәсе башлыгы Рогов исеменә җибәрелгән хатында «Идегәй» дастанын урыс теленә тәрҗемә итү эшенең бүгенге көндә хәрби диңгез флотында хезмәт итүче шагыйрь Семен Липкинга тапшырылганлыгы искә төшерелә. Шушы эшне үтәү өчен, аны янә өч айга хәрби хезмәттән азат итү хаҗәтлеге аңлатыла. Шушы хат-үтенеч нигезендә, С. Липкин хәрби хезмәттән азат ителә, тәрҗемәче Казанга килә.

Әмма дүрт ай үтүгә, әлеге Никитин дастан турында башкача сүз алып бара башлый. 1944 елның апрелендә «Идегәй» чын халык дастаны итеп мактала, ә шул ук елның 9 августында шул ук әсәр халыкка каршы феодаллар дастаны дип танытыла. Шушы көнне ВКП(б) ҮКында, аның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Иовчук һәм Никитин ясаган докладлар нигезендә «Татарстан партия оешмасында идеологик һәм масса-сәяси эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары» исемле карар чыгарыла. Бу карарда Алтын Урда тарихын матур буяуларга буяп күрсәтергә тырышкан тарихчыларны, «Идегәй» дастанын киң танытырга омтылучы әдәбиятчыларны милләтчелек хаталары җибәрүдә гаепliләр. Дастанны тәрҗемәләүче С. Липкин, Нәкый Исәнбәт кебек кимсетелүләргә дучар ителмәсә дә, гаепләүдән читтә калдырылмый. ВКП(б) ҮКында әнә шул документ кабул ителер алдыннан, сәяркәләрен шампан шәрәбендә коендырырга яраткан

Александров С. Липкин белән әңгәмә үткәрә. Ул аңа: «Сез тәрҗемә итә торган дастанның каһарманнары кайсы ил патриотлары булган?» — дип сорау бирә. «Ул илнең исеме — Дәште Кыпчак, ягъни Алтын Урда»,— ди шагыйрь җавап итеп.

Сәер әңгәмә әйбәт кенә тәмамлана, Александров тәрҗемәчегә дастанның басылып чыгачагын белдерә. Әмма бу икейөзле вәгъдә була. Югарыда карар аркасында, дастан китап рәвешендә бары тик 1990 елда гына дөнья күрә алды. Тәрҗемәсе исә 1991 елда басылды һәм С. Липкин Тукай премиясе белән бүләкләнде.

1944 елның 9 август карары Татарстанда милләтчелек белән көрәшүне башлап кына җибәрә. Шуннан соң Казанда партиянең Татарстан өлкә комитеты XIV пленумы уздырыла. Анда Үзәк Комитет карары буенча докладны Өлкә комитеты секретаре Малов сөйли. Бу доклад 66 биттән гыйбарәт, анда республикадагы идеологик эш бәйнә-бәйнә тикшерелә. Баксаң, Татарстанда урыс һәм татар халыкларының чит ил илбасарларына каршы бергәләп көрәшүен өйрәнү урынына, галимнәребез Алтын Урда тарихын тикшереп яткан, аны прогрессив, икътисады һәм мәдәнияте алга киткән дәүләт итеп күрсәткәннәр, аның төп сыйфаты — агрессивлык, урысларга карата илбасарлык булуын онытканнар икән! «Идегәй» исә халыкка каршы, милләтчел бер әсәр, имеш...

Никитин урынына беренче секретарь итеп җчбәрелгән Моратов: «Тарихчылар һәм әдәбиятчылар нәкъ менә сугыш елларында ни өчен соң әле Алтын Урданың алга киткән прогрессив дәүләт икәнлеген раслаган черек идеологияне күтәреп чыктылар? — дип сорау бирә. Аннары фикерен ул болай дәвам итә: — Бу кешеләрнең бурычы — үз гөнаһларын юу, чын фәнгә нигезләнгән, тарихи гаделлеккә туры килгән закончалыкны, республикабызда барган гигант үзгәрешләрне күрсәтә торган әсәрләр тудыру».

Алтын Урдага һәм «Идегәй» дастанына менә шундый бәя бирелә. Чөнки 1944 елда сугышның язмышы нигездә инде хәл ителгән була. Урыс булмаган халыкларның ватандарлык хисләрен дөрләтүгә инде ихтыяҗ бетә. Киресенчә, аларны инде үз урыннарына, ягъни икенчел пландагы урынга утыртыр вакыт җитә. Дистәләрчә халыклар тарихи ватаннарыннан сөрелә, аларның тарихи милли дәүләтчелеге дә юкка чыгарыла.

Большевистик сәясәт икенче юл алгач, татарга да башка язмыш языла.

Алтын Урдага, аның мәдәниятенә карата рәсми мөнәсәбәт үзгәрмәгән булса да, илленче-алтмышынчы елларда аларга багышланган кайбер хезмәтләр күренә башлый. Шулар арасыннан мин М. Сәфәргалиевнең «Алтын Урданың таркалуы» (Саранск, 1960) китабын күрсәтеп үтәр идем. Урыс җәмәгатьчелегендә дә бу дәүләткә карата яңа фикерләр пәйда була. Шуның нәтиҗәсендә, Сарай-Бәркә шәһәрендә археологик казынулар алып барыла, анда табылган матди мәдәният үрнәкләре Саратов шәһәре музеена куела.

Кыенлык белән булса да, җирле халык үткәнен, Алтын Урда мәмләкәте тарихын гомуми тарихның бер өлеше итеп тану гамәлгә керә, гаделлек өстенлек ала башлый. Мисалга, Лев Гумилев хезмәтләрендә Алтын Урдага чагыштырмача объектив бәя бирелгән, аның тарихыннан сәяси башбаштаклык катламнарын алып ташлау өчен күп кенә мәгълүмат китерелгән.

Бүгенге сәясәт тормышта һәм тарих гыйлемендә гаделлек тантана итүен сорый. Алтын Урда дәүләтенең 750 еллыгына багышлап Казанда уздырылган халыкара конференция озак еллар киң җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калдырылган үткәнебезне ачыклауга һәм барлауга саллы өлеш кертте. Моннан соң инде галимнәребез «ак таплар»ны бетерүгә җиң сызганып керешер, дип ышанырга мөмкин. Алтын Урда һәм аның мәдәнияте халкыбыз тарихында лаеклы урынын алыр, башка илләр һәм милләтләр белән хезмәттәшлектә яшәвебезгә яңа көч өстәр.

**Марсель Галиев**

# ӘРЕМ ИСЕ ӘРНҮЛЕ

Хаҗитарханның челтәрле күперен чыгып, төньяк тарафка юнәләбез. Кыйблабыз — үз гасырында исеме күпме телләрдә кабатланган шәһәр — Сарай-Бату (Сарай әл-Мәхрус)... Бөек Алтын Урда мәмләкәтенең тәүге башкаласы, мәшһүр кала урынын күрү!

Сулда Бузан елгасы шәйләнә. Йөгерек юлның як-ягында кайнап торган сусыл яшеллек. Гаҗәп куе, чук-чачаклы камышлыклар белән каймаланган күлләр ялтырап китә. Әкияттән ыргытылган түгәрәк көзге кебек түгәрәк күлләр отыры ешая. Шул күлләрнең таҗы булып ап-ак чәләннәр горур басканнар. Тын суга якты шәүләләре төшкән бу ыспай кошларның чыны суга төбәлгән яктамы, күккә караган яктамы — һич аера алмассың.

Кинәт кенә чүл башланды. Шадра җил сурәте җыерчыклаган кызгылт барханнарга карагач, уалучан дөньяның хәрәкәттәге мәңгелегенә ышанасың. Кай урыннарда ком барханнары кар көрте кебек юлга аркылы салган. Юл читендәге ихаталар янында, комнан яратылган шикелле, борынгылыкның сүзсез шаһитлары кебек, ваемсыз гына карап үркәчле дөяләр кала. Бераздан кызгылт комлыклар уйдык-уйдык чәнечкеле үләнле дала туфрагы белән алмашына.

Уйланып барам. Бу җирләрнең һәр карышы тарих каныннан сугарылгандыр. Җиле башка, һавасы бүтән, күге хәтерле. Гасырлар пәрдәсен ачасы иде дә, шул дәртле, гаярь, шанлы дәвер манзарасын бер генә мизгел тамаша кыласы иде. Юк, болай эзсез җуелмас, каядыр күк катларында язылып калгандыр бу сурәтләр... Йөзмеңнәрчә атлы гаскәрне сугыш театрына чыгарып, кылычка-кылыч китерү, җиһанны яуларга кызыгучы каһарманнарны ил сәхнәсенә чыгару юкка гына түгелдер. Күк тәхетендә утыручы илаһи затларның бу бәлки, безнең аң җиткәнчә әйтсәк, шахмат уйнау рәвешедер. Зур һөҗүмгә керер алдыннан ни өчен соң әле Чыңгыз хан, үз тирмәсенә бикләнеп, берничә тәүлек буе Мәңге Күк-Тәңрегә эндәшкән? Шундый мизгелләр була: Чыңгыз хан ук яңгыры астында кала, янәшәсендәгеләр ава, аңа исә ук тими. Наполеон ядрә яңгыры астында кала, кырыендагылар үлеп бетә, аңа бер пуля да тими, үлем эзләп ут эченә кереп карый, юк, үлем алмый. Атаклы Искәндәр белән дә шундый хәлләр була. Сәбәп бер: димәк, каһарманны сәхнәдән алырга вакыт җитмәгән, әлегә уен бетмәгән — Күкнең әмере шундый. Ә вакыты җиткәч инде аларны юк сәбәптән генә данияреннән иелеп алалар.

Әйе, япан дала җиленә колак салып тыңлансаң, әллә нинди уйлар башка килә. Бату хан атларының тоягы тиеп киткән һәрбер таш чарланган үз телендә сиңа эндәшә, тамыры белән тирән гасыр катламнарын капшаган һәр үлән үз телендә пышылдый. Таланган, каһәрләнгән Алтын Урда йортының ятим калып, дала киңлекләрендә каңгырып йөргән ИЗГЕ ИЯСЕ күзгә күренмәс куллары белән сине кысып ала...

* * *

Үлеменә берничә ел кала (1225 еллар) Чыңгыз хан үзе биләгән иксез-чиксез мәмләкәтен дүрткә бүлеп, өлкән хатыны Бөртәдән туган дүрт улына да өлеш чыгара. Кытай ягындамы, Европа тарафындамы, һәр улына алдагы көндә яуланачак һәм үз өлешенә кушачак илләрне дә әйтеп, васыять итеп калдыра.

Олы улы Җучига мәмләкәтнең төньяк-көнбатыш өлеше — Алтайдан алып Уралга кадәр, көньягы Аму-дәрья елгасы һәм Арал диңгезенә чаклы җирләр тия. «Җучи олусы» дип аталган бу олус Идел буе далаларына кадәр киңәеп, Җучи үлгәннән соң улы Батуга кала. Соңыннан инде бу олус Каракорымнан бәйсезлеккә ирешә, «Кыпчак патшалыгы», сонрак «Алтын Урда» дип атала башлый.

Кул астына йөзмеңнәрчә гаскәр туплаган Бату хан, Урта гасырның яшәү рәвеше кушканча, һәм, бабасы белән атасы васыятына тугры калып, олус чикләрен киңәйтү, яңа җирләр яулауны үзалдына максат итеп куя. Иң якын көрәштәше, бик күп яуларда сыналган, күпме тау-кыяларны, елга күлләрне бергә

кичкән Сүбүдәе бар бит аның. Чигенмәс һәм жиңелмәс стратег, ияр өстендә сугыш уты сулап олыгайган сыңар күзле Сүбүдәй баһадирны алып ул Европага походка чыга.

Зур шәһәрләрдән иң башта Киев алына. Килешү төзергә дип җибәрелгән илчеләрне үтерткән өчен киевлеләргә рәхим-шәфкать күрсәтмиләр. «Бату хан гаскәренең Карпат аша үтеп, Сайо елгасы буендагы хәлиткеч җиңүгә кадәрге сугыш театры җәмгысы 4—5 айны эченә ала. Шушы кыска гына арада Европаның ике көчле державасы Польша һәм Венгрия гаскәре юк ителә. Чехиянең армиясе сафтан чыгарыла» **(И. Кара-Дауан).**

Бату гаскәренең аерым отрядлары Босния, Албания, Сербия, Болгария җирләрен тетрәтеп чыгалар. Байракны «соңгы дәрьяга кадәр» илтергә дигән максат куйган Бату хан Адриатик диңгезенең кипарислы ярларына барып житә. Бу вакытта инде бәлки Сүбүдәй баһадирның хәрби планында, Атилла эзеннән барып, шәһәрләр шәһәре Римне камау максаты да өлгергәндер. Хәер, бу дәһшәтле, гарасатлы ташкынның Атлантик океанына барып чыгарга да кодрәте житә, аерым-аерым куркуга төшкән Европа илләрендә инде бу галәми ташкынны туктатырлык көч булмый. Әмма ләкин...тәре походларыннан муеннан канга, гөнаһка баткан Европага, нишләптер, Алла йөз белән борыла... Вена шәһәренә бер адым кала Бату гаскәре кинәт туктала. Атларның тезгенен киредән көнчыгышка боралар. 1241 тарихи ел була бу. Монголиянең башкаласы Каракорымнан бөек Үгедәй ханның үлеме хакында кайгылы хәбәр алына. Бату ханның ат тоягы астында калмаган Европа илләре Үгедәй каганның үлеменә бурычлы.

Шуннан соң гаскәр, Бату хан әмере буенча, Дунай тамагына кайтып туплана. Бату хан зирәк акыллы була. Дәүләт кирәгеннән артык киңәеп җәелсә, үзеннән-үзе чатный, тарала башлый, аны бер йодрыкта тоту авырлаша. Шуна күрә дә ул Дунай буендагы киңәшмәдә шундый карар чыгарта: яуланган Европа илләрен үз хөкемнәрендә калдырырга, Болгария белән Молдавияне кертеп, Җучи олусының көньяк-көнбатыш чиге итеп билгеләргә. Бу өлкәләрнең идарәчесе итеп Чыңгыз нәселеннән чыккан төмәнбәк Нугай сайлана.

Бату хан ерак Каракорымга кайтырга, ил башлыгын сайлау Корылтаенда катнашырга теләми. Идел буе даласында торып кала, оештыру-дәүләт эшләрен кайгырта башлый. Озак та үтми, мөселман осталары дәүләтнең башкаласы Сарайны төзү өчен туплана башлыйлар.

Алтын Урда дәүләтен киңәйтеп, мәшһүр шәһәрнең беренче сарае нигезенә көмеш тәңкә куеп калдырган, 1208 елда туып, кырык җиде яшендә вафат булган Бату хан, кеше буларак, нинди сыйфатларга ия сон? Тарихи фактларга үчле караштан чыгып түгел, ә вакыт каршында һәр сүзе өчен җаваплылык тоеп яисә үз күзе белән күргәнне язып калдырган итагатьле милләт вәкилләренә мөрәҗәгать итик. Менә Каракорымда һәм Сарайда булган папа Иннокентий IVнең рәсми вәкиле **Плано Карпини** (1182—1252) язмасына игътибар итик:

**«...Бату менә дигән сарай тота, аның 600 меңлек гаскәре бар. Атка атланып йөргәндә аның янәшәсеннән баш очында зонтик тотып баралар. Бөтен татар кенәзләре һәм аларның хатыннары да шулай итә.**

**...Хан станына кергәндә безне ике ут арасыннан үткәрделәр. Ут кешене яман ниятләрдән чистарта, хәтта яшерелгән агуың булса, аның да көчен бетерә, диделәр татарлар. Без берничә мәртәбә бил бөгеп, чатырның бусагасына басмыйча гына эчкә үттек. Бату үзенең бер хатыны белән түрдә, тәхеттә утыра иде. Безне сул якка утырттылар. Иннокентийның славян, гарәб, татар телләренә тәрҗемә ителгән хатын Бату бик игътибар белән укып чыкты. Ул үзе дә, яраннары да алтын һәм көмеш савытлардан нидер эчеп куялар иде. Церемония вакытында гел музыка уйнап, җыр аһәңе яңгырап торды. Батуның йөзе кызгылт төстә, ул яраннарына ягымлы эндәшә, калганнарга исә бик кырыс иде. Яуда ул хәйләкәр, усал, тәҗрибәле булуы белән дан тота иде.»**

Түбәндәге өзекләр исә татар-монголлар тарафыннан яуланган илләрдә яшәгән тарихчылар язмасыннан китерелә:

**«Бату хан акыллы һәм гадел дәүләт эшлеклесе була. Ул бигрәк тә шәһәр һәм сәүдәне үз канат астында тота. Төрле тарафлардан аның станына сәүдәгәрләр кызыл мал төяп киләләр. Бату хан үзе чыгып, һәртөрле товарларны тотып карый, мулдан акча түләп һәммәсен ала. Аңа хезмәткә яисә сәүдә эше белән килгән берәү дә үзенә файда алмыйча китми» (Әл әд-Дин Җүвәйни — фарсы тарихчысы).**

**«Бату ханга һәрдаим патшалар, кенәзләр, сәүдәгәрләр — хаксызга рәнжетелеп, җир-мөлкәтеннән коры калганнар килә. Ул аларның эшен карап гадел хөкем чыгара, биләмәләрен, кенәзлекләрен кайтарып бирә. Ул ярлыкларны һәм ташлама**

**ясалган грамоталарны юмарт тарата һәм аның ихтыярына кем дә каршы килә алмый иде». (Киракос Гандзакеци — әрмән тарихчысы).**

**«Бату хан кеше буларак гадел иде. Ул патшалык иткән дәвердә аның хакимиятендәге ислам илләре аның үзеннән дә, түбәнбәкләреннән дә зыян күрмәде» (Әл Җуржани — әфган тарихчысы).**

* * *

Менә ул Сарай-Бату, күп калаларга баш кала!

Шәһәрнең көнбатыш ягының гранит ярларын сыйпап аккан якты сулы Актүбә елгасы җилкәнен киергән кораблар белән мыжгып тора. Кайсы гына илнең байрагы күтәрелмәгән мачталарына. Өчән (өч җилкәнле), бишән (биш җилкәнле) дип аталган татар корабларының дулкын ера торган алгы өлеше горур аккош муенын хәтерләтә. Пристаньнәр шау-гөр итеп тора: йөк төйиләр, йөк бушаталар.

Дөньяның һәр тарафыннан килгән меңнәрчә ташчылар, нәкышчы рәссамнар, агач осталары — тагын әллә нинди һөнәр ияләре бер сулышта торгызган бу каланы. Коллар эш-булдыклылык күрсәтүгә үк ирекка чыгарылганнар, үзенә йорт төзеп, һөнәрчеләр кварталында урын алганнар. Һөнәре булмаганнарны, җир бүлеп биреп, «сабанчы» иткәннәр. Кулыннан гөл тамган һөнәр ияләрен, архитекторларны бәяли белгәннәр татар ханнары.

Бату хан үлгәч (1255), аның Александр Невский белән туганлашкан улы Сартак берничә ай гына тәхеттә утыра. Сартак та, аның энесе Улагчы да үтерелгәч, Батуның энесе мөселман динен кабул иткән Бәркә тәхеткә менә. Яшәгән еллары — 1209—1266. Ул гомере буе абыйсының данынннан көнләшкән була. Шуңа күрә Сарай-Батуда калырга теләмичә, аннан да көчлерәк итеп Яңа Сарай (Сарай әл-Җәдид) шәһәрен төзетергә керешә. Шулай итеп, тиз арада Сарай-Бәркә шәһәре җәелеп китә, сәүдә үзәгенә әверелә.

**«Батуның варисы сәнгать һәм фәнгә гашыйк; үз янына рәссамнарны, галимнәрне тарта. Кыпчак башкаласын яңа биналар белән бизи һәм анда яшәүче россияннарга христиан динен тотарга иркенлек бирә»,** — дип яза **Н. М. Карамзин.**

Үзбәк хан (1312—1340) чорында Сарай-Бәркә бөтен дөньяга билгеле шанлы калага әверелә. Үзбәк хан берничә хатыны өстенә тагын Византия императоры Андроник кызына өйләнә. Византиядән ташчы-осталар, архитекторлар китертә. Мөселман осталары җитәкчелегендә бу чорда күпләп затлы мәчетләр төзелә. Рус өлкәләреннән монда шәп бүрәнә-саллар агызыла, Уралдан зәңгәр гранит, Кырымнан мәрмәр, Урта Азиядән майолик кирпечләр ташыла.

Үзбәк хан турында замандашы, галим **әл-Бирзали** менә нәрсә дип теркәп калдырган: **«Ул тырышып ислам динен тота. Чибәр кыяфәтле, озын буйлы, зирәк акылы белән аерылып тора».**

Үзбәк хан Европа һәм Азия белән мөнәсәбәтләрне җайлау, тәхетне ныгыту өчен сәяси туганлашуга да бара. Ул Мисыр халифе кызына өйләнә, Каһирәнең иң төп мәйданнарыннан берсе аның исемен йөртә. Кытай императоры Таган Тимернең Баялын исемле гүзәл кызын ул килен итеп Сарайга алып кайта. Европа һәм Азиянең дәүләт эшлеклеләре Үзбәк ханның һәр фикере белән исәпләшәләр.

Сарай-Бәркә дөнья илләренең үзәк базарына әйләнә. Һиндстаннан тәм-том, җәсминле чәйләр, Персиядән затлы келәмнәр, Византиядән сулышка ияреп кабара торган парча-тукымалар, Урта Азиядән ефәк, Себердән күз явын алырлык ак, төтенсү, зәңгәр, кара-кучкыл мехлар, Франция, Венгрия, Грузиядән кояшлы шәрапләр, Мисырдан Мансур нәселле ыспай чабышкы атлары, төрекмәннән Ахалтәкә нәселле аргамаклар, монголның «һава сулап кына да тора алган» тәбәнәк-түзем айгырлары, һәртөрле илнең сылу кол-кызлары — кыскасы, базарларда ерып йөргесез кеше һәм товар диңгезе, нинди генә телдә сөйләшмиләр, әмма халыкара тел булып татар теле тантана итә.

Татарлар эчке һәм тышкы базарга тире-күн, алтын-көмеш, асылташ бизәнү әйберләре, сәнгатьле эшләнгән сугыш кораллары чыгаралар. Эссе кояш астында салкын кымыз да монда бик югары бәяләнә. Идел, Актүбә, Бузан буйларында, бәрәкәтле җирдә үстерелгән кавын-карбыз, һәммә төрле яшелчә-җимешләр телеңне йотарлык татлы була.

Базарлардан ерак түгел генә Генуя, Венеция, Византия малтабарларының, рус, кытай, яһүд, әрмән, болгар сәүдәгәрләренең үз кәрвансарайлары балкып тора. Боларны төзегәндә инде, әлбәттә, үз иленнең йөзен күрсәтү, бер-береңнән арттырырга тырышу, ярыш хикмәте хөкем сөргән.

**«Урлашу, караклык, сәүдә эшендә алдашу, ялган мөнәсәбәтләр Урда көнкүрешенә хас булмый. Бүтән халыкларда гадәти саналырдай аз гына намуссыз эш кылган өчен дә татарны аяусыз җәза көтә. Намуслылык — татар холкының гасырлар кичеп, безнең көннәргә килеп җиткән иң күркәм сыйфаты» (М. Каратеев. «Русь и Орда»).**

Шәһәр үзәгендә — хан сарае. Халык телендә ул «Алтын таш» дип йөртелә. Өч сажен биеклегендәге гранит дивар белән уратып алынган сарайның фирүзә төсендәге мәһабәт гөмбәзенә, алтын аена дала ягыннан елмаеп чыккан кояш нуры төшүгә, илгә бөек эшләр алып киләсе фани көн башлана. Хорасан корычыннан бизәкләп коелган бинийаая авыр, биек сарай капкалары горур гына ачыла. Як-якта сакка баскан торгаутлар озын сөңгеләрен тартыбрак куялар. Төнге шәһәрнең иминлеген саклаган җайдаклар, мәйдан ташында тояк астыннан очкыннар чыгарып, сарайга кереп китәләр. Шул мәлдә йөзләрчә мәчет манарасыннан берьюлы иртәнге азан башлана.

Сарай-Бәркәдә мавритан стиле дә, кытай бизәкләре дә, Мисыр чалымы да, Византия архитектурасы да мөселман ансамблендә урын алган. Европа һәм Шәрекъ сәнгате кушылудан, ташка җан өреп төзелгән бу шәһәрне үз күзе белән күрүчеләр заманында, Сарай-Бәркә белән тиңләшер шәһәр җир йөзендә юк иде, дип язып калдырганнар. Ул чорда Париж, Римнәрдә халык саны Сарайның икедән берен генә тәшкил иткән.

Сарай-Бату һәм Сарай-Бәркә халкы эссе җәй көннәрендә табигать кочагына, аккошлы күл-елга буйларына җәйләүгә чыгып тирмәләр корган. Шәһәргә көз җитеп, кояш бераз юашлана төшкәч кенә кайта торган булганнар. Кайсыбер кыланчыграк байлар икешәр катлы мәһабәт йортларының зал почмагына тирмә корып, кай көннәрдә шунда яшәп алганнар. Бу, әлбәттә, гадәткә кергәнне канәгатьләндерүдән генә, салкын булган өчен түгел, монда биналар үзәктән җылытылган, керамик торбалар буйлап кайнар пар да, чиста су да өйләргә үк кертелгән була. Шәһәр зыялылары витраж тәрәзәле, зур гөмбәзле, идәне астан җылытыла торган мунчаларда парланып, бассейнда коенып, го, шахмат уйнап, сәясәт, әдәбият турында гаплəшеп, көне буе ял иткәннәр.

Татар шәһәрләрендә һәртөрле дин тотучыларның храмнарына да урын җиткән. Тәхеткә менгән һәрбер хан православие чиркәве һәм монастырьларга тулы хокуклар билгеләгән указлар чыгара. Төрле диннәргә сак караш Чыңгыз ханнан бирле шулай килә.

**«Алтын Урдада башында епископ торган рус епархиясе эшли, татарның бөтен зур шәһәрләрендә православие храмнары, Сарай-Бәркәдә исә биш чиркәү була. Моннан шул нәрсә ачык күренә, безнең Чиркәү татар хакимиятеннән бернинди тыю-чикләү күрмәде, киресенчә, урда ханнарыннан көчле яклау табып, үзебезнең рус кенәзләреннән тәтемәгән киң хокук һәм өстенлекләр алды» (М. Каратеев. «Русь и Орда»).**

Дәүләт буларак, әле картаерга вакыты җитмәгән Алтын Урда, аның чәчәк аткан шәһәрләре ни өчен кинәт кенә бетәргә дучар ителгән соң? Моның сәбәпләре хакында тирәнтен өйрәнеп язылган фәнни хезмәтләр бик аз әлегә. Милли аңы булган һәммә кешене бу сорау борчый, бәгырен телгәли.

Күк Урда... Ак Урда... Алтын Урда... Тәхет өчен туктаусыз канлы көрәш... Чыңгыз хан васыятына хыянәт итү... Мөселманның берләшә алмау кебек мәңгелек чире... Урта Азиядә дөньяны тетрәтәчәк Аксак Тимернең калкуы... Туктамыш ханның зирәклеге җитмәгән сәясәте.. Хәер, тарихның үз логикасы, аңа бүгенге күзлектән карап хисчән бәя бирергә омтылу — акылсызлыктыр. Шулай булган, шулай булырга тиеш...

* * *

Аксак Тимер 1391 елның язында Сәмәркандтан юлга чыга. Олуг тау итәгендәге ташка ул, Туран солтаны Тимер икейөзмеңлек гаскәр белән Туктамышны канга батырырга бара, дип чокытып яздырта (бу таш Эрмитажда саклана). Шушы елның 18 июнендә Чистай белән Самара арасында, Кондырчы дигән урында ике яктан да ике йөзмеңләп яугир катнашкан коточкыч сугыш була. Туктамыш гаскәре тар-мар ителә. Ләкин бу җиңелү әле Алтын Урда кебек зур мәмләкәтнең нигезен тетрәтә алмый.

Кайчандыр Туктамыш белән Тимербәк якыннан аралашып яшәгән булалар. Туктамыш гаскәрен җуеп, яраланып кайткан чакларында аны Тимербәк күтәреп

ала, тагын үзенең гаскәрен биреп тора. Әмма тәхет биеклегенә менеп, сәяси дулкынга эләккәч, кешелекле тойгыларга караганда хакими тойгылар өстенлек аладыр шул. Һәрберсе үз максатына омтыла, алар кан дошманга әвереләләр. Икенче тапкыр яуга керер алдыннан Тимербәк аңа мондый хат юллый:

**«Кодрәтле Алла хакына сорыйм: син кыпчак ханы, шайтан котыртыгы белән нигә дип тагын коралга тотындың? Соңгы сугышта көчеңне, байлыгыңны, хакимлегеңне көл иткәнемне оныттыңмыни, акылыңа кил, рәхмәтсез! Минем алда никадәр бурычлы икәнеңне хәтерлә. Әлегә вакыт бар: үчлекне булдырмый калырга мөмкин. Солых телисеңме, орышмы? Сайла. Мин кайсына да барам. Тик шуны онытма, бусында инде сиңа рәхим-шәфкать булмаячак!»**

Бу кисәтүдән соң икеләнебрәк калган Туктамыш ханны, данга кызыгып, яңа сугышларга атлыгып торган гаскәр башлыклары үз ягына аударалар. Һәрвакыттагыча, халык язмышын берничә кеше хәл итә.

1395 елның язында, Кавказ таулары арасыннан ургылып аккан Терек елгасы ярында ике гаскәр тагын кылычка-кылыч килә. Туктамыш кичү урынын сагалап аргы якта, Тимербәк бирге якта тукталып калалар. Икенче көнне Тимербәк яр кырыйлап алга таба кузгала. Туктамыш гаскәре дә, бер карышка да калышмыйча, урыныннан куба. Өч көн буе кара болыт кебек гаскәр күзгә-күз карашып баралар. Төнлә Тимербәк шундый хәйлә кора: хатын-кызларга һәм әсирләргә шлемнар кигертергә, аларны яугир кыяфәтенә кертергә боера. Үзе исә, төп гаскәрне алып, төн эчендә кичү урынына төшеп җитә. Елганың аргы ягына чыгып, берни сизми калган Туктамышның артына төшә.

Канлы, хәлиткеч сугыш нибары өч сәгать дәвам итә. Туктамыш хан кырылган, тапталган, изелгән сугыш кырын ташлап китә. Тиз арада гаскәр туплап, тагын бер талпынып карый. Әмма... Шушы елда Тимербәк Самара борылышына кадәрге Идел буе шәһәрләрен кырып чыга, Сарай-Бәркә, Сарай-Бату, Әстерхан калаларыннан да яу-гарасат үтә. Шәһәрләр талана, җимерелә, исән калган халкы әсирлеккә, коллыкка куыла.

Тугандаш халыклар канга-кан килгән бу тарихи сугышны, тынын кысып, Европа күзәтә. Киләчәктә дә шушылай, мөселман илләрен чәкәштереп, эчтән көчсезләндереп тоту өчен бик нечкә, хәйләкәр сәясәт кирәклеген белеп күзәтә. Чөнки мөселман илләренә тынычлык бирдеңме, нииндидер тылсым өргәндәй, җәһәт кенә үсеш алалар да... Дөньялыкта алар табынган ислам дине ин тыныч, кешелекле, сабыр дин икәне гамәли тормышта күренә башлар да... меннәр чистарынып, исламият ягына авышмасмы?! Шуның өчен мөселман илләрен гел үзара чәкәштереп торырга кирәк...

Бу сугышны һәрберсе үз каланчасыннан торып рус кенәзләре дә күзәтә. Аксак Тимер ягында яңгыраган җиңү фанфараларының кайтавазы Русьның чиркәү урманнары калкасы киңлекләрендә каһкаһә булып, шатлыктан бәргәләнә.

**«Үзләрен коткарабыз дип, татарлар Русьны шундый язмыштан йолып калдылар ки, ул язмыш турында уйларга да куркыныч»,— дип яза Лев Гумилев.**

Шунысы гаҗәп: Идел капкалары ачылган, Руська яу чабарга бернинди киртәләр юк, ни өчен Мәскәүне тынычлыкта калдыра Аксак Тимер?

Беренче сәбәп: Русь — гадәттән тыш ярлы ил. Кызыктырмый. Алтын-көмешләр, елкылдавык затлы мехлар — болар бар да рус язмаларындагы сонлап килгән әкияти хыял. Бу байлыкларга ирешү өчен гасыр ярым вакыт үтәргә тиеш тә, Казан ханлыгын, Урал-Себерне, Якутны басып алырга кирәк әле минемчә.

Икенче сәбәп: Кырымда көчләр күп. Туктамыш тагын гаскәр туплый. Дон-Кубань арасында чиркәсләр кайный. Мондый көчне тылда калдырып төньякка күтәрелү кирәкме?

Өченче сәбәп: атаклы философ, шагыйрь, астролог Әлүй-Чуцайның Чыңгыз ханга: «Атка атланып дөньяны яулап була, әмма атка атланып дөнья белән идарә итеп булмый»,— дигәнен Аксак Тимер яхшы белә. Билгеле бер вакытта атны тыеп, иярдән төшү кирәклеге аның зирәк акылында икеләнү тудырмый. Тагын өч елдан аның кылычы асылташлы таулар иле Һиндстанга сузылачак...

Ә Русьның бөек кенәзләре, кирәк чакта ханнар каршында тезләнеп, фарсы келәменә маңгай орып, кирәк чакта йодрыгын артка яшереп, сәясәтнең хәйләле алымнарына төшенә-төшенә, сабыр гына түл җыялар. Төрки халыклар кайнарланып, гасыр буена үзара чәкәләшеп, бүлгәләнеп бетәләр дә... татарның хәлсезләнгән тәненә ике башлы каракош үткен тырнакларын батыра һәм хәтер җелеген суыра башлый.

* * *

Менə без ерак гасырларның гүзəл шəһəре — Сарай-Бату урынында басып торабыз. Күпме хыялланып та, инде килеп күргəч, йөрəк нəүмиз кыслып куйды. Бер минут тынлык... ышанасы килми: иксез-чиксез киңлеклəргə җəелгəн буш дала. Күз элəгердəй берни калмаган. Бары көмешсу əрем сабаклары гына кайнар дала җилендə моңсу тибрəнə. Кисəтүле, сагышлы, əрнүле əрем исе...

Кабергə əйлəнгəн шəһəр өстеннəн сак кына атлыйбыз. Анда-санда кирпеч, кызыл чүлмəк ватыклары күренə. Шəһəрдə тормыш сүнгəн. Актүбə елгасы да берничə гасыр элек үк арырак чигенгəн. Ярында өянкелəр шаулый.

Монда казу эшлəрен Мəскəү профессоры Рəшит Булатов житəкчелегендəге көньяк Россия экспедициясе башкара. Алтын Урда шəһəрлəрен беренче булып казый башлаган атаклы академик Г. Федоров-Давыдовның укучысы Рəшит əфəнде, күренеп тора, үз эшенə бирелгəн кеше. Кайнар җил, кояш астында үзе дə ком гарəбенə əйлəнеп беткəн. Тарихны яратып, белеп сөйли, тик... татар дигəн сүзне бер дə кулланмаска тырыша.

1395 елда таланганнан соң да əле Сарай-Батуда тормыш дəвам итə, бары тик 1480 елда гына яшəүдəн туктый. Сарай-Бəркə исə көн эчендə кəл итела.

Үзе яшəгəн Сəмəркандн тирəсенə кышлаклар төзетеп, аларга Шираз, Димəшекъ, Багдад, Солтания кебек данлыклы мөселман шəһəрлəре исемен бирдерткəн Аксак Тимер, Сəмəрканд дөньяның беренче шəһəре булырга тиеш, ди. Шуна күрəме, бүтəн дəүлəтлəрнең башкаласын аеруча явызлык белəн җимертə. Сарай-Бəркəнең һəммə кешесе, соңгы тамчы канына кадəр сугышып, батырларча һəлак була. Монда археологлар тапкан бер генə скелет та исəн түгел, һəрберсе кылычтан, уктан яралаңган, киселгəн, туралган. Шунысы гаҗəп: бу шəһəрлəр берсе дə кальга диварлары белəн əйлəндереп алынмаган. Татарларның үз көченə артык ышануыннанмы бу?..

Аксак Тимер, үзе мөселман булуына карамастан, кардəш илнең башкаласында бернəрсəне дə аямый, алтышар манаралы бəһасез архитектура җəүһəрлəре — мəчетлəргə кадəр җимертə.

Кайчан гына əле ул Шəрекънең гүзəл шəһəре Исфаганда (Иран) житмеш мең кеше баш сөягеннəн пирамида өйдерткəн була. Кече Азия шəһəре Сиваста (Төркия) дүрт мең кешене терелəй күмдерə, Исфизарда (Əфганстан) ике мең тере кешедəн, ватык кирпеч һəм измə белəн кушып, манара төзетə. Явыз шигъриятка хирес җанны шундый манзара белəн сугарып тору кирəк булгандыр, күрəсең. Тимербəк Сарай-Бəркəдə дə баш сөягеннəн өелгəн манара калдыра.

Алтын Урда дəүлəтенə кергəн Идел буенда, хəзерге Волгоград өлкəсе саналган җирлəрдə генə дə татарларның онытылгыз шəһəр урыны билгеле. Ə Украина далаларында, Кара диңгез буенда, Молдавиядə күпме? Бөтенесе юк ителгəн, җир белəн тигезлəнгəн.

Олы яулар узгач, цивилизацияле шəһəр урыннарына карындык тəрəзəле, җир идəнле, тəтене эчкə тула торган фəкыйрь йортлар салып, рус крестьяннарын күчереп утырталар. Болгардан алып Əстерханга, Кырымга, Кавказга кадəр шулай. Дөньяда рустан да күчмəрəк халык юк. Яхшы җирлəрнең каймагын алып, табигатьне туздырып, ярлыландырып бара да бара. Алдагы диңгез ярына житкəч кенə берəзгə тукталa, аннары аргы якка чыгу хакында баш вата башлый, чөнки аны теге яктагы җирлəр кызыктыра. Бу хəрəкəт, күчмəлекнең бүгенге көндə дə тукталганы юк...

Алтын Урда шəһəрлəрен гасырлар буена талау бара. Əстерхан кремленең 6—8 метр калынлыктагы дивары Сарай-Батудан алынган татар кирпеченнəн салынган. Ул кирпечнең зурлыгы, формасы үзенчəлекле. Кеше күзеннəн яшерер өченме, кремль диварының тышын соңыннан хəзерге заман кирпече белəн сиплəп чыкканнар. Əнə шулай итеп, Сарай-Бату хəрабəлəрен 1578 елда Явыз Иванның улы Федор патша сүттерə.

С. Петербург Академиясенең табигать белгече П. С. Паллас (1741—1811) узган гасырларда килгəн чакта əле, ике Сарайда да мəһабəт бина калдыклары офыктан ук күренə, дип язып калдырган. Паллас күз алдында, бер зур бина астыннан көмеш белəн тышланган табутлар табып алалар.

Ничə гасыр буе талау вəхшилегенə түзə алмыйча, табигать — Җил-Су-Кояш бу урыннарны ком-туфрак белəн күмəргə, усал ниятле кешелəр күзеннəн яшерергə тырышкан. Əмма бөтен тəн күзəнəге белəн тоясың: аста сулыш бар, шəһəр нигезе яши əле, чорларга тиң зурлыгының хəрабə эзлəрен ул килер буыннарга саклаган.

Монда үзебезнең археолог, тарих фəннəре докторы Əзһəр Мөхəммəдиев житəкчелегендəге Казан университеты студентлары да казу эше алып барганнар.

Без килүгә алар төрбә нигезен ачканнар иде. Кеше кулы тимәгән кабер килеп чыккач, бик нечкә эш, төштән сон эшләп бетерербез, дип алар Актүбә елгасы буендагы палатка-учак янына төшәләр. Ара да ерак түгел югыйсә, шул арада ниндидер бәндәләр, хәзинә эзләп, каберне пыр туздырып, сөякләрне таратып, мәсхәрә итеп китәләр. Әнә шулай... талау бүгенге көндә дә астыртын дәвам итә. Әллә нинди юлбасар шайкалар борынгы шәһәр урыннарында казынып, халыкның истәлеген хәкарә итеп йөриләр икән. Нишлисең, барысы да дала хөкемендә ята, хөкүмәт тарафыннан кайгырту юк.

— Шәһәрләр исән калмавын аңларга да була,— ди Әзһәр әфәнде, әрнүен эчкә яшереп.— Унсигезенче гасырда Россиядә курганнарны талау башлана. Кара диңгездән алып Алтайга кадәр бер генә исән курган да калмый... Шәһәр урыннарында мавзолейлар еш табыла. Кабер ташларын, язуларны кайчандыр махсус кырып, җимереп чыкканнар. Татарны күрәлмауны шулкадәр көчле сеңдергәннәр. Хәзер дә әле... борынгы шәһәр тирәсендәге рус авылы кешесеннән сорасаң, «Монда канэчкеч татарлар яшәгән»,— дип җавап бирәләр.

Әйе, ничә гасыр буена русны бәләкәйдән үк татарга каршы котыртып үстерәләр. Үчле тәрбияләнгән кеше кара күңелле, явыз булып үсә. Ә шундый бәндәләрдән тупланган милләт нинди булырга тиеш? Ялган идея, ялган тарих белән рус халкының рухын бозарга тырышу сәясәте бу!

Сарай-Батуда әрем исе. Әрем исе әрнүле... Гаҗәпкә калып уйланам: минем моннан дүрт мең ел элек салынган грек шәһәре Эфесны, сылу Клеопатра эзләре калган Бергама шәһәрләрен күргәнем бар. Алар икесе дә җир тетрәү аркасында җимерелгәннәр. Тип-тигез урам ташлары кичә генә җәелгән кебек. Аерым колонналары, диварлары исән. Җимерелеп төшкән бөтен ташлары урынында ята. Амфитеатр да бик тиз төзәтерлек. Эфеста грек осталары, читтән таш кертмичә, колонналы мәһабәт бинаны торгызып яталар иде. Китапханә бинасы икән... Мең еллар буена бу шәһәр хәрабәләре нинди генә халыклар, нинди генә дәүләтләр кулына калмаган. Әмма бер ташына да тимәгәннәр. Төрекләр дә кагылмаганнар. Ә ташы нинди диген, ташы! Җемелдәп торган ап-ак мәрмәр. Бәхетле төбәктә туып үлгән шәһәрләр Россия җирендә булсамы! Парфенонынны да сүтә, коллизеенны да җимерә һәм... мал абзары ясый, ишек төбенә түши яисә болай гына вата...

Алтын Урда шәһәрләрендә казу эшләре ныклы нигезгә куелмаган. Сарай-Батуда хан сарае — «Алтын таш» урыны билгеле. Әмма аны казып ачу өчен бик күп акча кирәк. Үз тарихы да шушында килеп ялгана икәнен онытырга тырышкан Мәскәү акча бирергә теләми. Тарихи урыннарны казыганда чыккан уникаль әйберләр дистәләрчә шәһәрләрнең музейларына таратылган. Ә күпмесе урлангач, яшерелгән, юк ителгән. Ә күпмесе шовинист галимнәр тарафыннан башка милләт казанышы итеп үзләштерелгән. Моннан алынган байлыкларны бер кулга җыеп карасаң, бу бөек дәүләтнең, бу бөек халыкның никадәр алга киткән мәдәниятка, сәнгатькә ирешкән булуын күреп шаккатыр идең.

Археологларны кайсы өлкә, кайсы шәһәр финанслый, чыккан байлыкны да шулар ала. Монда хәл шундый: борынгы бина калдыкларын ачалар, фотога алалар, сызымнарын төшерәләр дә киредән күмәләр. Шулай итеп, шәһәрләр икенче мәртәбә үлемгә дучар ителә.

Төзергә иде ике Сарай янында пристаньнар, ачарга иде хәрабәләрне, кайсыларын яңадан торгызып, музейлар, кунакханәләр төзеп китертергә иде дөнья галимнәрен, кызыксынган туристларны; ул чакта инде бөтен ялган тарихлар челпәрәмә килеп, Алтын Урданың бөеклеге башка халыклар күзенә ачылыр иде. Сугышларсыз, җимерүләрсез ничек яшәргә, дигән дөньяви форумнар шушында үтәр иде.

Үзен тудырган анадан ваз кичкән кебек, Россия Алтын Урда мирасына гомер буе кара якты, каһәрле тарих ясады, татарның хәтерен буып торды, үткән зурлыклардан ваз кичтереп, оялту халәтенә китерде.

Тарих капусын аз гына ачсаң да, урда рухыннан һәм урда җирлегеннән яратылган Россиянең үз элгәренә караганда ун башка арттарак калган дәүләт булып формалашуы фаш ителә. Ирек, мөмкинлек бирелсәме — татар белем, мәгърифәт ягыннан шунда ук алга сикереш ясый, хәтта хәрби өлкәдә дә һәр өч генерал. Һәр өч маршалның берсе татардан чыгачак. Яу кырларында янәшә күмелгән өч сугышчының да берсе безнең милләттән бит. Үз-үзенә «киң күңелле» дигән мөһер таккан русның татарга карата гасырлык тарлыгы әнә шул хакыйкатьне ачык белеп хәвефләнүдән килә. Бу аның үкенечле ялгышы. Бүтән милләтләр арты белән борылса да, рус янәшәсендә татар калачак. Чөнки язмышлар чуалып һәм буталып беткән. Кайсы чакта ярсулы берәр шовинистка: «Көзгегә кара, туган, күзләреңнән татар карап тора бит!» — дип кычкырасы килә...

Бүгенге көндә Россиядән бәйсезлек алган илләр яңа тарих язачаклар. Борынгы славян мәркәзе Киев тә Мәскәү басымыннан аеры тарихын тергезәчәк. Менә шул чакта инде вакыт һәм яссылык ягыннан, шагрен күне кебек кечерәя һәм көтекләнә барган тарихын иненә салган Русь, янадан Алтын Урда тарихына кайтып сыену урыны эзләмәсме?..

Исемен атау да хәтәр милләтчелек саналган елларда «Җучи олусы»н фәнни яктан тикшергән Миркасыйм Госманов кебек сирәк галимнәргә һәрдаим каршылыклар белән көрәшергә туры килде. Әмма алар тамак ялына эшләүче көнлекче галим-голәмә дәрәҗәсенә төшмәделәр.

Сталин коргаксыган кулы белән картада чикләрен билгеләгән республикабыз кысаларыннан чыгып, ниһаять, татарга үз тарихына, үз җирләренә кинрәк карарга мөмкинлек туды. Быелның август аенда Татарстан Фәннәр Академиясе Алтын Урданың 750 еллыгына карата үткәргән фәнни конференциясе шуның беренче, мәгънәле мисалы булды. Шунда катнашкан бер төркем галимнәрнең Идел буйлап Әстерханга, Сарай-Батуга гыйльми сәяхәте әлеге конференциягә нәтиҗәле йомгак ясау иде.

* * *

Теплоходта Алтын Урдага багышланган киңәшмәдә әйтелгән кайбер фикерләрнең сөземтәсен китерик:

**«...Алтын Урда юктан барлыкка килмәгән. Ерак бабаларыбыз — һуннар безнең эрага кадәр үк корыч койганнар. Руник язмаларга кадәр мең еллар элек безнең язмабыз булган.»**

**«...Казандагы конференциядә глобаль идея күренмәде. Бу чорны татар халкы күзлегеннән чыгып күтәрергә иде».**

**«...Татарлар тарихта бер төбәкне өйрәнә башласалар, фил аягы астыннан чыккан тычкан кебек, аяк чалырга азапланучы мөтәгалимнәр табыла. Болгар белән шулай булды. Алтын Урдага кул сузучылар да табылачак.»**

**«...Алтын Урда күпмилләтле дәүләт булган. Әмма аның нигезен, дәүләтнең төп җитәкче, сәяси көчен татарлар тәшкил иткән. Ул — татар дәүләте.»**

**«...Моңа кадәр без Россия эчендәге чыганакларны гына өйрәндек. Алтын Урдага багышланган чит ил хезмәтләрен тиз арада тәрҗемә итәргә кирәк.»**

**«...Узган ел Әстерхан өлкәсе һәм безнең дәүләт җитәкчеләре югарылыгында икеяклы килешү төзелде. Әстерхан өлкәсенә кергән тарихи ядькәрләребезне саклауны оештыруны бу килешүгә аерым маддә итеп кертергә иде.»**

Шундый фикерләр, уйланулар, киңәшләр, борчу-эзләнүләр. Бу киңәшмәдә катнашкан, беренче тапкыр гыйльми сәяхәткә барган Казан, башка шәһәр һәм чит ил галим һәм язучыларының исемнәрен атап китү фарыз булыр:

Равил Фәхретдинов, Шамил Мөхәммәдьяров (Мәскәү), Әбрар Кәримуллин, Индус Таһиров, Шәрифҗан Асылгәрәев, Әгъдәс Борһанов (Мәскәү), Тәлгат Галиуллин, Надир Дәүләт (Төркия), Хафиз Малик (АКШ), Равил Кузеев (Уфа), Калил Эллис (АКШ), Вахит Хаков, Нияз Мәҗитов (Уфа), Әзһәр Мөхәммәдиев, Дамир Исхаков, Мостафа Өнәр (Төркия), Әмирхан Еники, Миргазиян Юныс (Мәскәү).

Нәтиҗә: Алтын Урда дәүләте бөек цивилизацияле дәүләт булган. Аның мирасы гомумкешелек мирасы. Бу бәһасез мирасны өйрәнүне, киләчәк буыннарга җиткерүне, казылма ядькәрләрне халыкара хокук нигезендә саклауны оештыруны гамәлгә кертү өчен шушы киңәшмәдә катнашкан галим-язучылар исеменнән «ЮНЕСКО»га, күрше республика-илләрнең галимнәренә, дәүләт җитәкчеләренә мөрәҗәгать кабул ителде. Татарстан Фәннәр Академиясе кузгаткан бу мөрәҗәгать киләчәктә, бәлки, дәүләткүләм югарылыкта яңгыраш алыр. Уян, хәтер! Дөньяга ишетелерлек итеп халык күңелендә чаң сук!

* * *

Өстәлемдә — Сарай-Бату туфрагыннан алып кайткан чүлмәк ватыгы, фирүзә төсен җуймаган кирпеч кисәге. Тагын...бер учма әрем. Әремдә — балбаллы бөек дала хәтере, учаклардан агылган төтеннең әчкелтем төсе, тояк астында калып та таптала белмәү көче. Әремдә — көмеш-җил, ватан-җир исе.

ӘРЕМ ИСЕ ӘРНҮЛЕ...

*1993. Август*



Тәүфикъ Әйди

# ХӘЗИНӘЛӘР УРТАК

### ТӨРЕК-ТАТАР БАГЛАНЫШЛАРЫ

## Кереш

**Татар әдәбияты һәм сәнгате, иҗтимагый фикере үсешендә Төркия белән бәйләнешләребез беренче дәрәҗә әһәмиятле урын тота. Тоталитар совет режимы патша Русиясеннән мираска алган пантөркизм карачкысын бик тырышып файдаланганлыктан, фикер ияләребез ул мөнәсәбәтләрне махсус яктыртудан әлегә кадәр тыелып килде. Ул гына да түгел, шушы йөзнең егерменче елларыннан алып багланышларыбыз тулаем сүнеп калды. Бары хәзер, туксанынчы елларда гына, без төрек кардәшләребез белән өзелгән багланышларыбызны юлга салырга керештек, җитмеш елга сузылган кара бушлыкның табигый үсешебезгә салган каһәрле зыянын фәһемли башладык.**

**Кардәш халыкларның үзара тыгыз аралашуы, тату хезмәттәшлеге аларның аерым-аерым һәм тулаем көчәюенә, зуррак тизлек белән үсешенә этәргеч бирә. Без моңа татар-төрек мисалында да ышана алабыз. XIX гасыр — XX йөз башында ныгып киткән багланышларыбыз татар халкының кабат уянуына, мәгарифе сан һәм сыйфат ягыннан алга таба зур сикереш ясавына, әдәбияты-сәнгате җанлануына, вакытлы матбугаты барлыкка килүенә һәм киңәюенә, тере суы эчергәндәй, шифалы тәэсир итте (13, 14, 15, 26, 55, 65)[1].**

**Мондый тәэсир тегe яки бу күләмдә борынгырак дәверләрдә дә татарның рухи тормышына дәрман өстәп торган (54, 55). Үз нәүбәтендә татар халкының укымышлылыгы, иҗатка һәвәслеге һәм әдәби мираска игътибарлылыгы төрек кардәшләргә шулай ук игелекле йогынты ясаган (58), XX йөздә, бигрәк тә Русиядәге Ватандарлар сугышыннан соң күп кенә күренекле татар мәдәни, сәяси эшлеклеләренең Кече Азиягә күчеп килүе исә Төркиянең иҗтимагый фикере, гуманитар фәннәре үсешенә куәтле этәргеч биргән, дәүләтнең Көнбатыш казанышларын үзләштереп тизрәк көчәюенә хезмәт иткән (1, 22, 45, 52, 59, 69 — № 5641, № 5642, № 5669, № 5671; 70).**

---

Тәүфикъ ӘЙДИ (1941) — *әдип, «Елан угы» романы, «Бoҗра» повесте, хикәя һәм эссе җыентыклары авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

[1] Саннар сызыкча аша бирелгәндә, беренчесе чыганакны, икенчесе — шундагы битне күрсәтә.

**Татар-төрек бәйләнешләрен яктыртуга багышланган махсус хезмәтләр күренмәсә дә, бу тема кайбер басмаларда шактый дәрәҗәдә чагылдырыла. Күптомлы «Татар әдәбияты тарихы»нда, бигрәк тә аның 3 томындагы «Көнчыгыш традицияләрен үстереп» бүлегендә (523-537 бб.) әдәби тәэсирләргә кагылган байтак мәгълүмат китерелә һәм фикерләр белдерелә. Мондый мәгълүматларны «Галиәсгар Камал турында истәлекләр» (15), «Мөхәммәтгаяз Исхакый» (45), «Тукай турында замандашлары» (65), «Тукай турында истәлекләр» (66) китапларыннан, Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» (10), Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (50) әсәрләреннән дә табып була. Ф. Кәриминең «Истанбул мәктәпләре» (38), Р. Фәхретдиннең «Әхмәт Мидхәт» (11-109) А. Айданың «Садрый Максуди Арсал» (1), Ә. Канлыдәрәнең «Русия төрекләреннән Муса Җарулла Биги» (69-№ 5675), Х. Миңнегуловның «Сәйф Сараи» (43), Г. Б. Таймасның «Казанлы төрек мәшһүрләреннән ике Максудиләр» (52), Ә. Тимернең «Йосыф Акчура» (59) хезмәтләре татар-төрек бәйләнешләрен күзаллар өчен инде тарихка әйләнгән бик күп серләрне ача. Төркия вакытлы матбугатында мәшһүр мөһаҗир татарларга багышланган мәкаләләр даими дөнья күреп тора, шулардан Н. Бинаркның «Чагыбызның бөек төрек белгене Рәшит Рәхмәти Арат» («Казан» ж., 1970, № 1. Анкара), «Габдулла Баттал» («Казан» ж., 1978, № 8), Т. Гүләнсойның «Әхмәт Тимерен хәяте вә әсәрләре» («Ерҗийес» ж., 1983, Кайсәри), И. Исханның «Акдәс Нигъмәт Куратын аркасыннан» «Бәлгәләрлә төрек тарихи дәргесе» ж., 1971, № 7—8) аеруча игътибарга лаек. Мондый хезмәтләрнең тулырак тезмәсен «Төркия дышындакы төрекләр библиографиясе»нең 2 томыннан (69—665-730) барларга мөмкин. Анда теркәлгән хезмәтләр арасында Г. Б. Таймасның «Казан төрекләре» китабының ике басмасы (53), аның ук төрле журналларда дөнья күргән, театрыбызга, музеебызга, нәшриятебезгә багышланган мәкаләләре (69—№ 6031, № 6164), М. Таһирның белем һәм тәрбия бирүебезне, фольклорыбызны, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез хәлен сурәтләгән мәкаләләре (69—№№ 5979, 6016, 6135), Н. Дәүләтнең «Урыслаштырмада Казан төрекләре үрнәге» (69—№ 6059), Т. Мамашның «Казан ханлыгының соңгы көннәре» (69—№ 6155) язмалары һ. б. бар. Татар халкына кагылган ул хезмәтләрне Төркиядә яшәүче милләттәшләребез иҗат итә. Алар арасында Йосыф Акчура, Рәшит Рәхмәти Арат, Әхмәт Тимерләр аеруча тырышлык күрсәтә. «Ислам энциклопедиясе», «Төрек дөньясы әл китабы» бүлешмәлекләренә Р. Аратның «Казан» (69-№ 5749), Ә. Тимернең «Төньяк төрек әдәбияты» (69-5970), «Татарларның җәелүе» (69-6160) һ. б. мәкаләләр кертелә.**

**Төркиядә шагыйрь һәм әдипләребез, галимнәребез һәм фикер ияләребез турында даими язып торалар. Ш. Мәрҗани, Й. Акчура, Г. Исхакый, Г. Тукай, С. Максуди, Р. Аратлар хакында аерым китаплар да, мәкаләләр дә, аларның үз әсәрләре дә төрек укучысына күп мәртәбәләр тәкъдим ителә. Бу җәһәттән «Төрек йорты» (Истанбул), «Мәгълүмат» (Истанбул), «Йени форум» (Анкара), «Төрек күлтүре» (Анкара), «Төрек дөньясы» (Истанбул), «Ерҗийес» (Кайсәри), «Казан» (Анкара), «Кардәш әдәбиятлар» (Измир), «Төрек дөньясы араштырмалары» (Истанбул), «Әмәл» (Анкара) журналлары аеруча игътибар күрсәтә. Милләттәшләребез төрек, татар телләрендә нәшер иткән «Казан» журналы (1970—1980) мөһаҗирләребезне һәм төрек халкын татар әдәбияты һәм сәнгате, күренекле шәхесләребез белән таныштыруга мактаулы өлеш кертте. Аның сәхифәләрендә, алдарак саналган фикер ияләребездән тыш, Һ. Атласи, Г. Баруди, бертуган Бубыйлар, М. Гафури, К. Насыйри, Г. Б. Таймас, М. Фәйзи, Р. Фәхретдин һәм башкаларның тормышы вә эшчәнлеге сурәтләнә, әсәрләреннән үрнәкләр асыл нөсхәдә һәм тәрҗемәдә танытыла. Бу журнал ватаныннан читтә, башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез тормышын да яктыртырга тырыша.**

**Кызганыч ки, Татарстан җөмһүриятендә төрекләрне, аларның рухи байлыкларын татар укучысына таныту шундый ук күләмдә гамәлгә ашырылмады. Әмма нидер эшләнде — бу хакта киләсе бүлекләрдә сүз булыр.**

## Бер күрешү — бер гомер

Без әле кайчан гына, борынгы бабаларыбызны Идел-Кама буйларына VIII—IX гасырларда килеп урнаша башлаган, дип саный идек. Тарих фәненең үсеше, анда, ниһаять, татар галимнәренең дә җиң сызганып эшкә керешүе бу күчешне III гасырга нисбәтләргә мөмкинлек бирде. Ләкин «европалашуыбыз»ны III гасырга чигерү, бәлки, соңгы сүз булмас, төркиләрнең элгәреге дулкыны Идел-Кама буйларына тагын да алданрак җәелә башлавы

ачыклануы да бик ихтимал. Европацентризм төркиләрне монда килмешәк итеп кенә күрергә теләгәнлектән, аның фәндә фәкать үзенә «ошаган» ачышлар гына ясап мавыгуы сер түгел. Нәкъ менә шуның тырышлыгы белән дә төрекләрнең Кече Азиядә төпләнүе Малазгирт янында дошманнарны җиңгән 1071 елдан исәпләнеп киленде. Урыс телендәге белешмәлекләрне актарсаң, Кече Азиядә XI йөздә генә сәлҗук төрекләренең тамыр җибәрүен укыячаксың. Әмма чынлыкта Алгы һәм Кече Азиядә төрки кабиләләрнең әүвәлге дулкыны күпкә элгәрәк — б. э. к. 5000 елларда ук килеп урнашуы ачыкланды (67-56). Бу хакыйкать борынгы шумер, хури (хурри), һәтит (хетт), аккад халыклары составында төрки ырулар да булуы белән раслана — әлеге халыклардан калган чүлмәк шакмаклардагы язуларда төрки исемнәр, сүзләр һәм җөмләләр дә очрый.

Шулай икән, төрек белән татар күптән аерылган, димәк, Үзәк Азиядәге ташъязмаларны (V—VIII йөзләр), XII йөзгә кадәр иҗат ителгән әдәби әсәрләрне уртак мирас итеп санарлык җирлек тә бетә түгелме соң?

Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Төркиләр Үзәк Азиядән бүтән тарафларга төрле вакытларда дулкын-дулкын күчкән, бу күчешләр һәрвакыт һәм мотлак бер генә юнәлештә баргандыр дип раслау да бик кыен. Ә уртаклыкны соңгы дулкын күчешләр дә барлыкка китерә ала лабаса.

Ничек кенә булмасын, татар белән төрекнең бер ата-бабадан яралуы, аларның гореф-гадәтләре һәм телләре, шул телләрдә барлыкка китерелгән халык авыз иҗатларының уртаклыгы яки үтә якынлыгы бәрәүдә дә шик уятмый. Тугызынчы гасырдан алып ике халыкның да ислам динен кабул итә башлавы бу якынлыкны, охшашлыкны ныгытуга өстәмә оеткы сала. Төрки кабиләләр, халыклар яшәгән төбәкләр арасында сәүдә кәрваннары йөри, Идел-Кама буйларыннан Гарәбстанга мөселманнар хаҗ кылырга агыла — шуларның һәммәсе төрле кабилә вәкилләренең чын мәгънәсендә «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» аралашуына китерми калмый. Шуңа күрә аларга Үзәк Азиядә сакланган ташъязмалар аңлаешлы, уртак булып кала һәм, хәтта, изге васыять кебек кабул ителә. Мәхмүт Кашгарлының (XI йөз) «Диване лөгатет — төрек» сүзлеге, Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» (1069), Әхмәт Йөгнәкленең (XII йөз) «һибәтелхәкаикъ» поэмалары, Әхмәт Ясәвинең (1166 елда вафат) «Хикмәтләр диваны» әсәре болгар-татарны һәм госманлы төреген бердәй илһамландыра. Аралары ерак булса да, ул заманда әле Кече Азия һәм Идел-Кама буе төркиләре теле хәзергедәй үк аерылмый, шуңа күрә болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Йосыф кыйссасы» (XIII йөз), Алтын Урда иҗатчысы Б. Рабгузинең «Кыйссасел әнбия»се (XIV йөз) — Анадулыда, сүз сәнгате җәүһәрләре «Сәет Баттал газый хикәясе», «Салсалнамә», Гашыйк пашаның «Гарибнамә»се, М. Чәләбинең «Мөхәммәдия»се Идел-Кама буйларында асыл нөсхәләрендә яратып укыла (54-465). Төрекләрнең атаклы «Дәдәм Коркыт китабы» безнең якларда шулкадәр яратып кабул ителгән ки, берзаман аның болгар-татар варианты та барлыкка килгән (54-536).

Әмма, әдәби бәйләнешләрне җентекләп сурәтләргә керешкәнче, ике халыкның җанлы аралашуына киңрәк тукталу урынлы булыр. Болгар патшасы Әхмәт ибн-Җафарның 930 елларда хаҗга баруы билгеле (57-50). Ул һәм аннан соңгы байтак хаҗиларыбыз Мәккәгә Урта Азия һәм Багдад аша юнәлә, төрекләрнең Кече Азиягә күчеп китәргә өлгермәгән бер дулкын ата-бабалары белән алар шул юлда очрашкандыр дип фараз кылырга мөмкин. Хаҗга Кече Азия аша бару Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверендә, бигрәк тә госманлылар Константинопольне яулап алып (1453 ел), аны Истанбулга әйләндергәч, җайга салына. Шушы заманда турыдан-туры сәүдә итү дә башлана: Идел, Дон елгалары буйлап Азак диңгезенә, аннан Кара диңгез аша Истанбулга бездән металл һәм көн әйберләре, затлы мех, бал, балавыз илтеп саталар, госманлылардан Казанга келәм, алтын-көмеш, салкын корал, кипкән җимешләр китерелә (57—77, 79, 88). Ике арада хаҗилар, сәүдәгәрләр генә түгел, рухи байлык иҗат итүчеләр дә йөри. Мисалга, Кече Азиядә туган шагыйрь Өмми Камал (Исмәгыйль. 1475 елда вафат) күп гомерен Идел буенда уздыра (54—464). Ул үзе бу хакта: «Гарибәм, горбәтә кәлдем илемдән»,— дип яза. Ата-бабаларыбыз белән аралашып яшәгәнлектән, аның иҗатына телебез һәм әдәбиятыбыз тәэсире ачык сизелә. Үз нәүбәтендә Өмми Камал шигырьләре Кече Азиядә түгел, Идел буенда кульязма рәвешендә киңрәк тарала. Аның иҗаты Төркиядә махсус өйрәнелмәгән хәлдә, татар укучылары тарафыннан сөеп укыла, «Диван»ы Казанда берничә тапкыр нәшер ителә (35—60) — ул Идел буенда үз шагыйребез шикелле таныла.

1666 елның көзендә мәшһүр төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби Әстерхан һәм Сарай Бәркә шәһәрләренә дә килә, шуларга якын-тирәдәге татар авылларында

да була (72—234) һәм ата-бабаларыбыз турында: «Татарлар беркайчан да гайбәт сөйләми, ялганламый, яла якмый, бирәүдән дә курыкмый... Алр чирләми, нык гәүдәле... Җитезләр, кыюлар»,— дип хәбәр итә (72—137). Әстерхан, Сарай, Казан шәһәрләре халкының гореф-гадәтләре, көнкүреше, дингә мөнәсәбәте, Идел буенең табигате хакында байтак кызыклы мәгълүматлар китерә, үзе аралашкан аерым кешеләр белән таныштыра, укучылар арасында киң таралган гыйльми һәм әдәби әсәрләрне телгә ала.

Ә. Чәләбине яңа буын милләттәшләренә татар галиме Ризаэтдин Фәхретдин (1859—1936) таныта (71—143).

Хаҗга укымышлы кешеләр еш барганлыктан, аларның байтагы (Г. Баруди, М. Яташева һ. б.) изге сәфәрләре турында хатирәләр яза. Бу истәлекләрнең бер өлеше, туган телебездә вакытлы матбугат барлыкка килгәч, укучыларга килеп ирешә (34—36, 71—144). Мисалга, күренекле галимебез Шиһабетдин Мәрҗани хатирәсеннән без аның Истанбулга 1880 елда килүен, монда байтак күренекле укымышлылар, җөмләдән, шәйхелислам Әхмәт Әсгать, гаделия министры Әхмәт Җәүдәт паша, тышкы эшләр министры Гасыйм паша һ. б. белән очрашуын беләбез. Татар галименең Госманлы империясе башкаласына килүе турында Истанбул гәзитләрендә хәбәрләр басыла. Әлеге очрашулар вакытында Төркия һәм Идел буе, мөселман дөньясы рухи тормышы хакында фикер алышалар. Мәрҗани хуҗаларга үз әсәрләрен һәм якташларының әһәмиятле санаган китапларын бүләк итә (71: 118—122. «Рихләтел Мәрҗани», Казан, 1898). Төркия укымышлылары Мәрҗанинең әсәрләрен саф гарәп телендә язуына соклана, аның тирән белеменә югары бәя бирә, киләчәктә дә хәбәрләшеп яшәргә сүз куеша.

Татар рухи тормышындагы торгынлыкка, томаналыкка каршы беренче баш күтәргән ислахчыбыз Габденнасыйр Курсавиның (1776—1812) хаҗ сәфәре Истанбулда өзелә — ул шунда чирләп китеп вафат була һәм Солтания мәчете янында Өскедар мәхәлләсендә күмелә (55—547).

Күренекле шагыйребез Дәрдемәнд 1880—1881 елларда Истанбулда яши, хосусый рәвештә төрек теле һәм әдәбиятын өйрәнә, күңелен биләгән кайбер әдипләр белән аралаша (12—251). Фөзүли, Габделхак Хәмит (1852—1937), Тәүфикъ Риза, Габдулла Җәүдәтләр иҗаты белән танышу аның әдәби зәвыген үстерә, аны иҗат эшенә илһамландыра. Ватанына кайткач, ул төрекчәдән кайбер хикәя, романнар тәрҗемә итә башлый, үз шигырьләрен язганда да төрек каләмдәшләре тәҗрибәсенә таяна (56—196).

1888 елда Төркиягә татарның беренче романчысы Муса Акъегет күчеп килә. Ул монда «Мөлкия» гали мәктәбен тәмамлый, аннары шунда ук урыс теле укытырга керешә. 1908 елда ул монда «Мәтин» исемле матбага ача һәм шул ук исемдә гәзит чыгарырга тотына. Бу эштә уңышка ирешмәгәч, Анадулының (Кече Азиянең эчкәрге өлеше) бер өязенә хезмәткәр булып китә. Соңрак Истанбулда китапханәдә хезмәт итә (13—200, 50—82, 55—558).

XIX йөз ахыры — XX йөз башында татар яшьләре арасында дөньяви югары белем алу теләге елдан-ел арта бара, әмма патша Русиясе колониаль сәясәте бу омтылышка ныклы киртә сала, аларны илнең югары уку йортларына кабул итми. Алдынгы яшьләребез шуннан соң бар өметләрен чит илгә, башлыча Төркиягә юнәлтергә мәҗбүр була. Дин уртаклыгы, телләрнең якынлыгы, Госманлы империясе дәүләт эшлеклеләренең Русиядән килүче төрки кардәшләренә теләктәшлек күрсәтүе аралашуның көчәюенә китерә. Нәҗип Гасрый язганча, татар шәкертләренең Төркиягә барып, андагы гимназия һәм хәрби уку йортларына кереп укуы ихтыяҗга һәм модага әйләнә (17—66). 1891 елда Гобәйдулла Бубый, Харис Фәйзи, Фатыйх Кәримиләр Истанбул дәрелфөнүнендә белем алырга керешә (11—117, 118). Алар монда төрек, гарәп, фарсы телләрен камил үзләштерә, табигать фәннәре, математика, физика, тарих, әдәбият белән тирәнтен таныша. Фатыйх Кәрими монда француз телен өйрәнүгә дә нык игътибар бирә (11—119). Төрек укымышлары белән якыннан аралашу аларның күңел дөньясын баета, туган илгә кайтып эшләр өчен белем дә, гайрәт тә өсти. Татар дөньясында дан казанган алдынгы рухлы «Бубый», «Галия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения» мәдрәсәләрендә Төркиядән алып кайткан дәресләкләр буенча Истанбулда белем алган яшьләребез укыта башлый (11—89). Харис Фәйзи география, гомум тарих, табигать белеме буенча дәресләкләр яза (11—123) һәм «Хөсәения» дә сабак бирә. Гобәйдулла Бубый туган авылы мәдрәсәсен үзгәртеп кора (11—99).

Булачак талантлы язучыбыз Шәриф Камал 1900 елларда Истанбулга килә һәм монда бер ел дәвамында «Дәрелмөгаллим» дә сабак тыңлый, буш вакытларында тамак хакына язу-сызу эшләрен башкара, әнә шулай төрек җәмгыятенең төрле катламнары тормышы белән таныша (56—316). Мәхмүт Алмаев Истанбул-

га килеп, типография эшләрен өйрәнә, һөнәр алу аңа соңрак ватанга әйләнеп кайткач, «Чүкеч» журналын чыгарырга юл ача (15—178).

Галиәсгар Камал Истанбулга ике мәртәбә килә. 1901 елдагы сәфәрендә ул төрек язучылары, җөмләдән, Нәмикъ Кәмал белән таныша һәм Казанда ачкан «Мәгариф» китап кибетенә бик күп төрек әдәбияты җыйнап алып кайта, аны халыкка сатуны оештыра (15—9). 1912 елда ул монда «Йолдыз» газите хәбәрчесе сыйфатында килә. Ике ай дәвамында күп кенә төрек эшлеклеләре белән аралашып, матбугат дөньясын күзәтеп, Балкан сугышы вакыйгаларын өйрәнеп, анализлап, егермеләп мәкалә яза (15—179).

XX йөз башында татарның беренче театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче Габдрахман Кәрәм Истанбул дәрелфөнүненең әдәбият-сәнгать бүлеген тәмамлый (18—276).

1905—1906 елларда хаҗга баручы Габдулла Бубый (1871—1922) да Истанбулда туктала. Ул инде күптән Әхмәт Мидхәтнең яңа мәдәниятне ислам дине белән килештерүгә, яраштыруга багышланган әсәрләренә ихлас куйганлыктан, монда фикердәшләрен барлый, үзе дә христиан динен кире кагу рухындагы уйларын уртаклаша (11—99).

Әдәбият галимебез, профессор Габдрахман Сәгъди 1908—1911 елларда Истанбул дәрелфүнөнендә белем ала (18—425).

Күренекле дин галиме Муса Биги дә Истанбул мөхите белән танышуга ихласлык күрсәтә (11—111). Күренекле шагыйребез Сәгыйть Сүнчәләй 1926—1927 елларда РСФСРның Измирдәге консуллыгында тәрҗемәче булып эшли (18—436).

Югарыда саналган татар мәгърифәтчеләренең, язучыларының күпчелеге Төркиядә белем алу максатында яки хаҗга барышлый кыска вакытка гына тукталса, фикер ияләребезнең монда озаграк яшәп калучылары, хәтта гомеренең зуррак өлешен яки тулаем соңгы дәверен шушында уздыручылар да бар. Габдерәшит Ибраһим, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Садрый Максуди Арсал, Габделбари Баттал Таймас, Рәшит Рәхмәти Арат, Хәмит Зөбәер Кушай, Әхмәт Тимер — саный китсәң, алар бик күп.

Татар уяныш, яңарыш хәрәкәтенең ялкынлы каһарманы Г. Ибраһим (1850—1944, туган елы 1853 дип тә күрсәтелә, тәмам ачыкланмаган), мәсәлән Истанбулга әүвәл мәртәбә 1877 елда аяк баса. 1881 елда монда яңадан әйләнеп килгәч, ул төрек мәгърифәтчеләренең беренче дәрәҗә якты йолдызлары Нәмикъ Кәмал, Әхмәт Рәшит паша, Мөгаллим Наҗи (1850—1893), Җамалетдин Әфгани, Әхмәт Мидхәтләр җыйналган даирәгә үтеп керә, алар белән бергә төрки кавемнәрне аурупалаштыру, аларны империалистлар тарафыннан изелүдән коткару, мәгариф-тәрбия челтәрен яңарту программаларын һәм чараларын тикшерә. 1895—1897, 1910—1917, 1918—1930, 1932—1933 елларда Төркиядә даими яшәгәндә, Госманлы империясен һәлакәттән коткару, Төркия җөмһүриятен ныгыту, Төркиядән тыштa калган төрки кавемнәрне ят халыклар йогынтысыннан саклап калу хакында төрек фикердәшләре белән тыгыз хезмәттәшлектә яши. Күренекле төрек шагыйре Мәхмәт Акыйф аның белән дуслашып кына калмый, «Сафахәт» поэмасында Габдерәшит Ибраһимны Фәез исеме астында зур мәхәббәт белән сурәтли. Матбагачы Әшрәф Әдип исә милләттәшебезнең сәяхәтнамәләрен «Сыйраты мөстәкыйм» журналында һәм аерым китаплар тезмәсе рәвешендә бастырып чыгара (73—31, 32, 33).

Халкыбызның мәшһүр фикер иясе, иҗтимагый хәрәкәтебезнең күренекле каһарманы Йосыф Акчура (1876—1935) Истанбулга бала чагында 1883 елда килә, шушында үсә, белем ала. Ул 1889—1890, 1904—1908, 1917—1919 елларда — ватанында, 1899—1904 елларда Парижда яши, калган тормышын исә Төркиядә уздыра. Төрки халыкларны үзара якынайту, аларны бер максат тирәсенә туплау, Төркия дәүләтен яңадан көчәйтү хакына Й. Акчура журналист, галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак җиң сызганып хезмәт кыла, төрки кавемнәрнең күренекле сәясәтчеләре, Төркиянең атаклы язучылары, матбагачылары, милләтвәкилләре (парламент депутатлары) белән иңгә-иң эшли, матбугат чыгарыша, университетта укыта (50). Төркиядә, Франциядә туплаган белеменнән һәм тормыш тәҗрибәсеннән газиз халкына да өлеш чыгара — Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих һәм география укыта, «Казан мөхбире» газитен редакцияли (11—123), «Мөселман иттифагы» партиясен оештыруда башлап йөри, инде тәмам Төркиядә төпләнеп яшәргә керешкәч тә, «Вакыт» газитенә мәкаләләр җибәреп тора.

Габделбари Баттал Таймас язуынча (45—175), Гаяз Исхакый (1878—1954) Истанбулга беренче тапкыр 1909 елда килә һәм монда ике ел чамасы яши. Ул

Истанбулда тиз арада күренекле фикер ияләре һәм язучылар, журналистлар белән таныша, төрек мәдәни хәрәкәтенә катнашып китә. Танылган әдип Сөләйман Назыйф һәм башкалар белән төрек әдәби теле хакында бәхәскә керә, бу бәхәс Агаһ Сырры Левендиең «Төрек дилиндә гәлишмә вә сәдәләшмә сафһалары» хезмәтендә дә чагылдырыла. Г. Исхакый, гади (халыкчан) тел һәм купшы (сарай) тел табигатен аңлатып, «Сыйраты мөстәкыйм» журналында берничә мәкалә бастыра, төрек язучыларын гарәп-фарсы алынмаларыннан котылган гади төрки телдә, Анадулы игенчеләре һәм терлекчеләре җиңел аңлый торган телдә язарга өнди, «Төрек дәрнәге»ндә татар әдәбиятына баглы интервьюлар бирә (28, 45—75).

Г. Исхакый егерменче еллардан алып Төркиядә еш була, 1925—1927, 1940—1954 елларда исә шушында төпләнеп яши. Ул монда чакта да әсәрләрен, нигездә, туган телендә яза, милләттәшләрен Идел-Уралны азат итү, татар халкын бәйсезлеккә ирештерү көрәшенә тупларга тырыша. Әмма төрек әдәбиятын да укый, «Төрек йорты» журналына (45—11), бүтән басмаларга да мәкаләләр яза, төрек каләмдәшләре, фикер ияләре белән дә даими багланышта яши.

— Бервакыт мин остазым Гаяз Исхакыйның күренекле төрек язучысы Пәйәми Сафа белән әңгәмә корып торуына шаһит булдым,— диде миңа Гали Акыш (25.VI.1993. Казан).— П. Сафа (1899—1961) «Ялгызбыз», «Без — кеше» һ. б. әсәрләр, җәмгысе 15 ләп әйбәт роман авторы, китаплары кат-кат басыла иде. Гәп корып торганда Г. Исхакый аңа: «Пәйәми бәй, сез тормышчан, җитди, сәнгатьчә матур романнар язасыз, шул ук вакытта кушамат астында секс, җиңелчә маҗара романнары да бастырып ятасыз. Нигә соклandыргыч сәләтегезне затсыз язмаларга әрәм итәсез?» — диде. Пәйәми бәй аңа үкенечле төстә: «Әгәр шуларны язмасам, ачтан үләр идем мин»,— дип җавап бирде.

Күренә ки, Г. Исхакый танылган төрек каләмдәшләре белән аларның иҗатын яхшы белеп аралаша, әдәбиятның халык өчен тормыш мәктәбе булырга, язучының халык күзен ачарга хезмәт итәргә тиешлеге хакында Төркиядәге каләмдәшләренә дә искәртеп тора.

Алда саналган башка эшлеклеләребезнең дә төрекләргә йөзләгән-меңләгән җеп белән бәйләнүен расларга мөмкин. Милләттәшләребез Төркиягә шулкадәр үзләшкән һәм сеңгән ки, монда аларның Идел-Урал буе татары икәнлеген күпчелек белми дә. Садрый Максуди (1879—1957), Рәшит Рәхмәти Арат (1900—1964), Габделбари Баттал Таймас (1883—1960), Хәмит Зөбәер Кушай (1897—1984), Әхмәт Тимер (1912 дә туган), Әкътәс Нигъмәт Курат (1903—1971), Зәки Вәлиди Туган (1890—1970) нәкъ менә шундый шәхесләрдән. Алар — Төркиядә югары уку йортларында укытучы, профессор, гыйльми җәмгыятьләр коручы, институтлар оештыручы, дәүләт һәм җәмәгать эшләрен төпкә җигелеп тартучы затлар. Аңлашыла ки, бу шәхесләр көн саен, сәгать саен төрек кардәшләребез белән аралашып торган, хезмәттәшлек иткән. Аларның тормышы һәм эшчәнлеге, казанышлары турында Төркиядә күп кенә махсус китаплар, мәкаләләр чыгарылуы (1, 45, 52, 59, 69 һ. б.) бер дә гаҗәп түгел — милләттәшләребез татар-төрек багланышларын бөтен барлыклары белән гамәлгә куеп яшәгән ләбаса!

Гаяз Исхакый бер чыгышында 1890 елларда Идел-Уралдан Төркиягә 50 меңләп татар күчеп китүен сөйли (45—298). Аларның бер өлеше төрле михнәт-афәтләрдән юлда вафат була, икенче өлеше кире борылып кайта, әмма күпчелеге изге дип саналган Госманлы җиренә барып җитә һәм шунда тамырлана. Әнә шулай татар-төрек багланышлары тагын да киңәя, төркиләрнең ике тармагы арасында рухи хәзинәләр, тормыш тәҗрибәсе алмашу, үзара аңлашу һәм дуслашу яңа баскычка күтәрелә.

Төркия, аерым алганда, Истанбул шәһәре күп кенә татар язучыларына һәм галимнәренә (Г. Курсавый, М. Акъегет, Й. Акчура, Г. Исхакый...) яңа ватан, аларның мәңгелек йокыга оеган изге җир булып китә. Шул ук вакытта Төркия татар халкы мәдәниятен үстерүгә хезмәт итәчәк шәхесләрне дә бирә. Язучыбыз Атилла Расих 1915 елда Истанбулда дөньяга килә (47—63,64). Ләбиб Каран (75—157), Гали Акыш (4, 73—98, 99), Надыйр Дәүләт (19, 20, 69) шушында белем-тәрбия алып, Мәхмүт Таһир, Әсфәндияр Чынбай (4, 6, 76) Анкарада чыныгып, милли азатлык көрәшебезгә кушылып китәләр, төрек телендә һәм туган шивәләрендә байтак әсәрләрен бастырып чыгаралар. Аңлашыла ки, бу эшләр дә төрек кардәшләребез белән бары тик аңлашып яшәү, алар ярдәменә таяну аркасында гына мөмкин була.

Татар-төрек аралашуы Идел буе җирлегендә дә бара. Мисалга, XIX йөздә Казан университетының көнчыгыш телләре бүлегендә төрек Госман Котлышый

эшли (55—19). Шул дәвердә монда татар укымышлылары И. Хәлфин, М. Г. Мәхмүдов, Ә. Дәминов, С. Мортазин һәм бүтәннәр дә хезмәт итә, димәк, танышу, дуслык элемтәләрен барлыкка китерү өчен алшартлар әзер була.

XIX йөз ахырын күздә тотып, Галиәсгар Камал: «Мәдрәсәи Мөхәммәдиядә каравылчы булып эшләүче бер төрек бар иде. Шуңардан төрек теле өйрәнергә тотындым. Аз вакыт эчендә төрекчә сөйләшергә мәуффәкъ булдым»,— ди (15—134).

Шәриф Каюмовның хәтерләвенчә, 1904—1905 елларда Уральск шәһәренә Габделвәли исемле бер төрек егете килә. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыган Габдулла Тукай аның белән бик тиз дуслашып китә, «Тукайның төрек телендә сөйләшә белүе һәм фикердә бер булулары аларны якынлаштырды, дип уйлыйм,— ди Каюмов.— Төрек Вәли Төркиядән нинди дер сәбәп белән качыпмы, сөрелепме килгән егет булырга кирәк... Тукай ара-тирә төрек Вәли белән төрекчә җырлыйлар иде, ашханәгә бергә төшеп, бергә юынып, бергә ашап-эчеп тордылар» (66—61).

«Язын көймәдә пикниккә чыгалар. Мәдрәсә яныннан кузгалып киткәндә Тукай Гомәр хәлфә белән «Мөхәммәдия»дән:

Чөн адәм җәннәтә керди,
Юҗә гыйззәтләри ирди,

— дип җырлап җибәрәләр. Төрек Вәли дә шунда тыңлап бара» (66—64).

«Мәдрәсә бабыннан сүз чыкса, Габдулла Тукай әфәнде иң матур хатирәгә шул шәкертне сөйли иде,— ди Г. Кариев.— Шул шәкерт берлә алар җәй буе бергә җырлап, бергә йөреп, ач булсалар да, рәхәт, хозур үткәргәннәр. Габдулла әфәнденең иң матур җәе шул төрек шәкерте берлә үткән. Ул төрек шәкертенең шигырьләреннән бәгъзеләрен Габдулла әфәнде 1907 елларда миңа Уральскида вакытта укыган иде... Шул төрек шәкерте белән торган заманнарда Габдулла әфәнде төрек романнарын... бик яратып укый иде» (66—55, 56).

Г. Кариев хәтерләвенчә, «Г. Тукайга төрек шәкертенең түземлеге, әхлаклылыгы, гүзәл тәрбиясе бик нык тәэсир иткән» (66—55).

1910 һәм 1914 елларда Казанга Төркия премьер-министры Хөсәен Хилми паша килә һәм монда шәһәр җәмәгатьчелеге белән очраша. Шул сәфәрләрнең берсендә ул Н. Ф. Катановның 9000 томлы китапханәсен сатып ала һәм Истанбулга җибәртә. Бу хәзинәне Төркиягә күчеп барган язучыбыз Муса Акъегет тәртипкә сала (80—329).

1913 елның җәендә Төркия шәйхелисламы Мәхмүт Әсгать Русия шәһәрләре буйлап сәяхәт кыла, шушы сәфәрендә ул Казанга да килә, монда язучы Фатыйх Әмирхан белән дә очраша (79—486).

1921 елның 16 октябрендә исә Фатыйх Әмирхан янына Төркия парламенты депутаты Исмәгыйль Сөбхи Суйсаллы килә һәм алар бер сәгать буе сөйләшеп утыралар (80—196, 197).

Беренче дөнья сугышында Русия кулына меңләгән төрек хәрби әсирләре эләгә, аларның байтагы Идел-Урал, Себер өлкәләрендә — татарлар яши торган губерналарда да җәфа чигә. Милләттәшләребез хәвефле хәлдә калган әсирләрнең хәлен җиңеләйтү, аларны ачлык-ялангачлыктан коткару, иреккә чыгуларына булышу өчен кулларыннан килгәннең һәммәсен эшли. Бу кешелекле, кардәшләрчә ярдәмнең көчәюенә Төркиянең Кызыл ай җәмгыятеннән 1918—1919 елларда рәсми вәкил булып килгән Йосыф Акчура да өлеш кертә (59 — 58, 59, 61). Кардәшлек, дуслык тегеяки бу як бәлагә тарыганда сынала. Төрек хәрби әсирләре татар туганнарының шәфкатьле мөнәсәбәтенә рәхмәт укыгандыр, исән-сау илләренә кайткач та моны рәхмәт хисе белән хәтерләрендә тоткандыр, дип ышанырга тулы нигез бар.

Озын бер тәнәфестән соң Татарстан белән Төркия арасында җанлы аралашу сиксәненче елларда яңадан юлга салына башлады — бер төркем татар язучылары турист сыйфатында Истанбулны һәм Измирне, Эгей һәм Ак диңгез буйларын, данлы борынгы тарихи һәйкәлләрне, ямьле табигатьне тамаша кылып кайтты. Туксанынчы елларда инде галимнәребез, язучыларыбыз һәм артистларыбыз татар мәдәниятенең һәм фәненең тулы хокуклы рәсми вәкилләре рәвешендә Төркия туфрагына аяк басты. Алар арасында Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Мәдинә Маликова, Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев, Әбрар Кәримуллин, Мирфатыйх Зәкиев, Рафаил Мөхәммәтдинев, Роберт Батулла һәм бу юлларның авторы да бар иде. Төрки шигырь һәм фольклор фестивальләрендә, гыйльми симпозиум һәм конференцияләрдә, төрки

язучылар киңәшмәләрендә, сәнгать бәйрәмнәрендә Татарстан вәкилләре эчтәлекле чыгышлары, эшлекле гамәлләре белән хезмәттәшлегебезне киңәйтүгә һәм ныгытуга лаеклы өлеш кертте. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, һәвәскәр балалар ансамблебез төрек тамашачылары алдында уңышлы чыгыш ясап, аларның кайнар мәхәббәтләрен казанды. Татар мәдәнияте, фәне илчеләренә Төркия матбугаты, радио-телевидениесе илтифатлы булды — төрек җәмәгатьчелеге Идел-Уралдагы кардәшләре хакында шактый мәгълүмат алды.

Төрек язучылары һәм галимнәренең Татарстанга килә башлаулары безнең элемтәләрне тагын да ныгытып җибәрде. Шагыйрь Яхъя Акъэнгин, әдипләрдән Сәвинеч Чокум, Гөнүл Пултар, галимнәрдән Туран Язган, Садыйк Турал, Фикрәт Төрекмән, Шабан Караташ, Фәхретдин Кырзыуглы, Гөлчен Чадырлыуглы, Надыйр Дәүләт, Мостафа Өнәр һәм бүтәннәр Татарстанны тамаша кылып, укымышлыларыбыз белән очрашып, безне Төркия казанышлары белән таныштырды, уртак мәнфәгатьләребезне кайгырту хакында киңәш-табыш итте. Кунакларыбыз матбугат, радио-телевидение аша да чыгышлар ясады.

Тагын шунысы дә сөенечле: Татарстан капкалары тышкы дөньяга ачылгач ук, бөек остазларын тудырып үстергән җиргә, халыкка хөрмәт күрсәтү өчен агымдагы бөтен эшләрен ташлап, башкалабызга беренче булып Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Габделбари Баттал, Нигъмәт Куратларның шәкертләре — бүген инде Төркия иҗтимагый тормышында күренекле роль уйнаучы Нәвзат Карагил («Йени Баты Тракия» журналы мөхәррире), Нәвзат Төректән («Әрҗийес» журналы мөхәррире) һәм бүтәннәр аяк басты. Йөрәгендә туганлык хисләре кайнаган Нәвзәт Карагилнең төрек-татар җәмәгатьчелеге тупланган бер очрашуда ялкынланып: «Мин Казанны бөтен төрки кавемнәрнең бөек бер гыйлем мәркәзе саныйм, төркиләрне йокымсырап ятудан уяткан, аларны тәрәккъый юлына басарга өндәгән, Төркияне ныгытуга салмак өлеш керткән мәшһүр сәясәтчеләр, галимнәрнең ватанына килеп, чиксез күп рәхмәтләр илә баш ия алуымнан бәхетлемен... Моннан соң без иңгә-иң алга атларбыз, үзара ярдәмләшеп яшәрбез, сезнең асылыгызга кайтуыгызга һәммәбез ярдәм итәр. XXI гасыр төркиләр күтәрелеше гасыры булыр!» — (1991. Казан) диюе әле дә хәтеремдә.

Торгынлык елларында Төркиягә тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, журналист Асия Хәсәнева белән аның каләмдәше Хәләф Гарданов кына бара алса, хәзер яңадан-яңа иҗат эшлеклеләребез Татарстаннан Төркиягә күпер сала, халыкларыбызның төрле катламнары «Казан-Истанбул-Казан» һава юлы буйлап сәяхәт кыла. Мондый үсә барган бәйләнешләр матди һәм рухи кыйммәтләр алмашуга, дуслыгыбызны ныгытуга тансык этәргеч бирә.

## Күңелләр якынлыгы

Татарның мәгълүм фикер иясе Галимҗан Ибраһимов бер хезмәтендә: «Шулай ук безгә госманлы тәэсире дә зур булды. Кәлибули шагыйренең даһиянә язган «Мөхәммәдия»се бездә һәм шигырь һәм җыр, һәм музыка уларак гасырлар буенча җан азыгы булды. Истанбулның башка күп әсәрләре дә бездә үз итеп укылды» (26—353, 345),— ди. Ул шушы фикеренә башка хезмәтләрендә дә кат-кат әйләнеп кайта, аны тагын да тирәнәйтә һәм киңәйтә төшә. «Башка туфракта туып та, бездә үз әдәби малыбыз кабиленнән булып киткән әсәрләр(дән)... бер груһы,— «Мөхәммәдия», «Сәетбаттал» кеби,— госманлылардан керде. Болар бездә гаммәнең кыйммәтле җан азыгы — үзләшкән әсәрләре булганга, әлбәттә, шул вакытның тарихын тулы белү өчен бездә өйрәнелергә — дәреслеккә кертелергә, әдәбият тарихыбызда, кайдан килүләре әйтелеп, тикшерелергә тиешләр» (26-356),— ди.

Төрек кардәшләребез тарафыннан барлыкка китерелгән, алар үз телләренә тәрҗемә иткән әсәрләрнең Идел-Урал буенда борынгы заманнардан бирле җан азыгы булып килүе бик күп мисаллар белән раслана. Әйтик, Җәләлетдин Руми әсәрләрен халкыбыз асыл нөсхәдә укый. Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салиховлар үз иҗатларын Җ. Руми «Мәснәви»енә таянып та җәелдерә (58—69). Җ. Руми, Фөзүли иҗатларын шагыйребез Шәмсетдин Зәки дә яратып укый (55—174). Руми әсәрләре татар нәширләре тарафыннан аерым да, күмәк җыентыкларга кертеп тә, асыл телендә дә, тәрҗемәләнеп тә бастырыла (55—252).

Гашыйк пашаның «Гарибнамә» поэмасы (1330) Идел буенча аеруча киң таралган. Энциклопедик эчтәлектәге күренекле бу әсәр Җ. Руминың «Мәснә-

ви»енә ияреп язылган. Шунысы игътибарга лаек: аның әлегә кадәр мәгълүм 25 кульязмасыннан уникесе татар хаттатлары тарафыннан күчереп язылган, Төркиядә табылган нөсхәләре 12 мең юллы булса, Казандагы ике нөсхәдә 16 мең юл теркәлгән (54—461,462).

Төрек шагыйре Әхмәт Гирмиянинең (1329—1412) «Йосыф вә Зөләйха» поэмасының хәзергә билгеле бердәнбер кульязма нөсхәсе Татарстанда саклангaн (54—544). Кастамунилы Шади 1359 елда Гали хәлифә улы Хөсәен каһарманлыкларын сурәтләгән дастан язган, ул 1713 елда бездә — Идел буенда күчерелгән (58—64, 65). Сөләйман Чәләби (1422 дә вафат) Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышы, тууы һәм соңгы сәгатьләре турында безнең укучыларга да җиңел аңлаешлы «Мәүләден-нәби» поэмасын иҗат итә һәм ул Идел-Уралда сөеп укыла торган әсәрләрнең берсенә әйләнә. Г. Ибраһимов югары бәяләгән («даһиянә»!) «Мөхәммәдия» поэмасы Мөхәммәт Чәләби (1451 дә вафат) тарафыннан язылган. Бу әсәр 1845 елда Казанда беренче мәртәбә басылып чыга һәм тиз арада укучылар арасында зур мәхәббәт казана (54—35). Татар укучысы аны үз хәзинәсе итеп кабул итә. Борынгы әдәбиятыбыз белгече Марсель Әхмәтҗанов миңа бу әсәрнең Төркиядә хәтта мәгълүм дә түгеллеген, Каюм Насыйриның исә «Календаре»нда М. Чәләбине татар дип раславын хәбәр итте.

Мөхәммәт Чәләбинең энесе Әхмәт Бижан Язычы углының «Әнварел-гашыйкыйн» (1450—1460) әсәрен дә татарлар яратып укый — ул да халкыбыз арасында киң таралган (54—545). Шул ук Марсель Әхмәтҗанов раслаганча, Әүлия Чәләбинең «Җиһаннамә»сен Шиһаб Мәрҗани һәм бүтән укымышлыларыбыз әйбәт белгән.

Билгеле ки, Болгар һәм Казан ханлыклары дәүләт архивлары, күп кенә сәнгать әсәрләребез илбасарлар тарафыннан рәхимсез төстә юк ителгән, алардан берән-сәрән ярлыклар, кульязмалар, әйберләр генә исән калган. Шундыйлардан Казан ханлыгына нигез салучы (1437) Олуг Мөхәммәт ханның 1428 елда язылган бер фәрманы Истанбулның Тупкапы сараена килеп эләгеп, сакланып килә (54—544). XVI йөз урталарында Казанда яшәгән шагыйрь Мөхәммәтшәриф төрек солтаннарының берсе тәкъдиме буенча әсәр язган — хәзер ул да Истанбулда саклана (54—546).

Төрек-әзербайҗан шагыйре М. Фөзүли (1494—1556) шигырьләре дә бездә киң тарала. Аның традицияләрен XIX йөз татар әдәбиятында Ш. Зәки дәвам иттерә (56—527). Шунысы кызык, М. Лермонтовның «Пәйгамбәр» шигырен урысчадан тәрҗемә иткәндә (XX йөз башы), Г. Тукай аны Фөзүли рухындарак эшкәртә (56—530).

Татар шагыйре Утыз Имәни (1754—1834) иҗатына Җ. Руми һәм Гашыйк паша әсәрләре тәэсирен тоярга мөмкин (54—468). Бу шифалы йогынты аннан соң да дәвам итә, әйтик, күренекле шагыйребез Сәгыйть Рәмиев (1880—1926) Руми әсәрләрен асыл нөсхәдә укый, байтагын ятлап та ала (56—182).

Татар шагыйрьләре Өмми Камал иҗатын да яхшы белгән. Бу Мәүлә Колыйдан (XVII йөз) Дәрдемәндкәчә (1859—1921) каләм осталарыбыз иҗатында ачык сизелә. XVIII йөздә «Вакты сәхәр китабы» Ө. Камал шигыре формасында язылa, ул Тукайга да таныш була.

Ө. Камалның кайбер шигырьләре исә татар шагыйре Хөсам Кятибнең (XIV йөз) «Җөмҗөмә солтан»ын искә төшерә. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки, алдарак язганыбызча, Ө. Камал Идел буена килеп, ата-бабаларыбыз арасында яши. Шунлыктан, аның аерым әсәрләре туган телебезгә бик якын һәм җиңел аңлаешлы. Аның Идел буе язма әдәбияты белән танышуы да табигый. Мөхәммәт Гали (1893—1952) Ө. Камал хакында: «Татарның борынгы һәм соңрак чор шигъриятендә үзенең эзен дә калдырганлыгы бик ачык» («Совет әдәбияты», 1941, № 5, 61 б.),— дип яза.

Борынгы төрек әдәбияты Идел буенда шулкадәр киң тарала ки, әдәбият галимебез Җамал Вәлиди 1912 елда: «Шүрлегендә йә мич кашында... Сәетбаттал булмаган татар өе сирәктер» (10),— дип белдерә.

Шул ук вакытта Идел буеның бик күп борынгы әсәрләрне саклап калуын да әйтеп китү зарур. Әхмәт Ясәви (1166 да вафат), Сөләйман Бакырганый (1186 да вафат) шигърияте татарлар арасында сакланып, бүтән төркиләргә Идел буеннан кабат тарала (55—39).

Әдәби бәйләнешләребезне нығытуда төрек теленә тәрҗемә ителгән бүтән халыклар мирасы да әһәмиятле урын тота. Әйтик, төрек шагыйре Суди XVI йөздә Хафизның «Диван»ын тәрҗемә итә, Сәгъдинең «Гөлестан»ына аңлатмалар яза — болар Идел буенда да игътибар казана (54—462).

Сәгъди Ширазиның «Гөлестан»ын (1258) Сәйф Сараи 1391 елда фарсычадан төрки-татарчага тәрҗемәли һәм аны «Гөлестан бит-төрки» исемендә укучыларга тәкъдим итә (44—37). Дөнья классик әдәбиятының иң күренекле әсәрләреннән исәпләнгән Сәгъди «Гөлестан»ы күп төрки телләргә, шул исәптән, госманлычага да берничә тапкыр тәрҗемә ителә. Шуның белән бергә, госманлылар С. Сараи тәрҗемәсен дә укый. Аның «Гөлестан бит-төрки»е турында төрек галимнәреннән Рагиб Холуси, Фуат Күпрүлезадә мәгълүматлар бирә, соңгысы аның хакында: «XVI гасырда кыпчак телендә әдәби нәсернең моннан да гүзәл үрнәге булмас» (44—6),— дип бәя бирә. Профессор Фәридун Нәфис Үзлүк 1954 елда С. Сараи кульъязмасын (факсимиле) Анкарада бастырып чыгара, китапка кереш сүз яза. Алтын Урда әдипләре, галимнәре хакында мәгълүмат бирә.

Заһир Бигиев (1870—1902) француз романнарын төрекчә тәрҗемәдә укый, әсәрләрен француз һәм төрек романнары тәэсирендә иҗат итә (17—66). Француз язучылары әсәрләре белән шагыйребез Нәҗип Думавый (1883—1933) төрек телендә таныша (56—532, 533).

XX йөз башында татар әдәбиятының башка төрки әдәбиятлар белән бәйләнешы тагын да тирәнәя. Бу очракта төрек әдәбиятына мөнәсәбәт, аның тәҗрибәсен үзләштерү алгырак сафка чыга. XIX йөз ахырында — XX йөз башында иҗат иткән язучыларыбызның байтагы төрек вакытлы матбугатын даими күзәтеп бара, төрек әдәбияты-сәнгатеннән яхшы хәбәрдар яши. Нәҗип Гасрый язганча, сәүдәгәрләребез Истанбулдан төрек китапларын алып кайтып сата — бу җәдитчелек килеп чыгуга да мөһим этәргеч һәм җирлек бирә (17—65). Татарда яңа әдәби жанрлар белән танышу төрек һәм урыс әдәбиятлары тәэсирендә башлануын профессор Габдрахман Сәгъди (1889—1956) дә күрсәтеп уза (50—76). Татар мәдрәсәләренә һәм матбугат редакцияләренә Төркиядән китаплар, гәзит-журналлар алдыру (66—34, 54) да танышлыкның тирәнәюенә уңай йогынты ясый.

Г. Ибраһимов безгә чыгтай (борынгы үзбәк) әдәбияты тәэсирен телгә алганнан соң: «Икенче яктан, хаҗилар Истанбулдан, Анадулыдан кайбер китаплар китерделәр. «Мөхәммәдия»ләр бездә үз җәүһәребез кебек урын алды. Менә шул ике — чыгтай һәм госманлы — тәэсире астында татарның борынгы әдәбияты яшәде, акрынлап үсте, эчтәлекне генә түгел, әдәбилекне дә, стильне, атаманы да шул тәэсир астында ясады» (27—217),— ди. Аннары шуңа мисал итеп Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» романын китерә һәм «Акъегетнең хикәясендә госманлык эзе юк түгел» (27—223),— дип белдерә.

Татар реалистик прозасы һәм драматургиясенә нигез салучы классигыбыз Гаяз Исхакый (1878—1954) 1897 елда төрек әдәбиятына ихлас бирә башлый (28). Ул кардәш халык язучыларының күп кенә хикәяләре, романнары, пьесалары белән таныша, Нәмикъ Кәмал, Әхмәт Мидхәт әсәрләрен аеруча ярата (29—637, 642).

Төрек әдәбияты күренекле язучыбыз Шәриф Камал (1884—1942) зәвыге калыплашуда да әһәмиятле урын тота. Европадагыча новелла жанрына нигез салган каләмдәше Халит Зыя Ушаклыгил иҗаты аңа аеруча якын була (56—531).

Шулай да, татар-төрек әдәби бәйләнешләрына мисал эзләгәндә Галиәсгар Камал (1878—1933), Фатыйх Әмирхан (1886—1926), Галимҗан Ибраһимов (1887—1938), Габдулла Тукай (1886—1913) исемнәрен телгә алу урынлырак. Аларның һәммәсе урыс әдәбияты белән танышуга да зур әһәмият бирә, әмма яшьлекләрендә иң күп укыганнары — төрек әдәбияты һәм матбугаты була.

Бу хәл төрек теленең аңлаешлырак булуына гына бәйләнмәгән. XIX йөз ахырында татарлар һәм төрекләр алдында мәгариф һәм мәдәнияттә һәм, гомумән, рухи тормышта бер үк бурычлар тора: фикердә һәм гамәлдә урта гасырлар торгынлыгыннан котылу, ислам динен, яшәеш фәлсәфәсен искергән төшенчәләрдән арындыру, дөньяви белем алу һәм кәсеп итүдә Аурупаның алдынгы халыкларына ияру.

Патша Русиясе бу яңарыш хәрәкәтенә даими аяк чалып торганлыктан, татарларның әлеге омтылышы XIX йөз ахырында да киң җәелеп китә алмый. Сәяси бәйсезлеген югалтмаган Төркиядә исә, иҗтимагый шартлар ничек кенә караңгы һәм кысынкы булмасын, дәүләтчелекне саклау ихтыяҗы Икенче Габделхәмит солтанны кайбер яңалыкларга юл ачарга мәҗбүр итә. Ул тәхеттә утырган дәвернең ахырларында, мәсәлән, илдә 36 мең мәктәп, шул исәптән, урта һәм югары уку йортлары да эшли. Хокук, мөлкия, малчылык-ветеренария, сәүдә, инженерлык махсус гали мәктәпләре ачыла, Хәрби-медицина, Галатасарай лицейләрендә укучылар саны арттырыла (21—188). 1876—1890 елларда төрек телендә 4 мең китап (елына — 260 ар), шул исәптән, бер мең әдәби әсәр, 500 дәреслек, бер мең фәнни һәм фәнни-популяр басмалар нәшер ителә (21—191).

1870 еллар ахырынача төрек теленә унлап роман һәм Мольерның кайбер пьесалары тәрҗемәләнә. 1880—1890 елларда Аурупа язучылары әсәрләрен төрекчәләштерү кискен арта. Һомер, Шекспир, Мольер, Бальзак, Гюго, Флобер, Золя, Байрон, Гете, Шиллер әсәрләре төрек укучысына тәкъдим ителә, аталы-уллы Дюмалар, Ж. Верн романнары аеруча киң таратыла, француз әдәбиятын бастыру тәрҗемәләр арасында беренче урынга чыга (21—204, 205), 1889-1890 елларда гына да алар саны 76 га җитә, әсәрләрне төрекчәләштерүдә язучылардан Әхмәт Мидхәт, Шәмсетдин Сами бәй, Әхмәт Рәсим, Хөсәен Рәхмиләр дә катнаша (21—206). Бу эш аларга, әлбәттә, әдәби осталык мәктәбе дә була. Фәнни-популяр китаплар арасында Б. Фуатның «Вольтер», Сәетбәй белән Р. Рәсимнең «Төрле халыклар гореф-гадәте», Ә. Рәсимнең «Гарәп мәдәнияте тәрәккыйсе» һәм башка хезмәтләр дә басыла. 1882 елдан нәшер ителә башлаган «Мәшһүр кешеләр көтепханәсе» сериясендә Әбугалисина, Наполеон, Галилей, Гутенберг, Эзоп, Һарун әр-Рәшит һәм бүтәннәр хакында китаплар чыгарыла (21—207). Бу китапларның байтагы Идел-Урал буена да килеп җитә. Үз алдына Төркияне яңарту бурычын куйган «Сәрвәтефөнүн» (1891 дә нигезләнә) фәнни-популяр журналы, 1896 елда Тәүфикъ Фикрәт баш мөхәррир булып килгәч, заманы өчен бик зур тиражда — 4000 нөсхәдә тарала башлый. 1884 елда Халит Зыя Ушаклыгил Измир шәһәрендә төрек басмачылыгына нигез сала. 1879—1907 елларда Төркиядән тышта — Париж, Женева, Лондон, Каһирәләрдә хөр рухлы 120 ләп гәзит нәшер ителә (21). Менә шушы шартларда төрек әдәбияты зур җанланыш кичерә. Әхмәт Мидхәт ялгызы гына да 1876—1890 елларда 140 исемдә китап, брошюра чыгара, алар арасында 68 роман (29 тәрҗемә), 51 фәнни, фәнни-популяр очерк, 6 пьеса, 7 гәзит-журнал да исәпләнә. Ә. Мидхәткә «язу машинасы» исеме тагыла! XIX йөздә төрек язучылары 75 роман бастырып чыгарса (7—261, 262, 263), бер 1910 елда гына да инде аларның саны унбергә җитә (7—263). Нәмикъ Кәмалның «Госманлы империясе тарихы», Әхмәт Рәфикънең «Фазләкәи (кыскача — Т. Ә.) тарихы госмания» кебек дәреслекләре төрекләрнең данлы үткәнен сурәтләп игътибар казана.

Заманы өчен шактый күп саналган шушы хәзинәнең зур гына өлеше татар укучысына да тәкъдим ителә. Г. Камалның «Мәгариф» кибете өчен Төркиядән бик күп китап алып кайтуы хакында алдарак язып үтелде. Монда тагын шуны искәртәсе килә: Г. Камал беренче нәүбәттә — язучы, фикер иясе; иң кайнар теләге — бай эчтәлекле, гыйбрәтле әсәрләрне мөмкин кадәр күбрәк укытып, туган халкын тәрәккый иттерү. Шуңа күрә ул алып кайткан хәзинәсен иптәшләре һәм дусларына гына түгел, киң гаммәгә таныту чарасын да күрә башлый. Мисалга, «Йолдыз» гәзитендә (1909, № 369) төрек галиме Мәхмүт Әсгатьнең «Тарихы ислам» китабын мактап яза. «Лисаны төрекчәдәр. Һәр ни кадәр мөхәррире госманлы исә дә, лисаны төрекчәнең бик җиңелләреннәндер, рөшди мәктәпләрдә укытыр өчен яхшы бер әсәрдер» (32—187),— ди. Бу язмадан аңлашылганча, Казанның «Милләт» матбагасы әлеге әсәрне асыл нөсхәсендәгечә 1908 елда бастырып чыгарган. Бу дәвердә ашыгыч кирәк тоелгән төрекчә әсәрләрне татар укучысына тизрәк җиткерү максатында тәрҗемәсез бастыру гамәлгә кергән була.

Кәрим Әмири раслаганча, Г. Камал мәдрәсә шәкерте чагында ук төрек әдәбиятын, матбугатын уку белән мавыгып китә (15—133). Ул төрекчә шулкадәр күп укыган ки, әсәрнең исеме һәм авторы әйтелмәсә дә, бераз караштыру белән аның кемнеке һәм нинди әсәр икәнлеген чамалар хәлгә җиткән. Мәсәлән, «милли роман» дип басылган «Мәшъүм чифтлек» («Явызлыкның җәзасы») әсәренең төрекчәгә тәрҗемә ителгән бер француз әдибе хикәясе икәнлеген ачыклаган (32—192, 193).

Г. Камал шәкерт чагында ук, ата-анасыннан качып-посып, урыс театрына йөри башлый. Шул елларда ул төрекчә сәхнә әсәрләре белән дә таныша. Моны ул үзе болай искә ала: «Арадан Нәмикъ Кәмалның таш басмада язылып басылган «Зәваллы чуҗык» дигән драмасы килеп чыга. Нинди зур байлык! Җитмәсә, мин инде төрекчә дә бераз сукалый башладым. Аны, кат-кат укып, аңлыйм... Н. Кәмалның китабы мине кузгатып җибәрә дә, мин үзем уйлап йөргән «Бәхетсез егет» дигән нәрсәмнең беренче редакциясен язып, укытучыма... күрсәтәм» (32—306).

Г. Камал күңелен биләгән «Зәваллы чужык»ны 1899 елда татарчага тәрҗемәли һәм ул «Кызганыч бала» исемендә татар сәхнәсенә күтәрелә.

Беренче татар профессиональ театры 1906 елның декабрендә Казанда «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе» пьесаларын уйнап дөньяга килә. «Гыйшык бәласе» дә — Нәмикъ Кәмал әсәре («Мәхәббәт мажаралары»), аны төрекчәдән Габдрахман Кәрәм тәрҗемә итә (18—276). Менә шушы вакыйга гына да татар

театрын барлыкка китерүдә госманлы төрекләре нинди әһәмиятле урын тотуын ачык күрсәтә. Татар драматургиясенең ике алтын баганасы — Г. Камал белән Г. Исхакый нәкъ менә төрек сәхнә әсәрләре белән танышып, әүвәлге сәхнә мәктәбен уза. Төрек телендә француз һәм бүтән чит ил пьесаларын уку, Истанбулда театр уеннарын тамаша кылу аларның сәхнә сәнгатенә мәхәббәтен тагын да үстерә, зәвыкъләрен күтәрә, иҗади дәртләрен көчәйтә. Казанда урысча спектакльләргә йөрү, анда куелган асыл һәм тәрҗемә әсәрләр белән танышу инде яхшы ук нык тамырланган белем һәм тәҗрибәне тагын да тирәнәйтү һәм баету өчен өстәмә этәргеч кенә бирә. Моңа Г. Камал иҗаты белән кинрәк танышкан саен ныграк ышанасың.

Г. Камал Истанбулга икенче мәртәбә баруында (1912—1913) төрек театрын янә тамаша кылырга тели, ләкин Балкан сугышы җәелгән заманда Истанбулда спектакльләр уйналмый тора. Сәяхәтчебез шуннан соң: «Китап базарында булган төрекчә театр әсәрләренең һәммәсен дә җыйдым. Казанга кайтканнан соң... ул китапларны берәм-берәм укып чыктым... «Дөхтәре һинд», «Әшбәр», «Тәзәр» исемендәге әсәрләр илә «Пенти Хәмит» дигән бер пьеса гына күзгә төшәрлек иде» (32—274),— ди. Г. Камал бер төрек драматургының «Пенти Хәмит»ен тәрҗемәли — ул Мольерның «Саран»ы булып чыга!

Г. Камал озын иҗат гомерендә туган теленә 100 ләп әсәр тәрҗемә итә, алар арасында төрек драматургиясе иң абруйлы урынны били, мисалга, Нәмикъ Кәмалның «Ватан яхут Силистра», Габделхак Хәмитнең (1852—1937) «Һинд кызы» татар сәхнәсендә озак еллар уңышлы уйнала. Мондый бәхетле язмыш Н. Кәмалның «Кызганыч бала»сына да насыйп була (15—178).

Г. Камалның төрек әдәбиятына мәхәббәте революциядән соң да юкка чыкмый, аның төрекчәдән тәрҗемә итеп язган «Шәркъ гыйшкы» пьесасы 1923 елда сәхнәгә куела (15—107).

Г. Камалның иҗади үсешендә һәм житлегүендә төрек драматурглары, аерым алганда, Нәмикъ Кәмал, Габделхак Хәмитләрнең шифалы тәэсире бәхәссез. Аларның беренчесе — гарәп, фарсы телләрен белүдән тыш, французчаны да яхшы үзләштергән укымышлы, алдынгы карашлы әдип, шагыйрь, тәнкыйтьче, тәрҗемәче һәм публицист та. Икенчесе — инглиз, француз, фарсы телләрен яхшы белүче укымышлы дипломат, шагыйрь, драма әсәрләрендә (31 пьеса авторы) колонизаторларга, тираниягә каршы нәфрәт, ирек һәм тигезлеккә сусау, фәкыйрьләргә шәфкать тулы. Мондый затларның Г. Камалга йогынтысы хасиятләрен ачу — киләчәк эш. Шул ук вакытта «татар театрының атасы» саналган Галиәсгар Камалның бик тиз аякка басуы, өлкән каләмдәшләре тәҗрибәсен иҗади өйрәнүе, таләпчән анализлавы, язучылык эшендә татар тормышына, милли гореф-гадәтләребезгә, үз әдәби традицияләребезгә нык таянуы аркасында, халыкчан телдә чын милли сәхнә әсәрләребезне тудыруы хак. Моңа «Төрек сүзе» (1914, № 10) газите дә игътибар итә: «Шималь төрекләре — татарлар... яңа пьесаларының юклыгына шикаять итәләр. Хәлбуки, шималь төрекләренең Галиәсгар Камал кеби халык әдипләренең халык телендә язылмыш берничә пьесалары Истанбул теле белән язылып, Төркиядә сәхнәгә куелса, йөз мәртәбә уйналса биләә ялыктырмаслар иде» (31—389),— ди.

А. Н. Островский, М. Горький, Мольер һәм бүтән күренекле драматурглар иҗатын яратып өйрәнсә дә, Г. Камал башлыча иҗтимагый хәятебез охшашлыгына бәйле рәвештәме, кабат-кабат Төркия мәдәни тормышына тартыла. 1912 елда ул «Йолдыз» (1912.XII.23) газитендә «Мәрхүм Әхмәт Мидхәт әфәнде» дигән мәкаләсен бастыра. Монда ул төрек әдәбиятында роман һәм новелла жанрларына нигез салучы әдип, тарих, дин, фәлсәфә, география һәм башка гыйлемнәргә багышлап күп кенә китаплар язган галим, мәгърифәтче турында вафаты уңаеннан мәгълүмат бирә, аны «бөтен ислам галәменең иң зур мөхәррир вә әдипләреннән һәм дә философларыннан» дип югары бәяли, төрек җәмгыятенең шундый бөек бер асыл затын тиешенчә хөрмәтли алмавына ачына. Шушы мәкаләсендә ул «гүзәл сүз остасы, киң мәгълүмат иясе, мөгаллим» Исмәгыйль Хаккыйны да зур ихтирам белән телгә ала, Ә. Мидхәт белән И. Хаккыйны — ике бөек төрек эшлеклесен соңгы юлга озатуда җәмәгатьчелекнең бик-бик аз катнашуына уфтана (32—270, 271).

Бу хәл, бер яктан, артык гаҗәп тә түгел. Чөнки солтан Икенче Габделхәмит заманында И. Шинасиның (1826—1971) «Шагыйрьнең өйләнүе», Нәмикъ Кәмалның «Гөлнихәл», «Кызганыч бала», «Ватан яхут Силистра», Габделхак Хәмитнең «Нәстәрин» («Кыр чәчәге») һәм башка әсәрләре, Тәүфикъ Фикрәт шигырьләре ватаннарында тыела һәм озак вакыт нәшер ителми (21—202). Төрек халкын хөрриятктә чыгару, аның тормышын җиңеләйтү, Төркияне демократик рухта

үзгәртеп кору тарафдарларына бәйсез илләрендә яшәү һәм якты максатларына ирешү өчен көрәшү бер дә җиңел булмый. Шуңа күрә «халыклар төрмәсе» Русиядә җәфа чиккән татар халкының алдынгы уллары һәм кызлары югарыда саналган төрек зыялыларын фикердәшләре, көрәштәшләре итеп күрә, алардан гыйбрәт алу, өйрәнү генә түгел, аларга терәк һәм ярдәмче булырга да тырыша.

Яңа төрек әдәбиятын яхшы белгән язучыларыбызның берсе Галимҗан Ибраһимов була. Ул Ибраһим Шинаси иҗатын, Тәүфикъ Фикрәт романтизмын күңеленә якын итә, Әхмәт Мидхәтнең мажаралы әсәрләрен кызыксынып укый. 1913 елда Ф. Кәримгә язган хатында Габделхак Хәмитнең әдәби куәтенә хәйран калуын белдерә («Совет әдәбияты», 1963, № 1. 108 б.). Нәмикъ Кәмал, Әхмәт Рәсим кебек мәгърифәтче язучыларның әсәрләре, төрек галимнәренең әдәбиятка багышланган тикшеренүләре дә Г. Ибраһимовның игътибарын казана (56—531, 532).

«Төрек әдәбияты дип мотлак итеп әйтелсә дә,— ди Г. Ибраһимов,— Әхмәт Мидхәт әфәнденең фән һәм дингә карата... башкалар белән бәхәскә кереп язылган әсәрләре, Мәхмүт Әсгать вә Исмәгыйль Хаккыйларның дини фәлсәфәгә баглы язган әсәрләре түгел, бәлки Ә. Мидхәтнең «Хөсәен Фәллах», «Хөсәен Мәлләх» вә таныштырулары, Фөзүли, Синан паша, Гошшакыйзадә, Хәлит Зыя, Әхмәт Рәсим, Тәүфикъ Фикрәт, Хикмәт бәк вә саир әдип вә шагыйрьләрнең шигъри вә әдәби әсәрләре зиһенгә хозур итә вә шулар күздә тотыладыр» (26—21).

Икенче бер әсәрендә Г. Ибраһимов госманлы әдәбияты дигәндә Нәфгый Әкрам Кәмал, Хәмди Әмин бәк, Шинасилар күз алдына килүен дә искәртә (26—226).

Г. Ибраһимов үз хезмәтләрен язганда Тәүфикъ Риза белән Хөсәен Данишларның «Робагыять Гомәр Хәйям» китабын файдалана (26—431). Солтан Габделхәмит, Әхмәт Мидхәт исемнәре аның «Безнең көннәр» романына да килеп керә (25—452). «Яшь йөрәкләр» романы каһарманы укымышлы Мәрьямнең китап киштәсендә Әхмәт Рәсим (1867-1932), Нәмикъ Кәмал (1840—1883) кебек төрек язучыларының гыйшык романнары тезелеп тора (24—110). Мәрьям кызлар мәктәбендә Төркиядә укып кайткан мөгаллимнәрдән сабак ала (24—105). Халит Зыяның (1866-1945) «Халидә» романын укыса — Халидә, «Фәрди вә Шөрәкя»сен укыса, үзен һаҗәр итеп күрә, ләкин бәхетсезлеккә очрамый (24—104).

Г. Ибраһимов — реалист язучы. Әгәр татар тормышы төрекләрнеке белән бергә үрелмәсә, ул һич тә Мәрьям кебек каһарманнарны сурәтләмәс иде. Димәк, XIX йөз ахыры — XX йөз башында татар-төрек бәйләнешләре әдәбиятыбыз һәм сәнгатебездә, мәгарифебездә бер кан әйләнеше системасы тәшкил итә. Г. Ибраһимов шуңа ишарә ясагандай: «Фатыйх Кәрими кебек кайбер мөхәррирләр... Тукай кебек шагыйрьләр... байтак вакытлар... ярым госманлы тәэсирендә бардылар» (27—225),— ди.

Әлбәттә, госманлы тәэсире татар язучыларына бердәй тимәгән, әмма XIX йөз ахыры — XX йөз башында ул йогынтыны теге яки бу дәрәҗәдә татымаган укымышлыларыбыз, мөгаен, булмагандыр. Бу хәл мәдрәсәләребездә Төркиядә басылган дәреслекләр, әдәби, дини, фәнни китапларның күп кулланыла башлавы нәтиҗәсендә дә киң таралгандыр (Габдулла Бубый. «Бубый мәдрәсәсе тарихы». Кульязма. КДУ фәнни китапханәсе. 207 т.). Әнә шулай төрек дөньясы күренекле язучыбыз Фатыйх Әмирхан иҗатына да килеп керә. Аның «Картайдым» (1909) хикәясе каһарманы Әхмәт Мидхәт эшчәнлеген белә, аңа охшарга теләп, фәс кия һәм миссионерларга каршы көрәшкә күтәрелә (77—44). «Татар кызы» (1909) хикәясендә Истанбул, Айя-Суфия мәчете телгә алына (77—56). «Милләт тәрәкъкый иттерү» (1908) хикәясендә яңа фикерле Хөсәен шәкерт «Гәнеҗ төрекләр» хәрәкәтеннән хәбәрдарлыгын күрсәтә (77—37). Фәтхулла хәзрәт (Шул исемдәге әсәр. 1909). Сәетбаттал Газый сыманрак итеп... тавыш чыгара (78—76). Зәйнәп Әминева раславынча, Фатыйх Әмирхан Әхмәт Мидхәт эшчәнлеге белән үзе дә бик кызыксынган (70—73), аны 1910 елда «милләткә хезмәт итүче китапчы һәм педагог» әсәрендә дә телгә ала (79—174).

Ф. Әмирхан татар укучылары игътибарын төрек мәдәниятенә, Төркиягә җәлеп итәр өчен даими тырыша. Мисалга «Әл-ислах» гәзитендә (21.VII.1909) урысча чыгарылган «Турецкий сборник» җыентыгына рецензия бастыра, анда Төркия хәлләре белән танышу өчен бу җыентыкның файдалы булуын белдерә, әмма андагы «Төркиянең артта калуына ислам дине сәбәпче» дигән фикер белән килешмәвен искәртә (80—101, 102).

Ф. Әмирхан «Тәрбиятел әтфаль» (1907, № 1) журналында «Истанбул шәһәре» дигән мәкаләсен урнаштыра. «Истанбул шәһәренең һавасы йомшак вә жылы-

дыр, халкы бер миллионнан артыграк вә яртыдан күбрәге — терекләрдер... 670 тән артык мәсжед, 560 һәртөрле мәктәп вә 146 мәдрәсәи руханиясе бардыр... 40 ка якын гәзитә вә журналлар чыгадыр» (79—26, 27),— ди ул анда. Язучы икенче бер мәкаләсендә («Йолдыз», 5.X.1910) Казанга Х. Хилми паша килү хәбәренә бер төзәтмә кертә (80—110, 111), «Төрек милләтчелеге һәм Русия советлар власте» мәкаләсендә («Кызыл Армия», 22.VI.1920) Мостафа Кәмал житәкчелегендәге Төркиянең Советлар Русиясе белән хезмәттәшлеген хуплый. Русия белән Госманлы империяләре мөнәсәбәтенә анализ ясап, Беренче Дөнья сугышының Төркияне бүлү максатында алып барылуын, Русиядәге революциянең тарихи дошманлыкка чик куюын, төрек милләтенең бәйсезлек көрәшенә ярдәмгә килүен аңлата (78—386, 387), Русия революциясенең Төркиягә йогу хәвефе юклыгын, чөнки анда әле капиталистлар-буржуйлар барлыкка килергә өлгермәвен, Төркиянең чын байлыгы чит ил һәм төрек булмаган буржуйлар кулында туплануын, ул байлык мәмләкәт кулына күчсә, бөтен терекләргә дә яхшы гына булачагын фараз итә (79—390, 391).

Татар-төрек багланышларының якты бер сәхифәсе Габдулла Тукай исеменә бәйләнгән. Ул Уральскийның «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкерте дәверендә үк төрек китаплары укырга керешә. Төркиядән куылган Галделвәли Әмрулланың шушы шәһәргә килүе Тукайның госманлы матбугаты һәм әдәбияты белән кызыксынуын тагын да дөрләтеп җибәрә. Замандашлары: «Габдулла гарәп, фарсы һәм төрек телләрен бик яхшы белә иде (66—51),— дип хәбәр итә.— Бер төрек шәкерте Габделвәли белән бик дус булды. Төннәр буе бер бүлмәдә сөйләшәләр, бәхәсләшәләр иде. Тукай аннан күп мәгълүмат алды булса кирәк... Габделвәлинең шагыйрь булуын, Габдулланың аннан төрек телен өйрәнүен» бүтән шәкертләр дә белеп тора (66—49).

Әнә шул дәвердә үк Тукай Нәмикъ Кәмал, Габделхак Хәмит, Габделхәмит Зыя паша, Тәүфикъ Фикрәт, Халит Зыя, Габдулла Җәүдәтләр иҗаты белән таныша һәм аларны югары бәяли, байтак шигырьләрен ятлап та ала (56—531). Иптәшләре искәртүенчә, мәдрәсә сабакларыннан бушаган чакларда ул ишекле-түрле йөри-йөри көйләп «Мөхәммәдия» укырга ярата (66—60). Вафа Бәхтияров хәтерләвенчә, Тукай төрек басмаларыннан «Җөмһүрият» (Париж), «Төрек» (Каһирә) гәзитләрен, «Төрек йорты» (Истанбул) журналын укый. Сатирик журналлардан «Мулла Насретдин» (Тбилиси) һәм «Кара гүз» (Истанбул) белән танышып бара. Тукайның сатирик сәләте ачылуга һәм үсүгә, шомаруга, тирәнәюгә бу ике журналның йогынтысы зур булды дип аңларга тиешбез» (66—79).

Г. Тукай Н. Кәмалның «Гыйшык бәласы» пьесасын Уральскида Г. Кариев, К. Мотыйгыйлар белән бергә уйнарга әзерләнә, репетицияләр ясый (66—59, 60). Н. Кәмалның «Ватан яхут Силистра» трагедиясен тәрҗемә итәргә керешә (66—79).

Тукай Казанның «Болгар» кунакханәсендә яшәгәндә, аның тәрәзә төбендәге китаплары арасында, Пушкин вә Лермонтов мәжмугаләре белән бергә, Габделхак Хәмитнең «Дәхтәре һиндү» («һинд кызы») җыентыгы ята (66—77).

Шәһер Шәрәф Тукай турында: «Миннән төрек әдипләренең байтак китапларын алып укыды,— ди.— «Госманлы әдәбияты нәмүнәләре» исемле басманы укыгач, «бу китапта моңа яраплык нәрсәләр дә бар икән»,— дигән иде... Габделхак Хәмитнең берничә әсәрен алып укыгач, аның фикерләренең ачыклыгын, шигырьләренең дә садә вә шигърияте куәтле булганын яратып сөйләде. Фәкать аның «Нәстәрин» («Кыр чәчәге») исемле әсәре белән танышкач кына «шундаен куәтле мәхәббәт берлән куәтле дошманлыкның бер күңелгә җыелуына минем хыялым җитми, Габделхак Хәмит тасвирларын башыма сыйдыра алмыйм»,— дип сөйләгән иде» (77—104).

Тора-бара Тукай Госманлы империясенең әдәбиятын гына түгел, аның тарихын, сәясәтен, эчке һәм тышкы көрәшләрен бик яхшы күзаллауга ирешә. Төрек дөньясын вакытлы матбугаты һәм китаплары, анда булып кайткан кешеләрнең сөйләүләре аша яхшы белгәнлектән, аны иҗатында татар һәм бөтен Русия чынбарлыгы белән янәшә чагылдыра. Ул да бердәнбер бәйсез төрки дәүләтне хөр, төрек халкын иркен тормышлы, зирәк аңлы, бәхетле итеп күрергә тели, ләкин чынлыкта аның күршеләреннән һәм алдынгы Аурупа илләреннән артта калуын күреп борчыла. Әмма: «И төрек, иң әүвәл үк әйтим сиңа — борының кылыч: Гыйльмилә хикмәт базарында синең урының кылыч» (62—175),— дип, кылыч борынлы Ибраһим Шинасый, Нәмикъ Кәмалларны искә төшерә, әле яхшы үзгәрешләр буласына өмет баглый. Төрек җәмгыятендәге томаналыкны, солтан «Габделхәмит исемле аюлар» (63—244) башбаштаклыгын, золымны камчылый, сатира уты белән көйдерә. Ул яраткан, фикердәш санаган төрек язучыла-

рыннан Нәмикъ Кәмал сөргенгә сөрелә, Габделхак Хәмит җәберләнә, Халит Зыя гаепләнә, аларның әсәрләре Казанга Төркиядән түгел, Көнбатыш Аурупадан, мөһаҗир төрек басмаларыннан килеп ирешә (21—186, 187; 63—214).

Италия-Төркия сугышы башлану сәбәбен мыскыл итеп, «былтыр, өенә карак кергәндә, хатыны белән сугышкан авыл мужигы кебек, Төркия зыялылары, Италия Траблисны талап ятканда, үзара җәнҗал вә скандал белән миләрен черетteләр» (64—232),— дип ачына шагыйрь.

«Мин шушылар илә милләтче» (1908), дигән юморескасында Тукай: «Тәмәкенең дә «Госманлы сигарасы» исемлесен махсус Истанбулдан алдырам» (64—76),— дип шаярткан була. Шул вакытта «Балкан көйләре» (1912) язмасында житди рәвештә төрекләрне данларга омтыла (62—257). Шагыйрь «Тәмсил» (1911) шигырендә дә Алмания, Австро-Венгрия, Италияне мыскыл итә, Төркияне исә читләтеп яклый (62—193). «Ялт-йолт» (1912, № 44) журналында мыскыллы рәсем астына Тукай Балкан хәлләрен үзенчә гәүдәләндергән ике юллык шигырь урнаштыра:

«Курыкмыймын, селкенми хәтта фәс чугым,
Мә, кирәксә, дүртенә дүрт йозрыгым» (62—213).

Әмма зәгыйфьләнгән Госманлы империясе шагыйрьнең өметен акламый. Шуннан соң Тукай Балкан сугышындагы төрекнең көчсезлеген мәзәк рәвешендә тасвирлый (64—252, 253) «Төркия — хәстә кеше, ул авырый» (64—246),— дип белдерә.

Тукай Төркия тормышын дөрес яктыртып, кыйммәтле мәгълүматлар биреп, милли матбугатыбызны баетканы өчен Йосыф Акчураны һәм Фатыйх Кәримине мактап телгә ала (64—249, 250), чынбарлыкны кәкре көзгедә чагылдырулары өчен кайбер төрек каләмдәшләрен исә «Мәддахе Истанбул шагыйрьләре»ндә (1908) болай шелтәли:

«Ушбулар язган шигырьнең бик кызык шигърияте:
«һа! — имеш, солтан тәти, «Йолдыз»* тәти, кызлар тәти!» (61—221).

Госманлы империясендәге фетнәләр Тукайның игътибарын даими тартып тора.

«Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут;
Анда дерзиләр кабынган, монда сүнсә — арнаут» (62—175)

— ди шагыйрь аптырап.

Башбаштак залимнең үлеме исә аны «Габделхәмит» (1909) шигырен язарга рухландыра:

«Утыз ел хөр фикерләрне үлтерт,
Төрекләрдә азатлык тамрын корыт,
Ватан яктыртучы шәмнәрне сүндерт,
Мөселманнан бөтен читләрне көлдерт,—
Утыз ел казыган баз бик тирән шул,
Менә инде Хәмитең шунда гөмберт! (62—27).

Г. Тукай иҗатында төрек һәм Төркия темасы һәрвакыт үзәк урыннарның берсен алып тора. «Яшь төрекләр»гә мөрәҗәгать итеп, ул 1906 елда ук «Әлгасрелҗәдит» (9.XI) гәзитендә «Борадәренә нәсихәт» шигырен бастыра һәм анда революцион яшьләрне икейөзле булмаска, көрәштә эзлеклелек һәм кыюлык күрсәтергә, хаклык һәм гаделлек өчен залим солтанга каршы күтәрелергә өнди (61—103).

*Дәвамы киләсе санда.*

---

* «Йолдыз» — солтан сарае.

*Дискуссия дәвам итә:*

**БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ**

# ЧЫН ӘДӘБИЯТ УЛ ИСКЕРМИ!

Дискуссиядә сүз соңгы елларда язылган әдәби әсәрләр турында бара. Ләкин әдәбиятны тирән аңлаган кеше шуны да яхшы төшенә бит: чын әдәбият әсәрләре беркайчан да искермиләр. Аларны укыган саен үзеңне борчыган, уйландырган мәсьәләләргә килеп юлыгасың, мәгънә тирәнлеген күреп шаклар катасың.

Мисал өчен бер генә әсәрне күрсәтәсем килә. Һади Такташның «Югалган матурлык» исемле пьесасы инде моннан ярты гасыр элек язылган. Әмма ул нәкъ менә бүген язылган сыман, хәзерге заман кешеләрен күздә тотып иҗат ителгән шикелле. Безнең чорда — ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр аеруча катлауланган, гаиләне саклау мәсьәләсе яңадан да актуальләшкән вакытта — бөек әдибебез иҗат иткән әлеге әсәрне тагын да тулырак аңлыйсың.

Биредәге вакыйгалар дүрт гаилә эчендә бара. Әсәрдә дүрт төрле һәм дүрт фаҗигале тормыш сурәтләп бирелә.

Менә кустарьлар артелендә (әйтерсең лә ул бүгенге кооператор) эшләүче Габдрахман белән аның егерме җиде яшьлек хатыны Җамал. Алар аерылышалар. Моның сәбәбен Җамал әсәрдә түбәндәге сүзләр белән аңлата:

— Эчә башлады... «Минем җилкәмне кимерәсең»,— дип гел кыйный башлады... Ә нәрсә, аяк-кулым исән чакта үз тамагымны үзем туйдырырмын әле.

Бераз киткәч, сүз яңадан шул турыда чыга:

Габдрахман. Неужели, асрау булып тору минем белән торудан артыграк?

Җамал. Билгеле! Ичмаса үз тамагымны үзем туйдырам. Тамагым тук, җаным тыныч. Сиңа кайтсам, син тагын да шулай эчеп йөрерсең... «Минем тапкан икмәкне ашап ятасың»,— дип тиргәрсең.

Өченче урында Газиз Җамалдан: «Нигә кайтмыйсың?» — дип сорагач, Җамал: «Ул мине артык җәберли, ашаган ашка кадәр тирги»,— дип җавап бирә.

Шулай итеп, бер үк вакыйга өч тапкыр кабатлана. Аларны берләштерсәк, бер нәрсәгә — аерылышуларының сәбәбен ачыклауга кайтып кала. Җамал гел Габдрахманны гына гаепләсә дә, биредә аның үзенең дә гаебе юк түгел. Ул, тамагым тук, җаным тыныч, дип, никадәр генә үзен ышандырырга тырышмасын, аны тулы бәхетле дип таный алмыйбыз. Революция хатын-кызга биргән ирекне берьяклы гына алып аңлау — Җамалның фаҗигасе. Билгеле, монда Габдрахманны да аклап булмый. Эчеп кайту — үзе үк гаиләнең тынычлыгын җимерә. Ир кеше элек-электән гаиләне туйдыручы саналган бит. Ә аның ашаткан икмәгенә кадәр санаулы. Нәтиҗәдә гаилә таркалды, матурлык югалды.

Икенче гаилә — шәһәрдәге кибет мөдире 40 яшьлек Бари Алиев белән аның 32 яшьлек хатыны Ниса Әюповалар гаиләсе. Биредә киресенчә. Баринын тормыш җитеш, хатыныннан бернәрсәне дә күпсенми, хәтта башкаларга да бурычка биреп тора. Тик бу бурычны түләргә уйлаучы гына юк. Үзенә чалбар сатып түләргә кала.

Бариның характерында яхшы белән начар каршылыгы бирелә. Аны һаман яхшы диләр. Ә ул үзенең йомшаклыгын белә, моның начар икәнен дә күрә, ләкин иң аянычы — Бари бернәрсәне үзгәртә дә, каршы да тора алмый.

Бари. Мин... их мин артык йомшак.

Хәмит. Син яхшы партиец, яхшы эшче.

Бари. Их канга сеңгән нәрсәне алып ташлавы авыр. Моңа минем табигатем гаепле, мәңге кеше сүзен тыңларга мәҗбүр булу, сүзгә каршы тора алмау, баш ию миндә шундый коллар табигате тудырды... Әллә ничә «Бу урыннан мине алыгыз»,— дип гариза бирдем. «Син хыянәтсез кеше, яхшы партиец»,— дип һаман калдырдылар.

Хәмит. Кызык... Сез үзегезнең бөтен йомшак якларыгызны беләсез, ә төзәтә алмыйсыз.

Тагын бер урында мондый сөйләшү була:

Нури. Бари ул — яхшы кеше...

Бари. Юк, юк алдыйсыз. Мин яхшы кеше түгел. Сез минем киемнәремне алыр өчен яхшы кеше дисез. Сез хатынымны, бөтен тынычлыгымны тартып алыр өчен әйтәсез...

Әйе, ир кешенең йомшак булуы — гаиләгә фаҗига китерә икән. Эштә биреп торган акчаларны соңгы чалбарын сатып түли алса да, ул гаиләне саклап кала алмый.

Өченче гаиләне алып тикшергәндә, Солтан белән Зөбәрҗәткә тукталабыз. Солтан «иректе мәхәббәт» ягында. Гаилә төзүгә җинел уйлап карый, бернинди җаваплылык тоймый. Әсәр башында ук аның бу карашын сиземләгән идек. Газиз белән Галия туенда «аталарча тост әйтәм» дигәч, Нури Солтанга: «Синең әле ата булырга үзеңнең өйләнгәнең юк»,— дигәч, Солтан аңа: «Өйләнми дә ата булып була»,— дип җавап бирә. Зөбәрҗәт белән өйләнешүләре дә уйлап эшләнгән эш түгел. Бүлмәдә ут сүнеп торган арада кызган баштан бер-берсенә тартылалар, ут янганны да сизмичә үбешәләр, шул кичтә үк өйләнешергә дә булалар. Газиз аларны: «Ләкин, иптәшләр, бу ялгыш адым булмасын, исерек баштан, бер-берегне яхшылап белми, өйләнүнең соңы начар булмасын»,— дип кисәтә дә әле.

Зөбәрҗәт белән яши башлагач та Солтанда үзгәреш күрмибез. Ул өчәр көн өйгә кайтмый, семья булып яшәүне мещанлык дип карый һәм ата булудан котылу өчен Зөбәрҗәттән аборт ясата.

Әлбәттә ашык-пошык кияүгә чыгуда Зөбәрҗәтне дә аклап булмый. Гаилә төзү — алай уйламыйча эшләнә торган эш булырга тиеш түгел. Шулай башланган тормыш күз яше, аерылышу белән тәмамлана.

Дүртенче гаилә — бер-берсен яратышып, берсен-бере яхшы белеп өйләнешкән, икесе дә аңлы, укымышлы, яшьлек мәхәббәт дәртендә янучы 27 яшьлек инженер Газиз белән университетта укучы 21 яшьлек комсомолка Галия.

Галиянең теләкләре изге. Солтан аңа: «Шатланырга ашыкма. Элек шушы бүлмәләрне кара. Киләчәктә мәгънәви каберең булмасын»,— дигәч, Галия: «Юк, мин бу бүлмәләргә үләр өчен килмим, яшәр өчен, ике канатлы булып яшәр өчен, сөяр өчен киләм»,— дип җавап бирә. Шулай ук «юллар бер котыпка юнәлгән» дип, Газиз дә гаилә тормышының бал-ширбәтләрдән генә тормавын яхшы аңлый.

Һ. Такташ гаиләдә ирләрнең көчле шәхес булуында хатын-кызның нинди олы урын тотуын Газиз белән Галия сөйләшүендә шулкадәр дә табигый, матур итеп күрсәтә алган:

Галия. Синең баш әйләндергеч ирлек көчең мине көчсезләтә... Мин ул вакытта хатын икәнлегемне сизәм.

Газиз. Синдәге саф гакыл, тирән кешелек эченә уралган кызлык матурлыгы миндәге ул көчне үзе яндыра, сөеклем.

Кызлык матурлыгының табигать биргән олы хис булуын искәрткән сүзләр берничә урында кабатлана.

Тормыш Галияне бөтен барлыгы белән үз эченә бөтереп ала. Ул эшен дә жиренә җиткереп алып барырга тырыша, укуын да тәмамлый. Шулкадәр эшкә бирелә, беренче баласын тапканнан соң, хәтта, имезергә дә вакыт таба алмый. Күкрәк сөте җитмәгән, тәрбия күрмәгән бала рахит белән авырый һәм үлеп китә. Ә икенче баласына үзе аборт ясата. Беркөнне Галия төнге сәгать 11 дә кайтып кергәч, алар арасында шундый сүз була:

Газиз. Мин сине югалтудан куркам. Төннәр буе эшләрмен, синең сәламәт килеш елмаюын миңа иң зур бүләгең булыр. Синең сәламәтлегең миңа никадәр кыйммәт булса, синң тормышыңны бирергә әзер булган партияң өчен дә шулай ук кыйммәт.

Хамит белән Газиз арасында тагын мондый әңгәмә дә була:

Хәмит. Бүгенге гаилә — әллә нәрсә. Бүгенге гаиләдә бала проблемасы әллә ничек тора, — дигәч, Газиз ана бала проблемасы гына түгел, аталык-аналык мәсьәләләре дә инде шулай ук әллә ничек булуын, революция гаилә мәсьәләсендә алга бик күп проблемалар, бик күп каршылыклар китереп куюын әйтә.

Юк, Галия тәмәке тартып ирләргә охшарга тырышучы хатын-кызлардан түгел. Ул эштә, кешелекнең акыл югарылыгында ирләр белән бертигез булырга омтыла.

Алсыз-ялсыз үзен аямыйча тырышуының начар нәтиҗәсе күз алдында. Ул үзен көзгедә күреп әрнеп болай ди:

— Ах!.. миндә бер матурлык та калмаган! Мин яшьлегемне, аналыгымны югалттым. Мин бөтен матурлыгымны югалттым.

Шулай итеп, язучы безнең алга якты хыяллары чәлпәрәмә килгән, җылысы суынган, матурлыгы югалган дүрт гаиләне китереп бастырды.

Бу әсәр бүгенге тормыш өчен дә әһәмиятен югалтмаган кыйммәтле әсәр булып тора. Әйтерсең, Такташ бүгенге көннәрдәге гаилә тормышын алган да, берәм-берәм анализлый. Гүя ул, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр бозылуга, әхлак югалуга түзмичә, безгә дәшә. «Элек изге дип саналган нәрсә югалды бит», — ди.

Бүген әдәби әсәрләр иҗат итүче язучылар да әнә шулай искерми торган проблемалар, мәсьәләләр күтәрсеннәр иде. Аларның әсәрләре дә еллар узгач тоныкланмасын, саекмасын иде.

**Бану КАДЫЙРОВА,**
Апас урта мәктәбе укытучысы

# ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП...

«Казан утлары» журналында язучы Атилла Расихның «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» дигән истәлекләре басылган иде. Журналны ачу белән, кая әле берәр генә хатын укып карыйм, дип укый башлаган идем, әсәрнең ахырына чыкмыйча аерыла алмадым. Хатларның эчтәлеген укып бер төрле хисләр кичерергә мәҗбүр булсам, язучының хәтерендә калганнарны укып, икенче төрле тәэсирләнергә туры килде.

Без сугыш елларында хатлар язарга өйрәндек. Бик күп язарга туры килде әтиләребезгә, абыйларыбызга һәм, хәтта апаларыбызга да. Билгеле, төрле сәбәпләр аркасында (ул вакытларда бигрәк тә) барысын да хатларга язарга мөмкин түгел иде, язучы Атилла Расих кебек, хәтердәгеләре күбрәк калгандыр. Менә мин дә, хатларыннан бигрәк, хәтердәгеләре белән уртаклашмакчы булам.

... Менә мин, кулларымны юып, төрле төстәге төймәләр белән бизәлгән матур түбәтәемне киеп алам да, өстәл артында, сугыш кырындагы әтиемә, хат язып утырам. Әниемнең бер вакытта да эше бетеп тормый, ул ара-тирә нәрсәләр турында язарга кирәклекне онытмаска куша, ничек итеп язу исә минем өскә йөкләнә. Тышта кояш җылысы, кар күзәнәкләрен чагылдыра биреп, язны ашыктыра. Бәләкәй чана бавына, сәнәк һәм көрәк сапларына гына җайлашкан, дүртенче сыйныфта гына укыган малайның бармаклары башта каләмгә җайлаша алмый тордылар. Әкренләп хәреф артыннан хәреф теркәлде, сүз артыннан сүз һәм, ниһаять, алар хисләр булып кәгазь юлларына, баш миендәге сырларга охшап, тезелешеп утырдылар.

Хат язылып беткәч, укытып карыйлар. Монда инде әниемнең дә эше беткән, әниемнең әнисе — картинәй дә тыңлап торырга әзерләнгән, ике энекәшем, бер сеңлекәшем дә тыңлар өчен минем янга елышып утырганнар. Хат укылып беткәнче бер кеше бер сүз әйтми — шулай өйрәтелгән. Аннары, бераз тын торганнан соң, әнием: «Кара-ле!» — дип, соклануын белдерә. Бу — хат язучы өчен иң югары бәя дигән сүз. Аннары, җылтыр түбәтәйне баш очына күтәребрәк куя

биреп, шул ук кәгазьдән өчпочмаклы конверт ясагач: «Полевая почта...», дип адрес язасың.

Хәтеремдә, бу хатка иң зур яңалык итеп, салам белән ябылган өй түбәсеннән кар көрәгәндә зур бер кисәк карның саламнарны да ияртеп аска төшеп китүе иде. Үзем егылмыйча чак кына калган идем. Әйе, җәйге яңгырларда бу саламы юкарган урыннардан өй эченә яңгыр үтүен, кая карама савыт-сабаларга озак вакытлар су тамып торуның үзәкләрне сыкрандырганын язмадык шул инде. Сугышта снайпер булган кешегә тыныч булу кирәк, янәсе, көяләнмәсен, бер пуләсе дә читкә китмәсен.

Хат язу — бик җаваплы, язган кешең алдында саф күңелле булуны таләп итә торган изге нәрсә икән ул. Мин моны Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романын укыгач белдем. Габдулла Кырлайда торган вакытта Гөләнвәрнең армиягә киткән җан сөйгәне Фазыл өчен хат яздырганы хәтеремә төште. Нәрсәләр турында язарга икәнен Габдуллага берничек тә аңлата алмаса да, сабынлап юына, сандыктан алып яңа күлмәк кия, кершән-иннек яга, хәтта миң тә төртеп җибәргәч кенә хат яза башларга куша. Бу күренеш татар хатын-кызларында гына борынгыдан ук шулай килә икән, күрәсең, әнием мине дә шулайрак өйрәткәндер, диясе килә. Нинди гаҗәеп сафлык һәм гүзәллек бар монда: җан сөйгәнең белән кара-каршы утырып сөйләшкәндәй хисләр, мәхәббәтнең дә иң югары ноктасыдыр диясе килә. Тагын да бер кабатлап әйтсәм дә, язсам да гаеп булмас: мондый гореф-гадәт тик татарда гына булса булыр.

Адрес язылгач, кадерле түбәтәй китап шүрлегенә иплән кенә куела, бер өстеннән сыпырып та аласың, эх, вакытлары саерак шул, гел генә киеп йөрердәй югыйсә. Гөләнвәр дә Габдулланы озатканда болай ди: «Акыллым, мин хәзер киемнәремне салып куям, битемдәге кершәнне сөртеп ташлыйм, син минем киенгәнемне, исле сабын белән юынып, кершән ягынганымны берәүгә дә әйтмә, җаныем, әтиләргә ишетелсә, яхшы түгел, яме?»

Әнием әйтә торган иде: бабаларыгыз һәм аларның бабалары бик укымышлы кешеләр иде, китап тотсалар, («Коръән-Кәрим» һәм башка изге саналган дини китаплар), язу-сызуга тотынсалар, тәһарәт алып, юынып утырырлар иде, төрле чирләрне өшкерү белән дә авылдашларының савапларын алырлар иде, ди. Шулай булгач, безнең ыруыбыздан килә, ахры, мондый күркәм гадәтләр, дип уйлыйм мин үзем.

Хатлар. Хатлар... Хатларга язып сүзләр бетми. Ә кара-каршы күреп сөйләшкәндә күңел белән күңел сөйләшә, күзләр белән күзләр очраша, соң бу чакта сүзнең ни әһәмияте бар аның?!

Сугыш еллары ничек кенә авыр булмасын, бәләкәй генә малайлар булуга карамастан, үзебезнең сыйныфтагы кызларга күзебез төшеп, Мәҗнүн кебек хыялланып йөри идек. Күрәсең, адәми затның мондый омтылышы геннарына салынгандыр. Башкортстандагы татар шагыйре Әнгам Атнабаев әйтмешли, безне бер кеше бернәрсәгә өйрәтмәде, үзебез кача-поса өйрәндек. Шулай, күрше малае Равил белән утырдык та Әнисәгә мәхәббәт хаты яздык. Билгеле, язучысы дигәндә, иптәшебез Әбүзәр дип кул да куйдык. Тора-бара бу чынга китте, болар дуслаштылар гына түгел, чынлап яратыштылар, өйләнештеләр, балалар үстерделәр, хәзер Әбүзәр белән Әнисәнең оныклары җитеп киләләр, бик тә тату гомер итәләр. Менә сиңа хат белән шаяру!

Мин хат язам. Әле яза алмыйм, язарга тырышам, хәрефләр бик әкрен генә языла һәм бер-берсенә кушылалар. Сәбәбе: яздан чыгып киткән малайлар өч атна буе ерак басуда, Яугачы буе яланнарында сабан белән җир сөреп, тырмалап, куна-төнә яттык. Көн саен безнең эшләгәнне тикшерү өчен йә колхоз рәисе, йә бригадир килеп китә иде. Шуңа күрә безнең бармаклар, сабан тоткасына һәм чыбыркы сабына гына җәпләнеп беткәннәр иде, ә каләмнәрне буйсындыруны оныта язганнар. Яланның теге ягындарак, Мөдәррис исемле малайның чырыйлап кычкыруына борылып карасак, ни күзебез белән күрик, колхоз рәисе сугып-сугып ега тегене. Тартып торгызды да, тагын сугып җибәрде. Озак ятмады ул елап, ә рәис китте кырандаска утырып. Мөдәррис ни, торып, сабан тоткасына ябышты. Сугышларда дары исен татымаган яшьрәк малайлар шулай чыныкты безнең заманда. Шуларны хатка язып булмый бит инде, андыйларны гына өйдә әниләребезгә дә сөйләүче булмады. Шуларны сөйләп тә яки язып та ничек аларны тагын ут йоттырасың. Менә ни өчен түзгән ул Мөдәррис иптәшебез, мин шулай гына аңлыйм.

Атлар буразнада арып, туктап калгач, без Фәхрәй каенлыгына, Фәхрәй тишегенә су алырга бара идек. Таяк башларына бәйләнгән чыраларны яндырып, үрмәләп җир тишегенә кереп китә идек. Бераз үрмәләп баргач, киңәя, таш

коридор кебек, стеналар тигез киселгән тоташ таш кына, түбә түшәме тигез таш, аяк асты идән кебек тигез, кешедән каласы килми, күңел курка, аяк атлый. Ниһаять, уртада җыелган су ялтырый, каяндыр — биек түшәмнән икән — йодрык кадәрле тамчылар шартлап тамалар, тагын да куркынычрак. Коридор кинәя, су тирәнәя, ары үтәрлек түгел, алда — су тавышы, алда — караңгылык, алда — могҗиза... Су алып чыгу ягын чамалыйсың. Авыл малайларының күбесе монда керергә җөрьәт итми, бу — батырлык исәпләнә. Өйдәгеләр алдында мактанырга уйлап булса кирәк, бу турыда сөйләп күрсәттем. Ләкин әнием дә, картинәем дә бик шаккатмадылар, ә аларны тыңлап, үземнең күзләрем дүрт булды.

— Бабагызныкы ул. Үзе исән вакытта Фәхрелислам Тишеге диләр иде. Тишек алдында сырлап эшләнгән ишекләр, ишек тоткаларына чигелгән ак сөлгеләр эленгән була торган иде. Бабагыз үзе генә юынып, сөртенеп керә иде. Биек капка төбендә җигүле атлар белән ераклардан төрле сырхауларны алып киләләр иде. Атнагол, Турай авыллары ярминкәләре вакытында, тирә-якларга хәбәр итәр өчен, кешеләр җибәрелә торган иде. Даны еракларга таралган аның.

— Яугачы буендагы чокыр дип әйтергә куша безнең абый. Мәктәптә Фәхрәй Тишеге дип сөйләшмиләр, ди ул, культурно сөйләшергә куша,— дип кушылды энекәшем.

— Синең ул абыең җилкә чокыры белән колак тишеген дә аермый икән әле. Урамда күрсәм, тозлап-борычлап аңлатырмын мин ул малайга. Кара син аны...,— дип, кызып китте картинәебез.— Бабагызны кушып, авылыбызны Фәхерәйле Бишкурай дип йөрттеләр, шул тишек аркасында бит, чокыр өчен түгел. Бабасы шундагы шифалы су белән дәвалангандыр әле үзенең, рәхмәт төшкере.

— Кара-ле! — дип гаҗәпләнде әнием.

Уйларга бирелеп, хат укуымда да, онытылам икән. Кая, тагын укыйк әле бергәләп. «Хәзер бездә тәмам җәй булды. Көннәр ифрат матур. Яныбыздагы урманда сандугачлар сайрый. Күңел әллә кайларга ашкына...» Әйе, кырык дүртенче елның маенда без дә көн саен урманда идек. Аркада капчык, тезелешеп балтырган, кузгалак, юа, сарана, әтнек, какы, ашарга яраклы көпшәләр эзлибез, ни тапсак та — безнеке. Бәләкәйрәк хәлсез апайларыбызны җитәкләп алып барабыз, Урта тау буе урманына җиткәнче арыйлар иде. Ни өчендер сандугачлар сайрап торганын ишетеп хозурланганыбызны хәтерләмим. Ә менә, фәлән кешенең балалары урманнан кайтмаганнар, кунып калганнар хәлләре булмагач, дигән сүзләрне әниләр ишетеп, кайтып өйдә сөйли торганнар иде. Үлән ризыклардан башка азык ашамаган балалар шешенә башлагач, җәйге пионер лагерьларына, ял итү сылтавы белән, җибәрелүчеләр булды. Менә кайда ул яшәү өчен көрәш фронты. Ничә көннәр үлем белән якалашып хәрби госпитальдә һушына килә алмаган әткәбезгә шуларны язып булмый бит инде. Ул Казандагы егерменче мәктәптә урнашкан госпитальдә елга якын аунап ятты. Уң күзе чокырыннан зур кисәк снәрәт ярчыгын күзе-ние белән алып ташлаган булганнар.

Атилланың, язучы булырга омтылган кеше буларак, иптәшләре, дуслары, язучылар белән дә бик җылы аралашуы өчен күңелле булып куя. Болары инде дусларча хәстәрлекле, икенче төрле эчтәлек белән сугарылган. Габдрахман Әпсәләмов белән «Совет әдәбияты» журналындагы истәлекләр аша, хатлар аша танышулары минем күңелләремә сары май кебек ятты. Менә дуслык ничек башлана икән. Фатих Хөсни, Кави Нәҗмиләр белән очрашуларның күңелле булуы миңа бик тә охшады: аш белән бирелгән икмәкне ашап бетерә алмаганы, калдырганы өчен Фатихның соң дәрәҗәдә аптыравы миңа бик таныш. Бездә мондый гадәт юк, агайне, без алай сынык калдырып ашауны белмибез, ди ул Атиллага. Бу — бер уйлаганда бик йомшак кына итеп катыга утырту белән бер түгелме соң? Аңы булган кешегә аңларлыгы бар. Мин үзем дә үземнән кечеләрнең һәм балаларның сынык калдырмый ашаулары өчен тырыштым, үз балаларым бик тиз аңладылар, ә менә мәктәп ашханәсендә күп көрәшергә туры килде, гаиләләре белән танышу, әти-әниләр җыйналышы саен исемнәрен әйтә-әйтә сөйләп, хәтта ачуланышып бетә идек. «Ипекәй валчыгын зурласаң, олы кеше булырсың», «Сыныгыңны калдырма, бүленгән ашалсын — бәхетең шунда»,— дигән әйтемнәрне бервакытта да исләреннән чыгармаска өйрәтергә кирәк икән.

... Елтыр түбәтәйле малай хат язып утыра. Яза да тукталып тора, тагын яза, тагын туктала. Димәк, язылмаска тиешле авыл хәлләре дә бар икән, белеп язарга кирәк.

Хатымдагы иң шатлыклы хәбәрләрдән безнең сыйныфтагы берничә кешене комсомолга алу, андагы сорауларга мин генә тулы җавап бирә алуым иде. Уку өлгереше, тәртип һәм җәмәгать эшләрен бер укучы да арттырганы юк иде, гадәти малайлар һәм кызлар. Ә шулай да үзешчән сәнгать буенча алдынгылык

бездә булды. Әле дә хәтеремдә, сыйныфташыбыз Вәзих дигән малай әти-әниләр жыелышында авыл клубында Һади Такташның «Мокамай»ын жырлап, бөтенесен елатты, ул нинди көй булгандыр, нинди тавыш, менә, исемә төшкән саен, шуны уйлыйм да, җавап таба алмыйм. Билгеле, малаеның ни дәрәҗәдә үсүен әти кеше, хатларны укып, елмаеп-елмаеп куйгандыр. Шулай ук, ачлы-туклы, өшегән-туңган, кагылган-сугылган малай язган «Яз шатлыгы» исемле шигырьләрнең мәктәп стена газитендә чыгуы зур шатлык түгелмени? Күңелләрдәге канатларның тибрәнүен яшь шагыйрь үзе генә белә. Шигырьләр язмаган, анда үзенең исем-фамилиясен күрмәгән кеше аңлый алмый аны. Иҗат ялкынында януы турында әти-әнисенә, туганнарына язган хатлары белән минем йөрәк түрендәге яшьлек хыялларымны исемә төшереп, күңелләремне тибрәткән өчен Атилла Расихка илаһи рәхмәтемне белдерәм.

Безнең бәрәңге бакчасы арты аръяк урамындагы Фәрхетдин абзый, озак кына хәрби госпитальдә яткач, туган авылына кайтырга насыйп булган, дип яздым мин хатка. Хәләл җефете Хәмдениса түти дә бик сөенде. Ләкин, ул абзыйны ике кеше озата килгәннәр иде, вакыт-вакыт, «ычкынып» китсә, күзләрен алартып: «Урра! Алдан да аталар! Арттан да аталар! Кая качып котылырга!» — дип, калтырана-калтырана, кая керергә белми, башын әллә кайларга илтеп тыга иде. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бу чамасыз кычкырынулар безнең як урамга да ишетелә иде. Боларын хатка язу ник бер кеше күңеленә килеп керсен, башкалар да язмаганнардыр дип уйлыйм мин. Моны нәрсә дисең: шатлыкның артында ачы хәсрәт посып торган, башкача әйтеп булмый.

Хатлар — кеше язмышлары. Хатларда тормыш бер төрле булып кәгазь юлларына ятсалар, хәтерләрдә төер булып, тормыш үзенчә агышлар кичерә. Җилкәңне кашый биреп, иягеңә таянып, уйланыр нәрсәләр күп монда, уйлана белгән кешегә, фикер йөртү сәләте булганнарга. Хатны язучының фикерләвенә карап, укучының аңлый белүе дә кирәк икән. Шулай, еракларда күп еллар яшәгән Нажиянең әнисе хат яздырды миннән. Нилэр язарга икәнен сораштым да утырдым хат язарга. Бу әби белән минем карчыгым сөйләнә-сөйләнә чәй эчәләр, мин хат язам, башта җылтыр түбәтәй, өстә ак күлмәк, эре шакмаклы кара галстук. Укып күрсәттем, адрес та язып куйдым. Соңыннан, ничә айлар үткәч, күршебезгә Нажия балалары, хәләл җефете белән кайтып та төштеләр. Беренче күрү белән, исәнләшүдән алда, мыекларын бөтерә биреп, кияү булган кеше миңа ябырылды.

— Шулай хат язалар мыни, пнимаешь. Нажия син язган хатны укый да жылый, укый да жылый, пнимаешь. Подумаешь, ишек токтасы, таудагы ташлар, өянке һәм шомырт агачлары, пнимаешь. Нәрсәсе бардыр, шуңа жылап торырга. Андый хат язма яңадан, пнимаешь.

Нәрсә дип җавап бирим: кем аңлаган, кем аңламаган. Ә мин үзем Нажиянең сагынулары яңару дип аңладым, була бит ул шундый күңел тибрәнүләре. Шулай армия хезмәтен үтәү җәһәтеннән Себер урманнарында хезмәт иткәндә (әйтергә оят) минем үземне сагыну хисе басты: гаиләбезне, урамыбызны, каршы Нарат тауларын күрәсем, шунда йөрисем килә бит! Хат яздым күңелемдә булганын ачыклап. Өйдәгеләр хатымны җыелып утырып укыганнар һәм картинәем:

— Сагынган бит бу бала, җир җиләге кагы салырга кирәк,— дигән карарга килгән. Әнием дә: «Кара-ле!» — дип, хәйран калган һәм хуплап куйган. Ул вакытта өч ел ярым хезмәт итеп сагынганнарны басар өчен менә нинди хәстәрлекле булганнар авыл кешеләре. Сагыну, җирсәүне тик җир җиләге кагы гына баса икәнен белгәннәр алар. Дәвасы, дөрестән дә, шул булды, иптәшләребез белән бергәләп, бүлгәли-бүлгәли, авызларыбыз суын китерә-китерә, ах та их килеп чәйнәдек.

Безнең татар әдәбиятында, гомумән, әдәби әсәрләрдә, геройларның кичерешләрен укучыга җиткерү стиле итеп эпистоляр жанрда, ягъни хатлар язу формасында корылган әсәрләр күренгәләп куя. Бу җәһәттән күп укучыларга билгеле булган Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте бүген дә яратылып укыла. Минемчә, Атилла Расихның «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» дигән истәлекләре дә укучылар өчен хисләнеп укырлык. Хәер, укучының да, югарыда әйтелгәнчә, төрлесе була.

**Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ.**
Башкортстан, Туймазы районы,
Югары Бишенде авылы

# «МӨРТӘТ СОЦИАЛИСТ» ШИГЫРЕ

Бабичнын бу шигыре үз вакытында матбугатта күренмәгән. Беренче җыентыкларына да, билгеле, кертелә алмаган. Аны, Имай Насыйри күчермәсеннән алып, беренче мәртәбә башкорт телендәге җыентыгында бастырганнар. Шигырь авторның авылдашы З. Искужин күчермәсендә дә саклан- ган. Нәкъ менә анда ул «Мөртәт социалист» дип атала икән. Ә хәзерге җыентыкларга ул «Мөртәт социалистларга» дигән исем астында кертелә. Менә ул шигырь.

Искерәк шиблет эченнән ныгырак чолгау урап,
«Социалист» дип йөрисең, кып-кызыл билбау урап,
Кып-кызыл сүзләр салып йөрттең кара күкрәккә син,
Пычрак төрдең дә ыргыттың кызыл чүпрәккә син.
Тышка чыктың — мәрхәмәт, шәфкатьле сүзләр сөйлисең,
Өйгә кердең — кай фикерне изәтәм, дип уйлыйсың.
Тышка чыктың, алдыңа туфрак салып, икмәк турап,
Өйгә кердең — торды алдыңда төрле көмешләр шалтырап.
Нәгъре ордың: «Измәсен,— дип,— бай фәкыйрьләр җилкәсен,
Ә үзең ач җилкәсеннән күпме дәүләт чиртәсең?!..
Тыштагы бар эшең: җил якка салпы кыстыру.—
Өйдәге бар идеалың — бер тиенне меңгә үстерү.

Шагыйрьнең соңгы җыентыгын төзүче һәм искәрмәләр язучы Галимҗан Гыйльманов «Мөртәт социалист»ны: «Бабич бу очракта ренегат социалистларны күз уңында тота»,— дип аңлата.

Ш. Бабич җыентыгында 1917 елда язылган, һәм бу әсәрдән соңрак урнаштырылган «Буржуй» дигән шигырь дә бар. Әлеге әсәрнең язмышы бәхетлерәк булган. Ул беренче мәртәбә Уфада чыга башлаган «Безнең юл» газетының 9 санында басыла. Исеме бик тә «громоотводлы» булгач, һәммә җыентыкларына гына кертелеп калмый, төрле антологияләргә дә үтеп керә бу әсәр. Мин үзем аның һәр басмасын тикшермәдем, әмма әйбәт фәнни аппаратлы соңгы җыентыкта искәрмә фәлән бирелмәгәнлектән, һәр басмасында нәкъ шулай атап йөртеләдер дип уйлыйм.

Эзләнгәндә мин ул шигырьнең бөтенләй башкача аталган бер басмасына юлыктым. 1927 елда Г. Нигъмәти Мәскәүдә, Центриздатта «Азат мәктәп» дигән дәреслек-хрестоматия чыгара. Анда Ш. Бабичның бу шигыре дә кертелгән. Әмма анда ул «Мөртәт социалистлар» дип атала. Моны Г. Нигъмәтинең буташтыру нәтиҗәсе генә дип бәяли алмыйбыз. Бу атама әсәрнең эчтәлегенә дә тәңгәл килә. Г. Нигъмәти — Ш. Бабичка якын кешеләрдән. Алар мәдрәсәдә, бер әдәби түгәрәктә кайныйлар. Һәм, күрәсең, Г. Нигъмәти Бабичка иң якын кеше була — Бабич мәдрәсәне тәмамлап Тройскига киткәндә, мәдрәсәдә («Галия»дә) чыгарыла торган кульязма «Парлак» әдәби журналына редакторлык эшен ул нәкъ менә Нигъмәтигә тапшырып калдыра. Шигырьнең «мөртәт социалистлар» турында икәнен һәр юлы да кычкырып тора.

Кып-кызыл каннар йөгергән күзләреңнең агына
Күзләвең — корсак кына, сүзләрең — дөнья гына.—
«Социал,— димсең үзеңне,— кып-кызыл,— дип,— маңгаем?»
Ник кызыл ул? Чөнки имгәнсең фәкыйрьләр күз маен.
Ник кызыл каннан буялган күз төбеңнең керпеге?
Юк синең күңелең төбендә тамчы шәфкать бөртеге.
Ник синең мәкъһүр калын ирнең кара күчкыллана?—

Чөнки күңелендә фәкыйрьләргә ачу, мыскыл яна.
Шул көенчә син тагын булган буламсың «социал?»
Уң беләккә бәйләп алгансың кызылдан тастымал?..

Күргәнебезчә, бер үк әсәр ике җирдә ике төрле аталган. Хәзер инде уйлап карыйк: «Социал» атамасының, кызыл түшнең «буржуйга нинди катнашы бар? Күрәсең, Г. Нигъмәти шигырьне хакыйкый үз исеме белән басмада теркәп калдырасы иткән. «Безнең юл» газетыннан килә торган атамасына килгәндә, күрәсең, аны йә гәзит редакторы — Бабичның остазы, үзе «ата социалист» Г. Ибраһимов андый исем белән чыгарырга теләмәгән, яки Бабич үзе «социал»лар белән «буржуй» арасы якынлыгын искәртер өчен шул кәләпүшне кидереп, икесенә дә суктырасы иткән. Шигырьнең менә бу өлеше, күрәсең, маңгай гына кып-кызыл, күңелендә шәфкать бөртеге булмаган һәм хакимиятне кулларында тоткан, Вакытлы хөкүмәттәге социалистларга — ренегат социалистларга төбәп язылган. Бу шигырь конкретлыгы, төгәллеге, накалы белән беренче шигырьдән югары тора.

Беренче шигырьдәге «социал»ның тышкы күренешендә инде төптән үзгәрешләр барлыкка килгән. Әсәрдә игътибар да нәкъ шул үзгәрешләргә каратыла, аларга басым ясала. «Социал»ның (инде ул «социалист» дип үк атала) бар игътибары инде үзен «популист» итеп күрсәтүгә юнәлгән: искерәк шиблит — әэчтәге, чолгавы ныктан да ныграк; тышка, халык арасына чыкканда, итәгенә туфрак салып, өс киемен махсус керләндерә; халык арасында фәкыйрьләрне байлардан яклаучы булып җикеренә, ә максаты һаман шул ук: «Ачлар җилкәсеннән дәүләт чиертү» — шул ук икенче шигырьдәге «корсак кына, дөнья (мал, акча) гына. Ягъни бу инде яңа этаптагы, яңа баскычтагы (Октябрьдән соңгы) социалист. Менә шул үзенчәлекләре һәм әсәрдә сәнгатьчә төгәллекнең публицистик рационализм күләгәсендәрәк калуы, ашыгычлык билгеләре, конкретлыкка китерелеп җиткерелмәгән гыйбарәләр, ашыгычлык билгесе генә булган инверсияләр — болар әсәрнең автор әдәби иҗаттан сәяси хәрәкәт юлына киткән чорда язылган булуын искәртәләр.

Беренче карашка, бу әсәр шагыйрьнең «яңа социалистларга» карата оппозициягә басуын чагылдыра һәм объектив алганда, ул күренешнең ерак киләчәген — безнең көннәрдә нәрсәгә әйләнеп китәчәген ерактан күрүгә кайтып кала кебек. Бу әсәргә шундый югары бәяне биреп нокта куеп булыр иде дә...

Ләкин бу әсәр кемгәдер ачу нәтиҗәсендә генә мәйданга килгән нәрсә түгел.

Тема ул чорда актуальләшкән. Аңа Ш. Бабичтан башка да иң күренекле иҗат көчләре (Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш һ. б.) мөрәҗәгать иткәннәр. Шул рәткә куеп карау әсәрләрнең эчке мәгънәсен дә тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Бу «юнәлеш» әсәрләре арасында Ф. Әмирханның «Март каһарманы» хикәясе, әлбәттә, үзәк урынны тота. Ул да 1917 ел августында, әле Октябрь социалистлары хакимияткә менмәгән көннәрдә язылган. Әдип «Әсәрләр»енең беренче томындагы искәрмәдә: «...Митингларда нотыклар сөйләп йөреп кенә социалист булып була дип уйлаучы надан социалистларны ирония астына ала» диелгән. Ләкин мәсьәлә ничек «социалист» булу турында түгел ич, әсәрдә «социалист»ның асылындагы каршылык игътибарга алына. Февраль революциясе нәтиҗәсендә алар җинел яшәү юлын табалар: 70—80 нче еллардагы партия функционерлары кебек, эшне белмәгән һәм бер ни эшләмәгән хәлдә, дежур сүзләр сөйләп, митинг лозунглары такмаклап йөреп, хисапсыз күп төрле «комитет»ларда әгъза булып, шул «җитәкче» эше өчен һәр тармактан акча алып типтереп яши башлыйлар. Автор бу хәлнең марттан соң әле «шапырыну» гына булып, Октябрьдән соң исә фактка, системага әйләнүен махсус билгеләп, әсәр исеменең янәшәсенә чыгара. Бабич шигырьләрендәге «кара күкрәккә кып-кызыл сүзләр» салып йөрткән, урамга «искерәк шиблеттән», киемен «тузанландырыбрак» чыгучы «фәкыйрьне байлардан яклыйм» дип «нәгърә орып» йөрүче, «күзләве — корсак, максаты акча» булган социалистның да нәкъ шул Ф. Әмирхан әсәрендәге кеше икәне исбат итеп торуга мохтаҗ түгел кебек.

Ф. Бурнашның «Габделмән» дигән поэмасы да бу типның социаль йөзен һәм тарихи эволюциясен яктырта. Казанны урыслар алганда шаһзадә Габделмән урманга кача, анда көрәшкә күтәрелгән халыкка, партизан хәрәкәтенә җитәкче булып китә. Салкын кыш килә. Кыш көне урманда землянкада туңып ятмас өчен ул дошман ягына чыга, иптәшләрен тотып биреп, тулы ышаныч казана һәм яңа хуҗаларының чылбырдан ычкындырган котырган этенә әйләнә. Типтереп яшәү өчен («корсак күзләп»), ул үз нәселдәшләрен мәгънәсез газаплап, талап яшәүне кәсепкә әйләндерә. Аның карауы, үзе тиңсез сарайларда, муллык һәм иркенлектә, тәтәйләр белән типтертеп «оҗмахта» яши... Әйе, Шаһзадә, югары катлау, элеккеге хакимият вәкиле иде шул.

Һәр хәрәкәтне полиция үз кулында тоткан Россия илендә яңа шартларда да житәкчелек жепләрен үз кулыннан ычкындырмас өчен, бәлки, жандармериянең «тиешле оешмалары» үзләренең пычрак шпикларына, провакаторларына ашыгыч рәвештә «революционер»га, «социалист»ка әйләнергә күрсәтмә биргәндер? Әнә шулай итеп, «Терсәк белән төрткәләү осталары» көрәш сәгате узгач, чын көрәшчеләрне читкә этеп, көрәш мәйданын үз кулларына — «март каһарманнары» кулына алгандыр? Яшерен полициянең идән астыннан житәкләве нәтижәсендә, Февраль революциясе жиңү белән «яңа көрәшчеләр» — «март каһарманнары» — мәйданны тутыра, мәйданны биләп ала. Россия дәүләте кабат «жандарга» — полиция идарәсенә әйләнә, кичәге шарж — чынлыкка әйләнә. 1920 елның жәендә бер айдан артык вакыт яңа Россиядә булып киткән күзәтүчән Бертран Рассел да бу хәлгә игътибар итә: «Патша полициясенең элеккеге күп чиннары элеккеге ысуллары белән үк үзләренең элеккеге эшләрен эшли...» — дип яза ул.

Ф. Әмирхан, Ш. Бабич, Ф. Бурнаш әсәрләре белән татар әдәбияты революциянең «икенче көне»ндә үк чынбарлыкның менә шундый яшерен һәм четерекле почмагына да күз сала алган.

**Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ**

# ЧЫН БЕЗНЕҢЧӘ МАТУР, МИЛЛИ...

Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле төзелүгә быел 55 ел тулды. Коллектив бу бәйрәмен зур программалы матур концерт күрсәтеп, киң җәмәгатьчелек алдында иҗади отчет тотып билгеләп үтте.

Милли йөзебезне, халык моңын саклаучы талантлы ансамбльнең һәр концертын тамашачылар чын күңелдән яратып, үз итеп, күтәренке рух, ялкынлы дәрт белән куанып карыйлар, һәр концерт тамашачы күңелендә бәйрәмчә шатлык тудыра. Соңгы елларда киң җәмәгатьчелек телендә бу коллектив турында шундый бик матур бер сүз йөри: «Ансамбль — милли сәнгатебезнең йөзек кашы ул!». Чынлап та, энҗе-зөбәрҗәтләр белән бизәлгән гүзәл йөзек кашы кебек, безнең ансамблебез дә сәнгатебезне яктыртып, нурландырып, аның якты балкышын еракларга сибелдереп, халкыбыз күңелен матур киләчәккә әйдәп баручы бер көчтер. Әгәр дә ниндидер бер могҗиза булып, бөек Тукаебыз терелә калса, «Нәкъ безнеңчә матур, милли көй» дигән сүзләрен нәкъ менә шушы ансамбль турында әйтер иде сыман.

Коллектив юбилеена багышланган тантаналы концертлар кояшлы язгы көннәрдә узды. Апрель айларында ансамбль республикабызның нефть чыккан Әлмәт, Азнакай, Баулы шәһәрләрендә чыгыш ясады. Соңгы елларда мондый дуслык концертлары традициягә әйләнде. Ансамбль һәр яңа программасын менә алтынчы ел инде нефтьчеләргә күрсәтеп, илһамланып кайта. Ә быел ул аеруча тантаналы шартларда узды, чөнки нефтьчеләребез дә Татарстан нефте чыга башлауга 50 ел тулу көннәрен билгеләп үтәләр. Ике шөһрәтле, дус коллектив — бергәләп бәйрәм иттеләр: нефть төбәкләрендә атна буена җыр, моң яңгырады, сәхнәләр ансамбль артистларының ялкынлы, дәртле биюләреннән күңелле тетрәп торды.

Нефть төбәкләреннән кардәшлек концертлары уздырып илһамланып кайткан ансамбль коллективы һәр елны Тукай рухына багышлап уздырыла торган шигырь бәйрәме көннәрендә Самара каласына гастрольгә китте. Идел буена урнашкан Самара каласы Казанның бертуганы — якты, кояшлы, ямьле борынгы шәһәр. Идел суы киң җәелеп салмак кына аккан кебек, татарның моңнары да Идел дулкыннарыдай мәһабәт Самарага таба агыладыр шикелле; моннан соң да Казандагы һәр яңа җыр тиз арада анда барып җитеп, милләттәшләребезнең күңелләрен кузгатып, рухларын күтәреп яңгырый башлар...

Әйе, милләттәшләребез җыр һәм бию ансамблен сагынып көткәннәр, мин моның җанлы шаһиты булдым. Миңа ул көннәрдә ансамбль концертларын Самара тамашачылары белән бергәләп карау, аннан соң концерт турында фикер алышуларда катнашу насыйп булды. Милләттәшләребез ансамбль концертларын тирән дулкынлану белән каршы алдылар, артистларны алкышларга, чәчәкләргә күмделәр. Бирендәге татарларның Казаннан якты нур алып яшәүләрен үз күзем белән күрү, тою күңелемә чиксез рәхәтлек бирде.

Самарада «Туган тел» җәмгыяте тирәсенә тупланган Азат Надиров, Шамил Баһаутдинов, Әминә Шәмсетдинова, Рәшит Абдулов, Илгиз Колючев, бизнесменнар Равил Яһудин, Хәйдәр Сафиуллин кебек фидакярларның җан атып, җиң сызганып бергә эшләүләре нәтиҗәсендә, милләтнең уянуы, үз хокукларын якларга әзер торулары сизелә. Самара татарлары ансамбльнең бу яңа программасын мөстәкыйльлек юлында фидакярларча көрәшүче Татарстан Республикасының сәнгатьчә гәүдәләнгән йөзе, рухи халәте дип кабул иттеләр. «Казан безнең кыйблабыз, безнең шәһәребезгә Тукай рухын, Шигърият һәм яз бәйрәмен алып килдегез, рәхмәт сезгә, тагын килүегезне көтәбез!..» диделәр алар. Ансамбль концертларын Самарага бизнес эшләре белән килгән Төркиядәге «Идел — Урал» татар җәмгыяте рәисе Синан Отрав һәм башка төрек бизнесменнары карадылар.

«Безгә татар моңнары бик якын. Татар ансамбле турында ишетеп белә идек, ниһаять, менә күреп бәхетле булдык»,— дип, төрек дуслар ансамбльгә чын күңелләреннән рәхмәтләр әйттеләр. Синан бәй Отрав концерттан алган тәэсирләре белән уртаклашып болай диде:

— ***Мин Америкада, Японнядә, Алманиядә булдым, кая гына бармыйм, татарлар белән очрашам, милләттәшләребез һәркайда үзләренең милли җырларын, моңнарын яратып, милли ризыкларыбызны пешереп, чын татарча яшиләр. Бу эштә сәнгатьнең ярдәме бик зур. Халкыбыз җыр, моң тирәсенә туплана. Бу ансамбль җир шарының кайсы гына иленә барып концертлар куймасын, татарлар җанын, рухын бергә туплап китә. Татар халкына дәүләтчелек кирәк. Дәүләт өчен көрәштә тир аксын, яшь аксын, әмма ләкин кан акмасын. Ә күз яше сәнгатьнең гүзәллеген тоюдан аксын. Мин биредә Татар җыр һәм бию ансамбленең концертларын ике көн рәттән карадым. Күземнән шатлык яшьләре акты, милләтемнең сәләтле булуыннан соклану яшьләре...***

Самарада уңышлы чыгышлар ясап кайткан ансамбль, май аенда, президентыбыз М. Шәймиев үзе җитәкләгән делегация белән берлектә Венгриягә, аннан кайту белән төрки халыклар ансамбльләре фестиваленә Төркиягә барып кайтты. Җир шарының егермеләп илендә булырга өлгергән артистларның сәләтле чыгышларын ничәмә-ничә миллион тамашачы карагандыр . Кытай, Вьетнам, Япония, Корея, Монголия, Тунис, Италия, Мальта, Германия, Финляндия, Төркия... Ансамльнең чит илләргә барып куйган концертлары турында махсус өйрәнеп язарга кирәктер. Чит илләрдә яшәүче татарларның ансамблебез концертларын яратып, сагынып каршы алуы милли хисләр, нәсел тамырлары белән бәйләнсә, бөтенләй татар телен белмәгән чит-ят милләтләрнең дә татар концертларын яратып каравын ничек аңлатырга? Бу очракта сүзләр көчсез кебек. Ансамбльнең чыгышларында сәнгатьнең тылсым көче бар. Нинди зәвыклы, борынгыдан килгән сәнгате белән тәрбияләнгән нәфис хисле японнарны таң калдырган ансамбль бит ул! Бу турыда безнең ансамбль 1990 елда Япониядә концертлар биргән көннәрдә, Япон матбугаты бар дөньяга шаулап язып чыкты.

Каян гына кайтып кермәсен, кайсы илдә генә тамашачыларның мактауларын ишетеп күңелләре күтәрелмәсен, ансамбль артистлары тынычланып, уңышлардан баш әйләндереп, ял итәбез дип, өйләрендә озак юанмыйлар, программаны тагын да камилләштерү, башкару осталыгын тагын да үстерү өчен, репетицияләр ясарга керешәләр. Алар хәтта гастрольгә чыккач та, арып-талып поездда, автобуста яки самолетта, урынга килеп җитү белән озаклап ял итү турында уйламыйлар, концерт буласы сәхнәгә ашыгалар. Концерт башланырга санаулы сәгатьләр калган була, артистлар исә концерт буласы сәхнәдә тавышларын ачу өчен җырларны кабатлыйлар, ут уйнатып биюләргә репетиция ясыйлар. Репетицияләр ясап тору ансамбль өчен гадәти эш.

Эш дигәннән, эшләү өчен шартлар турында сүз башласак, бик күңелсез хәлләр турында язарга туры килә. Шушы елның март аенда ансамбль бинасының түшәме ишелеп төште. Озак еллар яңгыр сулары үтеп торудан черегән матча сынып төшкән мәлдә, ансамбль артистлары, бәхеткә каршы, бу бинада булмый, бу хәл артистлар концертка киткән чакка туры килә. Ләкин барыбер зур фаҗига була — бинада ремонт эшләре башкаручы эшчеләрнең берсе һәлак була, аның ике баласы ятим, хатыны тол кала. Яшь кенә төзүченең гомерен өзгән бу түшәм турында сүзләр күптән йөри иде инде югыйсә. Аның җимерелеп төшәчәге турында матбугатта да язып чыкканнар иде. Мәдәният министрлыгында да бу хакта беләләр иде, вакытында тиешле чаралар күрелмәде, ниһаять, зур бәхетсезлек килде, кеше һәлак булды. Ансамбльнең җитәкчеләре ничә еллар буена бу бинаның яраксызлыгы турында хөкүмәтебез җитәкчеләренә белдереп тордылар, ансамбльгә яңа бина бирүләрен үтенделәр, әмма... ансамбльгә яңа бина бирергә җыенулар турында әз-мәз сүзләр дә йөргәләде, шулай да эш шул иске бинаны ремонтлауга гына кайтып калды. Хәзер ремонт бара. Ул ремонт кайчан бетәр? Күпмегә сузылыр? Ремонт яхшы сыйфатлы булып тәгәлләнерме? Хөкүмәтебезнең бүгенге җитәкчеләренә үпкә белдереп, аларны ансамбльгә игътибарсызлыкта гаепләргә мөмкин булыр иде, ни өчен ансамбльгә тиз арада бер бина бирмиләр инде, диючеләр дә бар. Алай тиз генә, җиңел генә хәл итеп булмыйдыр шул. Әле ансамбльнең төзелүенә 55 ел тулу уңае белән котлап, хөкүмәтебез һәм аның президенты М. Шәймиевнең быел коллективка өр яңа «Икарус» автобусы бирүе турында ишеттек. Болай булса, шөкер, йөк урыныннан кузгалыр сыман...

Ансамбльгә яңа бина булдыру хыялга ашмас түгел кебек югыйсә. Бу турыда ансамбльнең җитәкчесе Лима Кустабаева болай ди:

*— Хөкүмәтебез җитәкчеләре, Министрлар кабинеты, Мәдәният министрлыгы, Татарстанның Мәдәният фонды, Бөтендөнья татарлары Конгрессының Башкарма комитеты бергәләп киңәшеп эшкә керешкәндә, безгә яңа бина салу эшен башкарып чыгып булыр иде. Әйтик, мисал өчен, Конгрессның Башкарма комитеты, яки Татарстан Мәдәният фонды бөтен татар халкына мөрәҗәгать итеп, ансамбльгә бина салу өчен акча җыю эшен башлап җибәрсә, бу эшкә аерым счет ачса, минемчә, безнең милләттәшләребез безгә ярдәм итәрләр иде. Халкыбызның бизнесменнары белән киңәшкәнем бар. Алар ярдәм итәргә торалар. Мәсәлән, Самара шәһәренең бизнесмены Хәйдәр Сафиуллин ансамбльгә яңа бина салу өчен кулдан килгәнчә акчалата ярдәм итәр идек, ди. Үзебезнең нефтьчеләребез һәм КамАЗ җитәкчеләре дә бу изге эшкә кушылыр иде, шәт. Чит илләрдәге милләттәшләребез дә ярдәм итәрләр иде. Безнең ансамбльне яратучылар читтә калмаслар. Хәзер бит заманасы шундый: күп кенә зур эшләрне башкарырга спонсорлар ярдәм итә.*

Шундый пародокс — эш шартлары юк, ә коллектив зур дәрт белән иҗат итә, коллективның иҗат уңышлары елдан-елга арта, үзенә генә хас иҗат йөзе камилләшә бара, программалар яңара тора. Ансамбль олуг сәнгатебез мәйданында иң абруйлы урында. Бу үсеш, бу уңышлар, программаларның яңарып торуы, әлбәттә, үзеннән үзе генә барлыкка килми. Бу иң элек көчле иҗат энергиясе, бай фантазиясе, эрудициясе, зур музыкаль белеме, оештыру сәләте булган Лима Кустабаеваның иҗат җимеше. Менә егерме елдан артык инде ул ансамбльне җитәкли.



*Остаз һәм шәкерт. Халкыбызның атаклы сәнгать эшлеклеләре* **Фәйзи Гаскәров** *белән* **Лима Кустабаева.**

Лима Кустабаева Казанга Магнитогорск шәһәреннән килә. Татарстаннан читтә туып-үскән татар кызына, әлбәттә, татар мәктәбендә уку насыйп булмый. Шулай да Лима чын татар җанлы булып үсә, татар теленә, татар моңына зур мәхәббәт белән караган әтисе, әнисе балаларын милли рухта тәрбиялиләр. Лима Магнитогорскидагы музыка училищесын бик яхшы билгеләренә тәмамлап, Казанга килә. Казан консерваториясен дә бик яхшы тәмамлап, үзен татар музыкасына хезмәткә багышларга карар бирә. Җыр һәм бию ансамбленә эшкә чакыргач, Лима әтисеннән киңәш сорый. Әтисе Гали ага: «Зөләйха Әхмәтова оештырган ансамбльгә чакыргач, бик яхшы, һичшиксез риза булып бар, кызым, ялгышмассың», — дип аңа фатихасын бирә. Бу гаиләдә Зөләйха Әхмәтованы бик хөрмәт

итәләр. Гомумән, Магнитогорскида ансамбль концертлары була калса, гаилә белән карарга баралар, өйләрендә һәрвакыт татар пластинкалары, бигрәк тә ансамбль башкарган халык көйләре язылган пластинкалар уйнаталар...

Лима Кустабаева ансамбльгә эшкә килгәндә, коллектив авыр хәлдә була, житәкчеләре ел саен алышынганга, ансамбль таркалу алдында тора. Репертуар искергән, кадрлар житми. Лима жиң сызганып эшкә керешә. Яңа репертуар булдыру өчен ансамбльнең үткәндәге ижат традицияләрен өйрәнә, яңача эшләү юлларын эзли. Ансамбльнең электән килгән халыкчан башкару алымнарын заманча башкару алымнары белән үрелдерергә, ансамбльнең яңа ижат йөзен табарга тырыша. Нәтижәдә, ансамбльнең таркалуга барган ижат эшен юлга сала, елдан-елга, концерттан-концертка уңышлар яулап, ансамбльне зур дөньяга алып чыга. Илебезнең төрле төбәкләрендә генә түгел, хәтта чит илләрдә дә танырлык, яратырлык коллектив итеп берләштерә. Лима Кустабаеваның ижат фантазиясе гажәп бай. Ансамбльнең һәр яңа программасы аның хыялында туа, бөреләнә һәм сәхнәдә чәчәк ата.

Ансамбльнең репертуарын сайлаганда, Кустабаева халык ижатына таяна, халкыбызның мәңге искермәс борынгы көйләрен алып, эшкәртеп, репертуарның үзәк юнәлешен билгели. Тукаебызның «халык жырлары халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер» дигән сүзләрен ул бер минутка да исеннән чыгармый. Халкыбызның борынгыдан калган бай мирасы үрнәкләрен бүгенге тамашачы күңелен кузгатырлык итеп башкару өчен, заман рухын, бүгенге көннең сулышын тоярга кирәк. Ул заман рухын тоеп, көйләребезнең иң гүзәл аһәңнәрен, иң нечкә төсмерләрен, саф моңнарын сакларга тырыша. Бу турыда сөйләшкәндә ул болай ди:

— ***Халык көйләре, халык моңы безнең ансамбль репертуарының жаны,каны. Халык көйләрендәге байлыкны түкми-чәчми тыңлаучыга житкерү — безнең төп бурычыбыз. Халыкчанлык, халыкчан башкару традицияләре безнең ансамбльнең ижат юнәлеше. Халыкчанлык ул безнең башкару алымнарыбыздан килеп чыга. Башкару алымнарыбыз урыс һәм башка милләтләрнең хор белән жырлау алымнарыннан бик нык аерыла. Күп тавышлы һәм һәр тавышны да каты кычкырып жырлау безгә хас түгел. Хор белән жырлауның стандарт алымнары безнең милли моңыбызны бирергә комачаулый, шуңа күрә без моңыбызны саклап, үзебезчә, нәкъ менә татарча жырларга омтылабыз һәм күбрәк очракта унисон[1] жырлау алымын кулланабыз.***

Әйе, бар иде шундый көннәр, элеккерәк елларда татар хорлары, һәм шул исәптән бу ансамбль дә урыс һәм башка милләтләргә ияреп, күп тавышлы башкару алымнары белән артык мавыгып китеп, һәр тавышны бертигез кычкырып башкарырга омтыла иде. Нәтижәдә, татар моңы югала, чын татарча жыр тумый иде. Соңгы елларда Лима Кустабаева житәкләгән ансамбль милли моңнарыбызны, милли аһәңнәребезне саклау өчен, күп тавышлы башкару алымына бик сак килә. Төп мелодия, төп көй үзәккә куелып яңгырый, күп очракта төп мелодияне, көйне солистлар башкара, солистлар аның бөтен милли үзенчәлекләрен, моңын саклап, иркенле жырлыйлар. Ә жырчы солистлар турында куанып шуны әйтик, озак еллар ансамбльдә эшләп, халкыбызның мәхәббәтен яулаган, тамашачылар арасында киң популярлык казанган, ансамбльнең горурлыгы булган, һәрберсе үзенең халыкчан моңлы тавышы белән аерылып торган Ания Туишева, Шамил Әхмәтжанов, Нәфисә Васильева, Миңлегөл Зәкиева, шулай ук Лена Бичарина, Халидә Хәсәновалар репертуарның матур яңгырашына зур өлеш кертәләр. Бу артистлардан башка ансамбль концертларын күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Башка солистларның да хезмәте әһәмиятле. Икенче, өченче тавышларны жырлаучылар көйне баету ролен уйныйлар. Артык кычкырмыйча, йомшак кына жырлап, уен кораллары авазына охшашрак матур яңгыраш тудыралар. Нәтижәдә бай, киң яңгырашлы милли көй туа. Артык кычкырмыйча гына, фон шикелле генә яңгыраган икенче, өченче тавышлар солистны тулыландыра, баета. Халкыбызның борынгыдан килгән гадәтләрен искә төшерсәк, бу бик урынлы. Гомумән безнең милләтебез элек-электән бөтен көченә акырып жырлауны өнәмәгән. Өлкәннәр хәзер дә шулай бар тавышына акырып жырлаучы жырчыларны яратып бетермиләр. Тагын Тукаебыз сүзләрен искә төшерик: «Бездә калын тавыш илә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны бик зур итеп ачып жырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә жырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбүл вә мөстәхсән күрелә...»

---

[1] Бер югарылыктагы берничә тавышның аһәңдәшлеге.



*Татарстанның халык артисты*
**Рәшит Мостафин.**

Ансамбль башкарган җырларның шулай халкыбыз традицияләрендәгечә янгыравына ирешү өчен хормейстер, Татарстанның халык артисткасы Венера Гәрәева зур тырышлык куя. Ул җаны-тәне белән ансамбльгә бирелгән, хор белән эшләүнең бөтен нечкәлекләрен белүче талантлы музыкант, дирижер. **«Милли моңнарыбызны саклап җырлау — безнең ансамблебезнең девизы»,**— ди ул. Венера Гәрәева хор белән җырлауның әле алда әйтелгән башка милләтләргә хас алымнарга иярмичә, үзебезчә, нәкъ менә татарча күп тавышлы җырлау алымнарын яхшы белә. Халык уен кораллары оркестры җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин да халыкчан башкару традицияләренә тугры, һәр башкарылган әсәрнең тамашачы күңелен кузгатырлык моңлы итеп, матур яңгыравына ирешү өчен, бар сәләтен биреп эшли, һәр уен коралының талантлы башкаручыларына ул остаз да, киңәшче дә. Ансамбль концертларының бер бөтен булып матур яңгырашында бу кечкенә оркестрның зур өлеше бар. Соңгы елларда кулына нинди инструмент эләксә, шуны даңгыр-доңгыр китереп колак тондыргыч тавышлар чыгаручы хәсрәт инструменталь ансамбльләр күбәеп китте. Рәшит Мостафин җитәкләгән бу һәр әсәргә сак килеп, колакка ятышлы, йомшак, ягымлы яңгырашка ирешкән коллективтан шул ансамбльләр әз генә үрнәк алсыннар иде.

Элеккерәк елларда ансамбльдә хор белән җырлау бер шаблонга корылган иде: хатын-кыз җырчылар сәхнәгә чыгып тезеләләр, ир-егет җырчылар махсус эшләнгән эскәмиягә менеп арткы рәткә басалар. Һәр җыр шулай тезелеп баскан килеш башкарыла. Артистлар бер кысага кертелгән кебек торалар, берниндир табигый хәрәкәт, иркенлек юк. Концертны алып баручы артист һәр номерны белдерә, җыр һәм биюләр аралашып бара, аерым номерлар бер-берсе белән үрелми, бәйләнми, бер бөтен яңгыраш, бер бөтен программа тумый иде. Ансамбль әкренләп бу шаблоннан китте. Бигрәк тә Кустабаева килгәч, ансамбльдә иҗади эзләнүләр башланды. Нәтиҗәдә, ансамбль концертлары тоташ бер мавыктыргыч күңелле һәм матур, җанлы тамаша характерын алды. Тамашачылар исә берсенә-берсе үрелеп барган музыкаль һәм хореографик күренешләрне аерыла алмыйча, ахырга кадәр зур кызыксыну белән, яратып карый. Бу күренешләрдә артистлар үзләрен нииндидер кысаларга кертелгән итеп тоймыйлар, чөнки сәхнәдә чын тормыштагыча иркенлек, хөрлек хөкем сөрә, сәнгатьчә уен бара.

Соңгы еллардагы программаларга күз салыйк. Алар тыгыз эчтәлек-сюжетлы аерым музыкаль-хореографик күренешләрдән тора. «Сабантуй», «Каз өмәсе», «Сәйдәшем», «Корбан бәйрәме», «Былбыллы ил Татарстан», «Шәрекъ клубы», «Төрки дөнья» — боларның һәммәсе халкыбызның уйларын, хыялларын, өметләрен, теләкләрен чагылдырган күренешләр, тамашалар. Болар бар да халкыбызның үткәннәре, бүгенге көне, киләчәге турында. Без еш кына традицияләрне яңартабыз, дибез. Традицияләрне яңартуның сәхнәдә сәнгатьчә иң матур үрнәкләрен нәкъ менә ансамблебез гәүдәләндерә дә инде. «Каз өмәсен» генә искә төшерик. Татар халкы эш сөючән, хезмәткә бирелгән халык. Җир эшен дә, иген үстерү серләрен дә белә. Мал да асрый, кош-корт үрчетергә дә һәвәс. Татар авылларында су буйларында су буйларын ямьләндереп көтү-көтү казлар каңгылдаша. Көзләр җитеп, ап-ак карлар яугач, авылларда каз өмәләре башлана. Каз өмәләре ул халкыбызның чисталыгы, пакьлеге, сафлыгы турында сөйли торган борынгыдан килгән матур гадәт. «Каз канаты» көе бу күренештә төп, үзәк көй. Ансамбль башкаруында аның матур, моңлы яңгырашы бу күренешне гүзәл бер яктылык, тоташ нур, балкышка әвереллдерә. Борынгы гадәткә сәнгатьчә канатлар үсә, сәхнәдә канатлы бәйрәм. Каз канатлары тотып очып-очып биюләр, канатлар

тотып, моңлы, сагышлы итеп җырлаулар — болар халкыбызның рухи бөеклеген, хыялга бай күңелен тасвирлый. Сәхнәдә казлар юып, су буеннан кайтып килүче чибәр кызларның шат йөзләрен, горур кыяфәтләрен күреп күңелләр сафлана, ансамбль кызлары исә, чыпылап та, чибәрләр, зифалар, игезләр кебек буйга бер тигезләр. Җыр, бию, тапкыр сүз, шаян такмаклар башкарыла — болар барсы да халкыбызның күңел җәүһәрләре. Бу җәүһәрләр югалмаска тиеш. Бүген татар халкының милли аңы уянган, милли аңы үсеш кичергән көннәрдә, бу кыйммәтләр үзләренең әһәмиятләрен тагын да арттыралар. Ансамбль тамашачыга шушы фикерне җиткерә.

«Сәйдәшем» дип аталган музыкаль-хореографик күренеш ансамбль репертуарында аерым урын тота. Шулай булмыйча, ул бит халкыбызның сөекле композиторы, татар профессиональ музыкасына нигез салган бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевкә багышланган. Концертны алып баручы шагыйрә Клара Булатова шигыреннән бер өзек укый:

Ул — Шопен дә, Бетховен дә түгел,—
Шулар заты, шулар кардәше.
Ул — татарның Җир-табигать биргән,
Кабатланмас мәшһүр Сәйдәше!

Әйе, ул мәшһүр Сәйдәш!... Халкыбыз үзенең Сәйдәшен йөрәге түрендә иң газиз, иң кадерле кешесе итеп саклый. Аның җырларын, маршларын, вальсларын күңелендә йөртә. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен бер шигырендә әйткәнчә, «Сәйдәш — халык мәхәббәте лауреаты ул!» Ансамбль Сәйдәшнең мәңге үлмәс моңнарын яңгыратып, Сәйдәшнең җанын, рухын терелтә, сәхнәдә могҗизалар тудыра. Сәйдәшнең илаһи көйләре ансамбль солистлары башкаруында гүзәл аһәңнәр белән яңгырап, тамашачыларны уйландыра, сагышландыра, тирән кичерешләр дәрьясына сала. Күпме тапкырлар тыңланган «Тургай» җыры Лена Бичарина башкаруында яңа аһәңнәр белән яңгырап, күңелне нечкәртеп, хисләрне сафландыра. Сәйдәшнең искиткеч матур музыкасына куелган «Шәрекъ биюе»н тамашачылар тын да алмый карыйлар. Костюмнар матур, заманча. «Шәрекъ биюе» ул үткәнебезне бүгенге белән тоташтырган салават күпере кебек — якты балкыш булып, ансамбльнең бу программасын бизәп тора.



*Ансамбльнең бер гүзәле*

Биюләр турында сүз чыккач, шуны билгеләп үтик, аларның матур, камил куелышы озак еллар ансамбльнең балетмейстеры булып эшләгән Татарстанның халык артисткасы Раилә Гарипованың тырыш хезмәте, иҗати фантазиясе җимеше. Ансамбль биюләрендә күпме хореографик табышлар, күпме яңалыклар белән очрашасың. Биюләр турында бүгенге татар матбугатында кызыклы язмалар чыгып тора. «Шәһри Казан» газетасында (1993 ел, 17 апрель саны) егерменче гасырның бөек биючесе Рудольф Нуриевка багышланган бер бит басылып чыкты. Татар милләтенең иң оста биючеләре турындагы мәкалә «Татар Европаны биеп тез чүктерәчәк» дип исемләнгән иде. Бу сүзләрдә нинди горурлык яңгырый! Бию белән тез чүктерү! Биеп тез чүктерү!.. Бу сүзләр бию сәнгатенең кодрәтен, көчен ачып сала. Безнең ансамблебез биюләрен карагач та, күңелгә шундый уйлар килә: күпме илләрдәге тамашачылар күңелен әсир иткән биюләр бит алар.

Бүген коллективта халык мәхәббәтен казанган, озык еллар ансамбльдә эшләп татар хореография сәнгатенең иң матур үрнәкләрен бирүче Равил Габдрахманов, Дамирә Вәлиева, Фердинанд Фәйзуллин, Кәүсәрия Габдрахманова, Рәмзия Әчүбакова һәм яшьләрдән Ләйсән Мостафина, Айрат Хәмитов кебек талантлы биючеләр бар.

Тамашачылар тагын «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасыннан җырлы-биюле бер өзек карыйлар. Бу өзек «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасының концертча кыскартылып (әйтергә кирәк — оста кыскартылган) эшләнгән варианты. Төп рольләрне яшьләр башкара: Мәйсәрә — Флүзә Ялалова, Булат — Фердинанд Фәттерахманов. Яшьләр үзләренең матур, ягымлы тавышлары белән тамашачыларның алкышларына күмеләләр. «Сәйдәшем» музыкаль-хореографик күренеш ансамбльнең уңышы, ә бу хезмәт бүгенге көндә Сәйдәш музыкасы мирасына иҗади якын килүнең матур үрнәге.

«Шәрекъ клубы» музыкаль-хореографик күренеш тә репертуарны баетып, тематиканы киңәйтеп, төрлеләндереп җибәрә. Коллектив бу күренештә халкыбызның үткәненә бер караш ташлый. Егерменче гасыр башында, милләтебезнең аңы уянган елларда, Казанда «Шәрекъ клубы» оештырыла. Татарлар тупланып яшәгән, татарларның тарихи җирлеге булган Өфе, Оренбург, Әстерхан, Троицк калаларында да мәдәният клублары ачыла. Бу клубларда татар зыялылары, сәнгать осталары халкыбызга музыкаль тәрбия бирә, анда яңа музыкаль әсәрләр, җырлар башкарыла, яңа шигырьләр укыла. Милләтебезнең горурлыгы булган Г. Тукай, Ф. Әмирханнар яратып йөргән, яратып чыгышлар ясаган данлы «Шәрекъ клубы» сәнгатебез тарихында матур сәхифә ул. Ансамбль үзенең программасына бу күренешне кертеп, милләтебезнең үткәне белән бүгенгесен тоташтыра кебек. Бу күренештә ансамбль тасвирлаган сәнгать мөстәкыйльлек өчен көрәшкән халкыбызның бүгенге уянуы, тормышыбызның бүгенге яңгырашы белән аваздаш. «Шәрекъ клубы»нда ансамбль артистлары башкарган борынгы көйләр, борынгы биюләр тамашачыны милләтебезнең моңлы үткәненә алып китә, уйландыра, сагышландыра. Ансамбльнең күренекле артисткасы Ания Туишева үзенең ягымлы, йомшак, моңлы тавышы белән халкыбызның борынгы көе «Әзифә»не искиткеч нәфис сәнгатьчә итеп башкара, күңелләр нечкәрә, өзгәләнә... Бу күренештәге биюләр үзләренә бер үзенчәлекле матур. Троицк татарлары бию гаҗәп кызыклы, күңелле. Бу биюне Лима Кустабаева яшьлеге Троицк каласында узган әнисе Камилә апага багышлап, аның истәлеге, аның яшьлеге итеп сәхнәгә күтәргән. Бу бию бик үзенчәлекле. Биредә үзенә бер төрле ритмда башкарыла торган матур хәрәкәтләр, алымнар бар. Валерий Кузнецов, Валерий Бурдиннар башкарган «Җизнәкәй» биюе татар халкының хөр фикерле, җор күңелле булуын, шаянлыгын, тапкырлыгын раслаучы күңелле бию. Шушы урында әйтеп китәсе килә: ансамбльдә милләте белән татар булмаган артистлар да бар. Урыс милләтеннән булган Наташа Голубьева, Валерий Кузнецов, Валерий Бурдиннар татар сәнгатенә бирелеп хезмәт итәләр, коллективка милли дуслык, бердәмлек хөкем сөрә. «Шәрекъ клубы» зәвык белән, матур итеп тегелгән костюмнары белән дә тамашачының игътибарын җәлеп итә.

Бүгенге репертуарда «Төрки дөнья» күренеше шулай ук ансамбльнең иҗади эзләнеп тапкан уңышы. Бу музыкаль-хореографик күренеш Казанда булып узган Бөтендөнья тюркологлары Конгрессы алдыннан махсус әзерләнгән иде. Ансамбль төрки халыкларның рухи, мәдәни дөньясын музыка, җыр, бию аша якты, матур бер күренеш итеп тасвирлауны максат итеп куйган иде. Сәхнәдә төрки моңнар агыла: татар, төрек, кыргыз, казакъ, кырым татарлары җырлары яңгырый, башкорт, чуаш, үзбәк, әзәрбәйҗан һ. б. төрки халыкларның биюләре башкарыла. Сәхнәдә — чын дуслык, кардәшлек, бәйрәм, тантана. Төрки халыкларның борынгы заманнардан килгән кан берлеген, моң берлеген раслап, бу күренешкә тирән фәлсәфи эчтәлек салынган. Төрле-төрле милли киемнәр кигән артистлар белән тулган сәхнә аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән кебек. Бу күренештә кайсы гына җырны, биюне аерым алып карасаң да, искиткеч осталык, гүзәллек белән очрашасың. Әйтик, «Мәлкән кичләре» дигән җырлы-биюле уен күренеше кемне генә дулкынландырмас икән. Керәшеннәр безнең үз татарларыбыз, аларның җырлары, биюләре гаҗәп үзенчәлекле. Бер-берсенә үрелгән, бер-берсен үстерә барган матур җыр-биюләрдән торган күренеш керәшен халкының борынгыдан килгән традицияләрен бербөтен итеп күз алдына китереп бастыра. Керәшенчә биегәндә, артистларның, халык сүзе белән әйтсәк, үкчәләреннән утлар чәчри!

Соңгы еллардагы программа — «Төрки дөнья» күренешенең ахыргы номеры татар яшьләренең күмәк биюе белән тәмамлана. Заманча хәрәкәтләр белән матур куелган бу бию менә ничә еллар инде сәхнәдән төшми. Биредә парлап биюче Дамирә Вәлиева белән Равил Габдрахмановлар татар биюен яшьлеккә хас дәрт белән чын осталарча башкаралар.

«Төрки дөнья» — программаның дуслык, туганлык байрагын җилфердәткән бәйрәмчә финалы. Ансамбльнең шушы еллардагы программасына кыскача ана-

лиз ясагач, тырыш, фидакяр артистлардан торган, заман белән бергә атлап баручы коллективның милләтебез өчен нинди зур сәнгать эше алып баруына сокланасың. Репертуар, программа турында Кустабаева тагын менә нәрсәләр сөйли:

— Без күбрәк халкыбызның үткәндәге күркәм сәхифәләренә, матур традицияләренә таянабыз. Ул традицияләрне яңартып, бүгенге белән үрелдереп, үз фантазиябез белән баетып, халкыбызга яңадан кайтарырга тырышабыз. Борынгы халык көйләрен, биюләрен өйрәнәбез, эшкәртәбез. Безнең халкыбызның бай иҗат мирасы — фольклорының әле тирән катламнарында ачылып җитмәгән гаҗәп энҗе-мәрҗәннәре бар. Фольклорга таянмасак, без үзебезнең нигезебезне югалтачакбыз. Халык көйләре, халык моңнары безнең иҗат тамырларыбыз ул...

Ансамбль оешкан көннәрдән алып аның репертуарында халкыбызның мәңге үлмәс борынгы көйләре — «Кара урман», «Гөлҗамал», «Зөлхиҗҗә», «Сибелә чәчәк», «Зиләйлүк», «Әллүки», «Сарман», «Рәйхан» кебек җырлар яңгырый. Бу җырлар — халкыбызның җаны, рухы. Җан сызлаганда, рух какшап киткәндә, бу җырлар кеше күңеленә дәва кебек тәэсир итә. Халкыбызның күренекле шагыйре Сибгат Хәким Кавказда дәваланып ятканда, ансамбль концертына бара, ансамбль башкаруында яңгыраган «Сибелә чәчәк» җырының йөрәккә дәва булып шифалы йогынты ясавы турында шигырь яза:

Бу йөрәккә төрле дәва кирәк,
Авыруларын аның тап, назла.
Савыгырмын, безнең ансамбльнең
Концертлары бара Кавказда.

Бу йөрәккә төрле дәва кирәк,
Тынам көндез, тынам төннәрдә.
Савыктыргыч, иң шифалы дәва,
Беләм, беләм, туган телләрдә.

Кычкырасым килә җиргә минем
Һич туймадым синдә яшәп дип...
Ә ансамбль үч иткәндәй, җырлый
Җырлый һаман «Сибелә чәчәк» дип.

«Сибелә чәчәк»... Болай, бу кадәрле
Моңсу түгел идең син элек.
Көз. Кавказда концерт. Ишетәм залдан:
«Сибелдек шул, дуслар, сибелдек...»

Әйе, безнең халкыбыз бөтен җир шарына сибелгән, сибелгән... Бу җыры белән ансамбль сибелгән халкыбызның күңелен, җанын берләшергә чакыра шикелле.

Соңгы елларда әзерләнгән программалардан тагын «Корбан бәйрәме» турында берничә сүз. Халкыбыз динебезгә йөз белән борылган көннәрдә, ансамбльнең бу хезмәте хуплауга лаек. Борынгы көйләребезне, мөнәҗәтләребезнең аһәңнәрен хәтерләткән музыкасы белән композитор Мәсгудә Шәмсетдинова тарафыннан иҗат ителгән бу композиция ислам диненең сафлыгын, кеше күңелен нурландырып торучы илаһи көчкә ия булуын гәүдәләндерә. Патетик стильдә куелган бу күренеш сәнгатьчә матур эшләнгән. Күренешнең нигезенә бөек гуманистик идея салынган: әдәм җанын, бала җанын саклап калу, корбан итеп хайван чалу — бу ислам диненең кешелекле кануннардан торуын күрсәтә. Күп кенә диннәрдә адәм баласын корбан итү кебек кыргый йолаларга капма-каршы ислам дине кешегә мәхәббәт белән карый. Бу күренеш шушы фикерне оста итеп тамашачыларга җиткерә. Быел Корбан бәйрәме көнендә Казанның Спорт сараенда күрсәтелеп, бу композиция тамашачыларыбызга зур бәйрәм бүләге булды. Залда яшьләр күп иде. Алар ислам диненең асылына төшенергә тырышып игътибар белән карадылар. Артистлар тигез матур тавыш белән тәкъбир әйткәндә, өлкән тамашачыларның күзләренә яшьләр килде. Бу концертта сәхнә лазер нурлары белән бизәлгән иде. Зәңгәр күк йөзе, яңа туган Ай, йолдызлар, мәчет манаралары, Сөембикә манарасы лазер нурлары белән күңелле уйнаклап сәхнәне яктыртып торды, концертка ямь өстәде. Лазер нурлары белән сәхнә бизәүне ансамбль татар сәнгатендә әле беренче башлап куллана.

Җыр, бию, оркестрда башкарылган музыка, костюмнар, калфаклар, милли читекләр, бизәнү әйберләре, хәтта чәч толымнары, чулпылар — ансамбль өчен барысы да әһәмиятле, барысы да бер максатка — татар сәнгатенең байлыгын ачарга ярдәм итәргә тиеш. Һәр чыгыш үзенә бер костюм, үзенә бер бизәлеш

сорый. Ансамбль артистларының бер концерт барышында биш-алты тапкыр костюм алыштырган чаклары була. Ләкин алар зарланмыйлар, иренмиләр. Үз образына хас киеме генә булсын. Хәзер, әлбәттә, кыйммәтчелек заманында, бәяләр көн саен артып торган көннәрдә, яңа костюмнар булдыру бик авыр эш. Костюмнар булдыру турында сүз чыккач, хормейстер Венера Гәрәева ачынып мондый сүзләр әйтте:

***— Костюмнар булдыру хәзер безнең өчен иң авыр эш. Хөкүмәтебез җитәкчеләре, Мәдәният министрлыгы бу турыда тиешенчә кайгыртмый. Уфа каласында үткәрелгән бер сәнгать фестиваленә баргач, мин шаккаттым. Уфа артистлары шундый яхшы, затлы бәрхеттән теккән костюмнар кигәннәр. Мондый костюмнарны ничек тектерә алдыгыз дигәч, алар горурланып болай диделәр: «Бу костюмнарны безнең өчен бер төн эчендә теген бирделәр. Хөкүмәтебез җитәкчеләре бу затлы бәрхетне безгә Франциядән кайтартты». Без көнләшеп куйдык. Моңарчы тектерелгән костюмнарыбызны сакларлык шартларыбыз да юк әле. Әлеге матча сынып төшкән бинада су торбалары шартлап, ничә миллион сумнарга тектерелгән костюмнарыбызны су басты.***

Авырлыклар күп, әмма ансамбль коллективы алар каршында каушап калырга җыенмый. Лима Кустабаева костюмнар булдыру өчен зур тырышлык куя. Костюмнар тектерү үзенә бер фантазия таләп итә торган эш. Моның өчен уникаль үрнәкләр сакланган музейларда булырга, халыкларның тарихи җирлегенә хас киемнәрне өйрәнергә, костюмнар өчен материаллар табарга, рәссамнәр, тегүче осталар белән эшләргә — барысы да Кустабаева җаваплылыгында. Һәр программага сценарий төзү, яки сценарий төзүче авторлар белән эшләү, режиссер буларак һәр чыгышны җанлы итеп сәхнәдә күрү — бу эшләрнең барсын да Кустабаева хуҗалык, оештыру эшләре белән бергә алып бара. Кустабаева үзенә дә, коллективка да таләпчән. Башкаларны эшләтә белә ул. Артистларның нәрсәгә сәләтле икәнен ачып, аларга дөрес иҗат юнәлеше бирә. Ансамбль коллективын мин зур бер гаиләгә оштам. Лима Кустабаева һәр артистның язмышы, тормышы белән кызыксынып, һәр артист турында аналарча кайгыртып яши. Бигрәк тә яшьләргә игътибарлы ул. Аңа артистларның һәркайсы төрле йомыш белән мөрәҗәгать итә. Эш көненең теләсә кайсы вакытында ул нинди йомыш белән керсә дә һәркемне кабул итә, тәкәбберлек аңа хас түгел. Мин аның ансамбль концерты барганда, залда халык арасында концерт карап утырганын күзәткәнем бар. Һәр артистның чыгышын ул беренче тапкыр күргәндәй, чын күңеле белән бирелеп карый, вакыт-вакыт йөзендә эчкерсез елмаю, ә кай вакыт күзләрендә яшь күренә... Ә елмаюы аның шундый мәрхәмәтле: балаларының уңышын күреп елмайган ана елмаюы, ана горурлыгы дияр идем мин аны.

Лима Кустабаевадан башка бу ансамбльне күз алдына китерергә мөмкин түгел. Мин үз гомеремдә күп кенә артист бригадалары белән гастрольләрдә йөрдем, күп концертлар алып бардым. Әмма ансамбльдәге кебек тәртипне, оешканлыкны күргәнем юк иде. Беркем бер концертка соңга калмый, сәхнәгә кичегеп чыкмый, гастрольгә чыкканда, поездга яки самолетка соңга калып килми. Егетләре шундый тәртипле. Поездларда барганда, хәзер бит кайчакта күмер юк дигән сылтау белән вагоннарга якмыйлар, чәй кайнатмыйлар. Андый чакларда ансамбль егетләре әллә каян күмер, утын табалар, вагонга үзләре ягалар, чәй кайнаталар, бөтен коллектив бер гаилә кебек юлда тату, дус баралар. Кустабаеваның тәрбиясе бу. Гомумән, мин шуны күреп йөрим, бу ансамбльне өч хатын: Кустабаева, Гәрәева, Гарипова тотып тора.

1991 елда Татар җыр-бию ансамбле филармониядән аерылып чыкты һәм мөстәкыйль эшли башлады. Хәзерге заманда мондый мөстәкыйльлек алулар гаҗәп түгел. Чөнки иҗат эшчәнлегендә иркенлек кирәк. Ансамбль үз репертуарын үзе булдырып, үз иҗат эшенә үзе җавап биреп, иркле эшләргә карар кылды. Берничә оешманың бер янчыктан акча алып, акча бүлешеп яшәүләре дә күп кыенлыклар тудыра бит. Бу аерылу ансамбльнең кыю адымы булды. Хәзер ул аерылып башка чыккан гаилә шикелле, үз көнен үзе күрә һәм үкенми. Эштә нинди авырлыклар чыкса да, аларны җиңәргә үзендә көч табачагына ышана.

Әлбәттә, җитәкче буларак, Кустабаевага эшләр артты, катлауланды. Административ эшләрдә, финанс һәм хуҗалык, оештыру эшләрендә аңа ансамбльнең үз артистлары — коллективның чын патриотлары Мөҗип Садыйков, Рәисә Җаббарова, Извиль Салихов h. б. лар булышалар.

Җыр-бию ансамбленең оешуына 55 ел вакыт узган. Аның иҗат юлында матур сәхифәләр калдырган шәхесләре, үзенең тарихы, күркәм эшләре бар. Бүгенге коллектив ансамбльне беренче башлап оештырган Зөләйха Әхмәтованы, берсеннән-берсе матур биюләр куйган балетмейстерлар Фәйзи Гаскәровны, Гай

Таһировны, ансамбль репертуарын булдыруда зур өлеш керткән композиторлар Александр Ключаревны, Җәүдәт Фәйзине, Заһит Хәбибуллинны хөрмәт белән искә ала. Алар ансамбльнең чын дуслары иде. Кызганычка каршы, бүгенге композиторлар исеменә ансамбль үпкә сүзе белдерә. Хәзерге буын композиторлары ансамбль өчен махсус әсәрләр язмыйлар. Бигрәк тә яшь композиторлар ансамбльгә иҗади якынаймыйлар. Бүгенге композитордан Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтов, Мәсгудә Шәмсетдинова, Әзһәр Абдуллиннан кала башкаларның әсәрләре ансамбль репертуарында юк диярлек. Шуны да әйтеп китик, кызганычка каршы, ансамбль соңгы елларда үзенең репертуарын булдыру мәсьәләсендә Республикабызның иҗат оешмалары тарафыннан сизелерлек ярдәм ала алмый. Иҗат оешмалары ансамбльгә йөз белән борылсыннар иде.

Ансамбльнең үткәннәре турында сөйләгәндә, аның иҗат юлында күркәм эз калдырган ветеран артистларны хөрмәт белән искә алырга кирәк. Халыкның зур мәхәббәтен яулаган җырчылар Разыя Тимерханова, Галия Гафиятуллина, Зәйтүнә Әхтәмова, Габдулла Рәхимкулов, Сөләйман Юсупов, Габделхак Шаһиев, Рәисә Тимофеева һәм биючеләр Фәйтүнә Абдуллина, Әнвәр Латыйпов, Мансур Гатиятуллин, Роза Мостафина, Әнсәрия Кретова, Әлфия Хөснетдинова, Римма Булякова, Фердинанд Гыймадеевлар белән бүгенге коллектив хаклы рәвештә горурлана. Шулай ук сәхнәдә беренче адымнарын шушы ансамбльдә атлап киткән халкыбызның яраткан җырчысы, эстрада йолдызы Әлфия Афзаловага да коллектив зур хөрмәт белән карый. Ансамбль һәр елны үзенең ветеран артистлары белән очрашып тора. Әле быел март аенда ансамбль үзенең ветераннары белән чәй янында сөйләшеп, җырлашып, биешеп, дусларча бәйрәм итеп алды. Ветераннар, шөкер, барсы да сау-сәламәтләр, үзләрен иҗат кешеләренә хас булганча, шат-дәртле хис итәләр, үзләрен формада тоталар, ансамбльнең эшләре белән кызыксыналар, үзләренең киңәшләрен бирәләр, тәҗрибәләрен уртаклашалар. Март аендагы очрашудан алган тәэсирләре белән уртаклашып, танылган җырчы Зәйтүнә Әхтәмова менә нәрсәләр сөйләде:

— Ансамбль безне онытмый. Рәхмәт аларга, һәр елны безне зурлап чакырып, очрашып торалар. Безнең хәлләребезне беләләр, акчалата бүләклиләр. Без ансамбльнең иҗат уңышлары өчен куанабыз. Ансамбль соңгы ун-унбиш ел эчендә гаҗәп дәрәҗәдә үсте. Репертуар кызыклы, кыйммәтчелек булуга да карамастан, костюмнар искиткеч матур; безнең артистлар кигән костюмнар белән чагыштырып карыйбыз да, без бик ярлы киенгәнбез икән дип шаккатабыз. «Шәрекъ клубы» күренешендәге матур костюмнарны күреп, сокланып, мин: «Их, менә хәзер ансамбльдә эшләсәң иде, шул матур костюмнарны киеп сәхнәләргә чыксаң иде»,— дип, кызыгам. Ансамбльнең җитәкчесе Лима Кустабаеваның тырышлыгы аркасында безнең ансамбль дөнья күләмендә танылып килә. Ансамбльдә эшләп киткән, бүген инде танылган шагыйрә Лена Шагыйрьҗан да үзенең фикерләре белән уртаклашты:

— Мин ансамбльдә озак эшләмәдем, нибары биш ел. Әмма ләкин бу биш ел минем гомеремдә иң матур истәлекләр калдырды. Ансамбльгә эшкә килгәндә, мин һәр авыл баласы шикелле, музыкаль белем ала алмаган бер кыз бала идем. Ансамбльдә башлангыч музыкаль белем алдым. Ансамбль миңа тормышта үз урынымны табарга ярдәм итте, миңа тормыш мәктәбе булды. Мин анда сәнгатьнең иң нәфис иҗат эше икәнлегенә төшендем, җырларга өйрәндем. Сәнгать, иҗат эше белән яшәргә, шигырь язарга тиешлегемне тойдым, һәм поэзиягә килдем.

Лена Шагыйрьҗанның ансамбльгә килү еллары Лима Кустабаеваның ансамбльне җитәкли башлаган елларына туры килә. Кустабаеваның хор өчен эшкәрткән беренче көе — халкыбызның онытылып барган борынгы көе «Олы юлның тузаны» була. Мәхмүт Нигъмәтҗанов җыйган халык җырлары китабыннан алып өйрәнә башлагач, Кустабаева җырның сүзләре бер генә куплет булуын күреп, борчуга төшә. Шул чакта ансамбльнең яшь җырчысы Лена Шагыйрьҗан бу көйгә тагын өстәп сүзләр яза һәм бер эчтәлеккә нигезләнгән, хәзер менә без яратып җырлый торган гаҗәп матур сүзләрдән торган «Олы юлның тузаны» дигән җыр туа:

Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем.
Кайда икән яшьлегем дип,
Шул юллардан эзләдем...

Бу җырны без сүзләре белән бергә халык җыры дип йөртәбез. Шагыйрәнең шигыре халыклашып киткән, бу — Ленаның зур бәхете. Ләкин Лена Шагыйрьҗан тыйнак, бу җырның сүзләре минеке дип йөрми. Ансамбльдә шагыйрә Долоресс

Гарипова, вакытлы матбугатта актив катнашучы хәбәрче һәм мәзәкче Рафаил Җаббаровлар кебек әдәби иҗат эше белән шөгыльләнүче җырчылар бүген дә бар.

Ансамбльдә соңгы елларда күркәм гадәтләр туган: гаилә, нәсел дәвамлылыгы традициягә кереп бара. Күп кенә артистлар үсеп буй җиткән балаларын ансамбльгә эшкә алып киләләр, үзләренең иҗат эстафеталарын балаларына тапшырырга телиләр. Миңлегөл Зәкиеваның кызы Ләйсән, Мөҗип Садыйковның улы Айрат, Нәфисә Василованың улы Илнур, Роза һәм Рәшит Мостафиннарның кызы Ләйсән — ансамбльгә яңа сулыш алып килүче талантлы яшь көчләр.

Элекке елларда ансамбль күбрәк ялгызак артистлардан торса, бүген ансамбльдә матур гаилә корган Габдрахмановлар, Фәйзуллиннар, Бурдиннар, Сибагатовлар, Кадерлеевалар, Мостафиннар кебек парлап эшләүчеләр бар. Бу гаилә тормышында тәртип булырга ярдәм итә. Гастрольләргә киткәндә, артистларның гаилә булып бергә-бергә йөрүләре хәерле.

Ансамбль үзенең киләчәге, алдагы көнендәге кадрлары турында кайгыртып яши. Киләчәкләрен ансамбль белән бәйләү өчен бер төркем яшүсмерләр ансамбль каршындагы «Юлдаш» студиясендә җырларга, биергә өйрәнәләр. Ансамбльнең танылган җырчысы Шамил Әхмәтҗановның кызы Чулпан Әхмәтҗанова инде ансамбль концертларында чыгышлар ясап, нәни җырчы буларак танылып килә. Быел булып узган Республика сәнгать фестивалендә Чулпан беренче урынны яулап алып, лауреат булды. Студиянең бер чыгарылышыннан Н. Мөхәммәтрәхимов, Л. Зарипова, М. Сәгъдиевалар ансамбльдә эшли башладылар да инде.

Бүген Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә йөзгә якын кеше эшли. Шуларның алтмыштан артыгы иҗат составын тәшкил итә. Зур коллектив. Барлык составы белән концерт бирә башласа, кайбер сәхнәләргә сыймый да. Әмма ләкин ансамбль кечкенә сәхнәле Мәдәният сарайларында да чыгышлар ясый, сәхнә кечкенә дип, концерт бирүдән баш тартмый. Әле быел яз гына Баулы шәһәрендә ансамбль килә дигәч, «сәхнәбез кечкенә инде, бездә алар чыгыш ясарга теләмәс яки ярты составы белән генә кечкенә программа күрсәтер» дип, Баулылар борчуга төшә. Юкка гына борчылалар, ансамбль зур программа белән, зур концерт биреп, Баулыларны таң калдыра. Рәхәтләнеп эшләргә бөтен шартлары булган бинасы, әзер программаларын тамашачыга күрсәтергә концерт залы булса, бу коллектив сәхнәдә могҗизалар тудырыр иде дип уйлап куясың.

Ансамбльнең уңышларын күрмәмешкә салышучылар, аның кечкенә генә җитешсезлеген дә күпертеп күрергә теләүчеләр, хаксыз рәвештә каты-каты тәнкыйть сүзләре әйтергә яратучылар да бар. Лима Кустабаева исеменә бәйләп, мондый сүзләр әйтелгәндә, ул сүзләрнең хаксыз икәнлеген ансамбльне якыннан белүчеләр яхшы аңлыйлар. 1986 елда ансамбль Мәскәүдә уздырылачак профессиональ ансамбльләрнең Бөтенсоюз фестиваль-конкурсында катнашырга җыена: программаны кабат-кабат эшли, көне-төне диярлек репетицияләр ясый. Иртәгә Мәскәүгә китәргә дигән көнне Мәдәният министрлыгы вәкилләре, филармония җитәкчеләре программаны карый да: «Ни өчен репертуарда Ленин турында, Партия турында җырларыгыз юк» дип, тагын төрле гаепләр табып, программаны каты тәнкыйтьләп, ансамбльнең эшен юкка чыгарып ташлый. Әмма ансамбль җитәкчеләре үзара кинәшәләр дә, үз фикерләрендә нык торып, тәвәккәлләп коллективны Мәскәүгә конкурска алып китәләр һәм анда бик уңышлы чыгыш ясап, Казанга беренче урынны алып, җиңү яулап кайталар. Бөтен дөньяга танылган сәнгать йолдызы, мәшһүр Моисеев җитәкләгән жюри коллективка иң югары бәяне бирә.

Татар җыр һәм бию ансамбле турында, аның эшендәге үзенчәлекләр хакында, аның уңышларының, камиллеккә ирешүләренең серләрен ачып, коллективның иҗат юлын, тарихын өйрәнеп музыка һәм сәнгать белгечләре зур-зур хезмәтләр язарлар әле. Чөнки Ансамбль — үзе бер дөнья, үзе бер тарих ул. Мин бу мәкаләмдә барысын да колачларга җыенмадым, барысын да колачлап бетерү мөмкин дә түгел. Мин тик үземнең күңелемә, җаныма сыйган кадәресеннән чыгып, үз белгәннәремне бәян итәргә тырыштым. Ансамбльнең матур эшләре минем күңелемдә горурлык хисе уята.

Республикабызның Г. Тукай бүләге лауреаты, Халыклар Дуслыгы Орденына ия булган ансамбль халкыбызның үз баласы, үз газизе, йөрәк пәрәсе. Ул — безнең сәнгатебезнең горурлыгы, якты йолдызы. Ул тагын да яктырак балкысын! Сәнгатебез күген тагын да нурлырак итсен! Җир шарындагы егермеләп илләрдә гастрольләрдә йөреп дан казанган коллективның алдагы сәфәрләре уң булсын!.. Японнар кебек зәвыклы японнарны хәйран калдырган ансамблебез әле бик күп халыкларны үзенең гүзәл сәнгате белән сокландырыр!

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА**

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ТУРЫНДА ФИЛЬМ

Татарстан Кинематографистларының Дәүләт Комитеты каршындагы «Мизгел» студиясе «Казан утлары»на хатлар» дип исемләнгән документаль фильм әзерләде. Кыска метражлы, ике кисәктән торган бу фильмда моңарчы татар халкының рухи энциклопедиясе булып килгән бу басманың 70 елдан артык узган юлы, эш башында торган зур шәхесләр, әдәбиятта күркәм урын тоткан әдипләр, аерым әсәрләр турында кинематографик сурәтләү чаралары белән мавыктыргыч итеп бәян ителә. Фильмда киноархивларда сакланып калган төрле елларның мәдәни-әдәби хроникасын чагылдырган йөзләрчә уникаль кадрлар бар. Алар, тарихи елъязма буларак, әдәбиятыбыз үткән данлы юлны шактый күз алдына китереп бастыра.

Фильмның сценарий авторы — З. Хөснияр, режиссеры һәм операторы — А. Привин.

## КӨНЬЯК КОРЕЯ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ТАТАРСТАНДА

15 октябрьдә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Көньяк Кореянең Ким У Джунг әфәнде рәислегендәге ДЭУ корпорациясе делегациясен кабул итте.

Билгеле булганча, Татарстан бу корпорация белән Алабуга автомобиль заводы базасында елына 300 мең җиңел автомобиль эшләп чыгарачак уртак предприятие төзү турында сөйләшүләр алып бара. Двигателенең егәрлеге 89 ат көчле, 5 урынлы заманча бу машиналар дөнья базары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Корпорация рәисе Ким У Джунг зур әһәмияткә ия булган генераль килешү проектын гамәлгә ашыруда нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Президент Минтимер Шәймиевка рәхмәт белдерде. Якын арада генераль килешүгә, уртак предприятие уставына, башка килешүләргә һәр ике як та кулларын куячаклар.

## БЕРӘҮ ДӘ, БЕРНИ ДӘ ОНЫТЫЛМАДЫ

1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында җиңүнең зур тарихи әһәмияткә ия булуын, Татарстан халыкларының фашизмны тар-мар итүгә өлеш кертүен исәпкә алып, Җөмһүриятебез Илбашы җиңүнең 50 еллыгын бәйрәм итү турында 1993 елның 11 октябрендә махсус Указ игълан итте. Аннан күренгәнчә, 1995 елның 9 маенда Татарстан Республикасы башкаласы Казанда Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм Кораллы Көчләр ветераннарының парады уздырылачак. Бер үк вакытта сугыш ветераннарының социаль-көнкүреш шартларын яхшырту, аларга медицина һәм матди ярдәм күрсәтүне көчәйтү, Татарстан Республикасы территориясендәге хәрби кешеләр күмелгән каберләрне, шулай ук 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга торгызылган мемориалларны һәм һәйкәлләрне тәртипкә китерү, Республиканың Хәтер Китабын төзүне тәмамлау буенча тиешле чаралар күреләчәк.

## БАТЫРЛАР КАЙТА!..

Фашизм тоткынлыгында Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең җәзалап үтерелүенә 50 ел тулган көннәрдә, ягъни 1994 елның августында, Казан Кремле каршындагы мәйданда герой-шагыйрьгә куелган мәһабәт һәйкәл янына Гайнан Кормаш, Фуат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев һәм Сәлим Бохаровларның да барельефлары өстәләчәк. Аларны М. Җәлил һәйкәлен иҗат иткән Мәскәү скульпторы В. Цигаль ясаган.

## ХӘТЕР КӨНЕ

Башкалабыз Казанның 1552 елда Дүртенче Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алынуына быелның 15 октябрендә 441 ел тулды. Шул уңайдан, җөмһүриятебез шәһәрләрендә һәм районнарында «Хәтер көне» үткәрелде.

Казанның Азатлык мәйданында үткәрелгән матәм митингысында Ульяновск, Пермь, Самара өлкәләреннән, Башкортстан Республикасыннан да вәкилләр катнашты. Аннары барлык халык, тәкъбир әйтеп, Казан Кремлендәге Сөембикә манарасы янына килде. Биредә Казанны саклауда шәһит киткән каһарман бабаларыбыз, милләттәшләребез, нәселдәшләребез рухына дога кылынды, алар истәлегенә һәйкәл төзү өчен акча җыелды.

## «БАГИРА» ЭКИПАЖЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

13 октябрьдә Татарстан Җөмһүриятенең Премьер-министры М. Сабиров «Рубин» спорт җәмгыяте клубыннан «Багира» яхтасы экипажын кабул итте. Билгеле булганча, әлеге экипаж быелгы җәйдә, яхта мачтасында Татарстан дәүләт флагын җилфердәтеп, Европа әйләнә сәяхәт иткән иде.

Премьер-министр экипаж җитәкчесе Алмаз Алеевка һәм тагын дүрт спортчыга йөзү вакытында зур тәвәккәллек һәм максатчан-

лык күрсәткәннәре, еравтагы чит илләрдә халык дипломатиясе хәрәкәте кысаларында башкарган эшләре өчен рәхмәт белдерде, истәлекле бүләкләр тапшырды.

## ШӘФКАТЬЛЕЛЕК ҮРНӘГЕ

Башкалабыз Казанда Мәскәүнең А. Чехов исемендәге театры артистлары бер атна дәвамында шәфкатьлелек спектакльләре күрсәттеләр. Людмила Гурченко, Любовь Полищук, Михаил Державин, Александр Ширвиндт, Константин Райкин кебек танылган артистларның уйнаучыларын тамашачылар алкышларга күмделәр.

Акция 10 октябрьдә Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, джаз музыкасы лауреаты, композитор һәм пианист Анатолий Кролл җитәкчелегендәге «МКС БЭНД» джаз оркестры концерты белән тәгәлләнде.

Йомгаклау тамашасында, шәфкатьлелек үрнәге күрсәткәннәре өчен рәхмәт белдереп, Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады.

Акция барышында җыелган акчага гариләр өчен махсус автобус сатып алыначак. Әлеге фикерне исә Мәскәү шәһәрендәге Халыкара коммерция союзы (генераль директоры — якташыбыз Рәшит Ахунов) күтәреп чыккан иде. Автобус өчен кирәкле сумманың зур өлешен шул оешма бирәчәк.

## ИСЛАМ ИНСТИТУТЫ АЧЫЛДЫ

Казанда «Мөхәммәдия» дип исемләнгән ислам институты ачылды. Ул татар дөньясында беренче югары дини уку йорты булачак. Аны оештыручылар — хаҗи Венерулла Ягъкуб җитәкчелегендәге «Иман» мәркәзе әһелләре. Мөгаллимнәр чакыруда һәм гарәп теле, дин дәресләкләре юнәтүдә «САAP» халыкара хәйрия-сәүдә җәмгыяте ярдәм иткән.

Ислам институтына 9-11 классны тәмамлаган 50 егет кабул ителде. Алар, биредә 5 ел дәвамында белем-тәрбия алгач, дин галимнәре, имамнар булып җитешәчәкләр.

## УРМАНЧЫЛАРЫБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЗУР ҖЫЕНЫ

6—7 октябрь көннәрендә Кама урман хуҗалыгында (Мамадыш районы) Татарстан урманчыларының 1 съезды үткәрелде. Республика тарихында беренче тапкыр уздырыла торган бу зур форумда Татарстан урман хуҗалыгы министры Ә. Гаянов эчтәлекле зур доклад белән чыкты.

Съезд эшендә республикабызның урман хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, лесничийлар, Татарстан Югары Советының экология һәм табигать ресурсларын нәтиҗәле файдалану мәсьәләләре буенча комиссия рәисе А. Колесник, Мәскәүдән Федераль хезмәтләр буенча рәис урынбасары А. Писаренко һәм башкалар катнашты.

Съездда урманнарыбызның бүгенге торышы, аларның киләчәге турында эшлеклеҗитди сөйләшү булды, дистәдән артык урман хуҗалыгы белгече чыгыш ясады.

Съезд көннәрендә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире — шушы төбәктән Югары Советка депутат итеп сайланган Р. Фәйзуллин, бүлек мөхәррире Ш. Мостафин, «Ватаным Татарстан» газетасы фотохәбәрчесе М. Шакирҗанов делегатлар белән очрашып, вакытлы матбугат битләрендә урманчыларның эшчәнлеген, тормышын һәрьяклап яктырту мәсьәләләре турында эчкерсез сөйләшүләр алып бардылар. Делегатларның зур күпчелеге 1994 елның 1 яртысы өчен «Казан утлары» журналына, «Ватаным Татарстан» газетасына язылды.

## АВЫЛ МӘКТӘБЕ — СӘНГАТЬ ГИМНАЗИЯСЕ

Җөмһүриятебезнең Мамадыш районындагы Кече Кирмән урта мәктәбе сәнгать гимназиясе итеп үзгәртеп корыла. Аның тынгысыз директоры — талантлы шагыйрь, Шәйхи Маннур исемендәге премия лауреаты Рафаил Газизов бу өлкәдә аеруча нәтиҗәле эшли. Ике катлы мәктәп-гимназиянең һәр бүлмәсе, һәр залы милли мәдәниятебезсәнгатебезне гәүдәләндергән рәсем-портретлар белән бизәлгән, һәртөрле язмалар-белешмәләр өч үрнәктә — гарәпчә, латинча, татарча (кириллицада) бирелгән. Укучылар дәресләргә милли киемнәрдә, түбәтәй-калфак киеп йөриләр.

Хәзерге вакытта мәктәптә Татарстан җөмһүриятенең атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Эрот Зариповның картиналар галереясе эшли. Күренекле каллиграф-рәссам, галим Нәҗип Исмәгыйль (Нәкъкаш) белән берлектә, Э. Зарипов мәктәп-гимназияне бизәүдә дә зур өлеш кертте.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле башкаруында «Сабантуй» исемле музыкаль-хореографик күренеш.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Рөстәм Кутуй.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Милләтебезнең мәшһүр язучысы Гаяз Исхакыйның чит илдә яшәгәндә иҗат ителгән «Идел-Урал» әсәре дистә еллар буена туган халкыбыздан яшереп киленде. Чөнки анда татар милләте турында зур хакыйкать сүзе әйтелгән иде. Әнә шул хакыйкать СССР дигән империяне кулда тотучыларга һәм аларның урыннардагы бик күп санлы куштаннарына ошамады. Менә, ниһаять, шушы әсәр туган телебездә беренче мәртәбә басылды.


Аны дөньяга чыгаруда Чаллы каласының танылган эшмәкәрләре, бертуган Ринат, Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар зур матди ярдәм күрсәткәннәр.

Китапның тиражы 100.000 данә.

Тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдиновның исеме татар укучыларына шулай ук бик яхшы таныш. Аның ерак дәверләр катламын тирәннән айкаучы фикергә һәм бүгенге укучылар күңелен дулкынландырырдай илһамлы сүзгә ия әсәрләре газета-журнал битләрендә еш басыла.

Шул ук бертуган Кашаповлар ярдәмендә Чаллыда бу танылган галимнең «Алтын Урда һәм татарлар» дигән китабы басылып чыкты. Китап рәсемнәр белән дә бизәлгән.

Аның да тиражы 100.000 данә.





Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 30 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог